
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7. 1993





**Татарстан халык язучысы**

**ФАТИХ ХӨСНИ**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

**(849)**

**1993**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Р. ӘХМӘТҖАН.** Туфан уты. *Шигырьләр* . . . . 3
**Ф. ЯХИН.** Ахырзаман пәйгамбәре. *Кыйсса* . . . 9
**М. ШАБАЕВ.** Янсын җаның, янсын... *Шигырьләр* 76
**Ф. ЯРУЛЛИН.** Кайту. *Повесть* . . . . . . . . 80
**Р. РАХМАН.** Җилле төн. *Шигырьләр* . . . . . 119
**Л. ИХСАНОВА.** Беренче гонорар кыйссасы . . . 123
**Н. ӘМИНЕВА.** Гел бөекләр, гел матурлар... *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 135
**Ф. ФӘИЗ.** Ике тәргәк — ике язмыш. *Хикәя* . . . 137

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. СИБАТ.** Борчулар һәм өмет яңадан *(Дискуссия дәвам итә: «Безнең тормыш. Безнең әдәбият»)* . 142

ӘДӘБИ МИРАС

**М. МӘҺДИЕВ.** Онытылмас шәхесләр . . . . . 148
**Х. МИҢНЕГОЛ.** Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты . . . . . . . . . . . . . 154

РУХИ МИРАС

**Я. АБДУЛЛИН.** Ислам безнең тарихыбызда һәм әдәбиятыбызда . . . . . . . . . . . . 164
**А. ФРАНК.** Үткәндә салынган күпер (XVIII — XIX йөзләрдә татар муллалары казакъ-кыргызлар арасында) . . . . . . . . . . . . . . 171

СӘНГАТЬ

**Г. АХУНОВ.** Исемнәре Дания . . . . . . . . 175
**К. МИҢЛЕБАЕВ.** Җаның җиде төсе . . . . . 181

Латин алифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . . 191

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повесть-притча Ф. ЯХИНА «Последний пророк конца света»; повесть Ф. ЯРУЛЛИНА «Возвращение»; рассказ Ф. ФАИЗА; стихи Роберта АХМЕТЗЯНОВА, М. ШАБАЕВА, Р. РАХМАН, Н. АМИНОВОЙ.
«Литературная критика»: статья Р. СИБАТА (Дискуссия «Наша жизнь. Наша литература»).
«Литературное наследие»: статьи М. МАГДЕЕВА «Незабываемые личности», Х. МИННЕГУЛОВА «Татарская литература и печать зарубежом».
«Духовное наследие»: статьи Я. АБДУЛЛИНА «Ислам в нашей жизни и литературе», А. ФРАНКА «Татарские муллы среди казах и киргиз в XVIII — XIX вв.».
«Искусство»: статьи Г. АХУНОВА «Дания», К. МИНЛЕБАЕВА «Семь светов души».
Навыки чтения на основе латинской графики.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина И. Зарипова «Сююмбикэ»; известная писательница и общественный деятель Ф. Байрамова.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 28.05.93 ел. Басарга кул куелды 1.07.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 25 351. Заказ Я-304. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.

## Роберт Әхмәтҗан



# Туфан уты

«... Әле берничә ел Аккош күлендә иҗат итәсе бар. Туфанның утсыз тәрәзәсенә карап...»

Сибгат Хәким.

Төн эченә кереп китте янып,
Башкайлары якты сүсән уты...
Ак таңнарга килеп чыга иде
Ут кабызган килеш Туфан йорты!..

Караларга каләм мангандамы,
Кай арада гына сүнгән уты?..

Кай арада җәй йөгереп үткән,
Кунган күзнең күмеш кырпаклары,
Күл комына кергән соңгы сазан?
Үбә ярны зирек яфраклары...

Кайчан гына, абагалар ерып,
Тургай гөлен эзләп йөргән чаклар?
Тәлгәшләргә тезгән ноталардай,
Сагыну көен җырлый ул яфраклар!

Давылгамы шаулый, кояшкамы,
Әллә безнең башка бу усаклар?!
Кышларгадыр,— килә яңа фасыл —
Килә җилдән, килә кар исләре!

---

Роберт ӘХМӘТҖАН (1935) — *шагыйрь, күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Туфан утын эзләп килгән сыман,
Коела кышның ап-ак варислары!..

Төнге сәгать. Борылып туктагандай,
Аның йорты калгый тып-тын гына,
Кораб сыман, кабызып бар утларын,
Шигъриятнең зәңгәр култыгында...

## Дәрвиш

*(Соңгы чатыр)*

Актардым да күңел дәфтәремне,
Өйдем бергә дәрвиш елларымны...
Чакырымнардан чакырып алдым, чакырып
Чакырымнары чикле юлларымны...

Барган саен килде тәҗрибә дә,
Вакытларны сорап ай-кояштан,
Кыйблам иде Казык йолдыз ягы,
Акты судай,
Исте җилдәй гомерем бертоташтан!

Далаларда, япан сахраларда
Кылган-акчәч сипте җыруларын...
Күрдем: кунган очар кошларның гел
Җилгә каршы карап торуларын.

Акты юлым җилгә, комга каршы,
Күк чатыры җирне тоташ япкан.
Алышынып торды ике шәмем:
Аем чыккан чакта Кояш баткан!

Изгелекләр кылмасам да җирдә,
Булмаса да иткән савапларым,
Юк канымда аккан хәрам азык,
Ятмый җанда адәм газаплары!..

Аңлар микән юлым адәм, гавам,—
Юрауларның инде юк кирәге...
Чүктем төбеңә. Соңгы тукталышым,
Чатырым булчы,
Ефәк тут тирәге!

## Бүре аулау

Усаклыкта, кардоннарда очты бәсләр,—
Оран салды ау быргысы дөньяга.
Узган төндә Ак бәрәнне бүре буган,—
Диде Авыл,— яу чыгабыз без аңа!
Кара инде,— дүрт аяклы мародёрны,—

Түбә тишеп төшкәннәр бит малларга.
Ит бәһасе кыен чакта — Ак бәрәнне!..—
Кирәк иде, явыз, моны аңларга!
Җыелдылар илнең изге бурзайлары,
Чыкты ирләр, мылтык киеп иңнәргә.
Мөмкин моны Наполеонга яу чыгуга,
Бөек Ватан ызгышына тиңләргә!
Кузгалдылар илнең асыл егетләре,—
Кемне кайдан, кемнәр җыеп бетергән!..
Әрәмәдә, тугай, Мирәт өсләрендә,
Бүреләрнең котын алып, Эт өрә!
Яланнарга сибелеп китте эт көтүе,
Күктә оча — дүрт канатка! — вертолет!
«Һәр канатлы — фәрештә» дип үз-үзләрен,
Очкан саен үзләреннән үртәлеп!
Яуга чыкты сәнәкләр вә табагачлар,
Чормадагы чабагачлар кузгалды:
«Бүре нәселен корыту кирәк!
Бетсен Бүре!»
Ярсулардан томаланды күз алды.
Капкаларын бәреп чыкты сугымчылар,
Бу бәйгегә өстәми дә әлләни,—
Кырый йорттан, саташыпмы, аң-таң булып,
Уклау тотып килеп чыккан бер әби!..
Каян килгән шул кадәрле хөсет кешегә,
Шулкадәр үч бу адәми җаннарга?—
Авылның бар мал-мөлкәтен кырганда да,
Төшмәс иде мондый ләгънәт җанварга!
Кырылдылар, сорыкайлар, әрдәнәләп —
Олау-олау бүре мәете ташылды.
Бетте Бүре. Тирә-юньдә тынды аваз,
Этләрнең дә ачулары басылды.
Узды олуг чистарту вә агония,—
Кешеләр вә этләр халкы — канәгатьләр!
Кызыл китап битләреннән улый Бүре,
Укый Бүре заманына ләгънәтләр...
Тынды дөнья. Җиңү, хаклык тантанасы,—
Уңлап бүре чыгарылды бер өйдән.
Бар торганы бер Ак Бәрән иде юкса,
Үч алулар, нәфес булды — эредән...

Бүре дә юк! Инде гавам аптырашта —
Кешеләрне аера алмый Бүредән.

## Бәйсезлек

Сорады бер агай: «Улым,
Ни соң ул «бәйсезлек?»
Бәй! Ошбу сорауны ишетү —
Үзе мәгънәсезлек!..

Хәер, агай, бу сөальгә
Бардыр шул хаккыгыз:
Чөнки, аның исемен дә күптән
Онытkан халкыбыз!

Ярый, күрсәтсен ди бирәү
Шундый иләмсезлек,—
Басмаса ярый татарны
Тоташ гамьсезлек!

* * *

Карт паркта каен шауладымы,
Син уфтандың бугай, туган як?
Шигъри бакчам минем,
Тәрәзәләр
Дүрт фасылга зарыгып торган як!
Әллә җилме, әллә синме юкса,
Таң алдыннан сузды моңлы көй?
Нихәл икән анда язын-көзен
Безне көтеп торган моңлы өй?

Ул әйтәдер әле: «Бик сагынсаң,
Бата-чума кайтып киләсең»..
Тик капканы әнкәй ачмас инде,
Зеңгелдәтеп капка келәсен,

Куанычтан Мохтар чыкмас өреп:
Пәрдәләрен ачып, өлгедән
Елмаймас шул ана...
Каршы алыр
Ишек алды тулы... җил генә!

Җил өереп алыр, өерер дә
Илтеп салыр хәтер-диңгезгә.
Тирән уфлап,
Йөрәгемә авар
Әнкәй рухы туган нигездә...
Сагынгандыр тормыш авазларын,
Самоварның җырын безнең өй.
Өй түрендә шаулый ятим тупыл:
«И мөкатдәс...» —
Үзәк өзгеч көй!

## Яшел болыным...

*(Сиңа язган хаттан)*

Күбәләктәй, җилфер-җилфер килгән чакларында, гөлләр бәйрәм ясый иде туган якларымда! Шатлыгыннан күкри-күкри килә иде болыт— талир тамчылары янды алкаларың булып! Инде, бәгърем, күрсәң иде — бездә шундый һава — зыкылы көн, елтыр-елтыр күктән ука ява!.. Яшел болынның гөлләрен, яшьлекнең гүзәл көннәрен сагынырга кала! Сагынырга гына... Кала...

Хәреф төшкән саен кәгазь көйри —
Сагынуларым шундый дәрәҗәдә!
Кошлар минем хәлне белеп килә,
Куна минем моңсу тәрәзәгә.

Кошлар киткәч, инә шәфәкъ нуры,
Бөреләнгән гөлләр, сизеп язны.
Кичке җилдән ишетәм ераклашып
Якынлашкан көен шигъри сазның!..

Язгы чатта гүя мәхәббәтең
Елап-көлеп сине көтеп торган.
Иңнәренә сарылып мәдхия яз,
Сөю утың саумы, шагыйрь туган?

Кәүсәләрдә ургып сут акканда,
Кайры исе чыккан бу кичләрдә,
Ят язларда түгел шигъри көймәң,—
Йөрәгеңне илтмә үкенечләргә!

Ян яналсаң илһам утларында,
Ялкыныңнан якты булсын һәр як...
Бөек поэмадыр: Яз куенында
Тавыш-тынсыз языла Яшел Байрак!

## Итил-су монологы

Мин ерактан киләм,
агып ятам,
Ватан,
бер үзәнең миннән күпсенмә!
Бер ходам һәм синең хакка агам,—
акмыйм җирдә вакыт үтсенгә,
күпсенмә!
Бөек еллар аша, бормаланып,
агып керәм
олуг Хәтер булып мин сезгә...
Каршыгызга тугайланып киләм,
Тарих юлын
гел тәкърарлап агам мин сезгә!
Илдәшләр дә килде, килмешәкләр дә,
ишкәкләр дә, саллы көпчәкләр дә
кыйнадылар суым — шап та шоп!
Яу-баскыннар төшә исләремә...
Көзге җилдә туңып, өсләремә
Күк чатырын
тартам
саташып!
Челтер-челтер йолдызларын коеп,
иңнәремдә күк ефәген тоеп,
убылып агам тирән уйларга.
Буйдан-буйга
Илне иңләп — юлда,

ә бер очым —
әллә... әү кайларда!
Сөңгеләр вә уклар,
чуен туплар
тиште, кисте бәгырь-суымны!
ә мин менә
агып яшим әле,
үзгәртмәдем —
салган юлымны!
Ак-карага Илне мин бүлмәдем
(беркемне дә кимсетмәдем).
Кем ул әйтте:
«Тот та — бүлгәлә!..»
Кемнәр бүлгән — аның
вөждан үлгән:
юл башымнан алып —
Хазаргача[1] —
суларымда тәре тирбәлә!
Аккан саен моңга мөлдерәп тулам,
җилләр җырын тыңлап онытылам,
Чишмә башы — гомер кояшым.
Моңнар белән онытып та куям
суларымны
кай җирләргә илтеп коясым.
Янган чакта күктә Кояш-тугърам,
Үзәннәрем минем яшел урам,
мөлдер-мөлдер ярым — агып торам —
һич кенә юк
шушы җирдә агып туясым!

---

[1] Хазар — Каспий



**Фәрит Яхин**

# АХЫРЗАМАН ПӘЙГАМБӘРЕ

*(Мәккә тормышы)*

КЫЙССА

## Изгелек нуры


Йа Бөек Зат, мескеннәрнең күңелләрен яктырт, наданнарның ахмаклыгын үзләренә күрсәт, гарипләреңне сихәтле ит, өммәтләреңне хозурла, сабыйларыңа өмет орлыкларын сал! Юкса безнең гомеребез җәһаләт базларында кала бирер. Җиргә яратылган сансыз адәмнәр, бер көн килеп, төркем-төркем булып гарасат мәйданына егылырлар, гафу үтенерләр. Безләрне яманнар рәтенә калдырма, йа Илаһи!

Вакыйгаларны мең еллар буена сөйләүчеләр бelә: Шайтан коткысыннан имин булсак, без Аллаһ юлыннан тайпылмабыз — көннәр үтеп, менә Габделмотталипның улы дөньяга килде. Баланы күрергә килүчеләр хәйран булдылар, аның йөзеннән үзенә бертөрле илаһи нур чәчелеп торыр иде. Бу нурдан кешеләрнең күңелләрендә изгелек шәме кабынды. Мәккә халкы бәхетле иде. Биләүдәге балага үз сыйфатына бәрабәр камил исем кирәк.

Габделмотталип гасырлардан бирле сөйләнелеп киленә торган бер вакыйганы исенә төшерде: Ахырзаман пәйгамбәренең атасы туган йортта гөнаһсыздан катил ителгән Яхъя пәйгамбәрнең җөббәсе булып, ул кием өстендә хуҗасының изге кан тамчысы кибеп, уңып беткән хәлдә торырга тиеш икән. Әгәр дә шушы шарт туры килсә, кан тамчысы тамган вакытындагы сыйфатка кереп, җөббәдән тәгәрәп җиргә төшәргә мәҗбүр иде. Габделмотталип бу җөббәне эзләтте. Чыннан да, Яхъя пәйгамбәрнең ул киеме улы туган урында иде. Җөббәне күтәрделәр. Яхъя пәйгамбәрнең гөнаһсыз кан тамчысын бар дип күрделәр. Ул күзгә күренеп әүвәлге хәленә кайтты, тәгәрәп җиргә төште, туфракка сеңде.

---

Фәрит Яхин (1961) — *галим, филология фәннәре кандидаты, «Пәйгамбәрләр тарихы» (1992), «Иман» (1993) һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*



Шулчак һәркем аһ итте. Хикмәтләрне юк әйбергә санаган кешеләрнең җаны икеләнде, ышанмас кешеләр хаклыкны танымый булдыра алмадылар. Шушы рәвешле җиргә Ахырзаман пәйгамбәренең атасы туганлыгы һәркемгә билгеле булды...

Хәбәрләрдә тагын да шулай килә: балага Габдулла, ягъни «Алланың яратканы» диярәк исем бирергә кирәк иде. Габделмотталип нәкъ шулай эшләде дә. Йөзе нурлы күркәм баланы Габдулла дип атадылар, аңа олы бәхетләр теләделәр.

Габдулла халыкларның соклангычы булып үсте. Көннәрдән беркөнне ул төш күрде. Төшендә көнбатыш һәм көнчыгыш тарафлардан ике нур хасил булып, аның каршында бергә кушылдылар. Бу нур үзенә күрә бер болыт күпертеп, Габдулланы эссе кояштан саклап торды. Бала моны атасы Габделмотталипка сөйләп бирде:

— Уянып киттем, каршымда бер күркәм зат хасил булып әйтте ки, синең үзеңә Аллаһы тәгаләдән әманәт буларак Ахырзаман пәйгамбәренең нуры тапшырылды, аны сакла, изгелектә булырсың, дип.

Габделмотталип моның ни изге эш булуын аңлап алды. Габдулланы юатып матур сүзләр әйтте, курыкмаска, ә бәлки горурлык белән яшәргә кирәклеген өйрәтте.

Гомер үтә торды. Габдулланың йөзендә изге нур һаман да саклана бирде. Көннәрдән беркөнне ул корыган агач каршысына килеп утырды. Күзләре белән агачны күзләде. Агач кинәттән яшәреп китте, яңадан да терек хәленә килде, яшел яфраклары дөньяга сөенеп тибрәнделәр. Бу хикмәтне күреп торган Габдулла ни-нәрсә уйларга да белмәде. Сәбәпне үзендә дип тә төшенмәде. Агачтан күзен алды, торып китте. Ә ул арада агач кабаттан корыды. Яфраклары коелдылар. Моны күреп алган Габдулла тагын да пошаманга төште. Килеп, әтисенә сөйләп бирде. Габделмотталип аны иркәләп юатты, сәбәбе — синең үзеңдә, дип аңлатты.

Бу вакыйгалар Габдулланың Ахырзаман пәйгамбәре атасы булуына зур дәлил иде. Аның йөзеннән Аллаһы тәгаләнең нуры китмәде, Габдулла да изгелеген саклады, зина юлларына төшмәде, кешеләрне кимсетмәде, алдамады, әманәткә хыянәт итмәде.

Габдулла — Йосыф төсле матур бала булып үсте, аның күркәмлеге хакында сүзләр халык арасына таралды. Кайбер хәбәрләрдән күренгәнчә, күп кенә падишаһлар аны үз мәмләкәтләренә соратып алырга хыялландылар, ә күпләр исә кияүләре итеп күрергә теләделәр. Әмма Габделмотталип моңа күнмәде. Имеш, Габдулланың егерме яшьләреннән узган вакытларында икән, Шам падишаһының кызы аны шәһәрләре аша үтеп барганда күреп алган һәм йөгереп каршысына чыккан, үзенең мәхәббәтен белдергән. Язмаларга караганда, ул кыз бик тә чибәр, укымышлы икән. Әмма Габдулла:

— Мин әтиемнең рөхсәтеннән башка өйләнә алмыйм,— дип җавап биргән.

Менә Габдуллага егерме биш яшь тулган. Яһүдиләр аның хакында ишетеп алганнар һәм, махсус кешеләр яллап, булачак пәйгамбәрнең атасын үтертергә кешеләр җибәргәннәр.

Көннәр бик эссе торган. Канга сусап килгән яһүдиләр Мәккә урамнарын кат-кат ураганнар. Шулай көннәр үткән. Менә бервакыт Габдулланы күреп алганнар һәм, артыннан төшеп, кылычларын чыгарганнар. Ни хикмәт, бу вакытта урамга Ваһап бине Манаф та чыккан булып, яһүдиләрнең Габдулла артыннан кылыч айкап килүләрен күреп ала. Инде генә егетне харап иттеләр дигәндә, каяндыр, ак атларга атланып, мәһабәт егланнар килеп чыга һәм яһүдиләрнең үзләрен һәлак итеп ташлый. Ваһап бине Манафның исе-акылы китә. Бу хикмәтле хәлне ни-нәрсә дип тә аңлатырга белми, чөнки аның мондый күркәм атлардагы баһадир сурәтле огланнарны Мәккәдә бер генә тапкыр да очратканы булмый. Аларның илаһи затлар икәнлегенә төшенеп ала. Ул моны кайтып хатынына сөйли һәм кызы Әминәне шушы Габдуллага кияүгә бирергә карар итүен әйтә.

Бу вакытларда Мәккә халкы иркә кызларының Габдуллага гыйшкы хакында белсәләр дә, берсе дә үз гүзәлләрен тапшырасылары килми. Моның бер зур сәбәбе бар: әгәр дә Габдулла потханәгә керсә, аны күреп, потлар җылый, аһ оралар икән. Халык, моңа хәйран калып, шул потларын аллалары сыйфатында күргәнлектән, аллаларыбыз аны яратмый, дип тавыш куптара һәм Габдуллага ышанычсыз, яратмыйча карый торган булалар. Шунлыктан ата-аналары мондый кияүгә кызларын бирүне уйларына да кертмиләр, хәтта моны бер яман эшкә саныйлар. Әмма Ваһап бине Манаф үз күзе алдында үткән яһүдиләр белән огланнар вакыйгасыннан соң Габдулланың гади кеше генә түгел, бәлки кәрамәт иясе зат икәнлеген аңлап, хатыны аша Габделмотталипка хәбәрен җиткерә, Әминәне кияүле итәсе килүен белдерә. Ул сүзләр Габделмотталипны уйга сала, чөнки улының нуры, әгәр өйләнә калса, Әминәгә күчәргә тиеш икәнен белә бит.

Әминә туташ Мәккә шәһәрендә иң күркәм кызлардан иде. Бик тә тәрбияле бала булып, яхшы холыклы, аңлы, гүзәл сыйфатта үсеп җиткәнлектән, пәйгамбәр анасы булуга бик тә лаеклы иде.

Бу хәбәрдән соң Габделмотталип Йәмән иленә юнәлде. Белүенчә, монда бик тә галим, изге китапларның серләрен аңлый торган бер укымышлы кеше яши икән. Ул — Алла бәндәсе, нәселе буенча яһүдиләрдән булса да, Бөек Хода юлыннан тайпылышсыз атлаганлыктан, бер дә җәбер-золым кылырдай адәмнәргә охшамаган иде.

Габделмотталип аның белән күрешеп, эшнең асылын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, Габдулланы кемгә өйләндерергә кирәклеген киңәште. Ә яһүди исә, үз чиратында, Габделмотталипның улы хакында барысын да сорашты, шуларны изге китапларда язылган хәлләр белән чагыштырып карады. Барысы хак һәм дөрес килгәнлеген күрде. Хак әмерен күздән читкә куймыйча, яңадан да барча мәгълүматны үлчәү тәлинкәсенә салды. Габдулланың язмышы хәл ителде. Аның һичшиксез Ахырзаман пәйгамбәренең әткәсе булырга тиешлеге ачыкланды. Аллаһы тәгаләдән әманәт итеп тапшырылган изге нур, Габдулла өйләнү белән, хатынына күчәсе булганлыктан, Әминәне дә сынап карадылар. Ул да пәйгамбәрнең анасы дип танылырга лаек иде.

Шушы эшләр тәмам җиренә җиткерелеп башкарылганнан соң, яһүдине Габделмотталип Мәккә шәһәренә алып килде. Аңа зур бүләкләр тапшырып, Ваһап бине Манаф кызы Әминә белән туачак Ахырзаман пәйгамбәренең атасы булу өчен лаеклы табылган Габдуллага аннан никах укыттылар.

Аллаһы тәгаләнең әмере җитеп, Габдулланың йөзендә булган Ахырзаман пәйгамбәренә тапшырылачак нур шул төнне Әминәгә күчте. Иртән үз ягыннан чыккан Габдулланың йөзендә ул нурның билгесе калмаганлыгын күрделәр, хәзер инде ул да карашы белән корыган агачлар-

ны тергезә, алдына килгән дошманнарын коралсыз итә алмый иде. Аллаһы тәгаләбезнең кодрәте киң вә чиксез!

Әминә ятактан нур эченә нур булып, балкып чыкты. Аның күркәм йөзе тагын да күркәмләнгән, гүзәлләнгән иде. Өстенә карап сүз әйтерлек кемсәләрнең телләре корыр, оятсыз багучыларның күзләре сукыраер иде. Шулай итеп, әманәткә тугрылык Әминәгә йөкләнде.

Бу хәлләрне белеп алган Иблис тәмам чарасыз калды. Аһ орып, диңгезләр ягына юнәлде. Кырык көн үз-үзен белештермичә, аңсыздан елап-ыңгырашып, кая барып бәрелергә белмәде. Аның болай да аяныч хәле тагын да яманрак иде. Шушы рәвешле исәрләнеп йөргәннән соң, ул Әбу-Кабис тавына килеп чыкты. Ничәмә-ничә көннәр буенча диңгезләр ерып йөргән Шайтанның йонлач тиресе шулкадәр юкарган иде ки, әгәр төртсәң, тишелеп китәр төсле һәм дә бөтен әгъзалары үтәдән-үтә күренеп торгандай иде. Әбу-Кабис тавына җыйналышкан җеннәр, диюләр, шайтан ыруы, аны бу хәлдә очратып, аһ-ваһ иттеләр.

Кабиләсенең каршысына басып, Шайтан сүз башлады:

— Халыкларны хак юлга кайтарачак, бәндәләрне иманлы итәчәк, аларга җәннәт юлын күрсәтәчәк Ахырзаман пәйгамбәре җиргә туарга аз вакытлар калып бара. Безләргә урын тарая...

Шайтан тагын да барысын да җентекләп сөйләп бирде. Җеннәр-диюләр хафага төштеләр.

Әминә бу вакытта корсаклы иде. Ул төш күрде. Төшендә аңа бер гүзәл зат килеп, күркәм сүзләр сөйләде һәм туачак баласының зур мәлик, Аллаһы тәгаләнең Ахырзаман пәйгамбәре булачагы хакында хәбәрләр бирде, исемен «Мөхәммәт» дип куярга боерды. Әминәнең төшенә күрә, балага шушы исемне атап та куйдылар.

Бу вакытларда Габделмотталипның әмере буенча Габдулла Шам шәһәренә сәүдә кәрванын йөретте. Ул Мәккәгә ашлык алып кайтырга тиеш иде. Ясрибка[1] барып җиттеләр. Әмма Габдулла шул вакыт бик каты авырый башлады. Кәрван кире борылды. Тик хуҗаларын саклап кала алмадылар, ул юлда вафат булды. Аны Дәрел-Наби авылы янында җирләделәр. Кайтып, атасына хәбәр бирделәр. Бу вакытта Габдуллага нибарысы егерме биш яшь тулып үткән генә иде.

Шушы хәлдән хикмәт бу иде ки, Аллаһы тәгаләбез Мөхәммәт пәйгамбәренә үзеннән башка берәүне ата итеп танытырга теләмәде. Һәрхәлдә, борынгы китаплар шул рәвешле тасвир итәләр, ә без исә ул йөз еллар буенча сыналып килгән дәлилләр белән бәхәс кылырга җыенмыйбыз. Адәмнәрнең сизгер күңел бизмәннәре тигезлек хәлен җуйса һәм чайкалып китсә, үзләре карасыннар, сынап баксыннар. Йа рәхмәтле Аллаһ, йа хаким, йа хафиз!.. И адәм баласы, белгел: Алладан ятим калудан да бөек хафа дөньяда юктыр.

## Пәйгамбәрнең тууы

Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүе хакында тарихларда төрле-төрле риваятьләр сөйләнелә. Шунысы билгеле ки, ул Гайсә пәйгамбәр мәгъсәте (миссиясе) вакытларыннан 570 ел соңрак вәхи алды. Китаплар аны Искәндәр вафатыннан соң 688 ел кичкәч, Давыт пәйгамбәр заманыннан 1800 ел үткәч, Муса галәйһис-сәламнән соң 2300 ел, Ибраһим пәйгамбәрдән 3000 ел, Нух галәйһис-сәлам заманыннан 4490 ел, Адәм пәйгамбәрдән соң 5750 еллар узганнан соң дөньяга килде, дип бәян итәләр.

Мөхәммәт пәйгамбәр Фил вакыйгасы елында 55 нче көнне туды, дип фараз кылучылар да юк түгел. Аның тәгәл туган көне бәндәләргә

[1] Ясриб (Ясрип) — Мәдинә шәһәренең борынгы исеме.

билгесез калды. Берәүләр Фил вакыйгасы[1] елының кырыгынчы көне дип, икенчеләр исә Фил вакыйгасы елыннан соң ике ел да ике ай узганнан соң дип хәбәрләр китерәләр. Араларында иң мәшһүре — рәбигыль-әүвәлнең мөселман календареның өченче ае (уникенче көне) һәм нәйсан аеның (апрель) егерменче көне дип дәлилләп сөйләгән сүзләр хакыйкатькә туры килә булса кирәк. Шушы соңгы хәбәрне бәян итүчеләр сүзләрен бу рәвешле исбат итәләр ки, Мөхәммәт пәйгамбәр дөньяга килгәндә бакчалар хуш исле чәчәктә иделәр, җир балкып тора иде, адәм балалары бәхет нурына төренгән иделәр һ. б. дип тәкрарлыйлар. Хәлбуки, изге пәйгамбәребезне гөл-бакчаларның яшәрүе, яшәү яме җиргә иңүе вакытыннан башка көнне туган дип күз алларына да китерергә теләмиләр. Әмма, ни генә сөйләмәсеннәр, Мөхәммәт галәйһис-сәламнең Ахырзаман пәйгамбәре сыйфатында дөньяда киләчәге хакында Аллаһы тәгалә алдан ук белеп торган иде, хәтта бу хакта Адәм атабыз да хәбәрдар булды. Шунлыктан Бөек Тәңре мөселманнарга үзенең сөекле илчесе җиргә килүе хакында төгәл көнен хәбәр итмәде. Үзенең күңелендә яшәгән пәйгамбәрен ул җиргә чиксезлектән китерде, аны шулай кадерләде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам Мәккә шәһәрендә, Бәни-һашим сарае дип танылган йортта дөньяга килде. Ул сарай соңрак Мөхәммәт бине Йосыф исеме белән дан алды. Чөнки аны шушы исемдәге Хиҗаз Йосыф Сәкафинең туганы үзенә сатып алган иде. Габделмәлик бине Мәрван заманнарында Һарун әр-Рәшитнең әтисе Алла йортына хаҗга килде, бу сарайны эзләп тапты һәм аны үзенә сатып алып, мәсчет итеп төзәттерде. Бу мәсчет мөселманнарның иң изге күрелгән урыннарыннан берсе булды.

Ә Мөхәммәт пәйгамбәребезнең Җиргә килү вакыйгасы китапларга бу рәвешле теркәлгән...

Әминә ханымның корсаклы чагы иде. Аңа күктән бер мәһабәт аваз ишетелде. Моңа ул бик тә хәвефләнде, актан да, карадан да уйларга белмәде, ни-нәрсә эшләргә карар итә алмады. Карынында бала йөрткән хатынның күңелендәге куркудан да яманрак, авыррак халәт дөньяда бармы икән? Әмма аның бу рәвешле хәле озак дәвам итмәде, ул арада бер газыйм күркәм зат пәйда булды, канаты белән аның корсагын сыйпап үтте, күңелендәге юклы-барлы хәвефләрне сөртеп алды. Әминәнең тәненә вә җанына күркәм бер тынычлану, рәхәтлек иңде.

Ул арада Әминә ханым күрде: каршында бер кое пәйда булды. Бу кое ширбәт коесы булып, татлы сулы иде. Хатынның җаны көеп, эчәсе килде. Коедан су алды. Ул сөттәй ак иде. Эчте. Сусавы басылды, эчкәне гаҗәеп дәрәҗәдә татлы иде.

Ул да булмады, йорт эчендә бер нур пәйда итте. Аның балкышы күзләрен камаштырды, аннан башка һичнәрсә күзенә чалынмады. Гүя сарай эче тәмам буш калып, шушы нурдан башка бүтән бер әйбернең монда барлыгы сизелмәде. Әминә ханым күзен нурдан ала алмады.

Шушы нур эченнән көтмәгәндә хатыннар чыктылар, аларның буйсыннары хөрмә агачыдай күркәм, йөзләре чибәр, куллары саф, чиста һәм ак иде. Аларны күргән һәрбер бәндә һушсыз булыр иде. Алар Әминә ханымны урап алдылар, кояштай якты йөзләре белән назлы карашларын аңа юнәлттеләр.

Ул арада озын тукыма хасил булып, Әминә ханымның тезләренә кадәр төште. Кошлар килделәр. Алар берсеннән-берсе күркәм һәм сокландыргыч иделәр, шушы тукыманы күтәреп тордылар, Әминә ханымны яман күздән сакладылар. Аларның корган шушы пәрдәләре ак болыттан да сафрак һәм пакь иде.

Шушы эшләр эшләнгәннән соң дөнья йөзенә Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләм килде. Гүя ки олы бер кеше төсле күтәрелде, сәҗдә итте һәм дога укыды. Ул арада бер ак болыт пәйда булып, аны үзенә

[1] Фил вакыйгасы елы — Мәккәгә корылыктан акылын җуйган фил кереп, бар нәрсәне җимергән бәла елы.

алды, кочагында җир-күкне әйләндерде. Ул да түгел, икенче бер ак болыт иңде, эченнән кеше авазлары, ат кешнәгән тавышлар ишетелде. Җәннәт хәзинәләрен саклаучы Ризван килеп, сабый бала — Мөхәммәтне кулына алды, сөйде, аны тәбрик итте, дөнья йөзеннән узган барлык пәйгамбәрләрнең асыл сыйфатларын аңа тапшырды...

Әлеге изге көн хакында сөйләнгән кайбер тарихлардан шул билгеле: имеш, Әминә ханым бала тудырганда йорт эчендә ялгызы булган. Хәтта өч көн буена, ни сәбәптәндер, аның янына һичкем кермәгән. Ишек каккан кешеләрнең дә беренчесе Мөхәммәт пәйгамбәребезнең бабасы Габделмотталип булуы мәгълүм.

Баланың күркәм сыйфатларын күреп, ул хәйран калган. Әминә ханым аңа ни-нәрсә тойганнары хакында бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Бу хәбәрләр Габделмотталипны, бер яктан, сөендерсә, икенче яктан, уйга да салган. Ул бит Мөхәммәт оныгының Җиргә пәйгамбәр булып киләсен алдан белеп торган, әтисе Габдуллада ук аның кайбер сыйфатларын күргән иде.

Әминәнең бу сүзләрен ишеткәннән соң Габделмотталип үзе белән булган вакыйгаларны сөйләргә керешә. Әйтте:

— Мин, Кәгъбәгә кереп, мөнәҗәтләр әйтә идем. Ибраһим угылы Исмәгыйль пәйгамбәрнең рухы килде, сәҗдә кыла башлады: «Җиргә Аллаһы тәгаләнең сөекле пәйгамбәре Мөхәммәт гайләйһис-сәлам килде, ул минем өммәтләремне туры юлга китерер, йөземне ак итәр», — дип хәбәр бирде. Ул арада потларның төсе бозылды. Тагын да аваз ишетелде. Барысы да Мөхәммәтнең туган көне белән берсен-берсе котларлар иде. Исемә син килдең, Бәни-Шәйбә капкасыннан чыктым... Синең сарайга житешкәндә күрдем ки, бер кош уң канатын җәеп, барыр юлымны бүлде. Эчкә үтә алмадым. Ул көнне күрдем, бу кошның сафлыгыннан Мәккә таулары нурга күмелгән иделәр... Йә, инде Мөхәммәтне үземә күрсәт! — дип әмер итте Габделмотталип.

Моңа каршы Әминә ханым:

— Мөхәммәт улымны бер кемсә яшел суга салып юындырды һәм өч көн буенча һичкемгә күрсәтмәскә боерды, — дип, ялвара башлады. Әмма Габделмотталип бу сүзләрне ишетергә теләмәде, кынысыннан кылычын чыгарды, аның белән кизәнде һәм:

— Йә Мөхәммәтне хәзер үк күрсәтәсең, йә икегезне дә урталай чабып өзәм, бу ни хәл?! — дип, дәһшәтен тыя алмас булды.

Моңа каршы Әминә ханым:

— Күрсәтә алмыйм, ул минем янымда юк! — дин җавап бирде һәм Габделмотталипның мәҗбүр итүе аркасында баланың кайдалыгын әйтеп бирде.

Габделмотталип күтәрелеп чыкты. Шул сарайны эзләп тапты. Керде. Каршысында бер пәһлеван кемсәне күрде, аның яныннан үтә алмады, оныгы Мөхәммәтне эзләп килүе хакында хәбәр бирде. Әмма ул кеше өч көн буенча пәйгамбәрне адәмиләрдән беркем дә күрергә тиеш түгеллеген, аның фәрештәләр тәрбиясендә генә торачагын әйтте.

Ни хикмәт, Габделмотталип ялтыраган кылычы белән берни эшли алмады, хәлсезлек тойды. Кулыннан кылычы төште, чарасыз калган карт борылып китәргә мәҗбүр булды. Мәккә халкына бу хакта сөйләргә дип теле тибрәнде.

Хәбәрләрдә тагын шулай бәян ителә ки, Әминә ханым Мөхәммәтне дөньяга китергәндә баланы кабул итүче кеше Сафиййа-банат булган. Аны иң беренче, пәйда булган нур хәйранга калдырган. Мөхәммәт тугач та сәҗдә иткән һәм, мөбарәк башын калкытып, Аллаһы тәгаләне атаган, үзен аның пәйгамбәре дип белдергән. Өченчедән, аның йөзендә илаһи нур күренгән, дүртенчедән, баланы Сафиййа юмакчы булган, әмма шунда аңа бер аваз ишетелгән һәм Мөхәммәтнең инде саф-пакь булуын, юарга кирәк түгеллеген хәбәр иткән, бишенчедән, бала сөннәтле булып туган, кендеге дә кисек икән, алтынчыдан, аркасында бер мөһере булып, анда

анын Аллаһы тәгалә илчесе булуы язылган икән. Мөхәммәт туу белән сәҗдә иткәндә Сафиййа аңа колагын куйган һәм: «Өммәтем, өммәтем!..— дигән сүзләрен ишеткән. Шул билгеле булсын, Сафиййа-банат хәбәрләренең хаклыгын бу вакытта янында булган башка ханымнар да раслыйлар.

Ул елларда Мәккәгә яһүдиләр килеп йөри иделәр. Мөхәммәт туган көннең икенчесендә ул яһүдиләр җыелыштылар, үзара сүз куерттылар. Килеп, корәиш кабиләсеннән сорадылар:

— Кичә сезнең арада бер галим бала туган булырга тиеш, хакмы?

Гарәпләргә билгеле — Габделмотталип килене Әминәдән башка кемсәнә бу араларда гына бала табар төсле түгел иде. Шуңа күрә барысы да анын тарафына таба борылдылар. Габделмотталип исә:

— Киленем бала тапмады әле,— дип хәбәр бирде. Чөнки ул Мөхәммәтнең дөньяга килүе хакында әлегә белми иде. Шулай да Әминә торган сарайга бер колны җибәреп соратты.

— Тәүратта язылган,— дип тәкърарлады яһүдиләр.— Шушы көннәрдә Җиргә сезнең арагыздан бер пәйгамбәр килергә тиеш.

Габделмотталипнын колы килеп житте. Әминәнең бала табуы хакында әйтте. Барысы да гаҗәпкә калдылар.

Риваятьләрдә шулай сөйләнде ки, өч көн үткәч, Габделмотталип, оныгы Мөхәммәтне күтәреп, халык алдына чыкты. Анын йөзендә бер нур барын күрделәр, ул нурдан бар тараф яктырып киткәндәй булды. Моны күреп торган яһүдиләр үзләренең изге китапларында язылган вакыйгаларнын хак икәнлеген белделәр, әмма курка калдылар. Тик балага зыян китерергә кулларыннан килмәде.

Көннәрдән беркөнне Мәккәгә Йосыф атлы бер яһүди килеп, корәишләрдән сорый башлады:

— Миңа Тәүраттан билгеле, сезнең арагызда шушы көннәрдә генә бер бала туган, аны миңа күрсәтегез,— дип.

Гарәпләрнең иң данлыклы кабиләсе — корәишләр монын сүзләренә тагын да гаҗәпсенеп калдылар. Әмма бу кунакчыл халыкта кеше үтенечен кире кагу гадәте юк иде. Алар Йосыф яһүдигә берничә көн генә элегрәк Мөхәммәтнең тууы хакында әйттеләр.

— Сез мине анын янына илтегез, миңа күрсәтегез,— диде теге.

Аны Әминәнең ятагына озаттылар. Мөхәммәт пәйгамбәр бишектә иде. Йосыф яһүдигә тоттырдылар. Балага бакты, йөзендә бер якты нур күрде. Һич әйтер сүз тапмады, һушсыз булып егылды. Янында торучы гарәпләр исә җәһәт кенә сабый баланы тотып калдылар. Ул арада яһүди айныды һәм:

— Бу баланы кылыч белән тураклап ташлагыз! — дип үтенә, ачулана башлады.— Юкса ул үсеп житәр һәм үзегезнең башыгызга житәр. Барыгызны үз диненә каратыр, чарасыз булырсыз. Буйсынмаганнарыгызны харап итеп ташлар. Сүземне тыңлагыз! Тәүратта язылган, бу бала Ахырзаман пәйгамбәре булыр,— диде.

Әмма корәиш гарәпләре анын сүзенә карап, баланы харап итмәделәр. Йосыф нинди генә мәкерле сүзләр сөйләмәсен, бу кара җанлы адәмне тыңламадылар.

Йолдызчы-мөнәҗҗәмнәр дә бер-бер хәбәр алдылар. Мөхәммәт туган көнне күктә бер Кызыл йолдыз хасил булды. Алар белә иделәр, әгәр күк йөзенә Кызыл йолдыз чыкса, бу — пәйгамбәр йолдызыдыр. Ул һәрвакыт пәйгамбәрне озата йөрер, аны хәвеф-хәтәрдән саклар. Йолдызчылар бу хикмәтне Мөхәммәт галәйһис-сәламгә нисбәт иттеләр. Күктә Кызыл йолдыз хасил булу берәүләр өчен зур шатлык һәм бәхет булып тоелса, икенчеләрне кайгы-хәсрәткә салды. Бу хәл бигрәк тә яһүдиләрне борчыды.

Көннәрдән беркөнне Мәккә шәһәрендә һич тә күренгәне булмаган бер яһүди Габделмотталип янына килде һәм:

— Яңа туган балагыз ни атлы? — диярәк сорау бирде. Моңа каршы Габделмотталип:

— Мөбарәк исеме Мөхәммәт булды! — дип җавап бирде.

Бу хәбәрне ишеткән яһүдинең йөзе кара коелып төште, кашлары маңгае өстенә менде.

Яһүдиләр, җыелыш корып, киңәш-табыш иттеләр. Вакыйгаларның агышы белән ризалашырга да, ризалашмаска да белмәделәр. Арадан бер мөхтәрәме аларны үз тирәсенә утыртты да:

— Аның пәйгамбәр булуына өч дәлил бар. Беренчесе, күк йөзендә Кызыл йолдыз балкый, икенчесе, исемен Мөхәммәт дип кушканнар, өченчесе, аны күрергә барлык олуг галимнәр һәм затлар килделәр,— дип барысын да бәйнә-бәйнә тасвир кыла башлады. Яһүдиләр Габделмотталипның оныгы Мөхәммәтнең чыннан да пәйгамбәр булуын шушы рәвешле белделәр, моның белән күңелләрендәге борчуларны гына арттырдылар.

Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләм туган көнне күктән бер өн килде. Җир йөзендә булган барлык потлар йөзтүбән егылдылар. Иртәгәсе көн потларга табынучыларның бәйрәме иде.

Хикәятләрдә болай дип сөйлиләр: Мәккәдә бер гаилә кешеләре башкалардан алда үз потлары янына килеп, аның егылып ятканын күрделәр. Ул вакытларда Мәккә гарәпләре потка табынучылар булып, Кәгъбәдә төрле-төрле таш сыннар куелган иде. Теге гаилә кешеләре үз потларын аягүрә бастырдылар. Әмма тырышлыклары юкка булды. Ул арада потлары тагын баштүбән әйләнеп төште, чактан гына авырлыгы белән үзләрен харап итеп ташламады. Болар тагын да эшкә керештеләр. Потның аякларын ныклап беркеттеләр, әмма ул тагын ауды. Болар аптырашта калдылар. Тагын да потларын аякка бастырдылар, аны егылмаслык итеп, җиргә казып утырттылар. Шул чагында бу сөекле потлары телгә килде һәм шигырь белән сөйли башлап, җиргә Мөхәммәт пәйгамбәрнең килүен, барлык потларның да маңгайлары белән җиргә каплануын, инде кешеләргә хак дин иңдереләчәген әйтеп бирде. Аның бу сүзләре бу мәҗүси гаиләгә шулкадәр тәэсир итте ки, алар моннан соң потханәгә килмәс булдылар.

* * *

Сасанидлар династиясеннән бер хөкемдар-кәсра бар иде. Ул бер тау итәгенә зиннәтләп сарай төзетте. Бик күп алтын-көмешләрен шушы бина өчен сарыф итте. Төзеткәне матур һәм бик күркәм булды. Аның бина ителеп беткән көнендә Мөхәммәт пәйгамбәр дөньяга килде. Бер өн ишетелеп, таулар урыннарыннан күчтеләр, җир селкенеп, шушы Хөсрәүнең күркәм сарае җимерелде.

Иртәгесен бу хәлне падишаһ күрде, күңеленә хәвефлек уты кереп оялады, җан кошы күкрәк читлегеннән очып чыгардай булды. Хөкемдарның хәле аһ иде. Сараеның җимерелү сәбәпләрен белергә теләге уянып, үзенә хезмәттә булган барлык йолдызчы-мөнәҗҗәмнәрне чакыртты:

— Бу ни хәл? Белегез! Юкса үзегез дә шушы хәлгә калырсыз! — дип әмер итте. Мөнәҗҗәмнәрнең балталары суга төшкәндәй булды. Аһ-ваһ иттеләр, ни дип тә җавап бирергә белмәделәр.

Аларның араларында Саип исемле бер гарәп бар иде. Йолдыз һәм сихер гыйлемендә аннан да остарак һәм маһиррак кеше булмаганлыктан, барчасы да аның җавабын көттеләр. Ул да чарасыз иде.

— И хөкемдар, кичне көтик, йолдызлар көндез күренмәс, иртәгә хәбәр бирербез,— диде. Саипның бу сүзләрен Хөсрәү кабул итте, аларга ирек бирде.

Төн җитүгә мөнәҗҗәмнәр күкне тикшерә башладылар. Йолдызларны санадылар, үзләренең сыналган чараларын кулланып, җисемнәрнең торышларын тикшерделәр, каршыларына сынау үлчәмнәрен салдылар. Саип гарәп исә тау ягына китте. Өскә күтәрелде. Күңеле ниндидер

авырлык һәм үзгәрешләрне тойды, акылы тотылды, ни бер уй, ни бер хәйләне башына сыйдыра алмады.

Ул шул рәвешле исәреп торганда күк йөзендә яшен күренде. Аның уты саф һәм яшел төстә булып, Хиҗаз ягыннан чыкты һәм көнбатышның читенә барып иреште.

Мөнәҗҗәм бу ни хәл икәнлекне бик төшенеп тә җитмәде. Йолдызчылар янына килеп, алар белән киңәш-уңаш итте. Бәйнә-бәйнә бу хәлне сөйләп бирде.

— Бу яшен югалу белән җиргә таң иңде,— дип сүзен бетерде ул.

Аның сөйләгәннәрен сынап бакканнан соң, барысы да хәтер бакчаларына өмет тулы күзләрен төбәделәр. Бу ни-нәрсә икәнлегенә төшенәселәре килде һәм, Җирдә берәр пәйгамбәр үлгән, яки туган булырга тиеш, дип фараз кылдылар. Хөкемдарга килеп, шушы рәвешле аңлатмалар бирделәр.

Падишаһ сараен тагын да төзетте. Инде генә аңа күченәм дигәндә, ул кабат ишелеп төште, күп кенә кешеләрне харап итте. Бу хәлдән аптыраган хөкемдар йолдызчы-сихерчеләрен кабаттан чакыртты, аларның ялган сөйләүләренә ачуы килүен әйтте. Тегеләр исә тагын да күк җисемнәрен тикшереп бактылар. Икенче кат шул ук хәбәрне җиткерделәр. Әмма өченче тапкыр күтәрелгән сарай бу юлысы да җимерелеп төште. Шуннан соң гына барысы да Җирдә пәйгамбәр тууы һәм бу эш аның хикмәтләреннән икәнлекне аңлап алдылар.

Көннәрдән беркөнне Хөсрәү падишаһ төш күрде. Төшен тәгъбирчеләргә сөйләп бирде:

— Бу кич йокыда идем. Көтмәгәндә җирләрем өстенә гарәп атлары һәм дөяләре килделәр, ил өстеннән таптап үттеләр. Моның мәгънәсе ни-нәрсә? — диде.

Юраучылар аһ-ваһ иттеләр. Кайдан башлап сөйләргә дә белмәделәр. Әмма җавап бирә алмыйча кала алмадылар.

— Гарәпләрнең падишаһы дөньяга килмәктер, аның гаскәрләре безнең өстебезгә төшеп, харап итә күрмәсен,— диделәр.

Аларның бу җаваплары падишаһка ошамады. Ул белә иде, гарәп кабиләләре инде ничә еллар падишаһсыз яшиләр, һичкемгә буйсынмыйлар, беркем алдында да муен-бил бөгеп йөрмиләр. Аларга падишаһлар кайчан да булса баш була алганы булмады. Шуңа күрә Хөсрәү кайчан да бу гарәпләрнең падишаһлары булыр дип күз алдына да китерә алмый иде.

Ул күршесе Басра хөкемдарына илчеләр җибәрде. Аннан төш юрый белүче кемсәләрне соратты. Үзен дә киңәш-табыш кылырга Шам иленә чакырды. Басра падишаһы хәбәрне алу белән үк атларын иярләтте, тиз ара Шамга килеп җитте. Тәгъбирчеләр төшне тагын да юрап бактылар. Аларның тәгъбирләре элеккечә калды. Төрле китапларны актарып, төш юрауның җитмеш төрле ысулын кулланып карадылар. Хөкемнәре бер дә башкача булмады. Аларны ишеткән хөкемдарлар хәсрәт-газап утыннан котыла алмадылар. Хәвеф диңгезләре ярларыннан ташып чыкты, шөһрәт кыяларын дулкын каплап үтте. Болар чарасыз булып калдылар. Тарих аларның алдан ук сиземләүләрен, уй-хәсрәтләрен дөрескә чыгарды.

Риваятьләр, хикәятләр, тарихлар Мөхәммәт саллаллаһ галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүе хакында, шул вакытларда булган хәлләр турында әнә шушы рәвештә сөйлиләр.

Тарихчылар Мөхәммәт пәйгамбәр хакында язганда күпвакыт шушы хәлләрне искә төшереп үтүне кирәк санамыйлар. Шулай итеп, кешеләрнең ничә гасырлар буена күз алларында йөрткән хәбәрләреннән безне мәхрүм итәләр. Алар, мөгаен, Мөхәммәтнең пәйгамбәрлеген шик астына куярга тырыша торганнардыр? Ә бәлки бу вакыйгаларга ышаныч күзе белән карарга теләмиләрдер? Анысын үзләре беләдер. Әмма бу сөйләгәннәрдә бер дә хакыйкать чаткысы юк икән дип әйтергә ярамас иде.

Дөрес, аларның булуын бүгенге тарихи белемнәребез раслый алырлык дәрәҗәдә түгелләр әле.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган вакытында ук йөзе нурлы булуы һәркемгә билгеле. Тагын шунысы кызыклы, Мөхәммәт галәйһис-сәламнең йөзе, башка гарәпләрдән, хәтта туганнарыннан да аермалы буларак, якты һәм бик тә ак булган. Аннан соң аның аркасында мөһере-миңе булуы да билгеле. Өченчедән, Мөхәммәт бик тә намуслы булган, ялган сөйләмәве белән аерылып торган.

Мөхәммәт галәйһис-сәламнең сөннәтле хәлдә туувы да билгеле. Бу исә хәзерге тыйб фәне тарафыннан да раслана һәм хәтта бүгенге көндә дә ир балаларның меңгә бере (бу сан китапларда төрлечә күрсәтелә) сөннәтле туувы сөйләнелә.

Боларның барысыннан да өстен төп дәлил дә юк түгел. Ул — Мөхәммәтнең, чыннан да, пәйгамбәр булып танылуы. Моны инде кешелек тарихыннан берничек тә сызып ташлап булмый.

Инде тагын шунсын әйтик, борынгы тарихлар, хикәятләр, риваятьләр вакыйгаларны матурлап, бизәп җибәргәннәр икән, монда хакыйкатькә хилаф әйберләр бар, дип карарга ярамый. Чөнки матур тел, ихлас күңелдән сурәтләнгән вакыйга ул әле кешене тәрбия дә кыла, аңа гүзәллек тойгылары белән эш итәргә илһам-көч бирә...

Шулай итеп, Мөхәммәтнең дөньяга килүе Мәккә халкы өчен дә, әйләнә тирәдәге мәмләкәтләр өчен дә ис китәрлек олуг вакыйга, тарихта зур борылыш була.

## Пәйгамбәрнең бала чагы

Мөхәммәт пәйгамбәр беренче җиде көндә үз әнкәсенең сөтен имде. Аннан соң аны сөт анасына тапшырдылар. Ул вакытларда байлар үзләренең балаларын коллардан имезә иделәр. Аллаһы тәгаләнең теләге белән Мөхәммәт пәйгамбәр Сәүбә исемле хатынның сөтен имде. Ул аның сөт анасы булды. Сәүбәнең хуҗасы Әбу-Ләһәп иде. Китапларда язылганча, Әбу-Ләһәп моннан соң Сәүбәне коллыктан азат итте, аңа ирек бирде. Сәүбәгә исә Мөхәммәт пәйгамбәрне шулай ук җиде генә көн имезергә насыйп булды. Моннан соң Мөхәммәтне үз кочагында йөртергә, аңа сөтен бирергә Хәлимә исемле хатынга Аллаһы тәгаләдән рөхсәт ителде. Шулай итеп, Габдулла кызы Хәлимә дәүләтле кылынып, тарихларда аның изге гамәле, күркәм исеме телгә алына торган булды.

Мәккә халкында бер гадәт бар иде. Алар үзләренең сабый балаларын күчмә тормышлы гарәпләргә тәрбия өчен бирә иделәр. Чөнки, беренчедән, Мәккә шәһәрендә һава бик эссе булып, сабыйлар өчен зыянлы күрелә. Икенчедән, Мәккә таифәсе сәүдәгәр халык булганга күрә, базар эшенә бик тә ихлас итеп, хатыннарын һаман да эш белән йөкли иделәр. Алар өчен авыл халкына биреп, бала тәрбия иттертү уңайлырак һәм дөрес эш булып аңлашыла иде. Һәм дә бик бай корәишләр шушы рәвешле балаларын үстерүне дан вә шөһрәт итеп күргәнлектән, сөт аналарына зур бүләкләр дә тапшыра иделәр. Ә бу исә, чын мәгънәсендә, корәишләрнең дәрәҗәсен күчмә гарәпләр каршысында күтәрә, мәккәлеләргә карата хөрмәт тудыра иде. Шуңа күрә дә шәһәр тирәсендә яшәүче күчмә гарәпләр Мәккәгә сугыш кылычы тотып килми иделәр. Хәлбуки, күчмә гарәп гаиләләренә тәрбиягә бала биреп торуның төбендә акыллы сәясәт тә ята иде.

Мәккә тирәсендә яшәүче кабиләләр татлы сулы, яхшы һавалы урыннарда тормыш кичерә. Әмма җәйләрен аларның далаларында үләннәр корып, бары кечерәк агачлык, сулык җирләрдә генә җан асрарга мөмкинлек була. Шундый күчмә гарәпләрнең берсе — Бәну-Сәгыйть кабиләсе

икән. Алар ел да, алдан ук белешеп куеп, Мәккәгә киләләр һәм имезер өчен сабыйлар алалар, шул рәвешле үзләренең авыр тормышларына бераз керем табалар.

Бу елда Мәккә һәм аның тирәсендә кətелмәгән корылык булып, гарәпләрнең болай да авыр тормышларын тагын да катлауландырган иде. Бәну-Сәгыйть кабиләсендә, житмәсә, эсселектән бер төрле авыру барлыкка килеп, сөт аналарының имчәкләрендәге сөтен дә киптергән. Бу исә Мәккәдән тәрбия өчен сабыйларны алуга мөмкинлекне бетергән, кабиләне төрле яклап авырлыклар чолгаган.

Габдулла бине Харис кызы Хәлимә — нәкъ шушы Бәну-Сәгыйть кабиләсеннән, Харис бине Габделгазиның хатыны була. Аларның гаиләсе байлардан саналмаган. Җитмәсә, Хәлимә үзе дә корсаклы булып, бер угыл таба. Әмма имчәкләрендә сөте булмаудан һәм ашарга таба алмаудан ул бик тә изалана. Көннәр буе дала буйлап азык эзләп йөри. Әмма ни хәл кыласың, агачлар күренсәләр дә, аларның җимешләре генә түгел, хәтта яфраклары да көйгән чаклар. Хәлимә ханым җиргә ятып, үлән ашый, шул рәвешле җан саклый.

Көннәрдән беркөнне Хәлимә ханым шушы рәвешле азык җыеп йөргәнендә бик арып китә һәм йокыга тала. Төш күрә. Төшендә аңа бер күркәм кеше килә, аны торгыза да якын-тирәдә күрелмәгән затлы кое янына китерә:

— Сусагансың, эч, бу коеның суы бик тәмле! — ди.

Хәлимә йотылып су эчә башлый. Әмма бу су дигәннәре сөт төсле булып, тәме шербәттән дә татлырак икән. Бу зат:

— Тагын эчәсең киләме? Эч! — дип кыстый.

Хәлимә ханым кабаттан эчә, сусынын тәмам басканчы кое яныннан китми. Бу күркәм зат исә:

— Бу кое гади кое түгел. Синең күкрәкләреңдә сөт корыган иде, бу кое суын эчкәч, имиләреңә сөт төшәр. Мәккәгә барырсың, анда бер күркәм, нурлы йөзле сабыйны тәрбиягә алырсың, исеме Мөхәммәт булыр. Әмма минем хакта һәм бу кое турында һичкемгә сөйләмәссен! — дип боера.

Шушы төштән соң Хәлимә уянып китә һәм күкрәкләреннән сөте ташып чыкканны күрә. Балалары янына килә. Ачлыктан елаган улына ими каптыра, сабый туйганчы имә дә йокыга китә. Әмма Хәлимәнең сөте һаман да кимеми, күкрәкләре кабарганнан кабара. Бу хәлне Бәну-Сәгыйть кызлары күреп алалар һәм:

— И Хәлимә, син әле элгәрерәк кенә кипшенеп беткән идең, бу ни хәл, күкрәкләрең күтәрелгән, бигрәк солтанат булганнар, — дип, аңа сокланалар һәм көнчелекле карашларын ташлыйлар да, — сиңа ни булды? Каян болай булдың? — дип сорыйлар. Әмма Хәлимә алар алдында чишелеп китми.

Ул көнне Бәну-Сәгыйть кабиләсе Мәккәгә тәрбиягә балалар алырга барырга тиеш була. Хәлимә ханым да шәһәргә килергә карар итә. Ире Харис бине Габделгази һәм уллары Габдулла, Әнис, Хизам белән юлга кузгала. Әмма Хәлимәнең дөясе бик арык булганлыктан, ул, гаиләсе белән бергә, Бәну-Сәгыйть кызларыннан артка кала.

Шул рәвешле ашыгып барганда Хәлимә бер тау янына җитә, ни хикмәт, кыяланып торган урыныннан урталай ярылып, эченнән бер карт килеп чыга. Хәлимә туктап кала.

Бу карт дигәннәре хөрмә агачы төсле күркәм сынлы бер ир булып, кулына кечкенә генә бер сөңге дә тоткан. Аны күреп, Хәлимә курка кала. Әйтер сүзе теле очында кибә. Әмма бу зат аны тынычландырып:

— И Хәлимә, мин сиңа зыян эшләүче түгелмен, киресенчә, сине хәвеф-хәтәрдән вә җен-пәри, дию-шайтан коткысыннан саклап йөрермен. Бер дә куркып калма! — дип белдерә. Һәм хатынның кая ашыгуы белән кызыксына.

— Мәккәдә бер күркәм ир бала дөньяга килеп, аны тәрбия кылган кешегә зур бәхетләр юлланыла дип ишеттек. Шәһәргә дөрраү агылдык.

Әмма минем дөям ябык һәм арганлык сәбәпле, көндәшләремнән калыштым. Ул бала миңа насыйп булмас дип куркамын,— дип җавап бирде Хәлимә ханым.

— Син бер дә хәвефкә калма, күңелеңнән шик-шөбһәләреңне җилгәр. Ул баланы чиста вә саф җаның белән кабул итеп алу тиеш. Морадыңа ирешерсең, иншалла! — дип бу күркәм зат аңа хәбәр бирде һәм үзе күздән гаип булды. Ул арада Хәлимәнең күзләре йомылды, керфекләре күп вакыт та үтмәстән кабат күтәрелделәр. Ул үзен Мәккә шәһәре янында күрде. Бу вакытта Бәну-Сәгыйть кызлары җилдертеп Мәккәгә җиткәннәр вә шәһәргә кереп бара иделәр. Хәлимә ханымның да дөясе алар артыннан калмады. Җиргә ахшам вакыты иңде.

Ул да булмады, Хәлимә ханымның алдында яшел ботаклы хөрмә агачы хасил булды, җимешләре дә шактый күп иде. Бәну-Сәгыйть кызлары бу хәлне күреп алдылар һәм:

— И Хәлимә, син безнең мәликәбез,— дип сокланып карадылар.

Ул арада бу хөрмә агачы ботагыннан бер җимеш өзелеп төште. Хәлимә ханым аны алып капты. Җимеш бик тә татлы, сусыл иде. Җанына сафлык, тәненә ныклык бирде.

Бәну-Сәгыйть кызлары Мәккәгә дүшәмбе көн килеп керделәр. Барысы да тәрбиягә балалар тапты, бәяләрне килештеләр. Әмма Хәлимәнең яңа туган улы бу вакытларда авырып киткән иде. Ул ашамас булды. Бу сәяхәте өчен анасы бик тә кайгыра башлап, ник килгәненә үкенә дә иде инде. Күзләренә яшьләр тыгылды. Җаны өзгәләнде.

Хәлимә ханым баласына тагын да ими каптырды. Ни хикмәт, улы имә башлады. Савыккандай булды, эреңләнгән күзен ачып, дөньяга бакты. Аның бу хәле әнкәсен тынычландырды.

Хәлимә ханым үзенә асрамага бала эзли башлады. Әмма бай гаиләләрдән булган сабыйларны Бәну-Сәгыйть кызлары алып бетергән иделәр. Хәлимә ханым үзенең өлешсез калганлыгын аңлап алды, бәхет китерәчәк күркәм бала дус кызларыма насыйп булган күрәсең, дип уйлады. Өмете киселде, күз алдыннан ышаныч нуры киткәндәй булды.

Шунда аның күзенә бер мөхтәрәм вә күркәм зат чалынды. Бу кемсәнең сыйфатлары Хәлимә ханымга үзгәчә бертөрле тәэсир ясады.

— Бу кем? — дип белеште ул халыктан. Аңа әйттеләр:

— Бу — Габделмотталип, Мәккәнең һәм корәишләрнең иң олуг кешеләреннән,— диделәр.

Хәлимә ханым аның артыннан килде. Сараена үтте.

— Син кем буласың? Ни борчулар монда китерде? — дип сорады аннан Габделмотталип.

— Исемем — Хәлимә атлы, Бәну-Сәгыйть кабиләсеннән булам. Сездә сабый барлыгын белешеп килдем, аны миңа күрсәтсәгез иде,— дип җавап бирде аңа Хәлимә ханым.

— Ул баланы мин сезнең кабилә кызларына күрсәткән идем, алырга тәкъдим дә иттем, әмма барчасы да баш тарттылар,— дип җавап бирде аңа Габделмотталип.— Чөнки ул ятим бала!

Әмма Хәлимә сабыйны күрергә теләде. Габделмотталип аны Әминә ханымның йортына алып килде. Сөт анасы табылуы хакында хәбәр бирде. Хәлимәне Мөхәммәт йоклаган бүлмәгә чакырдылар. Сабый ак биләүгә төрелгән килеш ята иде.

— Баланы үземә күрсәтсәгез иде? — диде Хәлимә.

Мөхәммәтне аның кулына тоттырдылар. Хәлимә ханым аның битен ачты, сабыйның нурлы йөзле күркәм сыйфатлары аның күңелен яулап алдылар. Әмма Хәлимә ханым баланы калдырып китте.

— Мин, кайтып, ирем белән килешеп килим,— диде. Ул вакытта аның гаиләсе дә Мәккәгә килеп җиткән иде инде.

Хәлимә иренә барчасын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ире исә каршы килмәде.

— Ул баланы алыйк, тәрбия итәрсең,— диде.

Хәлимәгә баланы китерделәр. Сабый йоклый иде. Хатынның күңеле тынычланды. Бары тик Мөхәммәтнең сихри күзләрен сагынганлыктан, сабыйны уятырга булды. Күкрәген аның иркә иреннәренә тидерде. Мөхәммәт нурлы күзләрен ачып җибәрде. Күкрәген капты һәм имә башлады.

Хәлимә үзенең күкрәкләренә сөтнең тагын да мулрак төшүен тойды. Мөхәммәт аның уң ягыннан имде. Аннары Хәлимә аны сул ягына күчерде, сул як имиен аның иреннәренә якын китерде. Әмма Мөхәммәт аны капмады. Хәлимә гаҗәпләнмичә булдыра алмады. Янадан уң ягына салды. Сабый имине капты. Шул көннән башлап Мөхәммәт пәйгамбәр, сабый гына булса да, кеше өлешенә кермәде. Сул як ими сөтен Хәлимәнең үз баласына калдырды. Бу ике сабый һичвакыт бер-берсенең ризыкларын бутамадылар, берсен-берсе өлешсез итмәделәр. Хәлимә ханым аларны алыштырып караса да, сабыйлар аның ихтыярына күнмәделәр.

Шулай итеп, Хәлимә ханым Мөхәммәткә сөт анасы булды, аны үзләре белән алып китте. Сабыйны ул ихластан яратып, үз баласыдай күрә, үз нарасыйлары белән бергә иркәли иде. Бу хәлләргә Бәну-Сәгыйть кызлары бик тә гаҗәпләнә вә аптыраша иделәр.

Баланы Хәлимә ханымга биргәч, Габделмотталип аңа әйтте:

— И адәмнәр арасында булган күркәм бәндә, бу баланы үз кулыңа күтәреп, тәрбияңә алып, син үзең дә күркәмнәрнең күркәме булдың. Хак тәгалә сиңа озын гомер, тормышыңа бетмәс-төкәнмәс бәрәкәтләр бирсен. Күркәм бәшарәт[1] иясе булырсың,- диде.

Әминә ханым Хәлимәгә баласының асыл зат икәнлеген, тудырган чагындагы күргән хәлләре хакында бәян итте һәм:

— Моннан өч көн элек төш күргән идем. Бер зат килде дә сөйләде: минем улымны Бәну-Сәгыйть кабиләсеннән Әбу-Зәипкә нисбәтле бер хатын тәрбиягә алырга тиеш икән,— диде.

Хәлимә аның бу сүзләреннән соң балкып китте һәм дә:

— Мин, чыннан да, Бәну-Сәгыйть кабиләсеннән, атамның да кушаматы Әбу-Зәип иде,— дип куанычын белдерде. Шуннан соң Мөхәммәтне үз баласыдай күрергә, аны сакларга мең вәгъдәләр бирде. Әминә дә аңа үз ягыннан төрле киңәшләр әйтте.

Хәлимә ханым Мөхәммәтне ире янына китерде. Аңа икесе дә карап-карап сокландылар. Ире:

— И Хәлимә, күпме гомерләр яшәп, минем һичвакыт мондый да күркәм, мондый да затлы, мондый да сөйкемле адәмне күргәнем юк иде,— дип, куанычын белдерде. Ул аны үз баласыдай яратты.

Мөхәммәтнең Хәлимәләр йортына килүеннән соң иң беренче булган хикмәтләрнең берсе шул иде: аларның дөяләре сөт бирә башлады. Күпме савып та сөте бетеп тормады. Моны күреп торган хуҗа кеше:

— И Хәлимә, бигрәк изге бала алып кайткансың икән, бу кадәр дә нигъмәтләр белән күмде үзебезне. Без — мескеннәргә дә Алланың рәхмәте төшәр көн булыр икән,— дип сөенечләрен кат-кат белдерде.

Ул төнне йоклаган җирдән Хәлимә ханым уянып китә һәм Мөхәммәт ягына күз сала. Күрә ки, Мөхәммәтне бер якты нур әйләндереп алган, ә аның кырында бер яшел нурани кемсә утыра, сабыйның йокысын саклый икән. Хәлимә ханым тиз-тиз ирен уята, алар икәүләп бу могҗизаны гаҗәпләнеп күзәтәләр.

— Зинһар эчен бу турыда һичкемгә сөйли күрмә, юкса дошманнар каныгырлар, харап итәрләр! — дип үтенде Хәлимә иреннән. Моннан соң да мондый хәл кабатлана торды. Аларның гаилә рәхәтләре артты. Хәлимә исә, Мәккәгә барып, Әминәгә бу вакыйгалардан хәбәрләр бирде.

Тормышлары көйләнеп, Хәлимә ханым Бәну-Сәгыйть кызлары-хатыннары арасында иң дәрәҗәле вә хөрмәтле кешегә әйләнде ки, аларга дуслары соклана, дошманнары көнчелек карашы белән бага башладылар.

---

[1] Бәшарәт — кешелеклелек.

Хәлимә куйларының җиленнәре көтүдән сөт белән тулып кайтыр иде. Алар күзгә күренеп көрәйделәр. Бу хәлне Бәну-Сәгыйть кабиләсе дә игътибарсыз калдырмады. Көннәрдән беркөнне ике арада тавыш чыкты. Усал телле хатыннар көтүчеләрне якалап алдылар:

— Нигә безнең куйларыбыз, сарыкларыбыз Хәлимәнеке төсле көр түгелләр, нигә аның маллары имчәкләренә тутырып сөт ташыйлар, ә безнекеләр кибегеп йөри? — дип ябыштылар.

— Ни өчен аның сарыкларын аерып көтәсез, безнең дә малларны Хәлимә маллары белән йөртегез!

— Аның малларын гына уйсу, үләнле җирләрдә көтәсез, ә безнекеләрне начар җиргә куасыз,— дип, күп сүзләр булды.

Боларга каршы көтүчеләр:

— И хатыннар, монда безнең бер генә дә гаебебез юк. Хәлимәнең дә сарыклары сезнекеләр белән бергә утлыйлар. Ни өчен аныкын гына аерым көтик ди инде? — дип аптырашта калдылар.

Бу хәлдән соң кабилә кешеләре көтүчеләрне тикшерә-караштыра башладылар. Хәл һаман да элеккечә кала бирде. Барлык көтүләр белән Хәлимәнең дә куйлары бергә утлый иде. Монда көтүчеләрнең гаебе юклыгын кабилә халкы төшенеп алды. Аллаһы тәгаләнең иркендәге эш булып, кабилә бер дуслык-иттифакка килгәнлектән, талашып-сугышып тормаганлыктан, аларның барчасына да изгелек нуры төште. Аллаһы тәгалә үзенең мәрхәмәтен аларга да юнәлтте. Табыннарын нигъмәтле итте. Хәлимәне куйлар аркасында бимазалап тормасыннар өчен аларның да сарыкларын көр итте, кабиләне бәхетле итте.

Тарих китапларында шулай языла ки, Мөхәммәт ике айлык вакытында үрмәләп йөри башлады, дүрт айлык чагында аягына басты, диварга тотынып йөрде. Биш айлыкта инде ул аяк өсте һич ярдәмсез атлый иде. Алты ай вакыты җитте дигәндә ул йөгерә үк башлады. Җиде айда инде һәр тарафны аңлап-күреп таный, борылып карый, күзәтә, бутамыйча аера башлады. Ә сигез айлык вакытында теле ачылып, сөйләшер, теләгеннән хәбәрләрен бирерлек хәлгә килгән иде. Ун айлыгында башка малайлар белән ук атып уйнар иде. Ике яшендә ул инде сабыйлар рәтеннән булмыйча, тере, ут кебек бер малай иде.

Хәлимә ханымның Мөхәммәт пәйгамбәребез хакында истәлекләрен барлаучылар шулай дип язалар ки, сабый вакытында ук рәсүлебез Аллаһы тәгаләнең берлеген һәм Галәмнең хуҗасы булуын хәбәр иткән, бисмилласыз һич тә ризыкка тотынмаган икән.

Тагын да хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, Мөхәммәт бишектә ята икән. Ул вакытларда аңа бары кырык көн генә була әле. Бишек янына бер кемсә килә. Кабиләнең бер сагышлы кешесе була бу. Күрә, сабый бишектә уйнап ята һәм күктәге Ай белән сөйләшә, бармакларын-кулларын болгый; Мөхәммәт кайсы якка күрсәтсә, Ай да шул тарафка күчә икән. Бу кешенең шушы хәлләрне күреп, исе китә.

Әйтәләр ки, Мөхәммәт пәйгамбәрнең бишектә чагында күзеннән бер тамчы яшь тамган. Шушы күз яше җиргә төшүгә, барлык үләннәр яшел ут ялкынына күмелгәннәр. Шуннан соң билгеле булган, әгәр Мөхәммәт пәйгамбәребез җиргә күз яшьләрен күбрәк тамызса, кыяматкәчә бөтен тарафны ут каплап аласы икән...

## Бишектән төшкән чаклар

Мөхәммәт ике яшенә җиткәч, имидән аерыла. Бу вакытта инде ул дүрт яшьлек балаларга охшаш була. Сабый имидән аерылгач, Хәлимә ханым аны Мәккәгә, әнисе Әминә тәрбиясенә илтергә тиеш була. Әмма рәсүлнең кабилә эчендә яшәве халыкка күп яхшылыклар китергәнгә күрә, Хәлимә аны үзендә генә калдырып торырга да тели.

Бары тик вәгъдәләшкән сүздән чыга алмаганлыктан, ире белән киңәшеп, Мөхәммәтне Мәккәгә китерә.

Ике ана зарыгып очрашалар. Хәлимә исә Әминә ханымга барча хәлләрне сөйләп бирә:

— Синең улың кабиләбездә тагын бераз торсын иде. Мәккәнең һавасы эссе, кире үзем белән алып китәргә рөхсәт итегез,— дип гозерли.

Хәлимәнең ире Харисның да тиз генә шушы күркәм һәм нур иясе сабыйдан аерыласы килми. Хатынының теләге белән шунда ук килешә. Алар үтенгәч һәм Мәккә шәһәренең һавасы сабый бала өчен зыянлы да күрелгәнлектән, Әминә ханым, үзенең малаен бик сагынган булса да, тагын да беразга Хәлимә тәрбиясендә калдырырга ризалыгын бирә.

Хәлимә белән Харис, тәрбиядәге уллары Мөхәммәтне алып, киредән Бәну-Сәгыйть кабиләсенә таба юл тоттылар. Кайткан чакларында носарилардан, ягъни христианнардан булган бер төркем белән очраштылар. Тегеләр исә боларның кулларындагы баланы күреп алдылар һәм кат-кат аңа текәп карадылар. Араларында сүз чыкты, сораштыра башладылар.

— Сезнең улыгыз күз авыруы белән интегә булса кирәк, зарланганы юкмы? — диделәр.

— Юк, зарланмый! — дип җавап бирде Хәлимәнең ире.

— И бу угылның ата һәм аналары, бу балагызны безгә бирегез, без исә сезләрне байлыкка күмәрбез,— дип үтенә башладылар.— Безнең изге китабыбызда язылгандыр, җирдә бер генә пәйгамбәр калачак. Белүебез буенча, ул бала хәзер туган булырга тиеш. Бу пәйгамбәр сезнең балагыз булса кирәк, сыйфатлары туры килә,— диделәр.

Аларның бу сүзләреннән соң Хәлимә дә, Харис та хәвефкә төштеләр. Төн җиткәнен көттеләр һәм, барчасы йоклап беткәч, алар арасыннан чыгып, Бәну-Сәгыйть кабиләсенә таба ашыктылар.

Мөхәммәткә өч яшь тулды. Хәлимәнең үз уллары куй бәрәннәре көтеп йөри иделәр. Сөт анасы Мөхәммәтне башта абыйлары белән җибәрмәде. Мөхәммәт ялгызы гына өйдә калды. Иртән торган чагында ялгызын гына күрде. Хәлимәдән сорады:

— Минем абыйларым кая?

— Алар куй бәрәннәре көтәргә киттеләр. Көндез шунда булалар, кич өйгә кайтырлар,— дип җавап бирде Хәлимә. Мөхәммәт үзе дә абыйлары янында булырга теләде, сөт анисеннән шуңа кат-кат рөхсәт сорады. Шушы кадәр дә изаланып үтенүләрен Хәлимә кире кага алмады, көтүлеккә илтте. Күз тиюдән саклау, бозыклыкларга тармасын өчен дип, аның мөбарәк муенына бөти кидертте. Әмма бу Мөхәммәткә ошамады, аны салып ыргытты, Хак тәгаләгә тәвәккәл итте.

Көннәрдән беркөнне Мөхәммәт белән бергә имеп үскән Нәсим энесе янына килде. Аның берүзен генә иптәшсез күргәнгә, Хәлимә:

— Мөхәммәт улым кайда калды? Нишләп ялгызың гына килдең? — дип борчыла башлады.

— Ул — кырда, бәрәннәр янында,— дип җавап бирде Нәсим.— Ә аны һавадагы бер болыт эссе кояш яктысыннан саклап йөри, ул безнең кебек эсседән газап чикми,— диде. Улының бу сүзләре ананы тагын да көчлерәк хәвефкә калдырды. Әмма бу болыт кисәге Аллаһы тәгаләнең хикмәтләреннән берсе иде, хәвеф-хәтәр уйларлык урын юк иде.

Шушы рәвешле өч айлап вакыт узып та китте. Көннәрдән беркөнне Хәлимә янына малае Нәсим елап кайтты. Аның сулуы капкан иде. Ана бик тә борчылды, сорады:

— Сөйлә, ни булды? Нигә елыйсың?

Улы күз яше аралаш сөйли бирде, башта ни-нәрсә тәкърарлаганын төшенеп җитмәделәр. Ул бераз тынычлана төште.

— Бер йорт янында идек. Куйларны карап утырганда күктән ялтыравык яшел киемле ике кеше төште, алар безнең кораиш кардәшебезне

үзләре белән алдылар. Тау башына китерделәр. Пычак белән эчен ярдылар. Кемнәр икәнен белмәдек, күргән кешеләребез түгел иде,— диде.

Аның бу сүзләреннән соң Хәлимә белән иренең котлары очты.

— Ни гомереңне елап үткәрдең, нигә килеп җиткәч тә әйтмәдең?— дип улларын орыша-орыша Мөхәммәтне эзләп чаптылар. Алар килеп җиткәндә тау башында Мөхәммәт сау-сәламәт утырып тора иде.

— И нур иясе балам, сөйлә, ни булды?—дип Хәлимә, аның йөзен-башын үбеп, кочагына алды.— Сине кем рәнҗетте?

Мөхәммәт әйтте:

— Ишектән чыккан төсле кинәттән ике кемсә күренде. Көмештән киенгәндәй иделәр. Берсенең кулында комган, икенчесенең кулында яшел ләгән иде. Эчендә кардан да аграк бер нәрсә тутырылган иде. Мине арадан табып алдылар. Тау башына китерделәр. Аркама яткырдылар да бүксәмне ярдылар. Мин күреп тордым. Һичбер авырту-әрнү сизмәдем. Алар исә эчемдәге бар әгъзаларымны алып, шул ләгәнгә салып юдылар, киредән үз урынына куйдылар. Аннан соң икенчесе мине торгызды. Үз эшемне башкарам дип, күкрәгемнән йөрәгемне чыгарды. Аны сыкты. Эченнән бер тамчы кара кан чыкты. Аны читкә ташлады. «Бу—синең эчеңдәге Шайтан коткысы иде, аны ташладык»,— диде. «Сине Шайтаннан һәм вәсвәсәдән имин иттек»,—дип йөрәгемә үзләре белән булган комганнан ниндидер ак әйбер тутырдылар, аны урынына куйдылар. Бернинди авырту да тоймадым, киресенчә, рәхәтлек вә йомшаклыктан башка һичнәрсә дә булмады. Шуннан соң алар миңа хәвефсез яшәргә, борчылмаска куштылар. Үзләре, күк капкасын ачып, шуннан кереп киттеләр!

Аның бу сүзләреннән соң Хәлимә белән ире Мөхәммәтне йорт эченә китерделәр. Бераздан абыйлары янына чыгарга рөхсәт иттеләр. Хәлимә, балалары киткәч:

— Йә, ни диярсең? Бу баланы исән-имин чагында әнисенә илтеп бирергә кирәктер, аның өчен бик тә хәвефләнәмен,— диде.

Хәлимәнең ире Харис әйтте:

— Әйе. Моннан да күркәмрәк изге бала кабат тумас. Беләсең, ул килгәнче хәлебез бик начар иде. Кабиләдә бездән дә фәкыйрь кеше юк иде. Инде менә мең шөкер, ул бездә тора башлаганнан бирле байлыгыбыз артты. Кабиләдә иң бай кешеләр рәтендә йөрибез. Куйларыбыз да өч йөздән артып китте. Безгә дә бәхет инде. Шул сәбәптән башкалар безгә хөсетлек итәрләр дип, мин дә куркам. Бар борчуларым шушыдыр,— диде.

Бу сүзләрдән соң Хәлимә Мөхәммәтне берәр күрәзәчегә илтеп карарга булды. Килде. Күрәзәче кемсә сихер иясе иде.

— Башта аның турында барчасын сөйләгез,— диде ул.

Хәлимә һәммәсен бәйнә-бәйнә хәбәр итте. Аның ул сүзләрен ишеткәч күрәзәче:

— Бу бала үсеп җитәр, сезнең потларыгызны бетертер, яңа дин китерер. Әгәр аны үтермәсәгез, динегезне корытыр, сезне башка дингә өндәр,— диюгә, Хәлимә Мөхәммәтне үз кочагына алды:

— Болай әйтәсеңне белгән булсам, монда килмәгән дә булыр идем. Бу сүзләрең өчен синең үзеңне катил итсеннәр,— диде дә яшәгән җирләренә кайтып китте.

Моннан соң кабилә хатыннары Хәлимәдән Мөхәммәтне Мәккәгә илтеп куярга сорадылар.

— Куркабыз, өстебезгә бу хәлләрдән соң бер-бер бәла килергә бик мөмкин бит!—диделәр.

Аларның ошбу сүзләреннән соң Хәлимә ханым курка калды. Мөхәммәтне күкрәгенә сыендырды. Аңа һичкемне якын җибәрмәде, үзеннән бер адым да читкә куймады. Әмма болай яшәү мөмкин түгел иде. Аны үзе белән алып, Мәккә шәһәренә килде. Мөхәммәтне дусларына

куйды, үзе киңәш-табыш итү өчен китте. Бераз җир үтүгә, тавыш ишетеп, кабат кайтты. Мөхәммәтне күрмәде.

— И кешеләр, монда бер баланы күрмәдегезме, югалттым булса кирәк? — дип белешә башлады.

Аннан:

— Кем баласы иде? — дип сорадылар.

— Габделмотталипныкы иде. Мин аны җаным кебек саклап, шәһәрегезгә китердем. Инде менә аны югалттым. Таба алмасам, җанымны да кызганмам. Тауга менеп ташланырмын, гәүдәм-тәнем парә-парә килеп ваклансын,— диеп, зар кылды Хәлимә. Әмма мәккәлеләр аның ул сүзләренә әллә ни игътибар итмәделәр.

Хәлимә башын тотты. «И Мөхәммәт, и Мөхәммәт!» — диеп елый башлады. Шунда аның янына бер карт кеше килде, сорады:

— И кем, ни кайгың бар? Нигә бу кадәр газап чигәсең?

— Ибраһим өммәте өчен әйт,— диде Хәлимә,— Мөхәммәт исемле баламны югалттым. Бик кадерлем иде. Әгәр таба алмасам, миңа таудан ташланып, җанымны кыярга кала!

— И Хәлимә, син минем Һабил исемле сыныма бар. Ул сиңа аның кайдалыгын әйтер,— диде бу карт.

— Бармыймын, Мөхәммәт туганда ул сының йөзе илән капланып төште,— диде аңа Хәлимә.

— И хатын, син диванасың,— диде аңа карт.— Ул чагында мин үзем барып сорыйм.

Аның артыннан Хәлимә дә иярде. Сорадылар.

— Һич ни-нәрсә белмибез, без белгәнче, аның бабасы Габделмотталип алдан сизеп өлгерә. Аны изге Тәңре саклый,— диделәр потлар.

Хәлимә Габделмотталип янына килде. Аңа елый-елый барча эшне аңлатып бирде. Бу сүзләрне ишетүгә, Габделмотталип кылычын айкады.

— Корәишләр минем сөекле улыма тимәсләр, башка бер кемсәләр аны тотып, харап итмәсеннәр! — дип Мәккә халкына хәбәр салды. Аның сүзе сүз булды. Мәккәлеләр атларына атландылар, кылычларын кыннарыннан чыгарып, төрле тарафларга чаптылар. Берсеннән дә хәбәр кайтып ирешмәде.

Габделмотталип Кәгъбәтуллага барды, мөнәҗәтләрен әйтте. Шулвакыт аваз ишетелде, хәбәр килде:

— Сөекле Мөхәммәт мәвез (ягъни, банан) агачы янындадыр!

Габделмотталип атына атланып, мәвез агачы янына чапты. Килеп җитте, оныгын исән-имин күрде. Ул кулына мәвез агачының яфракларын тотып тора иде.

Сорадылар:

— Кем син, нишләп монда торасың? — дип.

Мөхәммәт аларга нурлы йөзләрен балкытып карады да:

— Мин — Мөхәммәт бине Габделмотталип,— диде. Бабасы, бу сүзләрне ишетүгә, күңеле эреп, аны кочагына алды, атына утыртты, өенә алып кайтты.

Шушы хәлдән соң Хәлимәне Әминә белән Габделмотталип, зур бүләкләр биреп, үз кабиләсенә Мөхәммәт пәйгамбәрдән башка гына озатып җибәрделәр. Шулай итеп, пәйгамбәребезнең Бәну-Сәгыйть җирләрендәге тәрбиясе тәмам булды.

Тагын шулар билгеле булсын: Мөхәммәт пәйгамбәргә дин иңгәннән соң, Бәну-Сәгыйть кабиләсеннән беренчеләрдән булып исламга кергән кешеләр дә шушы сөт анасы Хәлимә ханым һәм аның ире Харис бине Габделгази иделәр. Ул вакытларда инде уллары Габдулла һәм Замрә белән Мәлкабә кинәт килгән үлемнән вафат иделәр. Әмма Мөхәммәтнең сөт карендәше Нәсим исән иде, ул да Хәлимәнең кыз карендәше Хизамә белән дин исламны кабул иттеләр. Барчасы да данлыклы сәхабәләрдән булдылар.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам алты яшенә җитте. Көннәрдән беркөнне әнисе Әминә ханым аны Мәдинә шәһәренә алып китте. Анда аның атасы күмелгән иде. Алар белән бергә Өмме-Имин дә килде.

Мәдинә шәһәре бай сәүдәгәрләр каласы булып, монда яһүди дә, гарәп тә, башкасы да бар иде. Мөхәммәт шәһәрдә үзе дә сәүдә эшен күзәтте, сату-алу шөгыленә өйрәнде, сәүдә кәрванын йөртү ысулларын күрде. Мәдинәдән берничә сәүдәгәр аны үзе белән алдылар, сату-алу иттеләр. Бу йөрүләрендә Мөхәммәтнең пәйгамбәрлеге ачыкланды. Аларга яһүдиләр очрадылар һәм үзара болай сөйләштеләр:

— Күрегез, моның бөтен сыйфатлары Ахырзаман пәйгамбәре тасвирына туры килә. Бу бала Ахырзаман пәйгамбәре булса кирәк!

Аларның бу сүзләрен Өмме-Имин ишетеп алды, хәвефкә төште. Яһүдиләрнең зыян-җәбер итүләреннән курка калды. Кайтып җитүгә, бу хакта Әминәгә бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бу хикәятен ишетүгә, Әминә кәрванны кузгатты. Алар Мәккәгә таба кайту юлына төштеләр. Ара якын түгел иде. Ни сәбәп, Әйва дип аталган җиргә җиткәч, Әминә ханым бик каты авырый башлады. Кәрванны туктатырга мәҗбүр булдылар.

Мөхәммәт исә һушсыз калган әнисенең башын тезләренә куеп елый иде. Ул ара Әминә ханым аңына килде. Телен тибрәтеп, берничә бәет укыды. Улының күркәм йөзенә багып торды һәм:

— Терек булган кеше үлмичә калмас, һәр яңа кием искерми тормас, әгәр мин үлсәм, исемем үлмәс, чөнки бер бөек пакъ затны тудыручымын,— диде дә вафат булды.

Әминәне шушы урында күмделәр. Хәбәрләргә караганда, Мөхәммәт пәйгамбәр инде данлыклы булган чагында әнкәсенең каберен күрергә бу тарафларга килде. Әмма урынны таба алмадылар. Аптырашта калган халыкның хәле мөшкел иде. Шул чагында пәйгамбәрнең каршысында ташлар елый башлады. Һәркем моны күреп алды, белделәр ки, Мөхәммәт галәйһис-сәламнең күркәмнәрдән-күркәм әнкәсе шушында жирләнгән! Бу урында берничә таш кабер рәвешен алып тора иде.

Мөхәммәт Мәккәгә Өмме-Имин белән кайтты. Юллары хәсрәт тулы иде. Өмме-Имин аны бабасы Габделмотталипка китерде. Мөхәммәт пәйгамбәр алты яшендә тулы ятим килеш, бабасы тәрбиясендә калды.

Мөхәммәт пәйгамбәргә җиде яшь булганда Габделмотталип аны алып, Йәмән иленә сәүдә белән киткән иде. Ул елларда Мәккәгә яңгыр яумады, барлык үлән вә агачлар тамырдан корыдылар. Эсседән халык гаҗиз иде. Бер кичне Мәккәнең мөхтәрәм карчыкларыннан берсе төш күрде. Төшендә тавыш ишетте. Имеш, Мәккәдә корәиш арасыннан бер пәйгамбәр бар икән. Ул кемсә калку буйлы, ак тәнле, күркәм йөзле, озын керфекле икән. Әгәр аны саф тәһарәт алдырып, Кәгъбәне җиде кат әйләндереп, Әбу-Кабис тавына китереп, яңгыр соратып дога укытсаң, «амин» диюенә, җир суга туеначак икән.

Бу карчык күргән төшен шәһәр халкына җиткерде. Ул көнне Йәмәннән Габделмотталип кайтып төшкән иде. Халык җыелышып аңа килде һәм аны төштәге зат дип белде. Аны иңнәренә күтәреп, Кәгъбәне җиде кат әйләндерделәр дә, Әбу-Кабис тавына китерделәр. Дога укырга куштылар. Габделмотталип Мөхәммәтне кочагына алды. Догасын кылды. Мөхәммәт «амин» диюгә, күктән ишелеп яңгыр ява башлады. Барлык халык Габделмотталипны пәйгамбәр дип танып ялгыштылар. Асылда Мөхәммәт галәйһис-сәламнең хикмәтләреннән иде бу. Бабасы моны бик яхшы белде.

Яңгыр туктаусыз койды. Мәккә урамнарыннан гөрләвекләр ташып акты. Урамның бер ягыннан икенчесенә чыгу да мөмкин түгел иде.

Erganakka кеше-фәлән төшсә, яңгыр суы аны да агызып китә иде. Бу хәлләрне Нух пәйгамбәр туфаныннан бирле Мәккәнең күргәне булмагандыр.

Габделмотталип Мөхәммәтне яхшы бала итеп үстерде. Аның йоклаган җиренә һичкемне кертмәде, урынына башка берәүне утыртмады. Хәтта Өмме-Иминнән дә нарасыен уяттырмый иде.

Бу тарафларда китап кадерен белүче галим кемсәләр дә бар иде. Алар Мөхәммәтне күзәтеп тордылар. Көннәрдән беркөнне бабасы Габделмотталип янына килделәр һәм:

— Бу сабыйдан да күркәмрәк баланы очратканыбыз юк. Аның аяк атлауларына кадәр Ибраһим галәйһис-сәламнең йөрешен хәтерләтә,— дип сөйләнделәр.

Бу вакытта Габделмотталип катында Әбу-Талип та бар иде. Аңа карап:

— Ишетеп тор, бу җәмагать ниләр сөйли! — диде аңа Габделмотталип.

Риваятьләрдә болай сөйләнелә ки, шушы хәлдән соң Әбу-Талипның мәхәббәте Мөхәммәт пәйгамбәргә төште һәм аңа һәрдаим хөрмәтләрен күрсәтә башлады, барча улларыннан да аны олуграк күрде, дәрәҗәле исемнәр белән атады, падишаһлар рәтеннән йөртте.

Көннәрдән беркөнне Габделмотталип үзенә кардәш-ыру тиешле кемсәләрне җыйнады.

— И кардәшләрем,— диде ул,— бу дөньядан киткәндә бердәнбер хәсрәтем кала. Ул да булса, Мөхәммәт оныгым. Минем аннан да кадерле балам юк иде. Кулларымда иркәләп үстердем. Мин киткәч, аның тормышлары авырайmasын иде дип хафаланам...

Арада Әбу-Ләһәп тә бар иде. Габделмотталипның ошбу сүзләреннән соң беренчеләрдән булып ул телгә килде һәм:

— Сөйләгәнегез Мөхәммәт хакында икәнлекне дөрес төшенгән булсак, һич тә кайгы-хәсрәттә булмагыз. Бу хезмәтне үз җилкәмә алырмын, аның өчен малымны да, җанымны да кызганмамын,— диеп, тез чүкте.

— Синең байлыгың зур, мал-мөлкәтең дә ару, әмма мәрхәмәтең аз булганга, бу ятим баламны сиңа һич тә тапшыра алмыйм,— дип Габделмотталип аңа туры җавап кайтарды.

Һашимилар нәселенең мөхтәрәме бу сүзләрне әйткәннән соң каршы сүз сөйләүгә җаваплаnмыш кеше җөрьәт итмәде. Ул арада Хәмзә килеп тезләнде.

— Бу хезмәтне миңа насыйп ит?! — дип сорады.

— Синең күңелең дә яхшы, күркәмлегең дә бар, әмма балаларың юк. Үз баласы булмаган бәндә ятимне камил рәвештә тәрбия итә алмас, аның тәрбиясенең һич югы бер ягы китек булыр, тапшыра алмыйм,— дип җавап бирде Габделмотталип.

Кабилә җитәкчесенең шушы сүзләреннән соң Габбас калыкты, дога һәм мактаулар укыды һәм:

— Әгәр бу хезмәткә мине лаек кылсаң, җанымны да шушы эшеңә багышлыймын,— дип үтенде.

— Син бу эшкә лаек кеше, әмма балаларың бик күп, баласы күп булган кемсәнә берсен генә аерым тәрбия итә алмас,— диде аңа һашимиларның карты.

Шул җаваптан соң Әбу-Талип урыныннан купты.

— Мин арадан иң таләпчән кешемен,— диде ул җайлап кына,— әмма үземнән өлкәннәр сүзләренә җавап алмый торып, алардан уза алмадым. Байлыгым да туганнарымнан кайтышрак булыр, яхшылыкларым да аларга караганда кимрәктер, әмма бу изге эш миңа тиеш булса кирәк.

Аның фикерен Габделмотталип тыныч кына тыңлап торды. Җавап өчен сүз айгырын чаптырмады. Ашыкмавыннан һәркем гаҗәпсенеп калды.

— Бу эшкә иң лаеклы кеше син, моны әйтмичә калып булмый,— диде ул көттереп кенә.— Әмма бар эшемдә дә мин Мөхәммәт улым белән киңәшеп торам, бу очракта да аның үзеннән сорамыйча булдыра алмамын,— дип оныгын чакыртты. Аңардан:

— Бу кешеләрнең кайсысын сайларсың?— дип сорады.— И күзем нуры, синең хәсрәтеңдә янамын, кайсысын кабул итәрсең?— дип тә өстәде. Бабасының шушы сүзләреннән соң Мөхәммәт пәйгамбәр Әбу-Талипның муенына барып үрелде, аны кочаклап алды, тезенә менеп утырды. Шуннан соң Габделмотталип:

— Мең шөкерләр булсын, минем теләгем белән улымның сайлаган кешесе бер булып чыкты,— дип сөенде һәм, Әбу-Талипка карап, болай диде:

— И Әбу-Талип, бу ятимнең кемнәр кулында тәрбия алганын беләсең, аның хакында сөйләгәннәремне дә ишеттең. Аны җаның кебек кадерле күр. Син аның атасы белән бер анадан туган кешесең. Бу — изге бала. Әгәр дә аның үсеп җиткәнен, башкарган эшләрен күрсәң, сүзләремнең хаклы булуын белерсең. Әгәр дөрес кеше икәнсең, аңа хөрмәтле булырсың, эшләрендә ярдәм итәрсең. Сүзеңне кабул иттем,— диде.— Моннан соң миңа гүргә керүе дә ансат вә җиңел булыр,— дип белдерде.

Бу мәҗлестән соң Габделмотталип фани дөньядан мәңгелеккә китте. Аның вафаты Мәккә халкын тетрәндерде. Аны шәһәр зиратына җирләделәр. Бу вакытларда аңа, китапларның бәяненә караганда, йөз дә ун яшь иде. Икенче бер язмаларда, Габделмотталип йөз дә егерме яшендә вафат дип белдерәләр. Ни генә булмасын, ул озын гомерле адәмиләрдән иде. Мөхәммәт инде сигез яшенә җиткән малай булып, бабасының үлемен бик авыр кичерде.

Вәгъдәсенә күрә, Әбу-Талип Мөхәммәтне үз янына алды. Аны һичкемнән кимсеттермәде, сораган әйберсен табып бирде, төннәрен үзе белән бергә кочагында гына йоклатты.

Риваятьләрдә шулай килә ки, Мөхәммәт пәйгамбәрдән алда һичкем ризыкка кулын сузмады. Барчасы аны көтте. Мөхәммәт табыннан ашамлык алып капса, ризык тәмам туклыклы булып китә, барчасының бердәй тамаклары туя иде. Әгәр инде аннан узып берәрсе уртак азыктан сынык алса, ашамлыклар да үпкәләп, тәме вә таты кими, бөтенесе дә табыннан торып киткәндә ризык капчыкларының буш икәнлеген тоя иделәр.

— Бу бала — минем бәхетем!— дип Әбу-Талип әйтә иде. Тагын да ул болай дип сөйли иде:

— Сахрада идек. Бик сусадым. Эчәсем килде. Бу хәлемнән Мөхәммәткә хәбәр бирдем. Ул тезләренә утырды. Аның үкчәсе астыннан чишмә саркып чыкты, аннан эчеп, сусавым тәмам басылды,— дия иде.

Шулай итеп, Мөхәммәтне тәрбия итү Әбу-Талипка авыр йөк булмыйча, шатлык вә җан рәхәтлеге алып килде. Бу сөенече белән ул бик тә горурлана иде. Шам тарафына барганнан соң Әбу-Талипның Мөхәммәт өчен җаваплылык тойгысы тагын да артты. Ул вакытларда пәйгамбәребезгә, кайбер китапларда әйтелгәнчә, ун яшь чамасы иде. Монда бер хикмәтле хәл булды. Аның хикәяте бу рәвешле:

Мәккәдә потлары арасында иң олуг вә зурысы — «Бувәнә» дигәне бар иде. Аның каршына барча кемсәнә килеп, баш орып, ихлас күңелдән табына иделәр. Бувәнәнең халык арасында дан-шөһрәте зур булып, алдына туктаусыз кәрван-кәрван юлчылар килгәннәр. Барчасы кулларын сузып, теләкләрен теләгәннәр, ярдәмен үтенгәннәр. Бу сынның гәүдәсе гаҗәеп зур булып, кешеләрнең инануы өчен төп таяныч икән. Бувәнә каршында Әбу-Талип зур сәүдә алдыннан һәм уңышлы эшләреннән соң табынырга яраткан. Мәккәлеләр аның янында көннәр буе китмичә торганнар. Ә беркөнне Әбу-Талип бу сын каршына Мөхәммәтне чакырган. Әмма пәйгамбәребез аның әмеренә буйсынмаган, табынудан баш тарткан. Әбу-Талипның моңа бик тә ачуы килгән, үзенең ни эшләгәнен белмичә, Мөхәммәтне орышып та ташлаган. Кулыннан җилтерәтеп,

шушы сын каршысына китереп бастырган. Әмма Мөхәммәт аңа табынудан һаман да баш тарткач, аптыраган Мәккә кешеләре:

— И юньсез бала, ни-нәрсә кылануың бу? — дигәннәр. Аларга каршы Мөхәммәт пәйгамбәребез:

— И халык, бу потка табынуда бик зур хәвефлегем бар, — дип җавап биргән.

— Әйт, ни хәвефең бар? — диюгә ул:

— Бу пот каршысына килеп басуыма, арага олы гәүдәле зат үзен куя һәм миңа: «Йә Мөхәммәт, бу потка кулыңны сузып табынма һәм һич тә боларның бәйрәменә катышма!» дип кычкырып әйтә, — диеп җавап бирде.

Моннан соң аны бу потка табынырга мәҗбүр итмәделәр.

Мөхәммәт пәйгамбәрне Әбу-Талип унике-унөч яшьләренә кадәр Мәккәдән читкә алып чыкмады. Сәүдәгәр булса да, эшен үз шәһәрендә генә йөртергә тырышты. Ә Мөхәммәт исә, агасы хезмәт белән мәшгуль булганда, үзе кебек үк балалар белән урамда уйнап йөри иде.

Тагын да шул билгеле, Мөхәммәт бала вакытында ук ялган сөйләүнең, кешене кимсетүнең, үчләшү, усаллык кылу кебек яманлыкларның ни-нәрсә икәнлеген дә белмәгән. Арада ул үтә дә намуслы һәм тәртипле булуы, олыларга — хөрмәт, сабыйларга игътибар күрсәтүе белән аерылып торган.

Ниһаять, унөч яше җиткәндә, Әбу-Талип Мөхәммәтне үзе белән Шам сәфәренә сәүдәгә алып киткән...

## Пәйгамбәребезнең үсмер чагы

Мөхәммәтнең унике яшь тә ике ай вә ун көнлек чагы иде. Әбу-Талип сәүдә кәрваны белән, бер төркемгә кушылып, Шам тарафына сәфәр итте. Ул юлга чыгар алдыннан Мөхәммәт пәйгамбәр үзен дә ияртүен үтенеп килде. Әмма Әбу-Талип:

— Мин бергә баручы корәиш иптәшләремнән сорадым, алар унике яшьлек баланы мондый сәфәргә алуны бер дә өнәмәделәр, — дип җавап бирде.

Әмма Мөхәммәт күзләреннән энҗедәй яшьләрен коя башлады. Елап утырган баланы күреп, Әбу-Талипның йөрәге кузгалды.

— Бу баланың үтенечен ничек итеп кире кагасың инде?! — диде дә аптырашта калды. — И улым, бәлки минем белән аерылуны уйлап шулай елыйсыңдыр?

Әбу-Талип чарасыз калды. Сәүдәгәрләр белән киңәшеп, аны үзе белән Шам тарафына алып барырга булды. Юлга чыктылар.

Килә-килә, Басрадан алты мил чаласы ераклыкта булган бер сумгага, ягъни монастырьга якынлаштылар. Бу сумгада дине буенча Изге Грегорьянга пәйгамбәр итеп карауч — Журжис — бер габит-монах бар иде. Аның исеме Бәхирә[1] булып, ул бик тә озаклап Аллага табынырга ярата иде. Бу кемсәнә изге китаплардан укып белде: җиргә Ахырзаман пәйгамбәре иңәргә тиеш! Ул хәтта бу иңәчәк изгенең асыл сыйфатларын да белеп куйды. Һәр үткән-сүткәннән ул сыйфатларны тикшереп-карап бакты.

Бу сумга янышнан сәүдәгәр корәиш кәрваннары үтеп-сүтеп йөри иделәр. Әмма монахлар һичкайчан ул мәҗүсиләргә капкаларын ачмадылар, кадер-хөрмәтләрен күрсәтмәделәр.

---

[1] Бәхирә — Журжис (Жорж) бине Искәндәр (Александрович), Гайсә пәйгамбәрнең Аллаһы тәгалә «улы», ягъни илаһи зат булмыйча, пәйгамбәр генә икәнлеген танучы нистур-носари христианы, монах. Сихерчелектә гаепләнеп, «Турсина» монастырена куылган. Аннан соң үзенә сумга төзетеп, шунда яшәгән. Яһүдиләр тарафыннан китаплары яндырылган, соңыннан үзе дә һәлак ителгән.

Ерактан Әбу-Талипның кәрваны килгәнен Әбу-Гадас габиде алдан ук күреп алды. Исе китте: кәрван өстендә бер кечкенә болыт кисәге алардан калмый иде. Кәрван кая борылса, болыт та шул якка авыша, кәрван кайда тuктаса, болыт та шунда туктый иде. Бу хәлне монах игътибар күзеннән ычкындырмады.

Кайбер риваятьләрдә сөйләнәлә ки, Бәхирә агачларның һәм ташларның сүзләренә колак салды. Алар:

—Әссәламегаләйкем йә рәсүллуллаһ!.. Сәлам сиңа, Алланың илчесе! —дип исәнләшә иделәр.

Кәрван сумга-монастырь янына килеп туктады. Сәүдәгәрләр гадәтләре буенча бу кичне шушында уздырдылар. Агасы Әбу-Талип белән Мөхәммәт бер корыган агач төбен сайладылар. Болыт исә Мөхәммәттән калмады. Агач ботакларына уралып, аларны күләгәләп торды. Иртәгесен бу агач яшәргән иде. Аның яшел яфраклары акрын гына искән талгын саба җилендә тибрәнештеләр. Бу хәлләрне күреп торган Бәхирәнең чарасы калмады, эче янды. Сумга капкасыннан алар янына таба китте. Барысының да гаҗәпләнүенә, каршы килеп, Мөхәммәтнең кулларыннан тотты һәм:

— И кешеләр, белеп торыгыз, бу бала — пәйгамбәрләрнең олысы һәм өлкәне, Аллаһы тәгаләнең ятраткaны булыр,— диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр бу монахның шушы рәвешле сүзләреннән бик тә гаҗәпсенде һәм сорады:

— Син моны нидән белдең? — дип.

— Кәрваныгыз монда килгәндә ничәмә таш вә агач сиңа сәҗдә итте, үзеңне сәламләп каршы алдылар. Ул гына да түгел, моннан башка да бик күп галәмәтләрне күрдем,— диде. — Алар барысы да синең пәйгамбәрлегеңне кат-кат дәлил итәләр. Инде сүземне кабул кылып, торган йортыбызга үтсәгез, без бик шат булыр идек,— диде.

Аның бу сүзләрен һәм чакыруларын Әбу-Талип һәм иптәшләре кабул иттеләр, сумга капкасыннан эчкә үттеләр. Билгеле ки, бу монастырьны «Әбу-Гадас» дип атап йөртә иделәр.

Бәхирә барчасын кунак итте. Сыйландылар. Ашаган чакларында һаман да игътибарын Мөхәммәткә юнәлтте. Күрде: Әбу-Талип бу баланы бик якын итә, хөрмәтен һаман белдереп тора.

— Бу үсмергә һәрдаим игътибар иттең, әллә бу синең улыңмы? — дип сорады аннан Бәхирә.

— Әйе, бу минем улым,— дип җавап бирде аңа Әбу-Талип.

— Минем белүемчә, аның әнкәсе дә, бабасы да юк инде,— диде аңа Бәхирә.— Дөресен сөйлә?!.

— Хактан да шулай, ул минем туганымның баласы,— дип Әбу-Талип тугры җавабын бирмичә кала алмады.

— Минем соравым белү өчен генә түгел, имтихан итү өчен дә. Хак сөйләсәң иде? — диде аңа габид.

Бу сүзләрне ишетүгә, Мөхәммәт пәйгамбәр:

— Алардан сорама, миннән сора. Тугры җавабымны алырсың,— дип әйтеп салды.

Бәхирә аңа имтихан өчен сорауларын бирә торды, Мөхәммәттән хак җавапларны алды.

— Оеп йокларсыңмы? — дип сорады Бәхирә.

— Күзләрем оер, әмма калебем оемас,— дип җавап бирде аңа Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Күзләреңдәге бу илаһи сөрмә һаман да торырмы, әллә коелып төшкәне дә бармы? — диде Бәхирә.

— Аның коелганын белгәнем булмады. Һаман да саклана дип беләмен,— диде җавабында рәсүл.

— Синдә Аллаһы тәгаләнең мөһер галәмәте бармы? — диде өченче соравында имтиханчы. Мөхәммәт пәйгамбәр, Әбу-Талипка мөрәҗәгать итеп, күлмәген күтәртте, аркасы ачылды. Уртада бер ит кисәге калкып

тора иде. Аллаһы тәгаләнең мөһерен барысы да күрделәр. Бәхирә бу мөһерне үбеп алды, күзләреннән яшьләре тәгәрәде һәм:

— Бу мөһер — синең Алла илчесе булуыңа дәлилдер. Аллаһы тәгаләнең илчесе булуыңа шаһит булдым,— диде.

Корәишләр дә бу хәлләрне белделәр. Мөхәммәтнең изге зат булуын таныдылар. Бәхирә габид — Әбу-Талипка:

— Бу — пәйгамбәрнең иң соңгысыдыр, аның шәригате бөтен Җир шарына таралыр, аның дине башкалардан өстен чыгар. Бу угланны син Шамга алып барма, яһүдиләр аңа дошманнар. Бер-бер зарар итәрләр. Алар аны тиз таныррлар, белми калмаслар,— диде.— Гайсә пәйгамбәргә ирешкән китаптан Ахырмазан пәйгамбәре хакында хәбәрләр килгән иде, баланы золымнан сакла,— дип нәсыйхәтләрен бирде.

Риваятьләрдә төрлечә сөйләнелә ки, Бәхирәнең шушы сүзләреннән соң Әбу-Талип үзенең сәүдәсен тәмам итте һәм Мөхәммәтне Мәккәгә алып кайтты. Икенче бер урында Әбу-Талипның Мөхәммәтне дөягә атландырып, туган шәһәренә кайтарып җибәрүе, ә үзенең Шамга китүе хакында сөйләнелә (Мөхәммәт Мәккәгә Әбу-Бәкернең колы Билал белән бергә кайткан дигән хәбәрләр дә бар). Ни генә булмасын, бу сәфәрдә Мөхәммәт пәйгамбәр Шам базарына барып керә алмады, борылып Мәккәгә кайтты. Ә Шамдагы яһүдиләр Ахырзаман пәйгамбәренең үз илләренә киләчәге хакында алдан ук белеп куйган иделәр. Аны харап итү өчен әзерлекләр күрделәр. Өч кешене яллап, Әбу-Гадас сумгасына җибәрделәр. Алар килгәндә Мөхәммәт монда юк иде.

Бу өч башкисәр сумга габиде Бәхирәнең үзләренә ярдәм күрсәтүен таләп иттеләр.

— Шушы вакытларда Ахырзаман пәйгамбәре килеп чыгар, аны катил итеп үтерү нияте белән монда килдек, син дә безгә кушылырсыңмы? — дип сорадылар.

Аларның ошбу сүзләре Бәхирәгә һич тә ошамады:

— Пәйгамбәрне үтерү — талаш-ызгышлар гына китереп чыгара, асылда, сез аңа һичбер зыян итә алмассыз, әмма яман ниятегез ачыкланыр, тәмугълы булурсыз. Бу уегыздан кире кайтыгыз, гөнаһсыз сабыйны үтерүдән яманрак һичбер эш дөньяда булмас,— дип, бу юньсезләргә вәгазьләрен укыды, үтенечләрен кылды. Болар исә, ни хикмәт, акылга килделәр, уйлаган эшләренең асылы яман икәнлекне аңлап алдылар һәм тәүбә иттеләр. Шуннан соң калган гомерләрен Бәхирә белән бергә кичерделәр. Әбу-Талип та Мөхәммәтне башка Шам ягына сәфәргә алмады. Васыятен исеннән чыгармады, сөеклесен күз карасыдай саклады.

Асылда бу вакыйга Мөхәммәтнең үсмер чагында булган иң олуг вакыйгаларның берсе иде. Аны соңыннан да корәишләр исләренә төшерделәр. Рәсүлебезнең пәйгамбәрлек сыйфатларын бәйнә-бәйнә билгеләп бирүче кешеләрнең берсе исә һәм беренчесе, һичшиксез, Әбу-Гадас сумгасы габиде Бәхирә иде.

Тарих китапларында сөйләнелә ки, бу вакытларда Мәккәдә гөнаһ эшләр, бер-берсен үтерүләр булгалап торды. Бер хикәяттә шундый хәбәр бар: Мәккәдә халык бик тыйнак һәм кунакчыл булганга, алар арасына төрле кабилә кешеләре килеп йөргәннәр. Әмма бер хатын фәхишәлек белән ирләрне аздыра башлаган, имеш. Ул үз янына берничә егет кемсәне дәшеп, аларга үзенең гаурәт җирләрен ачкан. Аннан соң кабиләсенә кайтып зарланган. Бу кабилә ирләренең ачулары кабарган. Алар Мәккәгә килеп, ызгыш-талаш оештырганнар. Нәтиҗәдә, берничә кеше харап булган. Әмма шәһәр халкы кан коюны туктатып кала алган. Үчләшү тирәнгә җәелмәгән.

Мондый орыш-талашлар төрле нәсел-гаиләләр арасында да булмый тормаган. Гарәпләр арасында кан өчен кан белән җавап бирү төп кануннардан саналган. Кем дә кем берәүне үтерсә, үтерелгән кешенең туганнары кан коючыдан үч алганнар. Үз чиратында, болары да кылычка ябышкан. Шулай итеп, золымның чиге югала торган булган. Моны туктатыр өчен корәишләр чарасыз булганнар.

Мөхәммәтнең яшь чагында Мәккәдә шундый чамасыз зур кан кою булып ала. Шушы вакытта беренче мәртәбә бу канунга, ягъни кан өчен кан белән җавап бирү тәртибенә үзгәреш кертелә. Гаепле як канны дошманыннан билгеле бер күләмдәге байлык бәрабәренә сатып алырга һәм солыхнамә төзергә үз өстенә бурыч алып, үчләшүләргә чик куела башлый. Борынгы тарихчылар моның шушы рәвешле уңай хәл ителүенә Мәккә халкы Мөхәммәткә бурычлы дип саныйлар, чөнки аның изгелеге аркасында шәһәр халкына шушындый акыллы канун чыгарырга мөмкин булган, диләр.

Хәлбуки, Мөхәммәт үзенең бабасы тәрбиясендә вакытта ук күп дөнья гыйлемен үзләштергән иде. Габделмотталип исә заманында Мәккә халкының иң дәрәҗәле аксакалы иде. Кабилә башлыкларыннан башка аксакаллар белән үзара уртак фикердә булып, гадел эш йөртә иде. Мөхәммәтне дә ул мондый киңәшмәләргә үзе белән алып барды, алдында утыртты. Габделмотталиптан кала дәрәҗәле аксакаллардан Фазыл бине Әл-Харис — Җүрһәмиләр кабиләсеннән, Фазыл бине Фидаил — шулай ук Җүрһәмиләрдән, Фазыл бине Вәдага — Котурилар кабиләсеннән иделәр. Болар барчасы халыкның олуглары булып, эшне татулык һәм киңәш белән дөреслек юлында йөрттеләр ки, залим кемсәнәләргә мондый шартларда Мәккә эчендә тору мөмкин түгел иде. Мөхәммәт пәйгамбәр әлеге аксакалларның мәҗлесләрендә бала чактан ук катнашып, гадел хөкем йөртү ысулларын өйрәнеп калды. Әмма заманнар кичү белән гадел тәртипләр онытыла башлады. Габделмотталип та күптән инде вафат иде.

Аксакалларның урынына өч кемсәне сайлап куйдылар: Харис бине Өмәййәт, Габдешамс һәм Һашим бине Әл-Мөгайрә. Болар исә яхшылык вә гаделлек белән эш итүдән читләштеләр, күбрәк үз байлыкларын ишәйтү уе белән яшәделәр.

Ул вакытларда Йәмәннән бер кемсә Мәккәгә сәүдә кәрванын китергән иде. Аның маллары шактый булып, шәһәрнең бер аксакалы аларны үзенә үзләштерде. Йәмән гарәбе чарасыз калды, дөреслекне эзләп таба алмады. Иртәнге як кояш чыккан вакытта ул Әбу-Кабис тавына менде, кычкырып сөйли башлады. Шәһәргә хәвеф килгәндә шушы рәвешле итәләр иде. Халык җыйналды. Бу гарәп үзе тарган золым хакында халыкка хәбәр бирде. Моның сүзләреннән соң Бәну-Һашим, Бәну-Зөһрә, Бәну-Тәммим, Бәну-Әсәд бине Габделгазиләр белән берлектә, Әбу-Талип бу гаделсезлек кылган бай кемсәнең ханәсенә килделәр, аны Йәмән гарәбенә байлыкларын кайтартып бирергә мәҗбүр иттеләр.

Күз алдыннан үткән ул хәлләр Мөхәммәт пәйгамбәрнең тәрбиясендә әһәмиятле урын тоттылар. Ул байлык артыннан куунның никадәр яман чир икәнлеген күреп вә аңлап үсте. Гаделлекнең дәрәҗәсе хакында белде, кеше малына кул сузмады, ялган юлга басмады.

Китапларда шулай сөйләнелә ки, Мөхәммәт галәйһис-сәлам, башка пәйгамбәрләр төсле үк, байлыкка кинәнеп яшәмәде, акыл илә гомер кичерде. Борынгы китап авторлары аның мәрхәмәтле вә шәфкатьле булып үсүенең төп сәбәбен кыенлыклар белән тормыш итүендә күрәләр. Әмма аларның фикерләре бер генә төрле аңлашылмасын: Мөхәммәт галәйһис-сәлам тумыштан бу сыйфатларның иясе иде. Яшәү рәвеше исә аның акылына кот кына бирде, үзенең күркәм сыйфатларын сакларга ярдәм итте.

## Мөхәммәтнең икенче тапкыр Шамга сәфәре

Бу вакытларда Мөхәммәт галәйһис-сәламгә егерме биш яшьләр тулып килә иде. Аллаһы тәгаләбезнең хикмәтләре күп булганлыктан, барысының сәбәпләрен аңлатып та бетерү мөмкин түгелдер. Шундыйлардан берсе бүдыр ки: Әбу-Талип үзенең байлыгы белән һич тә мактана алмады, бихисап күп акчаларын кесә төбендә һичбер

шикләнүсез шалтыратып йөрергә дә аңа насыйп түгел иде. Белгәнебезчә, Мөхәммәт пәйгамбәр яшәгән урында байлык (аның да төрле рәвешләре бар) һәм бәхет чәчәк атса да, ни сәбәп, Әбу-Талиптагы тормышы да шулай булды дип әйтә алмыйбыз. Фараз кылып, бары шуны гына кабатларга мөмкин, Мөхәммәтнең саулыгын-исәнлеген саклау уенда булган агасының ул вакытларда зур сәүдәләргә юлы тараеп калган иде. Һәм менә Мөхәммәт егет булып үсеп җитте, аның үзенә дә эшләрне тапшырырга мөмкин иде инде. Әмма Әбу-Талипның мөлкәте, Мәккә гарәпләренә хас булганча, сәүдә эшен җәелдереп җибәрергә колач бирми иде.

Көннәрдән беркөнне Әбу-Талип янына Габделмотталипның кызы Гатикә ханым килде һәм сүз башлап:

— Мөхәммәтнең өйләнер вакыты җитте, әзерләнергә кирәктер,— дип белдерде.

— Мин үзем дә кичә-көндез шушы уйда янамын, әмма бу эшне ничек башкарырга белмимен,— дип җавап кайтарды Әбу-Талип. Картның йөзендәге хәсрәт сызыклары хәлне ачык аңлатып тора иделәр.

Бу сүзләргә каршы Гатикә:

— Бергәләп эшләсәк, ничек булыр?— диде.

— Сөйлә, ни рәвешле?— диде Әбу-Талип.

— Шушы көннәрдә Мәккәдә байлыгы белән билгеле Хәдичә исемле бер хатын Шам тарафына кәрван әзерли, әмма эше тукталып тора, чөнки ышанычлы кешене таба алмый икән. Ул хатын минем танышым, үзе белән сөйләшеп карыйм, бәлки Мөхәммәтне үзенең ышанычлы сәүдәгәре итеп япларга ризалыгын биреп тә куяр,— дип белдерде Габделмотталипның кызы.

Хәдичә ханым бу вакытларда ирennән тол калган хатын иде. Холкыфигыле бик тә күркәм булып, байлыгы да җитешле, чибәрлектә дә кызлар сыйфатына тиң. Аны яучылап күп кенә кемсәләр ишегән каксалар да, Хәдичә ханым аларга якты йөзен күрсәтмәде. Һаман да ялгызы гына яши бирде. Әмма шунысы җайсыз: ул кәрваннарын үзе йөртә алмас иде.

Изге бер кичәдә ул төш күрде. Изелеп йоклый иде, күктәге Ай аңа карады. Ул да түгел, Айдан иңгән бер нур Хәдичәнең кочагына керде, кулы аша үтеп, яңадан күккә ашты, бөтен галәмне үзенең яктысы белән бизәде. Хәдичә ханым бу төшен кат-кат юрап карады, әмма ачык бер фикергә килә алмады. Кеше җибәртеп, тәгъбирче Вәраканы чакыртты, туганнары каршысында шушы төшен сөйләп бирде. Моңа каршы төш юраучы:

— И дөньяның бәхет иясе вә күкләрнең тәрбиясенә насыйп булган игелекле бала, бу төшнең тәгъбире бик тә күркәм вә гыйбрәтледер ки, бу нур — пәйгамбәрләр нуры, сиңа Ахырзаман пәйгамбәренең тормышына иптәш булырга насыйп икән! Ул сине үзенә хатын итеп алыр. Синең заманыңда аңа Аллаһы тәгаләдән вәхи килер, нуры бөтен галәмне яктыртыр, иң әүвәл аның янында изге кеше син булырсың, аңа да беренче булып син иман китерерсең, ул кемсәнә корәиш кабиләсеннән, һашим нәселеннәндер,— дип яхшы хәбәрләр бирде.

Бу тәгъбир Хәдичә ханымны сөендерде дә, уйлар диңгезенә дә салды.

Әбу-Талип белән килешенгәннән соң Гатикә ханым Хәдичәләргә килде. Үзенең яңалыгын аңа сөйләргә тиеш иде.

Хәдичә кабул итте, каршына утыртты, хәл-әхвәлен белеште һәм:

— Йә, әйтеп бир, без гаҗизләрнең тупсасын ни йомыш белән атлап кердең, тыңлармын!— диде.

— Сезнең үзегезгә билгеледер, абыемның бер улы калган иде, ул Габделмотталип атамда тәрбиядә үсте, әмма вафат булып, васыяте белән аны күп нәсыйхәтләр илә Әбу-Талипка калдырган иде, инде шул олан камил егет булып үсеп җитте. Ишеттек ки, Мәккәдән Шам сәүдәсенә бер кәрван әзерләгәнсез икән, анда хезмәткә шушы энебез Мөхәммәтне алдырсагыз иде?! — дип Гатикә үзенең үтенечен белдерде.

Хәдичә ханым белә иде: шәһәр халкы арасында Мөхәммәт үзенең тугры егет булуы белән аерылып торды. Акыллы булуы өстенә ул әле күркәм дә иде. Үзенең төше рас һәм хак килүенә гаҗәпләнеп, Хәдичә ханым Мөхәммәтне янына чакыртты. Аның күркәм йөзен күрде. Сәфәрнең көнен билгеләп, хезмәткә әзер торырга кушты.

Юлга чыгар көн килеп җиткәнче, Хәдичә ханым бер дөяне иярләтте, кеше утырыр урынны камыштан үрелгән чатыр белән әйләндереп алдырды. Үз янына колы Мәйсәрәне чакырып, аңа киемнәр бирде дә:

— Бу махсус хәзерләнеп куелган дөя өстенә Мөхәммәтне утыртырсың, менә шушы киемнәрне киендерерсең,— дип аңа боерды.— Әгәр дә мин кушканнарны җиренә җиткереп үтәсәң, сәфәрегез уңышлы тәмамланып, Мөхәммәт җәбер-золымнан имин булса, үзеңә ирек һәм теләгән малдан өлеш бирермен,— диде, вәгъдәләр куештылар.

Юлга чыгар көн килеп җиткәч, Мөхәммәт тә хезмәткә тиешле киемнәрне киенде. Кәрван хуҗасы йортына төште, Хәдичә ханымнан ишеткән теләкләрнең барчасы да изге иделәр.

Кәрван кузгалуга, Мәккә халкы аларны озата китте. Мөхәммәтнең туганнары күзләреннән энҗе яшьләр койды. Барысы да Әбу-Талипка үпкәләрен белдерделәр. Аларның бу сүзләреннән, китапларда шулай сөйләнелә ки, Әбу-Талипның хушы китте. Ул аңына килгәндә, кәрван ераклашып бара иде.

Шәһәрдән чыгуга Мәйсәрә Хәдичә ханым тапшырган эшләрнең барчасын да җиренә җиткереп үтәде. Камыштан чатыр корылган дөягә Мөхәммәтне хуҗасы биргән киемнәргә киендереп утыртты. Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә, Әбу-Җәһил, Гакабә, Шәйбә һ. б. бу сәфәрдә бийлә, ягъни купчая иделәр. Алар Мәйсәрәгә:

— Бу фәкыйрьне нигә шулай саклыйсың. Аңа иске киемнәр кидер, кара эшләрне эшләт,— дип әйттеләр.

— Мин сезнең колыгыз түгел, Хәдичә хуҗамның колы,— дип җавап бирде аларга каршы Мәйсәрә.— Ул ни кушкан булса, шуны җиренә җиткереп үтәргә тиешмен!

Хәдичәнең бер евнух кешесе бар иде. Хозәймә ибне Хәким-Сәлми кушаматлы иде. Бу сәфәрдә ул кемсәнә Мөхәммәткә иптәш булып юлга чыкты. Алар бик тә дуслаштылар. Хозәймә Мөхәммәттән бер дә читләшмәде. Һаман янында булды. Үзара бик тә тату һәм бер сүздә иделәр.

Юлда барган вакытларында ике дөя, тәмам хәлдән таеп, аяксыз калды. Бу хәлне күреп, Мәйсәрә белән Хозәймә Мөхәммәт янына килделәр, аңа бу хакта хәбәр бирделәр. Пәйгамбәребез шушы дөяләр янына килде, дога кылып, үзенең мөбарәк куллары белән аларның аякларын сыйпады. Хайваннарга дәрман керде, алар аякка бастылар, кәрван белән бергә атладылар. Бу хәлгә барчасының да исе китте.

Бара-бара килер юллары Басрага якынлашып җитә иде. Кәрван Бәхирәнең сумгасы янына тукталды. Бәхирә ул вакытларда вафат иде инде. Сумгада аның дусларыннан булган бер нистурияле кемсә бар иде. Бу вакытларда монда корылыктан агачлар да яфракларын койган иделәр. Мөхәммәт пәйгамбәр кәрваны килеп туктауга, бу агачлар яңадан яфрак ярып, хәтта җимешләре дә шул вакытта өлгереп җитте. Ул күренешләрне нистурияле монах күреп торды, исе-акылы китте. Тукталган кәрван янына чыкмый кала алмады.

Ул Мөхәммәт пәйгамбәрнең алдына килде һәм:

— Бөек Тәңре хакы өчен әйт, исемең ничек? — дип түбәнчелек белән сорады. Кулында бер китабы да бар иде. Аңа карап нидер укыды. Яңадан да Мөхәммәтнең йөзенә бакты, шуннан:

— Гайсә галәйһис-сәламгә «Инҗил»не иңдергән Алла исеме белән ант итеп әйтәм, бу — рәсүлдер,— дип пәйгамбәребезне танып алды.

Бу вакытта, бер-бер яман эштән сакланып, Хозәймә кынысыннан кылычын чыгарып, аны сугыш өчен әзерләп, кояшта ялтыратып тора

иде. Бу хәлне күреп алган гарәпләр барысы да алар янына җыелыша башладылар. Сораулары бер генә иде:

— Ни булды?

Ул арада нистурияле монах тизрәк сумгасына кереп качты. Җаны калтыранды. Бинага бер-бер зыян килүдән куркып, капка артыннан китмәде, Хозәймәнең кызуын басар өчен эшнең нәрсәдә булуын аңлатып бирергә мәҗбүр иде:

— Кулымдагы китабымның бер дә зыянлы урыны-җире юк бит. Мин бары тик монда язылганнарның хаклыгын гына белергә теләдем, китаптагы һәм тормыштагы Ахырзаман пәйгамбәрен чагыштырып карадым. Күзләгән кешем хактан да Ахырзаман пәйгамбәре икән. Аның шәригатенә дөньядагы барлык халыклар буйсыныргалар. Аны үтергән кешене Тәңре ярлыкамас,— диде.— Син аңа кем буласың? — дип Хозәймәдән сорады.

— Мин аның хезмәткәре буламын! — диде аңа евнух.

— Китабымнан тагын да шул күренә: аның, Ахырзаман пәйгамбәренең дошманнары күп булыр. Яһүди вә носариларга бу хәбәрләрне сөйли күрмә, җәбер-золым китерүләре бар,— дип аңа киңәшләрен бирде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Мөхәммәт янына Хозәймә килде һәм:

— Синдә кешеләр башкаларда булмаган сыйфатларны күрәләр, бөтен җир йөзе синең юлыңнан китәр, сиңа буйсыныр, диләр. Дошманың бар икән, мин дә аңа дошманлык кылырмын, дустың бар икән, мин дә аңа дуслык кулымны бирермен,— диде.

Раһип, ягъни монах, Хозәймә евнух белән сөйләшкәннән соң, үз янына Мәйсәрәне чакыртты һәм аннан Мөхәммәтнең сыйфатлары хакында мәгълүматлар ала башлады.

Мәйсәрә исә эссе көндә кошларның Мөхәммәт өстенә бер болыт хасил итүләрен, аягы алдында чишмә барлыкка килүен, кулы тиюгә ризыкларның татлы һәм туклыклы булуларын, йөзендә үзгә бер нур барлыгын раһипка бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Шуннан бу монах:

— Мин гомерем буе Ахырзаман пәйгамбәрен күрү өчен яшәдем, инде теләгем кабул булды. Бу кемсә чыннан да шул мин көткән Ахырзаман пәйгамбәре икән, берүк саклый күрегез. Шам базарына бармагыз, ул шәһәргә керә күрмәгез. Юкса аңа зыян итәрләр! — дип Мәйсәрәдән үтенде.

Мәйсәрә һәм Хозәймә аның сүзләрен кабул иттеләр. Шамга барырга кирәкмәс, дип киңәштеләр һәм товарларын Басра базарында гына сатарга булдылар.

Аларның сәүдәсе бик тә уңышлы чыкты. Күп табыш алдылар. Максатларына ирешеп, күңелләре камиллек һәм күркәмлек нурында чәчәк атты.

Басрада Мөхәммәт бер яһүди кешесе белән мөгамәләгә керде. Алар үзара шактый озак бергә булдылар. Яһүди аның Ахырзаман пәйгамбәре икәнлеген танып алды, үзенә дә ул хакта хәбәрләр бирде, аның җәннәт иясе икәнлеген әйтте. Бу хакта Мәйсәрәгә дә хәбәрләр бирде. Шәһәр халкыннан башка кемсәләр дә Мөхәммәтне күрергә килгәләделәр. Боларның барысы да Мәйсәрә һәм Хозәймә күз алдында булды.

Көннәрдән беркөнне һава бик тә эсселәнеп китте. Ике фәрештә кош сурәтендә очып килделәр һәм Мөхәммәтне ул көнне эссedән күләгәләп тордылар.

Бу сәфәрдә катнашкан кешеләрнең берсе Әбу-Бәкер иде. Хәдичәнең әмерен үтәп, ул һаман да Мөхәммәткә кадер-хөрмәт күрсәтте. Аның өчен махсус дөяне аерып асрады, затлы келәмнәр салып, аңа пәйгамбәрне утыртып йөртте. Бу хәлне күреп торган Әбу-Җәһил — Мөхәммәтнең кардәше, көнчелек утында янды. Әбу-Бәкергә килеп зарланды. Әмма аның сүзен тыңлаучы-тотучы булмады. Әбу-Бәкер дә Хәдичәнең әмереннән тайпылмады.

Кәрван Шам шәһәреннән Мәккәгә кайтыр юлга чыкты. Кайтып килгәндә Мөхәммәт пәйгамбәр утырган дөя юлдан адашты. Кәрваннан аерылып китте. Сәүдәгәрләр хәвефкә төштеләр.

Хикәячеләрнең сөйләүләренә караганда, Мөхәммәтнең дөясен Иблис мәлгунь тезгененнән тотып, читкә алып киткән, имеш тә. Җәбраил фәрештәгә бу хәлдә килеп ирешкән һәм ул дөяне янә дөрес юлга төшергән икән. Ни генә булмасын, Мөхәммәт утырган дөя кәрваннан аерылып китте. Ком сахрасында ялгыз калу — үлем тырнагына кабу белән бердәй иде.

Бу вакытларда сәүдә кәрваны Мәккәгә кайтып ирешергә тиеш иде инде. Хәдичә ханым юлларга кешеләр җибәреп, кәрванны каршы алырга, аның кайтуы хакында хәбәрләшеп торырга булды. Әмма көтелгән шатлыклы хәбәрләр килмәде, җибәрелгән кешеләр буш кул белән кайттылар. Хәдичә пошаманга калды. Кәрван соңарганнан соңарды. Көн артыннан көн үтте.

Хәдичә ханым йорт түбәсенә күзәтчеләрен мендерде. Алар кәрван кайтасы юлдан күзләрен алмадылар. Әмма юл тузаны күккә күтәрелмәде. Аптыраганнан Хәдичә ханым үзе дә сараеның алдына чыгып, калку урыннан Шам тарафын күзәтте. Аның янында Нәфисә ханым да бар иде. Ниһаять, бер көнне чүл уртасында бер дөя күренде. Аның өстендә кечкенә генә бер болыт та бар иде. Бу кинәттән күренгән дөя бик тә гаҗәеп һәм нурлы булып тоелды. Һәркемнең дә серне беләсе килде.

Кәрваннан аерылган бу дөя Хәдичә ханымның капкасы алдына килеп туктады. Аның өстендә Мөхәммәт утыра иде. Ул исә Хәдичәгә тапшыру өчен Мәйсәрәдән хат бирде. Хатны Хәдичә катына Нәфисә китерде. Анда сәүдәнең Мөхәммәт ярдәме белән бик тә уңышлы булуы хакында язылган иде.

Хәдичә җавап хатын төзеде. Мөхәммәткә тапшыруга, ул янә юлга чыкты. Кәрван янына көтелмәгәндә килеп чыкты. Аны күреп алган Әбу-Җәһил:

— Әнә, кәрваннан адашкан дөя килә! — дип сәүдәгәрләргә хәбәр бирде.

Мөхәммәт җавап хатын Мәйсәрәгә тапшыргач та, Әбу-Җәһил:

— Мин аның җиде көнлек юлны бер көн эчендә үтүенә ышанмыйм, бу мөмкин хәл түгел! — дип Мөхәммәттән көлде.

— Син ялгышасың, көнчелек итүеңдер, Мөхәммәт туры юлдан йөрде,— диде аңа Мәйсәрә. Әмма Әбу-Җәһил барыбер ышанмады, барысын да ялганга чыгарды.

Кәрван кайтып җитүгә, Әбу-Җәһил Хәдичәнең катына килде һәм:

— Кәрваныбыздан берничә көннәр элек берәр кемсәнә килмәдеме? — дип сораштырды. Моңа каршы Хәдичә:

— Кәрван килердән берничә көн элгәре Мөхәммәт миңа хат китергән иде, җавабын алып, кире юлга чыкты. Көннәр үтеп, кәрваным да исән-имин кайтып җитте,— дип җавап бирде.

Хәдичә ханым бу сәфәрдән соң Мәйсәрәдән булган хәлләрне үзе дә сораштырды. Мәйсәрә исә Мөхәммәт пәйгамбәребез белән булган вакыйгаларны, Мәккәдән чыгуга аны күктәге бер болыт кисәгенең һәрдаим күләгәләп йөрүе, сәүдәнең дә Мөхәммәт аркасында уңышлы тәмамлануы хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Боларны ишеткәч, Хәдичә ханымның күңеле сөенеч белән тулды. Күңелендә Мөхәммәткә карата гыйшык уты кабынды. Шатлыклы хәбәрләрне бәян итүе өчен, сәүдәнең төшемле тәмамлануына сөенеп, Хәдичә ханым Мәйсәрәгә күп байлыклар бүләк итте. Кәрван исә Шам базарыннан да шактый ук товарлар алып кайткан иде. Мәккәдә аларны саттылар, тагын да күбрәк керемле булдылар. Мәйсәрә монда да Мөхәммәтнең изгелеге барлыгын төшенеп алды.

Хәбәрләрдән шул билгеле, Мөхәммәткә Мәккә кызларыннан күпләр гашыйк иделәр. Әмма аның күңеле Хәдичә ханымнан бүтәнгә төшмәде.

Моның сәбәбен хикәячеләр Аллаһы тәгалә рәхмәтеннән күрәләр, хактыр да, бәхәс кылу урынсыз булыр.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең Шам тарафына шуңы икенче сәфәреннән соң Хәдичә ханымның мәхәббәте дә ныгыды. Үзен түгел, исемен ишетүгә, күңел түреннән бер хисси аһ авазы чыга һәм йөрәге урыныннан куба торган булып китте. Ул чын мәгънәсендә гомерендә беренче тапкыр гашыйк иде.

Хәбәрләрдән билгеле, Хәдичә ханым үз заманының иң күркәм хатыннарыннан берсе иде. Башкалардан ул акыл ягыннан да өстен чыкты. Шушы сыйфатлары аркасында аның катына яучылар да күп килделәр, әмма буш кул белән кайтып китә иделәр. Кайсылары йөк-йөк маллар китереп карады, әмма Хәдичә ханым аларның да сүзен кабул итмәде. Ә менә Мөхәммәткә гыйшкы төшкәннән бирле төн йокыларын югалтты.

Нәфисә ханым Хәдичәнең дус кызларыннан иде. Ул аның мәхәббәтеннән хәбәрдар булды. Мөхәммәт янына килде һәм әйтте:

— Йә Мөхәммәт хәзрәтләре, синең өйләнмәвеңдә, өйләнүдән тыелуыңда нинди сәбәп бар? — дип.

Аңа каршы пәйгамбәр:

— Минем кулымда бернинди байлык та юк, шул сәбәпле өйләнүдән тыелам, — дип җавабын бирде.

— И Мөхәммәт, — диде аңа Нәфисә. — Күркәм йөзле, зур мөлкәт хуҗасы, олы байлык иясе, камил акыллы бер хатын бар, әгәр аңа өйләнергә теләсәң, хезмәтеңдә булырмын!

Бу сүзләрне ишеткәч, Мөхәммәт пәйгамбәр уйга калды, гаҗәпләнүен яшермәде, фикер казанын шактый озак кайнатканнан соң:

— Ул хатын кем соң? — дип сорады.

— Хәдичә ханым! — диде аңа Нәфисә.

— Бу мәслихәт күрелгән ханымга яучы кем булыр? — дип сорауга каршы, Нәфисәдән:

— Бу эшне миңа йөкләсәң иде, — дигән җавапны алды.

Ул Хәдичәгә өйләнергә разый иде.

Аннан шушы җавапларны тапканнан соң Нәфисә ханым, Хәдичәгә килеп, куанычлы хәбәрен җиткерде. Бу яңалыкны Хәдичә ханым исә туганы Гамрә бине Әсәд һәм туганының улы Вәрака бине Нуфалга белдерде, Мөхәммәткә исә фәлән сәгатькә күрешергә килергә рөхсәт бирде. Бу хәбәр пәйгамбәрнең туганнарына килеп ирешүгә, Әбу-Талип һәм агалары аптырашта калдылар. Чөнки Мөхәммәтнең өстенә кидертергә бер кафтаны да юк иде. Ә йола буенча кафтан затлы булырга тиеш иде.

Мал вә байлыкларның булмавы Мөхәммәтнең Хәдичә ханымга өйләнүе өчен комачаулык итә иделәр. Ни хикмәт, Мөхәммәтнең өйләнергә җыенуын Әбу-Бәкер ишетеп алды һәм тупсаларыннан атлап керде. Барысының да пошаманга калганлыкларын күрде, сорады:

— И сөеклем, арадан бер булган галимем Мөхәммәт, хафагыз нинәрсә? Белимче. Үземне каршыгызда хезмәтче итеп күрүне мәртәбәгә саныйм, — диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр Әбу-Бәкергә барча эшне бәйнә-бәйнә аңлатып бирде. Боларны ишетүгә, дусты:

— Әбу-Талипның сөекле кардәше, заманыбызның даны, булган хәзрәтләрегез барчасы буштыр. Габделмотталиптан аманәт итеп калдырылган мең алтын, күркәм комачлар һәм кафтаннар миндә саклана, инде вакыты җитте булса кирәк. Үзегезгә тапшырырга рөхсәт итегез, алып килим, — диде һәм, барчасын сөендереп, малларны кайтару өчен китеп тә барды. Ул арада Хәдичә ханымнан да бүләк төсе итеп кафтаннар китерелде.

Сөйләшенү буенча Хәдичә ханым йортына алдан Әбу-Бәкер барды. Кияү бүләкләрен тапшырды, хезмәтчеләргә алтыннарны өләште. Ул көнне һәммә хезмәтчеләр ирекле булдылар.

Кәләше йортына Хәмзә белән килде Мөхәммәт. Алар артыннан Әбу-Талип һәм тагын да ике кеше килеп керделәр. Хәдичәнең туганы Гамрә бине Әсәд бик тә заһид-диндар кеше иде. Бу күрешүләрендә Әбу-Талип бер хөтбә сөйләде. Ул анда үзләренең нәселенең корәишләр арасында иң мактаулы булуын, Ибраһим вә Исмәгыйль пәйгамбәрләр нәселеннән икәнлеген, заманында Мисырдан чыгуларын сөйләп үткәннән соң, энесе Мөхәммәтнең мал белән данлык алмыйча, күркәмлектә һәм тугрылыкта танылуын бәйнә-бәйнә аңлатып бирде. Моннан соң Вәрака бине Нуфал сүз алды. Ул да, үз чиратында, нәселенең өстен якларын хисап төймәсе аша үткәрде. Болардан соң калым дәрәҗәсе билгеләнде һәм Гамрә әйтте:


— Шаһит булыгыз, Хәдичә ханымны Мөхәммәткә бирдем,— диде.

Шулай итеп, никах мәҗлесе тәмамланды. Бу мәҗлескә Әбу-Талип бер дөя чалдырды. Хәдичә ханымны Мөхәммәткә китерделәр. Хатын барлык байлыкларын ачып салды. Алар бер-берсен бик тә яраттылар. Ул вакытта Мөхәммәткә егерме биш яшь, Хәдичә ханымга кырык яшь иде.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең Шам тарафына булган икенче сәфәре менә шулай тәмамланды. Бу сәфәр, пәйгамбәребезгә дан вә шөһрәттән тыш, гаилә тормышын кору бәхетен дә китерде. Хәдичә ханым кебек акыллы хатынның ире булу Мөхәммәт өчен бик тә кирәк иде, чөнки тормыш тәҗрибәсе белән Хәдичә аңа шактый күп ярдәм күрсәтәчәк әле. Боларын, иншалла, алга таба күрербез.

## Кәгъбәне яңадан бина итү

Ул вакытларда Мөхәммәт пәйгамбәребезгә утыз биш яшьләр булып, хатыны Хәдичә ханым белән күркәм вә матур тормышта яшәп ята иделәр. Тагын да шул билгеле булсын, нәкъ шушы елда Мәккә халкы үзләренең потханәләре булган Бинаи-шәрифне яңартып салырга уйладылар.



Бу Бинаи-шәриф, ягъни Кәгъбәтулла, кайбер риваятьләрдә килгәнчә, Адәм пәйгамбәр тарафыннан төзетелгән иде. Нух туфаны күтәрелгәннән соң ул җимерелде һәм дә Исмәгыйль пәйгамбәргә тикле хәрабә хәлендә ятты. Ибраһим вә Исмәгыйль пәйгамбәрләр аны яңадан торгыздылар. Һәм шуннан соң күп заманнар үтте. Таштан корылган стеналары какшады. Диварлары әле-әле ишелеп китәр һәм гыйбәдәткә килгән кешеләрне харап итәр төсле иде.

Хикәятләрдә шулай сөйләнелә ки, бу бинаның ишеге юк иде. Шунлыктан җилләр анда үтәли йөри иделәр. Диварлары адәм югарылыгында булып, бинаның түшәме дә юк иде. Уртасында бер кое казылган, заманында яшәп узган җәрһәмиләр падишаһы аңа алтын кәҗә сынын ташлатып, тәмам боздырып, нәҗесләп киткән иде. Вакыйгаларны тәфсилләп язучылар тагын да шулай диләр ки, Мәккә таифәсе бу коены ачмакчы икән дә, әмма бина эченә сил (ташкын) кереп, эшләрен тагын да бозып куйган. Икенче берәүләр сүзеннән тагын шул килеп ирешә, бу коеның эченнән чыккан алтын кәҗә сынын табучылар бинаның капка өстенә урнаштырганнар икән дә, шуның аркасында диварлар какшаган, имештер. Әмма ни генә булмасын, нәкъ шушы елны Мәккә халкы Кәгъбәне яңадан корырга, аңа ишек куярга һәм түшәм җәяргә карар иттеләр.

Эш бүлешү башланды. Арада тәртип булсын өчен һәм талашорыштан саклану уеннан чыгып, кабиләләрнең олуглары шобага салдылар. Бинаның бер диварын төзәтү Бәни-Габделманаф һәм Зөһрә таифәсенә, икенчесен эшләү Бәни-Әсад ибне Габделгозайә һәм Бине-Габделдарә кабиләләренә, өченче тарафын исә Бәни-Тәмим Таифәсенә, дүртенче якны кору Бәни-Сәһим вә Бине-Гадийә халкына насыйп булды. Шулай оешып, эшне башларга булдылар. Әмма, ни хикмәт, диварларның ташларын кузгатырга курыктылар. Көн дә бинаны сүтәргә җыела иделәр дә чарасыз кала иделәр.

Моның сәбәбе шунда иде: Кәгъбә янындагы коеда аждаһа яшеренеп ята, ул диварның ташын кузгаткан адәмнең өстенә ташлана һәм аны йота икән, дигән хәбәр бар иде. Шунлыктан эш башланмады. Һәркем курка калды, кое төбеннән аждаһаның тавышын да ишеткәндәй булдылар. Шулай итеп, һичбер эш майтара алмадылар. Әмма бу эшне озакка калдырырга да ярамый иде.

Алар, бер фикергә килеп, догалар укыдылар. Тәңредән ярдәм сорадылар, аждаһадан азат итүен үтенделәр. Теләкләре кабул булып, ул аждаһа коедан күтәрелде. Аның канатлары ак, аяклары сары төстә иде. Аждаһа очып китте һәм Җийад тавына барып кунды. Моны күреп торган корәишләр бик тә сөенделәр:

— Тәңре үтенечләребезне кабул итте,— диештеләр. Әмма барыбер бинаны сүтәргә кыймадылар. Ташларга тотынган кулларын кире алдылар, дивардан читкә киттеләр. Шуннан соң арадан Вәлид бине Әл-Мөгайрә атлы кемсә чыкты һәм:

— И кардәшләр, мин барып ташны куйган урыныннан кузгатыйм, сез килеп ярдәм итәрсез,— диде һәм ялгызы гына диварга якынлашты. Барча корәиш хәзер бер-бер хәл булыр дип көттеләр. Сулышлары кысылды, йөрәкләре күкрәк читлекләрен ватып чыгардай булды. Менә Бине-Мөгайрә куллары белән дивар ташына ябышты. Урыныннан кузгатты. Әмма һичкем ярдәмгә ашыкмады. Барчасы читтән генә күзәтеп тордылар. Инде хәзер Бине-Мөгайрә белән бер-бер хәл булыр кебек иде.

Бу тәвәккәл адәм үз эшен белеп эшләде. Кубарылган ташны дивардан читкә алып куйды. Аның белән бер яман хәл дә булмавын күреп торган корәишләрнең дә күңеленә кыюлык иңде. Алар да диварга якынлаштылар һәм диварны сүтә башладылар. Ахшам вакыты житкәч, эш тукталды. Корәишләр:

— Вәлиднең сау-сәламәт калуы Хак тәгаләнең бу эшкә ризалыгын белдерә,— диешеп өйләренә таралыштылар.

Иртәгесен корәишләр бинаның диварларын сүтә башладылар. Әмма төзү эшен җитәкләү өчен арадан бер белдекле кеше табылмады. Тарихларда язылганча, Алла рәхмәте белән ул вакытларда Мәккәдән ерак түгел урында Рум көймәсе ярга чыгып ватылган иде. Андагы кешеләрдән бер кемсәнең биналар төзергә бик маһир булуы халыкка килеп иреште. Шәһәрнең олугларыннан берәүне шунда җибәреп, Якум атлы останы бу эшкә күндереп, кешеләре белән бергә Мәккәгә алып кайттылар. Оста әйтте:

— Сез теләгәнчә төзәтергә дисәгез, бинаны моннан кечерәк итеп салырга кирәк,— диде.

Корәишләр аның белән килештеләр. Бинаны яңадан төзү эшләре башланды.

Шул билгеле булсын, Кәгъбәне сүткәндә арадан бер яшел таш килеп чыкты. Анда Ибраһим вә Исмәгыйль пәйгамбәрләрнең бармак эзләре дә бар иде. Ташның изге икәнлеген һәркем белде, шунлыктан бинаны корганда кабиләләр арасында шушы ташны куяр өчен бәхәс китте. Һәркем бу эшкә үзен лаеклы дип санады. Изге ташка һәркайсының кулы сузылды. Бәхәс китте, бәхәс үзе белән тавыш-орышны ияртеп килде. Һич тә уртак фикергә килә алмадылар. Шунда эшне оештыручылардан булган Вәлид бине Әл-Мөгайрә:

— Җәмәгать, тынычланыгыз! Без болай талашып, берни дә эшли алмабыз. Минем мондый тәкъдимем бар: кем дә кем Бәни-Шәйбә капкасыннан керә һәм беренче булып килә, шул кеше изге ташыбызны урынына куяр,— диде.

Аның сүзе белән килештеләр. Шунда капкадан төзелеш барган җиргә Мөхәммәт килеп керде. Барча кемсәнең исләре китте. Ташны урынына ул куярга тиеш булды.

Мөхәммәт бу бәхәсне әллә кайдан белеп торган шикелле, туп-туры әлеге яшел таш янына килде, өстеннән ридәсен, ягъни дөя йонынннан эшләнгән киемен салды, мөбарәк куллары белән ташны алды һәм шушы ридәсе уртасына куйды. Аннан соң һәр кабиләдән берәр кешене чакырып китерде дә аларга ридәнең читләреннән тотып күтәрергә кушты. Ташны шул рәвештә куеласы урынына китерделәр. Мөхәммәтнең зирәклегенә һәммәсе рәхмәтле булдылар.

Ташны урынына Мөхәммәт пәйгамбәр үзе күтәреп куйды. Бу вакыйганың асыл мәгънәсе бик тирәндә иде. Заманында Ибраһим вә Исмәгыйль пәйгамбәрләр куйган бу изге ташны, вакытлар җитеп, кабаттан тергезелгән Кәгъбәтулла диварына Мөхәммәт пәйгамбәр үзе мөбарәк куллары белән урнаштырды.

Бу хәлләргә корәишләр хөшнүд-канәгать булдылар.

Кәгъбәтулланы дуслык белән төзеп бетерделәр, аңа түбә кордылар һәм ишекләр куйдылар. Изге таш Мөхәммәт пәйгамбәребез тарафыннан диварга утыртылганнан соң, Кәгъбәтулла нурланып-балкып китте.

Бу вакытларда Кәгъбәдә мәҗүсиләр хуҗа иде. Алар Ибраһим пәйгамбәрнең диненнән тайпылып, потларга табына башлаганлыктан, хак диннең ниндилеген күз алларына да китермәделәр. Әмма корәишләр арасыннан булган Вәрака дөрес юлны эзләде һәм Шам тарафына китеп барды, анда «Инҗил»не өйрәнде, носари диненә керде. Шулай да Мәккәдә яшәүне өстенрәк күрде. Габдулла бине Җәхиш тә, потларга табынырга теләмичә, Мәккәдән китеп торды һәм, эзләгән динен кабул итеп, Алла юлында булды. Алар икесе дә, Мөхәммәткә пәйгамбәрлек иңгәч, дин исламга керделәр. Өченче бер кемсәнең исеме Госман бине әл-Ховәйрис иде, ул да Мәккәдән китеп, үзенә дин эзләде, носарилар рәтенә басып, христиан динен алды, Румда вафат булды. Дүртенчесе исә Хәдичәнең абыйсы Гамрә бине Әсәд иде. Ул да потларга табынмады. Ибраһим пәйгамбәрнең динен эзләде. «Инҗил»не һәм «Тәүрат»ны өйрәнде. Әмма күңеле ризалык кылмады. Ниһаять, бер раһиптан Мәккәдән Ахырзаман пәйгамбәре чыгачагын ишетеп, шәһәренә әйләнеп кайтты.

Бу вакытларда Мөхәммәткә пәйгамбәрлек иңмәгән иде әле. Әмма ул да потларга табынмады. Һаман да Алла исемен теленнән төшермәде.

Шуны белергә кирәк ки, нәбилек иңмичә торып, намуслы кеше Алла исеменнән ялган пәйгамбәрлек итеп, кешеләргә сүз катарга тиеш түгел, чөнки бу рәвешле кылану ул — Иблис вәсвәсәсенә бирелү! Алладан вәхи килми торып, пәйгамбәр булырга тырышудан да зур гөнаһ җир йөзендә юктыр.

## Пәйгамбәрлек иңү

Тарихларда шулай сөйләнелә ки, Мөхәммәткә кырык яше туларга өч ел бар иде. Көннәрдән беркөнне ул ялгызы гына гыйбәдәт кылганда бер тавыш ишетте. Аптырашта калды. Бу өннең нинәрсә булуын төшенмәде. Килеп, Хәдичә ханымга бу тавыш хакында хәбәр бирде:

— Бер өн ишеттем, миңа хәвеф килә дип белдем,— диде. Хәдичә ханым үзенең иренә күркәм йөзен балкытып карады, сөеклесен күз карашы белән иркәләп алды һәм:

— И Мөхәммәт, сиңа яхшыдан тыш нинди хәвеф, яки яманлык ирешер икән, һичбер хәвеф сиңа кагылмас,— диде.

Иркәсенең шушындый да ягымлы итеп әйткән сүзләреннән соң Мөхәммәт тынычланды, булган хәлне яманга юрамады.

Вакыйгаларны җентекләп хәбәр итүчеләр Җәбраил галәйһис-сәламнең Аллаһы тәгалә әмере белән Мөхәммәткә өч яшеннән бирле хезмәттә булуын сөйлиләр. Әмма фәрештәне Мөхәммәт үзе күрмәгән, чөнки Аллаһы тәгаләнең әмер сәгате җитмәгән, диләр. Шул рәвешле вакыты-вакыты белән пәйгамбәребезнең вәхи-өн ишетүләре мөмкин хәл булып аңлашыла. Икенче бер риваятьләрдә исә Мөхәммәт җиде яшенә кергәндә аңа хезмәткә Исрафил фәрештә килгәнлеге сөйләнелә һәм вакыт-вакыт пәйгамбәребезгә күренүе, аны яманлыктан вә ялгышлыклардан саклавы бәян ителә. Исрафил шул рәвешле өч ел буена хезмәт күрсәтте. Моннан соң Җәбраил фәрештә Мөхәммәткә үзенең изгелекләрен кылды, егерме ел буена аңа хезмәт итте, аны олылады. Әмма Мөхәммәткә күренмәде, һәрдаим аның янында булганлыгын белдермәде. Шуннан соң рәсүлнең кырык яшенә кадәр бер фәрештә дә янына килмәде. Мөхәммәт үз хезмәтендә үзе булды, диләр.

Күктән вәхи иңгән көннәр алдыннан Мөхәммәт Хира тавындагы мәгарәдә ялгызы калып, көне-төне гыйбадәт кылды. Гыйбадәттән буш вакытларында күңеленә төрле уйлар тулды.

Бу тау куышы Мәккәдән өч мил ераклыгында иде. Вакыт-вакыт монда Хәдичә ханым да килеп китә иде.

— Син Мөхәммәткә нинди олы хөрмәтләр күрсәттең, аңа малларыңны бирдең, ә ул синнән качып йөри,— дип, Мәккә хатыннары Хәдичәгә теләсә нинди юк-бар сөйли башладылар. Әмма акыллы хатын аларга:

— Мөхәммәт бер дә яман эшләр белән йөрмәс, ул ялгыш дин тотудан китеп, хак дин өчен җанын фида итәргә әзер. Аннан ничә еллар бәхет вә хөрмәтләр күрдем, хәзер дә аның турында бер дә начар уйга төшмимен,— дип җавап бирә белде, гайбәтләренә чик куйды.

Выкыйгаларны сөйләүчеләр һәм тарихлар катламыннан килгән китапларда Мөхәммәтнең ул вакытта төрле пәйгамбәрләрнең шәригатьләрен тотуы хакында хәбәрләр бирәләр. Берләре Нух пәйгамбәр шәригате илә дога-сәҗдәдә булды, дисәләр, икенчеләре, башка пәйгамбәрнең шәригате белән яшәде, диләр. Өченчеләре исә, ул барлык пәйгамбәрләрнең шәригатен бергә тотты, дип исбатларга тырышалар. Әмма ни генә булмасын, шул ачык аңлашылырга тиеш: Мөхәммәт үзенә пәйгамбәрлек иңгәнче үк Аллаһы тәгаләбезнең берлеген белде, таныды, аңа салават-

ларын әйтте, бары пәйгамбәрлек кенә кыла алмады. Кырык яшенәчә аңа әле хак дин иңмәде.

Рамазан аеның шимбә кичәсендә Мөхәммәт галәйһис-сәламгә Җәбраил фәрештә килде. Әмма үзе күренмәде. Шул рәвешле, һәрдаим аның янында булды. Үзенең барлыгыннан хәбәр бирмәде.

Рамазан аеның унҗиденче көне, дүшәмбе дә җитте. Мөхәммәт галәйһис-сәлам догада иде. Шулвакыт Җәбраил фәрештә аңа үзенең барлыгыннан хәбәр бирде. Мөхәммәт галәйһис-сәлам догада булган җиреннән калыкты, уңына вә сулына карады. Һичкемне күрмәде. Шунда Җәбраил фәрештә аның каршына бер күркәм адәм сурәтендә пәйда булды. Ул Мөхәммәт галәйһис-сәламнең уң ягыннан үтеп, артына төште һәм үз хәленә кайтты. Аягы — җирдә, башы күккә иреште. Канатларын ачуга, мәгърип вә мәшрикъ тарафларына иреште. Мөхәммәт галәйһис-сәлам аның сурәтенә шаһит булды. Күрде: Җәбраил фәрештәнең аяклары сары, канатлары яшел, йөзе нурланган, тешләре ак һәм күркәм башының чәчләре кызыл мәрҗән төсендә, муенындагы кызыл якутка «Лә илаһә иллаллаһи, Мөхәммәдүр рәсүлуллаһи», ягъни, «Алладан башка илаһи зат юк, Мөхәммәт — аның илчесе», дип язылган иде. Кайбер риваятьләрдә Җәбраил фәрештәнең алты йөз мең канаты булуы, башында бер таҗы да барлыгы сурәтләнә.

Җәбраил галәйһис-сәламне күреп, Мөхәммәт бу тамашага аптырап калды һәм:

— Син кем буласың, минем бу кадәр бөек затны һич кенә дә күргәнем юк иде? — дип сорады.

— Мин — Җәбраил, Алланың пәйгамбәрләре янына килүче илчесемен,— дип җавап бирде аңа фәрештә. Аннары:

— Йә Мөхәммәт, укы...— диде ул.

— Нәрсә укыйм? Мин бит укый белмим,— диде аңа Мөхәммәт.

Шунда Җәбраил фәрештә канат астыннан бер китап чыгарды. Ул җәннәтнең әнҗе-мәрҗәннәре белән чигелгән иде. Аны Мөхәммәткә тоттырды һәм тагын:

— Укы! — диде.

— Мин бит язу танымыйм, укымышлы түгелмен,— дип җавап бирде аңа Мөхәммәт.— Мондый язу юк бит!

Шуннан соң Җәбраил фәрештә үзе укыды һәм Мөхәммәткә кабатлап барырга кушты. Шулай итеп, аңа Коръәннең беренче аяте иңде.

— Минем күңелемдә калды,— диде аңа Мөхәммәт пәйгамбәр. Шуннан соң Җәбраил фәрештә аягы белән җиргә типте. Бер чишмә саркып чыкты. Фәрештә исә пәйгамбәребезгә тәһарәт алу тәртибен күрсәтеп бирде. Кабатларга кушты. Мөхәммәт галәйһис-сәлам сафланды-чистарынды. Шуннан соң фәрештә рәсүлебезгә ике рәкәгать намаз укуны аңлатты. Моны да башкаргач, күктән бер тәхет иңде. Аның аяклары көмештән, утыргычы алтыннан иде. Үзе төрле энҗе-мәрҗән, якутлар белән бизәлгән иде. Җәбраил аның өстенә Мөхәммәтне утыртты. Канатларын сирпеде. Мөхәммәт пәйгамбәрне тәхетендә килеш һавага күтәреп, барлык тарафларны күрсәтте. Мең мәләик-фәрештәләр, тәхет янына килеп, рәсүлгә кадер-хөрмәт күрсәттеләр.

Шуннан соң Җәбраил канатын җиргә орды. Бер чишмә хасил булды. Ул сафланып тәһарәтләнде һәм:

— Шаһитмын, Алладан башка илаһи зат юк, аның илчесе хактыр. Син дә шушы рәвешле тәһарәт ал һәм мин әйткәннәрне кабатла,— дип белдерде.

Мөхәммәт пәйгамбәребез аның таләбен җиренә җиткереп үтәде, шаһитлыгын бирде. Шуннан бу билгеле булды: һәркем шушы рәвешле тәһарәт алса, барлык гөнаһларыннан ярлыкаланыла һәм җәннәтле була. Моны үтәмәгән кешеләр исә тәмуг кисәве хәленә төшәчәкләр икән.

Шушыннан соң Җәбраил фәрештә күк катына күтәрелде. Мөхәммәт пәйгамбәр исә тау ягына таба атлады. Анда күктән бер өн килде.

Мөхәммәт пәйгамбәр күтәрелеп карауга, адәм сурәтле Җәбраил фәрештәне күрде һәм аның:

— Йә Мөхәммәт, син инде Аллаһы тәгаләбезнең рәсүлесең,— дигән сүзләрен ишетте.— Әгәр күктән түбәнгә баксам, сине һәрдаим күреп торырмын,— диде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам өенә кайтып җитте. Хәдичә янына килгәндә генә Җәбраил хәзрәтләре юкка чыкты. Пәйгамбәребез Хәдичә ханымның тезенә егылды. Ул калтырана иде.

— Мин хәвефкә тардым,— дип, Мөхәммәт Хәдичәгә вакыйганы бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Тыныч кына тыңлаганнан соң хатыны әйтте:

— И Мөхәммәт, Аллаһы тәгалә сиңа бер хәвеф-хәтәр дә китермәс, ул сиңа пәйгамбәрлек биргән. Синдәй дә яхшы холыклы, матур табигатьле, камил акыллы бәндәсенә мондый изге бурычны йөкләгән икән, аны ихластан үтәргә кирәк,— диде.

Әмма Мөхәммәт пәйгамбәрнең хәвефе бетмәде. Ул аптырашта иде, үзенә килгән затның Җәбраил фәрештәме, әллә инде Иблисме икәнлеген тәгаен генә белә алмады.

— Әгәр теләсәң, бу хәлне туганым Вәракага сөйлим. Ул «Инҗил»не камил рәвештә белә, гарәпчәгә дә күркәм сурәттә тәрҗемә иткән иде. Ул төгәл хәбәрләр бирмәсме?— диде Мөхәммәт галәйһис-сәламгә Хәдичә.

Ул вакытта Вәрака бине Нуфал бер карт иде. Күзләре дә сукырайган, сәламәтлеге дә какшаган иде. Ул һаман да кыз туганнарыннан булган Хәдичә ханымның тәрбиясендә яши иде. Гомерен Аллаһы тәгаләнең хак юлын эзләүгә сарыф итте.

— И абзам-туганым, миңа Җәбраилдән бер-бер хәбәр бирсәң иде?— дип үтенде аннан Хәдичә.

— Шәһәребез — потчылар йорты, монда потлар бар, шунлыктан иманы камил булган Җәбраил бу илгә килмәс,— дип җавап бирде аңа Вәрака.

— Мөхәммәт әйтер, аңа Җәбраил килгән һәм аңа хак дин китерүен тәкърарлаган,— диде Хәдичә, туганына эшне аңлата башлап.

— И Хәдичә, әгәр туры-хак сөйләсәң, ул бәндә бөек намус иясе булыр. Җәбраил галәйһис-сәлам Муса һәм Гайсә пәйгамбәрләргә дә килгән иде...— диде Вәрака.

— И туганым, әйтче, «Тәүрат» һәм «Инҗил»дә бу заман бер фәкыйрь вә ятим бәндәгә Җәбраил килүеннән хәбәрләр юкмы? Ул кемсәнең байлыгы вә акылы камил булырмы? Бер яхшы вә хөрмәтле хатынны Аллаһы тәгалә аның бәхете итәрме?— дип сорады.

Моңа каршы Вәрака әйтте:

— Әйе, ул хатын син буласың, синең барлык сыйфатларың «Тәүрат» вә «Инҗил»дә хәбәр ителгәнгә туры килә. Ул бәхет иясе бәндәне агачлар һәм ташлар сәламләр вә нәүбәттә шәһадәт итәрләр, дигән риваятьләр бар. И Хәдичә, Җәбраил фәрештә бер килгән җиренә кабаттан килер. Син дә анда бар. Ул күренүгә, чәчеңне ач, әгәр дә фәрештә булса, югалыр, Иблис булса, азар!— диде.

Шушы сөйләшүдән соң Хәдичә ханым Мөхәммәт янына килде һәм:

— Әгәр дә ул күренгән зат тагын да сиңа килә калса, мине дәшәрсең,— диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр догага утыргач, Җәбраил фәрештә аның янына тагын килде. Аны күрүгә, Мөхәммәт Хәдичә ханымны чакырды. Хәбәрне алуга, хатыны килеп тә җитте, Мөхәммәтне сул тезенә алды һәм сорады:

— Ул затны күрәсеңме?— дип.

— Күрәм!— дип җавап бирде аңа Мөхәммәт пәйгамбәр.

Шуннан соң Хәдичә ханым ирен сул як тезенә алды да:

— Һаман да аны күрәсеңме?— диде.

— Күрәм!— диде аңа ире.

Шуннан соң Хәдичә ханым Мөхәммәт галәйһис-сәламне кочагына алды, соравын кабатлады. Ире исә:

— Күрәм! — дип җавап бирде.

Мөхәммәтнең шушы җавабыннан соң Хәдичә ханым чәчен ачып җибәрде дә:

— Һаман да ул затны күрәсеңме? — дип сорады.

Мөхәммәт пәйгамбәр Хәдичә ханымның Вәракадан алган киңәшләреннән хәбәрсез иде. Үз чиратында Хәдичә дә иренә хаклыкта Җәбраил килгәнлекне беләсе килә һәм сынап карау нияте дә юк түгел иде.

— Инде югалды, күренми, — диде Мөхәммәт.

— И Мөхәммәт, сиңа изгелекләр яусын, әле күренгән бу зат Иблис түгел, фәрештәдер! Аның сиңа китергән сүзе рахманидыр! — дип пәйгамбәребезне сөендерде.

Шуннан соң Хәдичә ханым бу вакыйганы туганы Вәракага килеп сөйләде. Аның сүзләренә инанганнан соң:

— И Хәдичә, минем яныма Мөхәммәтне чакыртсаң иде, сөйләшер идем, — дип үтенде Вәрака.

Хәдичә ханым туганының сүзен кире какмады, ирен чакыртып китерде. Мөхәммәт килүгә, Вәрака:

— И бәхет иясе. Муса галәйһис-сәлам үз заманында шулай дип белдереп калдырган. Әйткән: миннән соң бер пәйгамбәр килер, исеме Әхмәт булыр, дигән. Ул Әхмәт дигәннәре син булырсың. Бу исемгә Гайсә галәйһис-сәлам дә лаек булырга теләгән, әмма Аллаһы тәгалә аңа насыйп итмәгән, — диде һәм, — әгәр дә яшь егет исәм, мин синең яклаучың булыр идем. Үзеңнең кавемең сине шәһәрдән куалаганда да янында булыр идем. Әмма мин — картайдым инде, шулай да шәригатеңә керергә рөхсәт ит, — диде.

Вәраканың бу сүзләрен ишеткәч, Мөхәммәт пәйгамбәр:

— Мине кавемем чыннан да шәһәремнән китәргә мәҗбүр итәчәкмени? — дип сорады, күңеле боегып калды.

Вәрака исә аның аякларын үпте һәм:

— Кешеләр арасына килгән пәйгамбәрләрнең барчасын да үз халкы кире каккан, чөнки алар үз араларында пәйгамбәр туунын ни бөек вакыйга икәнлеген аңлап бетермиләр. Сине дә бу кавемең шәһәреңнән китәргә мәҗбүр итәр, — дип белдерде.

Шушы вакыйгалардан соң озак та тормады, Вәрака вафат булды. Мөхәммәт пәйгамбәр аны төшендә күрде. Вәраканың җаны җәннәтле булган иде. Ул, яшел чапан киеп, иман китерде. Бу төшен Мөхәммәт Хәдичә ханымга сөйләде, аны сөендерде, үзе дә Вәраканың иман китерүенә куанган иде.

Туганы Вәрака вафатыннан соң Хәдичә ханым Гаддас раһиб хозурына барды. Бу — носари монахлардан булган кемсә, озын гомерләр яшәп, кашлары да күзләренә кадәр төшеп тора иде.

— Бу кергән хатын корәиштән хөрмәтле бәндәдер, — дип Хәдичәне каршы алды ул.

— Әйе, — диеп Хәдичә ханым җавап бирүгә, башына чалмасын чалды, кашларын күтәртебрәк куйды да:

— И хөрмәтлем, якынрак утыр, колакларым ишетми, — дип белдерде. Әмма Хәдичә аның яныннан урын алмады, бәлки иелебрәк килде дә:

— И Гаддас, миңа Җәбраил галәйһис-сәламнән хәбәр бирсәң иде, — дип үтенде.

— Аллаһы тәгаләгә табынмаган кешеләргә Җәбраил фәрештә килерме? — диде сорауга каршы сорау белән раһиб.

— Әмма миңа аның хакында хәбәрләр бирсәң иде? — диде тагын да Хәдичә ханым.

— Нәрсә өчен мондый таләпне куясың? — диде тагын сорауга сорау белән Гаддас. — Сәбәбе нидер? Сәбәбен әйтми торып, Җәбраил фәрештә хакында хәбәремне бирмәм! — диде ул.

— Мөхәммәт бине Габдулла бине Габделмотталип үзенә Җәбраил фәрештә килә диеп әйтә,— дип серен чиште Хәдичә.

— Җәбраил фәрештә Муса вә Гайсә пәйгамбәрләргә вәхи китерде. Әгәр бу потлар белән тулган шәһәргә Җәбраил галәйһис-сәлам килде исә, безләргә бөек хәер вә бәхетләр иңәр. Әмма шул рәвешле Иблис-шайтан да килергә, җеннәр дә күренергә мөмкиннәр. Алар да вәсвәсә кылып, кешеләргә коткы сала белер, барчаларны адаштырыр. Менә бу китапны ул зат килгән җиргә куйсак, шайтан-җен булса, янып юкка чыгар, ә фәрештә килсә, аңа һичбер зыян булмас, бу китапны күреп, ул качмас,— диде һәм Хәдичәгә шул китабын тапшырды.

Бу вакытта Мөхәммәткә Җәбраил яңа бер аять китерде. Хәдичә бу аятьне пәйгамбәребез авызыннан ишетте. Фәрештә исә китапны күреп качмады. Хәдичә ул затның чыннан да Җәбраил булуына ианнды. Иренә:

— Гаддаска бар, йә рәсүлуллаһ, атам вә бабам сиңа фида булсын,— диде.

Гаддаска килделәр. Раһиб аны үз янына чакырып алды. Аркасындагы мөһерен кулы белән капшады, Мөхәммәт алдында сәҗдә кылды һәм, башын күтәреп:

— Валлаһи, син шул пәйгамбәр икәнсең. Синең килүеңне Муса вә Гайсә пәйгамбәрләр бәхәс иттеләр. Валлаһи, әгәр мин синең үз халкыңны дингә чакырган вакытыңда яшәсәм, кылычымны кынысыннан чыгарыр идем, юлыңда җаным фида булыр иде,— диде. Аннары: — Сиңа фәрештәдән берәр әмер булмадымы? — дип сорады.

— Юк! — диде аңа Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Әмер килер, син бу шәһәрнең халкын дингә өндәрсең, әмма алар сиңа каршы чыгарлар, сине үтерергә теләрләр. Син бу шәһәрдән һиҗрәт кылырсың. Әмма фәрештәләр сиңа һәрдаим ярдәм итеп торырлар,— диде.

Бу ике диндарның дәлилләреннән соң Мөхәммәтнең пәйгамбәрлеге, аның янына килгән затның фәрештә булуында һичбер шик-шөбһә калмады. Әмма моннан соң Җәбраил галәйһис-сәлам өч ел буена Мөхәммәт пәйгамбәр янына килмәде. Рәсүл аптырашта калды, әмма намаз-догалардан аерылмады.

Тарихлардан шул мәгълүм, өч ел үткәннән соң Җәбраил галәйһис-сәлам тагын да Мөхәммәт пәйгамбәр каршына килеп чыкты. Мөхәммәт аны бер тәхет өстендә утырган рәвештә күрде. Ул тәхет күк белән җир арасында эленеп тора иде.

Шушы очрашуларыннан соң Мөхәммәткә бер-бер артлы тагын да вәхи иңә башлады. Җәбраилнең өч ел буена килми тору сәбәбе шуннан гыйбарәт иде ки, ул пәйгамбәребезне сабырлыкка өйрәтте. Икенче яктан аның хакыйкыйлыгын, тугрылыгын, намус камиллеген дә сынап каравы иде. Мөхәммәт галәйһис-сәлам исә, вәхи килми торып, үзлегеннән бер генә аятьне дә әйтмәде. Алдашу юлына басмады, Җәбраил фәрештәдән хәбәр көтте. Өч ел буена сыналганнан соң, әлбәттә, Мөхәммәткә Аллаһы тәгаләнең сүзе ирешә. Шушыннан сабырлы кешеләрнең саф күңелле, туры сүзле, күркәм намус иясе булуларын белделәр.

## Беренче мөселманнар

Мөхәммәт пәйгамбәргә хатыны Хәдичә ханым күп тапкырлар ярдәм кулын сузды. Инде дә рәсүл үз көченә ышанып торсын өчен һәм Мәккә халкының дошманлыгыннан курыкмасын дип аңа:

— И Мөхәммәт, син Алланың илчесе, гамь-сагыш диңгезенә төшеп, буеңны сындырма, динеңә дошман кешеләр барыбер һәлак булырлар,— дип әйтә торды.

Җәбраил галәйһис-сәлам Хәдичә ханымга бу хезмәтләре өчен рәхмәтле иде. Асылда Мөхәммәт пәйгамбәр һәм аның хатыны Хәдичә ханым беренче мөселманнар булдылар. Бер килүендә Җәбраил фәрештә:

— И Хәдичә, сиңа Аллаһы тәгаләбезнең сәламнәре иреште һәм мин Җәбраил галәйһис-сәламнән сәлам! — диеп белдерде.

Фәрештәнең шушы сүзләрен ишетеп торган Мөхәммәт пәйгамбәр:

— Хәдичә, ишетәсеңме, Җәбраил галәйһис-сәлам сиңа Аллаһы тәгаләбездән сәлам ирештерде? — дип сорады.

Шуннан соң Хәдичә дә үзенең сәламнәрен тапшырды. Вакыйгаларда шулай сөйләнелә ки, шушы көннең ахырында икенче кеше булып хәзрәте Гали иманга килде, Хәдичәдән соң ул да мөселман булды.

Гали хәзрәтләре Мөхәммәтнең тәрбиясендә яши иде. Бу вакытларда аңа ун яшь тулып, ул үз алдына акыллы гына фикер йөртүче үсмер булып килә иде. Хәдичәгә Аллаһы тәгаләдән Җәбраил фәрештә сәлам китергән көнне Гали өлкәннәр катына үтте һәм Мөхәммәт белән Хәдичәнең дога вакытына туры килде.

— Сез нишлисез? — дип сорады.

— Бу — Аллаһы тәгаләдән иңгән дин, аны олылап намаз укыйбыз. Сине дә шул дингә дәгъвә итәм! — дип белдерде Галигә Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Бу нинди дин? Мин аның хакында ишеткәнем юк,— диде хәзрәте Гали.— Мин башта атам белән киңәшим, аннан соң ул дингә керүкермәвем хакында әйтермен! — дип белдерде.

Атасы янына барырга дип юлга чыккан Гали хәзрәтләре урам уртасында тукталып калды һәм: «Ни өчен әле бу хакта атам белән киңәшергә тиешлемен?» — дип уйланды да кире борылып кайтты. Шул кичне ул иман китерде, хак мөселман булды.

Өченче кеше булып Зәйд бине Харис исламга керде. Аның хикәяте китапларда бу рәвешле сөйләнелә...

Хәдичә ханымның Хәким ибне Хаззам исемле туган тиешле агасы бар иде. Көннәрдән беркөнне ул кол хезмәтчеләрне сатарга дип Шам тарафыннан Мәккә шәһәренә китерде. Туганын күрергә, аның хәл-әхвәлен белешергә Хәдичә үзе килде. Хәким бине Хаззам кыз туганы Хәдичәне бик җылы каршы алды һәм:

— Бу малайларның кайсын телисең, шунысын ал,— дип сатарга китерелгән колларны тәкъдим итте. Хәдичә исә Зәйдне сайлап алды һәм ире Мөхәммәткә китереп бүләк итте. Мөхәммәт Зәйдне бик якын күрде, уллыкка алып, аңа азатлык бирде.

Вакыйганың бу өлеше вәхигә кадәр булган иде.

Шам тарафында яшәүче атасы Харис улы Зәйднең Мәккә тарафына илтеп сатылуын ишеткән иде. Ул, күп юллар кичеп, шәһәргә килде. Халыктан сораша торган, Зәйднең Мөхәммәтләр йортында яшәвен белеп алды. Рәсүл каршына килеп, канлы яшьләрен агызды, аны үзенә кайтарып бирүен үтенде.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам Зәйдне чакыртты һәм:

— Синең атаң үзеңне ерак юлдан эзләп килгән, теләсәң, аның белән китәрсең, теләсәң, минем йортымда малаемдай яшәп калырсың,— диде.

Рәсүлнең бу сүзләрен ишеткәннән соң Зәйд ибне Харис:

— Атам янында хуҗа булып яшәгәнче, кабул итсәң, сезнең колыгыз булып калуны өстенрәк күрәм! — дип җавап бирде, атасыннан гафу үтенеп, Мөхәммәт пәйгамбәр янында калды. Ул вакытларда вәхи иңеп, рәсүлебез Зәйд бине Харисны исламга өндәгән, ул инде мөселманлык алган иде.

Мөхәммәт пәйгамбәр, Мәккә таифәсенең җәбер-золымыннан шикләнеп, намаз уку өчен шәһәрдән читкә чыга иде. Ул догада булганда, иминлеген һәрвакыт Гали саклап торды. Әбу-Талип та, Фатыйма да уллары Галинең ислам динендә икәнлеген белми иделәр. Әмма беркөнне Әбу-Талип улы Хәйдәр белән бергә шәһәрдән читкә нindидер эш белән

килде, Мөхәммәтнең намаз урынына очрап, читтән генә карап тордылар һәм шуннан соң пәйгамбәр янына Әбу-Талип килде дә:

— Син нәрсә эшлисең? — дип сорады.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам серен чиште:

— Аллаһы тәгаләне бердәнбер вә тиңдәше юк дип таны. Аллаһы тәгаләдән башка зат гыйбадәткә лаек түгел! — дип белдерде.

Әмма Әбу-Талип иман китермәде:

— Синең бабаң Габделмотталип табынган потлардан башкага гыйбадәт кыласым юк! — дип ачуланды.

Әмма улы Хәйдәр исә энесе Гали төсле үк иман китерде һәм Мөхәммәтнең догаларын аның артыннан кабатлап барды. Рәсүлебез аңа:

— Син җәннәткә кергәч, иңенә канатлар эленеп, очып йөрерсең,— дип дога укыды. Теләгең Аллаһы тәгалә кабул итте. Фәрештәләргә генә хас булган канат аңа да бирелде.

Бу хәлләрдән соң Әбу-Талип хатыны Фатыймага эшне сөйләп бирде. Сүз Мәккә халкына таралды. Алар хәвеф дингезенең кара упкынына күмелделәр.

Күп еллар элгәре Әбу-Бәкер белән бер вакыйга булган иде. Аны хикәяләүчеләр болайрак дип сөйлиләр...

Әбу-Бәкерне хәйран итеп, күк йөзендә ай төсле бер нур пәйда булып, вак кисәкләргә бүленде һәм Мәккәнең йортларына коелды. Берсе исә Әбу-Бәкергә туры килде.

Озак та үтми, ул нурлар, бергә җыелып, элеккеге хәленә кайттылар, әмма Әбу-Бәкергә насыйп булганы күккә күтәрелмәде. Бу вакыйгадан соң аптырашта калган сәүдәгәр ни уйларга да белмәде. Моның аңлатмасын эзләп, бер яһүдигә мөрәҗәгать итте, әмма ул кемсә:

— Игътибар итмә, бу бер очраклы нәрсә генә,— дип аны тынычландырды.

Еллар үтеп, Әбу-Бәкер Бәхирә сумгасына, килеп чыкты, аңа да бу вакыйгадан хәбәр бирде һәм тәгъбирен үтенде. Бәхирә исә:

— Мәккәдә бер олуг зат туган булса кирәк, ул Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре булыр. Син исә аның вәзире булырсың. Үзе вафат булгач, аның урынында калырсың. Бу нур вакыйгасы менә шул хакта сөйли,— дип хәбәр бирде.

Гомерләр кичкәннән соң, Мәккә халкыннан Әбу-Бәкер Мөхәммәт пәйгамбәр хакында ишетте һәм аңа килеп:

— Сиңа дин иңгәнен, вәхи килгәнен ишеттем, хак сүзме? Хак булса, пәйгамбәрлеккә дәлилләрең ни-нәрсә? — дип сорады.

Моңа каршы Мөхәммәт галәйһис-сәлам шушы нур вакыйгасын сөйләп бирде, тәгъбирен белдерде. Гаҗәпкә калган Әбу-Бәкер:

— Минем бу хәл турында һичкемгә сөйләгәнем булмады. Миннән хәбәр алган кешеләрне дә син күрмәдең. Алар да сөйли алмагандыр. Үзем исә аптырашта калдым. Син бу хакта хәбәрне кайдан алдың? — диде.

— Миңа бу турыда Җәбраил галәйһис-сәлам хәбәр бирде,— диде рәсүл үзенең җавабында.

Бу сүзләрне ишеткәч, Әбу-Бәкер дә иман китерде. Мөхәммәтнең иң якыннарыннан берсе булып китте. Әбу-Бәкер әс-Сыйддыйк, дип йөртелә башлады. «Әс-Сыйддыйк» дигән «титулы» исә «дусты» дигән мәгънәдә, ягъни рәсүлебез Мөхәммәтнең иң якын дусты төшенчәсен үз эченә сыйдыра иде.

Әбу-Бәкернең исләлекләреннән дип шундый хәбәрләр сөйләнелә ки, көннәрдән беркөнне аңардан сорадылар:

— Син ни өчен Мөхәммәткә иман китердең, аның пәйгамбәр булуын кайдан белдең? — диделәр.

Әбу-Бәкер әйтте:

— Кызу көн иде, агач күләгәсенә килдем. Шул вакыт агачның телгә килеп, Мөхәммәтнең рәсүл булуы, аңа Аллаһы тәгаләдән вәхи ирешүе хакында кош-кортларга хәбәр бирүен ишеттем. Агач миңа:

— Бар Мөхәммәт пәйгамбәргә иман китер, барча халыклар да аңа иман китерерләр, әмма син алар арасында Мөхәммәт рәсүлнең иң якыны һәм иң кадерле дусты, аның эшләрен дәвам итүче булырсың,— диде.

Мин шунда Мөхәммәт пәйгамбәр янына барырга карар иттем. Боларның барчасын рәсүлгә сөйләп бирдем...

Әбу-Бәкер кебек данлыклы вә бай кешенең исламга керүе, билгеле, Мәккә кяферләрен аптырашта калдырган иде, чөнки ул һәр эшне акыл үлчәве тәлинкәләренә куеп, кат-кат үлчәмичә башларга бер дә ашыкмый һәм арада горур вә дәрәҗәле кемсәләрдән иде.

Хикәятләрдә тагын шулай сөйләнелә: көннәрдән беркөнне Мөхәммәт пәйгамбәр Әбу-Бәкернең бусагасын атлап керде һәм аның белән сөйләшергә теләген белдерде. Әбу-Бәкер исә Мөхәммәт белән күптәннән таныш иде, аларның үзара дуслыклары да бар иде. Тагын да шуны әйтәләр, Әбу-Бәкер Мөхәммәтне бик тә хөрмәт иткән, электән аңа ярдәм биреп килгән, диләр. Без моны күреп-укып киткән идек инде.

— Бу кич миңа бер фәрештә килде, кешеләрне хак дингә өндәргә кушты, Аллаһы тәгаләнең әмерен җиткерде,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр һәм Әбу-Бәкергә хак дин турында аңлатып бирде.

Әбу-Бәкер бу вакытта Йәмән иленнән сәүдә итеп кайткан, юлы бик уңышлы булган иде. Анда ул бер карт белән танышты. Бу кемсә озын гомерле, акыл вә гыйлем иясе иде. Әбу-Бәкер аны китап укып утырган чагында күрде. Сөйләшеп киттеләр, хәл-әхвәл белештеләр. Бу карт аңардан:

— Син Мәккә кешесе, корәиш кабиләсеннән түгелме? — дип сорады.— Шәһәрегездә Ахырзаман пәйгамбәре пәйда булыр, ул хак динне китерер, барча адәмнәр аның юлын дөрес күрерләр, мөселман булырлар, ә син исә аның иң якын дусты бул, эшендә ярдәмче вә киңәшче бул! — диде. Дәлил өчен, китабыннан берничә хәбәрне укып күрсәтте.

Әбу-Бәкер Мәккәгә килеп җитүгә, аның ишеген кактылар. Алар: Әбу-Җәһил, Шәйбә, Әбу-Бухтури һәм дә берничә гарәп иде. Күрештеләр. Сүзләре озын булды. Мөхәммәт пәйгамбәрнең яңа дингә халыкны чакыруыннан бердәй зарландылар. Әбу-Бәкергә аның артыннан иярмәскә киңәшләрен бирделәр һәм рәсүлне һәлак итәргә кирәклеген фикер сандыкларына салдылар.

Алар китүгә озак та үтмәде, Мөхәммәт пәйгамбәр үзе дә Әбу-Бәкернең ишеген ачып керде. Дустын исламга чакырды. Әбу-Бәкер исә:

— Пәйгамбәрләрнең хикмәтле эшләре була, синең ни-нәрсә? — дип сорады. Күңеленнән Әбу-Җәһил вә иптәшләренең киңәшләреннән чыкмады.

— Син Йәмән илендә булдың, анда бер карт белән очраштың. Аның сөйләгәннәре барчасы да хактыр,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Мин Йәмән илендә бик күп картларны очратып сөйләштем, кайсы хакында әйтәсең? — дип янадан сорады Әбу-Бәкер.

Мөхәммәт пәйгамбәрегез аңарга карт хакында белгән хәбәрләрен җиткәрде. Боларга Әбу-Бәкернең исе китте.

— Син моны кайдан белдең? — диде Әбу-Бәкер.

— Миңа фәрештә килде, бу хакта ул белдерде,— диде аңа рәсүл.

Бу сөйләшүдән соң Әбу-Бәкер иман китерде, дип хәбәр бирә галимнәр. Ни генә булмасын, Әбу-Бәкернең исламга керүе Әбу-Җәһил тарафдарларын хәйранга калдырды. Үзләренең үтенечләрен аяк астына салып таптавына аларның ачулары килде. Соңга калганчы, эш узганчы Мөхәммәтне үзләре һәлак итеп ташларга карар кылдылар.

Әбу-Бәкернең иманга килүе Мөхәммәт пәйгамбәр өчен гаять тә әһәмиятле булды, көчә бермә-бер артты.

Әбу-Бәкер иман китерү белән, үзенә мәҗлескә туган-тумачаларын, якыннарын, балаларын җыйнады. Аларны ислам диненә өндәде. Бу көнне аның фатихасы белән Госман бине Гафан, Зәбир бине Гавам, Талха бине Габдулла, Сәгыйть бине Әбу-Ваккас, Габдеррахман бине

Гауф — барчасы мөселман булдылар, кызы Әсма да исламга керде. Болар Мәккәнең дәрәҗәле кешеләре иделәр.

Хәзрәте Госман бине Гафанның иман китерү вакыйгасын китаплар бу рәвешле хикәя кылалар. Госманның таныш бер хатыны бар иде. Аның исеме Сугъдә иде. Кәрәз бине Рабига кызы булып, кяһен, ягъни жрец хезмәтендә иде. Көннәрдән беркөнне Госман аның янына килде һәм үзенең язмышы хакында күрәзәлек итүен сорады. Сугъдә исә:

— Сиңа бер хатын насыйп булыр, әмма син аннан алда хатын күрерсең, өйләнгән булырсың, ул да синнән алда ир күргәннәрдән булыр. Бик чибәр һәм акыллы хатын, ул — олуг пәйгамбәр кызы булса кирәк,— дип хәбәр бирде.

Бу сүзләрдән Госман бине Гафан аптырап калды. Хатын дәвам итте:

— Бу көннәрдә Мәккәдә бер олуг пәйгамбәргә вәхи килгән, ул үз диненә башкаларны да өнди. Кемнәр аның юлыннан китәр, гыйлем диңгезендә йөзәр, кемнәр аңа каршы чыкса, муеннарын кылыч кисәр,— диде.

Бу сүзләрне ишетүгә, Госман бине Гафан Әбу-Бәкер янына килде, йомышын сөйләп бирде. Хәбәрләргә караганда, шушы утыруда Госман мәҗлес алдында иман китерде.

Мөселманнар да Кәгъбәтуллада кяферләргә катышмыйча гына намаз укый торган булдылар. Моңа исә Мәккә кяферләренең ачуы килде, һаман-һаман тавыш чыгарып тордылар. Шулай бер тапкырында бу кяферләр мөселманнарга каршы бигрәк каты гауга күтәрделәр, иманлыларны хакарәтли башладылар. Дога кылып утырган Сәгыйть бине Әбу-Ваккасның кул астында бер-бер әйбере булып, ул аның белән үзенә каршы төкрекләрен чәчеп килгән кяфернең маңгаена сукты, тегенең башы тишелеп, йөзенә кан агып төште. Асылда бу кан мөселманнарның кяферләрдән чыгарган каннарының тәүгесе булды. Моның өчен алар Аллаһы тәгаләдән ярлыкау үтенделәр, әмма Бөек Ходай бу эшнең дөреслеген белеп торды һәм Сәгыйтькә авыруларны дога белән терелтү өстенлеген бирде. Аның укыган догасы шифалы булып, һәрбер хаста кемсәнәгә файдасы тими калмады.

Китапларда исә Сәгыйть бине Әбу-Ваккасның картлык көнендә күзе сукыраюы бәян ителә. Әйтәләр ки, аңа мөселманнар килеп:

— И Сәгыйть, синең догаңның шифасыннан без барчабыз да савыктык, авыру газапларыннан арындык. Ни өчен үзең өчен дә бер дога кылып, Аллалан савыгу сорамыйсың? — диделәр. Аларга каршы Сәгыйть бине Әбу-Ваккас:

— И мөселман кардәшләрем, Аллаһы тәгаләнең казасы минем өчен сөекле, шуны аңлагыз! — диде.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең иманга чакыруларына колак салып, мөселман булган кешеләр Мәккә шәһәрендә арта торды. Аларның ислам дине алулары хакында аерым-аерым сөйләп тору мөмкин булмаганлыктан, боларга тукталып тормадык.

Вәхи килгәннән соң өч ел кичте. Көннәрнең берендә Аллаһы тәгалә Мөхәммәт рәсүлгә халыкларны ислам диненә өндәргә боерды. Пәйгамбәр хак диненә барчасын чакыра башлады. Аннан соң Саффа тавына килде дә:

— И корәишләр, барчагыз да җыелышып килегез, сүзләремә колак салыгыз,— дип аваз салды.

Халык җыйнала башлады. Ул сөйли торды:

— Аллаһы тәгалә миңа вәхиен җиткерде, үзенең рәсүле, пәйгамбәре итте,— дип Аллаһыбызның китабыннан Коръән аятен укыды. Әмма аның сүзләре ахырына ирешкән, Әбу-Ләһәп килеп:

— Минем туганымның улы дивана булган, аның сүзләренә колак салмагыз, өммәтегездән аерылмагыз,— дип Мөхәммәткә бүлдерде. Аның шушы сүзләреннән соң Мөхәммәт пәйгамбәр аптырап калды, өенә кайтып китте. Ул көнне беркем дә мөселманлыкка күчмәде, иман китермәде.

Мөхәммәт рәсүл дога укыды. Аңа Җәбраил галәйһис-сәлам килеп:

— Башка бу юл белән кяферләрне иманга чакырма, алар сиңа үчләшерләр, бер-берсеннән куркып, хак юлга басмаслар, аларны диңгә башка төрле итеп өндә,— дип хәбәр бирде.

Мөхәммәт пәйгамбәр шушыннан соң үзенә кунак итеп кырыклап карендәшен вә туган тиешлеләрен чакырып, мәҗлес корырга булды. Әбу-Талипны, Габбас, Әбу-Ләһәп һәм башкаларны чакырды. Сый әзерләтте.

Кунакларга табак тутырып ит китерделәр. Башлап Мөхәммәт авыз итте, башкаларга табакны тапшырды. Сыйланганнан соң, катык-сөттән ясалган әйрән бүлделәр. Моны да барысы да эчеп туйдылар. Рәсүл сүз башларга гына торганда, Әбу-Ләһәп:

— Безнең Мөхәммәткә сихер уты төшкән булса кирәк, шуны берегез дә сизмиме?— диде.

Аның бу сүзләреннән соң Мөхәммәт пәйгамбәр:

— Синең кабиләңнән һичбер кемсә үз халкына ярамаслык эш кылмады, ә син шуны эшләдең...— диде. Бу сүзләрдән мәҗлестәге барча кунаклар мәмнүн булдылар, Мөхәммәт ягына авыштылар.

Бу хәлне күреп торган пәйгамбәр, сүзгә керешеп, үзенең Аллаһы тәгалә тарафыннан сайланган рәсүл булуын, башкаларның иман китерергә тиешлеген аңлатып бирде һәм:

— Кемнәр хак юлга керәләр, алар минем карендәшләрем булалар, кемнәр исә каршы төшәләр, алар минем дошманнарым,— диде. Бу утыруда Гали калкып, үзенең ислам диненә керүен хәбәр итте. Шуннан соң Мөхәммәт:

— Ул минем олугларымнан булыр, аның әмере сезнең өчен дөрес булыр, аның сүзенә итагать итәрсез,— диде.

Мөхәммәтнең бу сүзләреннән корәишләр көлешә башладылар, Әбу-Талипка:

— Карендәшеңнең улы әйткән сүзләрне ишеттеңме? Инде Гали улыңа итагать итәсең, аның әмерен үтәрсең,— диделәр.

Бу сөйләшүдән соң кяферләрнең киреләге тагын да арта төште. Мәккә олугларыннан булган Әбу-Җәһил һәм аның иярченнәре Мөхәммәтне ничек булса да үтерергә карар кылдылар.

## Кяферләр арасында

Иманга килүчеләр булса да, Мәккә шәһәре көферлек диңгезенә баткан килеш кала бирде.

Мөхәммәт пәйгамбәргә каршы торган горуһның башында Әбу-Җәһил бине Һашим тора иде. Аның рәтендә мактанчык байлардан вә кабилә башлыкларыннан бу кемсәләр бар иде: Әбу-Ләһәп бине Габделмотталип, Гакабә бине Әбу-Мәгыйт, Хәким бине Әбул-Гас, Өмәййәт бине Хәләф, Әбу-Каййас бине Рәйгаф, Назар бине әл-Харис, Мөнәббиһ бине әл-Хиҗаҗ, Саип бине Фәйз, Гасыйм бине Сәгыйть, Харис бине Каййас, Әсвад бине Габделәсәд, Гасыйм бине Һашим. Аллаһы тәгаләнең аларга ләгънәте төште. Пәйгамбәренә аларны һәлак итәчәген белдерде.

Көферлек диңгезе кара дулкыннарын уйната бирде. Карап торып халыкны Әбу-Җәһил ахмаклары Мөхәммәт пәйгамбәргә каршы өндәде.

— Ул күренә калса, өстенә таш атыгыз!— дип котырттылар.

— Безне ата-бабадан килгән динебездән аермакчы була, исламга чакыра. Һәлак итмичә, аннан котыла алмабыз,— диделәр.

Кяферләрнең яманлыгы эч-бавырларын актарып кайнады. Мөхәммәтнең кая да булса барганын күрсәләр, яки изге азанын ишетсәләр, кубарылып шунда килерләр, аңа ташлар ата башлар иделәр.

Мөхәммәт гаҗиз булды. Җәбер һәм золымны күп күрде. Көннәрдән беркөнне аны базар халкы да ташлар атып каршы алды Бу кяферләр котырган эт өереннән бер генә сыйфат белән дә аерылып тормас иделәр.

Мөхәммәтнең аяклары җәрәхәтләнде. Көн эссе иде. Канга батты. Йөрәге өзгәләнде. Әмма күз яшен күрсәтмәде. Сабырлык вә горурлыгын югалтмады, кяферләр алдында аяктан егылмады. Шушы эт төркеменең кан күрүгә бугазы тыгылуын көтте. Алардан азат булгач, өенә кайтты. Күңелендәге рәнҗүләрен Аллаһы тәгаләбезгә мөнәҗәт белән сөйләп бирде:

— Йа Илаһи, синең теләк белән һәр ни килә; килә калса, хуш, кабул итәм. Ләкин зәгыйфеңне вә гаҗизеңне күрәсеңдер. Бу җәбер вә золымнарны үзеңнең ризалыгың өчен чиккәнемне-күргәнемне дә беләсеңдер. Ярдәм итү өчен көчең җитәдер...— дип, дога кылды. Шул мәлдә аның янына Җәбраил галәйһис-сәлам килеп иреште.

— И Аллаһы тәгаләнең яраткан колы. Аның сәламнәрен кабул итеп ал. Ул синең хәбәреңне ишетте. Җиргә бер фәрештә иңдерде. Аны синең сүзеңне тыңлар өчен җибәрде. Бу фәрештәгә таулар буйсына, әгәр теләр булсаң, җиренә җиткерер,— дип Җәбраил галәйһис-сәлам Мөхәммәт пәйгамбәргә аңлатып бирде.

Ул да булмады, рәсүл янына тауларга кодрәте житүче фәрештә килде. Әйтте:

— Йә Мөхәммәт, миңа Аллаһы тәгаләдән боерык иреште. Мәккәнең ике ягындагы тауларны бер-берсенә чәкәштерермен. Ни Мәккә, ни аның әһеле исән калмас. Ике тау астында көл булып изелерләр. Әмереңне әйт! — диде.

Мөхәммәт уйга калды. Бу кадәр рәнҗетүләре өчен Мәккә әһеленә үчне кайтару мөмкин иде. Әмма:

— Мин халкымның һәлак ителүенең сәбәпчесе булыр өчен килмәдем. Аларны Аллаһы тәгалә җир йөзендә бар кылган икән һәм араларына мине рәсүле итеп күндерүне кирәк тапкан икән, мин бөтенесен мөселман итми вә һәммәсенә Аллаһы тәгаләнең бирелгән танытмый юлымнан кайтмамын. Ни золымнары булса да, түзәрмен. Аллаһы тәгалә бурычын үтәү юлы — изге юл. Аннан тайпылмам! — дип җавап бирде бу фәрештәгә Мөхәммәт пәйгамбәр.

Шушы вакыйга Мөхәммәт галәйһис-сәламнең башка пәйгамбәрләр белән чагыштырганда никадәр бөек вә өстен булуын күрсәтте.

Ул вакытларда да корәиш кабиләләре изге саналган Кәгъбәгә хаҗ кыла вә аны зурлый иделәр. Бу хаҗ кылырга килгән халыкка күпне күргән һәм арада хөрмәт казанган Вәлид бине Мөгайрә Мөхәммәт пәйгамбәр хакында вә дине турында сөйләде. Арадан күпләр иман китерделәр.

Бу эшләр Мәккә кяферләренә ошамады. Алар гыйбадәтханәдә шулар хакында җыелышып сөйләшә башладылар. Шулвакыт урталарына Мөхәммәт килеп керде.

— Син ни өчен безнең корәишләрне бүләсең, аларны бер-берсенә каршы куясың? — дип кяферләр аңа ябыштылар.— Безне динебездән аерып, башка юлга өндәвеңә түзеп тордык, инде дә түземлегебез бетте,— дия-дия орыша, тавыш чыгара башладылар.

Араларыннан Мөхәммәт пәйгамбәр имин чыгарлык түгел иде. Әмма ул үзенең хак юлыннан ваз кичмәде.

Икенче көнне дә кяферләр җыелыш кордылар. Ачу зәһәрен чүмереп, һаман да уйларын ахмаклык баганасыннан чишеп җибәрергә ашыкмадылар.

— Ул сүзебезгә колак салмый. Барчабызны да харап итәргә уйлый икән. Үзен үтерик,— дип сөйләштеләр.

Шул вакытта араларына тагын да Мөхәммәт пәйгамбәр килеп керде. Тегеләр аңа һөҗүм иттеләр. Гакабәт бине Әбу-Мәгыйт аның янына килде. Ике куллап Мөхәммәтнең якасына ябышты.

Вакыйгалар шул рәвешле барган вакытта арага Әбу-Бәкер үтеп:

— Сез әле Мөхәммәтне харап итеп, үтерергә уйлыйсызмыни?! Бөтен кавемемне күтәреп китерермен. Ул безләргә изге аятьләр тапшырды,— дип әйтергә өлгермәде, кяферләр барчасы, пәйгамбәрне ташлап, Әбу-Бәкергә ябыштылар. Аны егып, типкәли башладылар. Ул арада халкына хәбәр ирешеп, Бәни-Тамимдар килеп җитте һәм Әбу-Бәкерне кяферләр кулыннан йолып алды.

Бу әле гаугаларның башы гына иде. Кяферләрнең йөрәк түренә шәйтаный коткы кереп оялады, бәгырьләрен кимерде. Алар, бер йортта җыелыш корып, янә дә Мөхәммәтне үтерергә килешенделәр.

Хәбәр Хәдичә ханымга ирешә. Кайгыга калды. Йөрәге тынычсызланды. Аһ орып, пәйгамбәр янына килде һәм хәсрәтен бәян итеп бирде. Аның сүзләрен тыңлаганнан соң, үзен үтерергә исәп тоткан кяферләр арасына килеп керде дә аларның йөзләренә тузан сипте. Бу хәлдән барчасы аптырап калды.

Көннәр үтә торды. Кяферләр арасыннан бер кешене күндереп, Мөхәммәт пәйгамбәр белән сөйләшергә вә иманга чакыруыннан туктатырга үзара килештерергә җибәрделәр. Ул кемсә, хәбәрләргә караганда, Әбул-Вәлид иде. Рәсүл янына үтеп сәлам бирде һәм:

— И корәиш арасында танылган борадарым баласы, сүзләремне тыңла, үгетләремә колак сал,— диде. Әгәр сиңа хатын кирәк булса, араларыбыздан чибәр кызны табып бирербез, әгәр дә инде байлык эзләсәң, алтын-көмешкә күмәрбез, телисең икән инде, барыбызга шәех итеп куярбыз. Әмма көчәя барган каршылыкларны бетер дә ата-бабадан килгән динебездән аерма!— дип ник килгәнлегеннән хәбәрен бирде.

Мөхәммәт пәйгамбәр Коръәннән бер аятьне укыды һәм сәҗдә итте. Әбул-Вәлид аның сүзләренә колак салып торды. Артыннан ихтыярсыз рәвештә кабатлады, ияреп сәҗдә кылды.

Рәсүл догасын тәмамлады.

— Йә Әбул-Вәлид, укыган аятьләремне ишеттең, инде бар, юлыңда бул!— диде.

Илче үз кавеме янына китте. Кяферләр аның һаман да әйләнеп кайтмаганы өчен борчылып тора иделәр. «Берәр сихер кылмадымы?»— дип тә сөйләнделәр.

Әбул-Вәлид алар янына кайтты һәм Мөхәммәтне мактап сөйләргә тотынды:

— Аннан шундый да җанга рәхәтлек бирә торган сүзләр ишеттем ки, аларны моңа кадәр һичкаян вә һичкемнән ишеткәнем булмады,— диде.

Кяферләргә бу сүзләре ошамады. Алар:

— Мөхәммәт сине сихерләгән,— ди башладылар.

— Мин сезгә күргәнемне вә ишеткәнемне сөйләдем, ышану-ышанмау — үз эшегез,— дип белдерде Әбул-Вәлид.

Кяферләр Мөхәммәт пәйгамбәрне сихер иясе вә кешеләрне аздыручы дип мыскыл итәргә теләделәр. Шулай итеп, аның дәрәҗәсен төшерергә теләделәр. Әмма моңа карап, Мөхәммәт галәйһис-сәлам аларга бәддога укымады, Мәккәнең вә аның иминлеген саклады, сабыр итте.

Көннәрдән беркөнне кяферләр Кәгъбәгә җыелыштылар. Әбу-Җәһил монда бер үлгән дөянең эчәгеләрен төяп алып килде. Мөхәммәт пәйгамбәр бу вакытта Кәгъбәтулла эчендә намаз укый иде. Әбу-Җәһил:

— Кайсыгыз батырчылык итеп аның өстенә бу дөя эчәгеләрен өяр?— дип сорады.

Арада бәдбәхет Гакабә бине Әбу-Мәгыйт тә бар иде. Ул шушы яман эшне башкаруны үз өстенә алды. Батырчылык кылды. Мөхәммәтнең догада вакытында аркасына бу эчәкләрне китереп салды. Әмма пәйгамбәр намаздан бүленмәде.

Бу хәбәрләр Фатыйма ханымга ирешә. Ул, урыныннан кубып, монда килде. Пәйгамбәрнең аркасыннан сасы эчәкләрне алып ташлады.

Бу вакытта Мөхәммәт намазын тәмам итеп, аннан туктаусыз көлешеп торган кяферләргә таба борылды һәм:

— Әссәламегаләйкем, Әбу-Җәһил бине һашим, Гакабә бине Әбу-Мәгыйт, Шәйбә бине Рабига, Вәлид бине Гакабә, Гакабә бине Могыйт, Аби бине Хәләф, Гомәр бине Вәлид,— диде. Күз алдына Аллаһы тәгалә әмере белән килер көннәрдә булачак Бәдер сугышы вакыйгалары килде, мәҗүси кяферләрнең вафаты вә һәлакәтләреннән хәбәрләр ирешә. Пәйгамбәрнең күңелен тәвәккәллек ташы ныгытты.

Бу эш белән кяферләр тынычланып калмадылар. Мөселманнарны җәберләү вә мыскыллау юлыннан иман тарафына борылырга җаннарының көченнән килмәде. Үчлек ташлары кызганнан кызды.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, кяфер Өмәййәт бине Хәләфнең Билал исемле колы бар иде. Ул кемсә (Алланың аңа рәхмәте яусын) хак мөселман булып, хуҗасына сиздермичә генә Кәгъбәдә Аллаһы тәгаләгә табына иде. Моны бине Хәләф белеп алды, кайнарланып, үч богавын аның муенына салды.

Бик эссе җәй көннәре булганлыктан, ком вә ташлар уттай кайнарланып кыза һәм атларның тояклары да пешә торган вакыт иде. Өмәййәт исә колы Билалны ни рәвешле җәберләргә вә мыскылларга кирәклеге хакында Мәккә кяферләре белән киңәште. Шуннан соң Билалны кайнар комга бәйләп салды, шул рәвешле көн-төнен үткәртеп, тәмам хәлсезләндереп бетерде. Болай гына да аның ачуын суыта алмады. Билалның тәннәре кояш вә ком эсселегеннән мәлҗерәп, уелып-уелып төштеләр. Бәдбәхет бине Хәләф исә җәзалауны тагын да дәвам иттерде. Билалны кайнар таш өстенә китереп салды, миңгерәүләтеп-гарипләтеп бетерде. Һәм:

— Иманыңнан кире кайт, юкса җаныңны алырмын! — диде.

Билалның телдә сүз әйләндерерлек хәле юк иде. Әмма ул иманыннан кире кайтмады:

— Алла бердәнбер! — дип җавабын бирә белде.

Билалның шушы газапларын күреп, ком вә ташларда изаланган чагында аңа Вәрака бине Нуфал очрады, иманнан кире кайтмауның бөеклеге хакында берничә кат бәетләр әйтеп үтте.

Билалның яман хәле хакында белеп, Әбу-Бәкер хәйранга калды. Җәза мәйданына килде. Билалның иманы нык булуын ишетеп алды. Башта бине Хәләфтән җәберләүләрне туктатуны үтенеп карады. Әмма кара кяфер:

— Бу бәндә минем колым, ни эшләтсәм, шул булыр, ни кылсам, шул иркемдә,— дип җавап бирде.

— Ул вакытта син аны миңа сат?! — диде Әбу-Бәкер.

— Бу колым инде эшкә ярамый, ә сиңа ун алтынга бирә алам,— диде бине Хәләф.

Әмма бу акчага ярты базарыңны сатып алырга мөмкин иде. Кем инде шулай итә?

Әбу-Бәкер мөселман карендәшен бәладән йолып алу өчен ун бөртек алтынын кызганмады, кабәхәт Өмәййәт бине Хәләф алдына сораганын китереп салды.

— Үзеңә гаҗәп зур зыян эшләдең, мин моның өчен тиен дә бирмәс идем,— дип көлде Әбу-Бәкердән бу бәдбәхет.

Әмма сахабә югалып калмады:

— Юк, гаҗәп зур файда эшләдем, әгәр дә бу бәндә бәрабәренә бар байлыгымны сорасаң да, җәлләмәс идем,— дип җавап бирде, мөселман карендәше Билалны кара козгын авызыннан тартып алды, өенә китереп юындырды, өстенә яхшы киемнәрен кидерде һәм халык алдында аны азат кеше дип игълан итте.

Мәккә кяферләре мөселманга кергән яки мөселманлыкка авышу хәлендә булган колларын җәберли-җәзалый башладылар. Берләрен ике дөя арасына тагып һәлак иттеләр, кайсыларын кайнар сахра комында

харап иттеләр, күпләрен кыйнап үтерделәр. Әмма ирекле кешеләрдән булган мөселманнарга кул сузарга кодрәтләреннән килмәде. Кан өчен кан белән түләү кануны яшәгән бу шәһәрдә берәүнең туганын үтерә калсаң, аның кардәш ыруы үзенең башына җитмичә, кан белән үчне кайтармыйча суынмый иде. Шунлыктан Мөхәммәт пәйгамбәрне дә харап итә алмадылар. Әмма бу эшкә Мәккә кяферләренең куллары кызышып торды, әле берсе, әле икенчесе сәбәп эзләде. Бары тик Мөхәммәтнең сабыр холыклы вә түземле булуы гына аны күп авырлыклардан һәм көтелмәгән хәлләрдән саклап калды.

Мөселманнар илдән китәргә, кайда булса да сыену эзләргә киңәштеләр. Әбу-Җәһил һәм аның кара җанлы иярченнәре, якын-тирә кяфер кабиләләре исламда булган сәүдәгәрләрдән әйберләр сатып алмаска, алар белән аралашмаска килештеләр. Сәүдә белән яшәүче, сәүдәдән башка тормышларын күз алдына да китерә алмаучы мөселманнар өчен моннан да зур авырлык бар идеме икән?! Җәбер-золым өстенә ачлык тырнагы да аларның якаларына таба кулын сузды. Бу хәлдән бары тик Мәккә кяферләре арасыннан китү белән генә котылып була иде. Мөхәммәт пәйгамбәр беренче һиҗрәт, яки «тәүге китү» дип аталган шушы күченүгә рөхсәтен бирде.

## Тәүге һиҗрәт

Бу вакыйга пәйгамбәрлек иңгәннең бишенче елында, ягъни 615 елда булды.

Мәккә кяферләренең җәбер-золымыннан хәлләре авырлашкан мөселманнар Мөхәммәт пәйгамбәр янына килделәр һәм аннан кайда булса качып котылу өчен рөхсәт сорадылар, Мәккәне ташлап китәргә теләкләрен белдерделәр. Пәйгамбәр аларга җавап бирмәде. Шуннан соң Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк Мөхәммәт галәйһис-сәлам янына керде, әйтте:

— Бине Гомәр вә бине Габдешәмесләрнең җәбер-җәфа күрүләре чиктән ашты, башка мөселманнарның да тормышлары авырлашканнан авырлаша бара, аларга Мәккәне ташлап берәр тарафка китәргә рөхсәт бир? — дип үтенде.

Мөхәммәт пәйгамбәр Хәбәш тарафына ишарә ясады. Хәбәш җире эфиоплар яши торган ил иде. Аның табигате һәм һавасы да Мәккәнеке төсле булып, диннәре дә мәҗүси түгел, бәлки Гайсә пәйгамбәр шәригатендә иделәр. Ислам халкы сәүдәгәр булганлыктан, хәбәшиләр өчен аларның монда килүе дә кулай күрелде.

Унбер кеше ир затыннан, дүрт кеше мөслимәләрдән Хәбәш җиренә һиҗрәт иттеләр. Аларга баш итеп Госман бине Гаффан һәм аның хатыны — Мөхәммәт пәйгамбәрнең кызы Оркыя (Рәкия) ханым билгеләнде.

Алар киттеләр. Озаткан мөселманнарның җаннары телгәләнеп вә суелып калды. Әмма күңелләрендә ышаныч уты бар иде әле: бәлки Хәбәш илендә ахмак Әбу-Җәһил коткысына бирелгән кяферләрнең җәбер-золымыннан алар булса да сакланып кала алырлар?

Бу һиҗрәттән соң Мөхәммәтнең күңеленә авыр уйлар килде. Җәбер вә золымның чиге булмау сәбәпле ул үзен диндәшләре алдында кыен хис итә иде. Пәйгамбәрнең бу халәтен, ни хикмәт, Иблис мәлгунь сизенеп алды һәм дә аны дога вакытында саташтырырга уйлады. Теләге кабул булсын өчен барлык мөмкинлекләрне файдаланырга тырышты.

Ул көнне Мөхәммәт галәйһис-сәлам Мәсчет Хәрамда намазда яңа бер аять укыды. Аңа ияреп барган мөселманнар аптырашта калдылар. Кяферләр исә сөенделәр. Вәлид бине Әл-Мөгайрә, Сәгыйть бине Әл-Гас, башка бер риваятьләрдә исә Гакабә бине Рабига, Өмәййәт бине Хәләф кебек кяферләр бу аятьтән соң күңелләрендәге сөенечләрен яшерә алмадылар. Алар җиргә ятып сәҗдә иттеләр. Араларында булган карт-

корылар исә, сәҗдәгә килә алмау сәбәпле, учларына туфрак алып, аны күкрәкләренә сипteләр, шулай итеп, сәҗдә рәвешен китерделәр.

Пәйгамбәргә килгән бу аятьнең мәгънәсе кяферләр өчен бик якын иде. Ул аларның Әл-Лат, Әл-Гузза, Әл-Манат исеме белән аталып йөртелгән потларын теленә алды һәм аларны Аллаһы тәгалә якыннарыннан вә кызларыннан дип атаган иде, ягъни болар олы потлар, алардан рәхим-шәфкать өмет итү тиешледер, дип белдергән иде.

Кяферләр сөенешеп хәбәрләшә башладылар:

— Пәйгамбәр безнең илаһларыбызны телгә алды, алардан рәхим-шәфкать өмет итте, әгәр дә аларга табына башласа, үзенә ризык бирербез, юл ачарбыз,— диештеләр.

Вәлид бине Мөгайрә исә хәзрәткә әйтте:

— Йә Мөхәммәт, син безнең юлга кайттың, шәригатең ахырына килә,— дип.



Бу сүзләр Мөхәммәт галәйһис-сәламне аптырашта калдырды. Хәтере яхшы булганлыктан, укылган аятьне кабат исенә алды. Гаҗәпләнүе чиктән ашты. Әмма бу аятьнең ни-нәрсә икәнлеген, кайдан килүен белә алмады. Әлеге дә баягы Җәбраил галәйһис-сәламнең Аллаһы тәгаләдән китергән вәхие булмадымы икән, дип, үзен юатырга тырышты, әмма бу ышанычы бушаган күңелендә урын таба алмады.

Ул белә иде: Аллаһы тәгалә сүзенә икеләнеп карарга һич тә ярамый. Аннан иңдерелгән һәрбер кәлимә үз заманына муафыйк рәвештә һәм дә мөэминнәр күңеле икеләнүсез кабул итәрлек хәлдә җибәрелә, юкса бәндәләр болай да кара вә караңгылар, саф илаһи сүзне дәверләр берлегендә җепкә тезеп бирсә, аңлый да алмас иделәр. Әмма бу аять? Ышанасы да килми. Кяферләрнең потлары Бөек Хода янәшәсенә куелды, ничек булды соң әле? Бу хәлне ничек аңлатырга? Кяферләр рәтенә басу белән бер түгелме бу?

Күңел нигрәсе бозылуга шунда ук шик-шөбһә корты да үзенең барлыгын сиздерде. Гүяки чыннан да шәригать дивары сүтелеп, дин бинасы җимерелә башлар кебек иде. Юк, Вәлид бине Мөгайрә ялгышмады. Исламның артка китүе хакында белеп әйтте. Ни хикмәт эш бу?

Мөхәммәт пәйгамбәр үз йортына әнә шундый хәсрәтле уйлары белән кайтып керде. Әмма Аллаһы тәгаләнең рәхмәте киң иде. Шушы хәлендәге Мөхәммәткә Җәбраил галәйһис-сәлам килде һәм аңа яңа бер аять китерде. Аллаһы тәгалә пәйгамбәренә эшне шушы вәхи белән аңлатып бирде. Шайтан килүе һәм, күңеленең какшаган чагыннан файдаланып, ялган сүзне колагына пышылдавы хакында белдерде. Пәйгамбәрләр дә Шайтан коткысыннан азат түгел иде шул.

Мәккә кяферләре Мөхәммәтнең яңа гына телендә булган аять хакында хәбәрләрен бөтен шәһәргә вә әйләнә-тирәгә таратып, ахмакларны шатлык-сөенеч дингезенә чумдырдылар. Әмма иртәрәк куанган булып чыктылар. Пәйгамбәрнең үз ялгышын төзәтүе, Шайтан коткысыннан арынуы хакында ишеткәч, барысы да өсләренә салкын су сипкәндәй сыңдылар. Әле генә:

— Мөхәммәт безнең потларыбызны күк Алласының якыннары дип атады, аңа җәбер вә золымны туктатыйк, юлына аркылы килмик,— дип сүз айгырларын чаптырган кяферләр инде хәзер:

— Мөхәммәт илаһларыбызның гали булуын тануына бик тә пошынган, үз юлына кире кайткан,— дип җәбер-җәфаларын арттырырга карар иттеләр. Мөселманнар исә, шушы соңгы хәбәрләрне ишеткәннән соң, күңелләрен ныгыта төштеләр, гүяки, авыр болыт өсләреннән үтеп китеп, аларга кояш якты йөзен күрсәтте, гүяки, әле яңа гына кар төшеп шиңдергән чәчәкләрне ягымлы нур кабат терелтте. Хакыйкать юлы үзенең эзенә кайтты. Иблиснең хәйләсе барып чыкмады.

Мөселманнарның беренче һиҗрәте хакында кяферләр белән идарә итүче башбаштак ахмаклар белешеп алган иделәр. Аларга ничек булса да комачау итәргә тырыштылар. Риваятьләрдә сөйләнелгәнчә, мөселман Госман ибне Мәзгунь исә Вәлид бине Мөгайрә кяфер даирәсенә керә иде. Аның һиҗрәте хакында ишетүгә, Вәлид ничек тә булса шушы туган тиешле энесен алып калырга тырышты.

— Мин сиңа тәрбия бирдем, үземнең улым кебек карап үстердем, һичбер кимсенү күрсәтмәдем, ә син исламга кердең! — дип аны ачуланып карады.— Мөхәммәт иярчене булудан тукта, мин сиңа кадер-хөрмәтемне кылырмын,— дип үгетләп тә карады, әмма Госман иманына тугрылыклы булып калды.

— Мин синең тәрбияңдә торуга караганда Аллаһы тәгаләнең карамагында булуны артыграк күрәм! — дип җавап бирде.

Вәлид аны якалап алды, мәсчетнең көньяк тарафына китереп, кабаттан орышуын дәвам итте. Хикәятләр шулай хәбәр итә ки, Госман бине Габделмөгайрә килде һәм Госман бине Мәзгуньгә таба якынаеп, аның күзенә сукты. Туганының күз төбе күгәреп чыкты. Моңа Вәлид, канәгать булып:

— Менә минем тәрбиямнән чыктың, инде кимсенүләргә юлыктың,— дип авызын ерып көлде.

Моңа каршы Госман:

— Миңа бу мөгамәлә бик тә хуш! — дип җавап бирде.

— Ни өчен? — диде Вәлид аптырап.

— Боларны мин ахирәт көненә сакларммын,— дип горур гына җавап бирде аңа Госман. Вәлиднең ерык авызыннан өркү галәмәте күкрәгенә үтте, тәкәбберлеге шиңеп калды.

Мөселманнар, ике ай дигәндә, Хәбәши иленә җиттеләр һәм монда үзләренә сыену урыны таптылар, сәүдәләрен җәелдереп җибәрделәр һәм Мәккә мөселманнары белән сату-алуны җайга салу эшен башладылар. Янә бусы да билгеле булсын, аларның берничәсе шушы илдә мәңгегә калачак иде, бер төркеме исә Мәдинә шәһәренә киләчәк, арадан берничәсе ялгышып, Гайсә пәйгамбәр шәригатенә күчәчәк. Әмма, шул ук вакытта, бу беренче һиҗрәтнең әһәмияте дә зур иде, чөнки мөселманнар вә аларның шәригате хакында күрше дәүләтләр дә хәбәрдар була башладылар. Гайсә пәйгамбәр шәригатендә булган хәбәшиләр исә гарәпләрнең Алла юлына басуларына, әлбәттә, сөенделәр. Шуңа күрә мөселманнардан шикаять белән килгән Мәккә кяферләренең сүзенә колак салмадылар.

## Икенче һиҗрәт

Бу икенче һиҗрәт тә Хәбәшиләр иленә булды. Мөхәммәт пәйгамбәр рөхсәтен биргәннән соң Аллаһы тәгалә ярдәме белән йөз дә өч кемсәнә мөселман юлга җыенды. Аларның сиксән икесе ир затыннан, калган егерме бере хатын-кыз иде. Соңыннан егерме дүрте генә (ирләрдән) Мәдинә шәһәренә килә алдылар, алар белән бергә егерме хатын да кайтты. Әмма бу хәлләргә хәзергә ерак әле...

Беренче һиҗрәт белән киткәннәр арасыннан берничә кемсәнә Мәккәгә әйләнеп кайттылар, үзләре белән бүләкләр дә китерделәр һәм:

— Хәбәшиләр җире безнең табигатебез төсле үк күркәм, һавасы исә безнекеннән дә яхшы, төрле җимешләргә вә ризыкларга бай, үзләре дә бер Аллага табынып, корбан чалу кебек эшләрне көн дә хасил кылалар, ятимнәрне вә сукбайларны хөрмәт итәләр,— дип, тәэсирләре хакында бәйнә-бәйнә сөйләделәр.— Без мөселманнар өчен аннан да кулайрак җир юк,— дип Мөхәммәт пәйгамбәрне дә Хәбәшиләр иленә чакырдылар. Әмма Рәсүл:

— Минем һиҗрәтем өчен Аллаһы тәгаләдән әмер ирешкәне юк, мин монда калам,— дип катгый рәвештә белдергәч, бу хакта кабаттан кайтарып сүз башлаучы булмады.

Бу хәбәрләрне ишеткәч, корәиш кабиләсенең кяферләре гаять тә ачуланып, мөселманнарга карата җәбер-золымнарын тагын да арттыра төштеләр. Арада Әбу-Бәкернең дәрәҗәсе зур иде. Артыннан күпләрнең мөселманлыкка авышуларыннан өреккән кяферләр исә аңа каршы золымны төрле яклап арттыра төштеләр. Исәпләре буенча шулай иде ки, әгәр дә Әбу-Бәкер кебек җан дусты булмаса, Мөхәммәт пәйгамбәрне җиңәргә мөмкин, имеш.

Әбу-Бәкернең Мәккәне ташлап чыгудан бүтән һичбер чарасы калмады. Шушы уе белән пәйгамбәр янына килде. Әмма сүз башларга кыймады. Мөхәммәт белән аерылышу фикере аның йөрәгенә кара кан булып ятты. Әмма китмичә дә һичбер чарасы калмаган иде.

Әбу-Бәкер Мәккәне ташлап чыкты. Күңеле тулы сагыш каралыгын вә авыр тойгыларын күтәреп, Хәбәш тарафына таба юл тотты. Алга барырга аягы тартмады, кире кайтырга батырчылыгы җитмәде. Бәни-Ләис кабиләсенә килеп чыкты. Боларның башлыгы булган Харис бине Йәзидәгә төште. Аның белән күрешеп, хәл-әхвәлләр сорашып, Әбу-Бәкер үзенең Мәккәдән китеп барышы хакында әйтте.

— Юк, синең кебек хөрмәтле вә кешелекле затның Мәккәдән китүе бер дә дөрес һәм дә мәгъкуль эшләрдән түгелдер. Син кешеләргә күпме яхшылыклар кылдың, холкың да, сыйфатларың да ил алдында хөрмәткә лаек,— дип Харис аны кирегә борырга тырышты.

— Минем инде Мәккәдә яшәргә бер генә дә чарам калмады, алар күрсәткән җәбер-золымга түзеп торырлыгым да юк хәзер, мин инде китәрмен,— диде аңа каршы Әбу-Бәкер, әмма барыбер аягы тартмады.

— Китмә,— диде аңа кабилә башлыгы.— Мин сине үз канат астыма алам, үзем барып Мәккә корәишләре белән әңгәмә кылам, синең кебек асыл затларның Мәккәдән китүенә берсе дә сөенмәсләр, кире кайтабыз,— диде ул сүзен тәмам итеп.

Алар Мәккәгә килделәр. Харис шунда корәишләр белән әңгәмә тотып сөйләште. Әбу-Бәкерне үз канаты астына алуы хакында хәбәр бирде. Шуннан соң Мәккә кяферләре:

— Әбу-Бәкернең Мәккәдә калуы безнең өчен бер дә кулай түгел, ул безнең арадан кешеләрне үз диненә кертә, үзенә ияртә. Без каршы! — диеп шаулаштылар. Сүз дәвам итеп, ахырдан:

— Сез канат астына алу аркасында гына шәһәребездә калдырабыз, әмма ләкин шартыбыз бар. Үз диненнән кайтсын, башкаларны исламга өндәмәсен,— диделәр. Шартны Харис кабул итте. Әбу-Бәкер Мәккәдә яшәп калды.

Иң беренче эш итеп, ул үзенә аерым мәсчет булдырды, шунда гыйбадәт кыла башлады. Аңа ияреп, кайбер кяферләр исламга керә тордылар. Корәишләр, моны сизенеп, тагын тавыш куптардылар. Харис бине Йәзидә катына килеп, шикаять иттеләр, шартларның төгәл үтәлмәвен белдерделәр. Бу сүзләрне ишетүгә Бәни-Ләис кабиләсе башлыгы Әбу-Бәкер алдына килде, шартларның бозылуын белдерде һәм аны үзенең канат астыннан чыгарды, иминлеген сакламаячагын әйтте.

— Мин синең өчен корәишләр белән дошманлашырга җыенмыйм, ярдәмемне кабаттан күрмәссең,— диде.

Аңа каршы Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк:

— Аллаһы тәгалә үз ярдәменнән аермасын, бар теләгем шул,— дип җавап бирде.

Мөселманнарның горурлыгы вә иманнарының ныклыгы кяферләрнең каршында янар уттай тәэсирле иде.

Хәбәш иленә киткән мөселманнарның тормышлары алга таба китүе хәбәрләре корәишләргә килеп ирешүгә, алар үз якларыннан бер илчелек төзеп, бу ил падишаһына үзләренең гозерләрен җиткерүне кирәк таптылар. Бик күп бүләкләр әзерләп, Гамер бине Әл-Гас вә Гомәр бине Әл-Вәлид, ә бер риваятьтә исә Габдеррахман бине Рабига исемле кемсәләрне Хәбәш падишаһы Нәҗаши хәзрәтләренә күндерделәр.

Илчеләр, көймәгә утыруга, авызларына шәраб коя башладылар. Юл җиңеллеге диген булып, һаман шул шөгыльләрендә булдылар. Әмма шәраб үз эшен эшли бирде. Гамер белән Гомәр арасында сүз чыгып, алар башта төрткәләшә, аннан соң сугыша ук башладылар. Форсаттан файдаланып, Гомәр җаен туры китереп, Гамерне җәһәт кенә суга төртеп төшерде. Төпсез диңгезнең шомлыгы Гамерне тиз айнытты. Ул ишкәккә ябышып калды һәм һәлакәттән котылды. Бу хәл Гомәрнең үзен дә шәраб исереклегеннән кайтарды. Илче дустына дуслык үтенеп, кул бирде. Гамер гафу итсә дә, күңелендә дошманлык очкыны пыскыган хәлендә калды.

Корәишләрнең илчелеге Хәбәш иленә иминлек белән килеп җитте. Аларны падишаһ хәзрәтләре Нәҗаши кабул итте. Болар күрделәр, Нәҗашинең янында бик тә гүзәл вә матур бер кол хатыны бар иде. Падишаһ аны гел үз якынында тота, хәтта тәхет кырыеннан да читкә җибәрми, бик тә ярата икән.

Корәиш илчелеге килгәндә дә бу гүзәл зат падишаһ Нәҗаши хәзрәтләре янында иде. Арадан Гомәргә бик яратып, хәтта, әйтергә кирәк, назлы күзләрен сирпеп, берничә кат карады. Моны илчелек сизенде. Падишаһ яныннан чыккач, Гамер:

— Сизденме, Гомәр, падишаһ янындагы теге гүзәл үзеңә ничек игътибар бирде, форсаттан файда табарга кирәк. Безнең эшебез яхшы тәмамлансын өчен дип әйтәм, аңа бүләкләрне бирик, син аны үзеңнең янына чакырырсың, шунда эшне сөйләшеп, аның аша падишаһ белән сүз йөртсәң, бик яхшы булыр иде,— дип Гомәрне котырта башлады. Моныеының исә бик тә кәефе килеп, күңеленә бу эшне беркетеп, үз җаен җайлады. Бу чибәргә бүләкләрен тәкъдим итеп, үз янына чакырды. Теге исә китергәнне кабул итми калмады. Моны белеп торган Гамер тиз генә падишаһ җәнапләре каршына ашыкты һәм Нәҗашига:

— Синең гүзәлең арабызда булган бер иребезгә гыйшык тота. Мин үзебезнең эш файдасына моны әйтмичә кала алмыйм. Әгәр шаһитлар кирәк икән, хәзер барыйк, күрербез,— дип аны Гомәр белән гүзәле янына китерде.

Кайбер китапларда падишаһ Гомәрне катил итте, дип хәбәр бирәләр, икенчеләрендә исә Нәҗашинең кинәттән килеп керүен күргән Гомәр акылыннан язып, таулар-сахралар арасында озак гизеп йөргән, шунда аны мөселманнар кулга төшергәннәр һәм хәбескә ябып куйганнар, шунда вафат булган, дип риваять кылалар. Ни генә булмасын, Гомәрдән Гамер көймәдә булган дошманлык өчен үч алып, аны мәңгегә Хәбәш илендә мәхрүм бер дивана җан итеп калдыруга иреште. Бу вакытта мөселманнар арасында татулык вә туганлык хисләре никадәр көчле вә ныклы булса, кяферләр арасында үзара бозылышу вә таркаулык шулкадәр үк зур иде.

Килгән илчелек падишаһның алдына күнде. Сарай хезмәтчеләре ришвәт өметендә тордылар. Корәишләр аларның алларына үзләре белән китерелгән бүләкләрен тезделәр.

— Йә, әйтегез, гозер-үтенечегез ни-нәрсә? — дип сорады Нәҗаши хәзрәтләре.

— Безнең монда килүебездә сәбәп бер генә,— диде Гамер бине Гас.— Ул да булса шул ки, безнең Мәккәдә үзен пәйгамбәр дип атаучы бер кемсә хасил булды. Халыкны аздырып, үз диненә өнди башлады. Ул һашим кабиләсеннән булып, үз диненә кергән кешеләрне өммәте вә милләте дип атый башлады. Безнең борынгыдан килгән динебезгә каршы төшеп, бер Аллага табынырга өнди. Аның мөселманнары, Мәккә тормышын ташлап, сезнең илегезгә күченделәр. Безгә аларны тотып бирсәгез, илебезгә кире кайтарыр идек? — дип үтенечennән хәбәр бирде.

Нәҗаши падишаһ «Инҗил» вә «Тәурат» китаплары белән эш йөртүче вә бер Аллага табынучы булганлыктан, үзенең галимнәре вә китаплары аша бу заманда дөнья йөзенә бер пәйгамбәрнең пәйда буласыннан хәбәрдар иде. Шунлыктан ул:

— Ул пәйгамбәрегезнең исеме кем була? — дип сорады.

Гамер бине Гас исә:

— Аның исеме Мөхәммәт,— дип җавап бирде.

— Кайсы мәзһәптән? — дип сорады падишаһ.

— Аларның мәзһәпләре ни-нәрсәдер, белмим,— дип җавап бирде бине Гас.

Аның бу җавабыннан падишаһ җәнапләре аптырашта калды һәм:

— Ул вакытта без мәҗлес корырбыз, ул кемнәрегезне дә дәшәрбез. Кара-каршы утыртып сорашырбыз. Аларны да тыңлау тиешледер. Әгәр дә ихлас күңелдән эш йөртсәгез, сезнеңчә булыр,— дип, Нәҗаши хәзрәтләре бу утырышын тәмам итте.

Хәбәрне мөселманнарга китереп җиткерделәр. Алар арадан Җәгъфәрне сайлап, барысы өчен дә ул җавап бирергә тиеш дип таптылар. Чөнки күп кеше сүз алып сөйли башласа, буталу вә тавыш чыгарудан ерак китеп булмый иде. Мөселманнар ислам шәригате буенча эш йөртүне зарур күрделәр.

Падишаһ үз янына, сарай хезмәтчеләреннән тыш, олы галимнәрен дә чакыртып алды. Илче корәишләр килеп, аның алдында түбәнчелек белән, башларын җиргә кадәр иделәр.

Җәгъфәр җитәкчелегендә мөселманнар да килеп җитте. Әмма алар баш кагып кына сәламнәрен җиткерделәр, сәҗдәгә килмәделәр. Падишаһ:

— Сез ни өчен башларыгызны җиргә тереп, йөзләрегез белән җир сөртеп, сәламнәрегезне җиткермисез? — дип сорады.

Моңа каршы Җәгъфәр:

— Безнең хәзрәтебез Мөхәммәт бары тик Аллаһы тәгаләгә генә сәҗдә кылырга ярый дип аңлатты, башкалар алдында сәҗдә итү шәригатебезгә сыймый,— дип җавап бирде. Бу сүзләрне падишаһ яратып кабул итте, күңеле булды. Каршында торган галим-голәмә аларга хөрмәт күрсәтте.

Шуннан соң мөселманнарның ни өчен падишаһ тарафына китерелүе хакында аңлатылып бирелде һәм галимнәренә каршы Җәгъфәр:

— Сорагыз, җавап бирик,— дип белдерде.

— Сез боларның колларымы? — диделәр.

Сорауга каршы Гамер:

— Юк, болар ирекле кешеләр,— диде.

— Боларга тиешле бурычыгыз бармы? — дип сорагач:

— Юк,— диделәр.

— Берәр кешегезне катил итеп, үтерделәрме?

— Юк.

Шунда Җәгъфәр сорау бирде:

— Болар бездән нәрсә таләп итәләр соң? — диде.

Гамер сөйләп китте:

— Болар безнең потларыбыздан көләләр, илаһи затларыбызны бар дип тә белмиләр, үзебезнең җаннарыбызны кара дип белдерәләр. Кабилә арасында дошманлык тудырдылар. Шәһәребезне таркаттылар...

Инде мөселманнар вәкиле Җәгъфәр сүз алды:

— Без бербөтен кавем идек, әмма арабызда бер пәйгамбәр туды. Ул безгә Аллаһы тәгалә гыйлемен китерде. Сөйләгән сүзләре күңелебезне уятты, без караңгылыктан котылдык. Әмма кабиләбезнең калган кешеләре иманга килергә теләмәде. Могҗиза таләп иттеләр. Пәйгамбәребезнең китергән дине үзе могҗиза булуын аңламадылар. Безгә дошманлыклар кыла башлап, золым вә җәберләренең чиге-чамасы булмады. Пәйгамбәребез Мөхәммәт саллаллаһ галәйһис-сәлам рөхсәте белән һиҗрәт юлына бастык. Падишаһлар арасыннан сезнең күркәгезне сайлап, шушында килдек. Безне боларга әсир кылмавыгызны үтенәбез.

— Ул пәйгамбәрегез сүзләреннән берәрсе исегездәме?— дип сорады Нәҗаши падишаһ.

— Әйе,— диде Җәгъфәр һәм Коръәннән бер аятьне күңелдән укып китте. Ул сүзләрне шундый да моңлы мәкам белән укыды ки, хәтта падишаһның йөзенә энҗедәй күз яше бөртекләре елгаладылар. Аның күңеле хушланды.

Гамернең бу эшләргә бик ачуы килде һәм мөселманнарга кара ягуын дәвам итте:

— Болар сезнең пәйгамбәрегез Гайсә хакында башкача сөйлиләр,— дип аваз салды.

— Йә, нәрсә сөйлисез?— дип, янә һиҗрәт кылган мөселманнарга мөрәҗәгать итте Нәҗаши.

Җәгъфәр хәзрәтләре Гайсә пәйгамбәр хакында Коръәндәге бер аятьне әйтте. Моңа да падишаһның күңеле булды һәм:

— Боларның диннәре белән безнең динебез арасында әллә ни аермалыклар юк икән. Сүзләрендә хаклык бар. Күренеп тора, аларга иңгән сүзләр безнең Муса вә Гайсә пәйгамбәрләребезгә килгән илаһтан булуы дөрес икән,— диде.

Аптырашта калган Гамергә ул:

— Гозерегез кабул ителми, мөселманнарны сезгә бирмим,— диде. Һәм алып килгән бүләкләрен кире тапшырып, Мәккә кяферләрен үз илләренә кайтарып җибәрде. Шулай итеп, мөселманнар Хәбәш илендә үзләренә беренче тапкыр сыену урыны таптылар, алар белән тату вә дустанә рәвештә яши башладылар. Мәккә кяферләре исә ачуларыннан бәгырьләрен кызыл канга манып, кайтып киттеләр.

Хәбәшиләр падишаһы булган Нәҗаши ул гидайларга вә гарипләргә, үз илләреннән качып китәргә мәҗбүр булган кемсәләргә бик тә хөрмәт белән карый, аларга ярдәмен күрсәтергә тырыша иде. Чөнки җәберзолымның ни-нәрсә икәнлеген ул үз язмышы аша бик яхшы белә иде.

Аның тарихы болардан гыйбарәт.

Хәбәрләрдән билгеле, Нәҗашиның атасы падишаһ иде. Аның илдә тагын бер ир туганы булып, унике малайга ата иде. Ә Нәҗаши исә атасына берданбер бала булып үсте. Менә шушы сәбәптән, хәбәшиләр төрле сүз йөртә башладылар:

— Падишаһ итеп аның абыйсын куярга кирәк, юкса бу олугыбызның бер генә малае бар. Кем белә, гомере чикләнеп, үлеп китәр, тәхеткә башка бер кеше килеп утыруы ихтимал. Илебез таркалыр, шуңа күрә бу падишаһыбызны үтерик,— диештеләр.

Нәҗашиның атасы Инҗәр атлы иде. Бу гаугаларны ул белми дә калды, ахмаклар аның башына җиттеләр, үзе урынына туган тиешле абыйсын куйдылар. Нәҗаши исә ятимлектә үсте.

Кешеләр язмышы ничек буласы җир йөзендәге бәндәләргә һич тә билгеле түгел. Нәҗаши хәзрәтләре бик тә акыллы вә олыларга һәм галимнәргә хөрмәт белән караучы адәм булып үсте. Аның шушы өстен-

лекләрен күреп торган сарай хезмәтчеләре вә олуглары аңа игътибар күзләрен юнәлтә башладылар. Әмма атасын үтерүләре сәбәпле:

— Без аны падишаһ итеп тәхеткә утыртсак, ул үчне кире кайтарыр, барчабызны харап итеп ташлар, илебезне таркатыр,— диешә башладылар. Уңнан вә сулдан фикер арбаларын сөйрәп, тәмам гаҗиз булдылар. Арадан берсе:

— Атасы төсле үк, аны да үтереп ташлыйк,— дип, кан исен акыл казаннарына бүлде. Әмма мәҗлестә аек фикер йөртерлек кемсәләр дә юк түгел иде. Арадан берсе:

— Юк инде. Җаннарыбыз болай да гөнаһлы, аны тагын да арттыруда һичбер мәгънә жимешләрен күрмим,— дип каршы төште һәм:— Мин аны кол итеп сатарга киңәш итәр идем,— диеп сүзен тәмам итте.

Ахмакларның күзләре урыннарына кайтып, акыллары томан арасыннан арчылган тау сыман калкынып, алар барчасы да бу киңәшнең бик тә мәгъкуль вә яраклы булуын аңладылар һәм Нәҗаши хәзрәтләрен алты йөз дирһәм алтын акча бәрабәренә сәүдәгәрләргә сатып та җибәрделәр.

Бу сәүдәгәрләр диңгез якасына житеп, көймәләренә утыру җаен карый башлаганда күк йөзенең кәефе китеп, өсләренә авыр кара болытларны сөрде һәм яңгыр ява башлады. Көймәгә утыру кичектерелде һәм Нәҗаши хәзрәтләре, рөхсәт алып, сахрага чыкты, туган туфрагы белән соңгы тапкыр хушлашып калырга теләде. Шулвакыт кинәттән яшен чатнады һәм утлы коерыгы белән диңгез ярында калган сәүдәгәрләр көймәсенә китереп орды. Көймә тәмам янып бетеп, көл булды.

Бу хәлне күреп торган хәбәшиләр исләрен вә акылларын югалттылар. Җаннары түренә аптырау дулкыны артыннан мескенлек хисе бәреп керде. Нәҗаши хәзрәтләре каршында тез чүкteләр, аның Күкләр каршында бөеклеген таныдылар, падишаһ итеп куярга карар кылдылар. Нәкъ шушы көнне аның язмышы тәмам хәл ителде, аягыннан башына кадәр бәхет кошының алтын канаты тиеп үтте.

Хәбәшиләр Нәҗашине сарайга китерделәр, бар хәлне сөйләп бирделәр. Барлык олуг бәндәләр дәрья якасына килсәләр, сәүдәгәрләр, сал ясап, диңгезгә төшмәкчеләр, әмма кузгала алмыйча аптырарлар. Сарай кешеләре бу хәлләрне күреп, котлары бугазларына менде. Барчасы Нәҗаши хәзрәтләренең алдына килеп, аякларына үзләренең «канлы» куллары белән ябыштылар, кичерү вә шәфкать сорадылар, аның башына падишаһлык таҗын кидереп, аркасына хөрмәт җәймәсен салдылар.

Шушы рәвешле шаһзадә Нәҗаши хәзрәтләре үзенә мирис тиешле тәхетенә менеп утырды, ихтирам вә олуглык белән фикер тәлинкәсенә хаклык үлчәмнәрен сала башлады. Әмма сәүдәгәрләрнең салы һаман да урыныннан кузгалмады. Базар әһеле, Нәҗашины сатып алган кемсә, үзенең акчасын кире кайтаруны теләп-үтенеп сарайга килде. Әмма падишаһ даирәсе кесәләренә һичбер авырлыксыз вә хаксыз рәвештә кергән алтыннан колак кагарга теләмәделәр. Шулвакыт Нәҗаши падишаһ:

— Бу сәүдәгәр үз хакын дөрес даулый, йә аңа акчасын кайтарып бирегез, йә булмаса колын китерегез. Хәтта ул кол падишаһ булса да!— диде.

Нәҗашиның шушы катгый сүзләрен ишетүгә, даирәсе тиешле алтынны сәүдә әһеленә чыгарып бирделәр. Падишаһларының бик хаклы вә төпле акыл иясе булуына янә бер кат ышандылар.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, менә моннан соң гына диңгез ярыннан инде ничә көннәр кузгала алмый торган базар әһеле үз илләренә кайтып китте. Тагын да бу хикәятнең мәгънәсе монда ки, Аллаһы тәгалә ришвәт алуны белми, син дә тәхет иясе булу өчен кыек юлга басма! Җир йөзендә яманлык вә ялган чүп урынына үрчесә дә, арада хакыйкать тарафдарлары очрамый калмас. Аллаһы тәгалә үзенә лаек һәм үз юлыннан тайпылышсыз атлаган бәндәләренә генә ярдәмен бирер. Хак — хаклыкны яклар, дигән сүз буш бер кәлимә түгелдер...

Гамер бине Әл-Гас илчелеге иленә кайтып киткәннән соң, хәбәши падишаһы Нәҗаши хәзрәтләре шушы хәлләрен исенә алып, озак кына уйланып утырды. Тарихларны хәбәр итүчеләр шулай дип язалар ки, бу уйларыңнан соң падишаһ олуг бер карарга килеп, Мөхәммәт галәйһиссәламгә бер хат язып күндерде:

**«Мин синең динеңнең хак дин икәнлеген аңлап, үзеңә иман китерергә булдым!»**

Хатны бер якыны аша тапшырды. Ул, Мәккә тарафына карап, диңгез култыгына төшкәндә, падишаһ үз якыннарын җыеп алды һәм:

— Мөхәммәт — чын мәгънәсендә хак юлдан баручы рәсүл, мин аңа иман китердем, сезне дә шушыны эшләргә чакырам,— дип әмерен җиткерде. Әмма ләкин хәбәшиләр аның сүзләрен кире кайтардылар:

— Юк, без аның диненә кермибез, үзебезнең диндә калабыз,— диделәр.

— Мөхәммәт диненә керсәгез, үзегезне олуг бәлаләрдән саклап калырсыз, Ахырзаман көнендә барчагызга җиңеллек вә ярлыкау килер,— диде падишаһ, әмма бу сүзләре дә хәбәшиләргә әллә ни йогынты ясый алмады, акыл кояшлары болыт артында калып, күңелләрен җылыта вә киреләкләрен шиңдерергә ашыкмады, җәһаләт күләгәсе аларны тоткын итте.

— Мин сезне имтихан итүем генә иде,— диде падишаһ үзенең шушы боз йөрәкле хәбәшиләренә, әмма үзе исламга керде һәм мөселманнар белән мөгамәләдә булды. Үзенә Җәгъфәрне чакыртып алып, аннан төрле аятьләрне тыңлады, Мөхәммәт пәйгамбәребезнең шәригатен төшенеп алды. Аның бу эшләрен күреп торган хәбәшиләр бер көнне аңа әйттеләр:

— Син, безнең падишаһыбыз була торып, динебездән тайпылдың! Мөселманнар белән мәҗлесләр корасың, сөйләшәсең, безләрдән читләштең!— диделәр.

Ул арада Мөхәммәт пәйгамбәрдән дә хат-мәктүп килде. Ул Җәгъфәр сәхабәне Нәҗаши падишаһка дин иңдерүче итеп билгеләде. Хәбәшиләрнең бу хәлләрен Мәккә кяферләре ишетеп алды. Аптырадылар. Нәҗаши падишаһның исламга керүенә ачулары килде.

Нәҗаши хәзрәтләре егермеләп хәбәшине Мөхәммәт пәйгамбәр янына күндерде. Алар Мәккәгә килделәр, рәсүлебез каршында тез чүктеләр вә үзләренең ислам динен эләп килүләреннән хәбәр бирделәр һәм:

— Син үзеңне Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре дип белдерәсең. Син китергән дин нинди була? Безгә шулардан хәбәр бир,— дип үтенделәр. Мөхәммәт галәйһис-сәлам Коръәннән аерым-аерым аятьләрне укыды, хәбәшиләрнең йөзләре нурланды, күзләреннән яшьләре чыкты. Алар үз күңелләрендә нindидер илаһи сер вә бөеклек хисен сизделәр, күгәргән акыллары агарып киткәндәй булды.

— Күренеп тора, Аллаһы тәгалә бер генә һәм син аның пәйгамбәре,— дип иман китерделәр. Шул вакытта алар янына Әбу-Җәһил белән Өмәййәт бине Хәләф килеп чыктылар да:

— Сез аны тыңламагыз, ул безне ничә еллар өндәп карады, әмма аның ялганнарына инанмадык. Мәккә калабыз элекләр бик тату иде, ул безне таркатты, үзара дошманлаштырды,— дип хәбәшиләрне үгетләргә керештеләр. Әмма болар:

— Без инде саф мөселман булдык, иманыбыз камил,— дип әйтүгә, кяферләр:

— Безне ул ун елга якын үз диненә өндәде, әмма без аның якынында булып та' адашмадык, ә сез диңгез артыннан килеп, аның ялганына ышандыгызмы?!— дип тавыш чыгардылар.

Бу егерме кемсә хәбәши, шушы сөйләшүләрдән соң, күңелләрен тагын да ныгыта төштеләр, Мәккә кяферләренең җаннары котсыз вә сукыр икәнлеген төшенделәр, Мөхәммәт пәйгамбәргә, Коръәнне өйрәнү өчен дип, килеп тә җиттеләр. Бу теләкләренә ирешкәннән һәм үзләрен ислам белән нурландырганнан соң, алар үз илләренә кайтып киттеләр.

Нәҗаши хәзрәтләренә Мөхәммәт пәйгамбәр хакында хәбәрләр бирделәр. Аларны тыңлагач, падишаһ:

— Аның дине һаман да үсештә булыр вә шәригате халыкларның җанын яулап алыр,— дип белдерде. Мөселманнар сәгадәтлек чишмәсеннән шатлык-сөенеч суын эчтеләр.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, хәбәшиләрнең кайсы Мөхәммәт пәйгамбәребезгә иман китерде, ә кайсылары Гайсә пәйгамбәр шәригатендә кала бирде. Мөселманнар һичкемне үз диннәренә көчләмәделәр, Нәҗаши хәзрәтләре дә көч куллану ягына авышмады. Әйтүләренә карaганда, Җәгъфәр сәхабә ул вакытларда аның катында калды һәм ислам шәригате буенча эш йөртүдә булышлык күрсәтте.

## Пәйгамбәрлекнең алтынчы елы

Мәккә кяферләре, караңгылык вә наданлыкта калып, потларга табынуларын дәвам иттеләр. Алар шушы ахмак эшләре белән мәшгуль булган чакларында яннарына Мөхәммәт пәйгамбәр һәм дә аның дусларыннан Габдулла бине Мәсгуд килделәр. Аларны күргәч, кяферләр бераз аптырабрак калдылар. Форсаттан файдаланып, Мөхәммәт галәйһис-сәлам:— Йа, корәиш, Аллаһы тәгалә бер, аннан башка илаһи зат юк дип әйтегез!— диде.

Кяферләр Вәлиднең поты янында иделәр. Рәсүлнең сүзләрен ишетүгә, бу кемсә үз кырыендагы Әбу-Җәһилгә:

— Йа, хаким карендәшем, ни диярсең, әгәр дә моны шушында оятлы итсәм?— диде, үзе ниндидер бер хәйлә җимешен йоткан бәндә шикелле киң итеп елмайды.

— Никадәр генә оятлы итсәң дә, мин каршы килмәм,— диде аңа Әбу-Җәһил.

Шуннан Вәлид үзенең потын корсагына терәп күтәрде дә, Мөхәммәт пәйгамбәр янына килеп:

— Син һаман Алланы үзеңә якын дип белдерергә яратасың, күр, минем аллам да миңа якын,— дип көлә башлады. Моның ахмак сүзләренә карата пәйгамбәр бер генә кәлимә дә җавап кайтармады. Кяферләр бу потка сәҗдә итә башладылар һәм:

— И безнең иябез вә аллабыз, безгә Мөхәммәт пәйгамбәрне үтерү җаен өйрәт?— дип үтенделәр.

Риваятьләрдә шулай сөйләнелә ки, имеш, бу пот телгә килеп, Мөхәммәтне үтерү кирәкләрен сөйләде, имеш, эченә Шайтан кереп оялаган иде, диләр.

Рәсүл боларның үз потларыннан ни-нәрсә сорауларын күреп-ишетеп торганлыктан, бик тә аптырады һәм өенә кайтып китте. Артыннан Габдулла бине Мәсгуд тә иярде.

Өендә Мөхәммәт пәйгамбәр борчылган хәлендә утырды. Бераз вакыт кичкәч, пәйгамбәрдән Габдулла бине Мәсгуд:

— Син ул потның ниләр сөйләгәнен ишеттеңме?— дип сорады.

— Ишеттем, корәишләр һаман да мине үтерергә атлыгып торалар, бу потның сөйләве дә һичкем түгел, Шайтан эше. Әмма моңа кадәр бер генә пәйгамбәргә дә Шайтан иярченнәре болай каршы чыга алмаганнар, киресенчә, аның коткысына бирелгән җаһилләр һәлакәткә очраганнар,— дип җавап бирде аңа Мөхәммәт галәйһис-сәлам:

Шулай да ул өеннән кяферләр алдына бүтәнчә чыкмас булды. Шул рәвештә өч көн үтте. Кич иде. Рәсүл белән бергә Габдулла бине Мәсгуд хәбәрләшеп утырганда кемнеңдер сәлам бирүе ишетелде. Мөхәммәт:

— Йә, кем бар анда, адәмиме, әллә башка затмы?— диде.

Сәлам биргән тавышның иясе күренмәде, әмма сөйләгән сүзләре ишетелә иде:

— Ул потның эченә бер җен кереп утырган иде, кяферләр алдында аларны котыртып сөйләде. Мин ул җенне бүген үтердем, мөселманнарны аның җәфа вә золымыннан азат иттем, башка һич яманлык юлына шакшы аягын тыга алмас! — диде әлеге зат.— Мин үзем дә җен затыннан булам,— дип белдерде ул.

— Синең исемең ничек соң? — диде пәйгамбәр.

— Исемен Мим-Хәҗ була,— диде җен.

— Мин сиңа башка исем кушам, моннан соң Габдулла дип аталырсың,— диде аңа Мөхәммәт галәйһис-сәлам. Җен исә рәхмәтле булды вә китеп барды.

Бу көнне бине Мәсгуд белән рәсүл тагын да теге пот янына бардылар. Кяферләр ихластан аңа табына вә тагын-тагын сүзләр әйтүен үтенеп маташа иделәр. Ул арада бу пот эченә шул Габдулла исеме бирелгән җен кереп оялады һәм Мөхәммәт пәйгамбәрне вә аның динен зурлап, тәгъбирләр әйтә башлады. Бу хәлдән алама кяферләрнең күзләре маңгайларына менде, авызларындагы зәһәр сүзләре тамакларына авыр таш булып тыгылды, ачу ташкыннары кубып, бу потны челпәрәмә китереп, кисәкләрен сахрага сиптеләр. Ул арада күңелләренә иман нуры керергә өлгергән кяфер вә кяфирәләр Мөхәммәт пәйгамбәр каршына килеп егылдылар, иман китереп, илаһи сүзләрне кабатладылар. Әмма Әбу-Җәһил иярченнәренең үчлек белән куллары озынайды һәм алар, килеп, Мөхәммәтнең чәчләреннән йолка, йөзенә суга башладылар.

— Йа корәишләр, мин сезнең пәйгамбәрегез, мондый да эш кылырга оят түгелме? — диде аларга рәсүлебез.

Бер кяфернең кулында таяк бар иде, ул аның белән Мөхәммәтнең корсагына төртте. Әйтәләр, бу хәлдән соң ул кяфернең кулы корыды, диләр. Рәсүл исә гыйбадәтханәгә кереп, үз хәленә эче пошып, башын күркәм кулларына салып, хәсрәт эчендә утырганда, янына җанашы Хәдичә йөгереп килде, чәчләреннән сыйпады, җанына ныклык энҗесен салу өчен күңелендә йөрткән назлы сүзләрен кабатлады:

— И минем гыйшкым, күз нурым Мөхәммәт! Тынычлан, сабыр бул... Алар синең хак пәйгамбәр булуыңны белмиләр, аларның йөрәкләрен караңгылык болыты каплап алган,— диде Хәдичә ханым аны юатып.

Китапларда шулай язалар ки, Мөхәммәтнең карендәшләреннән агасы Хәмзә бине Габделмотталип бик тә баһадир кеше иде. Ук атарга маһир булып, ул көнне сахрада ау белән мәшгуль иде. Көне буе бер газәлне куып йөрде. Тәмам арыды, әмма туганының авыр хәле хакында белми иде әле.

Шактый газаплангач, Хәмзә бу газәлнең каршына төште һәм угын төбәде, шул вакытта бу җанвар телгә килеп:

— И Хәмзә, миңа төбәп ук атканчы, туганыңны үтерер өчен кул күтәргән дошманнарыңа атсаң, мең мәртәбә яхшырак булыр иде,— диде. Бу сүзләрдән Хәмзә бине Габделмотталип аптырашта калып, өенә юнәлде.

Ул әле исламга кермәгән вә кяферләр рәтеннән иде. Хатыны аның алдына ит тулы табак китереп куйды. Ул Мөхәммәт белән булган хәлне белә иде, күзләреннән яшен тыя алмыйча:

— Әгәр дә Мөхәммәт бер ятим булмыйча, туганнарының ярдәмен тоеп яшәсә, аны болай кимсетмәсләр иде,— дип елап җибәрде һәм иренә аның хәленнән хәбәрләр бирде.

Хәмзә сорады:

— Ә атасы урынына калган Әбу-Талип кайда иде соң?

— Ул Мәккәдән чыгып киткән иде, дөяләрен карарга баруы иде, белмәгәндер,— диде хатыны.

— Ә агасы Әбу-Ләһәп ни карый икән соң?

— Ул үзенең өендә: «Мөхәммәт — сихерче, Мөхәммәт — ялганчы»,— дип ахмак сүзләр сөйләп утыра,— диде җавабында хатыны.

Бу сүзләрне ишетүгә, Хәмзә алдындагы ризыкны да авыз итмичә сикереп торды һәм, иңенә кылычын асып, урамга чыкты, кынының суырып, аны айкады вә кяферләр мәҗлес корган җиргә таба ашыкты.

Кяферләр бер ояиделәр.

Хәмзә исә алар янына бармады, Кәгъбәне әйләнеп чыгып, олылау эшен башкарды. Үзе ат өстендә, бер кулында — кылыч, икенчесендә ук-җәясе иде. Аның бу хәлен күреп торган кяферләр хәвефкә төштеләр. Хәмзәнең, башта исәпләшеп, аннан соң тауафка китмәве барсының йөрәкләренә курку салды, туганы өчен үч алырга килмиме, дип шикләнә калдылар.

Хәмзә тауафны башкарганнан соң, туры кяферләр каршысына килде һәм аларга сәлам дә бирмичә әйтте:

— Йә, кайсыгыз минем туганыма кагылды, аны кыйнады? Валлаһи дип әйтәм, әгәр дә үзем шунда булсам, барчагызны кылычым белән өзгәләп ташлаган булыр идем! — диде.

Һәркемнән алда туганы Әбу-Җәһил телгә килде һәм:

— Мин кагылдым Мөхәммәткә,— диде.

Ачуы кайнап торган Хәмзә, йөгәннән чыгып, Әбу-Җәһилнең караңгы йөзенә җәясе белән китереп сылады, маңгаена әләкте һәм берничә җирдән башын тиште.

— Ятим кешегә ул җәфаларыңны ни йөрәгең җитеп эшлисең,— диде ачуланып,— энең бит ул синең!

Әбу-Җәһилнең кардәш тиешле башка кешеләре монда иде, алар Хәмзәгә таба килергә җөрьәт итмәделәр, Әбу-Җәһилнең дә күңеленә курку төште, дошманлыкны шушының белән бетерәсе килде, җавап бирергә атлыккан туганнарына аркылы төшеп, аларны туктатып калды.

Бу күңелсез вакыйгадан соң Хәмзә исә Мөхәммәт пәйгамбәрнең йортына таба юл алды. Килде, күрде: рәсүл, Кәгъбә тарафына карап, гыйбадәт белән мәшгуль иде.

— Әссәламегаләйкем, туганым,— дип сәлам бирде Хәмзә. Әмма пәйгамбәр тиз генә җавап бирергә ашыкмады, бераздан гына:

— Әлегә терекбез әле,— диде.

Хәмзә, кяферләр табына торган потлар белән ант итеп:

— Лат вә Гузза хакы өчен сиңа ярдәмгә килдем,— диде.

— Син иман китерерсең, шул кяфер Әбу-Җәһилләргә кылыч күтәрерсең, гәүдәләрен аякларыннан, башларын муеннарыннан аерырсың, кара башларына аягың белән басарсың, Аллаһы тәгаләнең якыннарыннан булырсың,— диде аңа тыныч кына Мөхәммәт пәйгамбәр. Бу сүзләрне ишетүгә, Хәмзә:

— Мин инде алар белән дошманлаштым, Әбу-Җәһилнең маңгаен берничә җирдән җәя белән сугып ярдым, иптәшләренә дә тиешле җәзаларын бирдем,— диде.

— Син иманга килмичә, минем күңелем барыбер хуш булмас,— диде Мөхәммәт пәйгамбәр.

— Корәиш арасында сүз йөри, сиңа бер вәхи килгән дә, өммәтең, шуңа таянып күңелләрен ныклы тота. Ул сүзләрне каян ишеттең? — дип сорады Хәмзә.

— Алар — Раббым Аллаһы тәгалә сүзләредер,— дип җавап бирде Мөхәммәт.

— Ул кәлимәләрдән миңа беразын белдермәссеңме? — дип үтенде Хәмзә һәм Мөхәммәт галәйһис-сәлам аңа мөэминнәр хакындагы сүрәне яттан укып күрсәтте.

— Синең Раббың минем кеби кемсә эшләгән гөнаһларны ярлыкармы? — дип сорады Хәмзә.

— Синең күңелең караңгылык диңгезеннән Аллаһы тәгалә хозурына килгәнлектән, Раббым булган гөнаһларыңны ярлыкар,— диде рәсүл.

Бу сүзләрне ишетүгә, Хәмзә тагын да берничә аять вә сүрәне укуын үтенде, пәйгамбәр аның теләген үтәде. Хәмзә бихуш булып утырды.

— Безнең Мәккәдә мең дә биш йөз пот бар, шуларның өч йөз алтмышы Кәгъбә эчендә, әмма берсененең дә Аллаһы тәгалә белән бәйләнеше юк булса кирәк, синең Раббың бөтен җирдә үзенең хөкемнәрен йөртәдер,— дип белдерде Хәмзә.

— Әйе! — диде пәйгамбәр.

— Мин синең иманыңа ышанамын, әмма бу кич өемә кайтып уйлыйм әле,— дип Хәмзә бу көнне иман китермәде, Мөхәммәт белән саубуллашып, кайтып китте.

Риваятьләрдә шулай сөйләнелә ки, Җир йөзендәге диңгезләрнең, җилләрнең, тауларның һәм дә Кояшның хуҗалары булган фәрештәләр бар. Бу фәрештәләр ни-нәрсә әмер итсә, бу диңгез дә, җил дә, Кояш та, таулар да аларның сүзенә буйсына торган иделәр. Мәккә кяферләренең Мөхәммәт пәйгамбәргә китергән җәбер-золымнарын алар күреп тордылар һәм Аллаһы тәгалә әмере белән ул фәрештәләр шушы кичәдә рәсүлнең каршына килделәр дә:

— Боер, йа Аллаһы тәгаләбезнең сөекле колы? — дип үтенделәр.

— Мин аларның барчасын Нух галәйһис-сәлам кавеме хәленә калдырып, дулкыннарым астында гарык итәрмен,— диде диңгезләр өстеннән әмер йөртүче фәрештә.

— Җир йөзендә Аллаһы тәгаләнең куәтеннән дә куәтлерәк вә аның теләгеннән дә көчлерәк һичбер нәрсә булмас,— диде рәсул.

Икенче фәрештә әйтте:

— Әмереңне җиткер, йа пәйгамбәр, мин бу Мәккә кяферләрен Гад кавеме кебек җил белән һәлак итәрмен! — диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр тагын шул ук җавабын кабатлады:

— Лә хәүлә вә лә куәти, иллә билләһил-галиил-газыйм!

— Мин Кояш белән идарә итүче фәрештә, әмереңне җиткер. Бу Мәккә кяферләренә көчле ялкынны җибәреп, туфракларын ут өстендә утырган су кебек кайнап торган итәрмен,— диде өченче фәрештә.

Мөхәммәт пәйгамбәр тагын да шул ук җавабын кабатлады.

— Мин шушы Мәккә янына килермен, тауларга әмер биреп, кяферләр өстенә ишәрмен,— диде дүртенче фәрештә. Әмма пәйгамбәрнең җавабы һаман да шул булды:

— Мин үземнең кавемемне харап итәргә теләмим, алар хәзергә инанып җиткермиләр, пәйгамбәрлегемә ышанмыйлар, әмма мин аларның хак юлга керәселәренә өметтә яшим,— дип белдерде ул.— Ә сезгә әмер итәр өчен мин нишләргә тиеш, миңа буйсынырсызмы? — диде.

— Без пәйгамбәрләргә буйсынмыйбыз, әгәр дә алар бәддога укып, Аллаһы тәгаләдән ярдәм өмет итсәләр, безгә шул җитә. Пәйгамбәрләрнең бәддогасы безнең өчен әмер белән бер,— диделәр алар җавапта һәм Мөхәммәтне калдырып киттеләр.

Бу кичәдә Хәмзә исә Мөхәммәтнең тупсасына кырык мәртәбә килде, әмма кырыгында да кире борылып, кайтып китте. Шулай итеп төнен уздырды. Иртә таң белән ул рәсүлнең ишеген шакыды.

— Йа, карендәшемнең угылы, мин сиңа иман китерермен, әмма син тагын да кичә кылган төсле итеп кәлимәләреңне укысаң иде,— дип үтенде. Мөхәммәт пәйгамбәр аңа яңа бер аять әйтте. Хәмзә, нурланып, йөрәге вә акылы хозурлык тоеп, чын күңеленнән сөенеп тыңлады һәм:

— Алланың берлегенә вә аның пәйгамбәре Мөхәммәт булуына таныклык китерәм! — дип белдерде. Шулай итеп, Хәмзә хәзрәтләре дә мөселман булды.

Моннан соң Хәмзә кяферләр янына китте, алардан мөселманлыкка керергә рөхсәт сорарга иде исәбе.

Кяферләр мәҗлесендә Әбу-Җәһил баш кеше булганлыктан, барчасы да аның янында иделәр, авызыннан чыккан сүзләренә мөкиббән китеп, колак тотып тыңлый иделәр. Хәмзә хәзрәтләре алар арасына килеп керде, үзенең исламга керергә теләге барлыгын белдерде.

Әбу-Җәһилнең ачуы кабарды. Мәҗлестә булган бер зат:

— Син исламга күчәргә ашыкма, бераз сабыр ит, юкса өстеңә бер-бер газап килер,— дигәч, Хәмзә:

— Аллаһы тәгаләнең тәкъдиреннән тыш башка җәбер-золымның куркынычы юк, алар барчасы буш, Аллаһы тәгалә бер һәм Мөхәммәт, чын мәгънәсендә, аның колы вә пәйгамбәре,— диде.

Кяферләр аптырашта калдылар, телләре әйләнеп, сүз әйтер хәленә кайта алмады. Куллары сузылса да, баһадир Хәмзәгә ябышырга көчләреннән килмәде. Аны тыныч кына араларыннан чыгарырга мәҗбүр булдылар.

Тарихлардан шул билгеле, бу елны, ягъни 616 елда хәзрәте Әбу-Бәкер Мөхәммәт пәйгамбәр белән мәсчеткә килде, монда мөселманнар вә кяферләр җыелганнар иде. Шушында Әбу-Бәкер беренче тапкыр хөтбә әйтте, бу хөтбә тарихта булган иң беренче вә әүвәлегесе иде.

Монда килгәнче Мөхәммәт пәйгамбәр белән аның әңгәмәсе булып алган һәм:

— Безнең өммәтебезгә һаман да җәбер-җәфа кичереп яшәргә калды, мөселманнар һаман да артмыйлар,— дип Әбу-Бәкергә пәйгамбәр фикерне җиткергән иде. Шул билгеле, ул вакытта Мәккәдә утыз тугыз кеше ислам динендә иделәр.

Әбу-Бәкер мәсчеткә килеп хөтбә әйтүгә, мондагы булган кяферләр аны әйләндереп алдылар, Гатабә бине Рабига-ләгыйнь Әбу-Бәкернең йөзенә, аягыннан салып, каткан башмагы белән шундый каты итеп сукты ки, йөзе вә күзләре күгәреп чыктылар. Әбу-Бәкернең котмәгәндә эшләнгән бу эштән аңы китте, аны мөселманнар көчкә генә аралап калдылар, аңсыз килеш өенә илттеләр. Барчасы Әбу-Бәкер үлеп китәр, терелә алмас, дип уйлады.

Ул ахшам җиткәндә генә аңына килде.

— Пәйгамбәремнең хәле ничек, аңа ни булды?—дип борчылды ул.

Янында булган кешеләр:

— Үз хәлен белсә иде, пәйгамбәр хәлен сорый бит әле...—дип авызларын учлары белән каплап сөйләштеләр. Әнисе Өмме-Хәйр аңа ризык китерде, әмма Әбу-Бәкер:

— Пәйгамбәрнең хәле ничек? Шуны белмичә, авызыма бер тәгамризык капмамын,— диде.

Әйтерләр ки, әнкәсе шуннан соң Хаттап кызы Җәмиләдән Мөхәммәтнең хәлен белешергә кушты. Ул тиз генә хәбәр китерде. Әмма Әбу-Бәкер:

— Үзен күрмичә авызыма ризык капмам,—дип тагын да белдерде. Шуннан соң бу ике хатын аны култыгыннан күтәреп алдылар, Мөхәммәт янына китерделәр. Алар кочаклашып күрештеләр, хәлләрен белештеләр.

Риваятьләрдән билгеле булганча, шул вакыйгаларга шаһит адәм— Өмме-Хәйр ул көнне Мөхәммәт пәйгамбәргә иман китерде. Һәм дә бу елда хәзрәте Гомәр дә иманга килде.

Бу вакыйга болай булды.

Көннәрдән беркөнне Әбу-Җәһил вә аның имансыз даирәсе әңгәмә кылып утыра иделәр. Хак тәгаләдән Мөхәммәт галәйһис-сәламгә бер аять ирешеп, анда Әбу-Җәһил вә аның тарафдарлары җәһәннәмгә олагачагы аңлашылды. Бу хәбәрне мөселманнар авызыннан Мәккә кяферләре ишетеп, эчләренә ялкын төште. Бу ут җәһәннәм базыннан китерелгән булганлыктан, үзен сүндерер өчен кан таләп итте. Әңгәмәсен җыйнаштырган Әбу-Җәһил, сүз башлап:

— И корәиш, арагызда Мөхәммәтне үтерергә барырдай берәр кеше бармы? Аңарга кырык мең дирһәм бүләк булыр. Йә, кайсыгыз?—дип, теләген ахмаклар өстәленә китереп салды.

Корәишләр арасыннан Гомәр калыкты:

— Мин барам дисәм, ни әйтерсең, йә Абал-Хәким,— диде Әбу-Җәһилгә кяферләр арасында таралган сөекле кушаматы белән дәшеп.— Лат вә Гузза илаһларыбыз белән ант итеп әйтәм, моны миннән башка

һичкем эшли алмас! — дип гөнаһка йөзен куйды. Әбу-Җәһилнең кулына ябышып, Кәгъбәгә китте, шушы Лат вә Гузза исеме белән аталган иң бөек потлары алдында ант суын эчте һәм, гыйбадәтханәдән чыгып, кылычын кулына алды, Мөхәммәт пәйгамбәрне үтерергә дип ул яшәгән йортка таба юл тотты.

Гомәр үзенең антына тугрылыгы хакында уйланды. Шунда юлына Әбу-Зөһрә кабиләсеннән булган бер кемсә туры килде. Ул мөселман булып, үзенең иманын кяферләрдән яшерә иде.

— Син болай кай тарафка юл алдың? — дип сорады ул Гомәрдән.

— Мөхәммәт пәйгамбәрне үтерергә барышым,— диде тегесе.

— Бине Һашим вә бине Габделмотталип туганнарына нәрсә әйтерсең соң? Канлы үч алу башланачак бит,— диде Әбу-Зөһрә.

— Ә-ә-ә, син әле Мөхәммәтне яклыйсыңмыни? Ул вакытта, әүвәл мин сине чәнчелдерәм! — диде ачуланып Гомәр.

— Ярый, мин каршы түгел, иманга килгән мөселман кеше идем, теләгәнегезне эшләгез,— диде бу адәм бер дә офтанмыйча.— Әмма харап итәр алдыннан мине Ибраһим пәйгамбәрнең үз улын корбанга дип китергән җиренә алып бар, шунда үтерерсең,— дип үтенечен дә белдерде. Гомәрнең күңеленә бер миһербан орлыгы төшеп, ул моңа каршы килмәде, корбан китерү җиренә бардылар.

Монда халык җыелып, бер бозауны корбан өчен әзерләп тора иделәр. Шунда, риваятьләрдә язылганча, бозау телгә килеп, Аллаһы тәгаләнең берлегенә вә Мөхәммәтнең Алла пәйгамбәре булуына шаһитлык китерде. Аны ишетеп торган Гомәрнең кылыч тоткан кулы салынып төште, ни максат белән юлга чыгуын онытты. Борылып, кяфер корәишләре көтеп торган урынга китеп барды.

Теге мәлгуньнәр барысы да элекке урыннарында иделәр. Гомәр, авыз суларын корытып, бозаудан ишеткән сүзләрне кабатлады, үз хәлен үзе аңышмый торды. Аны тыңлаган кяферләр:

— Бу эшкә бер дә аптырама, бу — Мөхәммәтнең сихерче булуына янә бер дәлил генә. Ул бозау сихер галәмәтеннән башка нәрсә түгел,— дип кабаттан Гомәрнең күңелен гөнаһ эшенә турыладылар. Яңадан да бу ахмак иске юлына кайтты. Кылычын тотып, пәйгамбәргә үлем илтә китте.

Юлына Бәни-Габделмотталип нәселеннән булган Нәгыйм бине Габдулла очрады һәм:

— И Гомәр, бу рәвешле кая барасың? — дип сорады.

— Мөхәммәтне шушы кылычым белән чабып үтерергә барам,— диде җавабында Гомәр.

— Бәни-һашим вә дә Бәни-Габделмотталиптан курыкмыйсыңмы? Сине алай гына калдыру тиеш булмас,— диде Нәгыйм.

— Ә-ә, әле син дә Мөхәммәтне яклыйсыңмы? Сине дә сихерләдемени әле ул?! — дип Гомәр тавыш чыгара башлаган иде, Нәгыйм бине Габдулла әйтте:

— Юк, мин ата-бабам динендә, син мине үтерә алмыйсың, иң элек кыз карендәшең Фатыйма вә ире Сәгыйть бине Зәйд янына барып күр, алар ислам динендә, башта аларны үтер, аннан соң Мөхәммәткә дә кулыңны сузып карарсың,— диде.

Гомәрнең кызган ачу ташына су сипкәндәй булды. Бәгыре кайнап чыкты, холкы кайнарланды:

— Дәлилең нәрсә? — дип сорады.

— Дәлилем шушы булыр: син бер куйны корбан итеп чал, карендәш сеңлеңә вә киявеңә аның итен ашарга куш, әгәр капсалар, алар исламда түгел, әгәр инде ашамасалар, мөселман булырлар, чөнки мөэминнәр кяфер бугазлаган итне ашамыйлар,— диде Нәгыйм бине Габдулла.

Бу сүзләрне ишетүгә Гомәрнең ачу ташы янә «чож-ж!» итте. Ул үзенә туган тиешле Фатыйма торган йортка таба юнәлде.

Фатыйма белән Сәгыйть бу вакытта Хаббаб бине Харистан яңа бер аять өйрәнеп утыра иделәр. Ишекләрен бикле тотып, һичкемгә ачмадылар. Гомәр, килеп җитүгә, шакылдата башлады, мөселман кардәшләре укый торган әйберләрен яшереп куйдылар. Хаббаб, Гомәрнең күзенә чалынмас өчен, качып тору җаен карады.

— Сез ни-нәрсә укый идегез? — дип каты гына тавыш белән Гомәр усал күзләрен аларга төбәде. Сәгыйть бине Зәйд вә Фатыйма исә, юк, без болай гына сөйләшеп утыра идек, дип алдадылар. Чөнки башка чара юк иде.

Гомәр, әлбәттә, аларның сүзенә ышанмады. Куй чалды, итен Фатыйма белән Сәгыйтькә ашарга кушты. Әмма алар:

— Без синең кебек кяферләр суйган корбанга сузылмыйбыз, динебез кушмый, — дип ачылып киттеләр, үзләренең иманлы бәндә булуларын белдерделәр.

Алардан шушы сүзләрне ишетүгә Гомәр, кияве тиешле Сәгыйтьнең якасына ябышып, аны кыйный башлады. Арага Фатыйма сеңлесе килеп кергәч, Гомәр тагын бер ажгырып кизәнде, йодрыгы сеңлесенең йөзен җәрәхәтләде, аннан кан акты. Кан күрүгә, Гомәр айнып киткәндәй булды, кулы кыскарды.

— И Гомәр, син батыйл динне дәгъва итәсең, без хак дин юлындабыз. Рәсүлебезгә иман китердек, безне кисәкләп-кисәкләп туракласаң да хак диннән кайтмабыз, — дип белдерде Фатыйма.

Бу сүзләрне ишетүгә, Гомәрнең таләбе черек капчыктай аерылып китте, бөселеп төште.

Ул вакытта мөселманнардан фәкыйрьлеккә төшкән кешеләр Мөхәммәт пәйгамбәргә гозер вә үтенеч белән килгән иделәр. Алар үзләренең тормышлары һаман авырлашуын, ә кяферләрнең золым-зәһәренең көчәя баруын зарланып сөйләделәр. Пәйгамбәр Аллаһы тәгаләгә үтенеч юллады, исламга кем дә булса зур кешенең, олуг бәндәнең килүен теләде, шундый бер кемсәгә изгелек нурыннан өмет чаткысы салуын үтенде. Бу дога вакытында Җәбраил галәйһис-сәлам күк капусыннан пәйда булды һәм Мөхәммәт пәйгамбәргә хәбәр җиткерде. Мәккә кяферләреннән бер олуг кемсәнең ислам юлына күңеле авышачагын вә аның өммәтләре өчен чын күңелдән вә барлык батырлыкларын биреп тырышачагын белдерде.

Җәбраил фәрештәнең шушы сүзләре рәсүлебезгә ирешкән вакытта Хаббаб бине Харис хәзрәт качкан җиреннән чыккан, Сәгыйть вә Фатыйма тәһарәтләнгән, чистарынып-пакьләнеп, Хаббаб теленнән изге аятьне тыңларга әзер иделәр инде.

— Кая, тыңлап карыйм инде, мәгәр ни-нәрсәләр? — дип үтенечен Гомәр мөселманнар алдына кабаттан салды. Шунда Фатыйма:

— И абыем, син пакь вә тәһарәтле түгел, безнең бар укыганнарыбызның файдасы булмас, үзебезгә гөнаһысы гына төшәр. Шуңа күрә тәнеңне пакьләп, күңелеңне дөреслек вә сафлык юлына салсаң иде, — дип үтенде. Бу сүзләрдән соң Гомәр каршы килә алмады, тәһарәт алды. Шуннан соң гына Хаббаб бине Харис хәзрәт Гомәргә атап аятьләр укый башлады.

Коръән сүзләре Гомәргә үтәли тәэсир иттеләр, караңгылыкта вә наданлыкта чалышая башлаган намус вә кешелеклелек баганасы турайды, күзләренә энҗе яшьләр тулдылар вә бите буйлап кайнар чишмә төсле төшеп, сакалын су кылдылар. Ул тагын да тагын яңа аятьләрне укуны сорады, күңеле исламга тартылды. Мөселманлыкка якынайган саен күкрәгендә горурлык вә олуглык тойгысы арта бирен, тәнендә баһадирлык куәте урнашты.

Гомәр шушы кичәдә иман китерде һәм:

— Мине хәзрәтегез Мөхәммәт пәйгамбәргә алып барыгыз? — дип үтенде. Алар юлга төштеләр.

Сәгыйть, Хаббаб белән бергә аякларын юлга куюга, Гомәр арадан алгарак чыкты, кулындагы кылычы һаман да ялтырап торды. Бу вакытта Гомәрнең Мөхәммәт пәйгамбәрне үтерергә барасы хакындагы хәбәр

бөтен Мәккәгә таралып өлгергән иде инде. Барчасы курка калдылар. Хәзрәте Хәмзә баһадирга бу хәбәр килеп ирешүгә, пәйгамбәрнең тупсасына килеп басты, Гомәрне җиргә салып таптарга карар итте.

Алар килә бирделәр. Сәгыйть вә Хаббаб әлеге Гомәр артыннан һич кенә дә куып җитә алмый гаҗиз булып, тәмам хәлдән тайдылар, маңгайлары тирләде, аяк астыннан күтәрелгән тузан йөзләренә сыланды, барыбер пәйгамбәр янына атлыккан Гомәрне куып тоту аларга насыйп булмады. Мәккә халкы, аһ-ваһ итеп, артларыннан карап калды. Гомәрнең кулында кылычы, зәһәр ялтырап, алга таба сузылган иде. Бу кылычтан кан исе таралгандай булды. Гомәргә аркылы төшәргә һичкемнең көченнән вә гайрәтеннән килмәде. Әмма...

Мөхәммәт пәйгамбәрнең тупсасына килеп җитүенә, аны Хәмзә баһадир каршы алды вә юлыннан туктатты:

— Йа, Гомәр, сөйлә, ни йомыш белән килдең? Әгәр яман теләккә атлангансың икән, без, беләсеңдер, Габделмотталип нәселе, туганыбызның канын кайтармый калмабыз, бездә намус тойгысы көчле булганлыкны беләсеңдер...— дип әйтеп бетермәде, Мөхәммәт пәйгамбәр килеп чыкты.

Халык аһ итте. Сәгыйть вә Хаббабның хәбәре әле таралып өлгермәгән иде. Пәйгамбәр, тупсаны атлап чыгуга, Гомәрнең йөзендә иман нурын күрде, каршысына килде һәм аны кочагына алды. Әйтерләр, Гомәрнең кабыргалары бу кочак эчендә берсе берсенең арасына керде, кулыннан кылычы төшеп китте. Мөхәммәт аны кочагыннан чыгаруга, Гомәр үзе дә пәйгамбәрне кочып алды. Шушы кадәр дә дустанә итеп күрештеләр ки, берни аңламый калган халык аптырашта торды, Хәмзәнең йөзендә нур балкыды.

Бу көнне Мәккәгә Гомәрнең иман китерүе хакында хәбәр колактан-колакка гына йөреп түгел, урамнар буйлап йөгереп таралды. Кяферләрнең бәгырен бу яңалык телемләп кисте, мөселманнарның йөзләренә исә кояш чыгарды. Җәбраил галәйһис-сәламнең әйткәннәре чын мәгънәсендә рас килде, пәйгамбәрнең гозер-үтенече иминлек булып җиргә иңде, өммәтләренең күңелләрен хозурлады вә караңгы кичәләрен яктыртты.

Иртәгесен Мөхәммәт пәйгамбәр Мәккә урамына үзенең яраннары белән чыкты. Янында — хәзрәте Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк, сулында — хәзрәте Хәмзә, уңында — хәзрәте Гали вә аның янәшәсендә хәзрәте Гомәр вә башка сәхабәләр бар иде. Барчасы да кулларында кылычларын ялтыраттылар һәм дә Кәгъбәгә карап юл алдылар. Тамаша кылган кяферләр, шушы кырык мөселманның саф-саф булып тезелеп баруларын күреп, бик тә гаҗәпләнделәр вә аяк асларыннан җирнең чайкалып китә баруын тойдылар.

Ул вакытта кяферләрнең олылары Кәгъбәдә бер җыелыш корып утыра иделәр. Көтмәгәндә каршыларына яраннары белән Мөхәммәт пәйгамбәр килеп чыккач, барчасы да телсез калдылар. Араларында Гомәр сәхабәнең кылычы ялтырап күренде, аһ итеп: «Гомәр бу мөселманнарны безнең башка җитү өчен алып килгән икән»,— дип күңелләре тетрәнеп куйды. Кайбер кяферләр ал-артларын да карамыйча йөгерә-куча башладылар. Бер ишесе исә Гомәргә тел озайтып маташты. Кайберсе:

— Пәйгамбәрне үтерәм дип киткән иде, безне һәлак итәм дип килгән, монда ниндидер хикмәт булырга тиеш,— дип гаҗәпсенеп калдылар.

Ул арада Гомәр алга чыкты вә кяферләр арасында булган бер мөхтәрәм вә дәрәҗәлесен тотып алды, күккә чөеп, җиргә салды. Бу кяфер ул көнне Гомәр кулыннан үләсе иде, әмма яраннары житешеп килделәр һәм көч-хәл белән аны аралап алдылар. Шушы хәлләрне күргән җаһиллар, бик каты өркешеп, тиз арада Кәгъбәне ташлап чыктылар, кайсы кая качып беттеләр.

Бу вакыйгадан соң Мөхәммәт галәйһис-сәлам беренче тапкыр мәсчеттә иртәнге намазын укыды һәм аның артыннан беренче тапкыр хәзрәте Гомәр бик тә моңлы тавышы белән мөнәҗәт әйтте.

Мөхәммәт галәйһис-сәлам күрде: Кәгъбә эче потлар белән тулган иде. Моңа ачуы килде. Яраннары сәбәпне тиз төшенеп алдылар. Шулвакыт күкләрдән бер аять иңде, дип яза тарихчылар, пәйгамбәр аны кычкырып әйтте һәм барча потлар сәҗдәгә килеп, йөзтүбән әйләнешеп төштеләр. Бу вакыйга бөтен Мәккә эчен вә аның тирә-як тарафларын гаҗәпкә калдырды, кяферләр көнелен көнчелек вә салкын ахмаклык уты чолгап алды. Әнә шул рәвештә Гомәр хәзрәтләренең иманга килүе мөселманнарның эшен үргә таба җибәрде. Шушы көннән башлап ислам динендәге кешеләр хурлык күрмәделәр вә диннәре алга китә башлады.

Бу вакыйгалар Мөхәммәт пәйгамбәрлегенең алтынчы елында Мәккәне вә аның әйләнәсен хозурладылар, ислам ныклап аягына басты, үзенең хаклыгына вә көченә күпләрне ышандырды, аның нуры күпләрнең аңына вә җанына үтеп керде.

## Сигезенче елдан соң

Пәйгамбәрлекнең җиденче елы алланың рәхмәте белән хәвефхәтәрсез генә үтеп китте. Мәккә кяферләре Мөхәммәткә вә мөселманнарга каршы ачыктан-ачык чыгыш ясарга курыктылар. Гомәр вакыйгасыннан соң аңнарын җыя алмый тордылар, әмма көферлекләре көнел түрләреннән чыкмады, кара килеш кала бирде. Нәүбәтән сигезенче ел мәйданга килде, корәишләр яңа бер этлеккә ал куйдылар.

Бәни-Габделмотталип вә бәни-Һашим кабиләләре Мөхәммәт пәйгамбәрнең кан кардәшләре булып, арада Әбу-Талип мөхтәрәм вә хөрмәткә лаек кемсәнә иде. Мөхәммәт аның тәрбиясендә үскәнлектән, рәсүл хакында берәр сүз чыга калса, нәтиҗә өчен нигез итеп аның сүзләрен ала иделәр. Ә беркөнне Әбу-Талипны Мәккә кяферләре үз мәҗлесләренә дәштеләр һәм аңа:

— Йә син безгә Мөхәммәт пәйгамбәрне тотып бирәсең һәм без аны үтерәбез, яки ул безнең динебездән вә потларыбыздан көлми башлый, яисә шәһәребезне ташлап китә! — дип шарт куйдылар.

Әбу-Талип уңга да, сулга да борыла алмады. Таләпләр шактый кырыс вә авыр иде. Әбу-Талип, шагыйрь булганлыктан, күңеле хискә вә тойгыларга бай иде. Үз тәрбиясендә үскән Мөхәммәтнең язмышы өчен кайгырмый кала алмады, аның алдына килеп, сүз катарга уйлады.

— Иртәгә таң беленеп, кояш күтәрелүгә җавабыңны китер! — диделәр аңа корәишләр, — йә булмаса без үзебез барысын да эшләрбез, ризалыгыңны белдер, — дип сүзне уртадан өзделәр.

Әбу-Талип чарасыздан Мөхәммәт пәйгамбәр янына килде вә кяферләрнең таләпләре хакында аңа бәян итте.

— Мин бу шартларның берсенә дә күнә алмыйм, чөнки мин үз иркем белән түгел, бәлки Аллаһы тәгалә әмере белән эш йөртәм. Миңа андый әмернең ирешкәне юк, — дип кырт кисте рәсүл вә Әбу-Талипны калдырып китте.

Ул көнне Мәккә кяферләре бер килешү хаты төзеп, аңа кырык мөһерне сылап куйдылар. Риваятьләрдә бу мәктүпне төзүчеләр итеп берничә кеше күрсәтелә. Бер ише китапларда аның язучысын Мансур бине Гәкрәм бине Гамер дип бәян итсәләр, икенчеләре Назар бине Әл-Харис, яки Талиха бине Әбу-Талиха ләгыйньнәрне атыйлар. Өченче төр хезмәтләр исә бу кемсәләр әлеге хатны өчесе бергә язды, дип белдерәләр.

Ул мәктүпнең эчтәлеге шуннан гыйбарәт иде ки, кяферләр бу көннән башлап мөселманнар белән алыш-биреш йөртмәскә, кызларын аларга бирмәскә, болардан да кыз алмаска, егылганда ярдәм белән кул сузмаска дип килешү төзеделәр, шәхси мөһерләре белән сүз беркеттеләр вә аны Кәгъбәнең капкасына элеп куйдылар. Анда Бәни-Һашим вә Бәни-Габделмотталип нәселе белән дә аралашмаска дигән таләпләр куелды. Әгәр кем дә булса бу килешүне бозса, аңарга зур вә көчле газаплар кылырга карар бирделәр.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең нәсел-нәсәбе, туган вә кардәшләре мөселманнар белән бергә бик авыр хәлдә калды. Аларның якасына ачлык бүген-иртәгә килеп ябышырга мөмкин иде. Әгәр дә Әбу-Бәкер, Хәмзә вә Гомәрнең байлыклары вә мөселман кардәшләргә хәер-садакалары булмаса, бу хәлдә яшәү үлемнән башка һичбер җиргә алып бармас иде. Аллаһы тәгалә өчен мөселманнарның иман ныклыгын яки йомшаклыгын сыный торган вакытлары иде бу.

Мәккә базары көне-төне шаулап торды. Корәишләр сату-алу кылдылар, әмма бу эштән мөселманнар вә рәсүлнең кайбер карендәшләре, кяфер булуларына да карамастан, читләштерелгән иделәр. Кяферләр Мөхәммәтне үзләренә тотып бирергә кушып, таләпләрен яңартып торсалар да, Әбу-Талип аны аларга бирмәде, кяферләр аның горурлыгын сындыра алмадылар.

Әгәр дә берәр мөселман яки пәйгамбәрнең туганы базарга килсә һәм берәр сәүдәгәр белән килешенсә, товарын сатып алырга теләгәндә генә Мәккә кяферләреннән берәр баерак кемсә килә иде дә, артыграк бәя биреп, ул товарны үзенеке итә иде. Монда күзгә карап үчләшү күренеп тора иде. Тагын да берәр кеше, миһербанлык күрсәтеп, мөселманнарга ризык китерсә, корәишләр аның юлына аркылы төшә иделәр һәм китергән бүләк-күчтәнәчләрен йә җиргә сибә, яки үзләренә үзләштерә иделәр. Кяферләрнең җәбер-золымына каршы берни дә кылырга мөмкин түгел иде кебек. Аллаһы тәгалә дә ярдәмен ирештерергә ашыкмады. Ислам таифәсе аның сынауларын үтеп бетерергә тиеш, шуңа олуг сабырлыклар таләп ителә иде.

Мөхәммәт пәйгамбәр һәрвакыттагыча озын киез кием киенеп, чалмадан, йә булмаса башын яулык белән урап йөри бирде. Сакал-чәчен бик чиста вә пөхтә тотып, һичвакыт намаз-догасын калдырмады. Китапларда шулай язалар ки, пәйгамбәрнең чәче җилкәгә кадәр төшеп тора иде, йөзе якты вә нурлы, телендә сөйләнгән сүзе ачык вә аңлаешлы, кыска вә төгәл, камил фикерле иде. Аның сабырлыгы, ныклыгы һәркемгә үрнәк булды. Аллаһы тәгаләдән иңгән Коръән аятьләре ирекле вә ак шигырьне хәтерләткәнлектән, рифма вә ритм белән бәет сөйләүне кәсеп иткән ялган шагыйрьләр бу аятьләрне Мөхәммәт үзе язган дип кабул итә иделәр һәм аның шушындый «шигырьләре»ннән көлә иделәр. Хак тәгаләдән китерелгән сүзләрне вә аятьләрне пәйгамбәр, аларга карап, һич тә үзгәртүне кирәк тапмады. Ул шагыйрьләрнең мыскыллауларына игътибар күзен ташламады, «мин — шагыйрь» дип лаф ормады. Ходай тәгаләнең әмереннән чыкмады, рәсүл сыйфатында кала бирде. Аның мондый да ныклы вә сабыр булуы кяферләр арасында тагын да көнчелек утларын көчәйтте, бәгырьләре үч ялкынында көйде, әмма Аллаһы тәгалә аларның кулларын кыска кылган иде, сузылып-тартылып та Мөхәммәткә буйлары җитмәде. Рәсүлнең даны көннән-көн һаман да ишәя барды.

Мөселманнарның ач торуларына аларның карендәшләре вә дә якыннары пошаманда булдылар. Ничек тә ярдәм итәргә теләделәр. Көннәрдән беркөнне Хәдичәнең туган тиешле энекәше Хәким бине Хизам, аркасына бераз ризык алып, пәйгамбәрнең йортына китте. Юлында аңа Әбу-Җәһил мәлгунь очрады. Аркылы төште:

— Ә-ә!.. Син әле Мөхәммәткә ризык китерәсеңме, мин сине бар корәишләр алдында рисвай итәм,— дип тавыш куптарды. Артыннан

калмый іяреп килде. Чыгырыннан чыгып, кулын эшкә җикмәкче иде, Әбул-Бухтури бине Һашим күренде һәм:

— Нәрсә, апасына ризык илтә икән, моның ни начарлыгы бар соң? Илтсен. Бу бит әле Мөхәммәткә китерде дигән сүз түгел,— дип әйтүгә, Әбу-Җәһил тагын да кызып китте. Ни хикмәт, Әбул-Бухтуриның кулында дөя нуктасы бар иде, ул шуның белән Әбу-Җәһилнең башына орды. Бу хәлдән ахмакның очу куыгы шартлардай кабарган иде инде, эшнең ни белән бетәсен беркем дә күз алдына китермәде. Әмма, була бит шундый хәлләр, хәзрәте Хәмзә күренде. Бу баһадирны Әбу-Җәһил тиз шәйләп алды һәм корчаңгы эт төсле коерыгын кысты вә моннан ычкыну ягын карады.

Бу вакыйгадан соң пәйгамбәргә ярдәм итәргә теләүчеләр саны ишәеп китте. Бары тик корәишләрнең олуглары ни әйтер дип куркып кына тора иделәр.

Бер кичәдә Һашим бине Гомәр бине Рабига өч йөк ризыкны Бәни-Һашимга китерде. Моны Мәккә кяферләре белеп алдылар һәм юлына аркылы төштеләр, килешүне бозуына тавыш куптарып:

— Әгәр тагын да шундый хәл кабатланса, син безнең кеше булудан туктарсың, үзең дә алар хәлендә калырсың,— диделәр.

Әмма икенче кичәдә дә Һашим бине Гомәр бине Рабига тагын Бәни-Һашимга ике йөк ризык китерде. Моны бу юлы да корәишләр белеп алдылар, ачулары күкрәк читлекләрен җимереп чыгардай булды, тавыш китте, килешүнамәнең көче бетте һәм Әбу-Сафйан кяфер бик каты орышып:

— Бер дә сүзегездә тора алмыйсыз, әгәр болай эшли башласак, мөселманнарны буйсындыру һичкайчан мөмкин булмас. Килешүне бозган кемсәнәләр арабыздан китсен! — дип җикеренде.

Бу вакыйгадан соң Һашим бине Гомәр бине Рабига вә Хәким бине Хизан иманга килделәр вә сәхабәләргә кушылдылар. Әйтерләр, ул кичәдә Әбу-Сафйанга да иман нуры иңде, тора-бара аның күңеле исламга ныграк тартылды һәм ул да мөселманлыкка чыкты, әмма Әбу-Җәһилгә мәңге кяферлек сөреме буялган килеш калырга насыйп ителде.

Озак та үтмәде, Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияве Әбу-Гасибне Рабига Мәккәгә зур кәрван белән килеп төште. Бик күп иген вә җимешләр китерде. Барча мөселман рәсүлнең йортына җыелды вә ризыклы булып, ачлык бәласеннән котылып калдылар.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, Һашим бине Гомәр бине Әл-Харис, Заһир бине Өмәййәт, Мөттәгыйм бине Гадә, Нуфал бине Габдеманаф, Зәмәгать бине Әл-Әсвал бине Габделмотталип ибне Габделгази — бишесе бергә ислам динен кабул итәргә булдылар. Әмма килешү хатындагы сүзләрне исләренә төшереп, иң элек корәиш олугларыннан рөхсәт сорауны кирәк таптылар. Шул исәптә сүз беркетеп, кичен таралыштылар, ә иртә белән корәишләрнең җыен урынына килеп бастылар вә Һашим сүз башлады, исламга чыгарга исәпләре барын хәбәр итте. Шунда Әбу-Җәһил бик каты орыша башлап:

— Сез дә килешү мәктүбенә кулларыгызны куйдыгыз, иске динебездән чыгып, Мөхәммәткә иярүегез бер дә мактанырлык эш түгел. Сез дә ул мәктүп сүзләре белән килештегез,— дип аларның теләкләренә каршы төште.

— Без асылда ул мәктүптә язылган сүзләр белән килешми идек, сез мәҗбүр иткәнгә генә аңа буйсындык,— дип җавап бирде болар.— Бу килешүнамәгә без тамгаларыбызны салмадык,— дип тә өстәделәр.

Арадан корәишләр, аларның бу туры сүзләре белән килешмәүләрен белдереп, тавыш чыгардылар. Шушындый вакытта да гарәпләрнең исламга килүләренә, берьяктан, гаҗәпләнсәләр, икенче яктан, бик тә хәсетләнделәр.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә ки, Мөхәммәт пәйгамбәргә бу вакытта Җәбраил галәйһис-сәлам килеп ирешә вә кяферләрнең килешүнамәсенә көя төшеп, теткәләп бетерүен хәбәр итте һәм:

— Алла исеменнән тыш анда бер генә дә сүз калмады,— диде.

Мөхәммәт пәйгамбәр, моны ишетүгә, Әбу-Талип агасына барды һәм шушы хакта сөйләп бирде.

— Син моны каян белдең?— дип сорады агасы.

— Хак тәгаләнең бөек фәрештәләреннән Җәбраил галәй-һиссәлам житкерде,— дип җавап бирде пәйгамбәр.— Ул язуда Аллаһы тәгаләнең исеменнән тыш һичбер сүз сакланып калмаган,— диде.

Әбу-Талип исә Мөхәммәтнең бала чактан бирле хак сүзле кеше булып үсүен белә иде. Шунлыктан аның сүзләренә инануны кирәк тапты. Корәишләр утырыш корган җиргә китте.

Әбу-Талипның килеп керүе кяферләр арасында чебен кебек безләү авазларын уятты. Чөнки аның да исламга күчүеннән шикләнделәр. Күптән араларында күренми иде.

— Син безләрне исламга өндәргә йә булмаса алдарга дип килгән, ялгышасың, сиңа барыбер рәхим-шәфкатебез юк,— дип каршы алдылар.

Әбу-Талип ни йомыш белән йөрүен сөйләп бирде һәм килешүнамәләрен көя ашап бетерүен әйтте. Ул мөселманнарның күптән инде Кәгъбә капкасын атлап кермәүләрен белә иде.

— Бер Аллаһы тәгалә исеменнән тыш, башка барлык сүзләрегез теткәләнеп беткән булыр,— диде ул, хаклыгын белдереп.

Мәккә кяферләре, әлеге дә баягы, исламга килергә теләгән биш кемсәне алларында тотып, язмышларын хәл итеп утыра иделәр, Әбу-Талиптан мондый сүзләрне ишеткәч, аптырашта калдылар.

— Әгәр ялган сөйләр булсаң, үзеңне харап итеп ташларбыз,— дип капка өстеннән шул килешүнамә төргәген китерделәр вә чишеп җибәрделәр. Ахмакларның авызлары салынып төште. Әбу-Талипның китергән хәбәре хак булып чыкты. Чыннан да бу килешүнамә тәмам теткәләнеп беткән иде ки, бары тик Аллаһы тәгалә исеме язылган урын гына исән-сау калган иде. Шулай итеп, өч ел эчендә боларның килешү мәктүпләре тәмам эштән чыккан, асыл сыйфатын югалткан иде. Аның дәреслеге вә көче шул сәгатьтә үк бетте. Теге биш кемсә иман китерүдә ирекле булды...

*Кәгъбә күренешләре*
**Абдулла ДУБИН***ның*
*фотоархивыннан алынды.*

*(Ахыры бар.)*

# ШИГЪРИЯТ

## *Марс Шабаевка 60 яшь*

*Шәхес һәм шагыйрь буларак, Марс Шабаевны һичкем белән дә бутый алмыйсың. Тыштан караганда корырак, кырысрак күренгән шагыйрь, иҗатында да кырыс, усал, чәнечкелерәк эслүб (стиль) белән аерыла төсле; әмма шул ук вакытта тормышчан да, кешелекле дә эчке бер җылылык сизелә анда. Мин Марс Шабаевны кырыс дөнья, табигать һәм йөрәк уртаклыгын күрергә, җырда чагылдырырга тырышучы итеп күзаллыйм... Бу — тумышыннан ук аның табигатендә кебек...*

*Шигъри сулышында — ятимлеген дә сиздермичә, хыял иленә алып килгән гүзәл Минзәлә ягы. Әйе, әдәбиятыбызга күп шагыйрьләр бүләк иткән, шулай ук атаклы педучилищесы да булган Минзәлә. Монда инде башка төбәкләрдән дә барып укыганнар, әдәбият-сәнгать, фән дөньясына килә торганнар бихисап. Болар — педагог холкын үзләштергән зыялылар: пөхтәлек, уңганлык һәм... педантлык, үҗәтлек, кырыслык кебек «хәлфәлек» сыйфатлары... Белемгә омтылу зур, башка телләрне дә яхшы беләләр. Марс абыйдан мин шушы «дарелфөнүн» — Минзәлә педучилищесы турында повесть язуын үтенгәнем бар: Арча гына калмас бит «тарихта», сезнеке кемнән ким? Анда татар теле һәм әдәбияты укытучы бер гаҗәп «феномен» булган дип тә ишеткәнем бар...*

*Аннары — педагогия институты. И. Юзеевлар белән бер чорда уку, яза башлау... Әмма Хрущев чоры «җепшеге» «умырзая»ларының язмышы төрлечә: берәүләр шунда ук танылa... Ә М. Шабаев озак эзләнә. Рухы белән шул чорга — илленче елларга туры калса да, нигездә ул — алтмышынчы еллар шагыйре. Яңа ритм-стиле, шигъри чаралары, публицистика һәм лирика кушылган шигырь, поэмалары, балладалары белән... Әйе, «Яңа җыр», «Җирән Конрад», «Сине эзлим», «Әби-апа», һ. б. — шул еллар җимеше... Бу елларга караш һәм әдәби кыйммәтләр үзгәрсә дә, бер нәрсә бәхәссез кала: шагыйрьнең индивидуаль йөзе, дөньяга карашы, шәхес эзләнүләре.*

*Ә М. Шабаев — үз хаклыгына, дөреслегенә, холкына, үз иманына тугры калачак, мин моңа ышанам. Чөнки бүген шик астына алынган күп чынлыкларны ул үз йөрәге белән кичереп, акыл, тәҗрибәләр, эзләнүләр, югалтулар аша тапкан.*

*Бу — фаҗигаме ул, көрәш юлымы, табигый кеше гомере, яшәү өчен мәҗбүри этаплармы?! — барыбер, игътибарга, ихтирамга лаек.*

*М. Шабаев — «Салда сәяхәт» исемле повесть авторы да, ул — шулай ук атаклы У. Уитменның «Үлән яфраклары»н (шигырьләр һәм поэмалар сайланмасын), Е. Евтушенконың «Казан университеты» поэмасын, чеген фольклоры үрнәкләрен һ. б. тәрҗемә итте. Балалар өчен дә китаплары бар.*

*1976 елда исә шагыйрь Г. Тукай бүләгенә лаек булды.*

*Белемле, эрудицияле әдипнең хезмәт урыннары да гали булды: радиокомитетта, «Яшь ленинчы» газетасында бүлек мөдире, «Идел» альманахы редакторы, «Азат хатын», «Казан утлары» журналларының җаваплы сәркатибе, Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир булып эшләде. Боларның барысы да милли мәдәниятебезгә, әдәбиятыбызга багышланган гомер сәхифәләре...*

*Колоритлы шәхес, үзенчәлекле шагыйрьне 60 яше белән котлыйбыз!*

**Рәдиф ГАТАШ.**



# Марс Шабаев

## Янсын җаның, янсын...

«Кош кына да — өч йөз елны яши!
Ник табигать бездән кызганган?
Гомер кыска...» — диеп офтанасың,
Көнләшәсең һаман козгыннан.
Офтанма син!
Яшьтәмени хикмәт?
Туган көннән алып үлемгә
Еллар санау — бары бер шартлылык.
Гомер озынлыгын кем белгән?
Көннәр-айлар, еллар-гасырларга
Салып үлчәмик лә без аны —
Ялыктыргыч озын гомерләр дә
Барыбер мәңгелекнең тузаны.
Бик күп сыя гомер бизмәненә:
Яши белсәң янып-ялтырып;
Бер гөнаһың өчен вөждан сине
Тотып ярса, мең кат яткырып:
Чит җирләрдән кайтып егыла алсаң,
Елый алсаң туган нигездә:
Икәү бергә эри алсаң әгәр
Татлы...
               татлы...
                              татлы мизгелдә...
Яшәү тәме — хисләр чиксезлеге.
Югалтулар булсын, табышлар...
Онытылмас кыска куанычлар,
Онытырлык озын сагышлар...
Тамчысына кадәр йотлыгып эч:
Һәр мизгелең — хәят суыдыр.
Җаның ягып яшә, җаныңны як!
Көне килер, тән бер суыныр...
Еллар үткәч, кемдер бармак төртеп,
Тиңләмәсен, дисәң, козгынга —
Җаныңны як!

---

Марс ШАБАЕВ (1933) — *шагыйрь, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, «Көн арты көн», «Җыр тәме», «Гомер уты» һ. б. дистәләгән китаплар авторы. Казанда яши.*

Җылыт дөньяларын...
Янсын җаның, янсын, кызганма!

## Шәһре Болгар

Кара пулатлары, мунчалары
Күптән миңа таныш, билгеле...
Мин соң монда янә шул ташларны
Багар өчен генә килдемме?

Карап йөрим сине, Шәһре Болгар...
Хәрабәләреңә юк кадер!
Ташландык та җимерек —
Битарафлык...
Ни зиратың синең, ни кабер...

Кабер ташларының, кубарылып,
Кычкырасы, нәгърә орасы
Көне үткән микән, әллә алда? —
Ә кемнәрдән аны сорасы?

Ут-сөрем дә, көл-күмер дә хәзер
Күзгә кереп тормый —
Беткәннәр...
Бетмәгәннәр!
Алар безнең канда...
Безнең җанга-анга күчкәннәр.

Көл-күмергә калып вәйран булган
Канлы ярам — Шәһре Болгарым,
Хәрабәләреңнән күтәрелмәк,
Тормак була соңгы улларың...
Үлгәннәрнең рухы тынлык сорый...
Дөнья кумак була исәннәр.
Шәһре Болгар!
Хәрабәләреңдә
Тик битараф җилләр исәләр...

* * *

Яна илләр белән ил арасы...
Бер кузгалса,
Юк туктар чамасы —
Халыкларның аңа ни чарасы?!
Яшьне-картны ялмап гел барасы,
Корбаннарын һич юк кайтарасы,
Җан ярасы да ул,
Ил ярасы,
Бөтен кешелекнең йөз карасы,
Кара шигырьләрнең иң карасы —
Каһәр генә төшкән сугыш ласа!

## Ялгыз әби турында баллада

*(Юрий Разумовскийдан)*

Пыкраудан ук инде кәефе юк —
Йокы алмый ялгыз әбине.
Аны кызгангандай, абзарында
Сыеры авыр мышный...
Йә инде!
Озын-озак шыксыз төннәренең
Кара пәрдәләре артында —
Сугышлардан кайтмый калган ире...
Газиз улы...
Бик чыгасы йөгереп каршыга ...—
Хәле юк шул!
Тормыш аны бөкте,
Бөкте... бөгеп бетерә алмады:
Яшь тә чибәр иде — бирешмәде!
Ә язмышы барыбер алдады...
Ач-ялангач булды колхозында,
Эшләп йөрде коры «таяк»ка.
Ирсез-улсыз авыр иде аңа
Тернәкләнү, басу аякка.
Әмма барыбер күрше-күләннәрдән
Ким булмады — шөкер Аллага!
Хәстәрләнде инде: сөлге, димсең,
Кәфенлекләр, димсең... —
Бар да бар...
Тик сыеры менә бик кызганыч:
Авылда бер сөтлебикәне
Сатарлар шул...
Җандай газиз малкай
Чит кулларга китәр микәнни?
Акбаем да ятим калыр инде...
Иллә инде акыл үзендә!
Кемгә калдырсам да, сагыныр шул...
Хәзердән үк сагыш күзендә —
Сизенәдер, бахыр...
Торыйм әле...

Торды әби... иплэп киенде.
Тәһарәтен алды укына-укына:
«Әйдә, үлем, килсәң кил инде...»
Шунда сөтлебикә мөгрәп куйды,
Искәртте күк фани дөньяны.
Китәрсеңме инде бу дөньядан
Сыерыңны саумый гынамы?
Торды әби... әкрен генә чыкты.
Чиләкләре койма башында.
«Тордыңмыни? Хәлең юк...» — дигәндәй,
Акбай шыңшып килде каршына.
«Хәзер, Акбай, хәзер...» — чиләкләргә
Үрелде дә...
Калды эленеп
Коймасында...
Әле генә юып,
Киптерергә элгән кер кебек...

Уңып төсе киткән күзләрендә
Инде кояш сүнде микәнни?
Соңгы уе булды әбекәйнең:
«Саумый калдым сөтләбикәмне...»

## Төнге гөлем

*Баркарола*

Алтын шәфәкъ инә...
Әйтерсең лә
Яңа бер җыр керә күңелемә.
Алтынланып Идел-су тирбәлә —
Гүя йоклата ул сине минә
Тирбәлдереп кенә,
Төнге гөлем...

Комлы ярга кургаш дулкын кага...
Җәелә төн җиргә,
Төн дөм кара...
Идел җылы, тигез сулыш ала —
Синең сулышың да йоклаганда
Шулай җылы була,
Төнге гөлем...

Кай саксызы төн тынлыгын ваткан?
Сискәндергеч бер өн-аваз килә
Кинәт кенә шунда аргы яктан —
Төшләндең дә син сискәндең гүя,
Нигә икән, нигә,
Төнге гөлем?..

Кирәкмәгән шөбһә-шомнарымны
Юып ала Идел томанымы,
Әллә айның көмеш нурларымы?
Сак йокыңны саклап торганымны
Күзли йолдызлармы,
Төнге гөлем?..

Таң йолдызы —
Чулпан йолдыз яна...
Әкрен генә офык алсулана...
«Аерылабыз...» — диеп, моңсуланма,
Таң йокыңны бүлмә,
Төнге гөлем...

Син татлы бер төш күрерлек кенә,
Йөзеңнән нур бөркелерлек кенә,
Куеньмда бер эрерлек кенә,
Бер мизгеле бер гомерлек кенә
Вакытың бар әле,
Төнге гөлем...

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Фәнис Яруллин**

## КАЙТУ

ПОВЕСТЬ

*22 яшендә һәлак булган лейтенант Олег Шәйхетдиновка багышлыйм бу әсәремне.*

АВТОР

Улым! Менә тагын мин синең яныңа килдем. Еш килмәвем өчен рәнҗемә. Язмышның олы күсәге безнең башларга, һич көтмәгәндә, шундый итеп китереп сукты — әле һаман миңгерәүләнеп йөрибез, кая барып бәрелергә, кемнән ярдәм сорарга белмибез. Вакыт — табип, йөрәк ярасын шушы табип дәвалый, диләр. Ай-һай, давалый алыр микән? Чит җирләрнең салкын туфрагына сине күмеп кайтканга инде менә өч ел тулып узды. Кабереӊ туфрагына әнкәң белән утырткан чәчәкләр тамырланды, аларның орлыгыннан яңалары үсеп чыкты, әмма йөрәк яралары төзәлмәде. Күрәсең, кабереӊ өстендәге туфрак тигезләнсә дә, яра төзәлмәстер. Елый-елый әңкәңнең күзендә яше кипте. Хәзер без бер-беребезнең күзләренә туры карый алмыйбыз. Тел очларыбызда, җанны телгәләп, бер үк сорау тирбәлә: «Кем гаепле?» Илме, минме, таркалып баручы армияме, әллә бөтенебез дәме? Кайчан гына әле мин иң ватанпәрвәр кешеләрнең берсе идем, бүген исә бөтен дөньясын ватасы-җимерәсе, бар дөньяга ләгънәт яудырасы килә. Нигә кеше белән кеше, армия белән армия, илләр белән илләр үзара гел ызгышып яши? Нигә дөньяда туктаусыз сугышлар бара? Нигә? Нигә?..

Шушы, һәм җавабын таба алмаган башка йөзләрчә сораулар, чигәмә чүкеч белән туктаусыз сугып тора. Юләр кешедәй, кайвакыт төннәрен

---

Фәнис Яруллин (1938) — *шагыйрь, прозаик, драматург, күпсанлы китап, сәхнә әсәрләре авторы. М. Җәлил исемендәге бүләк лауреаты. Казанда яши.*

сикереп уянам. Нинди генә шат кешеләр арасында утырмыйм, нинди гүзәл җирләрдә йөрмим — шатлыклар арасыннан саркып чыгып, синең каберең күз алдымда калка. Үзең сау-сәламәт яшәп тә баланның тар каберләрдә ятуын күрүдән авыррак нәрсә юктыр дөньяда. Кайгыны үлчи алырдай үлчәү юк, диләр. Бар ул андый бизмән. Ул — йөрәк! Шушы бизмәннең бер тәлинкәсендә минем бөтен гомер: җиңү-җиңелүләр, хыял-өметләр, күтәрелү-төшүләр, кайгы-шатлыклар, ә икенче ягында син, улым. Синең як тәлинкә бүген авырлыктан җиргә тигән. Анда синең ашкынучан йөрәгеңнең челпәрәмә килгән өметләре, бөреләнә башлаган мәхәббәтеңнең утка көйгән чәчәге. Анда син йөрисе юллар, син менәсе үрләр, син кичәсе дәрьялар, син сокланасы алсу таңнар. Вакытсыз өзелгән гомер чәчәгеңнең бер яфрагын гына салсаң да минем барлык җиңү — уңышларымны басачак, чөнки синең як тәлинкәдә — авырлардан авыр кабер туфрагы.

Үлчәүнең икенче як тәлинкәсендә минем алтмыш елга якын гомерем. Шул гомернең яртысыннан күбесе хәрби хезмәттә үтте. Ничә еллар үз-үземне алдап: «Мин — Ватан сакчысы, минем хезмәтем — иң кирәкле хезмәт!» — дип яшәдем. Кемне якладым, кемне сакладым мин? Кая ул безнең уртак Ватан?

Үлчәү тәлинкәсенә салынган барлык гамәлләремнең очкан коштан төшеп калган мамыктай җиңел һәм тамырсыз икәнен аңлау болай да телгәләнгән бәгырьне парә-парә китерә. Синең кайгың өстенә үз гомеремнең шундый арзан, шундый мәгънәсез очлануын күрү күңелдә гарьлек, үкенү тудыра.

Хәрбиләр еламый, диләр. Мин үзем сине һәрвакыт чыдам, сабыр, нык итеп үстерергә тырыштым. Ә үзем каберең өстендә яшьләремне тыя алмый басып торам. Армия дигән албасты күңелемдәге кызгану һәм кешелеклелек хисләрен бөтенләйгә куып чыгара алмаган икән әле. Мин бүген елый, чистара алуыма шатланам. Ә кеше кайчан да булса бер чистарынырга, үзенең асылына кайтырга тиеш. Юкса без артык керләнеп беттек.

«Син әлек андый түгел идең, әти», — дисеңдер, улым. Әйе, мин әлек совет армиясенең кадровый офицеры идем, бүген — егерме ике яшьлек улын югалткан ата. Әлек мин хәр фикер йөртергә, үз акылым, үз теләгем белән яшәргә хаксыз бер сәясәтче идем, бүген — идеология богауларыннан арынган иректә кеше. Кеше үзенең кылган эшен, яшәгән гомерен ныклап аңлар өчен зур тетрәнүләр кичерергә тиештер, күрәсең. Мин бит, улым, сине генә түгел, үземнең үткәнемне һәм киләчәгемне дә югалттым. Үткәннәрсез яшәп булса да, киләчәксез яшәп булмый. Һәр таңга, яңа туган һәр көнгә сөенеп уяныр өчен кеше үзенә таяныр нокта табарга тиеш! Гомерем буе армиядә хезмәт итү, бер урыннан икенче урынга күченеп йөрүләр, һәрвакыт югарыдан килгән күрсәтмәләргә буйсынып яшәүләр мине шушы таяну ноктасыннан мәхрүм иткән икән. Бүген мин таяныр ноктаны таптым шикелле — ул атамнар, бабамнар нигезе икән. Мин шуңа ышандым: туган якларымда гына мин кабат терноклонә алачакмын.

Чит-ят җирләрдә мине калдырып китәсезмени?» — дип сорарсың, улым. Юк, калдырмыйбыз. Әгәр сине монда калдырып китсәк, нинди җан белән анда яшәрбез?! Син җыена башла, улым. Без сине үзебезнең туган җирләребезгә алып китәбез. Син дә, мин дә ватансыз кешеләр булып күп яшәдек. Ә кешегә тере вакытта гына түгел, үлгәч тә ватан кирәк икән — мин бүген шуны аңладым, улым.

Шулай! Син җыена тор, улым. Без әниең белән күңел хәрабәләре арасыннан синең якты истәлекләреңне тагын бер кат өскә калкытыйк. Без хәзер шул хатирәләр белән генә яшибез. Ком арасыннан килеп чыккан алтын бөртеге кебек, көннәрдән бер көнне, шушы хатирәләр арасыннан: «Кем гаепле соң?» — дигән сорауга җавап табарбыз төсле.

* * *

Сине дөньяга декабрь китерде, декабрь алды. Бу ай әниең белән минем өчен кайчандыр иң шатлыклы ай иде. Хәзер ул иң кайгылы айга әверелде. Менә әниең белән синең альбомнарыңны, көндәлекләреңне актарып утырабыз. Кара әле, улым, синең күзләрең гел әниеңнеке төсле икән. Ничектер элек моңа игътибар ителмәгән. Кара чәчле, кара кашлы кешеләрдә мондый ачык зәңгәр күзләр сирәк була бит. Егет кеше өчен син артык чибәр, артык тыйнак идең. Сиңа, бәлки, кыз бала булып туарга кирәк булгандыр. Ул вакытта, бәлки, гомерең болай мәгънәсез рәвештә өзелмәс иде.

Их, улым, уйларымның мондый көтелмәгән якларга кереп китүенә миңа рәнҗемә, яме. Болар күңелнең һаман сине югалту белән килешергә теләмичә чаң кагуы, карышуы. Ә бит син безнең иң зур өметебез, иң олы шатлыгыбыз идең.

Син туган көнне мин бүгенгедәй хәтерлим әле. Декабрьнең аяз, кояшлы көне иде. Гадәттәгечә, мин хезмәттә идем. Үзенең кем һәм кайдан икәнлеген әйтми генә бер хатын-кыз шалтыратты.

— Алла! Майор Шәйхиевме бу?

— Нәкъ үзе.

— Сөенчегә нәрсә бирәсез?

— Туктагыз әле, сез кем, нинди сөенче?

— Минем кем икәнлегем артык әһәмиятле түгел, сөенчегә нәрсә бирәсез, дим.

— Сөенчесе нәрсәдер бит. Бүләге шуңа карап булыр инде.

— Улыгыз бар, иптәш Шәйхиев.

— О-о, улым! — Мин трубканы куярга да онытып:— Улым бар минем, улым! — дип кычкырдым. Минем тавышка батальон командиры подполковник Андреев килеп керде. Ул чакта мин батальон командирының сәясәт буенча урынбасары идем.

— Нәрсә булды, иптәш майор, нигә кычкырасыз? — диде ул.

— Улым бар, иптәш подполковник!

— Котлыйм, дускай, котлыйм! — Ул минем кулны кысты.— Ә әнисе сау-сәламәтме, әйбәт котылганмы?

— Ах, ансын сорарга да онытканмын.— Менә бит ул... Ярый әле трубканы куярга өлгермәгән идем, миңа шалтыраткан шәфкать туташы да сабырлардан булып чыкты, күрәсең, трубканы куймаган иде. Минем:

— Әнисенең сәламәтлеге ничек, сеңлем? — дип соравыма:

— Әйбәт, иптәш ата кеше. Әнкәсе дә, улыгыз да бик яхшы хис итәләр үзләрен,— диде баягы шәфкатьле тавыш.

— Болай булгач, сөенче бүләге зурдан булыр, уйлый торыгыз. Телисез икән — күктән йолдыз алып төшеп бирә алам.

— Ансын ук теләмим, ләкин бер үтенечем бар сезгә.

— Бүген барлык үтенечләр үтәлергә тиешле көн.

— Сезнең батальонда минем бер танышым хезмәт итә, иптәш майор.— Ул танышының фамилиясен атады.— Шуңа ике-өч көнлек увольнение юллап бирә алсагыз, сездән иң зур бүләк шул булыр иде.

Ах, шайтан кызый, сорый белә бүләкне! Аның танышын яхшы беләм мин: өченче ротаның иң ялкау, иң булдыксыз бер солдаты. Рота командирлары үтенеп сорагач, аның белән берничә мәртәбә үзем сөйләшеп караган идем. Димәк, ягымлы тавышлы шәфкать туташы шул егетне ярата. Менә бит ул дөнья. Безнең теңкәне корыткан хөрәсән ялкавы — кемнеңдер иң якын кешесе. Ләкин, ничек кенә булмасын, биргән вәгъдәне үтәмичә ярамый. Шәфкать туташына сөенче бүләгемне, һичшиксез, бирәчәгемне әйтеп трубканы куйдым.

Ул көнне минем шатлыгымның иге-чиге юк иде. Ни сорасалар, шуны үтәргә әзер идем. Җитмәсә, эчкә сыймас шатлыгымны тагын да зурай-

тып, дус офицерлар котларга тотындылар: «Илгә тагын бер солдат арттыруың белән!» — диде берсе.

— Булачак генералның бәхетле атасына сәлам! — дип күрешге икенчесе.

— Безнең сөекле замполитыбызның фамилиясен дәвам иттерүчегә дан! — диде өченчесе.

Котлаулардан башым әйләнеп бетте. Ялгыз гына калып бәхетемнең зурлыгына төшенәсем, шатлыгымны җаныма салып үлчисем килде. Командир минем хәлемне аңлады, ул көнне миңа ял бирде. Мин сезнең янга — бала табу йортына ашыктым. Ләкин миңа шундый зур сөенеч китергән әниең, әниеңнең авыр газапларын җиңеләйтешкән мәрхәмәтле шәфкать туташлары янына буш кул белән барырга ярамый, чәчәкләр кирәк иде. Аларны каян табарга? Безнең хәрби шәһәрчектә чәчәк үстерүче теплицалар юк. Иң якын шәһәр — Чиләбе. Ул да бездән 50—55 чакрым ераклыкта. Нишләргә?

Кая барырга белми торганда штабтан дивизия командиры генерал Башмаков килеп чыкты. Аның белән партия җыелышларында гел бергә утырабыз. Ул мине якыннан белә иде.

— Майор Шәйхиев, — диде ул. — Нәрсә, әллә берәр чишеп булмастай проблема бармы?

— Так точно, иптәш генерал.

— Әйтеп карагыз, бәлки, бергәләп чишәрбез.

Мин эшнең нәрсәдә икәнен аңлатып бирдем.

— О-о, — диде генерал. — Ватанга солдат тапкан ананы котларга чәчәк таба алмасак, без кем булабыз?! Хәзер үк минем машинаны алыгыз да Чиләбегә сыпыртыгыз. — Генерал шоферын чакыртып китерде.

— Бүген сез майор Шәйхиев карамагында, — диде ул шоферына, — кая һәм нинди тизлек белән барырга теләсә дә буйсыныгыз.

Мин, генералга рәхмәт әйтеп, машинага кереп утырдым. «Волга», сыртына каеш камчы төшкән чабышкыдай, кинәт алга ыргылды. Күңелемдәге шатлык, җыр булып, тышка ургылды.

Ал да итәрбез әле,
Гөл дә итәрбез әле;
Киләчәктә совет илен
Чәчәк итәрбез әле.

Дөресен әйтергә кирәк, җырлау белән мактана алмыйм. Барлык белгән җырларым кайчандыр мәктәптә укыганда пионервожатый апа өйрәткән Ленин бабай һәм совет власте турындагы җырлар гына иде. Әмма миңа җырның үзеннән бигрәк, хисләремне тышка чыгару кирәк иде.

Алга дибез, алга дибез,
Алга таба барабыз;
Алга барырга кушкан бит
Безгә Ленин бабабыз.

Минем җырлап баруымны күргәч, шофер, бераз елмаеп:

— Сез татармыни, иптәш майор? — диде.

— Әйе.

— Мин дә татар. Башкортстан якларыннан.

— Әйбәт, әйбәт, дидем мин — Ә сез җырлый беләсезме?

— Беләм дә...

— Ниндирәк җырлар җырлый хәзер яшьләр?

— Төрлесен инде, иптәш майор.

— Берәр җыр җырла әле.

— Булмый, иптәш майор. Кешеләр алдында җырлый алмыйм мин.

— Ярый алайса, көчләмим.

Мин үз уйларыма чумдым. Йөрәгем: малай, малай! — дип типте. Үзеңне малай кешенең атасы итеп тою нинди рәхәт! Әгәр Халисәм ул тапмаса, командир бер букет чәчәк өчен илле чакрым арага үзенең машинасын кудырыр идеме? Хезмәттәш офицерларны гына кара: һәрберсе үзләре малай тапкандай сөенә. Ничек котларга белмиләр. Берсе хәтта: «Бездә өр-яңа диярлек бала бишеге бар, алып чык, әллә каян бишек эзләп йөрмә»,— диде. Рәхмәт аңа, әмма ничек инде өр-яңа малайны кемнеңдер иске бишегенә саласың?

Безнең малай ул дөньяда иң шәп малай булачак. Дөрес, мин үзем кызымны да бик яратам. Моннан сигез ел элек әнкәсе кызыбыз Розаны алып кайткач, сөенечтән очынып йөрүләрем онытылырлык кына түгел әле. Төннәрен уянмыйча озаграк йокласа, бу исән микән дип, шыпырт кына аның караваты янына барып караулар, тигез сулыш алып йоклавын күргәч җанга йөгергән рәхәтлек берни белән чагыштырырлык түгел. Ә менә хәзер инде малайлы да булдык. Малай ул шатлык кына түгел, бик зур горурлык та. Малае юк атага кешеләр, ничектер, кимсетебрәк караучан. Хәрбиләр арасында бу нәрсә аеруча нык сизелә. Монда бөтен нәрсә ватан язмышы белән үлчәнә. Ә ватанның язмышы малайлар, ягъни булачак солдатлар кулында.

Ул көнне без Чиләбе урамнарын кырык кат урасак урадык, әмма чәчәксез кайтмадык...

Берничә көннән Халисәм бала табу йортыннан чыкты. Бүреккә сыярлык кечкенә улымны кулларыма алып, әрле-бирле йөрендем. Куанычымнан йөрәгем дөп-дөп типте. Шушы кадерле җан иясен бар көчемә күкрәгемә кысасым килде. Халисә минем уйларымны сизгәндәй:

— Син саграк маташ, йә төшереп җибәрерсең, булмаса китер әле үземә,— дип, баланы алырга үрелде.

— Юк,— дидем,— мин моны хәзер беркемгә дә бирмим инде. Бу бит солдат. Әйеме, улым. Менә син ай үсәсен көн үсеп, әтиең кебек командир булырсың, шулаймы? Әйе, әйе, эге-эге диген, улым. Кычкырып әйт, бөтен дөнья ишетсен. Боларның гаиләсендә бер солдат арткан икән, дип дуслар сөенсен, дошман көенсен. Нинди дошман дисеңме, улым? Дошманнар күп инде алар. Безне бит төрле яктан империалистлар чолгап алган. Империализм ул — җиде башлы аждаһа, улым. Аждаһаның бер башын киссәң, ул баш урынына тагын ике баш үсеп чыга. Ул туктаусыз корбаннар сорый. Син, улым, әкият батырыдай, шушы аждаһаның башын кисәрсең. Нәселен корытырга кирәк аның.

— Әллә нинди аждаһаларың белән яңа туган баланың башын катырма әле,— дип, Халисә баланы минем кулдан алды.

— Әни, мин дә тотып карыйм әле шуны,— дип әнкәсе янына Роза йөгереп килде.

— Өлгерерсең әле, кызым,— диде Халисә,— хәзергә аның мәм-мәм ашыйсы килгән. Әйеме, улым?

Халисә малайны имезә башлады. Үзе, бәхетле елмаеп, миңа карады:

— Кара әле, Фәрит, нинди исем кушабыз соң улыбызга? — диде ул.

— Ниндиме? Минемчә, берәр интернациональ исем.

— Әстәгъфирулла! — диде Халисә,— ике татардан туган малай ни өчен әле ниндидер интернациональ исем йөртергә тиеш?

Мин ул чакта — совет иле, совет армиясе, совет халкы дигән төшенчәләрне миемә шыплап тутырган кызыл командир — үземнекен тәкърарларга тотындым.

— Безнең улыбыз татар авылында яшәмәячәк. Ул хәрби командир булачак. Әгәр без аңа татар исеме кушсак, мондагы балалар аны «гололобый татарчонок» дип ирештерәчәкләр. Гомумән, татар теле, татар исеме нәрсәгә кирәк ул? Менә мин үземнән генә алам. Татар авылында татар мәктәбе бетергән килеш хәрби училищега килеп кердем. Русчага күчү бик рәхәт булды дисеңме миңа? Белгән әйбереңне дә сөйләп бирә алмый интегәсең. Ялгыш ычкынган сүзеңнән көләргә торалар. Кыскасы

шул, әнкәсе, балага татар исеме кушмыйбыз. Бу татар авылы түгел. Хәрбиләр шәһәрчеге. Монда кешенең милләте юк.

— Милләтсез кеше буламыни?— диде Халисә.

— Милләт дип, үзеннән үлеп бара торган гореф-гадәтләренә ябышып яту искелек калдыгы гына. Без коммунизмда яшисе кешеләр. Коммунизмда кешеләр бары тик Ленин сөйләшкән телдә генә сөйләшәчәкләр.

Әйе, бүгенге көн күзлегеннән караганда бу купләргә бик көлке тоеладыр. Әмма ул чакта мин нәкъ шулай уйлый идем...

— Татар телендә сөйләшеп, шушы дәрәҗәгә ирешкәнсең бит әле,— диде Халисә.

— Юк, әнкәсе, хәрби училищега чыгып киткәндә мин үз-үземә сүз бирдем: моннан соң бер генә авыз сүз дә татарча сөйләшмәскә! Татарлыкны онытырга.

— Минем белән нигә татарча сөйләшәсең соң?

— Синең кәефеңне җибәрәсем килмәгәнгә. Аннары, мин бит синең белән өйдә сөйләшәм. Өй өчен, кухня өчен татар теле дә ярый. Ә тормыш итәргә рус теле кирәк.

— Бер авызга биш тел дә сыя!

— Сыюын сыя, тик кирәксез нәрсә белән аны тыгызлау артык. Балага рус исеме кушабыз, рус сүзләре белән теле ачылсын. Русча уйласын. Татарлыгын онытсын. Ул үзенең баласына тагын рус исеме кушар. Шуннан аның татарлыгы өч буында онытылыр.

— Кеше үзенең тамырын, үткәннәрен онытмаска тиеш. Ә кешене узганнары белән тел бәйли, шуны истән чыгарма, иптәш майор.

— Безнең тамырлар унҗиденче елгы революция вакытында ук өзелгән инде. Кечкенә милләтләр никадәр тизрәк бетсә, үзләре өчен шуның кадәр яхшырак. Алар бөек рус культурасыннан тизрәк авыз итә башлаячаклар.

Халисәм минем белән кызып бәхәсләшергә тотынды.

— Хәтта руслар үзләре дә бу кадәр үзләрен якламыйдыр,— диде ул.— Армия кешенең тышкы кабыгын гына түгел, эчен, уй-фикерләрен дә бу кадәр үк үзгәртәдер дип уйламый идем.

— Һәр нәрсәнең формасы белән эчтәлеге тәңгәл килергә тиеш,— дидем мин.— Өстемдә совет армиясе офицеры формасы йөртеп, башкача уйласам, мин кем булыр идем? Армия — Ватанның калканы. Калкан, гадәттә иң каты корычтан эшләнә. Ә офицер — армиягә калкан коя торган корыч ул. Русның бер олы шагыйре, әгәр совет кешеләреннән кадак ясасаң — иң каты кадак булыр иде, дигән.

— Совет кешеләреннән шул кадак белән шөреп кенә ясап бетерделәр инде,— диде Халисә. Мин ул вакытта бу сүзләргә әһәмият бирмәдем, әлеге сүзләрдә никадәр мәгънә барлыгын аңлар өчен миңа янадан егерме елдан артык яшәргә, сине югалту ачысын татырга, йөрәкне канлы яшь белән юарга кирәк булган икән...

Ул чагында мин тәки үземнекен иттем, сиңа Олег дип исем куштырдым. Дөрес, әниең:

— Ичмасам Алик дип кушыйк, татарчарак булыр дип караган иде, мин:

— Олег Кошевойлар кебек батыр булып үсәчәк ул минем улым. Кешене үзенең исеме дә тәрбияли,— дип, кырт кистем.

* * *

Менә, улым, хезмәт итәргә баргач синең безгә язган беренче хатың. Хатларың, кәнвәлекләреңне әниең һәркөн кабат-кабат укый. Укыган саен алар өстенә күз яшьләре тама. Хатларың яңгыр астында калган кәгазь кебек чуарланып бетте инде.

— Кадерлеләрем — әтием, әнием! — дип язасың син. — Ниһаять, мин бүген хезмәткә килеп урнаштым. Кайчан гына әле Чиләбедәге югары танк училищесы курсанты идем. Хәтерегездә микән, мине укырга озатканда искиткеч шәп табын әзерләгән идегез. Мәҗлескә бик күп офицерлар килде. Һәммәсе матур-матур тостлар әйтте. Шунда берсе әллә шаярып, әллә чынлап болай диде:

— Дусларым, минем сезгә бер соравым бар. Әйтегез әле, кеше җиргә нәрсәгә туа?

— Яшәр өчен.

— Кеше икәнлеген раслар өчен.

— Ә кеше икәнлегеңне ничек расларга була?

— Бөек ачышлар ясап, гасырлар буе онытылмаслык акыллы эшләр эшләп.

Бу бәхәс байтак дәвам итте, ләкин күбесе шушы фикерләрдән ерак китмәде. Шунда бер яшь капитан сикереп торды да:

— Офицер иптәшләр, — диде. — Минем уемча, кеше дөньяга армиядә хезмәт итәр өчен туа. — Аның сүзеннән кайберәүләр көлеште, кайберәүләр бәхәскә керде. Ә ул үзенең хаклы икәнен исбатларга тырышып, болай дәвам итте: — Ә нигә? Архимед әйткән бит: бирегез миңа шундый бер рычаг, шуның белән мин Җир шарының астын-өскә әйләндерермен, дигән. Әйдәгез әле уйлап карыйк: Җир шарының астын өскә әйләндерерлек рычаг нәрсә? Әлбәттә, армия. Шулай булгач, армиядә хезмәт итү безнең барыбыз өчен дә иң зур бәхет түгелмени?

— Браво, браво! Менә әйтте ичмасам. Капитан Румянцевка шушы сүзләре өчен генә дә бүгеннән майор дәрәҗәсе бирергә кирәк.

«Шәп әйттең», — дип капитанның кулын кыстылар, тик бер миңа таныш булмаган майор гына:

— Шәбен шәп әйттең, ләкин бик оста булгач, син шуны да әйт: дөньяның астын өскә әйләндерү нигә кирәк? Җир без рычаг тыгып әйләндермәсәк тә гел әйләнеп тора ләбаса.

— Аңламаганга салышмагыз, иптәш майор, — диде капитан Румянцев. — Җир, әлбәттә, әйләнә. Ләкин без аны үзебезнең якка әйләндерергә тиешбез. Йөзе белән коммунизмга таба борылсын ул.

Мәҗлес шактый кызган иде, капитанның сүзләрен хуплап, янә бер тост күтәрелде. Мин, бу капитанның сүзләренә ничек җавап бирерсең икән дип, сиңа карадым, әти. Безнең күзләр очрашты. Син үзеңә сүз алыр вакыт җиткәнен аңлап, торып бастың.

— Дуслар, хезмәттәшләр, офицерлар! Монда әйбәт, акыллы фикерләр күп әйтелде, аларны кабатлап тормыйм. Улымны югары командалык училищесына озатканда мин бары тик шуны гына әйтәм: улым, син кадровый офицер гаиләсендә тудың, синең бөтен балачагың хәрби шәһәрчектә үтте. Хәрби хезмәтнең, Ватанны саклауның иң изге эш икәнен беләсең. Син бөтен гомереңне шушы изге эшкә багышлаячаксың. Бу, әлбәттә, бик күркәм сыйфат. Миннән теләк шул: нинди генә авыр хәлдә калсаң да ике нәрсәгә хыянәт итмә: аларның берсе — Ватан, икенчесе — Намус.

Синең сүзләргә гөрләтеп кул чаптылар. Мәҗлес таралгач та без синең белән Ватанга хезмәт итү турындагы сүзне дәвам иттек. Бәлки әле төне буе сөйләшеп чыгар идек, әни бүлмәгә кереп:

— Җитәр инде сезгә. Баланы алҗытып бетерәсең тәмам. Бу сүзләреңне политзанятиедә солдатларыңа сөйләргә калдыр, — дип, безне вакытында туктата белде.

Мин әниемнең сагышлы, моңсу күзләренә карадым:

— Нәрсә, әни, минем училищега китүемә риза түгелме әллә син? — дидем.

— Юк, юк, — диде әни, — шикләнергә урын калдырмыйча, — риза.

Әниемне юатасым, иңнәреннән кочып, моңарчы әйтелмәгән матур сүзләр әйтәсем, аннан да бигрәк аның кочагына сыенып, үземне тагын

бер кат бала итеп тоясым килде. Әмма, әтием, синнән кыенсындым, бала-чагалыкта, сентиментальлектә гаепләрсең дип курыктым. Бары тик иртәгесен мине озатырга чыккач кына әнинең әллә нинди йомшаклык һәм җылылык бөркеп торган кочагына кереп бер мизгелгә эредем. Аның кулларыннан кучкән рәхәтлеккә оеп шактый тордым.

Әйе, искә төшерсәң, истәлекләр күп инде. Училищеда дүрт ел үтеп китте. Менә хәзер син әйткән Ватанга хезмәт итү башланды.

Хәрби сер булса да, әти, синнән яшермим, безне Кавказ арты Хәрби округына 7 нче Армия карамагына җибәрделәр. Чиләбе югары танк училищесын бетергән өч лейтенант белән без башта Ереванга килеп төштек. Анда берничә көн торганнан соң безне Кироваканга җибәрделәр. Монда бик үк тулы булмаган дивизиянең танк ротасына училищеда укыган дустым Владимир белән бергә туры килдек. Мине өченче, Владимирны беренче взводның командиры итеп куйдылар. Тормыш шартлары белән мактанырлык түгел. Рота командиры безгә: «Әлегә тулай торакта урыннар юк, әнә, уку бүлмәсенә урнашып торыгыз, җай чыккач тулай торакка кертербез»,— дип китеп барды. Владимир белән икебезгә бер бүлмә. Анда бер өстәл, ике урындык һәм ике карават. Стенада төрле плакатлар, уку өчен кирәкле стендлар. Бәдрәф ише нәрсәләр турында әйтеп тормыйм инде, ансына түзәр идең, юыныр өчен суы юклыгы ачуны китерә. Ашау-эчү такы-токы. Миңа бу Чиләбедәге хәрби училищедан соң, нindидер бер ташландык, руслар әйтмешли, «алла тарафыннан онытылган» бер җир булып тоела. Тагын шунсы, әти, монда Карабахның кайнар җилләре үзен бик сиздерә. Без килеп төшкән көнне нәкъ менә мин билгеләнгән взводтан бер әзербайҗан егете качкан иде. Биредәге командирлар әлеге хәлгә гади бер әйбер итеп кенә карадылар. Күрәсең, мондый хәл беренче генә түгелдер. Минем әле хәтеремдә, бәләкәй чакта, сезнең белән бергә хәрби шәһәрчектә яшәгәндә сезнең бер солдатыгыз автомат алып качкан иде. Сез бөтен ротаны тревога белән күтәреп, аны эзләдегез. Син хәтта ул көнне кунарга кайтмадың. Икенче көнне генә бик арып, бик ярсып кайтып кердең.

— Таптыгызмы?— дип сорады әни.

— Таптык,— дидең син.

— Хәзер нишләтәсез инде аны?

— Аны хәзер берни эшләтеп тә булмый инде, безнең камап алуыбызны күргәч, үзен-үзе атып үтерде. Тинтәк!

Син озак кына әрле-бирле йөрендең һәм болай дип дәвам иттең:

— Атылып үлүе генә җитмәгән, совет солдатына хас булмаганча сүзләр язып калдырган. Имеш, армия кешенең кешелеген бетерә, имеш, монда тыңлаучан, буйсынучан робот булып йөргәнче, үлүең яхшырак. Политик аңлату эшләре җитешми әле бездә. Армиянең, киресенчә, кешене кеше итү мәктәбе икәнен һәр солдатка төшендерү җитми. Монда, әлбәттә, гаепнең юан башы миндә. Партиянең акыллы карарларын һәр солдатның йөрәгенә ярып сала алмыйм, димәк.

Син шулай үзеңне озак битәрләдең, әти. Мин боларны нишләп искә төшерәм соң әле? Бүген, нишләптер, мин гел сезнең турыда уйлыйм. Әллә сагынам инде. Хәрби кеше үзенең күңелендәге андый хисләрне үтерергә тиеш икәнен аңлыйм, әти, ләкин сагынам. Әлегә ул хисләрне җиңә алмыйм. Ярый әле магнитофонны алганмын, андагы язмаларны тыңлыйм. Әнинең туган көнен уздырган чакта син, әти, үзеңнең бала чагыңны сөйләгән идең. Мин, сиңа сиздерми генә, син сөйләгәннәрне магнитофонга яздырып бардым. Хәер, бу турыда тәфсилләбрәк языйм әле. Чөнки бу — минем тормышымда иң бәхетле көннәрнең берсе иде. Училищены тәмамлап, безгә дипломнар тапшырасы көнне, яңа алган яшел «Жигули»егыз белән сез килеп төштегез.

— Запастагы полковникка кабыгыннан яңа гына чыккан лейтенанттан сәлам,— дип каршыладым сезне.

— Саумы, улым,— дип, икәүләп кочып алдыгыз.— Дипломнар тапшыру булдымыни инде, улым?

— Юк әле.

Озакламый безне Чиләбе шәһәренең үзәк мәйданына тезделәр. Һәммәбезгә тантаналы төстә дипломнар тапшырылды. Бу 1989 елның 23 июле иде. Дипломнар тапшыру тантанасы беткәч, без Чибәркүлгә киттек. Анда синең элек бергә хезмәт иткән дусларың яши иде. Аларда ике көн кунак булып, өйгә соңгы вакытта яшәгән җиребез — Пермьгә кайтырга чыктык. Первоуральск шәһәренә җиткәч, бер кибеткә туктадык. Әни кибеткә кереп китүгә син:

— Ә беләсеңме бүген нинди көн? — дип сорадың.

— Юк,— дидем,— нинди көн соң?

— Бүген әниеңнең туган көне. Үзенә сиздерми генә берәр сюрприз ясарга иде. Беләсеңме нәрсә, мин хәзер базарга сыптырам. Әниең сораса, заправкага китте диярсең.

Син бераздан урап килгәнче әни белән кибетләрдә йөрдек. Юлда бик матур урман аланына җиткәч, син:

— Карагыз әле, нинди шәп алан, әллә бераз туктап алабызмы? — дидең.

Туктадык. Ашыйсыбыз бик килгән иде. Әни машинадан ашъяулык алып, яшел чирәмгә җәйде. Син әнигә:

— Син, әнкәсе, ә-әнә теге тирәләрне урап кил әле, чишмә-мазар юкмы икән,— дидең. Безгә аны читкәрәк җибәреп тору кирәк иде. Әни китүгә табын әзерләргә тотындык. Көчкә күтәрерлек карбыз алгансың икән — табын уртасына аны куйдык. Карбыз янына шампан шәрабы килеп кунаклады. Бик шәп ысланган колбаса һәм тагын әлләниләр ашъяулык өстенә тезелде. Әни килгәч:

— О-о, сез мине читкә куып җибәреп бик каты сыйланмакчы идегезмени әле? — диде.— Бу кадәр сыйны кайдан таптыгыз?

— Әнә теге кошлар китереп китте,— дидең син. Һәм, кайсыбыз башлый дигәндәй, миңа карап куйдың. Мин шунда, синнән алдан үзем әниемне котлыйм дип:

— Әнием! — дидем.— Бүген әтиебез белән минем иң бәхетле көнебез. Бүген синең туган көнең, әни! Котлыйбыз үзеңне. Син безнең иң зур бәхетебез.

Без әнине икәүләп кочаклап үптек.

Шампан ачылды, карбыз туралды. Бик озак, бик күңелле утырдык. Шунда мин, әти, сиңа: «Әти, мин синең бала чагың турында, ничек үсүең, ничек хәрби кеше булып китүең, әни белән ничек танышуың турында ишетәсем килә,— дидем.— Әни миңа күп нәрсәләр сөйләсә дә синең хакта сораша башласам: «Үзе турында үзе сөйләр әле»,— дип, бу үтенечемне гел читкә кагып килде.

Син шунда яшел чирәмгә чалкан ятып, ике кулыңны баш астына салдың. Изүләрең чишеп җибәрдең. Синең шулай таралып, үзеңнең хәрби кеше икәнеңне онытып, балаларча мавыгып сөйләвеңә сокланып карап тордым».

* * *

— Мин, улым, ун балалы гаиләдә үстем. Сигез малай һәм ике кыз. Еллары нинди иде тагын! Ач яңаклы, яшьле күзле, сәләмә киемле елларга туры килде минем балачак. Иртән торуга гаиләдәге һәр кешене бары тик бер уй борчый: бүген нәрсә ашарга? Әти белән әни безнең ипи сорап тилмергән күзләребезне күрмәс өчен читкә борылалар. Хәер, алар өйдә рәтләп тормыйлар да. Без уянып ут алуга, бригадир килеп, аларны эшкә куалый башлый. Әни, бичара, бригадир нинди эшкә кушса — шунда чаба. Аның ашлык сугу

машинасына көлтә биреп торуларын мәңге онытасым юк. Андагы тузан, андагы авырлык! Хатын-кызларның күбесе, бик күбесе бу эшкә түзми, ә безнең әни түзә. Тузанга тончыкмас өчен ул авыз-борынын яулык белән бәйләп куя. Сугу машинасының киштәсенә китереп куелган авыр көлтәләрне үзенә таба шудырып китерә дә, бавын урак белән кисеп, машина барабанының олы авызына тыгып җибәрә. Сугу машинасының тимер тешләре минут эчендә көлтәне чәйнәп чыгара. Тимер тешле олы авызга тагын икенче көлтә кереп китә. Иртә таңнан кичке караңгыга чаклы шулай. Әнинең керфекләрен, яулык астыннан бөселеп чыккан чәчләрен тузан сара. Кайвакыт ул, күзенә кылчык-фәлән кермәсен дип, кырыйлары резина белән кысаланган махсус күзлек кия. Ләкин колхозның күзлек алырлык та акчасы юк. Күзлегеңне ватсаң — үзеңнән түләтәләр. Күзлеге ватылудан куркыпмы, әни аны күпвакыт кими. Ә ашлык сугу элек ел әйләнә дәвам итә иде. Без әнигә: «Нигә бу кадәр авыр эшкә йөрисең, бүтән җиңелрәк эшкә күч»,— дисәк, ул: «Моның, балалар, үзенә күрә хикмәте бар,— ди иде.— Күрәсез бит, әтиегез кешеләргә көне-төне балта чаба, мич чыгара, тегү тегә. Мин авыр эшкә йөрмәсәм аны да колхоз үзенә суырып алачак. Тамак туйдыручыбыз калмаячак...»

Әйе, безнең әтинең кулыннан килмәгән эш юк. Ул өйне нигез бүрәнәсеннән алып соңгы кадагына кадәр бер үзе эшли ала. Безнең авылда аның кулы тимәгән берәр өй бар микән? Юктыр, мөгаен. Кайсына мич чыгарган, кайсына тәрәзә капкачлары, рамнар ясаган. Кайсының өенең черек бүрәнәләрен алыштырган. Кемнәргәдер ихата әйләндерешкән, абзар-кура салышкан. Ә кыш җитсә авыл агайлары, үзләре иләгән тиреләрен күтәреп, әти янына киләләр. Әти җиделе лампа яктысында төне буе тун тегә.

Авыл агайлары, хәйләкәр елмаеп, алып кергән тиреләрен җәеп салалар.

— Карале, Миңнетдин абзый, тунның рәте китте бит. Миңа берәр тун әмәлләп бирә алмассыңмы?

— Ник әмәлләмәскә? Аллага шөкер, кул үзебезнеке.

— Ә тун янына берәр бүрек дисәм, ни әйтерсең?

— Ни әйтим: синнән әйтү — миннән үтәү! Бүрекле дә итәрбез үзеңне. Авылның шундый хөрмәтле кешесен бүрексез йөртеп булмас бит инде.

— Ә тун белән бүрек янына берәр пар бияләй дисәм?

— Әйтәсең икән — бияләен дә тегербез.

— Алайса, Миңнетдин абзый, шулай сөйләштек. Миңа шушы тиреләрдән тун белән бүрек өстенә бер пар бияләй тегеп бирерсең инде, яме.

— Ярар тегербез,— ди әти,— тик сиңа тагын ике бәрәнеңне суярга туры килер.

— Ничек ике бәрәнемне? Без бит шушы тиреләрдән дип сөйләштек.

— Юк, без шушы тиреләрдән димәдек. Әгәр инде шушы тиреләрдән бүрек, тун, бияләй тек дисең икән — алары инде биш яшьлек малаеңа булыр.

Икәүләп көлешеп алалар.

Аннары теге агай:

— Алайса, Миңнетдин абзый, болай гына итик: бер бүрек, бер тун, бер пар бияләй тек син болардан. Булган-булган малайның өсте бөтәйсен. Ә минем тунны ямаштырып җибәрсәң тагын өч ел чыдаячак әле. Дөресен генә әйткәндә, яңа тунны бик киясе дә килми. Яңа тун белән колхоз тиресен түгеп йөрү килешмәс иде.

Олыларның шулай юк-бар нәрсәдән кызык табып көлешеп утырулары, бер караганда гаҗәбрәк тоела иде. Хәзер уйлап карыйм да, алар үзләренең мәзәкләре белән борчулы уйларын ераккарак куарга тырышканнардыр, дигән нәтиҗәгә киләм.

Безнең әти, яше өлкән булу сәбәпле, сугышка бармаган. Ул яктан без, авылдагы күп кенә балалар белән чагыштырганда, бәхетле идек. Әти үзен сугышта ирләре үлеп калган толлар, ятимнәр алдында, ничектер,

бурычлы саный иде булса кирәк: андыйларның йомышын һичбер вакыт кире какмый иде. Билгеле инде, ул чакларда эшнең күбесе рәхмәткә эшләнә. Әгәр берәрсе әтине бәхилләтәсе килсә, ачы бал белән сыйлап җибәрә. Әти андый көннәрдә өйгә кәефләнеп кайта.

— Килер әле бер шундый заман: өстәл тулы ипи булыр,— дип сөйләп китә ул.

— Ул ипине теләсә кайчан кисеп ашарга ярармы соң, әти?—дип сорау яудырабыз.

— Ярар, ник ярамасын! Күпме теләсәгез, шуның кадәр ашарсыз.

— Теләгән кадәр ашасаң, бик тиз бетәр ул, әти.

— Бетсә, әниегез тагын салыр: эзләп-эзләп түгел, мич тутырып.

— Аның кадәр ипилек ашлыкны урлар өчен бик олы кесәләр кирәк булыр,— дип, энем Хәйдәр сүзгә кушыла.

— Ул чакта инде колхозда кесәләп урлау бетәчәк,— ди әти,— колхоз кешегә ипине өйдәге авыз санына карап бирәчәк.

— Әгәр кайбер кешеләрнең авазы ике булса, андыйларга ике өлеш бирерләрме?— ди икенче энем Госман. Без Госманның сүзеннән көлешеп алабыз. Күз алдына икешәр-өчәр авызлы кешеләр килә. Алар әллә ничә авыз белән берьюлы ашыйлар. Ул авызларга бөтен килеш ипиләр, бәрәңгеләр, самавыр кадәр кабаклар кереп китә. Ә Госман безне көлдерә алырлык сүз әйтә алуыннан канәгатьлек алып янә остара:

— Бер табышмак әйтимме үзегезгә?

— Әйт!

— Тик бушка түгел. Мичкә бәрәңге тәгәрәткәндә берне миңа артык бирсәгез генә әйтәм.

— Әйдә инде, әйт.

— Тыңлагыз алайса: «Үзе баралмый, үзе таралмый, үзе ашыга үзе ачыга».

— Бу табышмагың өчен артык бәрәңге бирү түгел, өлешсез калдырырга кирәк сине,— ди әти.— Кемнән ишеттең син моны?

— Урамдагы малайлардан.

— Бүтән кабатлыйсы булма, ишетсен колагың. Югыйсә бөтенебезне бәрәңге үсми торган җиргә җибәрерләр.

— Бәрәңге үсмәгән җирдә нәрсә ашап торалар, әти?

— Атаң башы!

Сүз һәрвакыт, нидән генә башласа да, ашауга кайтып кала. Әти безнең сораулардан котылыр өчен ишегалдына чыгып китә.

Ә иң күңелле көннәр — бәйрәм көннәре. Безнең әтине, синең кулың тәмле дип, сугымга йөртәләр. Шунда берәрсе суйган малның үпкә-бавырын, берәрсе эчәге яки тәпиен биреп җибәрә. Казанда гөбер-гөбер ит кайный. Ул кайчан пешеп чыгар икән дип, без авыздан сулар агызып, казан тирәсендә бөтереләбез.

Ит пешкәч, әти һәммәбезгә өлешләп бүлеп бирә. Яшенә, гаиләдә тоткан урынына карап, өлеш төрлечә була. Кечкенәрәкләр минеке бәләкәй дип шыңгырдый башласалар, әти кулындагы агач кашык комсызлanучының маңгаена төшәргә мөмкин.

Ашап туярга, чәчелгән борчаклардай, кайсыбыз кая чыгып сибеләбез. Урамдагы малайларга нәрсә ашавың белән мактанмасаң, ризык күңелгә төшеп җитми сыман. Өйдә тавыш басылуга, әти үзенең дога китапларын кулына ала. Китаплар безнең өйдә бер киштә. Барысы да диярлек калын һәм саргаешып беткәннәр. Әтинең иң кадерләп саклый торган китабы — Коръән. Аңа беребезгә дә тотынырга ярамаганын яхшы беләбез — кагылмыйбыз. Әти үзе дә Коръәнне кулына тотар алдыннан әйбәтләп юына, аннары бисмилласын әйтеп кенә ала. Коръән китабының һәр бите киң бушлык калдырып басылган. Әти әнә шул ачык урыннарга тормышта булган мөһим вакыйгаларны язып бара: кайсыбыз кайсы елны туган, кемне ничәнче елда армиягә алганнар, ул аннан кайчан кайткан, ничәнче числода сыер бозаулаган, кайсы елны бәрәңге уңган —

бөтенесе берәр-берәр җөмлә белән язып куелган. Без әтинең язуын укый алмыйбыз. Ул гарәп хәрефләре белән яза. Без аңа: «Син, әти, коръәнчә язасың»,— дибез. Ә кич белән, сәкегә тезелешеп йокларга яткач, әти безгә догалар өйрәтә. «Раббанә атыйнә фитдинья хәсәнәтен, вә фил ахирәти хәсәнәтән». Без аның артыннан кабатлыйбыз. Догалар укылып беткәч, берәребез әтигә сорау биреп куя: «Әти, кешеләрне алла яраткан дисең, ни өчен ул аларны ашамый торган итеп яратмаган? Ул шул хәтле кодрәтле булгач, ашамый торган итеп тә ярата алыр иде бит!» Әти соравыбызга җавап бирми. Йоклаганга салыша. Без аның йокламаганлыгын беләбез, әмма кабат сорау биреп йөдәтмибез. Үзебез хыял дөньясына чумабыз. Чынлап та, кешеләр ашамый яши алсалар, ничек шәп булыр иде. Дөньядагы бөтен кыенлык шул житмәүдән бит. Кешеләр ашамаса, колхозлар да налог салып интектермәс иде. Югыйсә сыерның сөтен, тавыгының йомыркасын, сарыгының йонын, бакчаның бәрәңгесен колхоз дигән убыр суырып бара. Калганын да үзебез ашый алмыйбыз: заем түләргә, кием-салым яңартырга, китап-дәфтәрләр алырга акча кирәк. Сөт-катыкны әни үзебездән ун чакрым ераклыктагы Октябрьски каласына илтеп сата. Кайвакыт чиләген күтәрешеп барырга безнең берәребезне ала. Без бик теләп барабыз, чөнки сөтеңне сата алсаң, берәр крәндил эләгүе мөмкин. Крендилне бик тиз ялт итеп куябыз, уртадагы тишеге генә кала.

Беркөнне шулай әни үзе белән мине алды. Иңенә көянтә-чиләк белән сөт асты, бер кулга кечкенә кәрзин белән күкәй, икенче кулына бер чиләк катык. Катык чиләгенең тоткасына аркылы таяк тыгып, таякның икенче башыннан мин күтәрештем. Авыл читеннән узучы юлга чыгып бастык. Машина көтәбез. Катык-сөт сатырга баручылар бездән башка да байтак. Ул чакларда шәһәр яки район тирәсендә шофер булып эшләүчеләр үзләренең йөк машиналары белән таң тишегеннән сөтчеләрне калага илтәләр иде. Йөк машинасының әрҗәсе шыгрым тула. Әгәр берьюлы гына сыеп бетмәсәләр, ике урыйлар иде. Менә без чыгып баскач, озак көттерми бер машина килеп туктады. Шоферы яңарак армиядән кайткан егет иде, ахры, өстендә хәрби кием. Машинага меңгергәнче үк хатыннардан акча җыя башлады ул. Менә кулын сузган шофер безнең әни янына килеп җитте. Әнинең аңа түләрлек акчасы юк иде.

— Улым,— диде әни шоферга,— яңадан бер барганда бүгенге өчен дә түләрмен, зинһар, утырт инде.

— Акчаң булгач утырырсың,— диде шофер һәм безне калдырып китеп бармакчы булды.

— Китмисең!— диде әни бик гаярь тавыш белән.— Менә моны күрәсеңме?— Әни күкрәгендәге Алтын йолдызына күрсәтте. Аны әнигә Герой ана булган өчен күптән түгел генә биргәннәр иде.

— Күрәм, мин сукыр түгел,— диде шофер.

— Күрүең күрсәң дә аңлап бетермисең бугай,— диде әни.— Бу, апаем, Герой аналарга гына бирелә торган Алтын йолдыз. Мондый йолдызлы кешеләр теләсә нинди машинага бушлай утырып йөрергә хаклы. Вәт шул!

Әни чиләкләрен машинадагы хатыннарга биреп менеп утырмакчы булган иде, ләкин шофер әллә нинди әшәке сүзләр белән әнигә ташланды. Тарткалаша торгач, әнинең бер чиләк сөте түгелеп китте. Тавыш купты. Кемдер әнине, кемдер шоферны яклады. Хәер, шоферны яклаучылар күбрәк иде бугай, чөнки һәркемнең тизрәк кузгалып китәсе килә. Бу тартыш нәрсә белән бетәр иде, билгесез, ләкин шулвакыт машина әрҗәсендәге нициндер бер хәрби кешенең: «Отставить!» — дигән тавышы ишетелде. Күрәсең, районнан утырып килгән булгандыр. Ул ярыйсы ук зур чиндагы офицер иде бугай. Армия тәртипләрен онытып өлгермәгән шофер әфисәрнең боеручан тавышыннан бер мәлгә югалып калды.

— Герой ана алдында хәзер үк гафу үтенегез һәм аны машинага утыртырга булышыгыз. Йә, нәрсә карап торасыз?— Әфисәр кобурасын капшап куйды.— Тагын бер тапкыр кабатлаганны көтәсезме?

Шофер әни янына килеп нәрсәдер мыгырданды. Гафу үтенүе булгандыр инде, ләкин безгә аның гафу үтенүеннән бигрәк, машинасына утыртуы кирәк иде.

Без утырып киттек. Юл буе мин бу әфисәрдән күземне ала алмадым. Аның куе яшел кителе, матур кокардалы фуражкасы, билендәге һәм бер як иңе аша төшкән сары каешы һәммәсе шулкадәр килешле иде, ирексездән: «Их, менә шушындый әфисәр булсаң иде»,— дип уйлап бардым.

Сөт сатып кайткач, күңелемдәге уйларымны дустым Наилгә чиштем. Наил минем яшьтәш. Аның әтисе сугышта, әнисе сугыш вакытында колхоз эшендә үпкәсенә салкын тидереп үлгән. Наилләр алты бала, өйләнгән абыйлары белән бергә яшиләр. Мин һәр шатлыгымны, һәр кайгымны иң беренче аңа сөйлим.

— Ну малай, бүген бер әфисәр күрдем,— дидем мин.— Менә ичмасам кеше! — һәм Наилгә сөт сатарга баргандагы вакыйганы сөйләдем.— Әйдә, малай, үскәч без дә әфисәрлеккә укырга китәбез.

— Син китәрсең,— диде Наил көрсенеп.— Мин быел мәктәпкә бармыйм шул. Колхозга эшкә йөри башлыйм. Колхозга эшкә йөргән кешеләргә өч йөз грамм ипи бирәләр.

— Соң, без бит әле дүрт класс кына бетердек. Син колхозда ни эшләрсең соң?

— Кырга тирес чыгарырмын. Мин үгез җигә беләм инде. Яз көннәрендә тырмага йөрермен. Җәй көне печәнгә. И-и, колхоз эшенең нәрсәсе бар аның.

Мин Наилне чын күңелемнән кызганып куйдым. Туйганчы ашамасак та, безнең хет елаганда баштан сыйпарга әниебез, тыңламаганда каешлап алырга әтиебез бар. Беркөнне Наилнең энесе Зәйтүн минем энекәштән болай дип сорый икән:

— Хәйдәр, сине әтиең кыйныймы?

— Сүзен тыңламасаң булгалый инде. Матчада сыек тал чыбыгы тора безнең.

— Әтиең кыйнагач, берәр миңа әйтерсең әле, яме?

— Нигә?

— Әти суккан җир нинди була икән, шуны күрәсе килә...

Ә бераздан, бакча утамаган өчен үзенә әтидән тиешле «өлешен» алгач, Хәйдәр урамга чыгып йөгергән.

— Менә карагыз, менә карагыз, болар әти чыбыклаган урыннар.

Малайлар Хәйдәрнең ыштанын салдырып «әти кулы»ның эзләрен карарга тотынганнар. Безнең урамда әтиле малайлар юк диярлек. Ул көнне Хәйдәр, орден алган батырдай, «әти эзләре» белән мактанып йөрде.

Яшерен хыялымны Наилгә сөйләгәннән соң миңа озакламый «Әфисәр» дигән кушамат тактылар. Ләкин мин бу кушаматка һич хурланмадым, киресенчә, горурландым гына. Дөресен әйткәндә, безнең авылда кушаматсыз кеше юк. Мулла абзыйларны, гел балда-майда йөзгәнгәдер инде, «Үрдәк» диләр. Безнең әти ни өчендер «Үрәтник». Бер күршебез — «Җен», икенчесе — «Черки», кемдер — «Чаташ», кемдер — «Хуҗа Насретдин».

Мин шулай «Әфисәр» булып алгач, малайлар бергә җыелган чагында әфисәрләр тормышы хакында сүз ешаеп китте.

— Әфисәрләр үгез җигеп тырмага йөрми инде,— ди беребез.

— Һы,— дип эләктереп ала икенчебез,— алар кулларына наган тотып команда биреп кенә утыра. Ә син үгез дисең.

— Әфисәрләргә паспорт бирәләр микән? — ди өченчебез.

— Әйттең сүз, аларга нәрсәгә паспорт?

— Нәрсәгә булсын, колхоздан качарга?

— Әфисәрләр армиядә була, ә армиядә колхоз юк.

— Колхозсыз илләр бар микән дөньяда?

— И аңгыра! Колхоз булмаса, бөтен кеше авылдан качып бетәчәк... Без шулай хыялланабыз. Малайлар инде мине чын әфисәр итеп саный.

— Әфисәрләрне бушка гына ашаталардыр, әйме? — дип әйтеп куя берсе.

— Әлбәттә! Аларның ашау байдан, үлем ходайдан инде,— ди икенче белдеклесе.

— Туйганчы ашарга ирек булса, син күпме ашый алыр идең?

— Көненә бер бидрә бәрәңге белән бер ипи.

— Ипи белән бәрәңгедән кала, тагын нинди ризыклар бар икән дөньяда?

Без саный башлыйбыз:

— Кабак!

— Чөгендер!

— Кәлҗемә!

— Прәнник!

— Бәлеш!

— Ботка!

Шуннан артыкка хыялыбыз җитми. Хәер, ашау турында күп сөйләнмәскә тырышабыз. Чөнки шундук ашыйсы килә башлый...

Бик нык теләгән теләк кабул була, диләр. Унынчы класстан соң мин Саратов хәрби училищесына укырга барып кердем. Өч елдан ялт итеп торган әфисәр киемнәре киеп, иңнәргә лейтенант погоннары тагып авылга кайттым. Яшем егерме ике булса да, әле малайлык бетмәгән. Эчтә горурлык. Авыл урамыннан яловый итекләремне шыгырдатып ашыкмыйча гына атлыйм. Менә күрегез: абзагыз чын офицер! Таныш-белешләр белән күрешкәндә үзләренә сиздермичә генә күзләренә карыйм. Янәсе ничек, ошыйммы мин сезгә? Ошаталар, сокланалар. Өлкәннәр мактап иңнәрдән кагып китә. Һәр яңа кеше белән очрашкан саен янә бер башка үсә барам.

Егет кешегә бәяне, әлбәттә, иң элек кызлар куя. Әгәр алар сине чын егеткә санамый икән, әтәчләнеп кенә әллә кем була алмыйсың.

Кичен клубка киттем. Клубта «вечер» бара. Кызлар, егетләр төрле уеннар уйныйлар, берәм-берәм дә, кара-каршы чыгып та бииләр.

— Мондый вечерлар искелек инде,— дидем янымдагы бер егеткә.

— Хәзер культурный кешеләр танцевать итә.

Дөресен әйтергә кирәк, җыр, бию дигән нәрсәләргә осталык чамалы минем. Ә менә училищеда укыганда танцевать итәргә бераз өйрәнеп кайткан идем.

— Танцыны без дә маташтырабыз,— диде янымдагы егет,— менә уеннарны уйнап бетергәч, танцыга күчәрбез.

Һәм яшьләр бераздан авыл уеннарын тәмамлап, танцыга күчтеләр. Ләкин монда иң өчендер кызлар гына пар-пар биеде. Егетләрнең кыюлыгы җитмәдеме, белми иделәрме — егет белән кыз парлары бик сирәк иде. Мин бу хәлгә хәтта сөенеп куйдым: менә хәзер үземне күрсәтергә була!

Клубка килеп керү белән кара кашлы, кара чәчле, зәп-зәңгәр күзле кызга күзем төшкән иде, шуны биергә чакырдым. Кыз карышмады. Мин аның биленнән эләктереп алдым. О-о, кызның нечкә,сыгылмалы биле, җитез хәрәкәтләре, оялчан елмаюы мине тәмам әсир итте.

— Исемең ничек, чибәркәй? — дидем.

— Исемемне сорап маташкан буласың, беләсең бит,— диде ул.

— Валлаһи белмим.

— Белмәсәң инде.

— Каян белим, безнең авылныкы да түгелдерсең әле. Безнең авылда мондый гүзәлләр юк иде шикелле.

Кызга минем сүзләр ошадымы, ул гади генә итеп:

— Мин Халисә бит, артурам Мөгелсем кызы,— диде.

— Шулаймыни?! Кара инде, син шундый матур кыз булып ни арада үстең соң?

— Син читтә йөргән арада...

Халисә белән бик тиз герләшеп китүебез кайбер егетләрнең саруын кайната башлады бугай, безнең якка усал-усал карашлар ташладылар. Кайберләре ата каздай ыслаштырып ук алгалый иде. — Чамала, Фәрит, сиңа болар бер-бер этлек эшләргә җыеналар,— диде Халисә.

— Ничава! — дидем.— Алардагы йодрык бездә дә чирләмәгән.

— Шулаен шулайдыр,— диде Халисә,— әмма сиздерми генә клубтан чыгып китсәң, яхшырак булыр иде.

— Син нәрсә? — Мин чак кына: офицер башым белән шушы авыл маңкаларыннан куркып качаргамы? — дип әйтеп ташламадым. Халисәнең мине яклавы, авыл егетләренә ботарларга бирмәскә тырышуы күңелемә хуш килде. Менә бит ул офицер булу нинди шәп! Юкса авылның иң чибәр кызы сине яклашыр идеме?!

Бәлки әле без Халисә белән озак биегән булыр идек, ләкин гармунчы шып итеп гармунын туктатты. Мин кызны җитәкләп кырыйдагы эскәмия янына чыгарып куйдым. Шул арада кинәт клубта ут сүнде. Мин аны-моны уйларга өлгермәдем, каты-каты йодрыклар өстемә ява башлады. Кемдер якадан эләктереп алды, кемдер бил каешыннан.

— Совет офицерын кыйнарга хакыгыз юк! Моның өчен беләсезме нәрсә булачагын? — дидем.

— Без совет офицерын түгел, кәпрәеп кайткан авыл егетен кыйныйбыз,— диде берсе һәм дык итеп кабыргага сылады. Билгеле, минем йодрыклар да тик кенә тормады. Кайсыдыр башы белән корсакны сөзде. Иң яманы — берсе погонны йолкып алды.

— Утны яндырыгыз, утны,— дип кычкырдым.— Монда политик җинаять эшләнә.

Кызлар чәр-чәр килде.

Утны яндырдылар. Минем пóгон үземнең аяк астында ята икән. Аны алып кесәгә салдым. Ут яныш китүгә, кызлар ягына күз ташладым: Халисә чыгып таймаганмы? Юк, ул кызлар арасында. Әнә ул минем янга йөгереп килде. Җиң эченнән хуш исле кульяулык тартып чыгарды:

— Битең канаган, Фәрит! — Ул хушбуй исе аңкып торган кульяулыгы белән минем битемне, маңгаемны сөртте. Шушы ләззәтле минутларны озайтыр өчен мин тагын бер кат кыйналырга әзер идем.

— Син аларга ачу саклама инде,— диде Халисә, клубтан чыккач.— Авыл егетләрен үзең беләсең бит.

— Син килеп битемне сөртә башлагач, мин барысын да кичердем, Халисә,— дидем.

Без ул көнне булачак әниең белән таң атканчы йөрдек. Бер авылда туып үсүебезгә карамастан, бер-беребезгә сөйләр сүзләребез, уртаклашыр яңалыкларыбыз күп иде. Әниең былтыр гына урта мәктәп тәмамлап, районагы бер удмурт авылында сатучы булып эшли башлаган икән. Ул чагында мин нәкъ менә синең кебек егет идем. Буем гына бераз кыскарак булгандыр. Ике ел буе хатлар алышып тордык, ә ике елдан мин әниеңне алып киттем.

Менә, улым, әниең белән шулай яши башладык. Ә соң синең яраткан кызың бармы?

* * *

Ул чагында минем соравыма җавап бирмәдең, кызарып кына куйдың. Күрәсең, йөрәгеңдәге иң яшерен хисне безгә ачып саласың килмәгәндер. Ә менә хәзер, синең альбомнарыңны карап утырганда, сиңа кызлар язган берничә хат килеп чыкты. Аларны алып укыганга гафу ит, улым, чөнки синең эчке дөньяңны, хезмәт итә башлагач нинди уйлар, нинди кичерешләр белән яшәвеңне беләсебез килә.

«Исәнме, минем генералым!» — дип башланып китә беренче хат. Беренче дим, чөнки син аның конвертына берле саны куйгансың. —

Хезмәт урынына барып урнашкач язган хатынны алдым. Ләкин мин аңлап бетермәдем: син кем булып йөрисең анда, кемнәр белән командовать итәсең? Гомумән, мин сезнең хәрбиләрнең тормышын аңламыйм. Ә хәрбиләрне яратам үзем. Хәрбиләрнең миңа шунысы ошый: алар бүген монда, иртәгә җәһәннәм астында. Нинди романтика! Мин бу Чиләбе шәһәреннән гарык инде. Менә быел уннны бетерү белән янына барам. Генерал хатыны булып йөрермен шунда. Генерал дип әйтүемә үпкәләмә, Олег, менә мин әйтте диярсең — син барыбер генерал булачаксың. Буйсының килгән, бераз калынаеп та китсәң — коеп куйган генерал инде. Безнең әти әйтә: начальник булыр өчен, иң беренче, кешегә гәүдә кирәк ди. Бәлки дөрестер бу. Шөшле буе солдат ничек кенә акыллы булмасын, аны генерал итәргә тиеш түгелләр, минемчә. Чөнки начальник үзенең тышкы кыяфәте, мәһабәт гәүдәсе белән үк «менә мин!» дип торырга тиеш. Кичә телевизордан кырык яшьлек бер генералны күрсәттеләр. Сиңа да унсигез ел калган икән дип карап утырдым. Унсигез елны гына мин түзәргә әзер. Әлегә шәхси машинаң юклыгын гафу итәм. Кирәк җиргә мине танк белән йөртерсең. Танкың бардыр бит? Танк белән, бәлки, тагын да романтичныйрактыр әле. Бер утырып карыйсы килә иде шуңа.

Карале, Дон Кихотым минем, син анда — үзеңнең Әрмәнстаныңда әрмән кызлары белән типтереп йөри күрмә тагын. Әрмән кызларын бик темпераментный диләр, берәрсе башыңны әйләндерсә, соңыннан качып та котыла алмассың. Андый эшеңне сизсәм, генерал дип тормам, колагыңны борып кайтырмын. Ә мин сизмәгән эш юк, чөнки мин — бераз күрәзәче.

Генералым, мин сиңа бер серемне ачарга булдым әле. Беләсеңме, мин бит сине апамнан тартып алдым. Апам Оля сине әти-әниләр белән таныштырырга дип өйгә чакырган иде. Сине күрү белән йөрәгем әллә нишләп куйды: «Бу егет минеке булырга тиеш!» — дидем үз-үземә. Безнең Оля ул егетләрне перчатка урынына алмаштырып тора. Үзе белән укый торган курсташ студентлары арасыннан гына да икәү килеп йөри. Коля дигәне Оля өчен тугызынчы кат балконнан ташланырга әзер. Коля белән Женясы гына җитмәгән, сине ияртеп кайткан. Тукта әле мин әйтәм, моны кызык итәргә кирәк, дим. Ләкин нәрсә эшләргә һич башка килми.

Уйлый торгач болай иттем: син әти-әниләр янына Оляның күзенә карап утырганда коридорга чыктым да Коляга: «Хәзер үк безгә килеп җит, кәләшеңнең башын бер курсант әйләндергән. Олядан колак кагасың килмәсә, берәр хәйлә тап», — дип шалтыраттым. Дөресен әйткәндә, минем сине Коля белән сугыштырасым килде. Коля бик көнче егет, әтәчләнергә ярата, ә кызлар өчен сугышкан егетләрне карап тору кызык бит.

Менә бер мәлне ах-ух итеп Коля килеп керде. Коляны күргәч, апа: «Мин бит сиңа бүген килергә кушмаган идем, нишләп йөрисең?» — дип ташланды. Мин Коляның әтәчләнә башлавын көттем: йә сиңа, йә Оляга килеп ябышыр, дип уйладым, ә ул мин көткәннән хәйләкәррәк булып чыкты. Әллә синең таза озын буең, дошманына ташланырга әзер торган уяулыгың аны шүрләтте: «Әйе, — диде Коля Оляга моңсу карап, — бүген килми идем, ләкин шундый хәл килеп чыкты». «Нинди хәл?» — диде апа. «Әни кинәт кенә бик каты чирләп китте. Үлгәнче булачак киленне бер күрәсем килә. Бу дөньядан киткәндә улымны кем кулларына калдырып киткәнемне белмәсәм, гүремдә тыныч ята алмам, ди. Яратмавыңны беләм, әмма үлем түшәгендә яткан кешегә мәрхәмәт күрсәтерсең дип ышанам. Әнинең гомере минутлар белән генә санала», — дип бетерде ул сүзен. Бу минутта Коляның күзләре шулкадәр сагышлы иде, хәтта үзем дә ышанып куйдым.

Безнең Оля егетләрне еш алыштырып торса да, авыру яки көчсез кешеләргә карата бик шәфкатьле, шуңа медицина институтына кергәндер инде ул. Ә менә Коля апамның шушы сыйфатыннан бик оста файдалана белде.

Оля чыгып киткәндә миңа:

— Марина, Олегка боегып утырырга ирек бирмә. Шахмат булса да уйнагыз. Олег шахмат уйнарга бик ярата,— дип чыгып китте.

Миңа аларның чыгып китүе генә кирәк иде. Синең бер алдыңа, бер артыңа төшеп маймылланырга тотындым. Әтиләр мине оялтырга тырыша башлагач, аларны үз бүлмәләренә куып чыгардым. Минем, бөтен дөньясында синең белән генә каласым килде. Дөрес, син миңа ул чакта бала-чага дип кенә карадың. Ә минем йөрәгемдә диңгезләр шаулый, янар таулар кайнар сулышын бөрки иде. Үземне шулай бер күрүдә гашыйк була аламдыр дип уйламый идем. Ни генә әйтмә, уналты яшь иде бит инде миңа. Ә безнең класстагы бөтен кызларның егетләре бар. Хәтта кызлар арасында беркөнне укытучылар: «Егетләр белән интим мөнәсәбәткә кергәнегез бармы?» — дип, яшерен анкета уздырдылар. Әйтсәм ышанмассың: алтмыш ике процент кыз «әйе» дип җавап биргән иде. Безне әти-әниләребез картаеп беткәнче бала-чагага саныйлар.

Ул көнне син минем белән рәтләп сөйләшмәдең. Хәер, апа чыгып китүгә минем белән чытлыкланырга тотынсаң, бәлки, синнән күңелем кайткан булыр иде. Минем нәкъ менә синең апага булган тугрылыгыңны сындырасым, сине җиңәсем килде. Җиңү бит ул мәхәббәт үк татлы нәрсә. Ә мәхәббәттә җиңү икеләтә татлырак.

Мин сине озатырга чыктым. Син кул биреп кенә китә башлагач: «Апа миңа синең күңелеңне күрергә боерык биреп калдырды. Башкача күңелеңне күтәрә алмадым инде, бер үбеп карыйм әле үзеңне»,— дип синең муеныңа сарылдым: Синең иреннәрең башта җавапсыз иде. Соңыннан син дә уяндың...

Оля шул китүдән Николайларында калды. Коля аны үзләрендә калырга ничек ризалата алгандыр. Ансын, бәлки, җизнәкәйдән берәр сөйләтермен әле. Аннан сиңа язармын. Ә туйларына чакыру билетын сиңа бирергә дип апам миңа калдырып киткән иде, мин аны сиңа бирмәдем. Апамны күрсәң, йә тагын аңа карый башларсың, дип курыктым.

Менә шул. Хатымны укый-укый армадыңмы әле? Арымасаң, тагын бер нәрсә язам. Беләсеңме, соңгы вакытта мин әти-әниләрне аңлап бетерми башладым. Миңа калса алар, минем синең белән дуслашуымны, сиңа баш-аяк гашыйк булуымны өнәп бетермиләр бугай. Юк, юк! Бу аларның сине яратмаулары түгел. Моның сәбәбе бүтәндә. Әгәр дөрес сиземләсәм, Оля кебек, бу кызыбыз да, көтмәгән-уйламаганда очып китәр дип куркалар шикелле алар. Әти әйтмешли, синең анда «кайнар нокта»га барып эләгүең дә бик сөенечле хәл түгел.

Йә, ярый, хәзергә җитеп торыр. Хәлләрең мөшкелләнә башласа, тиз арада миңа хәбәр ит. Мин синең яныңа очып барып җитәрмен. Әлегә менә мине бик сагынганда карый торырга, фоторәсемемне салам. Матур бит мин, әйеме? Кара аны, фоторәсемемне бүлмәңә килеп керү белән күз төшәрлек урында тот. Әгәр берәр кыз фатирыңа аяк басса, бу өй хуҗалы икән инде, дип борылып чыгып китәрлек булсын. Хәзергә сау бул, сәлам белән — синең Маринаң».

* * *

Маринаның сиңа язган беренче хатын укыгач, уйларым еракка китте. Аның сиңа «генералым!» дип яратып дәшүе йөргәмнең кайсыдыр катламында инде күмелә башлаган хатирәләрне өскә калкытты. Әниең белән без дә бит сине, улым, булачак генерал итеп күңелебезгә беркетеп куйган идек. Һәр ата үз улында үзенең тормышка ашмаган хыялларын эшкә ашыручысы, үзенең дәвамчысын күрә. Синнән яшермим, улым, генерал булырга мин дә тырышып-тырышып карадым. Хәрби академиягә керер өчен ике тапкыр Мәскәүгә бардым. Беренче

баруда безнең частьтан без өчәү идек. Капитан Владимиров, майор Кыям Дәүләтбаев һәм мин. Имтиханнарны без Дәүләтбаев белән әйбәт кенә бирдек, Владимиров кына бик ялтырый алмады. Кайткан вакытта ул:

— Сезне бүгеннән үк котларга була инде, егетләр, ә мин физикадан сынаттым бугай,— дип офтанган иде. Шунда аңа Дәүләтбаев:

— Котларга ашыкма әле, дустым. Сездә — русларда шундый бер мәкаль бар бит: «Не говори гоп, пока не перепрыгнул!» Әле чакыру килми торып, кердек дип күңелләрне ымсындырмыйк.

Дәүләтбаевның сизенүе дөрескә чыкты. Без имтиханда тиешле баллны җыя алмаганбыз, имеш. Минем контроль эшнең бер бите югалган. Дәүләтбаевның тагын нәрсәдер җитешмәгән. Мин үземнең академиягә үтә алмавыма бик гаҗәпләндем, ләкин иң гаҗәпләндергәне — Владимировның узуы булды. Ул хәтта үзе дә моны көтмәгән иде. Академиядән чакыру килгәч: «Егетләр, әллә бу ялгыш микән?» — дип ихластан сөйләнеп йөрде. Икәү генә калгач, Дәүләтбаев:

— Мин моның шулай буласын көткән идем,— диде.

— Нигә?

— Нигәме? Сәбәпләре моның тирәндәрәк. Үзең уйлап кара: син һәм мин кем дә, Владимиров кем?

— Владимиров — капитан,— дидем,— ә без майорлар. Икебез дә хәрби училище бетереп, армия тормышының ачысын-төчесен унбиш ел буе җилкәбездә татыган офицерлар. Белемебез дә Владимировныкыннан һич ким түгел. Төнлә йокыдан уятып сорасалар да имтихан сорауларына җавап бирә алачагыма шикләнмим мин.

— Ансы шулай,— диде Дәүләтбаев.— Тик монда хикмәт синең белән минем белемдә түгел.

— Алайса нәрсәдә соң?

— Безнең татарлыкта.

— Әйттең сүз,— дидем мин, чәпчеп.— Монда руслыкның, татарлыкның ни катнашы бар?

Дәүләтбаев әрле-бирле йөренде. Аның нәрсәнедер әйтеп бетермәве сизелеп тора иде. Әллә ул миңа ышанып җитмиме?

— Сүзне башлагансың икән, ахырына кадәр җиткер инде син, дустым,— дидем мин.

— Синең бер нәрсә турында уйлап караганың бармы, Фәрит?

— Нәрсә турында?

— Ни өчен безнең татарлар арасыннан зур полководецлар чыкмый? Нәрсә, без башка халыклардан аңгыраракмы? Яисә без ялкау, булдыксызлармы?

— Зур полководецлар алар бар халыкта да күп түгел инде.

— Алай димә. Син менә барлык югары постлардагы түрәләрне, армия генералларын, маршалларны санап кара. Дөньяда иң күп генераллар, иң күп маршаллар безнең илдә. Һәм шуларның туксан тугыз проценты руслар.

— Соң, без бит Рус илендә яшибез,— дидем мин, ни әйтергә белмичә.

— Юк, без Рус илендә түгел, Советлар Союзында яшибез,— диде Кыям, кыза башлап.— Ә болар икесе ике нәрсә.

Дәүләтбаев үзе Башкортстанда туып үскән татар. Әти-әниләре укытучылар булган. Татарлар турында ул күп укый. Ял вакытларында китапханәдән чыкмый, архивларда казынып ятарга ярата. Төпле белемле егет, шуңа күрә бүген мин аны бүлдермичә диярлек тыңладым. Ә ул:

— Мин инде маршаллар турында әйтмим дә,— дип дәвам итте.— Академия бетергән генераллары да бик әз безнең халыкның. Хәтта революциягә кадәр үк утыздан артык генералы булган татар халкы, барлык халыкларга «тигез тормыш бүләк иткән» революциядән соң кинәт кенә аңгыраеп калганмы әллә? Син әйтерсең: Бөек Ватан сугышын-

да йөздән артык генералыбыз булган дип. Ансы дөрес. Чөнки ул чакта фашизм җиңү өчен һәр халыкның үз арасыннан чыккан, шул халыкның характерлы сыйфатларын яхшы белгән командирлар кирәк иде. Моны югарыда утыручылар бик оста файдаланды. Сугыш беткәч, безнең кирәгебез калмады. Ә менә руслар арасыннан, сугыш вакытында әз генә үзләрен күрсәтергә өлгергән командирларны да академияләргә җибәреп укыттылар. Әзмени урта белеме юк килеш академия бетергән маршаллар?! Шулай, дустым, татар батырларын татар булганы өчен генә дә күрмәскә тырышалар. Син рейхстагка беренче булып байрак элүчеләрне беләсеңме?

— Беләм: Кантария, Егоров...

— Юк шул, юк. Кантариядән алда Владимир Маков группасындагы татар егете Гази Заһитов кадый рейхстаг өстенә беренче Җиңү байрагын.

— Кем әйтте аны сиңа?

— Кем әйтүе әһәмиятле түгел. Хакыйкатьне эзләүчеләр бар икән әле дөньяда. Һәм мин ышанам: хаклыкны нинди генә авыр таш белән бастырып куйма, аны кубарып ташлардай көчлеләр табылыр.

— Әгәр инде чынлап та рейхстагка беренче байракны кадаучы Гази Заһитов икән, яңадан анда Кантарияләрне, Егоровларны меңгерү нигә кирәк булган? — дидем мин.

— Кантария — грузин, Егоров — рус. Шуннан аңла инде үзең. Без бит халыклар дуслыгы «чәчәк аткан» илдә яшибез.

— Соң бит үзең Гази Заһитов Маков Владимир группасында булган дисең. Монда да халыклар дуслыгы чагылмыймыни?

— Син әллә артыгын беркатлы, әллә мине үртәп маташасың,— диде Кыям.— Сталинның грузин икәнен онытма, дустым. Сугыш вакытында «халыклар атасына» ярарга тырышучы командирлар әз булган дисеңме? Аларга Сталинның турыдан-туры приказы кирәкми, ялагай кеше югарыдагыларга ярау фәнен бик тиз үзләштерә. Татарларны кысу, аларның батырлыгын күрмәскә тырышуны мин сиңа йөзләрчә мисаллар белән раслый алам. Синең инде Әмәт-хан Солтан дигән легендар очучы турында ишеткәнең бардыр. Кырым татары ул. Менә шушы татар егете сугыш вакытында фашистларның җитмеш ике самолетын бәреп төшерә. Ә син аңа ничә тапкыр Советлар Союзы Герое исеме бирелгән дип уйлыйсың?

— Белмим шул.

— Ике тапкыр. Ә бит әле ул сугыштан соң да дистә еллар буенча яңа самолетларны сынаучы булып эшли. Геройга дүрт тапкыр тәкъдим ителә. Әмма һаман шушы татарлыгы комачаулый.

— Гел шул татарлыкка кайтарып калдырасың син.

— Мин түгел, фактлар үзе шулай сөйли моны, дустым. Син бит башсыз егет түгел, чагыштырып кара: Кожедуб алтмыш бер, Покрышкин илле тугыз самолет бәреп төшерә. Аларга өчәр тапкыр Герой исеме бирелгәнме — бирелгән...

Мин шактый вакыт сүзсез утырдым. Үз гомеремдә бер генә тапкыр да башыма мондый уйлар килеп караганы юк иде. Кыям әллә нәрсәләр белә икән. Бәлки, ул аларны Сталинга үчле булганга сөйлидер. Ни генә әйтмә, аның әтисе — Сталин чорында ГУЛАГ ачыларын татыган кеше. Гап-гади тарих укытучысының «халыклар атасы» каршында нинди гаебе булгандыр, алла белсен. Хәер, Кыямга карап фикер йөртсәң, аның әтисенең бик үк гади укытучы булмаганлыгын аңлавы авыр түгел.

— Уйла, уйла, дустым,— диде Дәүләтбаев.— Тормышта уйланырлык нәрсәләр күп. Безнең халкыбыз, әгәр чын дәүләтле халык булса, әллә кайчан бөтен дөньяга танылыр иде. Бездә батырлар да, башлылар да җитәрлек. Сугыш вакытында күкрәге белән дошман амбразурасын каплаучы дүрт йөздән артык кешенең егерме икесе татар икәнен әйтү дә җитә. Хәер, Александр Матросов үзе дә татар.

— Син нәрсә? — дип, сикереп тордым.— Каян алып әйтәсең моны?

— Соң, мин бит үзем Башкортстанныкы. Александр Матросов белән бер үк районнан — Учалыдан. Минем аларның авылларында булганым бар — Кунакбай авылында Юныс абзыйны белмәгән кеше юк. Газеталарда Александр Матросовның рәсеме чыккач: «Бу минем Шакирҗан бит»,— дип йөргән ул. Юныс абзый гына түгел, барлык авылдашлары таныган аны.

— Ә ни өчен соң ул Александр булып киткән?

— Анысы бүтән мәсьәлә инде аның. Акыллы кешеләр татарның башына гел сугып торуларын күрә килгәннәр. Кем исемен, кем динен алыштырган.

— Ай-һай,— дидем мин,— мондый фикерләр белән син ничек армиягә килә алдың?

— Армиядә мин гаделлек күбрәк дип уйлый идем. Хәзер фикерләрем үзгәрде. Бәлки, китәрмен дә әле.

— Юк, юк, китмә,— дидем мин.— Менә киләсе елда тагын академиягә имтиханнар биреп карарбыз. Мин ышанам: академиягә кергәч, әлеге фикерләреңнең дөрес түгеллегенә үзең үк аңлаячаксың.

— Рәхмәт,— диде Кыям,— бик теләсәң, академияңә үзең барырсың. Миннән җитеп торыр.

Һәм, минем үгетләүләремә карамастан, Кыям яңадан ул якка әйләнеп тә карамады. Без тагын өч офицер (икебез рус иде) имтиханнар тапшырырга Мәскәүгә киттек. Бу юлы мине өстәмә сораулар белән «батырдылар». Рус милләтеннән булган офицерлар шома гына узып киттеләр. Әмма шуннан соң да әле миңа акыл кермәде, партиянең югары мәктәбендә укый башладым. Мөмкин кадәр өскәрәк үрмәләп, хезмәттәш дустым Кыям Дәүләтбаевка: «Син хаклы түгел, менә миңа кара. Гади татар малае нинди дәрәҗәгә иреште»,— диясем килде. Әмма күпме тырышсам да, полковник дәрәҗәсеннән узып булмады. Ә Кыям Дәүләтбаев берничә елдан бөтенләйгә армиядән китте. Озаткан чакта аның белән тагын бер утырып сөйләштек.

— Мин синең карашларыңны үзгәртергә тырышмыйм,— диде ул,— чөнки моның мөмкин эш түгеллеген беләм. Бу лагерь системасы безнең каныбызга, җаныбызга ныклап сеңгән инде. Тикмәгә генәмени Сталин корбаннары эшафотка: «Яшәсен Сталин!» — дип кычкырып менгәннәр. Без бит кечкенәдән үк һәммәбез лагерьларда үскән кешеләр. Пионерлар — пионерлагерьда, без хәрбиләр — хәрби лагерьда, авыл кешеләре — колхоз дигән лагерьда, тоткыннар — үз лагерьларында. Безнең бөтен ил тоташ тимер койма белән әйләндереп алынган лагерь. Аннан беркем чыгып китә алмый. Чыгып китәргә теләүчеләрне без мушкага утыртып торабыз. Син әллә безгә армия империалистлардан саклану өчен кирәк дип уйлыйсыңмы? Юк, шушы лагерь системасын таркатмас өчен кирәк ул армия.

— Син бигрәк инде,— дидем Кыямга, ачуым килеп,— әллә нинди нәтиҗәләр чыгарырга торасың. Бездә татарларны кысалар диюең белән дә килешә алмыйм. Безнең татар халкын үз иленнән кумаганнар әле. Чәчән, карачай, немец, калмык, кырым татарлары кебек кусалар ни әйтер идең?

— Куалар иде, ләкин без Россиянең кече теле кебек, нәкъ авыз эчендә утырабыз. Дөрес, ул үзенең кече телен кисеп ташларга да күп сорамас иде, әмма безне куып таратуга караганда, буйсындыру аңа зуррак канәгатьләнү бирә. Көчле дошманны кол итү, аның ихтыярын сындырудан да ләззәтлерәк ни бар дөньяда? Патшалар ни өчен Пугачев кебек бунтарьларның башта аяк-кулларын, аннан соң гына башын кистергән? Чөнки корбаны болай озаграк җәфаланган. Безнең халык белән дә шул хәл: башта иркебезне, аннан динебезне, әкрен-әкрен телебезне ала тордылар. Ә ирексез, телсез, динсез кешенең үз фикере, үз ихтыяры була алмый, ул колга әйләнә.

Без Кыям Дәүләтбаев белән шулай аерылыштык. Яңадан аны очратырга туры килмәде. Менә хәзер, күпме еллар үткәч, Кыям дусның

никадәр хаклы икәнлеген күреп шаклар катып утырам. Улым, исән булсаң да, ай-һай, генерал дәрәҗәсенә ирешә алыр идең микән?

* * *

Маринаның икенче хаты бераз бүтәнчәрәк язылган булып чыкты. Элеккечә ярым шаярып «генералым!» димәгән, ә: «Олег,— дип кенә башлап киткән.— Соңгы вакытларда көнелем ни өчендер шомлана. Гел начар төшләр күрәм. Бүген, имеш, синең белән каядыр барырга чыкканбыз, өстебездә каргалар өере әйләнә. Кайберләре кинәт түбән ташланып сине чукырга килә. Син куасың, ташлар атасың, ләкин алар таштан да курыкмыйлар. Каркылдашалар, күбәйгәннән күбәяләр, усалланганнан усалланалар. Мин сиңа ярдәмгә ташланмакчы булам, ләкин син мине үзеңә якын җибәрмисең. Бар, дисең, читкә йөгер, юкса болар сине дә чукый башларлар, ә минем сине каргалардан чукытасым килми, дисең. Мин һаман яныңнан китмәгәч, ачуланып куып җибәрдең.

Менә шундый төш, Олег. Билгеле син төшләргә ышанмыйсың, ләкин мин бу төштән һич айный алмый. Шуңа күрә, элекке хатыма җавабың килмәсә дә, борчуларымны язып салырга уйладым. Кара аны, миннән бернәрсәне дә яшермә. Хатыңны озын итеп яз. Әгәр ун биттән дә ким язсаң, хатыңны укымаган килеш үзеңә җибәрәм. Озын итеп язылган хатыңны көтеп — синең Маринаң».

Маринаның шушы хатына җавап итептер инде, озын хат язгансың, улым, тик аны ни өчендер җибәрмәгәнсең. Бәлки, бу — хатыңның караламасы гынадыр, чөнки аның күп кенә урыннары сызылган, ә син бик пөхтәлек ярата идең, мондый сызгаланган хатны сөйгән кызыңа саласың килмәгәндер. Ни генә булмасын, бу хатыңны укыгач, сине тагын да ныграк аңладым. Хәер, сине генә түгел, үземне дә. Синең күзләрең йомылгач кына минекеләр ачыла башлады шул.

Үзем синең Маринага язган хатыңны укыйм, үзем синең һәр адымыңны күз алдымнан кичерәм. Менә ул хат.

«Марина! Бүген мин сиңа яңа исем уйлап таптым әле — Сары шөпшә! Син каршы килмәсәң, моннан ары мин сине шулай дип кенә атармын, яме. Ни өчен Сары шөпшәме? Моның үзенә күрә кечкенә генә тарихы бар. Кичә синең хатың килгәч, укып чыктым да өстәлгә куйдым. Башка вакыттагы кебек шунда ук җавап язарга утырмадым. Нигә дисәң, сиңа бераз үпкәләгән идем. Син анда: җавап хатың ун биттән ким булса, укымый кире кайтарам, дигәнсең. Ун битлек хат язу ул минем өчен ун чакрым араны ун мәртәбә йөгереп узуга караганда да авыррак. Менә шул сүзләрең өчен үпкәләп, караватка сузылып ятып, газеталар караштыра идем, ачык форточкадан бер сары шөпшә очып керде дә минем борын төбемдә выж-выж оча башлады. Куып-куып карыйм — китми генә. Ачуымнан, кулымдагы газетаны бөкләп тотып, моның берәр җайлырак җиргә кунганын көтә башладым. Ә ул, хәерсез, синең хат өстенә кунды. Хатың өстендә шөпшә үтереп, аны пычратасым килмәде, шөпшәне куаларга тотындым. Минем куалавымны күргәч, ул борыныма кунып, шәп итеп чагып алды. Шунда минем башыма: «Карале, бу бит Маринага хат язмаганга миңа ачулана түгелме соң? — дигән уй килде.— Әллә соң ул Маринам үзе микән?» Дөньяның без белмәгән хикмәтләре, серләре күп бит аның. Көннәрдән бер көнне син минем ачык тәрәзәмнән шөпшә яки кош булып очып керсәң, мин гаҗәпләнмәм кебек.

Газеталарымны бер якка ыргытып, сиңа хат язарга утырдым. Нәрсә языйм, нәрсә белән ун битне тутырыйм икән? Мөгаен, балачактан башларга кирәктер. Мин бит сиңа үземнең балачагым турында сөйләгәнем юк әле. Бер уйлаганда, мин дә шул үземнең яшьтәшләрем кебек: тудым,

укыдым, үстем. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Хәрби шәһәрчектә, кадровый офицер гаиләсендә туган малай бишектән төшүгә үк солдатка әверелә. Бу һич арттыру түгел, уенчыклар һәммәсе үтерү коралы: пистолет, пулемет, танк, самолет. Әти мине иртән «подъем!» дип уята, «отбой» белән яткыра. Миңа, әлбәттә, кызык. Әтием: «Менә молодец! Чын солдатлар җитезлегендә сикереп тора минем улым, караватын җыештыра, арыса шыңгырдамый»,— дип мактап та җибәрсә, түбәм күккә тия. Әтигә ияреп һәркөн салкын су белән юынам. Ә кайчагында, йомшаграк кар яуган көннәрне, урамга чыгып кар белән тәнне ышкыйбыз. Әти мине карга ауната. Бер-беребезгә карлар ыргытышабыз. Йөгерәбез, сикерәбез. Өйгә кергәч, бөтен тән уттай яна. Андый чакларда әни әтине җиңелчә генә тиргәп ташлый:

— Балага салкын тидертерсең әле. Аны үзең белән тиңлисең. Гомерлек чир эләктерсә...

Әти миңа хәйләкәр күз кыса:

— Солдат кешегә салкын тими, әйеме?

— Так точно! — дим мин, солдатларча тез басып.

Өйгә кунаклар килсә дә:

— Үскәч кем буласың инде син? — дип сорыйлар. Мин һич икеләнүләрсез:

— Командил булам,— дип җавап бирәм.

— Ә командир нишли соң ул?

— Командилмы? Командил кулына пистолет тотып «пах-пах» ата. Фашистлар егылып-егылып калалал.

— Хәзер фашистлар юк бит инде,— ди килгән кунак,— немец фашистларын җиңдек. Кемгә «пах-пах» итәрсең икән соң?

Мин ярдәм көтеп әтиемә карыйм. Әти:

— Социализмның дошманнары житәрлек аның диген, улым. Хәзер дошманның кулы озын: атом бомбалары тоткан куллар океан артыннан безгә үрелергә генә тора.

Әти безнең хәрби училищедан соң югары партия мәктәбе бетергән кеше. Мин белгәннән бирле ул — йә батальон, йә полк, йә часть командирының сәясәт буенча урынбасары. Шуңа күрә аның мондый фикер йөртүенә һичкем гаҗәпләнми. Әтиемнең: безне бөтен яктан дошман камап алган, әз генә уяулыгыңны югалттыңмы — бугазыңа пычак тыгачаклар, дигән сүзләре — аның бәгыреннән чыккан сүзләр. Хәер, мин әтием турында түгел, үземнең балачагым турында яза идем бит әле.

Әйе, җиде яшемдә инде мин армиядә җиде ел хезмәт иткән хәтле солдат тормышын белә идем. Укырга кергән елны әти минем туган көнгә пневматик пистолет алып бирде. Ул нәкъ чын пистолет төсле. Аның үзенә күрә пулясы да бар. Ул мишеньгә барып кадала, аны тартып аласың да яңадан атасың. И-и, бу бүләккә минем сөенүләрем! Чөнки мин аралаша торган малайлардан бөтенесенең дә мондый пистолеты юк. Малайлар каршында дәрәҗәм бер башка үсеп китте. Өйдә һәркөн ату ярышлары оештырабыз. Стенадагы обойның чәчәге дисеңме, тишек-тошык дисеңме, түшәмдәге лампочка дисеңме — берсе дә калмый. Бервакыт әни кайтып кергәндә лампочкалар ватыгы өстендә кыргый индеецлар биюе биеп ята идек, бик каты эләкте үзебезгә. Шуннан соң әни пистолетны каядыр яшереп куйды. Әмма әти аны яңадан миңа бирде. «Зарарлы әйбер түгел, уйнасыннар, улыбыз солдат буласы кеше, куллары күнегә торсын»,— диде. Ә бераз үсә төшкәч инде минем чын мылтыклар, чын автоматлар тотып карыйсым килә башлады. Безнең хәрби шәһәрчектә полигон, ату кырлары, стадион, тагын әллә ниләр бар иде. Мин еш кына әти янына барам, казармаларына, уку классларына керәм. Әлбәттә миңа, малай кешегә, иң кызыгы — ату кырларында солдатларның атарга өйрәнүләрен карау. Ничә яшемдә булганмындыр, миңа чын мылтык, чын автомат тотарга рөхсәт итә башладылар. Ә кулга корал тоткач, атып карыйсы килә. «Атыйм инде»,— дип әтинең буынына төшәм. Ниһаять,

рөхсәт алуга ирешәм. Билгеле, әтиемнең катгый күзәтүе астында инде. Чын коралдан атып карагач, мин шуны аңладым: корал ул нинди дер сихерле әйбер икән. Бер тоттыңмы, аны кабат тотасы, кабат атасы килә. Солдатны үтерүчегә әйләндерү авыр түгел, минемчә. Мин әтигә ялына башлыйм: «Әти, тагын алып бар инде шунда!» «Бишле»гә генә укысаң, алып барырмын»,— ди әти. Мин тырышам. Әти, минем ату коралларына хиреслегемне белеп алгач, киреләнсәм-нитсәм, шул мылтык, автоматларын тоттырмау белән куркыта иде.

Безнең офицерлар шәһәрчегендә һәр үсмер малайны чын патриот, чын солдат итеп тәрбияләр өчен һәммәсе уйланылган. Мәктәбебез Александр Матросов батырлыгын кабатлаган Советлар Союзы Герое сержант Каширин исемен йөртә. Герой Каширин шушындагы полкның бер ротасына мәңгелек исемлеккә теркәлгән. Кайчагында мәктәбебез белән без ул ротага барабыз. Анда геройга багышланган стенд бар. Гомумән, без балалар бакчасында чагында ук гел хәрбиләр белән аралашып үстек. Алар безнең бакчага, ә укый башлагач, мәктәпкә киләләр. Хәрби хезмәтнең искиткеч мавыктыргыч, искиткеч кирәклеге турында һәркөн ишетеп торабыз. Безгә, офицер малайларына, чынлап та хәрби тормыштан кызыклырак нәрсә юктыр кебек тоела.

Бәйрәм яки солдатларның хәрби ант кабул иткән көннәрендә барлык частьларны үзәк мәйданга тезәләр. Командирлар трибунада. Оркестр тантаналы марш уйный. Тигез адымнар белән солдатлар трибуна каршыннан уза. Безнең кеше малайларның йөрәге, очарга талпынган кош йөрәгедәй, ашкына. Тизрәк үсәсе, шушы бәхетле солдатлар кебек музыка астында марш атлап узасы килә. Без, офицер малайлары, беренче чиратта әтиләребезне күзлибез, әлбәттә.

— Әнә теге майор минем әти,— ди берсе.

— Ә минеке подполковник.

— Минеке полковник!

Әтиләребез белән горурланудан бугазларга кайнар төерләр утыра. Мондый чакларда хәтта төнлә йоклаганда да әнә шул тантаналы музыка, кыска-кыска команда тавышлары, шап-шоп басып баручы тигез рәтле сафлар күз алдыннан китми. Төне буе шулар белән саташып чыгасың.

Уникe яшькә кадәр мин шушы хәрби шәһәрчектә үстем. Бары тик җәйге каникул вакытларында гына «Кисагач» дигән күл буендагы пионер лагерена бара идем. Бу лагерь бик матур урында, күлнең матурлыгын, тирә-юньдәге урманнарның серлелеген язар өчен язучы таланты кирәктер. Ә шулай да мин әнә шул тирә-ягын биек койма белән әйләндереп алган хәрби шәһәрчегебезне сагына идем. Очар кошны гел читлектә асрасаң, ул үзенең читлеген сагына, ирекка җибәрсәң дә кире кайта, диләр,— дөрестер, мөгаен. Мин инде үземне хәрби тормыштан башка күз алдына китерә алмый башладым. Йөгерү, сикерү, йөзү кебекләргә ярыйсы ук җайлы күнексәм дә турникта уйнау дигән нәрсә шактый авыр бирелде. Бервакыт шулай әти белән спортзалда идек, ул минем турникта гәүдәмне ияккә кадәр күтәрә алмавымны күрде дә: «И улым, үзең офицер булырга җыенасың, үзең гәүдәңне дә күтәрә алмыйсың. Офицерга бит үз гәүдәсен генә түгел, күп тапкыр авыррак нәрсәләр күтәрергә туры киләчәк»,— диде. Әтинең шушы сүзе җитә калды. Җәй буе әтидән качып турникта азапландым. Ә берничә айдан мин аңа: «Әти, әйдәле спортзалга барып кайтыйк, бернәрсә күрсәтим үзеңә»,— дидем.

Башта мин юри әтине үртәр өчен турникка якын килми йөрдем. Ул: «Нәрсә, улым, сөзгәк кәҗә тәкәсеннән курыккан авыл малаедай, һаман турниктан куркасыңмы?» — дип әйткәч, үҗәтләнеп турникка барып ябыштым: башта гәүдәмне җәһәт кенә ыргытып менеп утырдым, аннары әйләнә башладым. Төшкәндә сальто ясап төштем. Әтинең соклануы, гаҗәпләнүе йөзенә чыккан иде. Мин аңардан: «Йә, әйт инде, хәзер миннән офицер чыгармы?» — дидем. «Чыгар, улым, чыгар. Мондый тырышлык белән син теләгеңә ирешерсең».

Ә бераздан әтине Пермь шәһәренә җибәрергә булдылар. Мондагы тормышка шулкадәр ныкияләшкән идем, әтигә ялына башладым: «Әти, китмик инде. Дөньяда безнең шәһәрчектән дә матур шәһәр юк. Монда автомат, пулемет, пушкалар...

— Хәрби кеше үз теләге белән йөрми, улым,— диде әтием.— Ватан кая кушса, мин шунда.

Күчереп йөрүләрдән әни дә туйган иде.

—Гомер буе чемодан өстендә утырып арытты инде,— дип, бераз сукранып алды.— Инде монда чынлап төпләндек ахры дип сөенгән идем. Юк икән — тагын бөтен әйберне пыран-заран китереп чыгып китәргә икән.

— Кемгә чыкканыңны белдең бит,— диде әти.

— Бик белеп бетермәгәнмен, күрәсең. Яшь чакта, юләр чакта офицерлар тормышы бик романтикалы булып күренә бит. Кием-салым пөхтә, буй-сын төз. Кызларны күбрәк менә шушы тышкы кабык кызыктыра. Гомер буе ирләре белән хәрби хезмәт арбасын тартып барачакларын күз алдына китерә алмый алар.

Әни, вакыт-вакыт зарланса да, әтинең хезмәте, аның шундый дәрәҗәгә ирешүе белән горурлана да иде.

Без Пермь шәһәренә күчеп килдек. Монда безгә гадәти шәһәр йортыннан квартира бирделәр. Мин дә шәһәр мәктәбенең алтынчы классында укый башладым. Яшерен-батырын түгел, хәрби шәһәрчектән соң миңа биредә бик күңелсез тоелды. Без тегендәге малайлар, солдатларга ошарга тырышып, төрле хәрби уеннар уйный идек. Ә монда хәрбиләрне телгә алучы да юк. Кемдер музыка мәктәбенә, кемдер фигуралы шууга, кемдер тагын әллә кая ашыга.

Апам Роза гына шәһәрне ошатты. Ул монда пединститутның чит телләр факультетына укырга керде. Инглиз телен мәктәптә укыганда ук шәп белә иде. Миңа да: «Урамда трай тибеп йөргәнче өйдә минем белән чит тел өйрән»,— ди иде. Апа әйтте дип кенә мин инглиз теленә ябышмадым, билгеле. Шулай бервакыт сүз арасында әти: «Их, офицерларның күбесе бигрәк надан. Ник берсе чит тел белсен»,— дип зарланып утырган иде. Шунда мин: «Офицерларга чит телләр белү кирәкмени, әти?» — дип сорадым. «Ничек кенә кирәк әле, улым,— диде әти.— Дошманыңның телен белмичә аның ни коралын, ни психологиясен өйрәнә алмыйсың. Безнең кешеләребез төрле җирләрдә бит, улым. Кайсы разведчик, кайсы хәрби киңәшче, кайсы тагын әллә кем. Чит тел белгән офицерларга хезмәт хакын да күбрәк түлиләр, улым.»

Әти белән шушы сөйләшүдән соң инглиз теленә ябыштым. Башта апам мине котыртса да, төрле сораулар белән йөдәтә башлагач, туя иде. Әмма мин үҗәтлегем белән аны җиңдем. Тел өйрәнүгә сәләтем булган, күрәсең: ике ел дигәндә апам белән инглизчә ярыйсы гына сукалый идек инде. Хәтта ул: «Син мине узып та китәсең болай булса»,— дип куйгалый иде.

Тик барыбер Пермь шәһәрен күңелем якын итә алмады. Минем шулай үземә урын таба алмый йөргәнемне күргәч, әти:

— Улым,— диде,— бирегә күчкәннән бирле син канаты каерылган коштай йөрисең, каршы килмәсәң, синең белән бер мәсьәлә хакында сөйләшергә иде...

— Нәрсә турында, әти?

— Күреп торам, улым, син хәрби шәһәрчектәге тормышыңны сагынасың. Дөресен әйтергә кирәк: мин моңа бик шат. Минем бөтен хыялым — сине зур командир итеп үстерү. Әллә, мин әйтәм, сигезне бетергәч Суворов училищесына китәсеңме?

— Ура, әти! Китәм.

— Тик, улым, син шуны белергә тиеш: ул юлга бер кердеңме — борылу юк. Суворов училищесын бетерүчеләр офицерлыкка укырга китә. Син бөтен гомереңне армиягә багышларга тиеш булачаксың.

— Бу бик шәп бит, әти. Үзең бит һәрвакыт, Ватанга хезмәт итүдән дә изгерәк эш юк, дисең.

— Үкенмәссеңме соң, улым?

— Ә син үкенәсеңмени, әти?

— Юк, улым, үкенмим. Гади крестьян баласы шушы дәрәҗәгә күтәрелә алган икән, моның өчен партиягә рәхмәт әйтергә генә кирәк. Бары тик совет илендә генә гади кешегә мондый бәхет эләгә ала.

Әти белән безнең арада шундый сөйләшү булды. Ә сигез классны бетергәч мин Свердловскидагы Суворов училищесына киттем.

Анда инде «син полковник малае» дип башыңнан сыйпамыйлар. Анда каты казарма режимы. Подъем белән торасың, отбой белән ятасың. Иртән торгач йөгереп кайтулар, салкын су белән юынулар. Хәлдән тайганчы спорт белән шөгыльләнүләр. Болар өстенә уку. Начар укырга, «икеле» алырга ярамый. Ә бит монда авылдан килгән йомшак малайлар да бар. Бервакыт шулай марш-бросок вакытында Сережа исемле малай хәлдән таеп егылды. Елап ята бу. Взвод командиры моның янына килде дә: «Встать!» — дип кычкырды. Сережа торырга маташа, ләкин тора алмый. Елый.

— Син кем, нәрсәгә елыйсың? — ди командир.

— Мин Сережа Николаев.

— Юк, син Сергей Николаев түгел, син булачак совет офицеры. — Ә совет офицерлары еламый, — ди командир. — Совет армиясе командиры утта янмый, суда батмый.

Аннары ул барыбызга мөрәҗәгать итеп:

— Менә үзегез уйлап карагыз: бүген сугыш чыкты, ди. Сез дошман кулына эләктегез, сезне җәзалыйлар, ди. Шулвакыт сез елап торырсызмы?

— Без дошман кулына төшмәячәкбез, — дип хор белән җавап бирәбез. Безнең җавап командирга ошый. Ул Сережаны торгызышырга дип безгә команда бирә.

Әти хезмәте буенча командировкаларга килгәндә минем янга кереп чыга. Тормышым, укуым турында сораша. Ләкин укытучыларга, командирларга: «Минем малайга бернинди ташламалар ясамагыз. Булачак офицер армия тормышының барлык авырлыкларын белергә тиеш», — ди. Кайвакыт әтинең шундый кырыслыгына хәтер дә кала. Нигә инде шунда берәр атнага өйгә кайтарырга сорамаска, нигә янга ешрак килмәскә? Үзем шундый уйлар уйлыйм, үзем үк шул уйларымнан оялам. Ә башкалар? Сережалар, Днмалар? Алар миннән көчсезрәк тә бит әле. Алар да тырышалар, укыйлар. Елый-елый еламаска өйрәнәләр. Чөнки без бит әле 14-15 яшьлек малайлар гына...»

Хат шушы урында өзелгән. Ничә көн язылгандыр, числосы куелмаган. Инде менә монда Маринаның соңгы хаты. «Генералым! — дип башлаган ул бу хатны да, — тиздән безнең кышкы каникуллар җитә, шунда янына киләм. Синең анда фатирың ничә бүлмәле? Әгәр шунда гына укырга калсам, урта мәктәп бармы? Менә күрерсең, үзем барсам, синең баш өстендә очып йөрүче каргалар калмаячак. Мин аларны куунын әфсенен беләм. Йә, ярый, Олег! Каникулларга күп калмый. Мине каршыларга оркестр ялла, үзең аэропортка танк белән кил. Танк бик ошап китсә, бәлки әле шуның белән ЗАГСка да барырбыз. Менә ичмасам оригинально булыр иде, әйеме? Мондагы кызларга танклар белән килүче туй кортежен төшергән фоторәсемнәрне салсам, көнләшүләреннән тәгәрәп үләчәкләр. Тиздән көт! Сине сагынып — Маринаң.»

Барлыгы өч хат. Әзме бу, күпме — әйтә алыйм. Каникулыңда, бәлки, ул янына барган булыр иде, тик син каникулларны көтмәдең шул, улым.

Минем үземә генә язган хатың шактый хәвефле иде. Тик мин, совет армиясе командиры, ул чагында сине аңлап бетермәдем. Синең йөрәк чаңының беренче авазларына саңгырау калдым. Мин аны кабат-кабат

укыйм, тойган кешегә җитәрлек икән анда хафаланыр нәрсәләр. «Әтием,— дип язасың син,— бу хатны үзеңә генә атап җибәрәм. Синең белән ирләрчә күзгә-күз карап сөйләшәсе килә. Ни өченме? Син, әти, һәрвакыт Ватанны бердәм, бөтен, какшамас изге бер нәрсә итеп аңлата идең. Мин дә синең сүзләр белән тулысынча килешә идем. Син, монын карашы үзгәргән икән, дип борчылма, юк, карашым үзгәрмәде, әмма мондагы кайбер күренешләр башкачарак уйларга мәҗбүр итә. Мин сиңа бервакыт телефоннан сөйләшкәндә, хәрби йөкләр ташыр өчен безнең дивизия карамагында махсус авторота оештырылуы турында әйткән идем. Һәр машинага, йөкне озатыр өчен, берәр офицер билгеләделәр. Мин хәзер йөкләр ташыйм: машина экипажының командиры саналам. Болары, әлбәттә, сүзем аңлашылсын өчен генә. Сиңа әйтергә теләгәнем шул, әти, беркөнне хәрби йөк белән кайтып килгәндә беренче взводның машинасына җирле боевиклар һөҗүм иткән. Монда андый хәлләр шактый еш булып тора, анысына хәзер исем китми инде. Корал складларына да һөҗүмнәр күп булa. Мине гаҗәпләндергәне шул: хәрби йөк дигәне гап-гади өй җиһазы булып чыга. Анысы кемгә диген әле, әти? Безнең полк командирына! Боевиклар машинада үзләре теләгән корал тапмагач, ачудан шофер белән йөкне озатучы лейтенантны атып киткәннәр. Берәүне чит илдән кайтартылган зиннәтле диван-кәнәфиләрдә йоклатыр өчен ике кеше гомерен бирде. Полк командирына нәрсә булды дисең? Утыра! Әлбәттә, төрмәдә түгел, үз урынында. Хәтта теге җиһазларны да кайтартып каядыр җибәргән, диделәр. Менә сиңа Ватанны саклаучы! Мин хәзер Ватанны болайрак күз алдына китерәм, әти: ул бер олы искергән шинель. Шул шинельне һәркем үзенә тарта. Берәүләр җиңеннән, икенчеләр якасыннан, өченчеләр итәгеннән өстери. Тартмаслар иде: бер шинель астында барлык халыклар сыеша алмый башлады.

Намус белән Ватан төшенчәсен син бер итеп аңлата идең, әти. Тик күп кенә командирларның карашы башкачак икән. Мин моны көннән-көн ныграк аңлый барам.

Әрмәнстан белән Азәрбайҗан арасындагы хәлләрне үзегез ишетеп торасыз инде. Әмма радиолар, телевизорлар аша тыңлау бер нәрсә, ә менә шул төбәкнең үзендә яшәү бөтенләй башка. Хәзер монда безнең 7 нче Армия солдатларын Бакуга җибәрәләр икән, дигән сүзләр йөри. Андагы рус телле халыкларны «якларга» кирәк, имеш. Хәзер декабрь, 1990 елның гыйнварыннан да калмый күпмедер контингент солдатны озатачаклар, диләр. Мин моңа ышанам. Чөнки үзебезнең частьта тулы әзерлек бара. Без моңа кадәр техниканы саклау хәлендә тота идек, ягъни тәгәрмәчләргә башмаклар кидерелгән, аккумуляторы алынган, һәр машинаныңниндидер детале алып, майлап куелган иде. Ә хәзер һәрберсе хәрби әзерлек хәленә китерелде. Атнасына икешәр, өчәр тапкыр сугышчан тревога белән шушы техниканы кабызабыз. Бөтен дөнья гөрләп тора. Мондый вакытта безнең тирәдән кошлар да качып бетә.

Әти, без бит армияне тышкы агрессиядән саклар өчен дип аңлый идек. Китапларда гел шулай язалар һәм син дә шулай аңлата идең. Әгәр көннәрдән бер көнне безне Бакуга җибәрсәләр һәм шундагы тыныч халыкка атарга приказ бирсәләр, без нишләргә тиеш? Атаргамы?

Шушы уйлар мине борчый, әти.

Менә әле күземә бер газета чагылды. Анда бер мәкаләдә, соңгы дүрт-биш ел эчендә армия һәм флотта кырык меңгә якын кешенең һәлак булуы турында языла. Коточкыч хәл бит бу, әти. Бу — дүрт Әфганстан сугышы дигән сүз.

Син, әти, минем улым үлемнән курка икән дип уйлама. Юк, үлемнән курыкмыйм мин, ләкин нәрсә хакына һәлак буласың бит... Мин тыныч халыкка корал күтәрүдән куркам.

Ярый, әти, хатым озынгарак китте бугай. Хәзергә сау бул. Әнигә күптән күп сәлам. Сезне һәрвакыт сагынып — улыгыз Олег. Декабрь 1989 ел.»

Синең шушы хәвеф һәм борчу тулы хатыңны алгач та мин һаман пошынмадым. Армиянең кызыл комиссары күңелемдә яши иде әле. Сиңа мондый хат язып җибәрдем: «Улым, күңелеңдәге борчуларыңны минем белән уртаклашуың өчен рәхмәт, ләкин син буяуларны куертыбрак җибәрәсең бугай. Мин сине аңлыйм, улым. Әле син яңа җирдә ияләшеп җитә алмыйсың. Аннары шунысы да бар: хыял белән чынбарлык тартышы бара синдә. Кешенең хыяллары тормышның кырыс чынбарлыгына бәрелеп туктаусыз сынала. Нишлисең бит, уйлар белән реаль тормыш һәрвакыт туры килеп бетми. Дөресен генә әйткәндә, безгә — хәрби кешеләргә — буш хыяллар белән артык мавыгырга ярамый. Без — кушканны үтәүче кешеләр. Ә уйлау, солдатны кая җибәрү, кемгә атарга кушу — югарыдагылар эше. Әгәр инде приказ булып, сиңа кемне дә булса үтерергә туры килә икән, бу синең намусыңа тап төшермәячәк, улым. Кеше кулына корал юкка бирелми.

Ә Ватанны уртак бер шинель дип әйтүең өчен сине бераз битәрләргә туры килер, ахры. Бер факттан чыгып андый олы нәтиҗә ясарга ярамый, улым. Ватан ул — җанлы организм. Аның башы, аягы, кулы бар. Әгәр кемдер аны башсыз, аяксыз яки кулсыз итәргә тели икән — андыйларга, һичшиксез, аяусыз булырга кирәк. Тик минем иманым камил: Советлар Союзы дигән бөек ил бервакытта да таркалмаячак. Үземнең ышанычымны дәлил итеп гимн сүзләрен китерәм:

Союз нерушимый республик свободных
Сплотила навеки великая Русь.
Да здравствует созданный волей народов
Единый, могучий Советский Союз.

Моннан да яхшырак итеп әйтә алмыйм инде мин, улым. Шушы сүзләрне күңелеңнән ешрак кабатла һәм ул синең шик-шөбһәләреңне таратырга ярдәм итәр. Әгәр инде приказ белән кая да булса җибәрәләр икән — хәрби кешенең аңа буйсынмый калырга хакы юк. Тик мин тыныч халыкка каршы армия кулланачакларына ышанмыйм. Син дә тыныч бул, улым».

...Әйе, менә шундый хат язып җибәрдем мин сиңа, улым. Хәзер шуны үзем кызара-кызара укыйм. Син юкка хафаланмагансың шул: туксанынчы елның гыйнварында Бакуга гаскәр керттеләр. Танклар тыныч халыкка каршы басты. Шулар арасында синең дә булуың мөмкин иде бит. Ләкин...

Ләкин, аяз көнне яшен суккандай итеп, безгә телеграмма килеп төште. Анда: «Сезнең улыгыз лейтенант Олег Шәйхиев үзенең хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булды!» — диелгән иде. Бу хәбәрдән әниең түшәккә егылды. Ә мин, күкрәгемне йодрыкларым белән төя-төя: «Ни өчен? Кем өчен? Аның кемгә үз тормышы белән түләрлек бурычы бар иде?» — дип өзгәләндем. Бар дөньясын пыран-заран туздырасым, үч аласым килде. Ләкин кемнән?

Мин тизрәк билет юнәтеп, синең янга очтым. Җансыз гәүдәңә озак карап тордым. Синең бөтен дөньяга сокланып караган күзләрең йомылган, йөзеңдәге оялчан елмаю сүнгән, башыңда яра эзләре ярылып ята иде. Җансыз күкрәгеңә ятып, тавышсыз еладым. Гадәттә, елаганнан соң кешегә әзме-күпме җиңеләю килә, әмма мин үземдә бернинди җиңеләю сизмәдем. Тамырларыма кан урынына эрегән кургаш тутыргандай, тәнем авырайды. Кемгә барып нәрсә сорашырга белмәдем. Гүяки минем артымнан килеп бик зур күсәк белән тондырдылар да үзләре каядыр качтылар. Хезмәттәш дусларың мине төрлечә юатырга тырышты, әмма кемнең ни әйткәнен, нинди киңәш биргәнен аңламадым. Сине торгызып бастырып, табутыңа үзем кереп ятасым килде.

Әз генә һуш җыеп, сөйләшер хәлгә килгәч, рота командирың майор Супроненко янына кердем.

— Берни дә яшерми сөйләп бирегез, иптәш майор. Улым нинди хәрби задание үтәгәндә һәлак булды?

— Сез үзегез хәрби кеше,— диде майор Супроненко,— шуңа күрә мине яхшы аңларсыз дип уйлыйм. Бездә бит һәрбер задание — хәрби.

— Конкретрак, майор, конкретрак.

— Конкретрак әйткәндә, тимер юл станциясеннән йөк алырга барганда, бозлавык булу сәбәпле, машиналары тәгәри. Үзегез беләсез: бездә тоташ таулыклар. Бозлавык вакытында таулы юлларда машинаның тәгәрәве бик табигый.

— Ә бозлавык көнне җибәрмәскә мөмкин түгел идеме?

— Сез, иптәш полковник, армия тормышын белмәгән кеше кебек фикер йөртәсез. Армиядә эш һава торышына карап эшләнми. Кирәк икән, юлларың нигә анда ун кат боз белән капланмый — заданиегә чыкмый ярамый.

Безнең сөйләшү вакытында батальон командиры подполковник Сергеев килеп керде.

— Сезмени инде лейтенант Шәйхиевның атасы? — диде ул.— Таныш булыйк, иптәш подполковник.

Без аның белән кул биреп күрештек. Мин запастагы кеше булсам да, билет алганда файдасы тияр бәлки дип, хәрби киемнәремне кигән идем. Подполковник минем кайгымны уртаклашуын белдерде. Мин аңардан:

— Авариянең сәбәпләре ачыкландымы соң әле? — дип сорадым.

— Әлегә барлык сәбәпләрен ачыклап бетерә алмадык,— диде Сергеев,ә ачыкланган кадәресеннән шул мәгълүм: лейтенант Шәйхиев шоферга машинаны ашыктырырга кушкан. Алар үзләреннән алда баручы берәүне узып китәргә уйлаганнар. Шунда теге машинага бәрелгәннәр һәм шофер машина белән идарә итә алмый башлаган.

Без озак кына сөйләшеп утырдык. Аннары мин:

— Шундый бозлавыкта нәрсә алып кайтырга тиеш булган алар? — дидем.

— Анысы әһәмиятле түгел,— диде Сергеев.

— Алай димәгез,— дидем мин.— Сезнең монда кемгәдер өй җиһазлары алып кайтканда да ике кеше һәлак булган. Шундый бозлавык көндә бәлки аны чүп кенә нәрсә өчен җибәргәннәрдер.

— Армиядә чүп нәрсә юк, иптәш полковник, сез моны белергә тиеш,— диде ул.— Хәтта командирга өй җиһазы алып кайту да шәхси йомыш була алмый. Командирларның тормышын, көнкүрешен кайгырту ул — армиянең сәламәтлеге турында кайгырту. Ә сезнең улыгызга килгәндә, күңелегезгә авыр булса да әйтим, ул тиешсезен дә күрә иде. Армиядәге субординация дигән төшенчәне бик үк аңлап бетерми иде шикелле.

Бу сүзләрдән минем йөземә кызыллык йөгерде.

— Нәрсә-нәрсә, әмма андый наданлыкта минем улымны гаепли алмассыз,— дидем кызып.— Дөрес, гаделлек өчен ул кайвакыт кайбер формальлекне саклап тормастан, үзе хаклы санаган фикерне, кемнең кем булуына карамастан, шартлатып йөзенә бәреп әйтә иде...

Мин боларның кабинетыннан авыр уйлар белән чыктым. Соңгы вакытта син яшәгән тулай торакка киттем. Бүлмәңә керү белән ишеккә каршы тумбочкада кечкенә катыргы рамда шук елмаеп торучы бер чибәр кыз рәсеме күземә чалынды. «Марина!» — дип уйлап куйдым. Һәм фоторәсемне кулыма алдым. Аның артына: «Самому самому — от самой самой» дип язылган иде. Синең әйберләреңне җыештырып маташканда бүлмәгә бер өлкән лейтенант килеп керде.

— Өлкән лейтенант Артур Капутикян,— дип күреште ул минем белән.— Сезнең улыгыз Олег белән соңгы өч атнада шушы бүлмәдә яшәдек. Шәп егет иде...— Ул көрсенеп куйды, бераздан сүзен дәвам итте: — Ләкин артык гаделлек яратучан иде. Галәттә, ялганның аягы

кыска, дисәләр дә, киресенчә, гаделлекнең аягы кыскарак. Минем әле үз гомеремдә турысын әйткән кешене яратучыны очратканым юк.

Артур Капутикян бераз кызмача иде, мин моны шундук сизеп алдым. Ул салган кешеләргә хас юмартлык белән тумбочка өстенә бер ярты һәм балык консервысы чыгарып куйды.

— Сезгә бүген бушанырга кирәк, юкса аяктан егылуыгыз бар,— диде ул.— Әле Олегны юлга алып чыкканчы, билетын алганчы, тегесенмонысын җыйганчы шактый вакыт үтәчәк. Бездә бит, үзегез беләсез, синең кайгы-хәсрәтең бар дип йөгереп тормыйлар.

Дөрестән дә мин бик арыган, йончыган идем, Артур салып биргән аракыны йотып куйгач әз генә җиңеләю тойдым. Ә Артур сөйләвен дәвам итте:

— Мин үзем шушы як кешесе, Әрмәнстанныкы. Олег белән бер ротадам. Мин икенче взвод командиры идем. «Идем» дим, чөнки байтактан инде армиядән китәргә рапорт яздым. Менә-менә җавап килер дип көтәм.

— Ни өчен армиядән китәсез, сез яшь бит әле?

— Нәкъ менә шул яшь булганым өчен китәм. Яшь чакта берәр һөнәр өйрәнеп калырга кирәк. Юкса соңга калуың мөмкин.

— Армия үзе һөнәр түгелмени? Сезне бит хөкүмәт хезмәт итсен өчен укыткан.

— Төзәтергә мөмкин икән, хатаны вакытында төзәтергә кирәк, иптәш полковник. Минемчә, әле соң түгел. Менә үзегез күреп торасыз: Карабах вакыйгалары җәелгәннән-җәелә бара. Анда кем сугыша дип уйлыйсыз? Әрмән белән Азәрбайҗан халыкларымы? Юк, халыклар бервакытта да үзләре сугыш башламый. Бу — югарыдагылар эше. Ә мин үгезләр сөзешкәндә, аңгыра сарык сыман, аларның мөгез астына барып керергә тиешме? Власть башында утыручы сөзгәк үгезләр өчен без аңгыра сарыклар гына бит.

Артур тагын бераз салып куйды.

— Ә беләсезме? — диде ул аннары.— Олегның үлемендә минем дә гаеп бар.

— Ничек? — Мин сикереп тордым.

— Ничекме? Ул рейска мин барырга тиеш идем. Ни өчендер кичтән рота командиры мине үзләренә кунакка чакырды. Бераз салдык, анымоны сөйләшеп утырдык. Мине озатканда ул: «Иртәгә рейска чыкмассың. Яшь лейтенантны җибәрербез. Армиягә тугрылыгын күрсәтсен әле»,— диде.

Мин моңа бик шат идем. Соңгы вакытта кирәкле йөккә караганда башлыклар үз йомышы белән күбрәк чаба башлаганны белә идем. Командирда кунакта булып кайтканнан соң тагын бер-ике йөз грамм өстәп җибәрдем. Иртәгесен кан басымымның күтәреләчәге ачык иде... Сез инде, әлбәттә, күңелегездән мине каргап утырасыз. Улым үлгәнче бу үлгән булсачы, дисез. Сезне яхшы аңлыйм. Әмма ни хәл итәсең, шулай килеп чыкты инде.

— Ә Олег сезнең урынга рейска чыгарга үзе риза булдымы?

— Сез улыгызны яхшы беләсездер дип уйлыйм. Ул приказга каршы торган кеше түгел. Дөрес, ул гаделлекне эзли, табарга тырыша. Ләкин монда гаделлек дигән нәрсәне җиде йозак белән бикләгәннәр дә ачкычын диңгез төбенә ыргытканнар. Аны табарлык кына түгел.

Мин Артурның салган баштан сөйләгән сүзләренә бик үк ышанып җитмәсәм дә, күңелдә авыр тәэсир калды. Һәлакәткә китергән сәбәпләрне эзләргә кирәк иде, әмма хәзер вакыт юк. Сине — йөрәк парәбезне үзебез яшәгән җиргә алып кайтырга, җирләргә кирәк. Җаның рәнҗеп ятарлык булмасын, дидем.

Артур ялгызымны бүлмәдә калдырып чыгып киткәч, синең чемоданыңнан көндәлек дәфтәреңне алып укырга утырдым, улым. Көндәлек язганыңны белми идем. Күрәсең, бары тик кәгазьгә генә ышанып тапшырырдай сүзләрең булган.

«Бүген безгә тулай торактан урын бирделәр. Кечкенә генә бүлмәдә ике офицер һәм бер прапорщик яшибез. Селкенергә дә урын юк. Монда, гомумән, кая барма — кысанлык. Хәтта ике тау арасына урнашкан Кировакан шәһәре үзе дә кысанлыктан интегә кебек. Безнең дивизия составына кергән частьләрне төрле хәрби шәһәрчекләргә таратканнар. Күрәсең, бер урында дивизия кадәр дивизияне тупларлык урын юктыр. Биредә тигез җирләр юк диярлек. Безгә иң якын шәһәр Степанован — аңа 25 чакрым чамасы, ә Ленинаканга — 70 ... Шушы шәһәрләр арасында күпме хәрби частьләр. Ирексездән элек үзебез яшәгән Чиләбе өлкәсендәге хәрби шәһәрчекләр күз алдына килә. Анда да кайсы гына урманга күз салма — керергә ярамый дигән билгеләр куелган. Димәк, анда хәрби частьләр яки хәрби заводлар. Халык исә күкрәп үскән урманга ял итәргә, җиләк-җимеш, гөмбә яки чәчәк җыярга да бара алмый. Биредә дә шул ук хәл. Һәрбер тау арасы хәрбиләр белән дыңгычлап тутырылган.

Безнең ил — дөньяда иң зур урманлы, иң зур коры җирле ил, дибез. Безнең ил иң зур армияле, иң күп кораллы ил дә. Моны тора-бара аңлыйсың икән. Беркөн бик аяныч хәл булды: бер яшь спортчы дельтоплан белән очканда тыелган зонага килеп чыккан. Таудан очып карыйсы килгәндер бичараның. Аны безнең часовойлар һавада килеш үк атып төшергәннәр. Дельтоплан белән әллә каян Америкадан диверсант килмәгәнлеге бик ачык югыйсә. Бу егеткә күп булса 18 яшьләр тирәсе. Армия кешене уйламаска, бары тик әмер үтәргә генә өйрәтә, ләкин ничек кенә тырышма — башны уйлаудан туктатып булмый. Әлеге егет һич күз алдыннан китми. Кешенең бит үз гомерендә бер булса да очып карыйсы, иң биек кыяга менеп, күкрәгән җилләргә куеп ерак офыкларны күзәтәсе, үзенең зур икәнен, кодрәтле икәнен раслыйсы килә. Мәсәлән, мин үземнең урыным бары тик армиядә итеп күрә идем. Шул максатка ирешер өчен бөтенесен эшләргә тотындым. Бу егетнең максаты, бәлки, очу булгандыр.

Биредә хезмәт итә башлавыма өченче ай китте. Инде хезмәттәшләремә, мондагы тормышка күнегергә вакыт. Әмма нигәдер җан тыныч түгел. Мин күз алдына китергән тәртип юк.

Рядовойлар вакыт үтсенгә генә йөри, офицерлар эчә. Зуррак командирлар үз кабинетларыннан башын чыгармыйча яталар. Икенче взвод командиры Капутикян көннәр буе кайдадыр югалып йөри. Кичләрен бераз төшереп кайтса, төрле юк-барны лыгырдарга тотына.

— Я, — дип башлый ул сүзен, — ни пычагыма армиягә килдең инде син?

— Ә син? — дим мин.

— Мин китәм. Бу хәл ителгән инде. Моңарчы җүләрләнеп йөрүем дә җиткән. Ни калган монда миңа? Без кемне кемнән саклыйбыз? Мәсәлән, сине монда кем чакырып китергән?

— Армия ул кунак түгел, аны чакырып китермиләр. Ватан өчен безнең монда булуыбыз кирәк икән, димәк, шушында безнең урыныбыз.

— Ә кая соң ул синең Ватаның? — дип кыза башлый Артур. — Йә, әйт: синеңчә, Ватан нәрсә?

— Ватан — кешенең туган иле! Туган җире...

— Ха-ха-ха! Синең бит хәтта туган җирең дә юк. Исемен атарга да ярамаган ниндидер хәрби шәһәрчектә тугансың. Шул хәрби шәһәрчекме синең Ватаның? Син шул койма белән әйләндереп алынган исемсез ноктаны саклар өчен Әрмәнстанга килдеңме?

— Ә син үзең соң совет армиясендә түгелмени?

— Мин хатамны аңладым инде. Рапортыма кул куйганнарын гына көтәм.

— Хатамны аңласам, мин дә китәрмен. Ләкин әлегә мин үземне ялгыштым дип санамыйм.

— Юк, син беркая китә алмыйсың, синең китәр җирең юк. Мин ичмасам үземнең туган авылыма кайтып егыла алам. Авылда әти-әниләремнең таркалып баручы нигезен торгызып, шунда төпләнә алам. Ә

синең нигезең юк. Әтинең гомер буе армиядә миен череткән. Аның нигезе бармы? Сез ватансыз, илсез кешеләр. Сезнең саклар, яклар нәрсәгез юк.

Артурга ачуым килә, ләкин күңелем белән аның сүзләрендә хаклык барлыкны тоям.

— Союз таркалырга тора,— дип дәвам итә Артур,— шуны сизенгән командирлар үзләренә майлырак калҗа эләктереп калырга тырышалар. Нәрсә генә ташымыйлар алар үз ояларына...

Әйе, беркөнне үземә дә тимер юл станциясенә бер «Волга» илтеп куярга туры килде. Дивизия командиры генерал Серебряков аны Мәскәүгә улына адреслап җибәргән, диделәр. Шушы хәлне әйтер өчен беркөнне үзебезнең полк командиры полковник Павлов янына кердем. Дөрес, аңа керү җиңел булмады, бераз хәйләгә барырга туры килде.

— Иптәш полковник,— дидем,— нәрсә була инде бу? Без үз гомерләребез бәрабәренә кемнәргәдер мебель, кемнәргәдер машиналар ташырга тиешме?

Полковник, көтмәгәндә өстенә кайнар су сипкәндәй, бер мәлгә тынсыз калды. Бите, кычыткан чаккан кебек, кызарып чыкты.

Аннары ул бар көченә:

— Отставить разговоры! — дип акырды. Мин инде аның баштан сыйпап чыгармаячагын белә идем, кергәч-кергәч сүземне әйтеп бетерим дидем.

— Нинди генә пост биләсәгез дә иң элек сез — партия солдаты. Ә мин комсомолец, иптәш полковник.

— Вон! — дип акырды полковник.— Мондый фикерләр белән сез совет офицеры исеменә тап төшерәсез. Сезне бүгеннән армиядән куарга кирәк!

— Мин моны Мәскәүгә оборона министрына язачакмын,— дидем, чыгып киткәндә.

Мине армиядән кууын кумадылар, җиде тәүлеккә гауптвахтага ябу белән чикләнделәр. Шушы көннән соң минем һәр адымымны күзәтү башланды. Йөк ташу булмаган көннәрдә бүтән взвод командирларына, гадәттә, ял бирәләр. Увольнениега чыгасыңмы, ялыңны өеңдә йоклап үткәрәсеңме — ансы синең эш. Ә менә миңа ял бирү бетте. Йөк ташымаган көннәрдә каравыл начальнигы итеп нарядка чыгаралар. Һич югы автопаркка дежур итеп куялар. Мин зарланмыйм, әмма күбрәк эшләткән саен эчемдә нининдидер бунт үсеп килгәнен сизәм. Ул каршылык кайчанга кадәр һәм нинди зурлыкта үсәр — белгән юк.

Минем җибәргән хатларыма кадәр күзәтү астына алынды, күрәсең. Шулай булмаса, әтиләргә язган хатларым җавапсыз калмас иде. Димәк, барып җитми. Юкса безнең әти җавап язмый кала торган кеше түгел. Бәлки минем хатларымның аның кулына барып кермәве яхшыга гынадыр. Ул борчыла башлар иде.

Их, әти, әти! Артыгын гадел итеп тәрбияләгәнсең шул безне. Тормышка яраклашуы, ай-һай, авыр. Ә башка юл юк — йә яраклашасың, йә сине юлдан алып ташлыйлар...»

Көндәлек шушында бетә.

Көндәлегең белән танышып чыккач, улым, күңелемдә шикләр уянды: синең үлемең очраклы гына булмагандыр, күрәсең. Мин моны тикшерәчәкмен әле. Мотлак тикшерәчәкмен...

* * *

Әйе, җәсәдеңне үзебез яши торган Пермь шәһәренә алып кайтып күмгәннән соң, яңадан хәрби частеңа юнәлдем. Рота командирыңа кердем.

— Авариянең сәбәпләре ачыкландымы инде? — дип сорыйм.

— Ачыкланды,— диде рота командиры.— Беренчедән, машинаның тормозы начар тоткан, икенчедән, машина капланганда кабинадагы бер тимер улыгызның арт чүмеченә китереп бәргән. Шул тимер бәрелмәсә, бәлки, исән калган булыр иде.

— Ә бит юлга чыгарга тиешле машинаның төзеклеген сез тикшерергә тиеш. Тормозы рәтләп тотмаган машинаны рейска чыгарырга сезнең хакыгыз юк иде, майор.

— Артык күп беләсез, полковник. Улыгыз үзегезгә ошаган булган икән.

— Әйе, мин улымны дөреслекнең күзенә туры карарга өйрәттем.

— Ләкин хакыйкать сез уйлаганча гына түгел. Ул катлаулырак. Төзек түгел машинаны рейска чыгарырга минем башыма тай типмәгән лә! Тормозы юлда бозылуы мөмкин түгелмени аның?

— Мөмкин. Әмма, өлкән лейтенант Капутикян әйтүенчә, ул машинаның тормозы моннан бер атна элек үк тотмый башлаган булган. Шофер тормоз шлангысын алыштыруларын сорап техник частьләр командирына мөрәҗәгать иткән. Ул кул гына селтәгән: янәсе моңарчы йөргән бит, моннан соң да йөрер. Кыскасы, улымның үлүендә турыдан-туры сез гаепле, майор Супроненко.

— Кемнең гаепле, кемнең гаепсез икәнен суд күрсәтер. Телисез икән — судка бирегез.

— Әлбәттә, бирәчәкмен. Бу килеш кенә йомып калдырырга вөҗданым да, һәлак булган улымның истәлеге дә рөхсәт итмәс.

Майор чыгарга кузгала башлады.

— Туктагыз әле, майор,— дидем мин.— Ә кабинадагы өченче кеше кем иде?

— Нинди өченче кеше? Кем әйтте аны сезгә? — диде ул тынычсызлана башлап.

— Кем әйтүе мөһим түгел, әмма өченче кешенең булуы хак. Мин ул кешене табып, судка шаһит итеп китерәчәкмен. Сез нәрсәнедер миннән яшерәсез.

— Яшермибез. Нигә яшерик.

— Алайса шофер кайда соң?

— Шофер авария вакытында җәрәхәтләр алган, госпитальгә озаттык.

— Кайдагы госпитальгә? Мин аны эзләп табарга тиеш.

— Милләте буенча ул чечен иде бугай, күрәсең, туган ягына җибәрелгәндер. Авыру кешегә кайчак туган як һавасы дарудан шәбрәк килешә.

— Шулай да сезгә кабинадагы өченче кеше турында исегезгә төшерергә туры киләчәк.

— Карагыз әле,— диде майор,— сез нишләп әле миннән сорау алып утырасыз? Ни хакыгыз бар? Моңынчы сезгә җавап биргәнмен икән: сезнең чал чәчләрегезне һәм погоныгыздагы йолдызларыгызны ихтирам итеп кенә иде. Инде сүзем бетте, хушыгыз.

Мин урамга чыктым. Кая барырга? Теге өченче кешене ничек табарга? Миңа өченче кешенең барлыгын автопаркта ул көнне дежур торган офицер әйткән иде. Ул һәр машинаның путевой листогын тикшереп чыгаручы. Шунда күреп калган.

Мин аны эзләп киттем. Ләкин аңа «әйбәт хезмәт иткән өчен» дип, чиратсыз ял биргәннәр. Һәм ул путевка белән каядыр китеп барган булып чыкты.

— Җепнең очын оста яшерәләр,— дип уйладым. Эшне судка гариза язудан башларга кирәктер, мөгаен. Юкса вакыт үтә. Мин Шерлок Холмс түгел. Үзем генә ерып чыга алмам. Ә мондагы командирларга чүпне читкә чыгармау хәерле. Полковник Павлов төлке кебек хәйләкәр. Әфганстанда да булган. Менә-менә генерал итүләрен көтә, ди. Шундый вакытта ничек инде ул үзенең шухыр-мухырларын ачарга ирек бирсен?

Мин ул чакта әле судларның гаделлегенә әзме-күпме ышана идем. Кировакан шәһәренә урнашкан хәрби гарнизон судына гариза кертеп бирдем. Суд эшне караганчы монда көтеп ятуда мәгънә юк иде, яңадан улым хезмәт иткән частька киттем. Хакыйкатьне бары тик шуннан гына табарга мөмкин кебек тоела иде миңа. Ләкин мине хәрби частька кермәделәр. Капкада торучы солдат: «Чит кешеләрне кертергә ярамый!» — дип юлыма аркылы төште. «Мин бит күптән түгел һәлак булган лейтенант Шәйхиевнең атасы, менә паспортым»,— дип карадым, ләкин солдат сүзендә нык торды. «Лейтенант Шәйхиевнең атасы түгел, полк командирының атасы булсагыз да кертмәскә куштылар».

Миңа борылып китүдән башка чара юк иде. Нишләргә белми аптырап торганда эчтән Артур Капутикян килеп чыкты.

— О-о, полковник! — диде ул, колачын җәеп.— Мин бит сезне югалттым.

Мин үземнең судка гариза бирергә баруымны сөйләдем.

— Ә минем сезгә бер яңалыгым бар,— диде ул, мине читкәрәк алып китеп.— Машинадагы өченче кешенең кем икәнен белдем мин.

— Кем? Ничек белә алдыгыз?

— Ничек белүем мөһим түгел. Анысы сер. Ә кем? дигән соравыгызга җавап бирәм: ул сезнең улыгыз белән рейска чыккан Үтәлиевнең бер дусты икән. Төрмәдән качып дусты янына килгән булган.

— Ничек соң ул хәрби частька керә алган?

— И-и, бала-чага кебек фикер йөртәсез. Монда күреп торасыз бит, бардак, төрмә тиклe төрмәдән кача алган икән, димәк, монда гына керә ала инде ул. Аннары шунсы бар: хәрбиләр арасында төрмәдән качкан кеше булыр дип беркемнең дә башына килми.

— Ничек табарга икән соң аны?

— Әйе, табу җиңел түгел, аны инде яңадан үз урынына — төрмәгә илтеп тыкканнар.

— Хәрби төрмәгәме?

— Юк, гражданскийга.

— Карале, Артур, миңа бит аны кичекмәстән күрергә кирәк.

— Ә-ә, онытып торам икән,— диде Артур,— мине котлый аласыз: кеше каны белән туенучы армия дигән аждаһадан котылдым. Мин бүгеннән ирекле кеше.— Мин аның кулын кыстым.— Сезгә, кулдан килгәнчә, ярдәм итәргә тырышырмын. Тиздән машина белән минем энем килеп җитәргә тиеш. Башта безгә кайтыйк, шунда бик шәп итеп уйлашырбыз.

Дөрестән дә, Артурны алырга энесе килде. Без аның энесенең «Волга»сына утырып Артурларга киттек. Юлда Артур бер урында машинаны туктатты.

— Иптәш полковник,— диде ул,— менә шушында һәлак була инде сезнең улыгыз. Аларның машинасы, тәгәрәгәннән соң, әнә теге ташка килеп бәрелә.

Без ул урыннарны озаклап карап йөрдек. Киткәндә кайбер җирләрне фотога төшереп алдым. Инде кузгалабыз гына дигәндә Артур болай диде:

— Туктагыз әле, иптәшләр, армиядән исән-имин котылсам, аны искә төшерүче барлык әйберләрне ут төртеп яндырырмын дигән сүзем бар иде. Бүген шул сүзне үтәр көн җитте. Әйдәгез әле, менә монда учак ягып җибәрик.

Без аның энесе белән чыбык-чабык җыйган арада Артур анадан тума чишенеп ыргытты. Өстенә энесе алып килгән киемнәрне киеп алды. Учак дөрләп яна башлагач, эчке бер ләззәт белән, киемнәрен берәм-берәм учакка ташлый торды. Янып беткәненә тәмам ышангач кына моннан кузгалып киттек. Армиядән котылуына бу кадәр шатланган кешене беренче күрүем иде әле. Моннан берничә ел элек булса, мин аның, һичшиксез, якасына барып ябышкан булыр идем. Әмма минем бүгенге хәлем Артурныкына бик охшаш иде.

Без Артурларга кичкә таба гына кайтып төштек. Аны зурлап көтеп торганнар. Бөтен авыллары җыелган. Баштарак минем иңдәге полковник погоннары аның туган-тумачаларын, дус-ишләрен бераз сагайткан иде, ләкин Артур минем белән таныштыргач, шикләре бетте.

Мәҗлес төне буе барды.

Икенче көнне Артур:

— Хәзер инде безгә кайбер стратегик планнар белән шөгыльләнергә вакыт,— диде.— Безнең монда ике төрмә бар. Берсендә, гадәттә, рецидивистлар утыра. Безнең «дустыбызны» шунда яшереп куюлары мөмкин.

— Ул «дустыбыз»ның исеме ничек соң?

— Әйтмәдеммени әле мин сезгә. Әгәр дөрес булса — Азизбәк Угланов. Ләкин андый кешеләрне исемнәренә караганда кушаматлары белән ныграк беләләр. Кушаматы «Күсәк» икән. Күрәсең, үзенең корбаннарына пычак ише нәрсә белән түгел, күсәк белән ташлана торган булгандыр.

Без Артур энесенең машинасы белән төрмәгә киттек. Артур миңа машинадан чыкмаска кушты.

— Без монда үзебез сөйләшеп карыйк әле,— диделәр алар һәм кулларына калын портфель тотып, төрмәгә таба киттеләр. Сакчы белән берничә сүз алышуга, эчкә уздылар. Ә бераздан балкып килеп чыктылар.

— Булды,— диде Артур,— эшләр пеште. Сезне хәзер «Күсәк» янына кертәчәкләр. Ләкин, иптәш полковник, сезгә бу киемнәрегезне алыштырырга туры килер. Хәрби кешеләргә аның нәфрәте зур, диделәр.

Алар баштан ук моны күз алдында тотканнар икән, багажниктан миңа кием алып бирделәр. Борын астына кара мыек чәпәделәр. Бу киемнәрне киеп җибәргәч, Артурларга ошый башлавымны күрдем.

— Унбиш минут вакыт сезгә,— диде төрмә начальнигы, мине керткәндә.

«Күсәк» аерым бүлмәдә мине көтеп тора иде инде. Мин аңа үземнең кем икәнлегемне әйттем. Һәм:

— Бары тик бу эштә син генә ярдәм итә алачаксың,— дидем.— Сөйлә, зинһар. Бу авария нилектән килеп чыкты? Очраклы хәлме бу? Яисә махсус оештырылган эшме?

«Күсәк», сөйләргәме-юкмы дигәндәй, ык-мык килеп торды. Мин аңарга: «Мин сине буш итмәм. Сөйлә генә»,— дип, ялварулы карап куйдым.

— Ярар, сөйләрмен,— диде ул авыр гына.— Ләкин сезнең акчагыз өчен түгел. Минем алардан үземнең үч аласым бар. Бәлки, моны сез башкарып чыгарсыз. Ә эш болай булды: декабрьнең сигезе көнне гражданский киемдәге ике кеше төрмәгә килеп, мине хәрби гарнизонга алып китте. «Кая алып барасыз?» — дигән соравыма җавап бирмәделәр. Анда мине бер бүлмәгә ябып куйдылар.

Бераздан яныма сары чәчле, сул битендә әз генә җөйле гражданский киемле кеше керде.

— Төрмәдән котыласың киләме? — дип сорады ул.

— Кемнең инде аннан котыласы килмәсен, гражданин начальник,— дим.

— Әгәр безгә ярдәм итсәң, сине ул дию пәрие авызыннан йолып алырга сүз бирәм. Син шул эшкә әзерме?

— Нинди эштер бит, гражданин начальник.

— Иртәгә тимер юл станциясенә бер «КамАЗ» барачак. Шофер янына машина экипажының командиры — бер лейтенант утырган булыр. Юлда менә шул лейтенантның башына житәргә кирәк. Син «КамАЗ»ның арткы кабинасына утырырсың. Кулыңа берәр тимер кисәге ал. Хәер, сине мондый эшкә өйрәтеп торасы юк инде. Йә, ничек?

Минем мондый «юеш» эшләр белән шөгыльләнгәнем юк иде, икеләнеп калдым. Җөйле бәндә минем алдыма бер төргәк акча ыргытты:

— Хатының, балаң бар икән. Шуларга җибәрерсең, берәр җиренә тыгып куй.

Төргәк ярыйсы гына саллы иде. Ләкин акча керә дә чыга — миңа ирек кирәк иде.

— Ярар,— дидем төргәкне куенга кыстырып.— «Эш»не эшләдем, ди. Ә төрмәдән котылуны миңа ҡем гарантияли?

— Дөрес сорау. Без анысын да уйлап куйдык. Ул машинаның шоферы Үтәлиев дигән егет. Бүген сез менә бу бүлмәдә аның белән кунарсыз. Тегенди-мондый сорау бирүче булса: син Үтәлиевның иң якын дусты. Шуны онытма. Гарантиягә килгәндә, менә монда сине вакытыннан алда азат итү турында кәгазь.

Ул кәгазьне күрсәтте. Анда чынлап та акка кара белән «үрнәк тәртибе өчен вакытыннан элек азат ителә»,— диелгән һәм түгәрәк пичәт сугылган иде.— Бу кәгазьне бүгеннән үк үзеңә бирә алам.— Ул кәгазьне миңа сузды.

— Бу эш бик табигый эшләнергә тиеш,— диде ул, янә кисәтеп.— Яки авария оештырырга, яисә ялгыш кабинадан төшереп калдыруны инсценировать итәргә кирәк. Башыңны төне буе эшләт. Тик кара аны: эшне эшләмәгән килеш качарга уйласаң — башың бетте диген.

Мин ул кадерле кәгазьне кесәмә яшердем. Үтәлиев янында кундым. Тик аңа үземнең заданием хакында сөйләп тормадым. Чөнки теге кеше шулай кушкан иде.

Икенче көнне иртән машина кузгалганчы ук кабинага гаражда аунап ятучы бер иске стартерны чүпрәккә төреп салып куйдым. Моның белән арт чүмеченә кундырсаң, тимер баш та ярылачак иде...

Мин «Күсәк»не буар дәрәҗәгә җитеп тыңладым. Ләкин кызарга ярамый иде. Ул дәвам итте:

— Юлга чыктык. Юллар шактый бозлавык иде. Мин җайлы чакны туры китерергә чамалап барам. Юлга чыгар алдыннан сезнең улыгыз шофердан:

— Бу кем? Ни өчен машинага чит кеше утырттыгыз? — дип төпченде. Шофер аңа:

— Бу минем авылдашым, өенә кайтып бара. Кешегә ярдәм итәргә кирәк бит инде,— диде.

Лейтенант бүтәнчә сорау бирмәде.

Мин, юлга чыгып бераз бару белән, артыбызга бер «Волга» тагылганын шәйләдем. Ул — без әкренәйсәк, әкренәйде, шәбәйсәк — шәбәйде. «Эшнең үтәлешен тикшерәләр»,— дип уйладым. «Волга»да дүрт кеше утыра иде. Бу «Волга»ның безнең арттан бер тотам калмый килүен лейтенант та күреп алган икән, ул шоферга:

— Болар җирле боевиклар түгел микән? Нигәдер шикле күренәләр,— диде.— Безнең машинада корал бар дип һөҗүм итүләре мөмкин. Болардан эзне яздырырга иде.

— Ничек? — диде шофер.

— Әнә, алда бер йөк машинасы бара. Теге борылышта син шуны узарга тырыш. Безнең арада бүтән машиналар булса, һөҗүм итәргә батырчылыклары җитмәс.

Шофер алдагы машинаны уза башлады. Ләкин каршыга килүче бер машинаны күргәч кинәт уңга алды. Безнең машина алда баручы «Татра»га бәрелде. Мин, үземә иң уңайлы вакыт килеп җиткәнен тоеп, аяк астымдагы чүпрәккә төрелгән стартер белән лейтенантка кундырдым. Селтәнгәндә кулым шоферга да эләгеп китте. Аның кулы рульдән ычкынды. Шул арада безнең машина асфальт читенә тәгәрәде. Шофер белән миңа берни булмады, ә лейтенант, тотынып калыр хәле калмаганлыктан, алгы тәрәзәдән чыгып очты. «Эшне» моннан да шәбрәк итеп эшләү мөмкин түгел иде. Бөтенесе бик табигый килеп чыкты. Инде бу тирәдән тизрәк таярга кирәк дип, кесәдәге кәгазьне капшап куйдым. Ләкин, без һушка килгәләгәнче, теге «Волга»дагы егетләр шофер белән минем кулны боргычлап алырга өлгерделәр. Ыңгырашып яткан лейтенантка әһәмият бирүче булмады. Иң беренче итеп минем кесәдәге «коткару кәгазен» алып, ертып аттылар.

Безнең капланасыбызны белгәндәй, тиздән «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп чыкты. Машинага салганда улыгыз исән иде әле, ул миңа таба күрсәтеп нидер әйтте. Күрәсең, аңа теге дөньяга китәргә «ашыгыч ярдәм» кешеләре ярдәм иткәндер.

Менә шул. Ә мине кире үз урыныма китереп тыктылар. Боларны мин сезгә нигә сөйләдемме? Тегеләрнең сүздә тормауларына ачу итеп. Җенем сөйми алдаган кешеләрне. Андыйларны монда бер көн дә яшәтмәсләр иде.

Ул сөйләүдән туктады. Мин бу кешегә ачулы да, шул ук вакытта дөресен сөйләве өчен рәхмәтле дә идем. Ул минем уйларымны сизгәндәй: «Мин баш тартсам — улыгызны бүтән кешедән үтертерләр иде. Андыйлар максатларыннан чигенмиләр,— диде...

Әйе, бик дөрес. Теге сул як битендә җөе булган сары чәчле кеше, әлбәттә, полковник Павлов. Яңагындагы җөй белән ул: «Бу минем Әфганстаннан алып кайткан орденым»,— дип мактанып та йөри, диделәр.

— Мин моны бу килеш калдырмаячакмын,— дидем мин,— ләкин миңа синең ярдәмең кирәк булачак.

— Нинди?

— Судка шаһит итеп чакырсалар, шушыларны сөйләрсеңме?

— Сөйләрмен. Нигә сөйләмәскә?

Безнең очрашу шуның белән тәмамланды. «Күсәк»не алып чыгып киттеләр. Мин Артур белән энесенә эшнең ничек булуын сөйләп бирдем. Артур үзен-үзе битәрләп: «И мин-аңгыра. Бу аварияне очраклы хәл дип уйладым. Белә идем бит югыйсә монда еланнар оясы икәнен». Без бергәләп уйлаша торгач, яңа дәлилләрне өстәп, судка икенче гариза язарга кирәк дип таптык.

Өйгә кайткач, Артур: «Карагыз әле, иптәшләр,— диде,— без бер нәрсәне онытып җибәргәнбез бит».

— Нәрсәне?

— «Күсәк» сөйләгәннәрне язып барып, аңардан кул куйдырып алырга иде безгә. Судка биргән гаризаңа шул дәлилләр өстәлсә тегеләрнең чигенерлек җирләре калмас иде.

— Иртәгә язып алырбыз,— дидем мин, беренче көнемнән бик канәгать калып. Башымда искиткеч планнар туды. Бу хәрби частька оялаган жуликлар өнен туздырам болай булгач. Армия йөзенә ыргытылган пычрак бит болар. Генштабка кадәр барып җитсәм җитәрмен, әмма бу елан оясын туздырырмын. Бәлки, шофер Үтәлиевне дә эзләп табып булыр.

Төнне мин көчкә генә уздырдым. Икенче көнне Артур белән иртүк төрмәгә киттек. Ләкин безне эчкә уздырмадылар. Дежурный:

— Төрмә начальнигы өйдә юк, беркемне кертә алмыйм,— диде.

— Начальнигың кайчан кайта соң?

— Алар безгә докладывать итеп йөрми, кайчан кайтасы килсә — шунда кайтыр.

Без төрмәгә атна буе көн саен бардык. Ниһаять, начальникны күрү бәхетенә ирештек. Ул, ниндидер шатлыгы бар кеше сыман, безне күтәренке күңел белән каршылады. Без исәнлек-саулык сорашкач, йомышыбызны әйттек.

— «Күсәк?» — дип торды ул бераз, кем турында сүз барганын белмәгән кебек. Аннары исенә төшергәндәй: «Ә-ә,— диде,— кызганыч, әмма сезне аның белән очраштыра алмыйм».

Артур портфеленнән зур гына төргәк акча алып, аңа сузды. Начальник, акчаны кулында сикерткәләп: — Кызганыч, ләкин бу мөмкин эш түгел,— диде.

— Ни өчен?

— Чөнки китте ул моннан.

— Кая китте?

— Ерак, бик ерак.— Начальник авыр сулап куйды: — Теге дөньяга ук китеп барды, бичара. Гөнаһлары артык зур иде шул.

— Ничек? Ул бит әле тап-таза иде,— дидем мин.

— Үзенә үзе кул салган, бичара!

Бу сүзләрне ишеткәч, баскан урынымда җир убылгандай булды. Без башларны түбән иеп чыгып киттек.

— Күңелем сизенгән иде аны,— диде Артур.— Андый шаһитны дөньяда яшәтмиләр инде, билгеле. Аның белән очрашуыгызны да «тегеләр»гә җиткергәннәр, димәк.

— Хәзер бердәнбер шаһит — шофер Үтәлиев кала,— дидем мин.

— Ай-һай, аны эзләп таба алырсызмы икән? — диде Артур.— Үтәлиевны дәваланырга җибәрдек, дигән сүз чеп-чи ялган бит ул.

— Ул бит сезнең взводтан, бәлки сез аның адресын беләсездер.

— Безнең бу авторотаны күптән түгел оештырганнар иде бит. Взводтагы шоферлар гел алышынып торды. Бәлки, бу махсус эшләнгән эш булгандыр. Хәер, Үтәлиев бервакыт үзенең Бакудан икәнлеген сөйләгән иде миңа. Баку хәрби Комиссариатына телеграмма сугарга кирәк. Һәм бүген үк.

Артурның зирәклегенә һәм миңа ярдәм итәргә атлыгып торуына шатланып куйдым. Шунда ук хәрби комиссариатка ашыгыч телеграмма суктык. Ә берничә көннән безгә мондый җавап килде: «Үтәлиев Гейдар Мамед оглы хәрби хезмәтен тутырып өенә кайтканда, поезд астына эләгеп, һәлак булды».

Мин, эчәргә дигән даруын кулыннан төшереп түккән авырудай, гаҗиз калдым. Бетте, бөтенесе бетте! Елан оясын туздырып булмады.

— Аларга безнең теш кенә үтми, туганкай,— диде Артур, мине юатып.

— Әллә генштабка барып карыйм микән? — дидем мин.— Бәлки комиссия җибәрерләр, тикшерерләр.

— Алай наив булмагыз инде,— диде Артур.— Балык башыннан чери дигән сүзләрне ишеткәнегез бардыр бит. Генштабтагыларның да авызы бар. Ә авызы барның авызына ни салырга белә инде алар. Моннан вагон-вагон әйбер китә икән, ул әйберләр бит урам хәерчесе өчен җибәрелми. Аларның һәрберсенең адресы бар.

Моннан соң Артурларда калуда мәгънә юк иде инде. Башымны түбән иеп, үземнең көчсезлегемә, язмышның шулкадәр гаделсезлегенә ачуым килде. Үземне-үзем өзгәләп ыргытыр дәрәҗәгә җиттем, хәтта, башымнан: «Әллә соң поезд асларына ташланыйм микән?» — дигән уйлар үтте. Ләкин минем моңа да көчем юк иде. Артур миңа: «Күңелегезгә авыр алмагыз,— диде,— ләкин сезнең үзегезгә дә бу тирәдә озак калырга ярамас. Башыгызга җитүләре мөмкин. Болар — мафия. Ә мафиянең иң куркынычы — армиядә. Чөнки армиядә — корал, үтерергә махсус өйрәтелгән кешеләр».

Артур белән килешми мөмкин түгел иде. Шулай итеп, улым, язмыш минем башыма олы күсәге белән тагын бер кат тондырды.

* * *

Улым! Дошманнарыбыздан үч ала алмавым өчен синең алда бик гаепле мин. Кулдан килгәнчә тырышып карадым, хәтта президентка, оборона министрына хатлар яздым. Ләкин аларда кеше кайгысы булмаган икән. Моны үзебез табынган уртак Ватан таркалгач кына белдек. Кеше кадере юк илдә дөреслек була алмый икән. Мин шуны аңладым. Үч алыр өчен дә иң элек күзләрнең ачылуы кирәк иде. Без табынган түрәләрне заман үз куллары белән кыйнатты. Бәлки бу безнең кебек рәнҗетелгәннәрнең каргышы төшү булгандыр. Инде менә безнең дә кайтыр көнебез килеп җитте. «Кая кайтасыз?» — дисеңме. Ата-бабаларыбызның тамыры калган якка. Дөрес, безнең анда нигез юк инде. Җил очырып алып киткән дүңгәләк кебек, туган нигезебездән без артык ерак

киттек. Ә җил-давыллар иң башта тамырсызларны очыра. Мин хәзер еш кына үземә шундый сорау бирәм: ни өчен язмыш безгә мондый рәхимсез булды? Һәм соравыма үзем үк җавап табам. Әлеге дә баягы шул — тамырсызлыктан. Искәргәнең бардыр, улым, беренче карашка зәгыйфь кенә күренгән гөлләр дә әллә нинди җил-давылларга түзә, чөнки алар тамырлары белән үзләре үскән җиргә ябышкан. Менә мин үземнең әти-әниләремне генә алам. Аларны бер яктан ачлык-хәерчелек яңаклады, икенче яктан хокуксызлык һәм талаулар, өченче яктан мыжлап торган бала-чага. Ләкин алар бирешмәде. Чөнки аларның таяну нокталары бар иде. Ә безне җир түгел, йолдызлар күбрәк кызыктырды. Йолдызларның да күктәгесе түгел, иңнәребездәгесе. Погоннарыбызда йолдызлар арткан саен югарырак күтәрелдек, дип уйладык. «Без» дип әйткәнемә үпкәләмә, улым. Мин монда үзем һәм үзем кебекләр турында сүз алып барам.

Хәзер үзебез наданга санап йөргән әти-әниләребезнең гомере белән үзебезнекен чагыштырып карыйм: алардан нәрсә калды да бездән нәрсә калды? Әтиемнең салган йортлары, чыгарган мичләре әле һаман бар. Ул йортларда кешеләр яши, бала-чагалар үстерә. Морҗалары һәркөн төтен чыгарып яңа көнне сәламли. Ә иң әһәмиятлесе — алар авыл халкы күңелендә. Кем белән генә сөйләшмә — кем баласы икәнеңне белеп алуга, сиңа хөрмәт, ихтирам артканын тоясың.

Ә бездән нәрсә калды?

Без изге һәм какшамас дип санаган Ватан таркалды. Теге вакытта син СССР дип аталган бөек державаны иске шинельгә тиңләгәч, сиңа хәтерем калган иде. Хәзер синең хаклы икәнлегеңә тулысынча ышандым. Ул иске шинельне төрле якка тарткалап кына калмадылар, өзгәләп үк бетерделәр. Кемгә якасы, кемгә җиңе, кемгә итәге эләкте. Без менә шушы иске шинель астында кояшны, йолдызлы-айлы күкләрне, офыклар киңлеген күрмичә яшәгәнбез. Безгә шул ертык шинель тишегеннән төшкән яктылык җиткән. Ә инде кемнәрдер артыграк үсеп бу шинельгә сыймый башласа — Прокруст ятагына сыешмаган бәндәнең башын яки аягын кисеп ятак белән тигезләгән кебек — озыннарны кыскарта барганнар.

Син, улым: «Нишләп, әтием, моңарчы бу кадәр сукыр булдың? Боларны элегрәк күрмәдең?» — дигән сорау бирергә хаклы. Безнең халыкта шундый бер әйтем бар: майны күп ашама — сукыраерсың, диләр. Мин моның мәгънәсенә төшенми идем. Ничек инде майны күп ашаганга кеше сукырайсын, ди. Баксаң-күрсәң, моның бик тирән эчке мәгънәсе бар икән. Нинди эчке мәгънәме? Менә болай, улым. Безне сукырайтыр өчен югарыдагылар безгә май каптырып килгән бит. Һәр елны иң яхшы курортларга бушлай путевкалар бирү дисеңме, илнең кайсы гына почмагына барып чыкма — югары класслы кунакханәләрдә урын әзерләп кую дисеңме, кешеләр аэропортларда, вокзалларда барасы җиренә билет ала алмыйча куна-төнә ятканда түш киереп иң яхшы урыннарда җәелеп утыру дисеңме — болар һәммәсе безнең күзләребезне сукырайту өчен бирелгән май кисәге булган. Без, беркатлылыгыбыз белән, аларны хезмәтебезгә хөрмәт дип кабул иткәнбез. Хәтта үзебезне башкалардан өстен саный башлаган идек. Дөрес, мин намусыма тап төшермәскә тырыштым. Хәзер аңлавымча, партиягә безнең кебек беркатлы, үзләренә фанатиклар-ча бирелгән кешеләр кирәк булган. Үзләренең пычрак эшләрен дә алар чиста куллы, намуслы кешеләрдән эшләтергә тырышканнар. Шунсыз алар халыкны ышандыра һәм власть башында җитмеш ел утыра алмаслар иде. Халыктан бигрәк үз мәнфәгатьләрен кайгыртучы партиянең бер рупоры булуым бүген минем җанымны туктаусыз кимереп тора. Икенче нәрсә — биеклек белән түбәнлекне бутау. Үз халкыннан ныграк ераклашкан саен биегрәк күтәреләсең, дип уйладым. Сиңа да бабаңнар телен өйрәтмәдем. Кирәкмәгән тел белән күңелеңне чүпләмим, дидем. Туган-үскән якларыма сирәк алым кайттым.

Соң булса да уң булсын дип, инде менә бабаларың янына алып кайтам. Чит-ят туфракларда сөякләрең рәнҗеп ятмасын. Үзебезнең йола-

ларыбыз белән, догалар укып, чын мөселманча итеп җирләячәкбез сине. Кешеләр исән чакта гына түгел, үлгәч тә үзенең нәсел-нәсәбенә якын булырга тиешләр. Шунда гына аларның җаннары тынычлык табачак. Ә җан барлыгына мин хәзер ышана башладым, улым. Еш кына битемә ниндидер йомшак җил кагылып киткәнен сизәм. Һәм шул ук минутта исемә син килеп төшәсең. Колагымда: бу мин, әти, дигән сүзләр ишетелгәндәй булды. Кешене аллага кайгы-хәсрәт тә якынайта икән. Әгәр дөнья тоташ шатлыктан гына торса, кешеләр алланы да, намусны да, әдәпне дә онытырлар иде. Бүген мин кайчандыр үзем ераклашкан нәрсәләргә якынаю сизәм. Үткәннәремә, тамырыма, асылыма кайтам. Бу бик авыр кайту, әлбәттә. Чөнки мин үземне сине югалту бәрабәренә таптым.

Әйдә, улым, юлга чыгыйк. Безне туган туфрагыбыз көтә...

*Кәгъбә куренешләре*
**Абдулла ДУБИН***ның*
*фотоархивыннан алынды.*

<<<<<

*Алдагы санда укыгыз*

## Хәсән Хәмидулла

# ТӘКЪДИР КАРШЫНДА

(БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫ ВАКЫЙГАЛАРЫННАН)

...Хөсәен тиз генә сикереп торды да тавыш ишетелгән якка китте. Озак та үтмәде, шул җиргә якынаеп, тавыш иясенең ыңгырашуын ап-ачык ишетә башлады. Ул инде төрле сугышларда йөри-йөри чыныгып беткәнгә, андый-мондый тозак, хәйлә-фәләннәрдән курыкмый иде. Ерак та бармыйча, ул бөек бер фаҗига каршында катып калды. Ике урман арасында кискә кебек кире сунга яткан ике кулсыз, ике аяксыз хәлдә чия кан эчендә бер кеше! Хөсәен тиз генә аның янына йөгереп барып аны күтәрергә уйлады. Ләкин бөтен җире кан вә туфраклар белән болганып беткәнгә, тотар җире юк иде. Шулай ук аның, киеменә карап, кайсы як гаскәре идекен дә танып әйтерлек түгел иде.

Хөсәен куллары белән аның яраларын тоткалап бакты да:

— Син мажармы, алманмы, урысмы? — дип сорады.

— Мин дә синең кебек үк урыс гаскәреннән булам. Бүген иртәнге һөҗүмдә, туп ядрәсе төшеп, менә шундый хәлгә килдем. Зинһар, мине, Алла ризасы өчен, тиз генә ат, әрнүемә чыдар хәлем юк, — дип ул абауларга тотынды, газапланып чыраен сытты.

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

**Бу өзек Финляндиядә яшәп иҗат иткән татар әдибе Хәсән Хәмидулланың повестеннан бирелде. Андагы фаҗигаи, гыйбрәтле хәлләр сезне дә, һичшиксе(з), битараф калдырмастыр.**

# ШИГЪРИЯТ



## Рифә Рахман

### Җилле төн

Ошыйммы... ошамыйм — барыбер.
Тормачы үпкәләп, ишелеп.
Син — исеп үтәр бер җил генә,
Китсә дә күлмәгем чишелеп,

Кулларым төймәләр, дерелдәр,
Изүем ачылыр кабаттан.
Син — кочар, үбәр бер җил генә,
Сагынып еларлык яратмам.

Ошыйммы, ошамыйм — барыбер.
Син — исеп үтәр бер җил генә...
Үзем дә үрелсәм, качасың,
Капласам, керәсең изүгә.

### Синең хактагы уй

Сорамый килгәнгә, шулайдыр —
Бу уем икеле-микеле.
Елмая, бернәрсә аңлатмый,
Елмая нәкъ синең шикелле.

Бер килә, бер китә үчегеп.
Беркемне тыңламый, ишетми.

---

Рифә РАХМАН (Харрасова) — *Казанда яшәүче яшь галимә. Г. Исхакый иҗатын өйрәнүчеләрнең берсе. Шигырьләре көндәлек матбугатта даими басыла килә.*

Син дә бит, акылдан яздырып,
Ачасың, ябасың ишекне.

Икеле-микеле бу уем,
Сәбәбен мин сиңа аңлатмыйм.
Ачасың, ябасың ишекне...
Шуңа да мин аны яратмыйм! —

Икеле-микеле бу уем.
(Тәкәббер!) бер килә, бер китә.
Йә үтә каранып як-якка,
Үчегеп шакый да ишеккә...

## Иясез кош

Торма карап, менә без дә бар, дигән күк,
Ярсызга яр, парсызга пар булыр өчен.
Тезләремә генә тигән кулыңнан да
Киемемне җил очырган төсле өшим.

Торма карап, караучылар бар да бит ул...
Кош кунмаган чәчәк була димени соң?
Бакчаларда инде җимеш өлгергән чак...
Синең кулга коелмас та, боегырсың.

Белеп торам, күреп торам күзләреңнән.
Менә без дә бар, дигән күк, торма карап.
Күкрәгемә генә тигән карашың да
Этә мине, этә синнән ераккарак.

Мин китәрмен, син калырсың өметләнеп.
Шул өмет күк, артларымнан сузылырсың.
Кулъяулыкны ыргытсам да, төшмәс сиңа.
Яшьләреңне мин сөртер күк, ник елыйсың?

## Ярат ла соң...

Сөю гөнаһ түгел, түгел, ярат ла соң.
Миңа гына була күрче мәрхәмәтле:
Җырларыма салып үтмә авыр моңнар,
Уйный күрмә, уйный күрмә мәхәббәтле.

Өзелергә генә торган ул сазымның
Шаярып та тарта күрмә кылларыннан.
Алырсың да кояшымны күзләремнән,
Көннәремне төннәремә ялгый алмам.

Сөю гөнаһ түгел, түгел, ярат ла соң;
Бәлки чынлап, тора булыр ишек шакып.
Минем сөю түгел лә ул сиңа каккан:
Сезнең яктан мин бит күптән киттем кайтып.

Миңа гына була күрче мәрхәмәтле,
Мин бит инде яши алмыйм утлар йотып.
Яши алмыйм, яши алмыйм синнән башка
Сикеренгән йөрәгемне учта тотып.

## Уйлаудан тую

Селкенмә, уй. Минем кебек текәл генә
Каршыдагы тал-тирәкнең кәүсәсенә.
Кадап куйдым карашымны — кача алмас,
Гаҗизләнеп беткәч тәмам сездән әнә.

Селкенмә, уй — син бит кубар яфрак түгел,
Ник күчәсең, җилләр исеп очырткан күк?
Бу халәттән айнымаска булышлык ит:
Сөйгәнемне уйлап торам, исем китеп.

Селкенмә, уй, мин-исерек чайкала, дип,
Эчмичә дә сәрхүш булу ярыйдыр бер.
Төп-төз агач төсле сыны карашымда,
Син китәрсең, хыялым да җимерелер.

## Төш кенә бул

Мине алдап, килеп киткән төш кенә бул.
Ул татлы төш кермәгәндер кемгә генә...
Исәрләнеп, күзләреңнең алмасыннан
Кайнар тирең таммасын ла мендәремә.

Төш кенә бул, төш кенә бул — килеп кунган
Сине уйлап йомылган ул керфегемә.
Сөю сүзе кадерсезгә китәр, димә,
Мин йөртермен түкми-чәчми бөртеген дә.

Мине алдап, килеп киткән төш кенә бул,
Башкача һич — беркайчан да кермә миңа.
Кайнар тирең тамса, мендәр, төшемдә дә
Берни дәшми, дер-дер килеп елар гына...

Елар гына, айный алмый, саубуллашмый.
Чәчләреңнең җылысына торыр посып,
Саташтырган шушы төнне искәртергә...
Онытыйм, дисәм, кочагына алыр кысып.

## Синең күзләр

Текәлеп карап торсам да,
Бирешмиләр сынауга.

Дөм караңгы күзләреңә
Кунмый булыр томан да.

Кунмыйдыр ай яктысы да
Көз алмаңа, ялтырап.
Алмалары салкыныннан
Көзләр тора калтырап.

Тартмый булыр көн куллары
Күзләреңнең пәрдәсен.
Яфрак булып коелалмас
Саргаймаган мәгънәсе.

Куна алмый шуып төшәр
Кыр казлары тавышы.
Селкенми дә күзләреңнең
Дөм караңгы сагышы.





## Ләбибә Ихсанова

*Ләбибә Ихсанова исеме әдәбият сөючеләргә, шул исәптән «Казан утлары» укучыларына да яхшы таныш. Әйе, ул — танылган балалар язучысы, аларның якын дусты, киңәшчесе һәм җәмәгать эшлеклесе булган әдибәбез. «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн», «Якты уйлар», «Робинзоннар илендә» кебек, татар, урыс, украин, эстон, чуваш һ.б.телләрдә дөнья күргән, чын мәгънәсендә кызыклы, мавҗаралы әсәрләр, повесть-хикәяләр, мәкаләләр авторы ул Ләбибә апабыз.*

*Заманында «Ялкын» журналының баш редакторы, Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир булып эшләве белән нәниләр дөньясына тагын да якынайды ул.*

*Һәм, ниһаять, Ләбибә Фәез кызы Ихсанова 1967—1978 елларда «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе булып эшләде. Шушы мохиттә инде 50 елга якын кайнап, әдәбиятыбызга хезмәт итә самими, мөлаем, ихлас күңелле Ләбибә ханым Ихсанова. Без хөрмәтле әдибәне олуг юбилее белән котлыйбыз һәм укучыларыбыз игътибарына аның яңа әсәреннән бер өзек тәкъдим итәбез.*

# БЕРЕНЧЕ ГОНОРАР КЫЙССАСЫ

«СЕР САНДЫГЫН АЧКАНДА» ӘСӘРЕННӘН ӨЗЕК

Мендәремне ятагымның тәрәзәгә караган башына кабартып салам да, сузылып ятып, боз челтәре аша төшкән сыек яктылыкта Виктор Гюгоның «Көлә торган кеше» романын укырга керешәм. Мин күбрәк русча китаплар укырга тырышам. Рәхәтләнеп сөйләшерлек итеп русча өйрәнәсем килә. Вата-сындыра сөйләвемне курсташларым гаеп итмәсәләр дә, белгәнеңне

җирәнә җиткереп әйтеп бирә алмау сынаулар вакытында кыен. Астрономиядән сынау биргәндә шундый хәлдә калуымны мин университеттан киткәнче онытмам, ахры. Профессор Дюковның алдына таратып ташлаган билетлар арасыннан берсен сайлап алгач, белгән сораулар дип сөенгән идем. Шул сөенечем белән җавап бирергә дә ашыгыбрак чыктым бугай. Җай гына сөйли башлаган җиремнән тотлыктым да калдым. Җавабым тел очымда гына югыйсә, шуны русчага әйләндереп әйтеп бирергә кодрәт җитми. Үземне үзем кыйнап ташлардай булып басып торам. Эх, дим, эчемнән генә, үзебезчә, татарча булса, шартлатып сөйләп бирер идем бит. Беләм, курсташларым да хәлемне аңлый, бигрәк тә Киевтан эвакуацияләнеп килгән Леля. Аның белән икәү әзерләнгән идек. Дәшмәвем озаккарак китте, ахры, профессор, тәбәнәк гәүдәсенә караганда шактый зур күренгән чал башын күтәреп карады да:

— Йә, сөйләгез,— дип ашыктырды.

Ә мин авыз да ача алмыйм. Гарьлегемнән тамагыма төен тыгылды, күземә яшь килде, менә-менә тамып төшәр кебек. Шул чагында, рәхмәт төшкере, Леля:

— Профессор, материалны белә ул, яхшы әзерләнде,— дип әйтмәсенме.

— Алай булгач, формуланы язып күрсәтегез,— диде Дюков, ул да хәлемә керде.

Шулай итеп, яхшы кешеләр аркасында семестрны коерыксыз гына тәмамлаган идем. Ә ул коерык дигәнең артыннан сөйрәлеп килгән бирәсе сынавың гына түгел, стипендиядән дә колак кагу дигән сүз иде.

Бүлмәбездә бергә яши торган Зоя белән Клара да булыша миңа. «Он» белән «Она»ны бутый башласам, акыл өйрәтмичә генә, төзәтеп әйтеп куялар. Маша белән генә борчагыбыз пешми. Бөдрәләткән сары чәчле, житен чәчәгедәй зәңгәр күзле чуваш кызының адым саен вәгазь укуын өнәмим. Аңлыйм да үзем, аның бу гадәте явызлыктан да түгел, бары тик бездән югарырак курста укыганга, үзен олысымак итеп тотудан гына, шулай да кытыгымны китерә. Зоя белән Кларага теше бик үтми үтүен, шуңар күрә тәрбия чараларын миңа куллана, тәҗрибә ясый... Әнә хәзер дә:

— Любка! Семинарыңны оныттыңмы әллә? Әкият укып ятасың,— диде.

— Любка түгел мин сиңа, Лә-би-бә!— дип, исемемне бүлеп-бүлеп, басым белән әйтәм.

— Ладно уж тебе,— ди ул, электр плитәсенә куйган майлы табадагы бәрәңгене чыжлатып әйләндерә-әйләндерә.— Иртәгә зачет алып кайтсаң, билләһи дип әйтәм, үзеңне почмакка тәре урынына утыртып куям да, көне-төне чукынам синә карап.

Миңа түгел, әниеңнең чын иконасына карап чукынсаң да гөнаһларыңны юып бетерә алмассың, дип уйлыйм: коменданттан яшереп электр плитәсе тотуын мин аның зур «гөнаһы» саныйм, шуны үзенә әйтеп бирергә телем генә җитми, хурланам шул телсезлегемнән. Аннан соң студентта ач карынга семинар кайгысы була димени? Шундый чакта корольләр, борынгы рыцарьлар тормышы белән мавыгуымның мәгънәсен аңлыймени ул майлы бәрәңгеләр генә ашап торган кыз? Чү! Авыздан сулар китерә башлады бит әле бу таба исе. Китабымны алып, Рәмзияләргә менмиме булмас, ахры.

Рәмзия белән бер факультетта укыйбыз, тик ул миннән бер елга соңга калып килде. Тарих-филология факультетының татар теле бүлегендә укучы кызлар белән бер бүлмәдә яши. География факультетында татарлардан гел икебез генә булганга, аның белән тиз дуслаштык. Кичке ашны да аның урта кул чиләк хәтле мискиендә уртактан пешереп ашыйбыз. Кайчагында аның тар караватында, кысыла-кысыла булса да, икәү бергә ятып йоклыйбыз.

— Үзебезгә генә күч инде,— диләр кызлар. Ә минем бүлмәдәшләремнән аерылып бетәсем килми. Иялләндем мин аларга. Хәтта көн дә диярлек әйткәләшеп торган шул Маша да якын күңелгә. Бер иялләндемме, чат ябыша торган гадәтем бар. Үзем башлап читләшсәм, аны рәнҗетермен, үпкәләтермен кебек булам. Әлеге дә баягы, русча әйбәт итеп сөйләшәсе килү теләгем дә бар бит әле. Шулай итеп, бер үземә ике бүлмә минем. Җаның кайсында тели, шунда яши бир.

Өстәл янына утырып, китабымны ачуым булды, ишек шакып, Шәрәф килеп керде. Эземә үк басып менгән инде әллә. Шәрәф — утызларга җитеп килгән фронтовик шагыйрь. Газета-журналларда шигырьләре күп басыла. «Тупчы Ваһап» дигән поэмасын радиодан ике көннең берендә кабатлап торалар. Татар Академия театры режиссеры Шириаздан Сарымсаков аны җирәнә җиткереп, борынгы дастаннар укыган кебек хис белән укый. Шундый кешенең бер дә эреләнмичә студент кызлар янына килеп йөрүенең сәбәбен мин генә беләм идем.

[Тө]ра-бара кызлар да төшенделәр. Анар үз кеше итеп карый башладылар. Җәми[лә], мине үртисе килгән чакларында, яманлап та куя хәтта:

— Шагыйрь дигәч тә, әллә кем түгел инде. Өс-башы да минем әтинеке [ш]ыкмак кына. Матур да түгел.

Ачу килә, билгеле. Артыннан килеп йөргән егетне кемнең хурлатасы килсен. [Җ]әмиләнең сүзләрен дә гел чынга алып булмый. Шәрәфнең соры күзләрен [к]аймалап торган озын керфекләре, шул керфекләр арасыннан сөзелеп чыккан [м]оңлы карашы әсир итә башлаган иде инде мине. Шулай да Җәмилә барында [г]ына булса да минем аны гади авыл егете кебек түгел, шагыйрьләрчә һавалы, [г]үркәм, зыялы кеше итеп күрәсем килә. Ә ул әнә тагын шул озын итәкле юка [п]альтодан килеп керде. Аягында кун итек, башында колагына ук батырып кигән [с]ара кепка. Суыктан кызарган перчаткасыз кулларын угалап торган егетнең [к]ысегән иреннәре арасыннан:

— Исәнмесез, кызлар,— дигән сүз чыкты.

Җәмилә, башкорт ягыннан килгән бик үткен, телчән кыз, киная белән [с]өйләшергә ярата. Бу юлы да яшькелт күзләрен мутландырып:

— Бигрәк тә кайсыбызның исәнлеге кирәк инде, ягъни мәсәлән,— дип авыз [е]рды.

Шәрәф килгәч, мавыгып уйный торган бер уеныбыз бар безнең. Кәгазьгә рифмадаш сүзләр язабыз да шуннан шигырь чыгарабыз. Әмма шигыребез такмаза гына түгел, форма ягыннан төзек, эчтәлеге белән мәгънәле булсын. Ярыш, билгеле Шәрәф белән икебезнең арада бара. Кызлар — секундант. Башта алар бу уенга бик теләп тотынганнар иде. Гап-гади сүзләрдән шигырь юллары тууын күзәтүе алар өчен дә кызык иде. Бигрәк тә уенның төп шарты — җиңелгән кешенең киногa билет алырга тиешлеген яраталар иде. Бу бәйгедә һәрвакытта да Шәрәф җиңелә, дөресрәге, җиңелгән булып кылана һәм икенче көнне бүлмәдәге бөтен кызларны киногa алып бара.

Майлы ботка да туйдыра, дигән сүз бар. Тора-бара кызлар да туйды бу мәзәктән. Һәркайсының үз эше бар булып чыкты. Бүген дә, савыт-сабаларын шалтыратып, Гөлсем беренче каттагы кухняга төшеп китте. Зәмзәмия артык житди кыз, уен-көлкеләргә бик катнашмый, бүген ул нидер укып утырган жиреннән бөтенләй кузгалмады. Җәмилә дә ары бәрелеп, бире сугылып йөри торгач, күршеләргә кереп китте. Рәмзия хәтта кунарга да кайтасы түгел. Зеленодольск кызы ул. Әнисе анда түшәктә ята. Ике көннең берендә Рәмзия хәл белергә кайтып йөри. Иртән лекциягә дә шуннан гына киләсе. Шулай килеп чыкты, бүген без өстәл янында Шәрәф белән икәү генә утырабыз. Шигырь белән шактый житди шөгыльләнә башлаган елларым иде ул. Әлешемә тигән көнлек ипине базарга чыгарып саткан акчага алган кун тышлы калын дәфтәремә инде шактый җыелды алар. Кайчан да булса бер басылып чыгулары турында уйларга базмасам да, тыңлап торырга вакытлары, аннан да бигрәк теләкләре булганда, кызларга укырга яратам. Татар бүлеге студентларының әдәбият түгәрәгенә йөрим. Аның һәр утырышына берме-икеме олы язучы килә. Егетләр судагы балык кебек йөзә мондый кичәләрдә. Ибраһим Нуруллин әкрен, йомшак тавышы белән кыска хикәяләр укый. Сугыштан авыр җәрәхәт алып кайткан егет ул. Сызлануларны ябык, көлсу йөзендә дә чыккан. Хикәяләре дә моңсу. Факультетта иң яхшы укучы диләр үзен. Ибраһимга зур өмет баглыйлар, дип ишеткәнем бар. Аның белән сөйләшеп торуы да рәхәт, үзенне дә игътибарга лаек кеше итеп сизәсең. Бер сөйләшү бер гомер, диләрме әле. Мөхмүт-Хәсән бөтенләй башка. Тәбәнәк буйлы, ут борчасы кебек житез бу егетнең Ленинград басмаханәсендә бер кечкенә генә китабы да басылып чыккан. Күкрәгендә Кызыл Байрак ордены, иңендә йолдызлы погоннар. Шигырьләрен дә ул сәхнәдәге артистлар кебек пафос белән кычкырып укый. Әхәт Нигъмәтуллин үзен эре тота, һавалы егет. Өс-башы да матур. Ибраһимнар шинельдән йөргәндә — каракул якалы пальто иде аның өстендә. Башкорт ягына чыгып, авыл әбиләрен фотога төшереп йөргән дә, шуның акчасына киенгән, дип сөйлиләр аның турында. Булса да булыр, көн күрергә осталыгы бар кебек. Аның моңлы итеп җырлавы ошый миңа, тавышы матур. Үзенең шигырь язганын да, хикәя язганын да хәтерләмим. Иптәшләренекен сүтәргә ярата болай. Без аны тәнкыйтьчә дип йөрибез. Якыннан аралашып киткәч, мин Әхәтнең самими кеше булуын да аңладым. Эчендәге тышында дип әйтер идем.

Билгеле инде, андый егетләр хозурында сүз алып сөйләргә, берәр шигырь укырга батырчылык итәмме соң, аллам сакласын. Сөйләгәннәрен йотардай булып, тыңлап утырудан узмыйм. Мин түгел, алар белән бергә укыган кызлар да

тын утыра биредә. Югыйсә, шигырь язмаган көнем юк үземнең. Караватт янымны чуарлап бетерәм. Акшарлы стенага карандаш белән язам да сөртәм, язам да сөртәм. Дәресен белмәгән баланың кара такта янында басып торганы кебек. Тик монда, киресенчә: тактасы — ак, буры кара. Укытучысы да үзем, укучысы да үзем. Шулай азаплана торгач, күңелемне канәгатьләндерерлек бер шигырь чыга тагын. Шуннан соң гына әлеге калын дәфтәремә күчереп язам. Лекцияләрне дә хәрефләре тоныграк төшкән китапка язган чак бит, шуңар кадерләп тотам мин аны.

Шигырь дип авыз күтәреп әйтергә Шәрәф алдында уңайсызланам, сынатасы да килми үзе. Ул биргән рифмаларга мәгънәлерәк, камилерәк юллар тезәсе килә. Алдымдагы кәгазьдә ике сүз.

Төсле — Өсте. Уйлап тап инде менә шуны. Нәрсәнең өсте икән дә, ни төсле булыр ул? Күз алдымнан төрле-төрле күренешләр йөгереп үтә башлады һәм кинәт...

Без укыганда «сугыш белеме» дигән дәрес керә иде. Кызларны шәфкать туташы итеп әзерлиләр. Алар төрле шартларда эшләргә тиеш булганга, чаңгыда йөрергә дә өйрәтәләр. Әле шушы атнада гына туйганчы чаңгы шуып кайткан идек. Менә мин «Швейцария» тау башында /тирән үзәннәр белән ергаланган тау бите булганга, Казанның ял паркын шулай дип йөртәләр иде ул елларда/, әйе, биек тау башында басып торам. Саф һава, житез хәрәкәт кан йөрешен тизләткән, барыбызның да битләр алсу, күзләр яңа, күңел күтәренке. Минем шушы тау астында, Казансу буенда җәелеп яткан тигез кыр өстеннән кош булып очасым килә. Ә кар өсте ап-ак, күз камаштырып җем-җем итә... Күз алдыма шул килде дә, шигырь юллары үзеннән үзе тезелә башлады.

Кояш нурында,
Ак ука төсле,
Җемелдәп тора
Салкын кар өсте.

Ул арада Шәрәф мин биргән сүзләргә берне генә түгел, өч куплет язган да тәмәке тартырга чыгып киткән иде инде. Ул бик күп тарта икән. Үзеннән гел тәмәке исе килә. Янында озаграк торсам, миңа да сеңә. Шуның аркасында кызлар янында көлкегә дә калганым бар. Бер көнне Офицерлар Йортында кино карап чыктык. Сәгать ярым ничек түзеп утыргандыр, Шәрәф чыгуга тәмәкесенә тотынды. Урамда ай яктысы, шылт иткән дә җил юк, җиңелчә салкын, коры һаваны баллы су урнына эчәсе килә.

— Шушы хәтле рәхәтлекне тәмәке төтене белән бутаган кешегә гаҗәпләнәм,— дим, киная белән.

— Сугышта өйрәндем. Армиягә киткәнче пиво да кабып карамаган, тәмәке дә тартмый торган әйбәт егет идем мин. Сугыш барсына да өйрәтә, хәтта кеше үтерергә дә...

Без шулай сөйләшә-сөйләшә, җәяүләп кенә, Карл Маркс урамы буйлап киттек, Арча кырына килеп чыктык, тимер юл күперенә дә җиттек. Тулай торак ишеге төбенә килеп туктагач та ярты сәгать басып торганбыздыр. Әле генә караган кино турындагы бәхәс шундый кызу булдымы, башка сүзләребез житәрлек идеме, ул борылып китәргә ашыкмады, мин керү ягын карамадым. Шәрәф тәмәкенең берсен ташлап өлгерми, шунда ук икенчесен кабыза. Мин дә аякларыма таракан йөгерә башлаганын сизмим.

Ишектән керүемә, каршыма Җәмилә килеп басты.

— Кайда булдың!

Минем кайларда йөрүем, әйтерсең, аңар бик кирәк инде. Сер бирмәдем:

— Кайда булыйм, көтепханәдә,— дидем.

Ә ул, хәйләкәр яшькелт күзләрен елтыратып, яныма ук килде дә, сипкелле борынын җыерып киемемне иснәп алды:

— Ә, белдем инде.

Кызлар шаркылдап көләргә тотындылар, мин дә елмаеп куйдым. Ялганым тотылудан түгел, Җәмиләнең кыяфәтеннән көләләр бит.

Шулай да Шәрәфнең күп тартуын яратмыйм. Ачуланса ачуланыр, языйм әле үзенә дидем дә, калдырып чыккан кәгазенә «Әшәке, Тартма»,— дип язып куйдым. Кергәч бер рәхәтләнеп көлде Шәрәф, аннары уйлап та тормыйча җавабын бирде:

Тәмәке — Әшәке!
Шартла — Тартма!

— Тәмәке кибете өстенә лозунг итеп язарга була икән моны,— дидем мин, аны куәтләп.

Ул шулай тиз һәм җиңел котылды. Хәтта Әшәке сүзен дә үзенә түгел, тәмәкегә борып җибәрде. Ә менә мина биргән табышмагы шактый катлаулы булды. Ут яна — Уйланам дигән рифмага туры килерлек сүзләрне озак уйладым. Уйлан, уйлан, ут булып янсаң да уйлан, дип кыздырам үземне. Язылачы юлларымның кешенен эчке халәтен, моңын, сагышын бирергә тиеш икәнен күңелем сизә. Төн уртасында ут яндырып кем шулай уйланып утыра, кемнең татлы йокысы бүленгән? Сугыштан улы кайтмаган ятим анамы ул? Әллә сөйгән ярын югалткан җиту кызмы? Аның сагыну сагышларын салыргамы бу юлларга? Бер генә минутка да кызын исеннән чыгармыйча сагынып яшәгән әниемнең сабыр карашын күргәндәй булам. Йөрәгемдә бар, күңелемдә бар, әйтергә теләгәнем тел очымда гына тора, тик кәгазьгә төшерә алмыйм. Ярый әле Шәрәф күзен төбәп кулыма карап утырмый, «Көлә торган кеше» битләрен актара. Шактый азаплана торгач:

Караңгы төн, ап-ак карлар ява,
Тәрәзәмдә минем Ут яна,
Ак карларга карап төннәр буе
Нигә икән шулай уйланам?

— дип яздым.

Ахырдан мин Шәрәфне озата чыгам. Тагын күрешергә булып аерылабыз...

Шәрәф Мөдәррис дигән шагыйрь барлыгын мәктәптә укыган чагымда ук «Яшь ленинчы» газетасыннан белә идем. Әмма бер өстәл артына утырып шигырь язышырбыз, озатышып йөрербез дип кем уйлаган ул чагында. Әллә бу язмыш дигәнең үзең туганчы ук, чыннан да, язылып куела инде. Язучылар клубында беренче тапкыр күргәч тә бик исем китмәгән иде үзенә. Ул чагында кемнәрне генә күрмәдек без Тукай исемендәге бу клубта. Шигырь, җыр кичәләре күңелебезне тәмам әсир итеп алган иде инде. Ул көнне көтеп кенә торабыз, ул көн безнең өчен изге. Кырык эшебез кырылып ятса да, шунда йөгерәбез. Ә студентның эше, билгеле инде — йә зачетка, йә сынауга әзерләнү. Иртәгесен кычкырып янсак та ис китми. Аһ, әгәр ул Тукай клубының стеналары телгә килеп сөйли алса! Ниләр генә күрмәде дә, кемнәрнең генә тавышын сеңдермәде бу таш диварлар. Телевизор, магнитофон дигәннәре булсамы ул чагында! Күпме кадерле истәлекләр сакланып калыр иде. Тик аларны белү түгел, исемнәрен ишеткән кешеләр дә сирәк булгандыр ул заманда...

Шәрәф белән якынаеп китүебез әлеге дә баягы шул күпне белергә яраткан Җәмилә аркасында булды дип уйлыйм. Әгәр ул диалектологиядән лекциягә чакырмаса, әгәр Җәләй ага шигыремне алып «Кызыл Татарстан» газетенда бастырып чыгармаса, әгәр беренче гонорарымны кесә каракларыннан алдырмасам, белмим, Шәрәф белән кара-каршы килеп бер сөйләшкән булыр идекме икән?.. Язмышымда зур борылыш ясаган бу вакыйганы йөгереп кенә үтеп китеп булмас, ахры. Ул бит тормыш юлымны бөтенләй икенче якка борып җибәрде. Үземнең генә түгел, әтием белән әниемнең дә, авылга кайтып укытучы булыр, дигән теләкләрен сүтеп ташлады. Шулай булгач...

Беренче каттагы зур бүлмәнең буеннан буена сузылган озын плитә янында Рәмзия белән аш пешерәбез. Кичке якларда ыгы-зыгы, шау-шу күп була монда. Студентларның кайсылары «бүре башы ашардай» булып ачыгып кайткан, кайберләренә тизрәк тамак туйдырып чыгып китәргә кирәк, уттай кызган плитә өстендә савытыңны куярлык урын тапмаган көннәр дә була. Ашыбызны берәрсе читкә алып куймасын дип, Рәмзия белән алмаш-тилмәш саклап торабыз. Менә Җәмилә дә төшеп җитте. Кемнәрнеңдер мискиләрен кысрыклап, үзенең ак калайдан ясалган савытын китереп куйды да миңа карап:

— Иртәгә сине Җәләй ага чакыра, барасыңмы? — диде.

Аңламый тордым башта. Нинди Җәләй, кая, ни өчен чакыра?

Диалектологиядән лекция дигәч кенә профессор Латыйф Җәләй турында сүз барганын төшендем. Нигә чакыра, каян белгән ул мине? Шунда йөрәгем еш-еш тибеп алды. Әллә шигырь язуымны ишеттеме икән?

— Нократ диалектын үтәбез. Безнең белән Нократ кызы да тора, дип әйткән идек, килсен әле лекциямә, дип чакырды.

Яшерен сөенечем юкка икәнен белгәч, бераз күңелем төште төшүен, тик Җәмилә кыстамаса да, лекциягә барачагым һәм анда җанлы экспонат булып утырачагым билгеле иде инде.

Беләм бит: Латыйф ага бу дөньяда Ләбибә исемле кыз яши, шигырьләр яза, география факультетында укыса да, башы-аягы белән татар әдәбиятына мөкиббән, дип башына да китерми. Ләкин ул үзе миңа бер елдан бирле таныш иде инде. Беренче тапкыр мин аны әдәбият түгәрәге утырышында күрдем. Астагы катта, вестибюль янәшәсендә үк, кысан бүлмәдә, өстәл лампасы яктылыгында кемнеңдер кульязмасынмы, башка берәр төрле кәгазьнеме караштырып утыра иде. Әлегә берәүгә дә күтәрелеп карамый, әкрен генә кереп, пышын-пышын гына сөйләшеп урыннарга утыручы студентлар аның өчен әлегә юк монда. Ул үз дөньясына чумган. Мин дә аның кем икәнен тәгаен генә белмичә, ләкин бүгенге мәҗлеснең хуҗасы булырга тиешлеген аңлап, бер кырыйдан күзәтеп утырам. Аз көчәнешле лампаның сүрән яктысында керпе кебек тырпаеп торган көлсу чәче, җыерчыклы түгәрәк йөзе ачык күренә. Муен тирәсе салынып төшкән яшел свитерын, шактый киелгән соры костюмын, мамыклы сырган чалбарын, зур киез итекләрен җентекләп карыйм. Шактый киң җилкәсе шиңә төшкән, аркасы бөкерәя башлаган кебек тоелды. Арганлык һәм картлык галәмәте, дип уйладым. Мин аның күзләрен генә күрә алмыйм. Бу күзләр дә талчыккандыр, дөньяга битараф карыйлардыр, бу утырышка да мәҗбүри, кушкан өчен генә килгәндер, каршында кемнәр генә утырса да аның өчен барыбер, шуңар күрә ул безгә күтәрелеп тә карамыйдыр кебек тоелды. Әмма бераздан башын күтәреп, күзлеген салгач һәм карлыкканрак тавыш белән бераз мишәрчәләтеп:

— Җыелып беттегезме, балалар,— дигәч, мин аның бик җылы карашлы кечкенә соры күзләрен дә күрдем. Кая ул арыганлык, кая ул битарафлык! Киресенчә, бераз гына хәйлә һәм яшьләрчә шаянлык та бар иде бу караштa.

Дөньяда су тамчысы кебек, берсенә берсе ошаган кеше юк, дип әйтәләр. Бер уйласаң, телләр дә шуның кебек бит. Менә без татар теле дип әйтәбез инде. Шул татар кешесе кайларга гына барып чыкса да, аны теленнән таныйлар, паспортына карап тору кирәкми. Дөнья күргән кеше: син фәлән як агае бит, яки син, түти, шул авылданмы, дип сораса, ялгышмас. «Базарга баргаллар, сыер сатып алгаллар»,— дип әйтсә, Дөбьяз кешесе белән сөйләшүеңне беләсең инде. «Миндәләгә барам әле. Миндәлә юлы такыр»,— дип бары тик шул якның егете генә җырлар. Үземнең ишеткәнем юк, ләкин Пермь ягындагы башкорт, татарларның сүз ахырына «кый» кушып сөйләшүләрен беләм. Бакчадагы гөлләрнең төрле-төрле чәчәк атуы кебек, телләрнең дә аерымлыгы үзенә бер матур. Бу аерымлыкның диалект дип, ә аны өйрәнүче фәннең диалектология дип аталуын ишеткәнем бар. Менә мин, әдәбият түгәрәге була торган таныш бүлмәдә, Латыйф ага Җәләйнең лекциясен тыңлап утырам. Ул борынгы заманда нократ дип аталган, безнең, авыл кешеләре Идел дип йөрткән Вятка елгасы буендагы татарларның тел үзенчәлекләрен сөйли. Сөйли-сөйли дә, шулаймы, кызым, дип миннән дөресләтеп ала. Менә ул, Идел буе табигатен сөйләвемне үтенде. Үзе барып күргән кебек, белеп сорады һәм миңа аның сүзен дәвам итәргә җайлы булды. Ни өчендер бүтән бер күренеш түгел, Иделдә боз аккан вакыт күз алдыма килде. Болганчык сары суда айкала-чайкала бозлар ага. Бер-берсенә бәрелеп ватылалар, малайларның «куча-мала» уйнаганнары кебек өсте-өстенә өеләләр, салкын су чаткылары чәчрәп юеш, комлы яр өстенә пыяла кебек үтә күренмәле, вак-вак боз кисәкләре чәчә. Без аны конфет суырган кебек суырып йөрибез, аннан да тәмле әйбер юктыр безнең өчен, елына бер генә килә торган тансык әйбер бит ул. Шунысы гаҗәп, бер генә бала да авырып түшәккә ятмый, берсенең дә тамагы шешми ул боз кәнфитеннән. Язгы ташу суы бөтен чир-чорны юып алып китә дигәннәре дөрес инде әллә? Әбиләр дә, әнә, җиңнәрен терсәккә тикле сызганып, шыр сөяккә калган нәзек беләкләрен юалар, бисмилла әйтеп, авыз-борыннарын Идел суы белән чайкыйлар, оныкларының ләмгә баткан кулларыннан җитәкләп су янына китерәләр, чырыйлатып, каткан борыннарын җебетәләр. Боз киткәндә Идел буена ярты авыл төшә. Агайлар аулак җиргә китеп кармак сала, хатын-кызлар яңа баш төртеп килгән сусыл юа, яшел кузгалактан авыз итеп йөриләр. Иңкү җирләрдә бераз дымсу, һәм урыны-урыны белән көпшәк кар ятса да, язгы җил болын өстен киптергән дип әйтерлек. Калку җирләр инде хәтфә кебек яшәреп тә килә. Анда җыр, анда бию, анда гармун тавышы, көлү авазлары... Анда яшьләр әйлән-бәйлән, «алырымкош»—озын уен уйныйлар. Егет белән кыз озын уенга китсә, син аларны көтмә инде. Гашыйкларның авызга авыз куеп сөйләшер сүзләре күп, серләрен исәр җилләр дә урламас, акчарлаклар да канат очларына элеп китмәс, аулак җирдә алар хәзер. Бәхет телик яшьләргә...

Мин дәртләнеп шулар турында сөйли башладым. Әз генә шагыйрьлек тә бар бит инде, сагыну да җитәрлек. Шулай да, хәйләкәр күзләрен кыса төшеп, елмаеп тыңлаган остаз, бераздан: «Шулай шул, кызым»,— дип бүлдерәсе итте.

Шунда ук житдиләнде һәм минем хисле монологымны студентларга анализларга кушты. Алар шулай бераз практик күнегүләр үткәреп алгач, янадан теориягә күчтеләр. Ә мин, бер урыныннан купкан күңелемне тынычландыра алмыйча, хыялымда йөзә бирдем. Менә ап-ачык итеп әниемне күргәндәй булдым. Капка төбенә чыккан да кулын каш өстенә куеп, югары очка карап тора. Еракта күренгән кешене кызым кайта түгелме, дип көтеп аладыр. Озакламый үзләренең капка төбендә Маһри түтәй күренер.

— Кемне көтәдериең? — дип кычкырыр ул, урам аша.

— Көтмидерием, болай гына торадырыем.

— Кызың хат язадырыемы соң?

— Хаты килеп торадырые үзе...

Бүлмәдәгеләрнең барысы берьюлы шыбырдашып кузгала башлагач, айнып киткәндәй булдым. Лекция тәмамланган икән. Студентларның бер ише ашыгып чыгып китте, бер кадәресе Җәләй аганың өстәле тирәсенә җыелып, сөйләшеп тора башлады. Мин аларның сүзе беткәнне көтеп, ишек төбенә килеп баскан идем инде. Кинәт Җәмиләнең:

— Абый, ул шигырьләр дә яза әле, — дигән сүзе колагыма керде. Минем турыда сөйләшәләр икән. Җәләй ага, кайда соң әле үзе, дигәндәй, як-ягына каранып алды, күргәч:

— Шулайменни, шигырьләреңне миңа да күрсәтерсеңме? — диде.

Гел үзем белән йөрткән шигырь дәфтәремне, ашыгып, профессорга бирүемне сизми дә калдым. Аның кире уйлавыннан, әлегә вакытым тар, бераздан алырмын, дип әйтүеннән шикләндемме? Дөресен генә әйткәндә, берни дә уйларга өлгермәдем, шулхәтле көтмәгәндә һәм уйламаганда килеп чыкты бу, әйтерсең лә мин үзем түгел, башка берәү кулымнан тартып алып бирде дәфтәремне. Ул «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, хәтта дәфтәремә күз дә салмады, кәгазьләре арасына кыстырды да чыгып китте. Мине үкенү хисе биләп алды: ник бирдем инде, әдәм көлкесенә калырга!

Шул көннән башлап ут йотып йөрим. Ә Җәләй агайдан бер хәбәр юк. Әгәр ул юк белән маташасың, шигырьләрен чүп, дип әйтсә, башка бервакытта да аның күзенә күренмәм, әдәбият түгәрәгенә дә йөрмәм, шигырь дә язмам. Ике көймәнең койрыгын тоту җүләрлек ул, үз фәнемне тырышып өйрәнермен дип үз-үземне юатып куйсам да, университеттан кайткан саен яшерен өмет белән кызларның күзенә карыйм. Кайчан да булса бер хәбәр алып килергә тиеш бит инде алар.

Шулай борчылып йөргән бервакытта, кышкы сессия башланыр алдыннан, профессор авырып киткән, зачет бирергә теләгән кызлар өемә килсен дип әйткән, дигән хәбәр китерделәр. Теге кызыгыз да килсен, дип, мине дә чакырган, рәхмәт төшкере.

Аларның фатиры Офицерлар йортыннан ерак түгел. Зур Кызыл урамының Ирек мәйданына чыккан башында, эчкә кертеп салынган таш йортта булып чыкты. Без, кыюсыз гына ишек шакып, шактый иркен, борынгы йортлардагыча биек түшәмле, шуңадыр салкынчарак тоелган бүлмәгә кергәндә Җәләй ага укып-язып утыра иде. Ә без аны урын өстендә ятадыр дип, бик уңайсызланып килгән идек. Авыруы хак булгандыр, йөзе сулган, күз карашлары тоныкъ, өстенә бик җылы киенгән. Аның өстендә озын, соры халат, халат изүеннән күкрәгенә уралган мамык шәл күренеп тора, башында формасын югалта язган гади кәләпүш. Ул, безнең сәламне алгач, янында булышып торган хатынына:

— Җаным, миңа кунаклар килде. Эшне куеп торыйк булмаса, — диде.

Шулай ук җылы итеп киенгән озынча ябык гәүдәле, кырыс йөзле ханым безгә карап:

— Түрдән узыгыз, — дип, күрше бүлмәгә чыгып китте.

Әллә ни байлык юк иде биредә. Өй җиһазлары да аз, вакытлыча килеп торган кешеләрнеке кебек гади дә үзе. Игътибарымны җәлеп иткәне, бирелдәге картотекаларның күплеге булды. Алар өстәл өстендә, урындыкларда, шкаф башында, кул сузып алырга кайда җайлы — шунда куелган. Кул ясуы кадәр кәгазь битендә күпме белешмә. Күпме юллар йөреп, аяк итен ашап, ничәмә-ничә кешеләр белән сөйләшеп, әллә ничә еллар җыйган байлык бит аларда. Сорасалар, хуҗасы миллион сумга да бирмәс иде аны. Ул — аның җаны. Баласы бит ул аның. Ә баланы кем акчага сата? Юк, кадерен белгәнгә җанын да кызганмый торган кеше, ахры, бу өйнең хуҗасы. Аның ишеге теләсә кемгә ачык, без булып без, йолкыш студентлар профессор хәтле профессорның түренә кереп утыра алгач, аның үз шәкертләренә, дипломантларына, аспирантларына бу картотекалардан файдалану рөхсәт ителә дә ителә инде, дип уйладым мин.

Җәмилә белән Зәмзәмия профессор белән әңгәмә корып утырган арада Раушан апа (мин аның исемен соңыннан, бу гаилә белән якыннанрак танышкач белдем. Ә Җәләй ага һәрвакыт аны яратып, Җануш дип дәшә иде) идән уртасындагы өстәлгә чәй әзерләде. Кечкенә бәллүр савытта вак итеп туралган шикәр куйды, борынгы затлы тәлинкә белән кәгазь калынлыгы итеп киселгән ипи телемнәре чыгарды. Яктыга куеп карасаң үтә күренмәле матур чәшкәләр тезде. Кайнар пар бөркеп торган ак чәйнекне ул соңыннан, Җәләй ага кызларның зачеткаларын сорап алгач кына китерде.

Җәләй аганың шигырь дәфтәремне кулына алуын күргәч, эсселе-суыклы булып киттем. Битемә кан йөгерде, ахры, колак очларыма хәтле кызыша башлады. Йөрәгем тибүе бүлмәдәгеләргә дә ишетелә кебек. Тар маңгай астыннан төбәп караган күзләрдәге җылылыкны күргәч кенә, әзерәк тынычландым.

— Бер шигыреңне «Кызыл Татарстан»га бирдем. Консультация бюросына йөрергә кирәк сиңа, кызым. Китап нәшриятына барып, Рокия Гыйззәтуллина дигән ханымны эзләп тап,— диде ул һәм барыбызны да чәй янына чакырды.

Өйдә пешкән тәмле чәйне эчәсебез бик килсә дә, тартындык, утырмадык. Рәхмәт әйтеп чыгып киттек.

Вакыт үтә торды. Минем башта көн дә бер кайгы: «Кызыл Татарстан» газетасын табып, тиз-тиз генә күз йөртеп чыгу. Кайчагында матбугат йортына төшеп, андагы китапханәдән дә карыйм. Китапханәче булып Мөслиха дигән кыз эшли биредә. Без аның белән әдәбият түгәрәгендә танышкан идек. Сахалиннан кайтып, педагогия институтына читтән торып укырга кергән. Бу ел әдәбият түгәрәгенә педагогия институтында укучылар да йөри башлады. Утырышлар тагын да җанлырак, күңеллерәк булып китте. Университет типографиясендә басылган «Ленинчы» газетасында шигырьләребез дә чыккалый инде. Хәтта безнең үзебезнең чын язучыбыз да бар. Сугышка хәтле үк язучылар союзына әгъза булып алынган шагыйрь Әхмәт Юныс әнә Ибраһимнар, Әхәтләр, Җәмиләләр белән бер курста укый. Ул инде тәҗрибәле язучы, басылып чыккан китаплары бар, шактый олы яшьтә һәм безнең кебек сыек талчыбыкларына акыллы, төпле киңәшләр бирә ала. Ә болай Әхмәт Фәйзи, Афзал Шамов, Фатих Хөсни кебек язучыларның әле берсе, әле икенчесе безнең янга килми калмый.

Шулай да сөенечле хәбәр миңа һич уйламаганда, көтмәгәндә килде. Биофак аудиторияләренең берсендә «Үсемлекләр географиясе» дигән лекция тыңлыйбыз. Профессорыбыз Баранов шактый олы яшьтә, картларча салмак кына атлап, бөкерәебрәк йөри торган кеше, мәчет картларыныкы кебек түгәрәк ак сакаллы, маңгае йодрык белән суккандай эчкә батып кергән, студентларга күтәрелеп карамыйча гына, үзалдына сөйләшкән кешедәй өстәленә иелеп, әкрен генә сөйли лекциясен. Өлкән курс студентлары аңар сынау бирү бик җайлы диләр. Билетларны өләшеп чыга да шкафлар артындагы кечкенә өстәленә килеп, үз эшенә утыра икән. Ун-унбиш минут үтүгә, белгәннәре үзләренең белгәннәрен, әрсезләре китап йә дәфтәрдән укыганнарын сөйләргә дип, берәм-берәм аның каршына киләләр, ди. Әмма тәҗрибәле карт кемнең кем икәнен бик тиз сизә һәм бер-ике өстәмә сорау биреп, әрсезләрне төп башына утырта икән. Ә болай студентлар ярата үзен. Лекцияләрен калдырмый йөрибез. Чөнки ул бернинди китаптан да табарга мөмкин булмаган мәгълүматлар бирә. Әле менә Ерак Көнчыгышның үсемлекләр дөньясын үтәбез. Аның кулында агач ботагына охшаш буынтыклы күрән жень-шень тамыры. Язучы һәм галим Владимир Арсеньев 1912 елда бу тамырның дөньяда иң зурысын урыс тайгасында табып алган, дип гомуми мәгълүматлар бирде дә галим кызыклы бер легенда сөйли башлады...

Борын-борын заманда, бер-беренә күрше булып, ике кабилә яшәгән, имеш. Аларның берсендә көчле, кыю, гадел егет Жень-Шень, ә икенчесендә шундый ук батыр, көчле, чибәр Сөн-Ши Хон яшәгән. Үсеп буй җиткәч, Сөн-Ши-Хон хунхуз (юлбасар) булып китә, явызлыгы белән тирә-яктагыларга көн күрсәтми, көпәкөндез талый, дөге, соя кырларын таптый. Тәмам җәфа чиккән кешеләр Жень-Шеньга мөрәҗәгать итәләр:

— Әй син, батыр һәм көчле, гадел һәм акыллы күршебез Жень-Шень, зинһар коткар безне бу явыздан,— диләр.

Жень-Шень аларның зарын тыңлый һәм Сөн-Ши-Хоны акылга утыртмак була. Ике егет арасында аяусыз тартыш китә. Сөн-Ши-Хон көчле егет була, әмма Жень-Шень аннан да көчлерәк, чөнки аның тамырларында җанварлар патшасы — юлбарыс каны ага икән. Жень-Шень явыз күршесен җинеп, кыяга бәйләп куя. Үкенечкә күрә, үзенең әсирен сеңлесе Лиу-Лага күрсәтмәкче була. Чибәр Лиу-Ла Сөн-Ши-Хоны күргәч үлеп гашыйк була һәм аны бәладән коткарырга тели. Менә төн житә, Сарай халкы каты йокыга тала. Бары Лиу-Ла гына

йокламый. Сакланып кына килә дә сөйгәнен әсирлектән коткара. Иртәгесен Жень-Шень Сөн-Ши-Хоның качып китүен белгәч, нык ярсый, бер минут та тормыйча артыннан куа китә. Озак та үтми, качкынны куып тота ул, ике арада тагын да хәтәррәк, тагын да аяусызрак көрәш башлана. Ташлар арасына ышыкланган Лиу-Ла, һуштан язарга житешеп, карап тора. Кайсына көч бирсен соң ул — берсе туган абыйсы, икенчесе жан сөйгәне. Менә Жень-Шень хәнжәрен жан ачуы белән дошманының күкрәгенә батыра һәм шул ук мәлне «аһ!» дигән аваз ишетеп, борылып карый. Канга баткан Сөн-Ши-Хон соңгы көчен жыеп, кылычын дошманына селти. Ике батыр берьюлы туган жиргә капланып төшәләр. Күршеләре, туганнары хакына һәлак булган Жень-Шеньне кадерләп жирлиләр һәм аның исәлеге итеп, адәмнәргә озын гомер, сәламәтлек һәм көч биргән үсемлек тамырын Жень-шень дип атыйлар...

Лекцияләрне сүзен сүзгә язып барырга өйрәнгән идем инде. Сынаулар вакытында ул безнең бердәнбер таянычыбыз. Чөнки фәнни китаплар юк дип әйтерлек, булганнарын да кулга бирергә бик ашыкмыйлар, китапханәгә йөреп укырга гына рөхсәт. Студентларның бик күбесендә сәгатьләр буе басылып утырырлык сабырлык та житми. Бар иде ул, бөтен дөньядан аерылып, китап кимереп утыручылар да бар иде. Алары аның Сталин йә Молотов стипендиатлары. Алар белән бик ярышып булмый. Лекцияләрне калдырмыйча йөргән һәм тырышып язып барганнарга да рәхмәт әйтерсен. ВУЗ бетергән кешенең кульязмасы лекция язып кына бозыла, дип әйтүләрендә хаклык бар анысы. Кайчагында таракан йөргән юлларга охшый ул, тик үз туганың үзеңә кадерле дигәндәй, ничек кенә жырмачланган булмасын, үз кулыңны үзең таныйсың. Ул көнне мин Барановның бер фикерен дә калдырмаска тырышып язып утыра идем. Янтыгыма төртүләренә дә ис китмәде, күршем ялгыш орынып куйды, дип уйладым. Икенче тапкыр жиңемнән тарткач һәм ручка кәгазь бите буйлап шуып киткәч кенә ачу белән борылып карадым. Ул ияге белән ишеккә таба ымлап күрсәтте. Ачык ишектән Рәмзиянең башын күргәч тә йөрәгем сулкылдап куйды. Юкка гына ээләп тапмаган инде ул мине. Аяк очларыма гына басып, кулы белән ишарәләп чакырып торган дустыма таба киттем.

— Ләбибә, сөенчеңә нәрсә бирәсең,— диде ул, кулын артка яшереп.

— Хат бармы?

— Хат кына көтәсеңмени?

— Әллә гәзитме?

— Гәзит шул, шигырең чыккан бит,— диде Рәмзия, «Кызыл Татарстан»ны баш очына күтәреп. Дустымның күзе көлә, авызы көлә, үзе мин үрелгән саен гәзитне бирмәс өчен читкә сикерә.

— Бие, биесәң бирәм.

— Интектермә инде, биемәгәнемне беләсең бит.

— Ал инде,— диде ул, ниһаять, миһербаны килеп, шигырь басылган битне ачып ук күрсәтте.

Гәзит укучылар өчен берни дә тормагандыр инде бу сан, дүртенче биттә, бер мәкалә астына кысрыклап керткән егерме юллык шигырьне күбесе укып та карамагандыр. Ә минем өчен күк капусы ачылгандай булды бу көн. Берлинны алып кайткан солдат кебек идем мин бу минутта. Гәзитне тотып, шунда ук Жәләй ага янына йөгерергә тиеш булганмындыр, бәлки. Үкенечкә күрә, алай итмәдем. Хискә бирелгән чакта кеше иң элек үзе турында уйлыймы икән әллә? Шатланса да үзем булдырдым дип шатлана, кайгырса да бу хәсрәт аның гына башына килгән кебек кылана. Шәфкать дигән хис кадерләүгә, яклауга мохтаж нәрсәләр ул. Без аны теләп, көтеп алабыз, аның колы булырга әзербез. Телебез белән әйтмәгәндә дә ялварулы күз карашларыбыз шул турыда сөйләмимени. Әгәр шуны күрмәсәк, сизмәсәк, күңелебездән рәнжемибезме әллә? Ялварып-ялварып та тавышыбызны ишетмәсә, без хәтта аллага да тел тидерәбез түгелме соң? Шигырьләремне укуны кичектерсә, теге вакытны мин дә Жәләй агага үпкәләмәс идемме әллә? Һич кенә дә хакым булмаса да. Бәлки бу ризасызлык минем йөземә дә чыкмас иде, кабынуга сүнеп тә бетәр иде, шулай да йөрәкнең әллә кайсы гына бер жирен чеметеп алгандай итәр иде бит. Ә мин үзем яхшылыкка каршы яхшылык белән кайтару турында уйламадым бу минутта, иң элек сабакташларым янына йөгердем. Сөенечемне алар белән уртаклашып бетергәч, хәтта шул исемемне дә татарча әйтә белмәгән Машага да күрсәтеп шаккатыргыч кына исемә төште ул минем.

— Күрдем мин аны. Тәбрик итәм,— диде Жәләй ага, күкләргә сикерергә бик ирек бирмичә генә. Ләкин сиздем мин аның жылысын, күз карашыннан, тавышыннан сиздем. Язганнарымны күзәтеп барачак ул, мохтаж булсам, ярдәм кулын сузарга әзер торачак...

Әллә ничек килде бу яз. Март башында ук кояш кыздырып, гөрләвекләр акты. Үзәк урамнарда кар бетеп асфальт ачылды, кешеләрнең күбесе җиңелчә киенеп, яшьләр яланбаш йөри башлады. Ишек алларында юып элгән керләр җилферди, күлдәвекләрдә кара каргалар су эчә. Кыш буе тыелып торган энергия, кояш нурына уянган кебек, аякларга, йөрәкләргә баш булды. Каядыр чыгып йөгерәсе, нәрсәдер эшлисе, кычкырып сөйләшәсе, башны артка ташлап, оныты-лып көләсе, хәрәкәт итәсе килә. Без утырган аудиториянең тәрәзә артына өченче кат турына хәтле үрелеп үскән карт тирәкнең ялангач ботакларына кунган чыпчыклар да:

— Чык, чык, чык,— дип чырылдашалар кебек.

Ләкин бер көнне... Ул төнне Җәмиләнең йокы аралаш кычкырган тавышына уянып киттем.

— Җәмилә, саташасың бит, икенче ягыңа әйләнеп ят,— дип төрткәләп уяттым аны.

— Уф, алла, үләм дип торам.

— Яман төш күрдеңме әллә?

— Бер немец кулы. Үзе үлгән, үзе артымнан йөгерә.

— Тоттырмадыңмы соң?

— Трамвайга утырып качтым.

— Төштә мәет күрсәң — көн бозыла, диләр.

Монысын безнең тавышка уянган Зәмзәмия әйтте. Өчебез дә борылып, пәрдәсез тәрәзәгә карадык, анда дөм караңгы төн чекерәеп тора иде.

Иртәгесен, чыннан да, болытлы, салкын, ямьсез көн каршылады. Эленке-салынкы гына җыенып, университетка киттек. Юлда очраган кешеләрнең йөзләре караңгы, урамнар, йортлар, шәрә юкәләр — барысы да боегып, бөрешеп, күңел-сезләнеп калган сыман. Салкын котып җиле итәктән тарта, аркадан этеп, йөгере-ргә мәҗбүр итә, куенга кереп, ит кунмаган арык тәнебезне өшетә, асфальт тузанын кубарып күзгә-башка сибә, теш арасында ком чытырдый. Шул бозылу-дан атна-ун көн начар һава торды. Вакыт-вакыт тары бөртегедәй эре кар сибәләп китә. Тышта коры салкын җил, бүлмәдә таш стена суыгы үзәккә үтә. Лекциядән кайтабыз да баштан-аяк бөркәнеп йә йоклыйбыз, йә борыныбызны гына чыга-рып, берәр китап укып ятабыз. Һичнәрсәгә кул бармый, хәтта сөйләшәсе дә килми.

Шулай күңелсезләнеп йөргән көннәрнең берендә, бүлмәдә ялгыз башым китап укып утырганда, ишек шакыдылар.

— Керегез,— дидем, күтәрелеп карамыйча гына.

Ишек ачылды, кемдер керде, аны-моны эндәшүче юк. Укудан бүленергә туры килде. Карасам... күземә күренәме дип торам — энем Ренат! Авызы колагы-на җиткән, күзләре ут яна. Янында яшьтәшем, дустым Фәрхинур басып тора.

— Энем! — дип йөгереп барып, кочып алдым Ренатны.

Авылда каникуллар башланды бит. Укытучы булып эшли башлаган Фә-рхинур шәһәрдәге туганнарын күреп кайтырга булган. Шуны ишетеп, әни дә Ренатны ияртеп җибәрергә уйлаган. Әз булса да азык-төлек илтер, хәлемне белеп кайтыр дип әйткәндер инде әнием-җаным. Чыннан да, Ренат өстәл өстенә бәләкәй-бәләкәй янчыклар белән әз генә он, әз генә борчак, шуның хәтле генә тары ярмасы алып куйды. Ахырдан ак төенчекне югары күтәреп, хәйләкәр елмайган көе:

— Монысы нәрсә, беләсеңме? — диде.

— Әллә уалмамы?

— Әни беребезгә дә бирмәде. Миңа да, юлда ашыйсы булма, апаң белән утырып чәй эчәрсез, диде.

Шешенке кабаклары астыннан елмаеп карап торган күршем алдында бөтен серне ачты да салды бит малай. Хәер, ни эшләп сер булсын, авыл укытучылары-ның ни хәлдә яшәвен белмимени ул, бигрәк тә бу авыр заманда. Әнием шушы бер таба уалманы пешереп җибәрер өчен дә ни хәтле мәшәкать кичергәндер әле. Ә уалма безнең өчен, чыннан да, патшалар ризыгы ул. Җылы сөткә басылган, ак майда кетердәп пешкән төче күмәчне уалма диләр безнең авылда. Авыл балала-ры өчен икесе дә перәннекләргә биргесез, сирәк эләгә торган тәмле аш. Бик тансыклаган чакта әниемнең, он булса уалма пешерер идек, мае юк, сөтен күрше дә бирер иде, дип шаяртканы искә төште. Шулай да вакыт-вакыт бәйрәм ясап ала иде ул безнең өчен. Кышкы озын кичләрдә олы мичне ягып томалагач, шушы уалманы пешереп ала иде. И ул кадерле кичләр! Җылы өйгә мич ашының тәмле исе таралган, өстәл өстендә самавыр гөжләп утыра, бөтен гаиләбез белән көле-шә-көлешә, сөйләшә-сөйләшә сөтле чәй эчәбез.

Шулай да хискә бирелеп утырыр чак түгел, юлчыларны кайнар чәй белән сыйларга кирәк, эчкә бераз җылы керсен. Кухня дигәнебез кечкә таба, студентлар кайтыр алдыннан гына ачыла. Бик кирәк чакта һәр этажның коридоры башында торган бүрек чаклы гына тимер мичләр коткара безне. Сынаулар, зачетлар бирелеп, язылган лекцияләрнең кирәге бетте дип уйланган кәгазьләрне ягып чәй кайнату озакмыни.

Газетада басылган шигырь өчен гонорар алган көннәрем иде. Гомеремдә беренче тапкыр гонорар алуым бит. Шигырь бастырган өчен акча түлиләр дип уйламаган да идем, Ибраһимнан ишеттем. «Совет әдәбияты» журналында бер хикәясе басылгач күп кенә акча алдым, дип әйткән иде. Кассир хатын акча санап биргәч, минем дә башым күккә тиде. Җитмәсә, энем килгән көннәр бит. Менә күрсәтәм инде мин анар Казанны. Кайда нинди кино бара, нинди спектакль куела — берсен дә калдырмабыз. Зоология бакчасындагы маймылларны да күрсен. Апасының нинди шәп җирдә укыганын сөйләп бирсен әле менә.

Без башта Яшь тамашачылар театрында балалар спектакленә барырга булдык. Көндез анда карасак, кичен цирк чиратта тора.

Билет булса ярар иде дип килгән идек, бәхетебез бар икән, касса тәрәзәсе шар ачык. Ренат чамасындагы өч-дүрт малайны искә алмасаң, күз төбәрлек кеше дә юк. Алары да театрга дип килгән балалар түгел, әллә кайдан күренеп тора, урамда уйнап йөргәннәр дә җылыныр җир эзләп бире кергәннәр. Мин аларга әйләнеп тә карамаган булыр идем, берсе Ренатның аркасына «дөң» итеп төртеп калды. Сөрлегеп китте мескенем. Арадан берсе — ябык, озын буйлысы, якасы яртылаш аерылып төшкән, сәдәпләре коелып беткән пальто кигәне, пальто астыннан каешланып каткан солдат гимнастеркасы күренеп торганы — ямьсез сүз әйтүгә, барысы бергә кычкырып көлә башладылар. Шунда ук безне онытып, төрткәләшергә, бәргәләшергә керештеләр. Кассадан билет сорап торган арада, әүмәкләшеп, миңа да кагылып киттеләр. Тизрәк билет алырга да, кереп китәргә кирәк бу җен балалары яныннан, дип уйлап бетермәдем, акчага дип кесәгә кулымны тыгуга, кайнар суга пешкәндәй чәчрәп киттем. Акчамнан җилләр искән! Себерке белән куып чыгаргандай, теге малайларның да берсе дә калмаган. Ачуымнан буыла язып, янымда торган энемә кычкырдым:

— Кая киттеләр?

— Те-тегендә, урамга, — диде энем, куркуыннанмы тотлыгып.

— Нәрсә карап тордың, акчаны урладылар бит әнә!

— Алар миңа куян колагы күрсәттеләр...

— Алай булгач, куян колагына карап тор инде, яме!

Ашардай булып энемнең күзләренә караган идем, имәнеп киттем. Күзләр түгел, кичеп чыга алмаслык хәсрәт диңгезе иде — курку да, үкенү дә, апасын кызгану да — барысы да бар иде анда. Кинәт миңа бик оят булып китте. Ни гаебе бар соң әле бу баланың? Үз гаебемне аңар сылтыйм түгелме соң? Үзем ачык авыз булгач, ул ни эшләсен. Энемне юатырлык, күңелен күрерлек сүзләр дә таба алмыйм үзем.

Мөслиха янына кереп хәлемне сөйләп бирергә теләү Матбугат йорты янынан узып барганда башыма килде бугай. Нәрсәдер өмет итүдән түгел, эчемне бушатасым килеп керергә булдым. Дөньяның бөтен кайгы-хәсрәтенә төкереп карый торган, бер тиен акча тотмыйча Сахалин хәтле җирдән кайта алган тапкыр һәм батыр кыз дип уйлаганга, җан тынычлыгы эзләп килдем мин аның янына.

Ул, чыннан да, күрүгә үк:

— Нәрсә булды, төсең качкан? — дип сорады.

Бүлмәдәге гөлләргә су сибә-сибә зарымны тыңлап торды да, банкасын куеп: «Утырып торыгыз әле, мин хәзер», — дип чыгып та китте.

Хәзер дигәне шактыйга сузылды аның. Кемнәрдер ишек ачып карады, кайсыдыр, Мөслиха юкмени, дип сорады. Соры шәлен күкрәгенә чалыштырып бәйләгән, яшүсмерләр кебек бәләкәй гәүдәле, кара хатын кереп, газетләр актара-актара шактый озак тәмәке пыскытып утырды. Мин инде, килүемә үкенеп, чыгып китәргә җыенган идем, авыз ерып Мөслиха әйләнеп керде. Ул минем турыда онытканга да икән инде. Коридорда танышын очратып, шуның белән сөйләшеп торганнар. Үпкәләсәң үпкәлә, үпкәләмәсәң юк инде бу кызга.

Безгә инде китәргә бик вакыт иде, Шәрәф Мөдәррис кереп, үземнән-үзем тукталып калдым. Тукай клубында шигырь укыганын тыңласам да, болай якыннан күргәнем юк иде әле. Алар Мөслиха белән сөйләшеп торган арада иркенләп күзәттем үзен. Бераз бөкерәебрәк йөри торган, уртачадан калкуырак буйлы кеше икән. Сугышның башыннан ахырына хәтле йөреп, рейхстагның җимерекләренә утырып Казанга хат язса да (мин боларны шигырь кичәсендә сөйләнгән сүзләр-

дән белә иде), ярым хәрбиләрчә кара китель, галифе һәм күн итектән йөрсә дә, солдатларча пөхтәлек һәм житезлек сизмәдем мин анда. Йомшак, юка чәчләрен артка тарап җибәргән, ачык, киң маңгае йөзен озынчалатып күрсәтә. Бу йөзне шактый зур борын һәм озын керфекләр артына яшеренгән соры күзләр бизәп тора. Ул бөтен кыяфәте белән тыныч тормыш өчен яратылган, ялгыз бүлмәдә шигырь язып кына утырырга тиеш кешегә ошый иде. Сөйләшүе кызык, кайбер авазларны мишәрчәләтеп, йомшак итеп әйтә. Аласы китапларын алып, эшен бетергәч, миңа борылып карады да:

— Иптәш кызың белән таныштырмадың да,— диде Мөслихага.

— Ләбибә. Университетта укый. Шигырьләр яза.

— «Зәңгәр чәчәкме?» — диде Шәрәф һәм аптырап торуымны күргәч, аңлатып бирде.— Күптән түгел Гыйззәтуллинага кергән идем. Яшьләрдән өметле шагыйрьләр бармы, дим. Бар, ди ул, кызлардан да шигырь язучы бар. «Зәңгәр чәчәк» шигырен шунда укыдым. Яраткан чәчәгем ул минем.

Газетада басылган шигырем турында әйтүен көткән идем. Культура бүлегендә эшли, диделәр бит аны. Күрми калуы турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Бәлки әле басарга үзе үк әзерләп биргәндер. Билгеле инде, ошатмаган ул аны, бары тик Латыйф ага Җәләй кебек олы кеше китергәнгә генә каршы килмәгәндер. «Зәңгәр чәчәк»не дә үзе яраткан өчен генә искә алды түгелме соң? Димәк, шигырь язуыма житди эш итеп карамый ул. Болай да җаным кыйналган чак иде, кинәт күңелем сүрелде. Эчемдәге йөземә дә чыкты, ахры.

— Сезгә нәрсә булды, күңелсезләндегез.

— Казалы булган әле ул, акчасын алдырган,— диде Мөслиха, Шәрәфнең соравына каршы.

Шагыйрь миңа бөтенләй чит кеше. Әле беренче очрашуыбыз һәм бер-ике авыз сүз алышудан узганыбыз юк. Дөресрәге, мин түгел, ул сөйләде бит әле. Җитмәсә, күңелемне күтәрерлек, канатландырырлык сүз дә әйтмәде. Юк инде, чит кеше алдында мескенләнеп, ачык авыз булуым турында сөйләп торасым юк.

— Булды инде,— дип кенә куйдым.

— Студентның акчасыз калуы начар,— диде Шәрәф һәм куен кесәсеннән акча алып, санамый-нитми, миңа сузды.— Шушы житеп торырмы?

Алырга да, алмаска да белмәдем мин ул акчаны. Күктән төшкән бу ярдәмгә сөенмәдем дип әйтсәм ялган булыр, сөендем, билгеле.

— Аның хәтлене... Кайчан кайтарып бирәм әле мин аны...

— Стипендия алган саен өч-дүрт тәңкә биреп барсаң ярар, тәмәкелек булса, миңа шул житкән.

Ни әйтергә белмичә әле Мөслихагә, әле Шәрәфкә, әле энем Ренатка карап алдым.

— Ал инде, Ләбибә апа, ал инде,— дигән ялваруны күрдем энемнең күзләрендә...

Мин, әлбәттә, бик тәртипле кешедәй, эзләп-эзләп, бурычымны бирә бардым. Шушы «финанс операциясе» якынаеп китүебез өчен бер сәбәп булыр дип, башта ук уйламасам да, тора-бара ул көннәр үзем өчен дә күңелле вакыйга булып китте. Очрашулар ешая барды. Берара озак кына күзенә күренми торгач, артымнан эзләп, тулай торакка ук килгән бу. Шунда бүлмәдәш кызлар белән дә танышып китте, озакламый үз кешегә әйләнде. Мин инде, вәгъдәле кеше буларак, акчам булуга бурычымны кайтарырга тырыша идем. Тик аңа карап, һич кимәтә алмыйм шуны. Бик өзелгән чакларымда тагын Шәрәф ярдәмгә килә. Яңадан ваклап-ваклап түләүләр китә...

# ШИГЪРИЯТ



## Нәҗибә Әминева

* * *

Гел бөекләр, гел матурлар
Йөри күк тирә-якта —
Бөтен кешене яратам
Җаным илһамлы чакта...

Ходаем, канат бирче, дип
Тели идем элек мин.
Инде менә үзем күккә
Күтәрелгән кебекмен.

...Үтә ул чак,
Бар дөньяның
Ачыла да чын йөзе:
Җир икән бит, бар икән бит
«Киенү», «ашау» сүзе...

Тартылсаң да, талпынсаң да
Аяклар җирдән купмый.
Дөньялыкта, яшәр өчен,
Ямьсезләнәсең күпме.

И тагын илһамлы мәлдә
Булырга бераз гына...
...Ходаем, канат бир —
Мине
Күтәр җирдән аз гына!..

---

Нәҗибә ӘМИНЕВА — *Башкортстанның Кушнаренко районы Әхмәт авылында яши. Башкорт телендә басылган берничә китап авторы. Шагыйрә Казан көндәлек матбугатында, шул исәптән журналыбызда да басылып килә.*

## Догам

«Ярлыкагыл,— дип,— үземне,
Әткәм-әнкәмне, Ходам»,
Балачакта кылган догам
Күр, инде онытылган!..

Безнең иманлы чакларга
Охшамас шул балалар,
«Гөнаһлыга — тәмуг» дисәң,
Ышанмас шул балалар...

Әй булсаң син, Теге дөнья,
Галәмдә бер почмакта,
Тәмугларда кайнап алгач,
Керер идек оҗмахка.

(Җирдә бит гөнаһсызлар да
Яши алмый казасыз,
Җир күтәрмәс гөнаһлылар
Кала кайчак җәзасыз...)

Әйе, ышаныч какшаган,
Гөнаһлы безнең күңел...
Гөнаһлы, әмма без әле
Мәңге тәмуглы түгел.

Түгел,
Ах, Тукай ярдәме —
Яралып килә догам:
«Ярлыкагылчы үземне,
Балаларымны, Ходам».

## Алда

Алда әле,
Әле күпне
Күреп китәсе — алда.
Бәхет белән бер-беребезне
Тәбрик итәсе — алда.
Кайгылардан бер-беребезне
Юатасылар — алда.
Бер-беребезне мәңгелеккә
Югалтасылар — алда...

## Сизмәм...

Хәлемне аңламый гөлләр —
Торалар гел шатланып,
Өзгәләнеп, өсләренә
Еласам да капланып...

Теләр идем хыянәтне,
Нахакларны сизмәскә.

Мин дә берчак булырмын бит
Үлән, тузан йә чәчкә?..

Өзелмәс ул чак үзәгем,
Башканыкын да өзмәм.
Түшләренә кадасыннар,
Йә таптасыннар — сизмәм...

* * *

Бу төннәрдә ай-йолдыздан
Ала алмыйм күземне,
Ачам Ай нурланган якка,
Яктылыкка йөземне.

Бу көннәрдә учым сузам
Кояшка, ак болытка.

Нигә җан күккә тартыла,
Үзем җирдә булып та?..—

Мәңгелек иленә шулай
Тартылган чакмы әллә?
Күкрәктән чыгып, бер күккә
Ашуы хакмы әллә?..

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Фаяз Фәиз**



# ИКЕ ТӨРГӘК — ИКЕ ЯЗМЫШ

хикәя

## I

Сәлам, дустым! Таныш булыйк: мин — яшь укытучы, ягъни пединститутны яңа гына тәмамлаган «юеш борын». «Юеш борын» булсам да, бер авыл мәктәбенә директор урынбасары итеп куйдылар әнә үземне. Ийе, димәк, сәләтем бар. Ә кәк же... Хәзер минем алдымда бөтен укытучы — үзләре, «юеш борын». Ийе... Пеләш башлы сәрхүш Рафик Сөләйманович та, өстәленә менеп укучы дәфтәрләрен өстән генә күзәтүче Васил Хөсәенович та, склеротик Әминә Габдулловна да, сөт белән күкәй кебек ризыкларны уңайсызланып булса да укучылардан җыючы ялгыз пенсионер Илһам Хәсәнович тә, кайбер җирс чирле булу сәбәпле җыелышларда да аягүрә басып торучы Борһан Фатыйхович та... Ийе, әйтәм ич, бөтенесе минем алдымда — юеш борыннар, чөнки алар миңа буйсына. Ә мин — житәкче.

Бервакыт мөхтәрәм директорыбыз — кайсы яктан килеп үлчәсәң дә тигез размерлы гәүдә иясе — миңа чираттагы мөһим вазифа йөкләде. Мәктәп артындагы чамасыз тулган бәдрәфне бетереп, яңа тәһарәтханәгә мөмкин кадәр тирәнрәк чокыр казырга кирәк иде. Ә нәрсә, була ул... Мин идарә итә беләм. Әй, кем анда — сәрхүшләр, склеротиклар, ачлытуклылар, чирлеләр, өстәлгә үрмәләп менүчеләр һәм башка зәгыйфь сәвит укытучылары — живо! Көрәк-ломнарыгызны алыгыз да минем янга җыйналыгыз! Безне бөек эш көтә — киләчәк көнне кайгыртып, мәңгелек чокыр казу!

Кызу эш башланды. Мин, әлбәттә, элеккеге коммунистларча, ә хәзерге демократларча үрнәк күрсәтеп, бер метр чамасы җирне беренче

---

Фаяз ФӘИЗ *(1956) — яшь язучы, тәрҗемәче. Проза әсәре белән журналда беренче тапкыр катнаша. Казанда яши.*

булып үзем казыдым. Аннары... Аннары эш китте инде. Әйе... Җыен имгәкләрне куып, ул чокырны үз кулларым белән Америка кыйтгасына барып җитәрлек итеп казыдым. Ийе...

Эш тәмамланды диярлек. Чокыр төбеннән тырпаеп чыккан ниндидер тимерне суырып алдым да өскә ыргыттым. Миңа буйсынучылар тимерне шундук җентекләп тикшерергә тотындылар.

— Авыр...— дип мыгырданды мәгънәле тавыш белән сәрхүш Рафик Сөләйманович.

Ач пенсионер Илһам Хәсәнович табылдыкны иң әүвәл тешләп карады, аннары тагын да мәгънәле итеп:

— Иптәшләр, тимер бу,— диде.

— Кая ул, кая?— дип кызыксынды тимер кисәгенә күзе төшкән сөекле Әминә Габдулловнабыз.

— Басып торганмы ул, ятыпмы?— дип үз сөален бирде көрәк тоткан Борһан Фатыйхович.

— Тикшерергә кирәк аны,— дип кырыс кына йомгаклады өстәл өсте башлыгы Васил Хөсәенович.

...Тимер кисәге, чыннан да, күрер күзгә сәер күренә иде. Ул авыр, тутыккан, ләкин һаман да нык, сынган чалгы яисә кылыч рәвешендәрәк иде. Табылдыкны агачка ыргытып карадым —«чек» итеп кенә кадалды бит черек нәмәрсә!

— Райүзәктә бер юләр бар,— дип хихылдады Рафик Сөләйманович,— районыбызның данлы тарихчысы. Тегенди-мондый чокырларда казыну — нәкъ аның эше. Аның янына бар, ул бу тимер кисәген, һичшиксез, борынгы грекныкы дияр, хи-хи!.. Киңәш өчен бер ярты, нәчәльник...

Ярар, буш шешә авызын яларга әзер торган Рафик абзый, рәхмәт, кәнишне, киңәшең өчен. Ә нигә? Иртәгә үк райүзәккә барырмын да...

Тәки барып чыктым. Районыбызның данлы тарихчысы Сәет абый Әхмәтҗанов, табылдыгымны бераз вакыт тикшергәннән соң, дулкынланды: күзләре нурлана, куллары калтырана.

— Бу нәрсә икәнлеген беләсеңме, улым?— дип сорады ул киеренке һәм тантаналы тавыш белән.

«Эһем... Теге хәмер колы хаклы булып чыкты микәнни? Бу абзый, чыннан да, борынгы грек әйберен тапкан кебек кылана».

— Балам, бу бит борынгы болгар кылычына бик охшаш әйбер. Бабаларыбыз кулында булганлыгы ихтимал моның. Борынгы болгар кылычының бердәнбер нөсхәсе Хельсинки музеенда гына саклана бит. И балам, Казанга бар, белгечләргә күрсәт бу табылдыкны, тикшерсеннәр, карасыннар. И балам...

Аның дулкынлануы миңа да күчте. Менә бит нәрсә булып чыкты. Эш хәйран җитди икән ләбаса.

Болгар... Бөек Болгар шәһәре... Сувар... Биләр... Җүкәтау... Ибраһим... Ак Сарай... Ничек әле?

Итил суы ака торур,
Кыя төби кака торур...

Чү... Күз алдыма болгар алыбы пәйда булды. Менә ул Идел буена килеп басты. Карашы — елганың аргы ягында, кулы — кылыч сабында, кылычы — кынында. Калкан тимерендә шәфәкъ нурлары чагылып уйный. Аты-аргамагы — бер урында тотып кара аны! — муенын дугадай бөгеп кешнәп ала, җиңел тоякларын җиргә бәрә.

Аргы яктан зур көймә якынлаша. Ай-һайлап, ишкәкчеләр су көмешен урталай ярып алалар. Болгар алыбы елмая, кыныннан кылычын чыгара һәм аны һавага чөеп куя: «Мин килдем, дуслар, мин сезгә җиңү турыйда хәбәр алып килдем!» — дия сыман...

* * *

— Әй, син, бәдрәф нәчәлниге! Баганага бәреләсең бит, күзлегеңне ватасың, дим, мырый!..

Бу — безнең мөхтәрәм, ыспай директор тавышы. Мәктәпнең күгәреп беткән йөк машинасына утырып авылга кайтышы икән. Кызмача. Янәшәсендә — ниндидер хатын.

— Әй, шәһәр чебене! Күрше авылда да бәдрәф чокыры казырга кирәк, диләр. Барасың мәллә? Бәлки, бу юлы инде бер чүлмәк алтын акча табарсың, ха-ха-ха!..

— Хи-хи-хи! — дип кушылды аңа нечкә тавышлы, кып-кызыл иренле хатын...

## II

Апрель ахыры иде бугай. Язгы сулар ташып, елгалар кузгалган чак. Идел елгасында да ат күтәрерлек бозлар ага иде әле. Паром йөрми икән. Кара мыеклы каравылчы паромны, эре бозлар агып беткәч кенә йөри башлар, — диде.

Идел суы ага торды. Эреле-ваклы бозларның мәһабәт йөзүе мине ни өчендер уйга-моңга салды. Әбием җырлаган көй исемә төште:

> Киң Иделне кичкәндә,
> Беләгем талды ишкәндә;
> Тулган Айга елап карыйм,
> Балалар искә төшкәндә...

Тузан туздырып бер «КамАЗ» машинасы килеп туктады.

— Нәрсә, йөрмиме әллә паром? — дип сорады түбәтәйле шофер егет.

— Күрмисеңмени?

— Тьфү, ләгънәт! Чаллы аша барырга туры килер, ахры. Ерак булса да...

Кабинадан чыгып, егет тәмәке көйрәтеп җибәрде.

Җил.

Идел суы ага тора.

Иделне кичсәң, Казанга туп-туры юл — синең алда. Хәер, Казанга туры юл бар микән ул?

Чү... Идел ягыннан мотор тавышы ишетелде.

Әйе, безгә таба зур көймә якынлаша иде. Бозлардан читләшеп, «Прогресс» дигән моторлы көймә безнең ярга килеп туктады. Көймәчеләргә ниндидер төргәк сузып, ике егет җиргә төште. Баксаң, ул төргәктә — аракы икән. Минут та узмагандыр, ике көймәче «гол-голт» итеп хәмерне чөмерә дә башладылар. Бераздан:

— Әйдә, кем теге якка чыга? — дип кычкырды «бравый» тавышлы көймәче егет. — Нибары бер ярты! Әйе бит, Витька? Даром-шаром!

Икенче көймәче дә берьюлы җанланып китте.

— И-их, Ильдуска-а, живем, мать твою!.. — дип тыпырчынды сары чәчлесе һәм җырларга кереште:

— Еду тиха-а па Волги-и...

— Парень, ну ты че, — бу Витьканың миңа эндәшүе иде, — Вали пузырь и прыгай в наш ковчег, а то без тебя якорь поднимаем.

> Еду тиха-а па Волги-и.
> И ни знаю, куда приплыву-у...

Казан! Кайда син, пайтәхетем? Йөрәгем сиңа ашкына, нурлы, моңлы Казан! Ә син... Ә син нигәдер якынлашкан саен ерагаясың.

Түземсезлек дигән сыйфат миңа тынгылык бирми. Һаман тизлек кирәк. Тизрәк, тизрәк, тизрәк, аһ, тизрәк!.. Өлгерим, дип, гомер буе ашыгам. Яратырга, ләгънәтләргә, фида кылырга, аңлатырга, аңларга һәм аңламаска өлгермим дип куркам...

Менә бүген дә ашыгам. Чаллы аша Казанга бару минем өчен гаять ерак, озак сәфәр булып күренә. Җитмәсә, күз алдымда — рәхим итегез, ике батыр көймәче егет. Тик... Тик... Аракы юк ич минем, каһәр... Аракы...

— Эй, парень, я тебе деньги дам, перевези,— дип сорап карыйм.

— Мы денег не пьем. Верно, Ильдусик? Придется отчаливать.

— Погоди!.. А если найду?

— Находи! — дип кызганды мине Витька дигәне.— Мы с Ильдуской пыдаждем малость.

Еду тиха-а па Волги-и,
Еду тиха-а-а па Волги-и-и!..

Мин тәмәке пыскыткан шофер янына йөгердем.

— Дустым! Йә, тыңла инде сүземне, сиңа да акча бирермен. Якындагы күрше авылга барып, аракымы, нәрсәме табыйк инде, ә?

— Юкка маташасың, брат, ташла ла бу чучкаларны. Әйдә, лутчы Чаллы аша элдертәбез, күп алмамын, янмыйдыр ич?

— Яна шул, дускаем, яна!..

— И-их... Төштең башыма. Ярый, киттек, тик алдан ук әйтәм: ярты сәгать кенә вакытым бар.

Әйткән сүз — аткан ук. Киттек.

Шуннан?

Шуннан... Ни әйтим соң?..

Бөтендөнья күләмендә танылган Бөек юллар бар.

Кытайдан безнең борынгы Ватаныбыз аша узган Бөек ефәк юлы булганы хак.

Көнчыгыштан Европага сузылган тәмләткечләр юлы мәгълүм.

Варягларның грекларга кылган бөек юлларын беләбез.

Викингларның Альбион утрауларына кадәр сузылган Бөек юлы булган.

Кубрат хан углы Гәспәрухның Балкан җирләренә бәхетле һәм фаҗигале бөек юлы булганы — хак.

Төркиләрнең Бөек каганатлар юлы мәгълүм.

Урыс патшалыкларының бөек империя юлын беләбез һәм аның ачысын татыйбыз.

Әмма... Әмма Бөек аракы юлы кайсы илдә вә кайсы мәдәни тарафта бар икән? Әйе, сүз дөрес уйлыйсыз: бернинди цивилизация дә белмәгән Бөек аракы юлы безнең ил буенча гына еландай боргаланып бара, һәм гаепсез корбаннар исәбенә чамасыз симергән гыйфрит бу юлдан тантаналы рәвештә атлый. Хәер, гыйфритның башы һәрвакыт аек, чөнки хәмер ерткычның йөрәгенә, күңеленә генә сеңә, башы аның һәрвакыт аек. Башы аек, күңеле исерек явызны ничек туктатырга? Кемнең көченнән килә бу?

* * *

Көймә бозлар арасында йөзә. Минем кулда ике төргәк: берсендә — тимер табылдык, икенчесендә — аракы.

— Еду тиха-а па Волги-и. Еду тиха-а... Тиха!.. Б-р-р!.. Ильдусик, куда заворачиваешь, падла?

Бозлар ага.

Көймә әле сулга, әле уңга борыла, йә артка чигенә, йә алга сикерә, «кырт» итеп бозларга тиеп китә.

Әйләнеп-тулганып бозлар ага, бихисап бозлар кәрваны... Яз... Җиһанга җылылык, назлылык рәхәте төшкән вакытта салкын боз кисәкләре Иделне баскан. Агып бетәрлек түгел шикелле.

Көймәчеләр куркудан айный башлады, маңгайларына тир чыкты: без чираттагы бозлар агымының нәкъ уртасына кергәнбез икән. Ат кадәрле бозлар, көймәне сытарга җыенгандай, хәвефле хәрәкәтләнә. Менә Витька, ишкәген алып, бозларны читкә этә-төртә башлады. Үзе сүгенә. Икенче яктан янә икенче бер боз кисәге якынлаша.

— А-а, черт!

Көймә чайкала. Витька, миңа икенче ишкәк тоттырып, ярдәм итәргә куша, нәрсәдер кычкыра. Кулымдагы төргәкләрне утыргыч өстенә куеп, мин дә бозлар һөҗүменә каршы көрәшә башладым.

Дыңң!.. Дың!

«Прогресс»ның башы кинәт өскә таба күтәрелде, көймәнең бар гәүдәсе тетрәнде, аннары уң якка ава башлады. Аягым тайды. Мин дә авам микәнни? Боз кыйпылчыклары кайнаган су сулышы йөземне салкынайтты.

— Витек, держи этого придурка!

Витька миңа таба ыргыла. Егылмас өчен утыргычка ябышмакчы булам, ләкин эскәмия дә, урыныннан чыгып, минем егылу хәрәкәтен кабатлый башлый...

Аягымнан көчкә тотып алып калдылар үземне...

* * *

Җил. Бозлы Идел суы ага. Кояш. Тыныч. Көймәнең моторы гына дерелди. Башымда берсеннән-берсе авыррак уйлар. Кулымда — нибары бер төргәк. Их, нигә ике төргәктән нәкъ менә кылыч кисәге төрелгәне Идел төпкелен сайлаган? Миңа үз табылдыгым кадерлерәк иде. Нигә мин дә кылыч артыннан бозлы суга дөмекмәдем икән?

Кулымда — аракылы төргәк. Ярга чыккач, мин шушы хәмерне, әлбәттә, Витька белән Ильдусикларга бирдем. Хезмәтләре өчен, янәсе...

Ә Идел суы әле дә булса тыныч кына агып тора иде.

Хуш, дустым! Таныш булыйк...



**Дискуссия дәвам итә:**

***«БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ»***

**Рафаэль Сибат**

# БОРЧУЛАР ҺӘМ ӨМЕТ ЯНӘШӘ

## Безнең тормыш. Ул нинди?

Әйе, беренче нәрсә кирәк дигәндә, һәр адәм баласы өчен иң тәүгеләре: һава, су, ашар өчен ризык, торыр өчен йорт, кияр өчен кием, дип әйтелә. Шулар кирәк. Болар барысы да материаль нәрсәләр, кеше алардан башка бер көн түгел, бер минут та яши алмаска мөмкин. Мәсәлән, суларга һава бетсә, кеше дә үләчәк. Әлеге материаль кирәклек күпмедер тәэмин ителгәч, кеше үзеннән үзе җан ризыгына үрелә.

Үзләрен-материалист дип атаучылар тәгълиматларында төп фикерне нәкъ менә шул матди бөтенлеккә юнәлттеләр һәм моның белән ялгышмадылар да. Аларның максаты ашау-эчү, киенү һәм сексуаль теләкләрдән башкаларны оныткан кешеләр — «эш атлары» булдыру иде. «Эш атлары» тыңлаучан бит. Әлеге эшче кешеләрдә Акыл-Аң, Җан-Рух кебек нәрсәләр үтерелергә, һич югы йоклаган хәлдә тотылырга тиеш иде. Моның өчен иң шәп наркоз — киләчәк шәп тормыш турындагы коммунистик идеология булды.

Россиядәге тоталитар режим ахыргы патшаларга кадәр нәкъ әнә шуңа омтылды һәм, йөз үк булмаса да, 90% моңа иреште дә. Интеллигенциянең кайбер алдынгы вәкилләреннән кала, йә кем үзбашка уйлады да, кем үз фикерен әйтергә җөрьәт итте?

Безнең илдәге халыкны 70 ел буе тимер сандыкка ябып, бикләп тоттылар. Ватан тоташ бер төрмә хәлендә булып, «дәүләт кеше өчен түгел, кеше дәүләт өчен» дигән унитар принцип астында яшәттеләр. Яшәмәдек — яшәттеләр!

Фикер йозак астында булып, бер генә «бөек юл», бер генә «дөреслек», бер генә «тәгълимат» бар иде. Синң юлны сызганнармы — тавышыңны чыгарма, бар шул юлдан! Ә «тегеләр»неке ялган — шуны бел!

Акыл-Аң, Җан-Рух тимер келәшчәләргә кысылган кыршаудагы җәмгыятьтә әдәбият-сәнгать, гомумән, культура яши һәм үсә аламы? Әйе, яши, зәгыйфь хәлдә булса да үсәргә тырыша. Асфальт юлны үлән тишкән кебек, язучы уе да карагруһ цензорлар калканын бәреп чыга ала. Кеше тәненә — булса да, җанына төрмә юк! Дөньяда иң иркле нәрсә адәм үзе түгел, ә аның җаны... Әнә шуңа күрә: бәндә баласы ач булса да, тук булса да, җан үзенең бервакытта да кол түгеллеген, иркле икәнен һәрвакыт сизеп килә һәм җай чыккан саен моны сиздереп тора.

Шуның иң көчле үрнәкләре әдәбиятта чагылды. Күпме генә бумасыннар, әдәбиятның тыштан беленеп торган тын алуыннан башка эчке сулышы да бар.

Фикер әнә шунда яшеренә, әнә шунда ирекле уйлар ята, әнә шунда яшәп килә торган тәртипләрдән — ризасызлык, канәгатьсезлек. Эчке сулыш подтекст кына түгел, әсәрнең көе-агышы, астан килә торган авазы, сак колак кына тота алган тавышы, иң зирәк һәм нечкә җаннар гына аңлый-тоя-ишетә алган аһәңе дә әнә шунда.

Тик шулай да бу сулышның яшеренүе, бик тирәнгә төпкә китүе әсәр тукымасын тотрыксыз итәргә һәм купләргә ул сизелмәскә мөмкин. Шуның белән әсәр үзкыйммәтен югалтып, тәэсир итү көче кимүгә китерә. Мондый артык яшеренеп язылган әдәбиятны телле, әмма тешсез әдәбият дип атарга була. Р. Батулланың 60 нчы елларда коммунизмның мираж икәнен аңлатып язган «Мираж» әсәрен аңламадылар әнә.

Ничек кенә булмасын, иң явыз цензура еллары да күңеленә иҗат орлыгы салынган кешене нидер тудырудан тыя алмый. Үзе өчен генә язамы, башкалар өчен дәме, иҗатчы гел рухи киңлек эзли, әгәр аны бик кыссалар, шул ук җан-күңел читкә тартыла, тәнне туган илен ташлап китәргә дә көчли. Моңа мисаллар рус әдәбиятында бик күп. Татар әдәбиятында да бар. Революциядән соң, мәсәлән, Гаяз Исхакый.

Әнә шулай, система-режим-тормыш кысуына карамастан, кеше җанының балкышы булган әдәбият яшәргә тырыша. Әмма бу бик тилмереп, бик авырдан яшәү. Хәтта Совет чоры рус әдәбиятын күпме генә зур һәм бөек дип мактама, Россия — СССРның Нобель премиясе лауреатлары Бунин, Солженицын, Бродскийны тудырды һәм үстерде генә, ә дөньяга аларны Франция һәм Америка бирде. Ни кызганыч, иң зур бүләккә ия булган дүрт бөек язучыдан өчесе «социалистик оҗмах»тан чит илләргә — «капиталистик тәмуг»ка качкан. Җәннәттән дә качалар микәнни соң? Безнең тормыш әнә шундый ташлап качардай җәннәт иде. Әмма илнең барлык гражданнары да эмиграциягә китә алмый, шуның кебек, бик күп язучылар да үз илендә калып, шунда иҗат иттеләр. Бер сүз белән әйткәндә, аларны илдән качарлык хәлгә китерүчеләр дә булмады, үзләре дә күсәк күтәрмәделәр. Казаннан Аксенов чит илгә китсә, аның белән бергә уйнап үскән Рөстәм Кутуй калды. Ә чын саф татар язучылары китү турында уйлап та карамадылар. Алар моны дезертирлык итеп кабул иттеләр. Тормыш нинди генә авыр, хәтта кабахәт булмасын — Туган Ил, Ватан төшенчәсен татар язучылары һәрвакыт иң изге хис итеп йөрәк түрендә сакладылар. Ә бит безнең татар тормышы тагын да ныграк кысылган, ныгракватылган иде...

Ә аның әдәбияты?

## Безнең әдәбият. Ул кемгә кирәк?

Әдәбият дигәч тә... һәркемнең әдәбиятка аз булса да үзенчә карашы бар. Иң беренче, әдәбият — үз-үзеңне танып белү чарасы ул. Үзеңне чагылдыру чарасы да. Икенчедән, әдәбият — сүзләр диңгезе көзгесендә кешеләр тормышының чагылышы. Әмма бу бәяләмәне «кешеләр» белән, бигрәк тә «үзең» белән генә чикләп калабыз икән, берьяклылык кына түгел, шактый ук беркатлылык та булыр, чөнки: әдәбият — теге яки бу халык тормышының образлар ярдәмендә тудырылган параллель тарихы да ул, аның чын мәгънәсендә милли чагылышы. Нәкъ менә милли чагылышы!

Бүгенге көнне халык тормышын чагылдыру ике төп юнәлештә бара. Беренчесе — тәнкыйди юнәлеш.

Әле кичә генә яшәп килгән тәртипләрне, системаны, тоталитарчыларның халыкны изеп-таптап килүен күкләргә чөеп мактаган «коммунизм җырчылары» бүген тулы бер хор белән аны кычкырып хурлаучыларга әйләнделәр. Медальнең икенче ягын күрсәттеләрме? Кичә «күн» иде, бүген — «иләк»ме?

Йә, әйтегез, мондый икейөзлелеккә, тотрыксыз идеягә, үзгәрүчән максат-иманга корылган әдәбият көчле һәм халык яратырдай булыр микән? Һәм шунысы да гаҗәп: шул ук кичә генә бу системадан җәбер күргән, аңа баш имәгән, киресенчә аның кара якларын сүккән Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Рабит Батулла кебекләр алай ук шаулап йөрмиләр. Алар элек ничек язсалар, һаман да шулай тыныч кына эшләрен дәвам итәләр. Чөнки бу алар өчен яңалык түгел.

Тәнкыйди юнәлештә язган, үзләренең яшьлек иманнарын югалтмаган, дөресрәге режим дигәненә бик үк буялмаган тагы берничә урта яшьләрдәге талантлы

авторларны да атамый ярамастыр. Марсель Галиев («Оҗмах ачкычы кемдә?»), Фәрит Гыйльми («Зәйтүнәкәй-акчарлагым»), Ринат Мөхәммәдиев («Кенәри — читлек кошы»).

Әдәби иҗаттагы икенче юнәлешне «Милли агым», дип билгеләү дөрес булыр. Нәрсә соң ул «Милли агым?» Бу чын-саф татарча, туган тел, халыкның гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре, дине, милли берлеге, милли характеры өчен янып-көеп язылган әсәрләр. Әнә шуларны ачыклау һәм күрсәтү. Аларга нинди идея салына? Егылган Милли Аңны күтәреп торгызу, җирдә яткан яисә сабый баладай мүкәләп кенә йөргән Милли Горурлыкны аягына бастыру. Икенче төрле гоманласак, бу халык өчен, халык турында язу. Ифрат авыр мәсьәлә!

Күренекле язучы Аяз Гыйләҗев әйткәндәй, бездәге кайбер әсәрләрдә Әхмәт, Галия, Илшат, Ләйләләр урынына Алеша, Галя, Илья, Лена дип куйсаң да, барыбер үзгәрмәс кебек. Өстәвенә, күп кенә яшьләр үзләрен шулай дип йөриләр дә. Тормыш шундый — язучы шуны чагылдыра.

Ләкин миллилек кирәк! Бүгенге әсәрләргә бәя биргәндә дә иң беренче миллилек каланчасыннан килергә иде. Әле искә алган мөхтәрәм язучыбыз да шуны хуплый. Безнең әдәбият икән — татар әдәбияты булсын! Ул тәүдә татар халкы өчен хезмәт итәргә тиеш. Гомумән, татар әдәбиятының татар укучысы булмаса, кемгә кирәк ул? Беркемгә дә. Иң ахырда китап язучы кешеләр белән бер төркем китап сөючеләр өчен генә кирәк булачак бит. Монысы инде элитар әдәбият. Күпмедер дәрәҗәдә ул да яшәргә тиештер, ләкин теле югалган, милли укучылары булмаган әдәбият — ул инде үле китаплар патшалыгы. Менә шуңа да әдәбият халык өчен яшәргә, ә халык үз әдәбиятын кайгыртырга тиеш. Шушыннан чыгып әйтә алабыз: бүгенге көндә дә һәм гомер-гомергә әдәбият өчен иң зур проблема: Милләтнең этнос буларак саклануы! Милләтнең үсеше һәм чәчәк атуы!

Әсәрләренә тотынганда, әнә шуны уйлап язарга тиештер язучылар. Бармы андыйлар бездә? Бар, әлбәттә. Шул ук Аяз Гыйләҗевнын тәнкыйди планда язылган «Балта кем кулында?» романын гына алыйк. Монда милләтнең манкорт өлеше — кулларында власть (балта) булганнар һәм милләтнең властьсыз чын татар өлеше күрсәтелә. Алар, соңгылары — гади, инсафлы, иманлы авыл кешеләре. Бәрелеш әнә шулар арасында. Мондый конфликт хәтта бер гаилә эчендә дә булырга мөмкин. Язучы дөрес тотып алган: идарәчеләрнең бик күбесе милләтебезне үтерүчеләр иде. Халыкны — эшче, крестьяннарны изүчеләр генә түгел, ә Милләтне (!) үтерүчеләр.

«Милли» язуның иң яхшы үрнәкләрен зур талант иясе Мөхәммәт Мәһдиев бирде: «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» һ. б. Гомумән, аның һәр әсәреннән, хәтта повесть-романнарындагы һәрбер деталеннән Татарлык затлы хушбуй күк аңкып тора. Милли әсәр шулай булырга тиеш тә. Ә бит болай язучылар күп түгел, әдәбиятны тулыландырып-җанландырып җибәрү өчен нәкъ менә шундый проза кирәк. Шул җитми...

Тагы ниләр җитми?

## Пессимизм яки безгә ниләр җитми?

Чыннан да... Инде сүз алганбыз икән, әйләнми-чолганмый гына әйтик соң: ниләр җитми безнең әдәбиятка? Шәхси фикерләребезне шәхестән башлыйк: иң беренче көчле шәхес җитми! Минемчә, проза әсәре — язучының башкалар турында язып, үзе һәм үз идеяләре турында сөйләве ул. Үзәктә шул умыртка баганасы тормый икән — әсәр аягүрә басып тора алмый. Шуңа да безгә иң әүвәл кыю фикер, яңа ачышлар, фәлсәфи анализлый белү җитми. Татар язучылары, бигрәк тә прозаиклары, философлар түгел. Эш аты булган татар халкы чын философларны аз тудырган. Алары да үткән чорларда гына. Кол халык ирекле уйлый алмый. Бүгенге көнне бик аз шагыйрьләрдә генә сизелә фәлсәфә. Ә бит Достоевский, Толстой, Сартр кебек классикларга һәм бүгенге дөнья әдәбиятының иң зур исемнәренә карап баксак, алар язучылар гына түгел, шактые философлар, күбесе — фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарлык уй-фикер җыегәрлегендәге инсаннар. Тормышны ике күз белән күреп язу бер нәрсә, ә шуңа җиде күңел күзе белән карап, мәгънә табу, шуны әзме-күпме генә шәйләүчеләргә аңламаганнарын ачыклап язу — икенче нәрсә. Бу нәрсәгә омтылу аз бездә, татар прозаиклары күбрәк тирәнгә түгел, ә озынлыкка язалар. Вертикаль кызыксындырмый — горизонталь!

Идеяләр төтендәй очкан, аяк астында тапталган чакта күпләр бигрәк тә югалып калды. Әзергә бәзерне тырыштыру рәхәт иде, ә күрсәтмәләрсез язу, үзенә Идел эзләү — бу куркыта, яисә көч житми.

Тагын...

Безнең язучыларда кыюлык юк. Тәвәккәл таш яра, ди. Безнекеләр ташка тотынмый, ә базардан көнбагыш алып чиртергә чаба — аны булдырабыз! Безгә жиңел булсын, кабыгын яруга ук төше чыксын.

Ижат — таш ярып орлык табу, үз күңеленә шуны чәчеп үстереп, кешеләргә күрсәтү.

Артык тыйнак без. Куркаклык белән мескенлек янында рәттән басып торучы тыйнаклык бу. Руслар әйткән «Дерзать!» бездә юк дәрәжәсендә. Үзара батыр булсак та, бер-береңне батырып кыйнаганда көчле кылансак та, читләр янында эреп калабыз, йөзгә шундук мескенлек чыга. Шуңамы, безнең әдәбият иярүче түгел, гомер буе иярүче. Ияручеләрдән лидерлар чыкмый, аларны югарыда бик күрергә теләмиләр, трибуналар — башкалар өчен. Дөнья әдәбияты мөнбәрләре дә... Язучыга иң элек ирек кирәк, мөстәкыйльлек кирәк. Татарстан тулысынча суверенитет алырга омтылган кебек, язучылар аның мөстәкыйльлеге өчен тырышып йөргәндә, үз ирекләре турында да онытмасалар, начар булмас иде. Сүз ижат иреге турында бара, чөнки ижатчы жанының ирексезлеге, бәхетсезлек һәм фажига булу өстенә, әдәбиятны коллыкка төшерүче, имгәтүче нәрсә ул.

Өченчедән, татар әдәбиятындагы яман чирләрнең берсе булып форма ярлылыгы, жанрларның бертөслеге дә тора. Бездә — бертөрле романнар, бертөрле повесть-хикәяләр. Бик күбесендә ачык һәм оригиналь стиль сизелми. Әйдәгез, мондый эксперимент уздырабыз: исемен куймый гына егерме язучының беркемгә дә билгеле булмаган берәр яңа әсәрен, әйтик, әдәбиятчы иптәшкә (гади укучыга түгел!) бирик һәм, укып карагач, кайсы әсәр кемнеке икәнен әйтүен көтик. Ул кемнәрне аерып алыр иде дисезме? Иманым камил: шул исемнәрне йөз-мең тапкыр кабатланган Ә. Еникине, Г. Бәшировны, М. Мәһдиевне, А. Гыйләжевне, М. Галиевне — тагын, күп дигәндә, биш-ун язучыны. Калганнарын бутый башлар, чөнки алар охшашлар. Үз йөзләре булганнары — без санап киткәннәр генә. Дөрес тә бит! Бездә стиль, әйтү рәвеше, «нәрсә турында түгел, ә ничек язарга?» дигән принцип начар эшләнгән. Хәтта саллы фикерле көчле әдәбиятчылар да стиль дигән нечкә-юка катлаулы челтәр турында киңәеп сөйләшергә яратмыйлар.

Ә әсәрнең агышы-тоны, музыкальлеге-моңы?

Гомумән, безнең әдәбият күбрәк коры сөйләп чыгуга гына корылган, бездә сурәтләү дигән нәрсә аз. Иң кулланылганы — хикәяләү алымы.

Әйтик, язучы берәр нәрсәне үзенчә күреп, үзенчә сурәтләп кенә карасын, «акыллы цензор — редактор» хәзер төзәтә: «дуга каш була мени? Ай каш, кара каш пжалысты, ә дуга каш бармый». Язучы бу кашны ни вакытта ник, ни өчен дуга итеп күрә, ул аны уйлап та карамый. Ә бит югыйсә барысы да герой характерына бәйләнгән, контекстан аңлашыла. Соң әдәбиятның байлыгы-матурлыгы да һәр язучының дөньяны үзенчә күрүеннән килә ләбаса. Менә шуңа һаман ияләнә алмыйбыз әле. Калып-стереотиптан чыга алмыйча жәфаланабыз. Мин ничек күрәм — син дә шулай күр, янәсе. Әлеге дә баягы 70 еллык идеология эше бу.

Йөрәккә тия торган әрнеткеч һәм пессимистик уйларны әйтеп бетерик инде. Күңелгә ошамаган як — язучылар ифрат аз язалар. Тирестә озак казынсаң гына энҗе чыгар дигәндәй, бик күп китаплардан берсе генә чын талантлы әсәр була һәм язучы төп шуның белән кешелек хәтерендә кала ич. Чын профессиональ язучы ел саен бер китап бастырып чыгарырга тиештер. Әнә французлардан Жорж Сименон үз гомерендә 600 том язган. Бу безнең, ким дигәндә, 50—60 татар язучысы язганга тора. Ярый, кемдер детектив жанрга түбәнсетеп тә карый, ди. Алай дисәк, Бальзакның «Кешелек комедиясе» 120 томнан торырга тиеш булган, 51 генә яшь яшәп тә ул шуның йөзләп томын язган...

Нишләп аз язабыз? Чөнки безнең татар әдәбиятында профессиональ булып 10—15 кенә әдип яза, калганнары тамак туйдыру өчен төрле җирләрдә эшләргә мәжбүрләр. Югыйсә, 7 миллионлы милләтнең, аз дигәндә, 700 профессиональ язучысы һәм 6—7 китап нәшрияты булырга тиеш. Ә безнең бер миллионлы эстонлыларныкы кадәр дә юк. Шулай булгач, ник язсын мескен татар язучысы, язган кадәрләрен кайда бастырырга да белми тилмереп йөри ич ул! Язылмагач, әдәбият каян килсен, бигрәк тә бөек әдәбият? Ә бөек әдәбиятның 10—20 бөек язучысы булырга тиеш.

Безнең проза миңа гүзәл бер кызны хәтерләтә. Ул гажәп матур: анда «шомырт кара бөдрә чәчләр», «айдай кашлар», «карлыгачдай күзләр», «чия

иреннәр». Әлеге туташ ифрат «тыйнак», «сабыр», «итагатьле». Бу чибәркәй бик тә әдәби сөйләшә, теле матур, әмма...

Көлеп җибәрә икән — аның тешсез икәнлеге күренә. Менә шулчак гүзәллек киңәт тоныкланып, төссезләнеп кала... Телле тешсез проза, телле тешсез әдәбият икән бу.

Менә шушындый пессимистик уйлар миндә.

Инде әллә оптимизмга да урын юкмы?

Бар! Ник булмасын, бар!!

## Оптимизм. Кемнәр бар?

Бөек тәнкыйтьче Белинский бервакыт: «Бездә әдәбият юк!» — дигән. Бу бит Пушкин, Лермонтов, Гогольләр иҗат иткән чорда! Болайга китсә, башкаларга ни дияргә кала?

Юк, Белинский ул вакытта француз әдәбиятының рус аңын яулаганын яхшы аңлаган (безнекен бүген рус әдәбияты яулаган кебек). Шуның өстенә аның хәтта Пушкин, Гоголь, Лермонтовларның да зур бер халык әдәбияты өчен аз диясе килгән. Иң кечкенә әдәбият та ике-өч исемгә генә атланып яши алмый. Шуңа күрә язучылар аз түгел, киресенчә күп кирәк икән. Сыйфат санга күчми, сан сыйфатка күчә. Икенче төрле әйткәндә, ике-өч арасыннан бер бөек язучы табуга караганда ике йөз, өч йөз әдип арасыннан табуы җиңелрәк. Табу-эзләү мәгънәсендә түгел, ә прозаикның ачылып китүе, зур әсәр язып танылуы төсмерендә алына.

Безнең татар әдәбиятына әдипләр килә тора, ачыла тора. Бар язучылар! Бар әдәбият! Барны бар диик әле.

Шундыйлардан берсе — Фоат Садри.

Ул үзенең «Таң җиле» романы белән шәп прозаик буларак нәкъ соңгы вакытта гына ачылды да китте. Тапкан чикләвек төшен «Таң җиле»ннән! Әлеге авторның әсәрен укый башлауга, ничектер детектив жанр буларак төсмерләнде. Жанр үзе булмаса да, алымнары тартым иде. Шуңамы әсәрне «тешләп карамый» гына:

— Йә, нишләрләр, табарлармы, утыртырлармы гаепләне! — кебек уй белән мәшгуль буласың башта.

Озак та үтми, автор гадәти генә башлаган (әле баш герой да ачыкланып бетми кебек) романның бөтен көчен-җегәрен бер калку һәм зур образ — Анага юнәлтә. Үзәктә кылдай калкып Нуриасма гына кала. Барлык башка геройлар аның җан күзгесендә чагылып-яктыртылып күрсәтелә.

Татар әдәбиятында болай да Ананы олылау — зурлау тәҗрибәсе нык яши, ә Фоат Садри үз героен легенда персонажы биеклегенә күтәрә язган. Әсәр ахырында Нуриасма миңа әкият герое кебек тоелды, хәтта күпмедер җирдән аерылган Рух буларак күренде.

Автор үз әсәрендә бер-берсенә бик нык бәйләнгән берничә сюжет линиясе белән эш итә:

1) Кешеләр тормышындагы Ялган.

Бу Ялган ил буенча җәелгән, югарыдан килеп, һәр гаилә эченә кергән. Менә шул Ялганның Хак-Дөреслек белән бәрелешүе Ана белән Бала арасында да бара. (Нуриасма һәм Мидхәт)

2) Милләт мәсьәләсе.

Авылда торучы һәм чыкылдап торган татар хатыны булган Нуриасма гаиләсе милли таркалуга юл алган: полковник Шәрифҗан марҗа белән тора (әсәрдән сизелә: бу марҗа полковникны гына ярата, ә ананы санламый да, шуңа авылга кайтып та йөрми. Андыйлардан туган балалар, кояш көнбатыштан калыкса да, татар булачак түгелләр). Кызы Илсөяр үзбәккә чыккан («үзбәк кияү»нең балалары да үзбәк булачак, бу номер да һәркайсыбызга билгеле). Тәрбиягә алып үстергән улы Фәрит белән килене Нәсимәнең телсез (сөйләшә алмый торган) балаларын үзләрендә авылда калдырып теләгә (татарчага!) әйләндерү вакыйгасы да милләт мәсьәләсенә карый. Авылда гына икән, саф милләт. Татарлык шунда гына калачак! Бу уй-хис өчен башка оялар урын юк...

Инде кече улы Мидхәтне Зөбәрҗәткә өйләндереп, Ана аларның ата-бабалар нигезендә татар булып калуларына ышана.

3) Гафу итү яисә итмәү концепциясе.

Бу мәсьәләне дә автор Нуриасма образы аркылы ике төрле чишкән: гөнаһларың зур икән — гафу юк сиңа!

Моның мисалы ире ягыннан туган тиешле Бәрия. Гөнаһларың булып, тәүбәгә килсәң, һәм бу кичерерлек эш икән — гафу итәм, ярлыкыйм!

4) Илаһилык — Иман.

Нуриасма, мәҗүсиләр кебек Җиргә һәм Кояшка табына. Монда Чулпы карчыгы — багучы сүзләре дә сер-сихер, хәтта мистика белән өртелгән. Үләр алдыннан чиста-саф, изге карчык Гыйзденисаттигә Коръән калдыруы да гаҗәп шәп символик күренеш (Әгәр бу китапны килене Зөбәрҗәткә калдырса? Нигәдер күңел шуны тели!)

Нуриасманы тагын да идеаллаштыру өчен әдип соңгы чиккә бара: үләргә яткан Ана төпчек улы белән килененең туйларын уздыруны сорый. Типик хәлме бу? Әлбәттә, юк! Моны йола да, гадәт тә, этикет та кушмый. Андый вакытта сабыр гына көтәләр.

Бер сүз белән әйткәндә, Фоат Садриның «Таң җиле»ндәге Ана образы — чын мәгънәсендәге «татар хатыны» дигән зур төшенчәгә ия. Бу китап татар хатынына — Анага — мәдхия һәм җыр. Җырны шагыйрь, композитор, музыкант, җырчы тудыра. Соңгы вакытларда радиодан еш кына «Әнкәйнең догалары» җырын тыңлыйбыз. Ул 1992 елның иң популяр җырына әйләнде. Бу җырны шагыйрь Роберт Миңнуллин, композитор Илгиз Закиров һәм җырчы Салават Фәтхетдинов кебек талантлы иҗатчылар халык күңеленә илттеләр. Ә прозаик Фоат Садри бер үзе «Таң җиле» — «Ана турында Җыр» тудыручы шагыйрь, композитор, җырчы булды.

«Таң җиле»н укып чыккач, күңелдәге күпмедер оптимизмга тагы бер дулкын өстәлде һәм Белинскийга антитеза буларак:

— Бар бездә әдәбият, бар! — дигән уй яктыра төште.

Бар икәнен барыбыз да күреп торабыз. Аның барлыгын һәрдаим тоеп тору өчен әле бүген дә бик актив эшләгән Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники кебек аксакалларны, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Миргазиян Юныс, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәдинә Маликова, Барлас Камалов, Вакыйф Нуруллин, Мәгъсүм Хуҗин, Ләбибә Ихсанова, Зәки Зәйнуллин, Гурий Тавлин, Әхсән Баянов кебек өлкән буын язучыларны, Рабит Батулла, Җәмит Рәхимов, Айдар Хәлим, Тәүфикъ Әйди, Рәфкать Кәрами, Марсель Галиев, Фәрит Гыйльми, Ринат Мөхәммәдиев, Әхәт Гаффар, Рашат Низамиев кебек урта буын әдипләрне, яшьләрдән Зиннур Хөснияр, Вахит Имамов, Заһид Мәхмүдиләрне, тагы да килеп, башка бик күп, бик күп прозаикларның әсәрләрен укып кына барырга кирәк.

Шуны да аңлыйк: әдәбият гел бөекләрдән, йә уртакуллардан гына тора алмый. Бөекләр дә начар нәрсә язып, уртакуллар да яхшы әсәр тудырулары ихтимал. Кем соң кемнең җанын ярып караган да, үлчәү тәлинкәләренә салып потенциаль мөмкинлекләрен белгән?! Кеше ифрат серле-сәер җан ул, һич көтмәгәндә яктырыпачылып китәргә мөмкин. Бигрәк тә иҗат эшендә.

Инде килеп, хәзер заманалар үзгәрде.

Телле, әмма тешсез әдәбиятыбызга тешләр үсәсе генә калды. Тәнкыйди тешләрме? Юк, тәнкыйди тешләр генә түгел...

Сүз монда милли тешләр турында бара. Телен үз артында мәңге саклар Милли Тешләр. Ирек тешләре. Ил — халык — зыялылар, иҗатчылар берләгенең, бөтенләгенең көче бу.

Тешләү өчен түгел, яшәү өчен булган тешләр.

Менә шундый Аллегория!

Һәм дә...

Тешле телсез мәкаләне шушында туктатсак та ярыйдыр дигән идем дә, ләкин ахырда үземне бик борчыган тагын бер нәрсәне өстәмичә кала алмыйм.

Алга киткән чит илләрдә иң кызыклы, иң көчле телевизион тапшырулар нәрсә турында дисез?

— Кинобоевикларммы?

— Юк!

— Секс фильмнары?

— Юк һәм юк!!

— Киштәләрдән ишелеп торган төрле товарлар, машина-яхталар, океан-диңгез буендагы ял итү күренешләре, дөнья буйлап круизлар, миллионерларның кызыктыргыч тормышлары, инде һич югында, сәясәт, дөнья хәлләреме?

— Юк, юк, юк! Цивилизацияле илләрдә иң кыйммәтле, иң шәп телетапшырулар китап турында. Әйе, әйе. Аларда китаплар да, язучылар да бездәгедән күп. Хәтта бик күпкә артык. Газета-журналлар да хәттин ашкан.

Ә без исә китаптан, әдәбияттан читләшеп барабыз...

Менә безнең фаҗигабез кайда!

Илдә рух үтерелмәсен!

# ОНЫТЫЛМАС ШӘХЕСЛӘР

## Афзал Шамов хатлары

Афзал ага белән якыннан танышуым 1960—61 елларда булды. Аннан инде Аккош күлендә җәйләрен бергә яшәдек: кем бала, кем онык үстерә иде. Кандидатлык диссертациясе язганда да мин аңа бик еш мөрәҗәгать иттем. Теге яки бу шәхесне (20—40 еллар) ачыкларга кирәк иде. Монда инде Афзал ага — компьютер, энциклопедия. Бу сөйләшүләр Аккош күлендә яки телефоннан бара. Алары инде кәгазьдә түгел. Ә менә Афзал аганың өч хаты — шул сөйләшүләрнең йөздән бер беркетмәсе. Хатның беренчесе шул — мин Афзал агадан сораганмын: Ф. Әмирханның «Хәят» повестендәге персонажларның прототипларын сез беләсез икән, ярдәм итегезче, дигәнмен. Җавап мондый:

**«М. Мәһдиевкә. Бу хатларны укып чыкканнан соң миңа шалтыратыгыз әле. Сезгә кирәкле бер уемны язарга онытканмын.**

*А. Ш. 28.XI.83».*

Тагын мондый хат:

**«Мөхәммәт туганкай!**

**Бу конвертта барлыгы дүрт хат. Барысы да Сәхи Рәхмәти кулы белән язылганнар. Әгәр аларны машинкада күчертеп алырга ниятегез булса, «Хәят» турындагысының бер копиясен миңа бирсәгез яхшы булыр иде.**

**Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Ф. Әмирхан архивы барлыгын беләсезме икән? Шунда әдип вафат булганнан соң төзелгән актта «Хәят» кульязмалары турында кайбер мәгълүматлар бар.**

**Сәхи Рәхмәти (1894—1972) журналист, тәрҗемәче. Үзбәкстан нәшриятләрендә, газета редакцияләрендә озак еллар эшләгән. Үзенең сөйләвенә караганда, Ш. Бабичның дусты. Ташкентта вафат.**

*Ихтирам белән Афзал Шамов.*
*28 ноябрь, 1983».*

Өченче хат:

**«Хөрмәтле Мөхәммәт туганкай!**

**Хатлар кире әйләнеп кайтты. Гыйльми хезмәтеңдә файдалары тисә, мин моңа чын күңелемнән шатланачакмын.**

**Бу хатлардан алынган мәгълүматларны теләсә кайда һәм теләсә ничек файдалана аласыз. Тик бер шартымны исегездә тотыгыз: С. Рәхмәти хатларыннан алынган икәнен күрсәтегез** *(китабымда мин шулай эшләдем — М. М.).*

**И. Аитов хатын таба алмадым** *(Ф. Әмирханның замандашы — М. М.)* **Югалмагандыр дип уйлыйм, берәр папкада кысылып ята торгандыр.**

**Р. Рәкыйбинең миндә котлау хатлары гына бар шикелле. Ш. Мөхәммәдьяров хатларында «Хәят» турында бер сүз дә юк. Алар исән чакта сораша алмыйча калдым. Бигрәк тә К. Мостакаев агадан сораша алмый калуыма үкенәм. Өендә дә, башка урыннарда да аның белән күп мәртәбәләр очраштым, ә бу турыда сөйләшергә башыма да килмәгән.**

**Яңа мәгълүматлар табылганчы «Хәят» кульъязмасының сатылуын кисеп әйтмәвегез яхшырак булыр. Эзләнүләргә урын калсын. М. Гайнуллинда берәр мәгълүмат юкмы? Гыйльми-әдәби эшләрегездә уңышлар теләп калам.**

*Афзал Шамов. 7.XII.1983»*

Сүз «Хәят» повестенең икенче, дөнья күрмәгән кисәге турында бара. Китабымны язганда мин ике ут арасында калдым. С. Рәхмәти яза: «Хәят»ның прототибы монда Ташкентта яши, ире белән, ди. Аларда әсәрнең икенче өлешенең кульъязмасы булырга тиеш, килегез, ди. Шунда ук шөбһә дә әйтә: прототипның төп кешесе Үлмәскамал белән ире Гатаулла заманында Ф. Әмирханнан бу кульъязманы сатып алдылар, китабын чыгармадылар, ди. Ф. Әмирхан турындагы китабымның кульъязмасын укыган иптәшләр минс сүгәләр: Фатих Әмирханны акчага сатылган итеп күрсәтәсең, диләр. Мин акланам: сатылмаган, кеше гаиләсенең тынычлыгын, иминлеген саклаган, намусы кушканча эш иткән. Безнең соңгы еллардагы әдәбиятта шундый пычраклыклар булмадымы? Персонажны тормыштагы конкрет шәхескә якынайтып, әдәбиятыбызны арзанайту булмадымы?

Дүртенче хат:

**«Хөрмәтле Мөхәммәт туганкай!**

**Партия архивында Ф. Әмирхан турында кызыклы гына бер материал укуым турында әйткән идем Сезгә. Шуның шифрын җибәрәм: фонд. 15. опись 6, связка 1.**

**1924—1927 елларда Совнарком председателе булып торган Хажи Габидуллинның бер докладына теркәлгән иде ул. Зур түгел, 5—6 битләр чамасында гына. Машинкада басылган.**

**Мин алтмышынчы елларда укыган идем аны. И. Нуруллинга да биргән идем мин бу шифрны. Таба алмаган иде ул аны. Чөнки анда, яңа тәртип урнаштырырга теләп, шифрларны үзгәрткәннәр икән.**

**Өстәмә мәгълүматлар кирәк булса, шалтыратыгыз. Телефоным 35-78-23.**

*Күп сәлам белән Афзал Шамов.*
*8 апрель. 1986 ел».*

Бу документларга өстәмә: үләренә өч-дүрт ай кала Афзал ага минем өйгә шылтыраткан. Эштән кайттым да, аның телефонын җыйдым. Афзал ага бик нык авыру иде. Ф. Әмирханның «Хәят» әсәрендәге персонажлар турында өч-дүрт яңа җөмлә әйтте дә, авыр сулап болай диде:

— Йә, ярый, Мөхәммәт, миңа сөйләшүе бик авыр,— дип телефонны өзде.

Күп тә үтми Афзал ага китеп барды. Мин аның табуты янында «энциклопедист галим» дип нотык сөйләдем.

Шул фикерем һич тә үзгәрмәс...

## Сибгат Хәким хатлары

Шагыйрь белән иҗат өлкәсендә танышу, элемтәгә керүем 1971 елдан башланды. Аңа, редколлегия әгъзасы буларак, «Казан утлары»ннан минем «Фронтовиклар»ымны биргәннәр. Ул укып чыккан да рецензия язган. Икене язган. Һәр икесенең беренче экземплярын миңа бирделәр.

**«ФРОНТОВИКЛАР»**

**1. Иң оста язылган образлар — хатын-кыз образлары. Белә, шайтан... Иң күңелдә калган образлар Рушад, Гата, Нәркис, Мөби, Мәсрүра, Хушият, Хәкимжан, Галиәхмәт, Мостафа, Закиров һ. б.**

**2. Галиәхмәтләр семьясы таралганчы әсәр бик табигый бара. Шул тирәдә кайбер ясалмалылык сизелә башлый. Саткан сыерның кире кайтуы — артык...**

**Гатаның председатель (райисполком) булгач сөйләгән речь ясалма, озын, кабатлана. Бер колхозның икенче колхозга булышуы турындагы сөйләнүләр күп, вариантлар-кабатлаулар китә. Башта Даутов корабль, яр артиллериясе турында... Аннан Гата һ. б. Соңга таба, гомумән, сугыш күбәя, сүз хисабына. Башта ул кыска һәм параллельләр иде, әдәби детальләр аша иде...**

**3. Бөтенесе дә русча тыгып сөйлиләр.**
**Калганнарын авторның үзенә сөйләрмен.**

*Сибгат Хәким.*
*7 август, 1971 ел.*

**«ФРОНТОВИКЛАР»** *(Икенче рецензия)*

**Мөхәммәт Мәһдиев әсәре. Роман.**

**Фронтовиклар — укытучылар...**

**Яңа автор. Хикәя яки повесть та түгел, роман. Икеләтә кызыксынып укыдым. Әсәр укытучылар тормышыннан. Укытучылык авыр, кыен, катлаулы хезмәт икән. Авырлыгына ышандым, автор ышандырды. Авыр булса да яраттым, язучы яраттырды. Балачагым, укыган елларым яңарды, укыткан укытучыларымны искә төшердем, мәктәпне сагындым... Язучы мине үз стихиясенә алып керде, шул тормышта тагын бер тапкыр яшәдем. Әдәби әсәрнең көче шунда.**

**Роман ахырына хәтле укыла, сине тота икән, бу — язучының уңышы, бәхете...**

**Яңа автор тормыштан килә, туры, ачык, аяусыз, усал... Галим көткән идем, талантлы язучы килә. Без анысына да шат.**

*7 август, 1971. Сибгат Хәким.*

**Ул елларда «Казан утлары» журналында минем «Кеше китә — җыры кала» исемле повестым эт типсәсендә йөри иде. Зәки Нури баш редактор вакытта ул әсәрне басылып ятканда журналны сүттереп, төшертеп калдырдылар. Обкомнан инде — М. Мусин, М. Вәлиев конторасыннан. Шуннан мин аның исемен үзгәрттем: «Авылым көндәлеге». Хәйлә белән кабат китердем. Журналдан моны Сибгат Хәкимгә биргәннәр. Аның фикере:**

**«Авылым көндәлеге». Укыдым. Һәр яңа кешенең талантын чамалар өчен укыйм. Үзем өчен. Күрми калуың бар. Ә минем берсен дә ычкындырасым килми. Прозаның үсеше кая таба?**

**Басылмый калган әсәр. Бите-бите белән сызылган. Сызылганнары белән укыдым. Без күргән, без кичергән тормыш. Кешеләр-образлар таныш. Без тормышта аралашкан кешеләр. Тормыш кисәге-кисәге белән куптарып умырып алынган, вакланмыйча, ясау юк. «Авылым көндәлеге» — укытучылар турындагы романга — «Солдатлар»га («Фронтовиклар»ны әйтә — М. М.) әзерлек тә, увертюра да, зур гомумиләштерүләргә кереш шикелле дә тоелды миңа. Шул ук вакытта аерым мөстәкыйль әсәр. Аерым җөмләләрне редакцияләү белән үк басыла торган әсәр. Кыскасы, бу автор минем өчен яңа, минем өчен прозада ачыш. Киң, бай тормыш чынлыгы. Хакыйкать олы, зур. Тигезләми, ышкыламый, шомартмый. Хәзергә шулай.**

*Сибгат Хәким. 2 январь, 1972».*

Актанышта үткәрелгән семинарда Сибгат ага белән Уразай дамбасы янында сөйләшкәнне язган идем инде. Кабатлыйм: анда бульдозер тау кучерә, ә ана йомран белән эти йомран оялары өстендә елап утыралар иде: җир куышында балалары бар бит, ә бульдозер гел якыная. Мин Сибгат абыйга шуны күрсәткән идем... Ул хат язды:

**«Мөхәммәт!**

**Актанышта Уразай дамбасы янында «Соңгы йомран»ны язарга сүз биргән идем. Кайткач дүрт шигырь яздым. Үзем шат, яратып эшләдем, настроение белән. Икесен басарлармы, юкмы, әйтүе читен. Шуңа күрә үзеңә салам. Басмасалар да үкенмим. Хәзер әйтәсе килгәнне, үзем теләгәнчә әйткәннән соң үкенмим мин, җан бушап кала, авырудан терелгәч бер рәхәтлек тоя организм.**

*Сәлам белән Сибгат Хәким. 1.VII.78».*

Бу хаты белән бергә Сибгат абый миңа машинкада басылган «Бәхетле бул, Актаныш» шигырен (багышлау белән: Мөхәммәт Мәһдиевкә дип куйган), «Йөгерә чәчәкләр офыкка», «Уразай», «Соңгы йомран» шигырьләрен җибәргән. Шунда ук бер шигыренең Р. Д. Моран тәрҗемәсендә эшләнгәне — «Будь счастлив, Актаныш!» Болар барысы да матбугатта басылдылар.

Ә бу хат Әмирхан Еникинең 70 еллыгы уңаеннан уздырылган кичә һәм банкетка кагылышлы. Ни өчендер Сибгат ага бу турыда миңа эчен бушаткан.

**«Мөхәммәт!**

**Әмирхан турында белгәнемне сөйләдем... Үз фикерем. Үзем уйлаганча. Минеке булып калыр. Банкетында Гали Халит бик ямьсез сүз әйтте: имеш, шагыйрьләр**

Әмирханның поэзиясе турында сөйләп, аның шөһрәте (артыпа) сыеналар. Шагыйрьләр кастасы, ди. Проза, яхшы проза поэзиясез булмый, бу — бәхәссез нәрсә. Минем үз шөһрәтем дә, аллага шөкер, Әмирханнықыннан ким түгел. Безнең тәнкыйтьнең бер күренешедер инде, ярый. Китабыгыз өчен рәхмәт, файдасы тиде, бик үз урынында булды.

Рувим Моран «Актанышъны тәрҗемә иткән, минемчә, әйбәт. Минем малай Рафаэль дә унбиш тәрҗемәдән шуны мактады. Башта ул аны тәрҗемә итә алмый азапланды, хәтта баш тартты, артык местный... (бер сүз тапылмый — М. М.) Төп нәрсә — су басу, дидем. Янадан алынды, тапкан рухын. Радио цикл әзерли, «Сов. Татария»гә дә подборка бирергә уйлыйм.

2 апрельдә Татар Академия театры бинасында минем иҗат кичәсе булырга тиеш, трансляция белән, цветной — төсле. Килегез!

*Сәлам белән Сибгат Хәким. 18.III.79».*

Тагын бер документ — шагыйрьнең «М. Мәһдиевкә» дигән шигыреnең кулдан язган ике бите. Тарихын инде язган идем. Кабатлыйм: 1983 елның көзендә Сибгат ага, Гариф Ахунов, Камил Кәримов, мин Арча авылларын узган идек: Г. Камал, Г. Курсави авыллары. Шул хисләрен кәгазьгә төшереп, ул ике-өч шигырь язган һәм шуларның берсен миңа, икенчесен Г. Ахуновка багышлап «Соц. Татарстан» да бастырган иде. Кульязманы мин архивка тапшырдым.

1983—85 елларда без фотограф Зөфәр Бәширов белән «Тукай» альбомын эшләдек. Тукайның 100 еллыгына. Шул уңай белән мин Сибгат абыйга сораулар җибәргән идем. Альбом текстына аның язганы керә алмады. Альбомның структурасы эш барышында үзгәрде. Менә аның язган җаваплары.

**«Мөхәммәт!**

**Сорауларга җавап бирергә тырышып карадым. Әйтеп бетереп булмый... Ул җавапны Сезнең киләчәктә язылачак романнан көтәм. Сез язсагыз язасыз, башка беркем дә түгел. Хәзер Сездән «Тукай» сорала. «Тукай» белән беркетергә кирәк. Дөнья хәтле архивыгыз барын беләм, Галимҗаннар, Әмирханнар рухы барын беләм, бер тотынсагыз. Казан арты кешесе язарга тиеш аны! Сезнең хәзер өлгергән чак.**

*Сәлам белән Сибгат Хәким.*
*21.VIII.84. (Аккош күле — М. М.).*

**«Тукай миңа бик иртә кергән. Ана сөте белән. Халык моңнарын тоя башлагач та. Татар халкы бар җирдә Тукай булган. «Кайчан?» дигән сорауга халык сулышы белән дип кенә җавап бирә алам. Шулай булмаса, язарга мин «Пар ат»тан тотынмас идем. Миннән аның беркайчан да чыкканы да юк. Хәтта Дугада да (шагыйрь үзе катнашкан «Курская Дуга» сугышын һәм бу турыдагы поэмаларын күздә тота — М. М.)... Сугышлар да мине аннан биздерә алмады. Нигә ул миннән чыкмый? Аңлатуы читен. Татарда Тукай туганы өчен куанам. Олыгайган саен күңелгә бер курку урнаша бара. Мин аннан бик авыр аерылырмын шикелле...**

**...***(бер сүз танылмый — М. М.)* **«Шагыйрь кем?» дигән сорауга җавапны җитмеш өч яшемә җиткәндә Тукайдан таптым. Шагыйрьлекне шагыйрь үзе яшәгән җәмгыятькә керткән рухи көченең микъдары белән үлчәнгәнлеген Тукайны укып аңладым. «Бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш» менә кайчан әйтелә икән. Тукай монда үзенең милли рухы белән яшь, шул яздыра, шул эчке энергиягә әйләнә. Яшь чакта алга-артка карамыйча ярыша-ярыша чапкан киләчәк шагыйрьләре дә, минем шикелле картая төшкәч, әлеге сорауга җавапны, барыбер, Тукайдан эзләячәкләр. «Шагыйрь кем?» — Такташ, Туфан, Җәлил дип килерләр дә, Тукайда тукталырлар. Шуңа бик нык инандым. Ә шагыйрьгә җавап табарга кирәк икән. Кыскасы, икенче заманда яшәсәм дә, дөньяга ике катлы тәрәзә аша карап яшәдем — Тукай аша. Бөтенесен теоретик нигезли алсам, мин шагыйрь дә булмас идем. Тукай — борчу. Тукайдан аерыласы килми...**

*21 июль, 1984. Сибгат Хәким.*

Алга таба тагын бер хат. Безнең Арчага сәяхәтебез нәтиҗәсендә Сибгат аганың шигырьләре «Соц. Татарстан»да басылгач, күрәсең, мин аңа рәхмәт хаты язганмын. Түбәндәге хат шуңа җавап дип уйлыйм.

**«Мөхәммәт!**

**Хатыгызны алдым, шигырьләр турында елы** *(шулай язылган — М. М.)* **сүзләрегез өчен рәхмәт. Туфанга да «Нигез» бик ошаган** *(ялгышмасам, Г. Ахунов*

*туып-үскән йорт нигезендә сарык-кәҗә көтүе йөрүе, авылның бетүе турында иде).* **Фикер йөртүчеләр күп, шигырьләр уйландырган. «Гөберчәк»не** *(минем туган авылым — М. М.)* **Сезгә багышлаган идем. Сызганнар. Кемгәдер ярамаган. Вакланалар.**

**Яктащлар белән очрашкансыз икән. Минем «Таныш өянкеләр»не җырладым, дигәч, аптырап калдым. Җырчы икәнсез. Авыл җырчысы. Мин җырларны авылның талантлы җырчылары җырлаганда тыңларга яратам. Бер насыйп булыр әле. Минем хәзер «Фатих Әмирхан»ны укыйсы килә. «Соц. Татарстан»дагы теге кеше** *(? — М. М.)* **язмаларын күрдем, укымадым, зәвыкны бозасы килмәде.**

**40 еллыкка** *(? — М. М.)* **«Современник»та** *(Мәскәүдәге китап нәшрияты — М. М.)* **яңа китап чыгып ята. Майга чыгып җитә диделәр. «Гөберчәк» анда кергән булырга тиеш. Р. Бохараев тәрҗемә иткән иде. Тәрҗемәсе әйбәт шикелле.**

**Мәскәү ике том Сайланманы керткән планга** *(татарча)*, **икесен дә 1986 да чыгарырга дигәннәр. Сатылу өчен. Шуларны әзерләп ятам. Исәнбәт — 4, Расих — 3 том, Ш. Галиев — 18 табак** *(сайланма)*, **Х. Туфанны бер том калдырганнар.**

*Сезгә уңышлар теләп, сәлам белән Сибгат Хәким.*
*16/III-85»*

«Гөберчәк» дигән шигырьгә Сибгат абый бик зур игътибар биргән. Аның алдагы хаты да шул турыда.

**«Мөхәммәт!**

**Менә Сезгә «Гөберчәк»нең русчасы. Миңа ошады, мин яраттым, Равиль Бохараев тәрҗемәсе. Үзем яраткан тәрҗемәләр сирәк. Бу күңелгә ятты. Сез дә укып карагыз. Алда чыгачак китапларыма кертермен.**

**Минем еллыклар бетте. Сезнең еллыклар алда. Киләчәктә минем өчен шушы шигырь сүз алыр. Шундый иҗат бәйрәмнәрендә укыла торган шигырь бу. Татарчасы да, русчасы да минем йөзне кызартмас. Тукайга, Туфанга, Муса Җәлилгә багышланган шигырьләрем арасында бу да курыкмый керер дип өмет итәм. Ярый әле, теге вакытта Сезнең якка ничек барып чыгылган. Хәзер шуңа куанам. Юл йөрү әкренләп кими. Камыт бавы кыса. Узган ел Кимегә дә кайтмадым. Быел җәй җиткәнен түземсезлек белән көтәм. Аннан — үкенмим. Узган ел кайта алмау аркасында бер егерме лирик шигырь, җырны югалттым. Ел буе тамагым туймый калган кеше шикелле йөрим. Яшәсен туган як! Яшәсен карт өянкеләр!**

*Сәлам белән Сибгат Хәким.*
*20/II-1986».*

Һәм шагыйрьнең миңа язган соңгы хаты. Мин аңа үземнең «Фатих Әмирхан» дигән юка гына китабымны җибәргән идем. Ф. Әмирханның 100 еллыгына. Ул хезмәтем башта «Казан утлары»нда «Яңа Бистә Прометее» исеме белән басылган иде. Инде шул китапны алгач язган хаты:

**«Мөхәммәт!**

**«Фатих Әмирхан»ны укыдым. Әдәби әсәрләрегезне укыган кебек аерылмыйча, тотлыкмыйча укыдым. Сезгә фән өлкәсе дә, матур әдәбият әсәрләре кебек биртигез. Фатих Әмирхан шикелле кешеләрнең булуына бер сөендем, шулар югарылыгында торып фикер йөртүчеләр өчен — икенче. Татар әдәбияты талантларга бай булган. Үткәне бай, зур. XIX йөз рус әдәбиятындагы кебек, бездә дә нәрсәдер бар...**

**«Фатих Әмирхан»ның русча-татарча чыгуы әйбәт (бер төпләмдә ике телдә иде — М. М.) Мин русчасын укыдым. Укысыннар, күрсеннәр бездә кемнәр барын! Бу — сезнең өлкә. Шушындый фәнни-әдәби публицистик очерклар кирәк. Моңа хәтле язылган монографияләрне укый алмый газапланганнан соң тын юлым кинәт ачылып китте. Рәхмәт.**

*Сәлам белән Сибгат Хәким.*
*31/III-86».*

**СОҢГЫ СҮЗ:** шагыйрь үзенең хатларында мине бик мактаган, бик зурлаган инде. Мин әдәбиятта, гыйлем өлкәсендә үз урынымны бик яхшы беләм. Сибгат ага бераз арттырган инде. Әдәбиятта, гыйлем дөньясында минем дошманнарым юк түгел. Ләкин бу — фаҗига түгел. Галимҗан Ибраһимов, хәтерем ялгышмаса, Тукайга багышлап язган мәкаләләренең берсендә *(ул мәкаләләр Г. Ибраһимовның сигез томлыгына кертелмәделәр. Чөнки без Ибраһимовны гөнаһсыз фәрештә итеп күрергә теләдек, аның намусында Тукай, Җ. Вәлиди, Г. Исхакый, Г. Рәхим,*

*Ф. Кәрими, Г. Газиз кебек корбаннар барлыгын бер-беребездән яшердек, күз йомдык)* бик акыллы бер фикер әйтә. Г. Ибраһимов — әзерлекле, искиткеч эрудицияле, куәтле гыйлем иясе — шул мәкаләләрнең берсендә шәрык философларыннан берсенең сүзләрен китерә: «Шәхси дошманың булмау бик зур кимчелек»,— ди.

Шуңа күрә әйтеп куям: Сибгат абыйның әлеге ун хатын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы кулъязмалар бүлеге мөдире, зур галим Марсель Әхмәтҗановка тапшырдым. Әгәр минем бу публикациямдә бер сүзгә, бер хәрефкә үзгәртү кертүем мөмкинлеге турында шөбһәләнәләр икән — барып карасыннар.

Бу хатларда сүз минем турыда түгел, шагыйрь Сибгат Хәким шәхесе, аның эчке дөньясы турында бара. Аның хатларын җыеп бер-ике том итеп бастырырга кирәк. Минем сизүемчә, аның хатлары меңләп, ә бәлки артыграктыр да: И. Юзеев, Н. Юзиев, Ш. Галиев, Ш. Маннапов, Г. Ахунов, М. Шәйхи, К. Сибгатуллин... Инде дә килеп Рәдифтә, Равилдә, Зөлфәттә, Мөдәрристә, Р. Харисста, Т. Галиуллинда, А. Гыйләҗевтә, Нуриханда, Әхсәндә...

Боларны бер кулга җыярга һәм бастырып чыгарырга иде. Руслар шулай итә бит: «Переписка, письма...» — фәлән, фәләннеке.

Әйдәгез, шагыйрьне әр-яңа баштан ачыйк әле...

**Мөхәммәт МӘҺДИЕВ**



**Хатыйп**

**Миңнегол**

# ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ МАТБУГАТЫ

**Беркем дә үз ирке белән туган җирен, Ватанын калдырып, чит якларга китеп бармый, аны бу адымга гадәттән тыш хәлләр, җитди сәбәпләр мәҗбүр итә. Монголлар һөҗүме вакытында безнең күп кенә әби-бабаларыбыз Мисырга, Сүриягә, Мажарстанга барып чыккан. XII—XV йөзләрдә Кырым аркылы һәм башка юллар белән Көнбатыш Европага эләгеп, тиз арада итальян, француз, немец, испан булып киткән төрки-татар «гаскәри»ләренең, «коллары»ның исәбе-хисабы юк. Явыз Иван походлары, көчләп чукындыру һәм урыслаштыру, Мәскәү һәм Петербург хакимиятенең рәхимсез милли-колониаль сәясәте дә күп меңләгән татарларны, туган җирләреннән кубарып, дүңгәләк кебек, дөньяның төрле төбәкләренә илтеп ташлады. «Аклар», «әсирләр» составында чит мәмләкәтләргә эләккән милләттәшләребезнең саны да берничә дистә меңгә якын. Һәм, гомумән, совет чорында ачлык, сугышлар, коточкыч салымнар, репрессияләр, «удар төзелешләр» нәтиҗәсендә татарларның таралышы аның бөтен бер милләт буларак яшәешен һәлакәт дәрәҗәсенә җиткерде. Дөрес, соңгы берничә елда татарда милли үзаң уяна башлады. Әмма бу гына әле реаль чынбарлыктагы аяныч хәлне үзгәртерлек түгел. Татарның милләт буларак янә туплануы, табигый халәткә килүе өчен әле гадәттән тыш күп тырышлык, шактый вакыт кирәк булачак.**

Халык тарала икән, аның әдипләре дә тарала. Татар әдәбияты тарихында моның мисаллары бик күп. XIV йөзне генә алып карыйк. Мәхмүд Сараи Гөлестаный, Сәйф Сараи, Мәхмүд ибне Фәттах Сараи, Бәркә Фәкыйһ — болар бит бар да әүвәл Идел-Урал буйларында яшәп, ахыргы гомерләрен Мисырда, Сүриядә үткәргән әдипләр. Колшәриф, Мәүла Колый, Әбелмәних Каргалы, Шәмсетдин Зәки, Дәрдемәнд кебек шагыйрьләрне илһамландырган Өмми Камал (XV йөз) тормышы да соңрак Кече Азиядә уза. Казан ханлыгы заманы чичәне Хәсән Кайгы Идел-Җаек буе далаларында күчеп йөреп, татар белән казакъның уртак шагыйренә әйләнә.

Хаҗитархан «нугае» Суфый Аллаяр да (1616—1713), гәрчә ул Урта Азия шагыйре булып танылса да, Идел-Урал буе татарлары арасында да яратып укыла. Аның «Сөбател-гаҗизин»е, Әл-Мөкәффәгънең «Кәлилә вә Димнә»се, Гаттарның «Пәнднамә»се, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Сәгъдинең «Гөлестан»ы кебек, татар укучыларын гасырлар буе илһамландырып килә. Таҗетдин Ялчыгол (1768—1838), Суфый Аллаяр китабына нигезләнеп, үзенең мәшһүр «Рисаләи Газизә»сен иҗат итә. Бу әсәрнең исә татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту ярдәмлеге буларак кулланылуы да мәгълүм.

---

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ (1939)— *әдәбият галиме, педагог, филология фәннәре докторы, профессор.* *«Сәйф Сараи...»*, *«Котб иҗаты»*, «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре», «XIX йөз татар хрестоматияләре», «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар» һәм башка гыйльми китаплар авторы. Казанда яши.

XIX—XX йөзләрдә, аеруча Октябрь инкыйлабыннан соң чит-ят җирләргә киткән, үзгә мәмләкәтләрдә язу-сызу, иҗат эше белән шөгыльләнгән татар әдип-галимнәренең саны бигрәк тә күп. Менә шуларның берсе — Муса Акъегетзадә (1864-65—19.VIII.1923). Татар әдәбиятына «Хисамеддин менла» (1886) исемле мәшһүр роман биргән бу әдип әүвәл туган ягы Чембарда һәм Пенза гимназиясендә укый, бераз вакыт Кырымдагы «Тәрҗеман» газетасында да эшли. 1887 елда ул Истанбулдагы «Мөгаллими Шаһания» исемле югары уку йортына укырга керә. Аннан соң төрек гаскәри уку йортында рус теле һәм әдәбияты укыта, 4—5 ел Сүриядә, көнчыгыш Анадулыда яшәп, эшләп ала. Гомеренең ахырын Истанбулда уздыра, нигездә, Н.Катанов китапханәсе хәзинәсен тәртипкә китерү белән шөгыльләнә.

Илгизәрлек, мөһаҗирлек ягыннан аеруча атаклы галим, дин белгече, әдәбиятчы, педагог, ориенталист *(шәрыкшенас)* Муса Ярулла Биги (1875—1949) язмышы гыйбрәтле. Ул Казандагы Күл буе мәдрәсәсендә, туган шәһәре Ростовтагы дәүләт лицеенда укый. 1895—1898 елларда Бохарада белем ала. Аннан — Истанбул. Исәбе — инженерлыкка уку. Әмма ул, Муса Акъегетзадә киңәше белән, Мисырдагы атаклы Әл-Әзһәрия университетына укырга керә. Күренекле галимнәр белән аралаша. Хаҗга баргач, өч ел гомерен Мәккә вә Мәдинә калаларында үткәрә. Бераздан Һиндстанга юнәлә. Ярты еллап анда яшәгәч, кабат Мисырга кайта. Янә анда укый, аннары укыта. Бу замандагы гарәп газета-журналларында аның берничә мәкаләсе дөнья күрә. 1904—1925 елларда Россиядә, СССРда яши. Ике дистәдән артык китап бастыра, Петербургта «Өлфәт» газетасын чыгара, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә гарәп теле вә әдәбияты укыта. Совет чорында төрле эзәрлекләүләргә дучар була. 1926 елда Мәккәдәге Ислам корылтаенда катнаша. Аннан — Шәркый Төркестан, Әфганстан, Мисыр. 1932—1935 елларда Суомида (Финляндиядә) балалар укыта. Соңра Берлин, Истанбул аша Иранга, Гыйракка, Мисырга бара. Ул илләрдә 2—3 ел гомерен уздыргач, 1938 елда Япониягә, Кытайга юнәлә. Пекинда бераз торгач, Һиндстанга килеп төпләнә. Монда фәнни тикшеренүгә, укыту-тәрбиягә күңел бирә. Инглиз хакимияте аны, сәяси эше өчен, Пешавар төрмәсенә утырта. Әмма мөселман җәмәгатьчелегенең көчле таләбе, җирле халыкның демонстрацияләр уздыруы нәтиҗәсендә аны зинданнан чыгарырга мәҗбүр булалар. Муса Бигинең бу вакытта инде күзләре начар күрә, аяклары да начар йөри. 1947 елда Истанбулда хастаханәдә дәвалана. Бик күп телләрне белгән, күп китаплар, хезмәтләр авторы, бөтен ислам дөньясының мәшһүр шәхесе Муса Ярулла Биги Каһирәдә вафат була. Аның гарәп мәдәнияте хакындагы хезмәтләре, Әл-Мәгарридән; Хафиздан тәрҗемәләре әдәбият фәне өчен аеруча кыйммәтле. Г.Ибраһимов үзенең «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» исемле гаугалы хезмәтендә *(Мәскәү, 1924, 70 б.)* шул чорның сәяси, идеологик догмалары белән артык мавыгып, Муса Бигине «татар контрларының шәбе, каһарманы», «панисламист», «бөтен гомерен татар буржуа сәдакасы белән яшәгән адәм», дип кискен тәнкыйтьли *(7—9 б.)*. Әмма ул да Муса Бигинең талантын инкарь итә алмый, аны «гадәттән тыш зирәк, тырыш, «Коръән»не яттан белүче, динче бер галим»,— дип атый *(8 б.)*.

Шунысын да әйтик: Муса Бигинең күпсанлы балалары, кардәшләре — билгеле, мәшһүр затлар. Язучы Заһир Биги — аның бертуган энесе. Кызы Фатыйма апа — Шәрык телләренең һәм әдәбиятларының зур белгече, профессор Габдрахман ага Таһирҗановичның (1907—1983) хатыны. Габдерәшит Муса улы Бигиев (1918 елгы) — Магниткаены коручыларның берсе (ул анда 1934 елдан бирле эшли), техник фәннәр докторы, профессор, Магнитогорск тау-металлургия институтының корыч кою кафедрасы мөдире, металлургия фәнендә дөньядагы иң зур галимнәрнең берсе, күпсанлы гыйльми монографияләр, дәреслекләр авторы. Аның хакында моннан берничә ел элек «Правда» газетасында зур очерк та басылган иде. (**Карагыз:** *В.Кузьмищев. Прогноз на завтра: живущие по совести — «Правда», 16.IV.1986*). Әле быел гына Габдерәшит аганың 75 еллык юбилеен бөтен Магнитогорск җәмәгатьчелеге, андагы милләттәшләребез тантаналы төстә билгеләп үттеләр *(«Ватаным Татарстан», 3.II.1993)*. Муса Бигинең бер улы Әхмәт (1910 елгы) — авиация инженеры, майор була. Сугышта әсирлеккә эләгә. Аннан Алманиядә яши. Язучылык, журналистлык белән шөгыльләнә. Сталин һәм татарлар хакында немец телендә язган китабы өчен аңа күп кенә кыенлыклар да күрергә туры килә.

Мөһаҗирәттәге *(эмиграциядәге)* татар мәдәниятенең берничә төбәге бар: Ерак Шәрык (Кытай, Япония, Корея), Шәркый Төркестан (Голҗа...), Финляндия, Төркия, Алмания, Румыния, Ляһестан (Польша), АКШ һ. б. (Сүз, нигездә, безнең гасыр хакында бара.) Харбин, Хайлар, Токио, Нагоя, Голҗа, Хельсинки һәм

татарлар күпләп яшәгән кайбер башка калаларда татар мәктәпләренең эшләве мәгълүм (хәзер — юк). Төрле әдәби-музыкаль кичәләр оештырыла, бергәләп милли, дини бәйрәмнәр уздырыла. Безнең халык төрле тамашалар, спектакльләр карарга ярата. Мөгаен, шуңадыр инде, татарлар яшәгән һәр төбәктә үзешчән артистларның күпләгән драма әсәрләрен, аеруча «Беренче театр», «Таһир-Зөһрә», «Галиябану», «Зөләйха», «Ян-Баевич» пьесаларын сәхнәләштерүләре билгеле. Куаныч ки, бу традиция Финляндия һәм Америка татарларында бүген дә дәвам иттерелә. 1992 елда Хельсинкидәге милләттәшләребез «Беренче театр» һәм «Асыльяр» драмаларын мәшһүр Швед театрының сәхнәсендә уйнадылар *(режиссеры — Луара Шакирҗанова)*. Шунысы кызыклы: Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә *(июнь, 1992)* «Асыльяр» пьесасы Финляндия үзешчәннәре һәм Г.Камал театры артистлары катнашында Казан сәхнәсендә дә күрсәтелде, конгресс кунаклары һәм тамашачылар тарафыннан уңай бәяләнде. *(Асия Юнысова. Бергә булырбыз әле. «Ватаным Татарстан». 26.VI.1992)*.

Туган телнең, мәдәниятнең саклануында һәм үсешендә, милли мәктәп белән беррәттән, вакытлы матбугатның, басма сүзнең гаять зур роль уйнавы бәхәссез хакыйкать. Шуны күздә тотып, читтәге безнең милләттәшләр дә төрле газета-журналлар чыгарырга тырышканнар. Бу эш аеруча Ерак Шәрык төбәгендә уңышлы барган. Анда 20—40 елларда дистәдән артык татарча газета-журналның нәшер кылынуы мәгълүм (алар барысы да гарәп язуында): «Ерак Шәрык» *(Харбин, 1920—1922)*, «Азат Шәрык» *(1923)*, «Шәкертләр таңы» *(Мукден, 1934—1935)*, «Игланыл хакыйкать» *(Токио, 1936)*, «Шәрык авазы» *(Тянцзинь, 1939—1940)*, «Япон мөхбире» *(Токио, 1931—1932)*, «Яңа Япон мөхбире» *(Токио, 1932—1945)*, «Рәсемләр мәҗмугасы» *(Токио, 1937)* журналлары, «Мең ел» *(Харбин, 1992. Бер саны чыга)*, «Ерак Шәрык» *(Харбин, 1924—1925)*, «Бәйрәм нуры» *(Харбин, 1934. Бер саны дөнья күрә)*, «Чаткы» *(Харбин, 1932—1933)*, «Тәммүз» *(Харбин, 1934)*, «Милли Байрак» *(Мукден, 1935—1945)* һ. б. газеталар. Болар арасында Гаяз Исхакый тарафыннан нигезләнгән «Милли Байрак» аеруча игътибарга лаек. (Бу газетаның мөхәррирләре һәм төп авторлары — Рокыя Мөхәммәдиш һәм Ибраһим Дәүләткилде. Болар — хәзерге татар дөньясының мәгълүм заты, Мәрмәрә (Истанбул) университеты профессоры Надир Дәүләтнең әти-әниләре.)

Финляндиядә исә татарча түбәндәге газета-журналлар чыга: «Мәгърифәт» *(Атналык газета. 16.01.1925—12.04.1925. Кими каласы. Мөхәррире — Хәсән Хәмидулла)*; «Шимал очкыннары» *(1943—1977. Мәҗмуга әүвәл Кимидә, аннан Хельсинкида басыла. Чыгаручысы — Хәсән Хәмидулла)*; «Белдереш» *(1948. Хельсинки. Мөхәррирләре — Гобәйдулла Мортазин, Зиннәт Алкара, Госман Али. Мәҗмуганың бары бер саны гына дөнья күрә)*; «Ак юл» *(1967—1974. Оулу, Хельсинки. Газетаның 63 саны чыга. Мөхәррире — Садрый Хәмит)*; «Тавыш» *(1967, 1—6 саннар. Оулу. Газетаны Садрый Хәмит нәшер итә)*; «Финляндия ислам мәхәлләсе» *(1949. 1—6 саннар. Тампере. Мәҗмуганы Хәбибрахман Шакир һәм Фатыйх Арат чыгара)*; «Ислам мәхәлләсе» *(1950—1951. Барлыгы 11 саны дөнья күрә. Тампере. Бу мәҗмуга — «Финляндия ислам мәхәлләсе»нең дәвамы)*; «Мәхәллә хәбәрләре» *(1949—1963. Тампере-Хельсинки. Мәҗмуга-бюллетень Финляндия ислам җәмгыяте тарафыннан нәшер ителә)* һ. б.

Алманиядә дә татар телендә берничә газета-журналның нәшер ителүе мәгълүм. Болар арасында Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә чыккан «Яңа милли юл» *23.XII.1928—IX.1939)* журналы аеруча мөһим. Ул, нигездә, Берлинда нәшер ителә. Берничә саны Варшауда да дөнья күрә. Иҗтимагый, сәяси, әдәби, гыйльми характердагы бу журнал татар тарихының елъязмасы, милли-азатлык көрәшенең штабы. «Яңа милли юл»ның *(ул 1930 елга кадәр «Милли юл» исемен йөртә)* 136 саны чыга *(Барлыгы 4 мең бит тирәсе[1])*.

Алманиядә янә түбәндәге газета-журналлар нәшер кылына: «Җиһател-ислам» *(«Ислам дөньясы», 1916, Берлин. Газетаны чыгаручылар: Г.Идриси, Р.Ибраһим)*; «Татар иле» журналы *(15 көнгә бер чыга. Барлыгы 11 саны дөнья күрә. 1919. Б.Сәйфелмөлек)*; «Кечерәк җуаткыч» *(«Әдәби вә фольклор гәзитә». Ул Беренче Бөтендөнья сугышы елларында татар әсирләре тарафыннан чыгарыла)*; «Идел-Урал» газетасы *(1942—1944. Кыям Али )*; «Татар әдәбияты» журналы *(Сугыш еллары. Берлин. Мөхәррире: Әнвәргали Айдагулов, әдәби кушаматы — Әнвәр Галим. Гомеренең ахырын ул Нью-Йоркта уздыра һәм 1988 елның 3 мартында шунда ук вафат та була)*; «Очар яфраклар» *(Ной Үлем. Газета 1947—*

---

[1] Хатыйп Миңнегулов. Азатлык көрәшенең мөнбәре. «Казан утлары», 1993, № 3. 122—128 бб.

*1948 елларда чыга. Мөхәррире: Габделхаликъ Алимзадә. Бу милләттәшебез дә Нью-Йоркта дөнья куя);* «Азат Ватан» *(Мюнхен. «Әдәби-сәяси мәҗмуга». 1952—1953. Әкрәм Фәйзуллин. Латин графикасында);* «Милли Байрак» журналы *(Мюнхен, 1953)* һ. б. Сугыштан соң Алманиядә татарча газета-журналлар чыгаруда Минһаҗ Исмәгыйли дә катнаша[1]. 40—60 елларда аның катнашында «Безнең фикер» *(барлыгы—10 сан),* «Таң йолдызы» *(2 сан)* кебек «милли, әдәби, сәяси мәҗмуга»ларның һәм «Урал авазы», «Азат Ватан» исемле газеталарның чыгуы хакында аерым мәгълүматлар бар. Алманиядә дөнья күргән татарча газета-журналларның төп өлеше гарәп графикасында. Калганнары — латин язуында.

Мөһаҗир татарларның, Идел-Урал буеннан киткән галим-әдипләрнең төп өлеше — Төркиядә. Әмма шуңа да карамастан, биредә татарча чыккан газета-журналлар, китаплар, Ерак Шәрык, Финляндия, Алмания белән чагыштырганда, азрак. Бу, күрәсең, телләр якынлыгыннан һәм төрекләрең башка төрки халыкларны төрекнең шивәсе *(«Казан төреге», «Кафказ төреге»...)* дип каравыннан киләдер. Ләкин Төркиядә дә «Казан төрекләре» тарафыннан нәшер кылынган берничә төрекчә-татарча газета-журнал бар: «Мизан» *(1908, Истанбул. Газетаның мөхәррире Морад бәй);* «Тәгърифи мөслимин» *(Атналык әдәби мәҗмуга. 1910, Истанбул.— Р.Ибраһим вә А.Таҗетдин);* «Ислам» *(Айга ике чыккан әдәби-дини мәҗмуга. 1914, Истанбул. Нашире — Н.Сабит);* «Ислам дөньясы» *(1910 еллар, Казанлы таләбәләр мәҗмугасы. Истанбул.);* «Тукай бюллетене» *(1965—1968, Истанбул)* һ. б. Кайбер авторлар Төркиядә «Идел-Урал» мәҗмугасының да берничә саны чыгуын искәртәләр.

Төркиядә «Казан төрекләре» тарафыннан һәм алар өчен чыгарылган газета-журналлар арасында «Казан» мәҗмугасы мөһим урынны алып тора[2]. Ул 1970—1980 елларда нәшер кылына. Барлыгы — 23 сан. Журнал, нигездә, төрек телендә чыга. Әмма анда әдәби текстлар еш кына әүвәл татарча, аннан төрекчә бирелә. Журналның авторлары һәм хезмәткәрләре арасында без Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир *(1922—26. XII. 1991),* Наилә Бинарк һәм башка билгеле милләттәшләребезне очратабыз.

Шәркый Төркестанда, Румыниядә, Швециядә һәм татарлар яшәгән кайбер башка төбәкләрдә дә татарча газета-журналлар чыгуы яисә чыгып алуы мәгълүм. Мәсәлән, Швециядә татарлар Икенче Бөтендөнья сугышы вакытыннан бирле яши. 80 ләп кеше. 1949 елда Стокгольмдә «Швециядә дин һәм мәдәният эшләре буенча төрек-ислам ассоциациясе» төзелә. Бераздан «Швеция ислам җәмгыяте» дип үзгәртелгән бу оешма 1967 елда «Безнең фикер» исемле мәҗмуга да чыгарып ала. Тәүфикъ Әйди язганча *(Добруджадан сәлам! «Ватаным Татарстан», 25.XI.1992),* Румыниядә 70 мең чамасы төрек-татар яши. Анда җирле төрки шивәсендә 1990 елның апреленнән айлык «Кара диңгез» газетасы һәм «Рәнекләр» *(«Төсләр»)* исемле еллык альманах чыга башлый.

Әлбәттә, чит илләрдә чыккан татарча газета-журналларның эчтәлеге, рухы төрле-төрле. Мәсәлән, «Яңа милли юл», «Милли байрак»та сәяси як, Идел-Урал идеясе көчле. Ә инде айга бер мәртәбә чыгучы «Яңа Япон мөхбире» журналы күбрәк дини, икътисади мәсьәләләр белән шөгыльләнә. Хәтта аның 30 еллардагы аерым саннарында Идел-Урал идеясенә, Гаяз Исхакыйга каршы материаллар да бар. Мәсәлән, бер мәкаләдә *(1934, № 21. 49—51 б.)* Токио имамы Корбангали хәзрәт белән Гаяз Исхакый арасындагы бәхәсләр чагылыш тапкан.

Эш шунда ки, 30 елларның урталарында Гаяз Исхакыйның Ерак Шәрыкка килүе, милләттәшләребезне милли-азатлык көрәшенә чакыруы, корылтайлар уздыруы, «Милли байрак»ка нигез салуы бу төбәктәге аерым шәхесләрнең каршылыгына очрый, бәхәсләр тууга сәбәпче була. Бу бәхәсләр билгеле бер дәрәҗәдә вакытлы матбугатка да үтеп керә.

Әмма, нәрсә генә булмасын, чит илләрдәге газета-журналларда аерымлыкка караганда, уртаклык, мәсләки якынлык көчле. Ул татар милләтенең язмышын үзәккә куюдан, халкыбызның бүгенгесе, киләчәге турында кайгыртудан гыйбарәт.

Газета-журналлардан тыш, чит мәмләкәтләрдә милләттәшләребез тарафыннан шактый гына татарча китаплар да чыгарыла. Аларның күпчелеге гарәп язуында. Бу китаплар арасында әдәби, педагогик, гыйльми, дини, музыкаль

---

[1] Тәүфикъ Әйди. Читтә солтан булганчы... («Шәһри Казан», 30.XI.1990); Александр Филиппов. Сагыш. («Ағиман», 1992, № 2. 41—45б.) һ.б.

[2] Хатыйп Миңнегулов. «Казан» мәҗмугасы. («Кызыл Таң», 1992, 10, 12, 15, 16, 17, 19 сентябрь саннары)

басмалар, сүзлекләр, төрле календарьлар бар. Аларның бер өлеше үзтума, икенче өлеше ватанда чыккан китапларның күчермәләре яисә яңартылган басмалары.

Ерак Шәрыкта, газета-журналлар күпләп чыккан кебек, татарча китаплар да шактый гына дөнья күрә. Аларның саны дүрт дистәгә якын. Бу китаплар, нигездә, Токиодагы «Матбагаи исламия»дә нәшер ителә. Арада Харбин, Мукден, Кобе калаларында чыкканнары да бар.

Ерак Шәрыкта басылган татар китаплары хакында инде без «Шәһри Казан» газетасында дөнья күргән «Милләт бетмәсә, аның теле вә әдәбияты яшәр!» исемле мәкаләбездә *(1992, 13 июнь)* күп кенә мәгълүматлар биргән идек. Шуңа күрә биредә берничә фактны гына атап китәбез.

Менә минем алда «Кызларга махсус милли шигырьләр» китабы *(Токио, «Матбагаи исламия», 1936, 24 б. «Бастырып таратучысы: Мөнирә ханым Сөләймания»)*. Бу уку китабы кереш сүз белән бастырылган. Анда мондый юллар бар: бу — «кызларымызга уку өчен һәм дини, һәм милли рух бирү өчен сөйкемле бер әдәбият кисәгедер». Китапка матур эчтәлекле милли шигырьләр урнаштырылган: «Кыз балаларның теләге», «Укучы яшь кызга», «Укучы кызлар», «Имтихан алды», «Умарта корты», «Кем бәхетсез» һ. б. Искәрмәдән күренгәнчә, китаптагы шигырьләрне Мөнирә ханым Сөләймания үзе язган. Аларның үзәгендә алланы зурлау, белем-мәгърифәткә өндәү, ата-ананы хөрмәт итү, милләт өчен көрәш һ. б. мотивлар. Үзләренең рухлары, эчтәлекләре белән бу шигырьләр XX йөз башы татар шигърияте белән турыдан-туры керешеп китәләр.

1933 елда Токиода Тукай әсәрләренең биш томлыгы дөнья күрә. Г. Ибраһимов һәм М.Корбангалиләрнең аерым дәреслекләре нәшер кылына. Болардан тыш башка китапларның да басылуы мәгълүм: Хөсәен Габдүш. Дүрт хикәя *(Токио, 1931, 83 б.)*; Г. Баттал. Төрек-татар тарихы *(Мукден, 1938, 155 б.)*; Солтан. Шигырьләр *(Харбин, 1929, 27 б.)*. Исхак Хәйрулла. Төш. *(Харбин, 1922, 20 б.)* һ. б.

Татар китапларының чит мәмләкәтләрдә иң күп чыккан урыны — Финляндия. Биредә бер меңгә якын гына милләттәшебез яши. Әмма, шуңа да карамастан, алар соңгы 50-60 ел эчендә генә дә 100 дән артык китап[1] нәшер иттеләр[2]. Мәсәлән, Нижгар ягында туып үсеп, аннан Финляндиягә киткән Хәсән Хәмидулла *(25.XI.1900—6.XI.1988)* һәм Садрый Хәмитнең *(11.X.1905—14.XII.1987)* үзләре язып бастырган китаплары гына да берничә дистә. Аларның күпчелеген оригиналь әдәби әсәрләр, җөмләдән шигырьләр, поэмалар, драмалар тәшкил итә. 70 елларда Гәүһәр Туганайның *(ул 1911 елгы)* ике кисәктән торган «Шигырьләр мәҗмугасы» дөнья күрде. Шунысын да әйтик: Гәүһәр апа тумышы белән Баулы ягындагы Кәрәкәшле авылыннан. Татар мәдәниятен яхшы белә, хәзер дә иҗат эшен дәвам итә. Хөсәен Садыйк *(1906—1973)*, Гайсә Хәкимҗан *(1896—1972)* һәм Финляндиядә яшәгән кайбер башка каләм әһелләренең дә оригиналь әсәрләре нәшер кылынган.

Суомидагы татар китаплары әүвәл гарәп, соңгы елларда латин хәрефләре белән басыла.

Шунысы гыйбрәтле: Финляндиядә гомер кичерүче милләттәшләребез, гәрчә алар аз санлы булсалар да, инде менә 100 ел буена үзләренең телләрен, гореф-гадәтләрен, милли үзлекләрен шактый дәрәҗәдә саклап калганнар. Биредә, әлбәттә, ислам дине, катнаш никахлар булмау белән беррәттән, татар китабының күпләп чыгуы вә укылуы да мөһим роль уйнаган

Алманиядә, милли газета-журналлардан тыш, татарча китаплар да дөнья күрә: «Програм». Русияле ислам шәкертләренә ярдәм җәмгыяте. Берлин, 1918, 12 б.; Муса Ярулла Биги. «Исламият әлифбасы». Берлин, 1920. *(Бу хезмәте өчен автор совет төрмәсенә дә утыртыла.)*; «Халык моңнары» . Берлин, 1932, 16 б.; Галимҗан Идрис. «Бугаз мәсьәләсе» («Нинди итләр хәләл»). Берлин, 1933, 16 б. 1937—1939 елларда Гаяз Исхакыйның Берлинда дүрт китабы нәшер ителә: «Дулкын эчендә» *(70 б.)*, «Өйгә таба» *(88 б.)* «Ян-Баевич» *(70 б.)*, «Көз» *(74 б.)*. Алманиядә, нигездә Мюнхендә, Икенче дөнья сугышыннан соң да берничә татар китабының чыгуы мәгълүм. Алар арасында Г.Тукайның «Шигырьләр» җыентыгы, Т.Дәүләтшиннең «Татар әдәбияты», «Татар тарихы», «Татар халык жыр-

---

[1] Чагыштырып карагыз: Урта Азиядә миллионга якын, Мәскәүдә 200 меңнән артык, Санкт-Петербургта 100 меңләп татар яши. Ә аларда соңгы берничә дистә елда татарча китап, газета-журнал чыкканы бармы? Юк дәрәҗәсендә.

[2] Бу хакта: Илбарис Надиров. Финляндия татарлары. «Казан утлары». 1992,№2, 176—188 б.; Әбрар Кәримуллин. Суоми иленең татар китаплары. «Казан утлары», 1990. № 9. 177—183 б.; Хатыйп Миңнегулов. «Бигрәк тә татар җанлы кеше иде» (Хәсән Хәмидулла турында.) «Ватаным Татарстан», 21.VI.1992.

лары», Минhажның ике кисәктән торган «Шигырьләр китабы» *(I—1952; II—1968)*, Ш.Нигъмәтинең «Шигырьләр»е, шулай ук «Безнең өмет», «Безнең фикер» кебек мәҗмугалар бар *(«Казан» журналы. 1978, № 21, 55—56 б.)*. 1989 елда Алманиянең Висбаден каласында Тамырбәк Дәүләтшин, Ирма Дәүләтшин(а), Сәмих Тизҗанның «Татарча-немецчә сүзлеге» нәшер ителде (365 б.). 17 меңнән артык сүзне үз эченә алган бу китап — татар дөньясы өчен уникаль күренеш. Әмма, кызганыч ки, бу кыйммәтле сүзлекнең безнең мәдәниятебезгә кирәклеге хакында моннан ике еллар элек язып чыксак та[1], әле хәзергәчә аның илдәге студентларга, татар кешеләренә алдырылганы юк.

Татарча китаплары белән электән мәшhүр Йосыф Акчура, Садрый Максудый, Зәки Вәлиди, Габдулла Баттал, Төркиягә күчкәч, үз хезмәтләрен, шул исәптән татар тарихына hәм мәдәниятенә багышланганнарын да, нигездә, төрекчә язалар. Кайберләренең французча, немецчә басылган китаплары да бар.

Гомумән, Төркиядә басылган татарча китаплар чагыштырмача аз. Боларга шагыйрь Исфәндияр *(Әсфәндияр)* Ишгайның[2] «Җәhәннәмнән котылганнар» *(1956)*, «Вөҗдан гыйсъяны» *(1961)*, «Хөррият, хөррият» *(1963)* исемле җыентыкларын, Әхмәт Ләбиб Каранның «Шиhабетдин Мәрҗани: тормышы hәм әсәрләре» *(«Таң» матбагасы. 1960, 79 б.)*, «Татарларның төп чыгышы» *(Истанбул, 1962, 96 б.)* монографияләрен hәм «Яшь вакытым җырлары» *(Истанбул, 1959. 96 б.)*, «Төшенчәмнең җырлары» *(Истанбул, 1959. 96 б.)* кебек шигырь тупламнарын hәм тагын берничә китапны кертергә мөмкин.

Кызганыч ки, башка мәмләкәтләрдә чыккан татарча китаплар хакында хәзергә мәгълүматларыбыз бик сыек. 1963 елда Әхмәт Гәрәйнең гарәп язуында ике кульязма китабы Нью-Йоркта күбәйтеп таратыла. Аларның беренчесе «Ниләр, ниләр, тагы да ниләр» дип атала. Анда шагыйрьнең төрле елларда hәм калаларда *(Каhирә, Хартум, Нью-Йоркта)* язылган берничә шигыре тупланган. Мәсәлән, авторның 1953 елда Күк Нил буенда иҗат иткән «Үрнәк» парчасыннан бер строфа:

*Кыр казлары язда Африкадан*
*Урал якларына очалар.*
*Безнең илдә җәйдә кунак булып,*
*Көзгә каршы кире кайталар...*

Алга таба шагыйрь кошлар язмышыннан кешеләр язмышына күчә, бердәмлектә, үзара ярдәмдә кыр казыннан үрнәк алырга чакыра: «Чөнки берлек, берлектә зур куәт, Берләшкәнләр генә яшиләр».

Әхмәт Гәрәйнең Нью-Йоркта чыккан икенче китабы Американың мәшhүр шагыйрәсе Эмилия Дикинсоннан *(Emily Dikinson. 1830—1886)* тәрҗемәләрне үз эченә ала. Инглизчә hәм татарча текстлар янәшә бирелгән. Тәрҗемәче Америка шагыйрәсе белән Сания Гыйффәт *(1899—1957)* әсәрләре арасында бераз охшашлык таба hәм, мөгаен, шуңа күрәдер китабының ахырында татар шагыйрәсенең дә өч шигырен урнаштыра: «Тормыш көзгесе» драмасыннан, «Егерме ел элек ил» *(Милләт мәҗлесенең юбилее уңае белән»)* hәм «Актык теләк».

М. Госманов язуынча, Шәркый Төркестанда да *(нигездә, Голҗа каласында)* берничә татар китабы дөнья күрә. 1935—1936 елларда, мәсәлән, мәктәпләр өчен Малик Биктимиревнең «Җәгърафия» китабы hәм «Туган тел» дәреслек-хрестоматиясе бастырыла. 1947 елда Хәмит Тәхфи *(ул хәзер Ташкентта яши)* тарафыннан Г. Тукайның «Сайланма шигырьләре» нәшер кылына[3].

Румыниядә, Болгариядә hәм кайбер бүтән илләрдә чыккан татар китаплары хакында әлегә кулыбызда конкрет мәгълүматлар юк.

---

[1] Х. Миңнегулов. М. Хайруллин. Звезда Тамурбека Давлетшина «Вечерняя Казань» 14.IX.1990. Мәкаләдә, нигездә, Т. Дәүләтшинның сүзлеге hәм рус телендә чыккан «Советский Татарстан: Теория и практика национальной политики» *(Лөндон, 1974. 392 с.)* хакында сүз бара. Т. Дәүләтшин хакында мәгълүматлар: Әхмәт Сәхапов. Мюнхен институты профессоры. «Мирас» 1992, № 1. 89—93 б.

[2] Әсфәндияр Чынбай (1980—1992) чыгышы белән Төмән өлкәсенең Тубыл районындагы Кызылбай авылыннан. Тубылда, Екатеринбургта, Оренбургта укый. Мәктәптә, Ульяновск, Тубыл педагогия училищеларында татар теле hәм әдәбияты укыта. Сугышта әсирлеккә эләгә, лагерь газапларын күрә. 1948 елдан алып Төркиядә яши. *(Сагыйдә Арысланбай мәкаләсе. «Шәhри Казан». 3.X.1992.)*

[3] Миркасыйм Госманов. Чәчелгән орлыклар: Голҗа татарлары. «Казан утлары», 1992, № 4, 76, 98 бб.

## II

XX йөздә чит илләрдә гомер кичергән милләттәшләребез үзара аралашып, керешеп яшәгәннәр. Бер төбәктә чыккан татарча газета-журналлар һәм басма китаплар да татарлар яшәгән икенче төбәкләргә тиз ирешкән, шулай итеп, рухи байлык та тиз арада уртак хәзинәгә әверелгән. Төрле күченүләр булуы да мәгълүм. Мәсәлән, Ерак Шәрыкта *(Маньчжуриядә, Япониядә, Кореяда...)* яшәүче татарларның зур өлеше Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Төркиягә, АКШка, Австралиягә күчеп китә. Варшаудагы Идел-Урал татарлары да сугыш елларында, нигездә, дөньяның төрле төбәкләренә таралып бетә. Шәркый Төркестанда яшәүче милләттәшләребезнең 80 проценты 1954—1959 елларда СССРга әйләнеп кайта *(Хәмит Төхфи, Миркасыйм Госманов һ. б.)*, ә кайберләре Төркиягә, Америкага, Австралиягә юнәлә. Хәзер Шәркый Төркестанда 4 меңләп кенә татарның яшәве мәгълүм.

Читтәге әдипләрнең дә шактые еш күченеп йөрергә мәҗбүр була. Мәсәлән, Гаяз Исхакый Төркиядә, Варшауда, Парижда, Лондонда, Ерак Шәрыкта һәм башка төбәкләрдә яши. Сания Гыйффәтнең дә илдән киткәннән соңгы яшәү географиясе шактый киң: Кытай, Төркия, Финляндия һәм янә Төркия. Ә инде Әхмәт Гәрәй — татар әдипләреннән дөньяны иң күп гизүчеләрнең берседер. Ул Үзбәкстанда туа, икенче дөнья сугышында алманнарга әсирлеккә эләгә, аннан — инглизләргә. Бераз вакыт Италиядә яшәп ала. Озак еллар гарәп илләрендә *(Мисыр, Судан һ. б.)* тора. Аннан — Төркиядә һәм АКШта.

Чит илләрдәге татар әдәбияты, татар матбугаты дип сөйләү ул шактый дәрәҗәдә шартлы күренеш. Ни өчен? Чөнки бу мәдәният төбе-тамыры белән татар язмышы, Идел-йорт белән бәйләнешле, ул бары тик бер үк гомумтатар мәдәниятенең үзгә тарихи шартларда яшәеш һәм дәвам ителеш формасы гына. Бу нәрсәләрдә күренә соң?

Беренчедән, чит илләрдә басылган татарча китаплар, газета-журналлар иң беренче чиратта татар укучыларын күздә тотып, татар кешеләре тарафыннан чыгарылган. Авторларга гына игътибар итегез: Гаяз Исхакый, Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Садрый Хәмит, Шаһвәли Келәүле *(Илдәр)*, Әсфәндияр Ишгай, Ш. Нигъмәти, Гәүһәр Туганай, Әхмәт Ләбиб Каран, Минһаҗ һ. б.— болар бит барысы да илдә туып, үсеп киткән кешеләр! Ә кайберләре Идел-йортта яшәгән вакытта ук әдип буларак танылалар. Чит илләрдә туып, үсеп, татарча иҗат иткән каләм әһелләре гадәттән тыш аз. Булганнары да гаиләдә яисә мәктәптә татар тәрбиясе алган кешеләр. Мәсәлән, күп кенә пьесалар, дәреслекләр, гыйльми мәкаләләр авторы Наилә Бинарк 1940 елда Кореяда зыялы гына татар гаиләсендә туа, татар әдәбиятын укып үсә. Суомида татар баларын укыта, Төркиядәге «Казан» журналында эшли. Ә инде читтә яшәүче хәзерге милләттәшләребез Гали Акыш, Надир Дәүләт, Фәрит Иделле кебек күренекле затлар, әдәби иҗаттан бигрәк, нигездә, фәнни тикшеренү, сәяси-мәдәни агарту белән шөгыльләнәләр.

Икенчедән, һәм илдәге, һәм чит мәмләкәтләрдәге татар мәдәниятенең үзәгендә — милләт язмышы, татар халкының тарихы, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйланулар, татар кешеләренең рухи халәте.

Өченчедән, читтәге әдәбият та меңәр ел буе тупланып килгән шигъри казанышларга, фольклор мирасына нигезләнеп үсә. Идел, Агыйдел, Казан, Сөембикә, Тукай мөһаҗир иҗатчыларыбыз өчен дә изге образлар, якын төшенчәләр. Иң мөһиме — бер үк татар язма һәм сөйләмә теле һәм илдәге, һәм мөһаҗәрәттәге әдәбият өчен уртак.

Чит мәмләкәтләрдәге һәм илдәге язма мәдәният, бер-берсе белән никадәр генә якын, тыгыз бәйләнештә булмасын, алар үзара тәмам керешеп, тәңгәлләшеп китмиләр.

Һәм мөһаҗәрәттәге, һәм илдәге язма әдәбият үзгә иҗтимагый-тарихи шартларда туа һәм яши. Совет чоры әдәбияты өчен хас булган күп кенә темалар һәм проблемалар *(кумәкләшү, хосусый милекчелеккә каршы көрәш, партия җитәкчелеге, динне фаш итү, «интернационализм» һ. б.)* читтәге газета-журналларда һәм басма китапларда бик күзгә ташланмый. Булган очракта да алар башкачарак, тәнкыйди пландарак карала.

Билгеле булганча, Октябрьгә кадәрге татар әдәбиятында һәм вакытлы матбугатында милли-азатлык темасы шактый нык урын ала һәм шуңа нисбәтән, тормышта да татарның милли үзаңы куәтле үсеп китә. Кызганыч ки, совет чорында, Мәскәү хакимиятенең коточкыч басымы нәтиҗәсендә, бу мөһим традиция өзелеп кала язды. Үз милләтен яратучы, аның тәрәккыяте өчен тырышучы

милләтпәрвәр, милләтче төшенчәләре тискәре мәгънә алды, хәтта илгә, халыкка дошман дәрәҗәсенә күтәрелде. Мөһаҗәрәттәге каләм әһелләре исә инкыйлабкача традицияләрне дәвам итеп кенә калмадылар, милли азатлык, татар темасын, яңа сәяси-тарихи вазгыятьне исәпкә алып, тагын да тирәнәйттеләр, тагын да үстерделәр. Әдәби әсәрләрдә һәм публицистикада татар тарихы, татар тормышы чагыштырмача тулырак һәм объективрак яктыртылды, мөстәкыйль татар дәүләте, Идел-Урал җөмһүрияте төзү төп максатларның берсе итеп куелды. Мәскәү хакимиятенең милли сәясәте, совет халкы исеме астында урыслаштыру политикасы уздыруы тәнкыйтькә очрады.

Соңгы елларда татарның үзаңы кузгалуда, милли-азатлык хәрәкәте көчәюендә, реаль тормыш белән беррәттән, мөһаҗәрәттәге татар әдәбиятының һәм матбугатының да роле зур булды.

Фаҗигале татар тарихы өчен элек-электән туган җирдән, якыннардан аерылу хас. Мөгаен, шуңа күрәдер дә аерылу, сагыну — татар әдәбиятында һәм җырбәетләрендә иң тирән чагылдырылган мотивлар. Чит мәмләкәтләргә элеккән кешеләрдә сагыну тойгылары аеруча көчле. Бу мөһаҗәрәттәге һәр каләм иясенең язмасыннан диярлек бөркелеп тора. Хөсәен Габдүш хикәяләрен илне, туган җирне сагыну симфониясе дип атарга мөмкин булыр иде. Аның «Үзебез өчен» әсәренең каһарманы Габдулла Сөембикә манарасыннан ничек итеп «орел»ны алуны сөйли дә, ахырда, моңаеп, җырлап җибәрә:

*Карлыгач, кая барасың,*
*Бармыйсыңмы безнең илләргә?*
*Барсаң да гына безнең илләргәләй...*
*Сәлам әйтче туган илләргә...*
*Сәлам әй... т*
*Нечкә билләргә.*

Мөһаҗәрәттәге татар язма мәдәнияте, нигездә, гарәп язуында; тел-стиле, лексик составы, грамматик төзелеше белән дә Октябрьгә кадәр татар әдәби теленә якын тора. Совет чорында телебезгә кергән урыс сүзләре һәм алынмалары анда чагыштырмача аз. Җирле шивәләр дә шактый мул файдаланылган. Төрек теле йогынтысы сизелә. Хәтта Көнбатыш Европа телләренең аерым сүзләре дә төрек аша алынган. Кыскасы, мөһаҗәрәттә туган язма истәлекләрдә тел-стиль ягыннан да бүген безгә гыйбрәт, тәҗрибә алырлык урыннар бар.

Мөһаҗәрәттәге каләм әһелләренең язмаларында чит-ят җирләр, башка халыклар, аларның тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре дә теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш тапканнар. Бу яктан аеруча «Яңа Япон мөхбире» журналы игътибарга лаек. Аның һәр санында бу мәмләкәткә мөнәсәбәтле материаллар, рәсемнәр бар. Менә журналның 1938 елгы апрель саны *(№ 61)*. Ул японнарның сакура, ягъни «чия чәчкәсе бәйрәме»нә багышланган. Бу хакта мәҗмуганың тышлыгында рәсем, ә 4—7 битләрдә «Япониядә чия чәчкәсе» дигән махсус мәкалә бар. Язмада сакура бәйрәменең асылы аңлатыла. Мәкалә болай башлана: «Бөтен дөньяда Япуниягә чия мәмләкәте диләр... Япуниядә төрле төсле чәчкәле чия агачының үстерелүе вә һәр йирдә багчаларда тулы булуының меңь еллык тарихы бар...

... Чия чәчкәсе Япуниядә *(мәркәздә)* апрельнең уникарында ата башлый. Вә бер атна эчендә болыт кеби бөтен офыкны каплый вә дәхи бер атна эчендә коелып бетәдер. Япун самурайлары *(хәрби катлау кешеләре, батыр сугышчылар.— Х. М.)* үзләренә чия чәчкәсен үрнәк кылып тотмышлар вә чия чәчкәсе кебек күрсәтәчәк матурлыгыны бердән тулы рәвешдә күрсәтеп, матурлыгың беткәч, мәйдандан югалу кирәк дигәнләр...» *(4 б.)*.

Башка илләр, халыклар, аларның табигате, яшәү рәвешләре, тарихы хакында язмалар еш кына татар күзлегеннән, милләтебезгә мөнәсәбәттә карала. Әмма, гомумән, татар газета-журналлары татарлар өчен генә түгел, ә кайбер башка илләрне, милләтләрне, халыкара вакыйгаларны һәм дөнья тарихи агышын өйрәнү өчен дә билгеле бер чыганак булып торалар. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның «Финляндиядә» мәкаләсе *(«Яңа милли юл», 1937, № 4—5 бб.)* Суоми тарихын һәм Финляндия — СССР мөнәсәбәтләрен тикшерүчеләр өчен дә менә дигән материал. Читтә чыккан татарча басмаларда, нәшер итү урынына карап, финчә, немецчә, япунча, полякча, төрекчә язмалар да очрый.

Үзгә мәмләкәтләрдә татарча газета-журналлар, китаплар чыгару эше, милли мәдәниятнең һәм мәгарифнең башка тармакларындагы кебек үк, халкыбызның үзе тарафыннан, үз хисабына башкарылган. Милләттәшләребез арасында Әхмәт Вәли Мәңгәр кебек бай, хәлле кешеләрнең *(химаячеләрнең, спонсорлар-*

*ның)* чагыштырмача аз булуы, сәяси киртәләр аркасында милли мәдәният һәм мәгариф эшләрен оештыру гаять авыр бара *(Гаяз Исхакыйның, Хәсәен Габдушнең газета-журналлар чыгаруга, китаплар бастыруга рөхсәт ала алмыйча, акча, мөмкинлек таба алмыйча өзгәләнүләре үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Әйтергә, язырга теләгән күпме сүз, күпме фикер югалып калган!)*. Әмма шуңа да карамастан, халкыбызның зыялылары, милләтпәрвәрләре, матди, иҗтимагый-сәяси кыенлыкларны җиңеп, татарлар яшәгән һәр төбәктә, һәр илдә диярлек Ислам, Казан төрекләре, төрек-татар, Сөембикә, Тукай һәм башка исемдәге дини, мәдәни, мәгариф җәмгыятьләре, берлекләре, оешмалары, мәркәзләре төзиләр, шулар ярдәмендә милли һәм рухи тәрбия эше алып баралар.

Чит мәмләкәтләрдәге татар әдәбиятын һәм матбугатын гомуми күзәтү дә шуны күрсәтә: туган тел мөхитеннән, туган мәктәбеннән, туган җиреннән, асыл Ватаныннан аерылган мәдәният һәм аның әһелләре озак яшәми, күп дигәндә дүрт-биш дистә елда, икенче-өченче буында инкыйразга, ягъни бетүгә йөз тота. Күп кенә галим-әдипләр, киләчәк шарт-хәлләрне алдан ук аңлап, тиз арада икенче телгә күчеп, үзгә милләт хадимчесе булып та китәләр. Моңа мисаллар читтә генә түгел, элеккеге СССР илендәге татарлар арасында да җитәрлек.

Башка мәмләкәтләрдә татар әдәбияты, татар матбугаты, татар мәктәбе хәзерге көндә яшәми дә, тумый да диярлек. Хәтта моңа кадәр бик күп кенә китаплар, газета-журналлар чыгарган, без уңай яктан телгә ала торган Финляндиядә дә татар милли мәдәнияте бетүгә бара. Чөнки анда да хәзер татар мәктәбе юк, балалар, яшьләр, үзләре дә сизмәстән, кайвакыт финчәгә күчеп китәләр, татарчаны фин акценты белән сөйләшүче милләттәшләребез арта бара. *(Әмма шулай булса да, Финляндия татарларына рәхмәт әйтергә кирәк: алар, ничәмәничә ел буе чит төбәктә яшәсәләр дә, туган телләрен саклап калганнар. Ә безнең милләт мәркәзендә, Казан татарлары арасында үз телләрендә акцент белән генә түгел, хәтта бөтенләй сөйләшә алмаучылар да буа буарлык. Бу — бик кызганыч хәл. Әмма ул — рәхимсез чынбарлык.)*

Без «татарлар күп, алар фәлән миллион», «безнең халык бөтен Союзда, бөтен дөньяда яши», дип сөйләргә, хәтта мактанып алырга да яратабыз. Әмма халыкның таралуы, сибелүе һич тә мактана, горурлана торган әйбер түгел. Чөнки ул — милли фаҗига. Таралган, сибелгән халыкның, этник берлек буларак, киләчәге өметсез: ул иртәме, бераз соңмы, барыбер бетәчәк, ассимиляцияләнәчәк, башка милләтләр тарафыннан йотылачак. Ерак мәмләкәтләрдәге татарларны гына түгел, Магадандагы, Санкт-Петербургтагы, Донбасстагы, Кузбасстагы һәм элеккеге Союзның Идел-йорттан башка бик күп төбәкләрендә татарларны да киләчәктә әнә шул язмыш көтә.

Милләт яшәсен өчен, аның теле, мәктәбе, мәдәнияте, дине, гореф-гадәтләре яшәргә тиеш. Моның өчен исә халыкның чагыштырмача оешып, милли мөхит тудырып яшәве, үз язмышына үзенең хуҗа булуы зарури. Озак гасырлар буе бөтен дөньяга таралган яһүдләрнең Израиль дәүләтенә көннән-көн ныграк туплана барулары, совет немецларының Германиягә күпләп күченүләре, башка халыклар, шул исәптән, татарлар өчен дә гыйбрәтле. Бу уңай белән Гәрәй Рәхимнең «Татар кешесе» шигыре, ирексездән, хәтергә килә. Автор татарларның Иделен, үз йортын калдырып, бөтен дөньяга сибелүен тасвирлый да, ахырда болай ди:

*Болай каңгырып йөрмә,*
*Кайт син туган илеңә,*
*Борынгылар түренә.*
*Бит куй Идел җиренә,*
*Баш куй Болгар җиренә,*
*Әйдә, татар кешесе!*

* * *

Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты — рухи мирасыбызның хәләл бер өлеше. Ул мәдәният һәм әдәби процессны тулыландырып кына калмый, ә халкыбызның рухи тарихын, үткән катлаулы юлын, башка илләр һәм милләтләр белән бәйләнешләрен киңрәк, тагын да тулырак, ачыграк итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Анда бүгенге көнгә аваздаш яклар да күп. Шуңа күрә мөһаҗәрәттәге язма истәлекләрне өйрәнү, аларны хәзерге укучыларга җиткерү — татар фәне алдында торган бурычларның берсе.

Чит илләрдәге язма истәлекләрне тудыручыларның күпчелеге катлаулы язмышка ия. Әмма бу хәл аларны гыйльми өйрәнүдә, гадел бәяләүдә киртә булырга тиеш түгел. Чөнки бу шәхесләр үзләре дә, аларның язганнары да хәзер тарихи, объектив күренеш итеп каралырга тиеш. Фән исә, билгеле булганча, иң беренче чиратта мәгълүматлар белән эш итә.

Читтәге язма истәлекләрнең әдәби дәрәҗәләре төрлечә. Гаяз Исхакый, Хөсәен Габдүшләрнең талантлы язмалары белән беррәттән, шигъри яктан зәгыйфь ядкярләр дә шактый очрый. Әмма биредә дә бер хакыйкатьне истә тотарга кирәк: теләсә нинди әсәр, китап ул нинди генә булмасын, безнең язма мирасыбызның бер өлеше. Шуңа күрә үткәндәге мәдәни ядкярләрне без мөмкин кадәр тулырак, бөтенрәк алырга бурычлы.

## *Безнең календарь*

# Сөббух Рәфыйковның тууына 80 ел

Сөббух Рәфыйков — заманында шәхес культы шаукымыннан җәбер күргән, гомеренең иҗади яктан иң уңдырышлы булырга тиешле ун елын сөргендә уздырган язучыларыбызның берсе. Аны Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкарганда, 1937 елда кулга алалар. Бу вакытта ул, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтының тел-әдәбият бүлегендә укый торган була. Шулай итеп, язмыш кушуы буенча, яшь язучы 1937 елның октябреннән 1957 елның августына кадәр төньяк өлкәләрдә һәм Красноярск краенда Сталин лагерьларында газап чигә.

Сөббух Һади улы Рәфыйков тумышы белән Сарман районыннан. Ул 1913 елның 15 июлендә Нөркәй авылында туа. 1925—1930 елларда башта Чаллыда һәм Алабугада тугыз еллык мәктәптә, аннары Казанда югары уку йортына әзерлек курсларында укый.

1931 елдан башлап ул — журналистлык эшендә: республика «Колхоз газите» редакциясендә әдәби хезмәткәр, Сарман районында чыга торган «Комбайн» газитендә җаваплы редактор урынбасары, республика комсомол газите — «Кызыл яшьләр» редакциясендә бүлек мөдире һәм Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир...

1957 елда сөргеннән әйләнеп кайтканнан соң, Сөббух Рәфыйков шактый гомер «Социалистик Татарстан» газитенең башта Зәй төбәгендәге үз хәбәрчесе (1958—1961), аннары штаттан тыш хәбәрчесе булып эшли.

Әйткәнебезчә, С. Рәфыйков кулына каләмне яшьли ала. 1931—1937 еллар арасында аның шигырь һәм хикәяләре тупланган «Үсү җырлары», «Соңгы талпыну», «Үсмерчак» исемле мәҗмугалары дөнья күрә. 1957 елда «Ак төннәр» дигән шигъри китабы нәшер ителә.

Сөббух Рәфыйковка язучы буларак танылу алып килгән әсәре — «Беренче яз» романы 1958 елда иҗат ителә. Биредә әдип 1920—1930 елларда татар авылында барган социаль үзгәрешләрне шул заманга хас реаль күренешләр, җанлы образлар аша чагылдыра. Бу роман укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан югары бәяләнә. «Авыл иртәсе» романында исә язучы әлеге теманы дәвам итә, вакыт ягыннан безнең көннәргә якынайта. Ул гомеренең соңгы елларында Зәй гидроэлектростанциясе төзелешендә эшләүчеләр турында «Тын елга буенда» исемле яңа роман иҗат итте. Бу әсәр башта «Казан утлары» журналында (1971 ел, 2—6 саннар) дөнья күрде, аннары Татарстан китап нәшриятында нәшер ителде. Кызганыч ки, бу китабын автор үзе күреп сөенә алмады, ул 1971 елның 21 ноябрендә вафат булды.

Сөббух Рәфыйков 1965 елдан бирле Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Яхъя Абдуллин,**
*фәлсәфә фәннәре докторы, профессор*

# ИСЛАМ БЕЗНЕҢ ТАРИХЫБЫЗДА ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫБЫЗДА

Дистәләгән еллар дәвамында безнең тормышыбызда атеистик идеология хакимлек итте һәм ул халкыбыз аңыннан ислам динен куу өчен бөтен тырышлыгын куйды. Шушы максатларда рәсми пропаганда ислам дине кануннарын бозып күрсәтергә тырышты, аңа пычрак атты; аның барлыкка килүе, тарихы һәм җәмгыять тормышындагы роле бозып күрсәтелде. Бу пропаганданың асыл максаты ничек кенә булса да, исламны җәмгыять тормышында һичнинди уңай роль уйнамаган тискәре күренеш итеп танытуга кайтып кала иде. Бу пычрак пропаганда исламны, аның тарафдарларын сәяси эзәрлекләүләр белән беркетелде һәм көчәйтелде.

80 еллар азагында илдә җәелгән яңарыш — дингә, шул хисаптан исламга карата да бүтәнчә карау мөмкинлеген тудырды. Ислам безнең тарихыбызда бик борынгыдан кергән һәм халкыбызның тормышында зур роль уйнаган рухи корал.

922 елда Идел буена Багдад хәлифәлегенең илчелеге килә һәм шушы уңайдан үткәрелгән тантаналар вакытында ислам Европаның көнчыгышында аякка басып килә торган яңа дәүләтнең — Идел-Кама Болгарстанының рәсми дине дип игълан ителә. Бу вакыйга безнең бабаларыбыз болгарларның исламга күчүе йомгагы иде. Ә күчеш X гасырдан күп элек башлана. Ш. Мәрҗани «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» дигән хезмәтендә болгарларның исламга X йөздән күп элек тартыла башлаулары турында сөйләүче ышанычлы дәлилләр китерә һәм алар арасында дәвалаучылар кыяфәтендә дингә өндәүчеләр йөргәнлеген әйтеп үтә. Болгарларның гарәпләр белән аралашулары гарәп-хәзәр сугышлары вакытында ук башлану мөмкинлегенә ишарә ясый. Шушы характердагы фактларны һәрьяклап тикшергәннән соң, болгарларның исламга күчә башлаулары Һарун әр-Рәшид һәм Мәэмүн хәлифәләр идарә иткән чорларга туры килә дигән фикерне әйтә *(Мәрҗани Ш. «Мөстәфад әл-әхбар», I т. Казан, 1987, 52—57 бб.)*. Бу хәлифәләрнең беренчесе 786—809 елларда, ә икенчесе — 813—833 елларда идарә иткән булалар. Димәк, болгарлар исламга VIII гасырның азагында һәм IX гасырның башында ук күчә башлыйлар. IX гасырда болгарлар арасында ислам йолаларының яхшы ук киң таралуы турында археологик тикшеренүләр дә сөйли. Һәм, ниһаять, Иран географы Ибн Рустәнең болгар авылларында мәчет-мәктәпләр булуы турында язып калдырган хәбәре. Бу хәбәр дә IX йөзгә карый.

Әлбәттә, инде IX гасырда ук бөтен болгар халкы мөселман була дип әйтергә ярамас. IX йөздәге болгар зиярәтләрында мөселманнар белән мәҗүсиләрнең каберләре аралашып ята. Бу турыда Е. А. Халикова үзенең «Мусульманские некрологи Волжской Булгарии» дигән хезмәтендә ачык дәлилләр китерә *(Казан,*

*1986)*.Ш. Мәржани язган һәм болгарларның исламга Һарун әр-Рәшит, Мәэмүн хәлифәләр заманында кучүләре турында сөйләүче чыганаклар, мөгаен, болгарларның аерым төркемнәрен генә күздә тотадыр.

Русьның христианлыкны кабул итүенә багышлап чыгарылган бер мәкалә «Выбор князя Владимира» дип исемләнгән иде. Русьтан аермалы буларак, болгарларның исламны кабул итүе патшаларының шушы динне башлап сайлавы нәтиҗәсе түгел иде. Алар халык буларак үзләре акрынлап шушы дингә тартыла. Башта аларның бер төркеме, соңыннан башкалары шушы динне кабул итә. Алмыш ханның исламны формалашып килә торган дәүләтенең рәсми дине дип игълан итүе мәгълүм тарихи агышның табигый йомгагы була.

Болгарларның исламны кабул итүенә алардагы икътисади-иҗтимагый һәм рухи үсеш китерә. Шуның белән бергә аларның нәкъ менә исламны кабул итүләрендә араларында мәҗүсилек заманында таралган ышанулар да үз ролен уйный. Башка төрки халыклардагы кебек үк, болгарлар арасында да, тәңре идеясе киң таралган була. Шушы идеологиянең үсеше, әйтергә кирәк, болгарларны бер алла фикерен кабул итүгә турыдан-туры этәрә дә. Ә бер алла фикере ислам тәгълиматының асылын тәшкил итә. Әле хәзер дә татарлар арасында тәңре төшенчәсенең ходай төшенчәсе белән беррәттән Алланың синонимы булып кала бирүе шуңа күрә очраклы хәл түгел.

Әйтелгәннәр — болгарларның нәкъ менә исламны кабул итүенең эчке сәбәпләре. Әмма моның тышкы сәбәпләре дә бар. Болгарларның якын күршеләре славяннар һәм угыр-фин кабиләләре бу вакытта мәҗүсилектә яши. Христианлашкан Европада грек-рим чоры мирасы онытылган, ә кешеләрнең аңында схоластика сөреме киң таралган була. Гарәп-мөселман дөньясы исә IX-XI гасырларда чәчәк ату чорын кичерә. Бу чорда анда бик кызу рәвештә антик дөнья калдырган мирасны үзләштерү бара. Антик заманның Сократ, Платон, Аристотель, Плотин, Пифагор, Эвклид, Гиппократ кебек зур акыл ияләренен әсәрләре гарәп теленә тәрҗемә ителә. Фәлсәфә буенча зур-зур трактатлар, фәнни хезмәтләр языла, әдәбият һәм эстетик фикер үсә, шәһәр тормышы кайный. Гарәпләрнең бу казанышлары бабаларыбызның игътибарын үзенә җәлеп итми калмый һәм исламны кабул итү өчен билгеле бер алшарт тудыра.

Болгарлар тормышында һәм аларның варислары — Идел буе татарларының тарихи язмышында ислам әһәмиятле һәм күпьяклы роль уйнады. Бу турыда сүз алып барганда, беренче чиратта, идеологик система буларак исламның үзенчәлекләрен күз алдына китерү зарур. Ислам — дөньякүләм таралган диннәрнең берсе. Башка диннәр кебек үк, аңа да үз кануннары, кагыйдәләре хас. Әмма аның эчтәлеге бу догматика, норма һәм символлар белән чикләнми. Исламның башка ягы да бар. Ул киң планлы һәм күпкырлы мәдәни-идеологик система, дөньяга карашның тулы бер формасы. Үзенчәлекле идеологик система буларак, ул үзендә дини карашлар белән бергә фәлсәфи төшенчәләр тезмәсен дә, социаль һәм этик концепцияләрне дә берләштерә. Ислам шулай ук җәмгыять тормышын, кешеләрнең көндәлек эш-гамәл тотышларын, аларның үзара мөнәсәбәтләрен билгеләүче кануният та. Мөселман дөньясында иҗтимагый-сәяси, этик һәм фәлсәфи мәсьәләләрне хәл итү, аларның таралышы ислам билгеләгән тышча эчендә барды.

Фикһе гыйлемен алып карыйк. Фикһе гыйлеме, гадәттә, исламның хокук тәгълиматы рәвешендә танылa. Әмма фикһе чынлыкта бер хокук мәсьәләләре белән генә чикләнми. Ул үзендә җәмгыять төшенчәсенә кагылышлы бик күп проблемаларны берләштерә. Хокук мәсьәләләре белән беррәттән ул, шулай ук, фәлсәфәне дә, илаһи тәгълиматны да, сәясәтне дә, әхлак мәсьәләләрен дә, мантыйкны һәм тел гыйлемен дә тикшерә. Шәригать белән дә эш шулай тора. Гадәттә соңгысын хокукый һәм әхлакый нормалар җыентыгы дибрәк күзаллыйлар. **Әмма киң планда алганда, шәригать үз алдына кеше яшәешенең бөтен якларын да яхшылык-яманлык күзлегеннән чыгып бизмәнләү бурычы куя.** Шуның белән бергә, ул үз эченә кеше яшәешенең иң төп сәбәпләрен ачу, аның универсум белән бәйләнешен һәм табигатен өйрәтү вазифаларын да ала. Димәк, фикһе гыйлеме дә, шәригать тә иҗтимагый, фәлсәфи, хокукый һәм әхлакый проблемаларның барысын колачлый һәм аларга җавап бирергә тырыша. Исламның болгар-татар тарихында тоткан урыны аның шушы киң колачлы мәдәни-идеологик система булуы белән билгеләнә дә.

Хәзер болгарларның исламны кабул итүләренең әһәмиятен күрсәтүче кайбер факторлар:

**Беренчедән,** болгарларның Урта Иделдә ныклап тамыр җәюе Идел-Кама регионында болгар дәүләтенең формалашуы белән янәшә бара һәм ислам бу

дәүләтнең идеологик һәм хокукый нигезләре вазифасын үти. Болгарларның исламны кабул итүенең әһәмияте беренче чиратта шушының белән билгеләнә дә. Дәүләт дине дип игълан ителгәч, ул аерым кабиләләрнең мәҗүсилек белән бәйләнгән йолаларына каршы көрәшне уңышлырак үти башлый һәм бу кабиләләрне бердәм дәүләт хакимияте тирәсенә туплауга ярдәм итә.

**Икенчедән,** ислам шулай ук болгарларның, аларга якын башка төрки һәм төрки булмаган кабиләләрнең бердәм кавем-милләт булып берләшүенә идеологик алшарт булды һәм болгарларның бу динне кабул итүенең икенче зур әһәмияте шушында. Болгарларның элеккеге мәҗүсилек диннәре аларны берләштерү юлында ныклы терәк була алмады. Моның өчен аның идеологик нигезләре дә, оешасы да юк иде. Ислам исә идеологик яктан да, оешу ягыннан да нык үскән дин буларак болгарларда бердәм мәдәният формалашуга нигез ташлары сала һәм алар арасында барлыкка килгән милли үзаңның аерылгысыз компонентына әйләнә. Ул формалашып килүче бу халыкны идеологик яктан берләштерә, болгар җәмгыяте әгъзаларын бер-берсенә өзелмәслек җепләр белән бәйли һәм бу милләткә дәүләтләре юкка чыкканнан соң да, башка исем астында булса да, үзен саклау мөмкинлеген ача.

**Өченчедән,** исламны кабул итү болгар җәмәгатьчелеген ул вакытта дөньякүләм алдынгы урында торган гарәп-мөселман мәдәниятенә якынайта. Болгарларның бу мәдәният белән танышлыгы әле исламның Урта Иделдә рәсми дин итеп игълан ителүенә кадәр үк, болгарлар арасына ислам үтеп керүнең беренче адымнарыннан ук башлана. Гарәп чыганакларында сакланып калган бер хәбәр шул турыда сөйли. Бу хәбәрне язып калдырган автор гарәп-мөселман мәдәниятенең күренекле вәкиле әл-Җаһизны 200 биттән торган һәм болгар ханына адресланган хатында Алла Китабы турында бер сүз дә әйтмәүдә гаепли. Бу дәлил болгарларның инде IX гасырның беренче яртысында ук (әл-Җаһиз шул чорда иҗат итә) гарәп дөньясы белән дини яктан гына түгел, мәдәният мәсьәләләре буенча да күпкырлы бәйләнешләргә кергән булулары турында сөйли. Ислам дәүләтнең рәсми дине итеп игълан ителгәч, болгарлар белән Багдад хәлифәлеге арасында икътисад һәм сәүдә өлкәсендә, сәясәт һәм рухият өлкәсендә дә ныклы элемтәләр урнаша. Нәтиҗәдә Идел буена ул заманда гарәп дөньясында үсеш алган фәнни-фәлсәфи фикерләр һәм әдәби әсәрләр үтеп керә.

Ислам кабул ителгәч моңа кадәр болгарлар арасында таралган чөй (рун) язуы гарәп язуы белән алыштырыла һәм болгар язма мәдәниятенең нигез ташлары салына. Гарәп телен һәм язуын белү Идел-Чулман буйларыннан чыккан төркиләргә гарәп телендә иҗат ителгән бай әдәби мирас белән танышу мөмкинлеге ачты. Ә бу үз нәүбәтендә болгарларда фәнни-фәлсәфи фикер тууында, болгар мәдәниятенең вә мәгърифәтенең үсүендә, әдәбият ядкәрләре иҗат итүдә мөһим роль уйнады. Тарих безгә Шәех Әхмәт әл-Болгари, Әбу ибн Идрис әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бин Йосыф әл-Болгари, Әбу Мөхәммәд Садыр ибн Галәветдин әл-Болгари, Хуҗа Хәсән әл-Болгари кебек олы галим вә фәлсәфәчеләрнең исемнәрен китереп җиткерде. (Кара: **Мәрҗани Ш.** *Мөстәфад әл-әхбар...* I т. Казан, 1897, 78—83 бб.). Бу галимнәрнең хезмәтләре Болгарстанның үзендә дә, шулай ук аннан читтә дә киң таралган була.

Ягкуб ибн Ногман әл-Болгариның әле XI гасырда язылган «Тәварихы Болгария» исемле китабы турында, мәсәлән, гарәп сәяхәтчесе һәм укымышлысы Әбу Хәмид әл-Гарнәти һәм киң карашлы галим Зәкәрия Казвини бик җылы сүзләр язып калдыра. Хаҗи Әхмәт әл-Болгариның «Әл-Җамиг», «Әт-Тарика» һәм «Әл-Фаваид» дип исемләнгән китаплары бөтен Якын вә Урта Көнчыгышка тарала. Таҗетдин ибн Йуныс әл-Болгари фармакология буенча «Әт-Тирьяк әл-кәбир» исемле китап язып калдыра. Фәлсәфә, илаһият гыйлеме (богословие), тарих, медицина һәм фармакологиядән тыш, болгар галимнәре астрономия һ. б. бик күп фәннәр белән дә шөгыльләнәләр. Әл-Гарнәти калдырган мәгълүматларга караганда, болгар галимнәре күк җисемнәре турында тикшерүләр алып бару максатында төньякка бик еракларга барып җитә торган булалар. Әле монгол яуларына кадәр үк болгар әдәбиятының Кол Гали язган «Кыйссаи Йосыф» кебек гүзәл әсәрләр иҗат ителә.

Мәдәниятнең мөһим өлеше — мәгърифәт. Ислам канаты астына тартылу болгар-татар мәдәниятенең бу мөһим өлешенең нигез ташларын салуга да мөмкинлек тудырды. Исламны кабул иткәч үк болгарлар арасында уку-укыту эшендә билгеле бер система туа. Мәчетләр каршында яшәп килгән мәктәп-мәдрәсәләрдә дин сабаклары белән бергә дөньяви гыйлемнәр укытуга да әһәмият бирелә. Әл-Гарнәтиның ерак Андалусиядән улын Болгарга укытырга алып килүе үзе генә дә бу илдә уку-укыту эшләренең яхшы ук югарылыкта торганлыгы турында сөйли.

Уку-укыту эшләрендә Болгар заманында урнашкан бу традиция Алтын Урда дәверендә дә, Казан ханлыгында да дәвам итә. Ш. Мәрҗани ул вакытта Казанда зур мәдрәсә эшләгәнлеге турында яза. Бу мәдрәсә шәкертләренең ул замандагы гыйлемнәрнең тулы комплексын өйрәнергә мөмкинлекләре була. Әле болгар чорында урнашкан традиция буенча шәһәрнең һәр мәчете каршында мәктәп эшли. Уку йортлары Казан ханлыгының авылларында да күзәтелә. М. Худяков язуына караганда, ул вакытта Адай авылы мәдрәсәсе бик данлыклы була. 35 ел дәвамында аның мөдәрисе булып Ишмөхәммәт бин Тугмөхәммәт эшли. Бу мәдрәсә озак еллар яши һәм үзенә бик күп укучылар тарта (**Худяков М.** *Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар». Казан, 1923. 162 б.).*

**Дүртенчедән,** ислам мәдәнияте — асылы белән шәһәр мәдәнияте. Ислам мәдәниятенең бу үзенчәлеге Идел-Чулман Болгарстанында да үзен сиздерә. Биредә дә күп кенә шәһәрләр барлыкка килә һәм үсә. Бу шәһәрләр матди һәм рухи мәдәният учакларына әйләнәләр. Идел-Чулман Болгарстаны җирендә археологлар тарафыннан 150 дән артык шәһәр калдыклары табылган (**Р. Г. Фахрутдинов.** *Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казан, 1975. 190—191 бб.).* Бер-бер артлы Болгар дәүләтенең башкалалары булып торган Болгар һәм Биләр шәһәрләре бигрәк тә нык үсә. Соңгысы, мәсәлән, үзендә яшәгән халыкның саны һәм мәйданы буенча ул заманның иң эре шәһәрләреннән саналган Киев, Париж һәм Владимирны узып китә. Идел-Чулман Болгарстаны шәһәрләрендә мәһабәт архитектура корылмалары калкып чыга, сарайлар, мәчетләр, үзәк җылыту системасы булган ташпулатлар салына. Шәһәрләр үсеше исә рухи тормышның да үсүенә илтә.

Шәһәрләр үсеше белән шулай ук җитештерү көчләренең, кәсепчелекнең, һөнәрчелекнең, сәүдәнең үсүе дә бәйләнгән. Болгарстанда чуен коюю башлана һәм камилләшә, чүлмәкчелек һәм күн эшкәртү һөнәре үзенең үсешендә яңа адымнар ясый, тимерчелек осталыгы яңа баскычлар яулый. Болгарлар инде XIV гасырда ук, Европада беренче булып, яхшы сыйфатлы чуен коя башлыйлар.

**Бишенчедән,** Ислам кабул итүнең болгар сурәтләү сәнгате өчен нәтиҗәләре үзенчәлекле һәм каршылыклы булды. Ислам, билгеле ки, кеше вә хайваннарның сурәтләрен ясауны хупламый. Шунлыктан исламны кабул иткән болгарлар арасында кеше һәм хайван образларын сынлы сәнгать чаралары белән гәүдәләндерү туктый. Ә мондый сәнгать аларда ислам кабул иткәнче яхшы ук үскән була. Шул ук вакыт сәнгатьнең гамәли төрләре, мәсәлән, ювилерлык сәнгате, күнгә һәм тукымага чигү, бизәү сәнгате яңа үсеш ала. Кульязма китаплар таралу бизәү сәнгатенең яңа төрләре, аерым әйткәндә, китап бизәүне һәм каллиграфик язмаларны үстерә. Гарәп-мөселман дөньясы белән алыш-биреш итү архитектура үсешенә дә яңа этәргеч ясый. Сәнгатьнең яңа төре — кабер ташлары бизәү барлыкка килә һәм зур үсеш ала. Төрки халыкларда таш һәм башка төрле билгеләр кую күптән килә. Орхон-Енисей һәйкәлләре һәм кыпчак далаларында очрый торган балбаллар шуның дәлилләре. Болгарларда бу киләчәк (традиция) каберләргә матур итеп бизәлгән ташлар кую рәвешендә үстерелә. Бу ташларда болгар бабаларыбызның әхлак һәм матурлык төшенчәләренә бәйле фикерләр чагылыш таба.

**Алтынчыдан,** мәсьәләнең тагын бер кыры — исламны кабул иткән болгар җәмгыятенең әхлакый карашларында үзгәрешләр. Диннәрдә теге яки бу рәвештә гомумкешелек әхлак нормалары чагыла. Алар гаделлек, шәфкать, мәхәббәт, әхлакый камиллек, гуманизм идеалларын алга сөрә. Бу исламга да кагыла. Болгарлар арасында тарала башлау белән ислам иҗтимагый яшәеш мәсьәләсендә мәҗүсилек дәверендә урнашкан карашларга каршы эзлекле көрәш алып бара, кыргыйлыкны, шәфкатьсезлек һәм көчләү күренешләрен гаепли, яңа әхлакый карашлар таралуы өчен тырыша. Бу болгар-татарларның тормышында күпкырлы тәэсир ясый, аларны әхлакый үсештә яңа баскычларга күтәрә, тарихларына һәм тормыш-көнкүрешләренә яңа эз сала.

**Җиденчедән,** һәм, ниһаять, ислам кабул итүнең халык язмышында, аның үзен этник берәмлек буларак саклый алуында уйнаган роле. XIII гасырдан башлап Идел-Чулман буйларына кабат-кабат биниһая авыр җәбер-золым ябырыла, ил өстеннән давыл-өермәләр үтә, халык коточкыч тетрәнүләр кичерүгә дучар ителә. Мондый дәһшәтләрнең беренчесен монгол яулары китерә. Бату хан гаскәрләре Болгарстан җирендә җимерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар, тапталган кырлар калдыра, иксез-чиксез кеше каны коела. Шулай да Болгарстан халкы үзен саклап кала ала. Соңыннан да Чыңгызхан токымнары болгар җиренә кабат-кабат ябырылалар. Болгар тәмам җимерелгәннән соң да бу халык Чулманның төньягында яңа җир эшкәртү һәм һөнәрчелек үзәкләре тудырды, үзенең

традицион мәдәниятен үстерде. Бу шартларда ислам халыкны берләштереп тотуда, аның этник бөтенлеген һәм үзенчәлеген саклауда хәлиткеч көч булды.

Ислам мәдәнияте вәкилләре буларак болгарлар Хәрәзем белән бергә Алтын Урда мәдәниятенең формалашуында да, ул биләгән киң далаларда яңа һөнәр һәм сәүдә үзәкләре барлыкка килүдә дә зур роль уйнадылар. Ахыр чиктә, бу далада яшәгән мәҗүси кабиләләр нәкъ менә Болгарстан һәм Хәрәзем тәэсирендә ислам кабул итә.

Казанның явыз Иван тарафыннан яулап алынуы борынгы болгарлар токымына — инде урыс елъязмаларында татарлар дип атала башлаган халыкка яңа авыр сынаулар китерде. Урыс тарихчысы М. Худяков бу яулап алу вакытында Казан халкы өстенә бинаһая җәбер-золымнар төшүен, күбесе кырылуын, монда туган матди һәм рухи мәдәният ядкәрләренең юкка чыгарылуын күрсәтеп үтә.

**«Басып алынган Казанның халкын үтерү-кыру,** — дип язды ул, — **урыс тарихының коточкыч сәхифәләреннән берсен тәшкил итә... Православие гаскәриләренең казанлыларга каршы оештырган тәре походы тарихта тиңдәше булмаган кан коюлар һәм инсани корбаннар белән тәмамланды... Чиктән тыш күләмнәрдә өзелгән кеше гомерләреннән, елгадай аккан күз яшьләреннән, Казан халкы өстенә төшкән коточкыч җәбер-золым, газап һәм кайгылардан тыш, хәсрәт белән тулган 2 октябрь көне (1552 елда Иван IV тарафыннан Казанның алынуы көне) төрле буыннар тарафыннан озак еллар буена тупланган материал байлыкларның, аулак урыннарда кадерләп сакланган мәдәният ядкәрләренең һәм көнкүреш кирәк-яракларының рәхимсез төстә юкка чыгарылуына китерде. Алар барысы да аяусыз рәвештә ватылды, җимерелде, аяк астына салып тапталды».** (**Худяков М.** *Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар. Казан, 1923. 153—154 бб.*).

Икенче бер урыс тарихчысы, Казан университеты профессоры Н. Н. Фирсов басып алынган халыкка карата патша һәм аның яраннары сәясәтен тасвирлап, болай дип язды: **«Казан төбәгенә урыс алпавытлары һәм монастырьлар үтеп керү белән җирле халыкны системалы рәвештә дини яктан эзәрлекләргә тотындылар. Бу эзәрлекләүләрне даими төстә православие руханиларының йогынтысын тоеп яшәгән илбасар Иван IV үзе башлады. Ул татарларның мәчетләрен җимерде, әяңаларын торгызуны тыйды. Мәскәү руханилары бу төбәкне гадәттән тыш үсүзлелек белән чукындырырга керешә».** (**Фирсов Н. Н.** *Татарстанның үткәне. Казан, 1926. 26—27 бб.*).

Нигезе Явыз Иван тарафыннан салынган бу милли кысу һәм эзәрлекләүләр патша хөкүмәте тарафыннан татарларга карата гасырлар буена үткәрелгән сәясәтнең үзәгендә ятты.

Бу сәясәт Казан җирендә үзенең тулы чагылышын тапты. Асылы белән ул ачыктан-ачык шовинистик характерда булды һәм болгарларның токымы булган татарларны мөстәкыйль халык буларак юкка чыгаруга юнәлдерелгән иде. Бу максатта җирле халыкның теленә, диненә, мәдәниятенә һәм гореф-гадәтләренә каршы көчле эзәрлекләү сәясәте үткәрелде. Патша хөкүмәте һәм аның урындагы сатраплары татар халкына карата социаль, экономик, милли, сәяси һәм хокукый басым режимы урнаштырдылар. Халык барысын да татыды: камчысын да, казак нагайкасын да, төрмәсен дә, сөрген-себерләрен дә. Татарларга каршы хәрби командалар өстерелеп торылды, аларның гыйбадәтханәләре һәм изге урыннары җимерелде, традицияләре һәм милли хисләре мәсхәрәләнде.

Татарларның зиратларыннан кабер ташлары алынып чиркәү һәм монастырьларның нигезенә салынды, китапханәләр яндырылды, башка мәдәният учаклары һәм истәлекләре юкка чыгарылды. Шундый чаралар ярдәмендә патша самодержавиесе татарларның милли үзаңын юкка чыгарырга тырыша, аларның үз тарихларын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен онытуларына ирешергә теләде.

Шушы җәбер-золымнарга карамастан татар халкы үзен, милли хосусиятләрен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклап кала алды. Бу очракта да без тулы ышаныч белән, халыкның милли аңына сеңгән ислам хәлиткеч роль уйнады, дип әйтә алабыз. Халыкның милли мөстәкыйльлеген саклауда нәкъ менә ислам идеологик терәк вазифасын үтәде. Патша самодержавиесе һәм миссионерлар көчләп христианлык таккан бер чорда татарлар исламда этник, рухи һәм мәдәни бердәмлекләрен саклау чарасы күрделәр.

Татарларның милли үзенчәлекләрен саклауда мөселман мәктәпләре зур роль уйнады. Идел буе татарлары, көчле эзәрлекләүләргә карамастан, уку-укыту мәсьәләсендә әле болгар чорында урнашкан традициягә турылыклы булып калдылар, барлы-юклы сәрмаялары исәбенә мәктәпләр тоттылар. Бу үз чиратында халыкка билгеле бер күләмдә укымышлы булырга ярдәм итте. Моны миссионерлар да танырга мәҗбүр булды.

Әйтелгәннәр исламның болгар-татар тарихында, урыс патшалары һәм миссионерларның басымына карамастан, этник бердәмлекләрен саклауда уңай роль уйнавы турында сөйли. Әмма тормыш каршылыклы, иҗтимагый күренешләр дә купкырлы. Тарихи агышның билгеле бер чорында берьяклы рухи юнәлеш тоту татар тормышында үзенең тискәре якларын да күрсәтә башлый. Монда да патша хөкүмәтенең татарларга карата үткәрелгән сәясәте тәэсире бар. Бу сәясәт татарлар арасында патриархаль мөнәсәбәтләрне консервацияләүгә, халыкны замана фәненнән һәм мәдәниятеннән ераклашуга этәрә, кешеләрне милли бөтенлекне саклау өчен тормышның инде артка калган формаларына һәм традицияләргә ябышып ятарга мәҗбүр итә, массалар арасында дин әһелләренең үткәнгә ябышып ятучы консерватив катламы тәэсирен көчәйтә.

Хәлне мөселман дөньясында соңгы гасырларда тамыр җәйгән күренешләр дә катлауландыра. Кайчандыр фән һәм мәдәният үсешенең алгы сызыгында торган бу дөнья тора-бара зәгыйфьләнә. Кешеләрнең аның иярүчәнлек сөреме белән ала, үткән заманның бөекләре әйткәннәргә сукырларча ышану тамыр җәя, тәнкыйди фикер йөртү эзәрлекләнә башлый һәм хәзерге заман кешеләренең мөстәкыйль фикер йөртү мөмкинлекләре кире кагыла. Менә фәнни-фәлсәфи эзләнүләрне гаепләү өстәлә, догматизм, схоластика, фанатиклык тамыр җәя. Бу күренешләр татарлар арасына да үтеп керә.

Акрынлап мөселманнарның үз араларыннан бу торгынлык һәм туңлык чиреннән арынуга, иҗтимагый яңарышка әйдәүче көчләр үсеп чыга. Бу көчләрнең алдынгы сафына татар халкының уллары килеп баса. Габделнасыйр Курсави (1776—1812) шуларның беренчеләреннән иде. Ул ныклы дәлилләр белән иярүчәнлеккә каршы чыкты, һәркемнең аек фикер йөртергә, иҗади эзләнүләргә хокукы барлыгын яклады. Г. Курсави эшен күренекле мәгърифәтчебез тарихчы галим һәм фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889) дәвам иттерде, иярү һәм табынуны көчле тәнкыйть уты астына алды, кеше гакылына ирек даулады. Ш. Мәрҗанинең тәнкыйди ысулы халыкның тормыш юлында үткәннән калган киртәләргә каршы, аны фән, мәдәният, сәнгать казанышларына якынайтуга юнәлдерелгән иде. Шул ук вакыт Курсави дә, Мәрҗани дә бу чыгышлары белән һич тә исламнан аерылмадылар, халык алдында торган мәсьәләләрне дини нигездә торып анализладылар, үзләренең дәлилләрендә изге китапларга таяндылар.

Курсави белән Мәрҗани эшчәнлеге татар халкы тарихында тирән эз калдырды, үз халкы турында борчылучыларга, аның барыр юлларын ачыкларга тырышучыларга маяк вазифасын үтәде.

Үткәннән калган рухи мирасны яңадан бәяләүдә яңа адым җәдитчеләр тарафыннан ясалды. Бу хәрәкәт безнең төбәктә узган гасырның соңгы чирегендә тамыр җәйде һәм аның асылы Исмәгыйль Гаспралы, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Әхмәтһади Максуди, Шәмсетдин Күлтәси, Габдерәшит Ибраһимов, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Хәсәнгата Габәши, Һади Атласи һ. б. эшчәнлегендә һәм иҗатында ачык чагылышын тапты. Җәдитчеләр арасыннан татар революцион демократиясенең Галиәсгар Камал һәм Гаяз Исхакый кебек вәкилләре, татар демократик мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре чыкты.

Җәдитчелек асылда бик катлаулы иҗтимагый хәрәкәт булды. Ул үзенә төрле төсмерләрне туплаган иде. Җәдитчелекнең эчтәлеге, аның вәкилләренең эшчәнлеге, алар үз алдына куйган бурычлар бу хәрәкәт үсешенең барлык баскычларында да бертөрле булып калмады. Илдәге хәл үзгәрү белән бергә җәдитчеләр эшчәнлегенең эчтәлеге дә үзгәрә барды. Беренче адымнарында алар бары мөселман мәктәбенә һәм анда уку-укыту эшләренә үзгәрешләр кертү идеясе белән чыктылар. Җәдитчелек үзенең исемен дә мәктәптә яңа ысул (ысулы җәдит) белән укытудан алды. Тора-бара җәдитчеләр иҗтимагый тормышның башка якларын үзгәртергә кирәклеген дә аңлый башлый. Җәдитчелек үсешенең соңгы баскычы инде чорның бөтен социаль һәм идеологик проблемаларын, шул исәптән дини һәм илаһи тәгълимат мәсьәләләрен дә колачлый иде.

Җәдитчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарлар арасында дини әдәбият белән беррәттән фәнни әдәбиятның да дәрәҗәсе артты, татар телендә арифметика, география, физика, биология, гигиена, тарих һ. б. фәннәр буенча китаплар тарала башлады. Җәдитчелек хәрәкәтенә яңа, реалистик әдәбиятның беренче адымнары да, сәнгати фикердә тәнкыйди агым формалашу да, хатын-кызлар арасында хөррият хәрәкәте дә нык бәйләнгән.

Шулай да җәдитчеләр алдында торган проблемаларның иң мөһиме — мәктәп мәсьәләсе, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе. Җәдитчеләр бу очракта милләтнең язмышы, аның киләчәге яшьләр кулында икәнлеген аңлап, яшь буынны

ничек итеп тәрбияләүгә бәйләнгәнлеген белеп эш иттеләр. «Тәрәккыят заманыбызның иң зиядә дикъкать ителәчәк вә иң бөек гыйбрәт алыначак җәһәте дә — ысул тәгълим вә тәдрис җәһәтедер,— дип язды Ш. Күлтәси.— Шул ысул тәгълим вә тәдрисләрне җиңеләйтү аркасында хәзерге заманның алга киткән мәмләкәтләре меңнәрчә галим-голяма вә әдипләр, хакимнәр вә табибләр, йөзләрчә инженер вә астрономнар, географлар вә тарихчылар, химия билгечләре һәм диңгезчеләр, сәясәтчеләр һәм яхшы хәзерлекле хәрбиләр, игенчелек һәм сәнәгать белгечләре җитештерделәр» (**Күлтәси Ш.** *Һәйяте җәдидә. Казан, 1896. 5 б.)*.

Мәктәп мәсьәләсендә җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында бик кискен көрәш җәелде. Бу көрәш үз тирәсенә киң җәмәгатьчелек игътибарын да җәлеп итте. Кадимчеләр уку-укыту мәсьәләсендә иске тәртипләрне саклау тарафдарлары буларак чыктылар, ә бу эштә яңалык кертүне ислам кануннарыннан тайпылу дип санадылар. Җәдитчеләр исә мәктәп эшендә реформа үткәрүне алга сөрделәр. Алар мәктәпләр эшенең мөселманлык таләпләренә нигезләнгән булырга тиешлегеннән һич кенә дә баш тартмадылар. Әмма мөселманлыкны саклау белән бергә алар мәктәпне заман гыйлемен, фән казанышларын тарату учагына әйләндерү кирәклеген дә алга сөрделәр. Җәдит мәктәпләрендә дин сабаклары белән бергә татар һәм урыс телләре дә, математика да, тарих та, география дә, башка дөньяви фәннәр дә укытылды. Шулай итеп җәдитчеләр мөселманлыкка тугрылыкны саклаган хәлдә татарлар алдында хәзерге заман фәнен һәм мәдәниятен үзләштерү юлы да ачтылар.

Җәдиди мәктәпләрдә дөньяви фәннәр белән бергә дин дәресләре дә керүе революциягә кадәр татарлар арасында уку-укыту мәсьәләләре яктыртылган хезмәтләрдә, җәдитчелек бу өлкәдә бернәрсә дә бирмәде, җәдит мәктәпләре кадими мәктәпләрдән берни белән дә аерылмадылар, дигән уйдырма таратылуга бер сылтау булды. Әмма мондый хезмәтләрнең авторлары җәдит мәктәпләреннән татарның Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Һ. Такташ кебек зур әдипләре, культура эшлеклеләре чыгуын, бу мәктәпләрнең гади халык балаларына җиңел ысул белән укырга-язарга өйрәнү, табигать һәм иҗтимагый фәннәр нигезләре белән танышуга мөмкинлек ачуын читләтеп үттеләр. Аннары шул җәдиди типтагы мәдрәсәләрнең берсеннән зур язучыбыз һәм күпкырлы галимебез Г. Ибраһимов та чыккан иде бит. Галим һәм язучы Нәкый Исәнбәт тә, күренекле шагыйрь Хәсән Туфан да шул ук мәдрәсә шәкертләре.

Болгар-татарлар тарихында исламның тоткан роленә бирелгән бу кыскача бәядә аны халкыбыз тарихыннан җиңел кул белән генә аерып алу һични белән дә аклана алмый торган бер нәрсә дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Ул, күренүенчә, безнең милләт булып формалашуыбызда һәм үсешебездә хәлиткеч роль уйнады, мәдәниятебезнең нигезендә ятты. Халкыбыз өстенә төшкән һәм озакка сузылган җәбер-золым елларында, кан коюлар, мыскыллаулар белән бәйләнгән христианлаштыру шартларында аңа үзен-үзе саклауда рухи таяныч булды. Һәм бүген дә, әгәр киләчәккә үзебезне милләт буларак сакларга теләсәк, без аны күңелләребездә йөртергә, өйрәнергә, аның әхлакый идеалларын үзебезгә маяк итеп алырга тиешбез. Милләт буларак безнең киләчәгебез шуңа бәйләнгән.

**Аллен Франк,**

АКШның Индиана университеты галиме

# ҮТКӘНДӘ САЛЫНГАН КҮПЕР

*XVIII—XIX йөзләрдә татар муллалары казакъ-кыргызлар арасында*

Тарихта ак таплар була алмый. Бу җәһәттән Казан басып алынган 1552 елдан 1917 елга кадәрге дәвердә татар мөселман җәмгыятьләренең, Мөселман диния нәзарәтенең, вакыф биләмәләренең, суфилык хәрәкәтенең һәм башка шундый бик күп нәрсәләрнең тарихын эзлекле рәвештә җентекләп өйрәнәсе бар әле. Шуңа күрә дә мин бу хезмәтемдә дүрт гасырлык чорны яктыртуны максат итеп куймадым, ә фәкать XVIII—XIX йөзләрдә Казагыстан белән Кыргызстан далаларында гомер кичергән күчмә халыклар арасында ислам динен ныгытуда татар муллалары башкарган игелекле эшкә тукталмакчы булам. Сүз дә юк, татар милләтеннән булган дин әһелләре бу төбәкләрнең мәдәни, дипломатик һәм сәяси тарихында җуелмаслык тирән эз калдырган.

Мәгълүм ки, Урта Идел буе татарларының казакъ далалары һәм Урта Азия халыклары белән бәйләнешы, ерак дәверләрнең дәвамы булып, XVIII йөздә яңа бер баскычка күтәрелә. Хәтта, Урта Идел өчен иң канлы елларда, урыс илбасарлары золымлык кылган заманда да, татар мөселман зыялылары Хәрәземдәге һәм Мавәраэннәһердәге мөселман үзәкләре белән элемтәне өзми. Аннан да ераккарак күз төшерсәк, татар-болгар дәүләтенең Урта Азия һәм, бигрәк тә, Хәрәзем белән сәүдә мөнәсәбәтләре X йөзләргә үк барып тоташа.

1552 һәм 1556 елларда Казан белән Хаҗитархан (Әстерхан) ханлыклары басып алынганнан соң, татарның аерым укымышлы-зыялылары Русиягә хезмәт итүгә күчә. XVI—XVII йөзләрдә татар гаскәриләре һәм тылмачлары башкорт җирләрен Русиягә кушуда һәм Себерне буйсындыруда шактый күпләп катнаша. Ә Русия империясенең Урта Азия халыклары белән элемтәсе тагын да көчәйгән XVIII—XIX гасырларда татарларның бу төбәктәге йогынтысы да үсә төшә. Шул ук вакытта урыс хакимияте вәкилләре Урта Азия мәдәни, икътисадый һәм сәяси мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен татарлардан файдалана һәм, хәтта, күпмедер дәрәҗәдә аларга бәйле була. Әмма шунысын да онытырга ярамый, әлеге татарлар — башлыча сәүдәгәрләр, дин әһелләре һәм аксөякләр, Урта Азиядә яшәүчеләрнең күбесе кебек, бер үк телдә диярлек сөйләшсәләр дә һәм бер үк динне тотсалар да, аларның сәяси мәнфәгатьләре һәм ихтыяҗлары җирле халыкныкы белән һич кенә дә тәңгәл килми. Димәк ки, XIX йөз урталарына кадәр диярлек урыс хакимияте белән татар зыялылары үзара һәр ике якка да файдалы эш йөртә.

Екатерина II нең мөселман динен яклауга һәм киңәйтүгә йөз тоткан сәясәтен тормышка ашыра башлаганчы ук казакъ далаларында татарларның дини йогынтысы һәм катнашы шактый сизелә. 1774 елда алман сәяхәтчесе Георги казакъ далаларында йөреп кайта. Ул җирле халыкның ислам динен өйрәнергә теләге сизелсә дә, аны гамәлгә ашыру өчен мөмкинлекләрнең җитешмәве, мәктәп-мәдрәсәләрнең бөтенләй диярлек булмавы турында яза. Алай гына да түгел, казакълар арасында мулла вазифасын үтәүче бик аз санлы кешеләр дә асылда Идел буе татарлары була. Алар «Муллакәлек» белән бергә мөгаллимлек итәләр, язу-сызу эшләре алып баралар яисә казакъ байларында вәзир-киңәшче хезмәтен үтиләр. Мәсәлән, Кече җөздә Нургали исемле ханның язу-сызу эшләрен, урыс телен дә әйбәт белүче татар кешесе алып баруын Георги әйтеп уза (**Асфендияров С. Д.** *Прошлое Казахстана в источниках и материалах. Алма-Ата. 1935. 196—197 б.*).

Казакъ бай-түрәләренә хезмәткә ялланган күп кенә шундый муллаларның исемнәре XVIII йөздәге дипломатия эшләре беркетмәләрендә теркәлеп калган. Аларның казакъ даирәсендә абруйлары, йогынтылары зур булуы бәхәссез. Бу чорларда казакъ хан-түрәләренең күпчелеге, урыс телен әйтеп тә тормастан, төрки телләрдә дә укый-яза белми. Шуңа күрә дә урыс дипломатиясе кәгазьләрен укуда һәм тәрҗемә итүдә, аларга җавап җибәрүдә татар муллалары гайрәт күрсәтә.

Мәсәлән, 1741 елда Нургалинең атасы Әбелхәер хан Оренбургтагы чик буе комиссиясе белән Әлмөхәммәт исемле татар мулласы ярдәмендә хат алыша *(Казахско-русские отношения в XVI—XVIII веках. Алма-Ата. 1961. 189 б.)*.1748 елда Йомагыл мулла Гуляев исемле урыс илчесенә һәм тылмачына Әбелхәер ханның үтерелүе турында хәбәр итә *(шунда ук, 425 б.)*. Урта жөз ханы Аблай,— монысы чын-чынлап бәйсез казакъ ханы була,— Монасыйп Мамбетов исемле мишәр кешесен үзенә кәгазь эшләрен алып баручы итеп билгели *(шунда ук, 622 б.)*. М. Мамбетов 1768 елда ук Оренбургка барып, Аблайның Кытай белән мөнәсәбәте хакында суд хезмәткәрләренә мәгълүматлар бирә *(***Сулейменов Р. Б., Моисеев В. А.** *Из истории Казахстана XVIII века. Алма-Ата. 1988. 101 б.)*. Аблай шулай ук Яһүд Усманов атлы мишәр мулласын үзендә шундый вазифа башкаручы кеше итеп тота. 1776 һәм 1779 елларда бу мулла урыс хәкимнәренә Аблайның кыргызларга һөҗүм итәргә ниятләвен житкерә *(шунда ук, 123, 131 б.)*. 1759 елда Аблай хан татар мулласы Азаматны урыс хакимнәре белән эш йөртүче йомышчысы итеп файдалана *(Казахские-русские отношения... 602 б.)*. 1762 елда Нургали ханга анын Русиягә тугрылыгы турындагы антын татар эш башкаручысы Габбас укый *(шунда ук, 639 б.)*.

XVIII йөздә татар мөселман дине оешмаларына патша хөкүмәтенең мөнәсәбәте уңай якка үзгәрә. 1740 елдан башлап әлеге дини оешмаларның йогынтысын көчәйтү максаты белән бик күп чаралар халыкка игълан ителә. Бу чараларның эшлекле нәтиҗәсе буларак, 1788 елда Оренбургта Мөселман диния нәзарәтенә нигез салына.

1745 елда Оренбургтан ерак түгел Каргалы авылында татар сәүдәгәрләре колониясе оеша, соңыннан ул Сәгыйть бистәсе буларак таныла. Бу бистәдә яшәүчеләргә рәсми рәвештә дин тоту иреге тәэмин ителә, мәчет салырга рөхсәт бирелә *(***Климович Л.** *Ислам в царской России. М., 1936. 19 б.)*. 1773 елда Екатерина II Русия ватандарларының теләсә нинди дин тоту ирегеn тану турында фәрман игълан итә, шуннан соң ун ел узуга Оренбургта мөфтият, ягъни татар рәсми дини идарәсе төзелә.

Бу чорда патша хөкүмәтенең казакъларга карата үткәргән дини сәясәте ачык. Мәсәлән, 1785 елда әби патша Уфа губернаторына указ тапшыра. Бу фәрман белән ул аңа казакълар арасында исламны тарату һәм аларны укыту максаты белән бу якларга Казан татарларын муллалар итеп җибәрү вазифасын йөкли. Бер елдан соң Екатерина патша Уфа һәм Себер губернаторы Барон Игельстронга казакъ далаларында мөселман мәктәпләре һәм мәчетләре салдыртырга, казакъча дәреслекләр чыгартырга, казакъ авылларына татар муллаларын җибәрергә әмер бирә. Әби патша шулай ук казакълар өчен дәүләт исәбенә Коръән чыгарырга куша *(***Климович Л.** *Ислам... 20—21 бб.)* һәм 1797 елда бу китап 3600 данә басылып та чыга. 1785 елга Оренбург, Троицк һәм Верхнеуральск шәһәрләрендә әби патша тарафыннан салдыртылган мәчетләр эшли башлый, алар шулай ук башка урыннарда да төзелә.

1782 елда оештырылган мөфтияткә Оренбург Мөселман диния нәзарәте статусы бирелә һәм ул алты елдан Уфага күчерелә. Ул Русиянең Европа өлешендә һәм Себердә яшәүче мөселманнарны, Русиягә буйсынган Кече һәм Урта жөз казакъларын үз канаты астына ала. Казакълар арасына җибәрү өчен муллалар әзерләү, аларга тиешле таныклык бирү, дини китаплар белән тәэмин итү — болар һәммәсе диния нәзарәтенең вазифасына керә. Алай гына да түгел, бу муллаларга казакъ дини оешмасының үзәген булдыру максаты куела. Күчмә ыругларда мөгаллимлек кылган һәм руханилык хезмәтен башкарган әлеге татар укымышлыларын гадәттә указлы «урыс муллалары» дип атап йөртәләр. Казакъ мохитында искиткеч югары абруйлы, ханнарның иң ышанычлы эшләрен башкаручы мондый муллалар, әлбәттә, күп булмаган. Бу хакта Эчке Урда әгъзасы, урыс гыйлеменә ия хаҗи Мөхәммәтсалих Бабаҗанов та язып калдырган. Ул мондый муллаларның 1801 елга чаклы бик аз булуы турында әйтә. Үлгән кешегә ясин чыгару өчен аларны хәтта 150 чакрымнардан алып кайта торган булганнар. Муллаларның житешмәве XIX йөз башында Русиянең бер өлешенә әйләнгән Эчке Урда өчен чын-чынлап бәлага әверелә. Аның ханы Җиһангир бу хакта озак баш вата. Үз кешеләрен укыту өчен Әстерхан, Уфа, Казан һәм Оренбургтан татар муллаларын китертеп яллый *(***Бабаҗанов Х. Х.— С.** *Заметка киргиза о киргизах. Северная пчела. 1861. № 4. 13 б.)*. Муллалар авылларда мәктәп-мәдрәсәләргә житәкчелек итә, туган, өйләнгән һәм үлгән кешеләрне теркәп баралар. Шулай ук Урданың үзәгендәге Хан сарае мәктәбе мөгаллимнәрен дә нигездә муллалар тәшкил итә. Бу мәктәптә алтмыш шәкерт, дин сабагы өйрәнү белән

биргә, урыс теленнән дә дәрес ала. Әлеге муллалар салым түләүдән һәм тән җәзасыннан азат ителә *(шунда ук)*.

Эчке Урдада дәүләт хезмәтен асылда татарлар алып бара. Мәсәлән, С. З. Зиманов «XVIII йөзнен ахырында һәм XIX йөзнең беренче яртысында Казагыстанның сәяси төзелеше» исемле китабында татар муллаларын дини «катлам» буларак тасвирлый. Чыннан да, Җиһангир хан Оренбург мөфтие кызына өйләнә. Мәдрәсә һәм мәктәпләр төзү эшенә нигез сала, күп кенә милләттәшләрен Казан һәм Оренбург мәдрәсәләренә укырга җибәрә. Урда муллаларның эшенә күзәтчелек итүне үз өстенә ала. Әйтик, хан сарае мәчете ахуны башка барлык мәчет һәм мәдрәсәләр, алардагы муллалар эшен тикшереп, барлап тора. Турыдан-туры хан житәкчелегендә комиссия төзелеп, ул муллалардан имтихан ала һәм аларга таныклык бирә. Шул рәвешчә, XIX йөз урталарына кадәр һәр казакъ ыруы мөстәкыйль мулласын булдыруга ирешә. Аларның һәркайсына хан таныклыгы тапшырылган, дип яза С. З. Зиманов. Кыскасы, Җиһангир хан хакимлек иткән чорда һәр 25 тирмәгә бер мәктәп һәм бер мәдрәсә туры килә *(***Бабажанов Х. Х.— С.** *Заметка... 14 б.)*. Эчке Урда эшләрендә татарлар катнашуының төп нәтиҗәләреннән берсе шунда ки: Җиһангир хан гадәти казакъ хөкемен шәригать хөкеме белән алмаштыруны кулай күрә. Шулай итеп, аерым бер ыру кешеләренә генә чикләнмәгән хокуктан файдалану мөмкинлегенә юл ябыла, аларның башкаларга йогынтысы кими төшә. Әлбәттә, бу хәл эзсез генә узмый. Чыннан да, бик күп байларда ул ачу тудыра һәм алар үз балаларын урыс мәктәбенә җибәрәләр.

Кырым сугышыннан соң патша хөкүмәтенең татар дини оешмаларына мөнәсәбәте кискен үзгәрә. Дошманлык хисләре ачыктан-ачык белдерелә, яңа мәчетләр салу тыела. Эчке Урдада, казакъларның үтенече буенча, татар мәдрәсәләрендә урыс теле дә укытыла башлый *(***Тажибаев Т. Т.** *Школы Внутренней (Букеевской) Орды во второй половине XIX века. Труды ИИАЕ АН КазССР. 1961. 127—128 бб.)*. 1892 елда, мәсәлән, Эчке Урдада эшләгән укытучыларның барысы да диярлек татар муллалары була. Алар уку йортларында да күпчелек тәшкил итә һәм хәтта хөкүмәт оештырган урыс-казакъ мәктәпләрендә дә белем бирәләр. Шуны да әйтергә кирәк, барлык уку-укыту эшләре урысча яки казакъча түгел, бәлкем татарча алып барыла (шунда ук, 129—131 бб.).

Кече жөзгә килгәндә исә, Чукан Вәлиханов, һәр авылда диярлек татар мулласы яки шәкерте укыта, дип яза. Әлбәттә, алар арасында Урта Азиядән чыккан муллалар да була *(***Вәлиханов Ч. Ч.** *Әсәрләр җыентыгы. Алма-Ата. 1961—1964. I том. 520 б.)*. Билгеле, ул мулла һәм шәкертләрнең барысы да тиешле таләпләргә җавап биреп бетерми. Моны исә Оренбург мөфтиятендә ришвәтчелекнең киң таралуы белән аңлатырга кирәк, ди ул.

XIX йөздә казакъ даласының сәяси тормышында да татар муллалары актив катнаша. Тулаем алганда, гадәти казакъ хөкеме кулланылмаган урыннарда муллалар, хөкүмәт күрсәтмәләрен үзләренчә аңлаталар. 1850 елларда Оренбургта Русия хакимияте вәкилләре Бохара һәм Хива муллалары килеп йөргәне өчен, казакъ авылларына, хәтта өчәр сум штраф салалар. *(***Терентьев М. А.** *Россия и Англия в Средней Азии. СПб. 1875. 349 б.)*.

Татар муллалары дипломатия эшләрендә дә файдаланыла. Екатерина II идарә иткән чорга чаклы ук ике татар мулласы Олы жөз ханы Сөек Аблаевка Россиягә буйсыну турында киңәш биргәннәре өчен император тарафыннан алтын медаль белән бүләкләнә *(***Джамгерчинов Б.** *Очерки политической истории Киргизии XIX века. Фрунзе, 1966. 29 б.)*.

Бу чорларда кыргыз мохитын да татар муллаларыннан башка күзаллавы кыен. Мәсәлән, мулла Галим Яһүдин 1847 елда манап Жантай Карабековка киңәшче һәм эш кәгазьләрен алып баручы булып урнаша *(шунда ук, 117—118 б.)*. Икенче бер татар мулласы Галим Якубовның Русия хакимияте белән кайбер кыргыз даирәләре арасында арадашчы булуы мәгълүм *(***Лунин Б. В.** *Взаимосвязи киргизского народа с народами России, Средней Азии и Казахстана. Фрунзе, 1985. 78 б.)*.

Шул заманның барлык язма чыганаклары да диярлек Казагыстан белән Кыргызстанда эш йөрткән татар муллаларына дошманлык хисе белән сугарылган. Бу авторлар арасында дошманлык хисен ачыктан-ачык игълан итүче, мәгаен, Чукан Вәлихановтыр. Ул турыдан-туры, татар муллалары һәм шәкертләре казакълар арасында «фанатизм» учагы кабыздылар, дип яза *(***Вәлиханов Ч. Ч.** *Әсәрләр... 519 б.)*. Ул указлы муллаларны Русия дәүләтенә тугры булмауда гаепли һәм казакъларны Уфа мөфтиятенә буйсынудан азат итәргә, бу якларда татар дин әһелләре санын бик нык чикләргә чакыра *(шунда ук, 526—528 б.)*.

Ч. Вәлиханов белән чагыштырганда, Бабаҗанов ислам диненә шул тиклем үк дошман түгел, әмма ул да Эчке Урдада эш йөрткән татар муллаларын тәнкыйть утында шактый биетә. Бабаҗанов аларны, казакъларга белем бирүдә киртә булып торалар, ислам дине белән бергә халыкка ырым-хорафатларын да сеңдерәләр, дип гаепли *(***Бабаҗанов Х. М.-С.** *Заметка... 13 б.)*.

XIX йөз ахырында казакъларга татар тәрбиясе шундый нык йогынты ясый ки, бу казакъ укымышлылары арасында татарга каршы ризасызлык хисләре уята. Алар казакъларның татарлашуыннан курка. Чыннан да, татар мәдрәсәләрендә генә түгел, урыс-казакъ мәктәпләрендә дә казакъ теле өйрәтелми. Казакъ балалары өчен Оренбург чик буе комиссиясе тарафыннан 1850 елда оештырылган мәктәп казакъ арасына татар мәдәниятенең ничек үтеп керүенә ачык мисал була ала. Бу мәктәпнең беренче инспекторы да, укытучылары һәм, хәтта, аш пешерүчеләре дә татар кешеләре була. Дин сабагын татар ахуны укыта, белем бирү фәкать татар телендә генә алып барыла. Әле алай гынамы, дип хәбәр итә Н. Х. Ильминский, казакълар арасында татар йогынтысын киметү турындагы рәсми күрсәтмәләр дә шушы ук телдә язылган *(***Ильминский Н. Х.** *Воспоминания об И. А. Алтынсарине. Казань, 1891. 160 б.)*. Ахыр чиктә Ильминский һәм урыс миссионерлары ярдәмендә казакъ педагогы Ибраһим Алтынсарин беренче милли мәктәбенә нигез сала. Ләкин шунысы кызык, хәтта, бу мәктәптә дә бик күп татар укытучылары (башлыча, керәшеннәр) белем бирә.

Ибраһим Алтынсарин казакъ телен чит тел сүзләреннән (аларны «татаризмнар» дип атый), аеруча татар һәм Бохара муллалары тарафыннан кулланышка кертелгән гарәп һәм фарсы сүзләреннән чистарту өчен тырыша. Ул ислам дине байрагы астында гыйлем алучы казакъларның үз телләреннән акрынлап татар һәм гарәп телләре файдасына ваз кичүе нәрсәгә китерәсен яхшы аңлый, казакъ аксөякләренең «татарлашуы» котылгысыз һәм мондый шартларда казакъ ханнары яклаган татар муллаларының йогынтысы арткannan-арта барачак, дигән нәтиҗә ясый. Бу галим татар һәм Бохара муллалары кулланган китапларның татар телендә язылган булуын да өнәми һәм бу дәреслекләрне далага кертмәс өчен көч түгә. *(***Алтынсарин И.** *Сайланма әсәрләр. Алма-Ата. 1957. 316, 325—327, 370—373 б.)*.

**Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: татар укымышлыларының, бигрәк тә дин әһелләренең узган гасырларда казакъ-кыргыз даласында алып барган игелекле, бәрәкәтле хезмәте бәхәссез. Мәгърифәт таратуда бер халыкның икенче халыкка ярдәм кулы сузуы, ике арада күпер салуы да дип аңларга кирәк моны.**

*Урысчадан* **Госман САДӘ** *тәрҗемәсе.*



# ИСЕМНӘРЕ ДАНИЯ

Ул — Камал театры артисткасы. Таланты — кояшлы яңгыр төсле. Үзе житез, моңлы, ягымлы, образга керә, яши, ышандыра.

Дания Нуруллина катнашкан күптөрле спектакльләрне карагач, мин шундый фикергә килдем һәм үземнең утыз ел буена алып бара торган көндәлекләремә шулай кыскача гына язып та куйдым.

Дания унөч яшьтән әнисез калган, абыйсы белән жиңгәсе кулында үскән. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, ул Казан театр училищесына укырга керергә килә. Һәм... хәзерге заман теле белән әйткәндә, «дөбердәп жимерелеп төшә». Ул хакта соңрак сөйләрбез. Хәзер без аның бер спектакльдәге уенына күз салыйк. Камал театры сәхнәсендә Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясе бара. Дания төп рольдә — Шәфәкъ образын ижат итә. Бирелә шамакайланып та, тавышын белән уйнап та, борғаланып-сыргаланып йөреп, кеше көлдереп тә булмый. Шәфәкъне спектакль азагында авылдашлары караңгы далага, ач бүреләр янына озаталар. Әмма аңарчы әле аның мәхәббәте, жаннарны айкап ала торган мәхәббәте бар. Адәм баласының тирән кичерешләрен, күңел тибрәнешләрен ничек үз жаны аша уздыра Дания? Героиня булып беренче мәртәбә уйнаучы, театр училищесы студенты Дания Нуруллина ничек итеп тамашачыны тетрәтерлек образ тудыра алды соң әле? Театр сәнгате ветераны Ширияздан ага Сарымсаковны тыңлап карыйк:

«Артист геройны аңлый һәм тоя белергә тиеш. Дания исә үз героенының фажигасен аңлый белде, эчке дөньясын жаны-тәне белән тоя алды. Нәтижәдә Шәфәкъ образын бербөтен итеп уйнап, үзенең яхшы зәвыклы булуын ачты... Алыйк, мәсәлән, Шәфәкъ-Даниянең сәхнәгә аш алып чыгу күренешен. Хәрәкәтләре шундый жиңел, гәүдәсе шундый сыгылмалы, уйнак. Гүя, үзе уйнаган образның кичерешләрен, рухи халәтен кичереп аңлата ул. Гүя, мәхәббәткә хаклы булуын тою хисе шулай очындыра, жилкендерә аны...»

Бу характеристиканы «Ай тотылган төндә» спектаклен сәхнәгә куйган режиссер бирә Дания Нуруллинага. Менә шушы гади-гадәти сүзләрдә без Даниянең, артистка буларак, талантына хас беренче билгеләмә белән очрашабыз: яхшы зәвык.

Зәвык төшенчәсе артист өчен аның беренче адымнарыннан ук билгеле булырга тиеш. Зәвыксыз артистлар йә тамашачыны уңайсыз хәлгә куярлык итеп арттыралар-шамакайланалар, йә инде кайнар хисләрне табигый кайнарлыкларына тикле алып менеп житкерә алмыйча, куәте чыгып беткән шампан шәрабы төсле «пышшш» итеп кенә сүнәләр.

Театр училищесы студенткасы Дания сеңлебез, димәк, беренче зур ролендә үк үзенең яхшы зәвыклы артистка, ак белән караны, яхшы белән яманны аера белә торган сәнгать кешесе икәнен раслап, тамашачы алдында беренче зур имтиханны узды. Урыслар андый чакта: «Молодчина!» — диләр, ә без, татарлар: «Егет икәнсең!» — дибез.

Егет икәнсең, Дания! Беренче ролеңне егетләрски башкардың, гәрчә, училищега кергән чагында «егетләрски» жимерелеп төшкән булсаң да!

Инде без хәзер теге чактагы «жимерелүнең» сәбәпләрен дә әйтеп бирик. Дания үскән йортта 8 бала була. Дания — төпчекләре. 56 яшендә, 1959 ел-

ны әнисе вафат була. Менә шул елларын, 13 яшьлек үсмер чорын ятимлек дип саный Дания. Тик әле ятимлеккә кадәрле алар өендәге гөрләп торган заманны да онытмыйк. Әти-әнисе җыр-бию яратучылар була Даниянең. Әнисе ай саен диярлек туганнарын чакыра, чакырып кына калмый, өйне җыр-бию белән тутыра. Ул елларның матурлыгын, илһамлы-нурлы сәгатьләрен гомерендә дә онытасы юк Даниянең.

Искож ягында, 114 нче мәктәптә укый Дания, абыйсы белән җиңгәсендә торып укый. Шул чорда ул Казанның ничәмә-ничә культура сараена биергә йөри. Искождан башлап Ленин исемендәге культура сараена тикле барып җиткән чаклары була. Әллә ничә төрле транспорт белән барырга кирәк бит аңа. Җанында ашкыну бар икән, җанында бию дәрте бер дә сүнми яши икән, барасың инде, җаным...

Сигезенчене тәмамлап, театр училищесына килгәндә, сине биетеп карамыйлар — син балет театрына яки Җыр-бию ансамбленә килмисең. Син барыннан да элек авыз тутырып, җайлы итеп шигырь сөйли белергә тиеш. Сүз дигән хикмәтле нәрсә синең авызда «ботка пешерү» төсендә түгел, ачык һәм һәркемгә дә аңлаешлы булып чыгарга тиеш.

Имтиханнарны кабул итүче Празат Исәнбәт, аңа йомшак кына итеп:

— Үсә төш, сеңлем,— ди.

Бер ел буена «үсә» Дания, нәрсәдә көчсез икәнен аңлап үсә, һәм, ниһаять, теләгенә ирешә: театр училищесына студент булып керә.

Дания Нуруллина үзе уйнаган иженче спектаклендә яңадан-яңа сыйфатлары белән ачыла. Аларны без **табигый ихласлык, романтика** дип билгели алыр идек. Театр училищесын тәмамлаган елны (бу 1966 ел буладыр), Дания Нуруллина Нәкый ага Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» трагедиясендә Айсылу образын иҗат итә. Шәфәкъ белән бер чамадарак образ дип исәпләргә була моны. Әмма биредә фаҗига инде гашыйк кызның акылдан шашуы белән психологик тирәнәя. Чын, ихлас, табигый хисләрдән тулышкан, дөньяның яме, гүзәллеге булган Айсылуны, битенә корым ягып, урам йөртәләр, хурлыйлар аны, кимсетәләр, битенә төкерәләр, кыскасы — саф күңелле кызның җанында тукыналар. Мәхәббәтнең ак сөлгедәй сафлыгы кара дегеткә батырыла. Айсылу кайгы-сагышны, халык алдында, урамда кимсетелүләрне күтәрә алмыйча акылдан яза. Сафлык алиһәсеннән, романтик югарылыктан исәр кызга әйләнү бик авыр психологик күчеш таләп итә. Күгәрченнәр төсле гөрләп, назлы күкрәк тавышы белән сөйләшә торган Дания-Айсылу көлә башлый. Шашып-шашып көлә Айсылу-Дания. Шул чамасыз, шашкын көлүе белән тамашачының җанын телеп-телеп ала. Тамашачы авыр итеп көрсенә, күз яшьләрен тыя алмыйча, тавышсыз елый, чөнки сабыйларча саф күңелле, садә җанлы, табигый-ихлас кызыкайның юләрләнүе безне җетрәтә...

Дания ханым Нуруллинага 1980 елны бүләк иткән «Кырлай егете» китабына Нәкый ага Исәнбәт шундый сүзләр язган:

«Кадерле Даниягә, «Миркәй-Айсылу»дан башлап, күпме әсәрләремдә гүзәл образлар иҗат иткән сөекле Даниягә тагын да уңышлы, шатлыклы көннәр, бәхетле гомерләр теләп: автор Нәкый Исәнбәт. 26 декабрь — 80, Казан». *(Соңгы сүз гарәп шрифтында язылган).*

Чама хисе...

Ихтимал, Дания, актриса буларак, **чама хисен югалтмавы** белән ота торгандыр. Ул сәхнәдә иҗат иткән дистәләрчә образ ышандыра, үзе артыннан ияртеп, сине дә шул героиня дөньясына алып кереп китә, шул мохиттә яшәргә мәҗбүр итә.

Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедиясендә Чәчәк, Б. Горбатовның «Бер төн»ендә Варя, В. Шукшинның «Эшлекле кешеләр»ендә Соня, Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми»ендә Фәүзия, Т. Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр»ендә Гөлфинә, К. Гольдониның «Хатыннар гайбәте»ендә Катэ — татар, урыс, итальян хатын-кызлары. Холыклары ягыннан, күңел кичерешләре ягыннан, болын чәчәкләре төсле, төрлесе төрле персонажлар: фаҗигале һәм сөенечле, сабыр-салмак һәм җилбәзәк-уйнак, кайнар җанлы яки салкын-битараф, ут өермәсе яки мәгърур-тәкәббер. Шушы холыкның, шушы капма-каршылыкның һәммәсен сәхнәдә тудыра Дания. Нинди генә кием кимәсен — аңа килешә. Беренчедән, ул сылу гәүдәле, шул сылулыгын аңлы рәвештә, сәхнә өчен дип саклый белә, аның гәүдәсендә кием капчыктай асылынып тормый, икенчедән — киеменә карап ул героинясының холкын таба, чама хисен беркайчан да югалтмый; йөреш-торышында, башны текә тотуында яки сагыш-моңнан иңрәп, басынкыланып калуында, җаннарны кинәндереп көлүендә, гөлдерәп сөйләшүендә — барысында, барысында ул чын, ул уйнамый, арттырмый-киметми, адәм баласы кичерә торган тойгыларның ка-

мил бер сөземтәсен тулы бер төгәллек, осталык, хәтта мин әйтер идем, виртуозлык белән, җан җылысы белән тамашачыга илтеп җиткерә.

Мисал өчен ул уйнаган спектакльләрнең бер-икесен генә күздән үткәрик.

Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр»ендәге Гөлфинә. Гап-гади бер авыл хатыны, 12 баланың әнисе. Алчак күңелле, самими-садә, шул ук вакытта сабыр да, түземле дә, ашыкмаучан табигатьле дә. Бу хатын бала табу йортындагы әйбәт атмосфераны, йомшакҗылы могамәләне тудыручы булып күңелгә керә бара. Башка әниләр аңа сыена, аңардан киңәш сорый. Ул — чын мәгънәсендәге авыл хатыны: гадилеге белән дә, күңел пакьлеге белән дә. Ә бит, уйлап баксаң, Дания — авыл кызы түгел. Шәһәрдә туып, шәһәрдә үскән, үзара сөйләшкән чакта, көндәлек тормышта кирәксә авызыннан ут чәчә, кулында ут уйната торган булдыклы, җитез, ашкын хисле, тәвәккәл холыклы Казан кызы. Ничек соң ул авыл хатыны образын шулхәтле дә төгәллек белән сәхнәгә алып чыга алды?

Моңарчы югарыда санап киткән сыйфатлар булышадыр аңа. Мин шулай дип уйлыйм. Югары зәвык. Табигый ихласлык. Чама хисен югалтмау. Болар өстенә тагын — искиткеч тырышлык, зур хезмәт кую, эзләү-эзләнү. Әйе, чамасыз зур хезмәт аның образларын чынга әверелдерә, табигать бүләк иткән кояшлы талантын тулы көченә ачарга мөмкинлек тудыра.

Хезмәт дигәннән, моннан унберунике ел элек Эльмира Шәрифуллина, «Гаилә һәм балалар» конкурсында катнашып, Дания ханымның кызы Айсылу белән бергә, үз өйләрендә аш-су әзерләвен, баласына ни рәвешле хезмәт тәрбиясе бирүен бик тәфсилләп язып чыккан иде. «Социалистик Татарстан» газетенда басылган ул очеркны мин күптән укыган булсам да, әнисе белән кызының сөйләшүе күңелгә кереп калган. Шушы көнгә тикле онытылмый. Бәлкем, мин ихтирам иткән артистка тормышы белән бәйле булганга онытылмый торгандыр.

«— Рольләрне өйдә дә өйрәнәм мин,— ди Дания ханым.— Өйрәнәм дә сөйләп, уйнап карыйм. Андый чакта үземне төгәл тотарга тырышам. Һәр хәрәкәтем, һәр адымым белән кызым Айсылуга үрнәк буласым килә...»

Болай булгач, «Әниләр һәм бәбиләр»дәге Гөлфинәнең ни өчен уңышлы, җанга ятышлы булып чыгуы аңлашыла төшә бит әле. Талант үзе генә,— әгәр ул хезмәт вә тырышлык белән кушылмаса,— тора-бара сүнәргә, тоныкланырга, бөтенләй дә юкка чыгарга мөмкин. Чын мәгънәсендәге зур талантка ия кешеләр аны саклый да, үстерә дә беләләр, тормыштан сәхнә өчен кирәкле бизәкләр, детальләр, янадан-яңа халәтләр, мимикалар эзлиләр.

«Әниләр һәм бәбиләр»дәге Гөлфинә, бала табу йортындагы башка әниләр төсле үк, ак халаттан. Әмма аның артка чөеп бәйләгән ак аулыгы, муенындагы бармак башы чаклы сары гәрәбәләре Гөлфинәне коеп куйган авыл хатыны итә дә куя. Ниндидер ялтыравыклы ак мәрҗән дә, энҗе дә такмаган, брошки да кадамаган, эре-эре сары гәрәбә таккан, ул әллә каян күренә, ул әллә каян ук Гөлфинәнең эчкерсез, беркатлы авыл апае икәнен әйтә дә тора. Димәк, Дания хатынның күзәтүчәнлеге дә, иншалла, җитәрлек икән. Гәрәбә дә, артка чөеп бәйләгән чытыр ак яулык та, сөйләшү рәвеше дә — барысы да шушы роль өчен. Ак яулыкка аеруча тукталасым килә. Аклык — төрки халыкларында сафлык, пөхтәлек билгесе. Ак яулык, ак алъяпкыч, ак сөлге, ниһаять, ак күңел! Болар безнең халыкта борын-борыннан сакланып килгән гадәт. Төрки халыкларында хәттаки мәетне соңгы юлга озаткан чакта да актан киенү гадәте булган — шул ук сафлык билгесе. Бездә бит мәет өстендә акырып елау да юк, мәет яшь дингезендә коеначак, дип куркыта иде авылда карчыклар.

Менә шушы кием билгеләре янына Дания ханымның кызы Айсылу белән булган әниләрчә җылы, таләпчән мөнәсәбәтен дә китереп кушсак, Гөлфинә образы безнең алда тәмам ачылып бетә яза.

Шушы уңайдан тагын бер тормыш хәлен әйтми китеп булмастыр. Дания сеңлебез 1971 елны кияүгә чыга, театрдан китә. Менә шунда инде аның өчен дөньядагы бизәкләр тоныклана, язы яз түгел, җәе җәй түгел дигәндәй, тоташ яңгырлы көзгә, тоташ суык кышка әйләнә аның гомере. Радиодан берәр спектакль яки артистлар чыгышын тыңлыймы, телевизордан Камал театры артистлары спектаклен трансляциялиләрме — йөрәкләре өзелеп төшәрдәй була Даниякәйнең. Ике ел буена ул өйдә утыра, бәби таба, аны бага, һәм, ниһаять 1973 елны кабат театрга әйләнеп кайта. Шуннан ары аның театрдан киткәне юк. Тормыш булгач — тормыш инде: төрле хәлләр булгалый. Дания ханым сөекле кызы Айсылуны ялгызы үстерә. Әмма күңелен төшерми. Кызын нилектән ялгыз үстерүенең сәбәпләрен ул берәүгә дә

сөйләп йөрми, шул исәптән, мин дә ул хәлнең асыл сәбәпләрен белә алмадым. Ничек кенә кыен булмасын, ул багалмасын тәртипле, тәрбияле һәм әдәпле кыз итеп үстереп җиткерә. 20 яшендәге Айсылу, әнисенең сөекле баласы, минем анлавымча, быел тормыш корып җибәрергә ниятли. Ихтимал, әнисе хакындагы әлеге язма дөнья күргәндә ул инде кияүгә чыккан булыр. Без аңа бәхетле тигез тормыш телик. Айсылу сеңлебез әнисен гел сөендереп кенә торсын!

Дания ханымның театрга килүенә быел 27 ел тулды. Училищеда укыган елларын да кертеп исәпләсәк — 30 ел. Озын гомер. Шул гомердә Дания Нуруллина утыздан артык спектакльдә уйнаган, күпчелеге — төп рольләр, героинялар. Аларның портретын эзләп тапканчы, аларның күңел хисләрен аңлаганчы күпме борчылу, мәшәкатьләр кичерергә туры килмәгәндер аңа. Ә рольләрдә ул ничәмә-ничә мәртәбә каргалган, кимсетелгән, күз яшьләре түккән, ничәмә-ничә мәртәбә, яз тургайлары сыман, канат кагып, күкләргә ашкан; ничәмә-ничә мәртәбә мәхәббәт утларында янган, аерылу, кире кагылу газапларын кичергән, ничәмә-ничә мәртәбә үлем белән очрашкан! Ай-һай, озын артист гомере! Гади бер обывательгомеренә караганда биш-ун мәртәбә озынрактыр, кызыграктыр, мәгънәлерәктер сәнгать кешеләренең тормышы. Тар карашлы бәндә, бер ел эчендә тормышын көйләү артыннан чабып, 365 көннең узганын сизми дә кала. Ә артист? Бер ел эчендә генә дә нинди кайнар дулкыннар уза аның җаныннан, нинди каршылыклар, икеләнүләр, уңышсызлыкка очрау, мең газап белән табылган бәхетле минутлар уза! Үзебезнең язучылык һөнәрен генә алып карыйк. Зур-зур романнарны язган чагында кемнәрнең генә «шкурасына» керергә туры килми. Нинди генә хисләрне, газапларны җан аша уздырырга туры килми. Татьяна кияүгә чыкты, дип җанын кая куярга белми йөри Пушкин. Украин язучысы Коцюбинский бәләкәй кызы үлеп яткан чагында, ә-әә, адәм баласының йөз сызыклары менә ничек үзгәрә икән, дип күзәтә, ә газиз баласының иң авыр минутларында да «каһәр суккан язучылык һөнәренең» килеп тыгылуын каргап бетерә алмый. Ә артистлар? Алар бит көн саен, сәгать саен диярлек эш көнендә генә түгел, ял көннәрендә дә башка бер кеше, тулаем бер образ тормышы белән яшиләр, ул булып уйлыйлар, ул булып йөриләр, ул булып фикер йөртәләр.

Мине, мәсәлән, Дания Нуруллинаның итальян бичәсен уйнавы кайчандыр таң калдырган иде. Италиядә зур бер комедия мәктәбе тудырган Карло Гольдониның «Хатыннар гайбәте»ндә Дания Катэ булып уйнады. Дания-Катэның темпераменты, мимикасы, кул-аяк хәрәкәтләре, өзлексез динамикада, өзлексез пулеметтан аткандай сөйләвендә Италия хатын-кызларының үз-үзләрен тотышы тирәнтен ачып бирелгән иде. Дания Нуруллинаны бу рольдә татар хатыны дип тә, марҗа дип тә әйтеп булмый, бу нәкъ менә коеп куйган итальян бичәсе иде. Мин моны бик ышанып әйтәм, чөнки шуннан алда гына мин Италиянең атаклы балалар язучысы Джанни Родари белән хатынын һәм унбиш яшьлек кызларын Татарстан буйлап йөрткән идем. Гап-гади гына хәлләрдә дә Джаннины хатыны, кызы шундук бик кайнарланып сөйли, кулларны бутый, йөзләренә әллә ниткән мимик үзгәрешләр кертәләр иде.



*«Соңгы корбан» (А. Островский) спектакленнән бер күренеш. Сулдан: Дания Нуруллина — Юлия Тугина, Ф. Ильская — Глафира Фирсовна, Ф. Халитов — Флор Федулыч.*

Мин үзем дә ул мәсьәләдә тыныч-сабыр кеше түгел. Шуңа күрәдер Джанни Родари: «Сезгә каян килгән ул итальяннар темпераменты, сез кулларны шулкадәр күп бутыйсыз, сөйләгән чакта шундый кычкырып, ашкынып сөйлисез, сезне тыңлаган чакта мин үземнең Италиядәге, Римдагы күршеләрем-

не искә төшерәм»,— дип дусларча көлгән иде ул миннән.

Инде менә Даниянең итальян бичәсенә әйләнеп кайтыйк. Кем дә кем Дания Нуруллинаның уйнавында Катэне күргән, аңардан соң бер генә артистканың да итальян кызын шундый темпераментлы, шундый кабатланмас образ итеп күргәне булмагандыр. Мин моны һич кенә арттырмыйча, гадельсез бәя бирәм дип курыкмыйча, күңелем кушканча әйтәм. Аның уенындагы осталык, көч-куәт, житезлек-виртуозлык бөтен сәхнәне биләп алган, бөтен сәхнәне тутырган, сәхнә үзе дә, андагы декорацияләр дә юкка чыккан иде...

Кабатлап әйтәм: Дания Нуруллинаның сәхнә тормышына табигыйлек хас. Бу, әлбәттә, аның, эчкерсезлегеннән, юмарт күңелле, ихлас-саф җанлы булуыннан киләдер. Нурихан Фәттахның «Кол Гали» трагедиясендәге Чәчәк исемле кыз очлы кама бүректән, күз явыңны алырдай затлы күлмәктән, күзләре дөньяга зур булып, гаҗәпләнеп ачылган мәхәббәт алиһәсе. «Чәчәк» исеме аңа бик тә туры килә, чөнки аның бар булмышы — кояшка керфекләрен ачып җибәргән гүзәл чәчәкне хәтерләтә.

Ә менә Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ындагы Зәмзәмбану исә усаллыкның, ныклыкның, башбирмәс үҗәтлекнең коеп та куйган бер үрнәге. Дания-Зәмзәмбануны тыңлаганда-караганда тәннәр чымырдап китә, чәчләр үрә тора. Бер үк артистканың шулчаклы нәфисләкне дә, чамадан ашкан явызлыкны да сәхнәдә гәүдәләндерә алуына таңнар каласың...

Сәнгать белгечләре артистларның диапазоны турында сүз йөртергә яраталар. Трагик артист, комик артист диган төшенчәләр бар алар телендә. Бу төшенчәләрне сәнгать белгечләре уйлап чыгармаган. Алар тормыштан, сәхнә тормышыннан алынганнар. Мин үзем, мәсәлән, Равил Шәрәфиевне берничек тә трагик образда итеп күз алдына китереп карый алмыйм. Дөрес, аның андый образларга да кереп караганы булды, тик — гомер буена сәхнәдә Шәрәфи мәзәкләрен күреп өйрәнгән тамашачылар — ул бик җитди, хәтта ки трагик образ булып чыккан чакта да, артист сәхнәгә аяк басу белән көлә башлыйлар, чөнки Равил аларны гомерлек көлү җаена көйләгән. Әнә шул көлүләре, дөресен әйткәндә, вакытсыз вә урынсыз көлүләре белән тамашачылар Равил Шәрәфиевнең трагедиясен җимерәләр.

Дания Нуруллина ике якны да булдыра — фаҗигаләр дә, мәзәкләр дә сыя аның күңеленә. Җинеллек-уйнаклык белән бергә, аңарда сабыр-басынкылык, моң-сагышлар да янәшә, тигез хокуклы булып яши ала. Бу очракта без Дания Нуруллина хакында: ул киң диапазонлы, зур колачлы иҗат кешесе дип авыз тутырып әйтә алабыз.

Аның бу сыйфатын хатын-кыз язучы Эльмира Шәрифуллина бик дөрес тотып алган. Моннан ун ел элек, 1983 елның март аенда «Азат хатын» журналында бастырган «Яңгыркаем, яу, яу!» исемле мәкаләсендә ул болай ди: «Артистканың иҗатын ачыграк күрү өчен, ул уйнаган рольләрнең кайберләрен чагыштырып карау кирәктер, бәлки. Кайсы пландагы геройлар аның иҗатында көчлерәк яңгырый соң? Мәсәлән, бер якта — бөтен милли колоритны җыйган, искиткеч тыйнак, оялчан, садә Шәфәкъ, Айсылу, Чәчәк рольләре, икенче якта — усал, зәһәр, оятсыз Зәмзәмбану ишеләр. Әлеге рольләрнең яшәешендәге, эчке дөньясындагы каршылык җир белән күк арасы кебек. Әмма һәр ике яктагы геройлар — уңае да, тискәресе дә тамашачыга тиешле кондициягә җиткереп, тулы канлы образлар булып тәкъдим ителгән. Бу инде, берсүзсез, артистканың актерлык осталыгын, киң диапазонлы булуын билгеләүче дәлил».

Эльмира Шәрифуллина фикере белән тулысынча килешәм, әмма ул әйтеп бетермәгән бер нәтиҗәне ясауны кирәк дип уйлыйм. Дания Нуруллина иҗат иткән образлар уңаймы, тискәреме, комикмы, трагикмы — аларны башкарган чакта Дания ханым җанындагы шигърияткә дә өсти. Менә шул җандагы шигърият аның образларын сәнгатьчә югарылыкка, сәхнә осталыгына күтәрә, менә шуңа күрә без ул обзарларны уңай яки тискәре итеп түгел, тулы канлы итеп, чын кешеләр итеп, безнең таныш дусларыбыз яки таныш дошманнарыбыз итеп кабул итәбез, аларның бәхеткә китергән финаллары да, фаҗигагә алып чыккан соңгы язмышлары да безне битараф калдыра алмый.

Инде үзенең туган йортына әйләнгән Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында утыз ел эшләү дәверендә Дания Нуруллина күп мәртәбәләр рәхмәт сүзе дә ишетте, Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемгә дә лаек булды.

Тик... эреләнмәде, борын чөймәде. Аны беренче мәртәбәсендә театр училищесына кабул итмәгән Празат абыйсына җанында үпкә сакламады, киресенчә, аңа рәхмәтле булды, ник дигәндә — ул аны тырыш хезмәт юлына,

чын артистлык юлына өндәде, үзе сәхнәгә куйган «Татар хатыны ниләр күрми», «Кичер мине, әнкә спектакльләрендә әйбәт рольләр бирде, өстәвенә — образларны җанландырудагы хәлиткеч моментка, персонажлар психологиясенә басым ясый-ясый, үзе уйнап күрсәтә-күрсәтә өйрәтте. Празат Исәнбәттән тыш аңа өлкән агасы Фоат Халитов бик нык ярдәм итте. Баш режиссер Марсель Сәлимҗановтан да, ул театрга аяк баскан чактагы баш режиссер Шириаздан ага Сарымсаковтан да, үзе белән бергә театрга килгән яшьтәшләреннән дә күп игелек күрде. Дуслыкиптәшлек хисе яшәгәндә генә театрда иҗади атмосфера туачагын ул җанытәне белән аңлады, әнә шул дуслыкиптәшлек тойгылары, театрдагы бердәмлек һәм ярдәмчеллек аңа Юлия Тугина (А. Островский — «Соңгы корбан»), Ирина (Н.Погодин — «Баһадирлар»), Варя (Б. Горбатов — «Бер төн»), Кадрия (А. Абдуллин — «Унөченче председатель»), Тәнзилә (Х. Вахит — «Оныта алмасаң, нишләрсең»), Айса (Ә. Баян — «Күзләре нинди иде»), Фаягөл (А. Гыйләҗев — «Китмәгез, тургайлар»), Гөлбану (Н. Исәнбәт — «Хуҗа Насретдин») кебек җитди зур образлар тудырырга мөмкинлек бирде.



*Дания Нуруллина «Ташкыннар» (Т. Гыйззәт) спектаклендә Зәмзәмбану ролендә.*

Театр, Камал театры — аның икенче туган йорты, шулай булып калачак та.

Дания ханымның актерлык хезмәте спектакльләрдә роль уйнау белән генә чикләнми. Сәхнәдән яки радиодан ул шигырь укыганда таң калып тыңлыйсың, туган телебезнең матурлыгын, образлылыгын, аһәңен артистка тавышының матур тембры, логик басымнарны нәкъ урынына китереп куюы, ашкынулы темпераменты белән безнең аңыбызга сеңдерә.

Күңелдә еллар буена йөргән уй-фикерем бар: әгәр моңарчы Татарстанда нәфис фильмнар студиясе булса, Дания Нуруллина күптән инде дөнья йолдызы булыр иде.

* * *

... Дания Нуруллинаның артистлык хезмәте хакындагы материалларны туплап, үзем күргән спектакльләр хакындагы әүвәлге фикерләремне кәгазьгә төшергәннән соң, мин аны, үзе белән кара-каршы утырып сөйләшү өчен өебезгә чакырдым. Очрашу-сөйләшү урынын Язучылар берлегенә дә, Мәдәният фондына да билгеләп караган идек, никтер алары барып чыкмады. Йә Даниянең репетициясе вакытына туры килә, йә мине берәр оешмага җәмәгать эше белән чакырып алалар. Ә вакыт уза тора, вакыт кадерле. Ниһаять, ул үзе безгә килде.

Ноябрьнең беренче салкын көне иде. Җанга тигән җепшәк карлардан, бәйләнчек салкын яңгырлардан соң, температураның 19 градус салкын икәнлеген хәбәр итте радио. Әнә шул суык көнне Дания безгә килеп керде. Үзенә бик тә килешле күгелҗем төстәге, затлы мехтан тегелгән күперенке якалы пальтодан, шундый ук йомшак затлы мех бүректән,— бит алмалары алсу, янып тора, күзләрендә очкыннар биешә, үзе күрешә, үзе көлә. Матур итеп, ихластан көлә, Шәһидә апасына, минем хәләл җефеткә мөрәҗәгать итеп:

— И-ии, кеше мәшәкатьләп йөрим инде шунда! Бу ямьсез заманда минем генә кайгымы инде сездә, туганкайларым...— ди.

Аның белән болай бик якыннан танышкан да, үзебез генә аерым табынга утырып чәй эчкән дә юк иде әле. Без бит аның сәхнә тормышын гына белә идек, сәхнәдә ул уйнаган рольләргә карап ихтирам итә идек.

Инде менә күрештек. Чүкердәшеп чәй эчтек. Озаклап эчтек чәйне, озаклап, матур итеп сөйләштек.

Ул безгә гадәти тормышта үзен тотуы, ягымлы-күркәм булуы белән бик ошады. Без аның хакында: «Әйбәт кеше, чын татар баласы, ә сәхнәдә җуелмас үз урынын яулап алган халык артисткасы»,— дигән фикердә калдык.

**Гариф АХУНОВ**

*27 гыйнуар, 1993.*

# ҖАННЫҢ ҖИДЕ ТӨСЕ

*Коесы булсын да чыккан суы тәмле булсын, энә белән казыдыңмы, дип сорамаслар.*

Татар халык мәкале



Габдулла Тукайның Уральскидан Казанга килгәч тә Галиәсгар Камал белән беренче күрешү-танышуына охшашрак хәл безнең талантлы рәссамыбыз Илдар Зарипов тормышында да булып ала.

Бер елны шулай, хатыны Светлана белән бергәләп, рәссам Кырымга, иҗат йортына бара. Шунда ул үзе белән бергә Суриков институтында укыган, хәзер инде Ленинградта яшәп ятучы рәссамны очратып, дустанә генә күрешә. Моның сабакташы исә үзенең юлдашына:

— Болар Казаннан килгән иптәшләр,— дип авыз ачарга да өлгерми, тегесе, өлкәнрәк яшьтәге сәнгать белгече:

— Бәй, Казаннан булгач, сез анда Илдар Зариповны да беләсездер әле?!— дип элэктереп ала да мактау сүзләре яудыра башлый.

Илдар белән Светлана бер-беренә карашып алалар да тыйнак кына елмаешалар.

Әти мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, берәүнең дә хәлләнеп-тернәкләнеп китүен күпсенмәде, берәүдән дә көнләшә белмәде. Фәлән кешеләр бура буратканнар, яисә, күршеләр уракка төшкәннәр, дигәнне ишетсә, һич кайгыга сабышмыйча, сабыр гына ихлас күңелдән: «Алла ярдәм бирсен инде үзләренә!»— дия торган иде. Гаҗәеп киң күңелле, көчле рухлы кеше генә әйтә ала андый сүзләрне.

Әтинең әнә шул сыйфаты, гәрчә аның шикелле көчле булмасам да, миңа да күчкән. Шәхсән мин үзем гомеремдә берәүдән дә көнләшмәдем. Үзебезнең татар халкына файдасы-хезмәте зуррак булган өчен генә көнләшмәссең ич инде! Шагыйрьләр һәм прозаиклар хезмәтенә дә, әдәби тәрҗемә осталарының энә белән кое казуына да гомерем буе сөенеп яшәдем.

Әнә шундый ук сыйфатны Илдар Зариповта да очратып, сабыйларча сөендем. Югыйсә бит еш кына иҗат кешеләренең бер-беренә көнләшеп каравына юлыгасың. Андый чакны, кеше бит гадәттә, икенче бер һөнәрмән ирешкән уңышка тыныч кына карый алмавын, шуңа гасабилануын сиздермәскә тырыша. Әгәр дә инде түрә-фәлән булса, үзеннән күп мәртәбә сәләтлерәк һөнәрдәшләренә мэтр булып, югарыдан карарга, акыл өйрәтергә маташа.

Моннан биш-ун ел элек Күргәзмә залында тугандаш кыргыз рәссамнарының картиналарын тамаша кылган идек. Әнә шул күргәзмәгә ике төрле караш үземне тетрәндергән иде. Берәвесе әйтте:

— Син дустым, ул күргәзмәгә барып вакытыңны әрәм итеп йөрмә. Безнең урта кул рәссамнар хәтле дә эшли белмиләр икән...— дип пичәт сукты.

Икенчесе, талантлырагы:

— Анда шактый гына үзенчәлекле әсәрләр бар. Көчле рәссамнар. Үзенчәлекле, эзләнүчән художниклар. Гыйбрәт алырга була алардан...— диде.

Күргәзмәдә, чыннан да, сокланырлык, анда менә дигән сәнгать әсәрләре куелган иде. Берсе әле дә күз алдымда. Залга килеп керү белән, өстенә атыларга әзер булган, ыжгырып торган табын айгырына тап буласың. Тымызык бер төн. Тау-таш арасы. Атлар чемченеп йөриләр. Матур-матур колыннар аналарына сыенышкан. Карап туймассың үзләренә. Көтүдә һәммәсе дә үзен тып-тыныч тота. Алар язмышларын айгырга ышанып тапшырганнар. Көтүче айгыр исә башын күтәргән, күзләре ут уйный. Аның бөтен гәүдәсе дошманы өстенә ыр-

гылырга әзер икәнлеген исбатлый. Бүре ише вак-төякне әйткән дә юк, арысланың белән дә алыша алыр иде бу айгыр. Ул — көтүнең иминлеген саклый.

...Илдар Зарипов исә бер караудан тамашачының күңеленә сеңеп калырдай камил, зур тәэссорат көченә ия булган сәнгать әсәрләреннән гыйбрәт алырга һәрчак әзер. Ул берәүгә дә кимсетеп карамас. Галерея-мазарда йөргәндә дә үзенә ошамаган картиналарны күрмәмешкә салышып узып китә, ә инде ошаганнары янында тукталып, соклануын яшермичә, озаклап карап тора. Мөгаен, авторның мондый камиллеккә ничек итеп ирешкәнен ачыклый, картинага анализ ясый, профессиональ яктан чыгып бәя бирә булыр. Шулай булыр, гыйбрәт ала булыр...

Чын зыялылар барчасы да шундый булырга тиешләр дә бит, кана... Гомумән, иҗат кешесенә, теләсә нинди һөнәр иясенә иң зур зыян китергән нәрсә — ул да булса мин-минлек галәмәте. Әгәр дә мәгәр кеше үзенең һөнәрендә бәләкәй генә үрне яулап алу белән чикләнә икән, артына борылып, түбәндәгеләргә масаеп карый икән,шул мизгелдә үк аның башы әйләнергә тотына, ул, бичара, баскан урынына лып итеп утырырга, һич югы чүгәләргә мәҗбүр була. Кая инде аңа күк йөзенә, югарыдагы тауларга баш күтәреп карау — ул алардан бөтенләйгә үк ваз кичә...

Ә менә Илдар Зарипов һәрвакыт киң күңелле, бүтәннәргә теләктәшлек кылучан зат. Ирешкән үрләренә мөкиббән китмичә, масаюның ни икәнен дә белмичә, сәнгатькярләрнең һәркайсына ул иҗат кешесе итеп, хөрмәт белән карый.

Гомумән, җаны-тәне белән милли сәнгать өчен янып көюче, аның казанышларын ишәйтергә омтылучы һөнәрмән, чын сәнгать әһеле, чын иҗатчы буларак, һәр милләт вәкилләренең дә үз халкына хезмәт итәргә, сәнгатьне баету дәрте белән янарга тиешлеген аңларга аның зиһене җитә. Менә ни сәбәпле ул хөсетлеккөнчелеккә бирелми.

Телефоннан хәбәрләшү, күргәзмә-мазарда очрашу дисеңме — рәссамның халәте рухаясен аңлау нисбәтеннән боларның һәркайсы үзенчә кадерле, үзенчә игътибарга лаек. Әйтик, телефоннан тавышын ишетү белән, үзең хөрмәт иткән кешенең исән-имин генә яшәп җимертеп эшләп ятуына, кәефе әйбәт икәненә инанасың, изге теләкләреңне күндерәсең...

Әмма рәссамның остаханәсендә күрешү-сөйләшүгә җитми инде. Монда син аның тәмамланган эшләрен күрәсең-өйрәнәсең, композициясен генә түгел, төсләр гармониясен дә күңеләңә сеңдерәсең. Сәнгатьтәге камиллек, гүзәллек, илаһи матурлык, табигатьтәге матурлыктан үзгә буларак, игътибарны аеруча нык җәлеп итә, хәтердә озаграк саклана, кайсыбер очракта хәтта гомерлеккә исеңдә кала. Моңа, ихтимал, сәнгатькярнең табигатьтә син үзең әллә нигә бер генә, әле анда да берән-сәрән күргән-очраткан гүзәллекнең һәммәсен бергә туплап, линза фокусында күрсәткән шикелле киндердә тасвирлап бирүе тәэсир итәдер. Сәбәбе гап-гади: анда-санда, берән-сәрән күргәндә әле син еш кына абайлап та өлгермисең, матурлыкка лаек бәяне дә биреп житкермисең. Ә инде олуг талант иясе әнә шул матурлыкны, табигатьнең үзендә әллә кайларга чәчелгән-сибелгән гүзәллекне рәссам күзе белән әллә кайлардан абайлап-күреп, аны берәмтекләп җыеп, һәммәсен бергә туплап, анда да әле хыялы белән баетып, нәкъ менә киндергә табигый булып ятардай төсләрне-бизәкләрне сайлап, табигатьтән килгән талантына йөрәк җылысын да кушып, дәртләнеп-канатланып иҗат итә икән инде — аның иҗат җимеше, әлбәттә, гүзәл килеп чыгачак, автор олуг камиллеккә ирешәчәк, картинасында сәнгатьчә дөреслекне гәүдәләндерүе белән синең күңеләңне җәлеп итәчәк. Картинаны ерактан да караштырасың, якынрак килеп тә күзәтәсең — һич кенә дә карап туймыйсың, аерыла алмыйсың. Кызык хәл бит, хәйран кызык хәл: шулчаклы зур мәгълүмат туплаган, сине таң калдырган киндер янында минутлар гынамы соң! — сәгатьләр узганны да абайламыйча басып торырга әзерсең; аяклар да арымый, күзең дә талмый.

Табигатьнең үзендә гаҗәеп күренешләргә очрыйсың. Куе урман эчендә гөмбә җыеп йөргәндә синең мөлдерәп торган күлгә юлыгуың ихтимал. Әйтик, агачлар сирәгәеп, аланы сөзәкләнеп, камышлар калкынып, ярлары баткакланып, шуларның уртасында күл хасил булса, гаҗәпләнмәс тә идең. Монда бит боларның берсе дә юк: урманның куелыгы һич кимемәде, һич кәтмәгәндә бер дигән күл пәйда булды да куйды. Һушыңны җыйгач, як-ягыңа карана башлыйсың. Искиткеч ямьле. Гүзәллекнең үзе. Барыннан да ныграк хәйран калдырганы шунда ки, әлеге күл бу урман өчен чит-ят түгел, аның кыяфәтенә һичбер төрле хилафлык китерми, әле, киресенчә, йөзек кашыдай, аның сихри гүзәллеген көчәйтеп җибәрә, ямь өстенә ямь өсти. Менә сиңа илаһи бер гармония!..

Табигатьнең әнә шундый таң калырлык халәтен, илаһи бер гармонияне Илдар Зарипов киндерләрендә күреп, тамашачы хәйран да нык тәэсирләнә, әлеге

күренеш аның күңеленә сеңеп кала, матурлыкка битараф яшәмәскә өйрәтә. Һәркем уйланырга мәҗбүр була — авторның бу чаклы гүзәллекне кайлардан табып бетерүе һәм ничек итеп шул кадәрле оста сурәтли алуы хакында баш вата.

Чынлап та, автор безнең һәркайсыбызга очравы ихтимал булган могҗизалы сюжет һәм күренешләрне табигатьнең үзеннән эзләп таба, аны рәссам күзе белән, күңел күзе белән күрә белгәнгә хәтеренә сеңдерә, этюд иттереп кәгазьгә яисә картонга төшерә. Ә инде яңа әсәрен язарга керешер алдыннан мона файдаланырлык әзер этюдларын барлап чыга. Әмма кичә язган этюды үз-үзенә карыс һәм таләпчән рәссамны бик сирәк очракта гына канәгатьләндерә. Һәрхәлдә, рәссам аны шул көенчә картинасына күчереп утыртмый, бәлки үзенең хыялына таянып, сайлаган сюжетына яраклаштырып үзгәртү ягын да чамалый.

Искиткеч зур талантка, олуг бер кодрәткә ия була торып та, яңа теманы язарга керешкәндә рәссам үз көченә бик үк ышанып бетми. Киндерне грунталаган чагына туры килеп, сораштыра калсаң, ул, рәнҗетмәгәем дип шөбһәләнгән сыман, каты бәрелмәскә тырышып кына:

— Үзем дә белмим бит әле нәрсә килеп чыгарын,— ди һәм: — Син керешәсең бер теманы язарга, бер күренешне сурәтләп бирергә — килеп чыга бөтенләй икенче нәрсә,— дип төшендереп бирергә ашыга. Буягычның сабы белән көмеш йөгергән башын кашыгандай итә һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрә.— Кайчагында берни килеп чыкмый! Андый хәлләр дә булгалый шул...

Бу бит әле теманы һәйбәтләп өйрәнгән хәлдә, һәммә нәрсәне күзаллаган килеш әйтелгән сүз. Һәм үзенең бәясен күтәрү өчен генә әйткән сүз дә түгел, ихластан сөйләү, күңел түрендә яткан дөреслекне яшерми-нитми әйтеп бирү. Аңа ышанмаска, шаярту гына дип кабул итәргә синең хакың юк. Ул чынлап та һәр яңа картинасының ни рәвешле очланасын алдан ук әйтә алмый. Ә инде үз-үзенә кирәгеннән артык ышану яки масаю аның табигатенә һич тә хас нәрсә түгел. Нинди сәләтле һәм әзерлекле була торып та ул еш кына «буразнага төшә алмыйча» — төсләрнең нәкъ бу урында кирәклекләрен таба алмыйча иза чигә. Ә инде төсләрне сиземле Зарипов, искиткеч шәп сиземле!

Чынлап та, математика галиме төрле саннарны, формулаларны исендә тоткан шикелле, рәссам да әллә күпме сюжетны, күренешне хәтерендә саклый. Дөресрәге, ул теләсә кайчан үзенә кирәкле хәлне, күренешне җинел генә күз алдына китерә һәм шуны тасвирлап бирә алыр иде сыман. Әмма Илдар аны тулаем әзер килеш, үзе уйлап чыгарган яки хәтер сандыгыннан актарып алган һәм күз алдына аермачык китергән хәлендә язып куюдан ерак тора. Эшли башлау белән, элек уйланган сюжетны үзгәртә. Аннары инде язу ысулын бик нык үзгәртә.

Илдар Зарипов кичә үзе ирешкән уңыштан канәгать калмый, тагын да алгарак китү өчен, сәнгатьтә нәкъ менә үз сүзен әйтү өчен, яңадан-яңа ысуллар уйлап чыгара — экспериментлар ясап баш вата. Менә нилектән аның әсәрләре арасында бер-берен тулысынча кабатлаган эшләрен тапмассың. Ә бит рәссам кайчагында үзенең әле генә тәмамлаган яки элегрәк язып ташлаган берәр әсәреннән канәгать булмыйча, шул ук сюжетка яңа әсәр язарга — яңачарак берәр эксперимент ясарга тотына. Әйе, үзенең иҗатына, башка төрле хезмәтенә чын мәгънәсендә таләпчән килгәндә, сәнгать остасына эзләнүнең чиге юк.

Кайчагында Илдар иптәшләре-дуслары камилгә санаган, тәмам эшләнеп беткән диган әсәреннән дә автор буларак үзе канәгатьләнү-юаныч тапмый, хуплау-мактау сүзләрен тыңласа да, үзе генә күргән кимчелекләргә күз йома алмый һәм әлеге картинасын, әйдә ярар, дип кенә күргәзмәгә илтергә бик алай ашыкмый.

Йа хода! Әле үзе, тәгаен эше бетте, бу инде картина буларак житлекте, дип санаган, барча тамашачы күргәзмәдә сокланып караган, сәнгать белгечләре үтереп мактаган, күзнең явын алырдай гүзәл әсәрен дә камилләштерергә керешә. Ярый да бит күркәмлек өчен берәр төрле чәчәк-бизәк кенә өстәсә яки анда-санда буявын куерта-сыекландыра төшсә! Ара-тирә автор үзгәртү-камилләштерү дәрте белән артыграк мавыгып китә дә... әсәрне бөтенләй үзгәртеп-бозып ташлый. Андый аянычлы хәлләр дә булгалый шул иҗат кешесенең гомерендә. Эксперимент ясау, яңа ысуллар эзләү белән мавыгучы рәссам иҗатында бигрәк тә...

Рәссам Илдар Зарипов иҗатына кагылышлы берәр сүз әйтсәң, еш кына:

— Ул портретлар ясыймы соң? — дип сорап куялар.

— Ясавын ясый да, фотографиядәге төгәллектән бигрәк, сәнгатьчәлеккә омтыла ул,— дисең.

Гәптәшеңә әнә әлеге сүзең генә кирәк икән, ул бик акыллы кеше сыман:

— Шулайдыр, шулайдыр. Фотографиядәге төгәллекне һәркем биреп житкерә алмый шул, ә портретның бөтен кыйммәте әнә шул төгәллектә! — дип куя.



*Ай нуры (1989 ел).*

Бу рәвешле акыл саткан кеше белән бәхәсләшеп торуда һичбер мәгънә юк. Ул синең сүзеңне ишетмәячәк, дәлилләреңә колак салмаячак, аның үз тугызы тугыз. Ә инде Илдар Зариповның портрет өлкәсендәге уңышын, нинди зур камиллеккә ирешүен күрсәтү өчен, кайбер әсәрләре — «Бишбалта сылуы», «Алсу», «Казан кызы Венера», «Зөлфия» белән «Настасья» кебек гүзәл вә камил әсәрләре — Ленинград сәнгать белгечләре тарафыннан хупланып, Рус музеена кабул ителгәнен әйтеп үтү дә җитәдер. Хәер, менә әле тагын «Айсылу», «Батыр» һ. б. әсәрләренең Мәскәүдәге Третьяков музеенда саклануын да, шактыеның Европада танылуын да, төрле музейларны бизәвен дә өстәп булыр иде.

Атналар-айлар буе Илдарның остаханәсенә эләгә алмый азапланам. Телефоннан вәгъдәләшергә дип кенә торасың инде — ул сине һич якын җибәрми.

— Эшләргә кирәк бит, абзыкай, бик дәртләнеп эшләп ятам. Килерсең әле берәр, күрешербез ничек тә,— дип котылу ягын карый.

Инде шимбә көнгә тәмам вәгъдәләшкән булам, ул тагын кирегә сукалый:

— Көннәр бигрәк җылы бит, бераз этюдка чыгып кермәкче идем, авылга барып кайтасы иде. Берәр көнгә кичектерә алмыйсыңмы соң?— дип самими генә сорау бирә.

Йә, ничек итеп рәнҗетәсең ди үзен? Килешми хәлең юк. Янә бер атнадан, җомга көнгә дип вәгъдәләшәсең.

Дәртләнеп эшләргә яратучы талант иясенең болар белән мавыкланып, көне буена берни майтара алмассың дип, очрашасы көнне өченче яртыдан ук торып, эшкә утырганы соңыннан гына безгә мәгълүм була.

Фотограф Дамир белән без килеп кергәндә, рәссам җиң сызганып эшләп, яңа бер киндерен язып ята иде. Иңе-буе бер чамадарак картина, әллә ни зур түгел, метр ярым чамасы гына. Игътибар үзәгендә тәрәзә. Тәрәзәнең тирә-ягын астан да, өстән дә, шулай ук уннан да, сулдан да кар баскан, бәс сарган. Бүрәнә рамына мул булып яткан кар салкын кыш хөкем сөргәнен сиздереп тора. Шунда үсеп утырган ак каен ботаклары тәрәзәнең бер читен каплый һәм үзенә күрә гармония китереп чыгара. Һәй, бүрәнәләрдә дә, каенда да түгел, тышкы суыкларга контраст сыйфатында тасвирланган эчке бер халәттә икән ләбаса хикмәт!

Синең соклануыңны, таң калып каравыңны могъкуль күреп, автор үзе елмая, кулын болгый-болгый, хыяллары белән уртаклаша:

— Бу авылның чите бит. Шүрәлеләр килә төнлә белән. Монда нинди чибәркәй мунча кирә икән, дип, куакларны аралап, агачның ботакларын аергалап, мунчага якын ук килә дә тәрәзәнең туңын өреп үзенә бер күз ясый. Кызык бит, әй! — дип, чын әкиятче шикелле онытылып сөйли дә сөйли.

Авторның шулай рухланып сөйләве, әлбәттә, сиңа да тәэсир итә. Үзең дә сизмәстән, син дә сихерләнәсең, әкият дөньясына кереп китәсең. Төш күргәндәй, телеңә салынып:

— Кайсы яктан соң сез, шүрәлеләр? Арча ягыннанмы, Дөбъязләрме? — дип сораган буласың.

Автор югалып калмый, көлә генә:

— Юк, без Киек ягыннан, диләр сиңа шүрәлеләр.— Синең аптырашта калуыңны шәйләп, тизрәк төшендерү чарасына керешә: — Илат елгасының теге ягы, Татарстанның чите инде ул авыл. Анысы аның әти авылы. Мари ягы. Аннан китә инде тайга урманнары... Аю-бүре әле дә бар анда. Теге, мәче төсле кыргый җанвар да бар, ничек диләр әле, рысьмы?

— Безнең авылда селәүсен диләр бугай.

— Әнә шулар да бар. Куе урман. Тайга...— Илдар бераз уйга калып, әзер көе яткан буягычын кулына ала да ап-ак мунча бүрәнәсенә кыйгачлап кара сызык сызып куя. Аннары буягычлы уң кулын дирижер сыман югары күтәргән килеш, читкәрәк китеп, әле генә сызган сызыгына, ничек төште икән бу, дип карап тора.— Анда саллы итеп салалар өйне, калын бүрәнәдән. Менә бола-а-ай анда бүрәнәләр, тигез, калын үзләре. Тайга бит. Урман...

Автор үзе шулай кулларын дирижердай болгаганда гүя тирә-якка моң чәчелә — кышкы суык чынлап ала да, бөтерелеп, читкә авыша, аның урынына җанга ятышлы бөтенләй икенче көй агыла башлый. Моннысы мунчаның ныгытып ягылганын, суының кайнар, парының эссе икәнлеген сөйли. Бигрәк тә инде себерке белән чабынып утыручы сылу затның матурлыгын мактый, аның чибәрлегенә мәдхия җырлый. Автор гаҗәеп куе итеп җылы төсләрне юкка гына салмаган шул: сары, көрән, кызгылт төсләр берсе белән берсе аралашып хәрәкәт, юк, алай гына түгел, җылы хисләр, якты өметләр китереп чыгара. Моңа карап һич тә син дәртләнмичә кала алмыйсың.

Хыялга бирелүеңне автор шундук шәйләп ала. Янына килеп баса да хәйран дәртләнеп:

— Җылы гына нәрсә килеп чыга бит. Кызык бит! Бер чәчәк шикелле утыра ул чибәркәй. Нинди нәфис үзенең тәннәре...— дип куя.

Син дә аның сүзен җөпләп:

— Тән симфониясе инде, һич тә бүтәнчә әйтеп булмый,— дисең.

Авторның шунда әйткән:

— Чибәр дә инде бездә, безнең авылда, безнең Дөбьяз ягында хатын-кызлар! Бүтән бер җирдә дә юк андый чибәрләр,— дигән сүзләре аның дөнья күргән егет икәнлеген, чибәрлеккә соклана белгәнен, кеше танырганын исбатлый.

Әмма үзенең һич кенә дә әкият дөньясыннан аерылырга исәбе юк:

— Шүрәлеләр чынлап та карыйлардыр инде төнлә белән тәрәзәдән. Урманда салкын, ә монда мунчадан эссе бәреп тора. Әнтә җылы шундый. Өстәвенә бер чибәркәй хушланып утыра сихәтләнеп. Кызыга шүрәлеләр. Кызыкмый хәле юк, шул тикле нәфис тәнне күргәч. Үзең дә кызыгырсың, әй! — дип, яңгыратып көлеп җибәрә.

Ул арада очып кына картинасы янына бара да янә бер сизелер-сизелмәс кенә сызык сызып куя. Аннары сиңа сер итеп кенә әйткәндәй:

— Мин үзем дә яратам авыл өенә тәрәзәдән карарга. Әнә бер әби утыра җеп эрләп... Теге өйдә яшь кенә бер хатын ай шикелле түгәрәк битле кыз баланың чәчен үреп маташа... Моннысында ике малай шашкамы, шахматмы уйнап утыралар. Шашкадыр инде ул...— дип сөйләп җибәрә, ахырдан гына үзенең һөнәренә якын нәтиҗә чыгарып куя:— Аларның бит һәркайсы — әзер сюжет. Менә мондый сюжет, менә мондый рәсем, картина, тотасы да язасы...

Илдарның сөйләгәннәренә өстәп, син дә авылны мактый башлыйсың:

— Ни әйтсәң дә, авыл халкы уңганрак була шул. Тик утырганнарын күрмәссең һичбер вакыт. Шәһәрнекеләр бит еш кына телевизорга капланa да кала, бар дөньясын оныта.

Хәер, минем сүзләр гәптәшемә кагылмый. Һич тә. Сөйләшкән арада да ул язылып яткан әлеге дә баягы «Бәхет» картинасының ике ягына бәләкәйрәк кенә ике әсәрен китереп куя. Аларын килештереп бетермичә, башкаларын куеп карый, тагын алмаштыра. Иң ахырдан уң кулда авыл урамы, коянтә белән сулы чиләкләр аскан бер яшь хатын-кыз, сул кулда авыл очы булып күренердәй кышкы урман кулай табыла. Әңгәмәгә һәм сайлавына үзенчә нәтиҗә ясагандай:

— Менә без синең белән триптих уйлап чыгардык,— дип, яңа идеясен бүлешә.

Һәй, шул чагында баш кагып кына торасы иде дә бит, юк, мин аңарга изге теләкләремне белдерү йөзеннән... кинәшләремне биреп азапланам. Даһилар бит, гадәттә, олы җанлы булучан. Илдарым да һич күтәрелеп бәрелми, көлә генә:

— Ярар, шулайрак эшләрбез аны! — дигән була.

Әлеге этюдларын, триптих идеясен хуплап:

— Бу эшләрең бигрәк төгәл, натурадан язгансыңдыр инде? — дим.

Нинди хыялга бай иҗатчым да:

— Әйе, дөрес әйтәсең. Болай гына уйлап чыгарып булмый. Натурадан язарга кирәк. Авылга бара торам. Әле менә моннысын узган шимбәдә генә язып кайттым,— ди.

Триптихка нигез ташлары булып ятасы картиналарын төрле яктан торып, башын кыегайта-кыегайта яңадан карап чыга да:

— Бик свежи әле бу. Мичтән генә чыккан ипи шикелле. Берәүнең дә күргәне юк әле. Син беренче күрәсең,— дип куя.



*Кышкы иртә (1992 ел).*

Шул чагында остаханәнең ишеге ачылып китә дә — бер сакал бай пәйда була. Рәссам Саша Переслегин икән, хатыны Зинаны да ияртkән. Эмоциягә бирелүчән, шаулап сөйләргә яратучан бу рәссамны күрмәгәнгә шактый вакыт узган иде, әле Ригадан килеп кенә төшкәннәр икән.

Илдар яңа кунакларга соңгы елларда язган картиналарын күрсәтергә ниятли. Иренмичә-нитмичә дистәләрчә әсәрен берәм-берәм чыгарып күрсәтә. Остаханә соклану вә хуплау авазлары белән тула. Мин сөенеп бетә алмыйм, чөнки Илдар үзе иҗат иткән әсәрләрне кабат-кабат күрсәтергә яратмый, миңа гел яңаларын, «мичтән генә чыкканнарын» күрсәтү белән чикләнгән, сүз дә нәкъ әнә шулар тирәсендә әйләнгән иде. Хәзер исә береннән-бере гүзәл киндерләр күңелемне җәлеп итә. Өйгә кайтулар да онытыла, эшлисе эшләрем дә истән чыга — мин гүзәллек дөньясын гизәм, сәнгать һавасын иркенләп сулыйм, картиналарның музыкасын-аһәңен рәхәтләнеп тыңлыйм, киндердә сурәтләнгән сылуларга сокланам, хозурланам.

Кунаклар да биһуш була. Саша:

— И чем старше он становится, тем он моложе в своих картинах,— дигән мактау сүзләрен әйтә. (Үзе олыгайган саен картиналарында яшәрә бара.)

Илдар үзе дә сәнгать әсәрләренә соклана белүен яшерми. Узган елны Германиядә аның шәхси күргәзмәсе була. Брауншвейг дигән бәләкәй генә бер шәһәрдә бугай, рәссамыбыз музейда мондый хәлгә юлыга.

— Зал буп-буш. Бер генә абзый урындыкка сеңгән, тынын да чыгармыйча утыруын белә. Бу нинди хикмәтле нәрсә икән, дип, ул караган картинага күз салсам — Рембрандт! Шаклар каттым. Юкса мин әйбәт беләм бит инде Рембрандтны. Мондый автопортретын һич күргәнем юк иде. Үзенең сурәтен генә түгел, бөтен мохитен биргән, якыннарын күрсәткән. Тик алары аның арткы планда, әсәрне баетыр өчен эшләнгән...— дип сөйли дә: — Теге абзый шикелле, мин дә, тәмам сихерләнеп, урындыкка сеңдем дә ике сәгать буена кымшанырга да куркып утырдым шул,— дип сүзен тәмамлый.

Журналыбыз тышлыгындагы картинаны да игътибарсыз калдырмыйк. Анда сагышлы-сары төсләрдә татар халкына җан атып торган, аз гына вакыт эчендә күп изгелек кылган Сөембикә ханбикәнең гүзәл образы тасвирлана. 1550 ел. Явыз Иванның күңелен күрергә тырышып, әле кайчан гына урыс явын кире кайтарган ханбикәне әсирлеккә дучар итәләр — Мәскәүгә җибәрәләр. Соңгы ханбикәбезнең илдән сөрелер алдыннан бәхилләшү мизгеле мәңгеләштерелгән. Арткы планда Казан каласының символына әверелгән һәм ханбикәнең исемен йөрткән, мәгърур башын болытларга чөйгән мәһабәт манара да сурәтләнгән.

Сөембикә манарасы хакында сүз чыккач, әңгәмәбез куерып, рәссамның янә дә бер гүзәл сыйфаты ачыла.

Илдар Зарипов — иҗатчы рәссам, һич тә фотограф түгел. Нинди генә әйберне дә күчереп сурәтләү белән канәгатьләнә алмый. Аның һәммә нәрсәгә дә үз күзе, сәнгатькяр күзе белән карый торган гадәте бар. Сөембикә манарасын тасвирларга күптән хыялланып йөри. Әмма озын манараны фотографча тасвирлау, ягъни тукми-чәчми, төп-төгәл итеп рәсемгә төшерү — иҗатчыга кызык түгел. Халкыбызның кору-төзү сәнгатендә йөзек кашы саналган манараның илаһилыгын аңлый рәссам, яхшы аңлый. Тик менә шуның гүзәллеген, илаһилыгын сәнгатьчә ышандырырлык итеп ни рәвешле гәүдәләндерү җаен таба алмый газаплана. Моңарчы яшәп килгән фотолар янына тагын берне өстисе килми, Сөембикә манарасына лаек, шундый ук тәэссорат көченә ия булырдай гүзәл сәнгать әсәре иҗат итәргә хыяллана. Хыялга бай сәнгатькяр моңа ничек тә ирешер, дип өметләник.


Мольбертка яңадан-яңа әсәр куела, шуларның гүзәллегенә сокланып, камиллегенә хәйран калып утыра бирәм. Шулай ук бу чаклы сәнгать әсәрләрен бер генә рәссам язып өлгерде микәнни? Безнең татар халкында шушындый маһир, илаһи кодрәткә ия һөнәрмәннәр бар микәнни? Булган тәкъдирдә без аларны санга сугабыз микән дә үзебезнең мөстәкыйль Татарстан Җөмһүриятендә кадерләрен беләбез микән — ошбу талантлы сәнгатькярләребезгә лазем халык рәссамы дигән исемне, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирәбез микән, ниһаять, замандыбызның асыл затлары белән горурланабыз микән? Әллә инде югыйсә, фәләнфәләничләрдән калышмаска тырышып, кино-теле-видео секс-бомбаларга мөкиббән китеп, менә бит Америкада искусство развиваться итә, бездә ничава падубнывы нит, дип, татарның үзендә туып-үскән даһи затларга, бөтен дөньяны сокландырган шәхесләргә, чын-чыннан милли сәнгатебезгә күз йомып караудан уза алмыйбыз микән?.. Сәнгатьсез генә суверенитет юк бит ул, егетләр, юк.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**



## *Латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре*

Шөкер, татарча Сүз Европа һәм Азия киңлекләрендә елдан-ел ешрак кабатлана башлады. Узган ел Лондонда яшәп иҗат итүче милләттәшебез, шагыйрь һәм галим Равил Бохараев тарафыннан Пакстанның Исламабад шәһәрендә «Азан» җыентыгы нәшер ителү моңа ачык мисал булып тора. Исеменнән үк аңлашканча, бу мәҗмугага Идел буе татарларының дини әсәрләре тупланган. Бастырып чыгаруның максатын билгеләп, мәҗмуганың нашире үзенең кереш сүзендә болай ди:




**— Мәгълүм ки, милли әдәбиятыбыз, шул җөмләдән дини шигъриятебез дә XII гасырдан, Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф» исемле бөек дастаны белән башлана... Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Аллаяр Суфи һәм башка Урта гасыр шагыйрьләребез шөбһәсез ул вакыттагы Азия вә Европаның атаклы шагыйрьләре белән бер дәрәҗәдә тормышлар. Бу китапта без күбрәк XVII—XX гасырдагы дини шигърият мисалларын сайладык, чөнки ул гасырлар татар милләте өчен иң авыр һәм дәһшәтле чорлардыр һәм бу чорларда яшәгән, җәфаланган, әмма нә иманын, нә милли аңын югалтмаган шагыйрьләрнең авазлары бүгенгә көнгә бик төгәл вә бик ярдәмле булып тоелды...**

**Бу китап — Ватандагы һәм горбәттәге татарларның беренче күмәк булдыруы, ләкин, Алла кушса, соңгысы түгел...**

Ышанабыз ки, татар милләтенең уяну таңында яңгыраган «Азан» тавышы журнал укучыларыбызны да битараф калдырмас. Шуны истә тотып, бу санда әлеге мәҗмугадан берничә үрнәк тәкъдим итәбез.

HIBATULLA IŞAN SƏETBATTAL SALIẊ

### TƏṆDƏ ÇANЬM

Təndə çanьm nicə kən mihman ikənder, belmədem,
ytde gomrem, barьsь xosran ikənder, belmədem.
Dənjada təzdem gьjmarət barь nadanlьq belən,
bu gьjmarət barcasь vəjran ikənder, belmədem.

Xabe gaflətdən kyzemne acmadьm tenlə torьb,
tenlə torgan bəndələr soltan ikənder, belmədem.
Qьjlmadьm ziker-tilavət merid-xafizlar belən,
Xaq qatьnda mogtəbər Qor'ən ikənder, belmədem.
Kem ki ingam qьjldь irsə, buldь goqba dəyləten,
bəndəneŋ jaxşь eşe - əxsən ikənder, belmədem.
Ylcəvemez dip qьjldьm irsə, denjada fizьq-fəçur,
bəndəne ylçəy çire, mizan ikənder, belmədem.
Kelle bir və sən, əj qaminə, julga kereb, təybə qьjl,
təybəle qol xaşirdə soltan ikənder, belmədem.
Takatem vəsqьncə qollьq itmədem, kəslan ideb,
takat əhlenə çavab asan ikənder, belmədem.
Qьjlmadьm zəhd təvəkkəl təybə və təkvi ideb,
əhle təkva əkrəm-el-insan ikənder, belmədem.
Əhle əylədem dieldem, jegerdem, tanьmadьm.
innə min ez vaçigьm Qor'əndə ikənder, belmədem.

Aşadьmn ectem denjavi dustlar ilə Xaq nigməten,
əh fi Alla oxravi ixvan ikənder, belmədem.
Xabe hurdən ləzzətendə gomreme qьjldьm tələf,
qyrdə juldaş - takat və iman ikənder, belmədem.
Xobbe denja ilə qalbem məel imeşter bi qeman,
denja səymək şirbəte şəjtan ikənder, belmədem.
Sejlə gizmeşem kə qyjə eşmeşem abe xəjət,
kelle nəfsin zaiqatul məvet ikənder, belmədem.
Hic keşe doşmanьna qььjlmaz çəfanь çanьma,
kənde nefsem uq qadər qьjlqan ikənder, belmədem.
Kyzlərem tuj-tamaşa, həzle-hezjan məçlesen,
bəna xaçət məçles - gьjrfan ikənder, belmədem.
Ber zaman əhle səqadət məçlesendə bulmadьm,
xəmre gaflətdən başьm seqran ikənder, belmədem.

Nitə tənbih itmədeŋez, i qarendəşlər, bəni
şomlьgьm başdan təmam aşqan ikənder, belmədem.
Ismem Alla hibəse uldisə nə xasьjl bənə,
nəfes qollьgьna çismem faş ikənder, belmədem.

## Kitap

Hic tə kyŋlem acьlmaslьq ecem poşsa,
yz yzemne kyrəlmicə ruxьm təşsə,
çəfa ciksəm, jedəp betsəm, bu başьmnь
qujalmьjca çanga çьlь hicber təşkə;
xəsrət soŋra, xəsrət kilep almaş, almaş
kyŋelsez uj beləm təmam əjlənsə baş,
kyzləremdə kibep tə çitməqən bulsa
xəzer qenə sьqьlьp-sьqьlьp jelaqan jəş,-
şul vaqьtta min qulьma Kitab alam,
anьŋ izge saxifələren aqtaram;
rəxətlənep kitə şunda çanьm, tənem,
şunnan qьna dərtlərem dərman tabam.
Uqьp barqan hərber julьm, hərber syzem
bula minem jul kyrssətyce joldьzьm;
sejmi başlьjm bu denjanьŋ vaqlьglarьn,
acьladьr, nurlanadьr kyŋlem, kyzem.
Çiŋellənəm, məgsumlanam min şul caqta,
rəxmət uqьjm uqьqanьm şul Kitapqa,
ьşanьcьm arta minem yz yzemə,
emid berlən qarьj başlьjm bulacaqqa.

1909

## РОССИЯ ХӨКҮМӘТЕ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ТАТАРСТАНДА

21 июньдә Чаллыга Россия Федерациясенең хөкүмәт делегациясе килде. Министрлар Советы Рәисе В. С. Черномырдин җитәкчелегендәге кунакларны Бигеш аэропортында Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев, Республика Югары Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин, Премьер-Министр М. Г. Сабиров һ. б. каршылады.

В. С. Черномырдин «КамАЗ» акционерлык җәмгыятенең күптән түгел генә яңгын булган дизель двигательләре заводы эшчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләре белән очрашты, интерклубта махсус киңәшмә үткәрде. Анда Россия һәм Татарстанның әлеге заводны торгызуга турыдан-туры мөнәсәбәте булган министрлык һәм ведомстволары, банклар, проект-төзү оешмалары катнашты. Киңәшмәдә Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев чыгыш ясады.

Россиянең хөкүмәт делегациясе, Татарстан Республикасы җитәкчеләре Алабуга автомобиль төзелеше мәйданында һәм җөмһүриятебезнең башка төбәкләрендә дә булдылар. Очрашулар соңында Татарстан-Россия арасында кайбер мәсьәләләр буенча хөкүмәтара килешүләргә кул куелды.

## ХАҖ КЫЛУЧЫЛАРНЫ КАБУЛ ИТҮ

Казан Кремлендә Җөмһүриятебез Илбашы Минтимер Шәймиев Мәккә һәм Мәдинәгә барып кайткан хаҗ кылучылар белән очрашты. Алар арасында Татарстан Республикасында мөселманнарның дини идарәсе рәисе мөфти Габдулла хәзрәт Галиулла, галимнәрдән Мирза Мәхмүтов, Тәлгат Галиуллин һ. б. бар иде.

Хаҗга барлыгы 167 кеше барды һәм алар унҗиде тәүлектән соң әйләнеп кайттылар. Очрашу барышында кунаклар үзләренең Согуд Гарәбстанында, изге җирләрдә алган тәэсирләре белән уртаклаштылар.

## ӘХМӘТ ЯСӘВИГӘ БАГЫШЛАНГАН ФӘННИ ФОРУМ

26-29 майда Төркиянең Кайсери шәһәрендә мөселман төрки халыкларның уртак шагыйре, суфичылык идеяләренә нигез салган Хуҗа Әхмәт Ясәвинең 900 еллыгына багышланган Халыкара симпозиум үткәрелде. Аңа дөньяның барлык төрки дәүләтләр һәм республикаларыннан галимнәр чакырылган иде. Бу фәнни форумда Татарстаннан академик М. З. Зәкиев Хуҗа Әхмәт Ясәвинең татар әдәбиятына йогынтысы, татарларда суфичылык идеясенең социаль һәм рухи нигезләре турында доклад ясады. Академик Әбрар Кәримуллинның докладлы исә Әхмәт Ясәви әсәрләренең Идел-Урал буенда таралуы, популярлыгы, шагыйрьнең «Диван хикмәт»енең Казанда басылу тарихы турында булды. Төрки халыкларда Ясәви әсәрләрен беренче булып татар нәширләре китап итеп чыгарган, аның «Диван хикмәт»е Казанда унга якын басма булып дөнья күргән. Төрки халыклар арасында бу әсәр 1917 елга хәтле бер тапкыр Ташкентта, бер-ике тапкыр Төркиядә генә басылган булып чыкты.

Бу форумда хәзерге көндә Анкара университетында татар теле буенча дәресләр бирүче профессор Фәрит Хәкимҗанов та катнашты. Аның докладлы «Әхмәт Ясәви вә Идел буе әдәби теле» дигән темага иде. Халыкара симпозиум, 1994 елны Хуҗа Әхмәт Ясәви елы дип игълан итүне сорап, ЮНЕСКОга мөрәҗәгать кабул итте.

## ИКЕ ИЛ ГАЛИМНӘРЕ ОЧРАШУЫ

Төркия Республикасы Фән һәм техника дәүләт комитеты (ТЮБИТАК) чакыруы буенча, 7-12 июнь көннәрендә Татарстан Фәннәр академиясе делегациясенең Төркиягә рәсми визиты булды. Делегация составында Җөмһүриятебезнең Фәннәр академиясе Президенты М. Х. Хәсәнов, академиянең баш гыйльми сәркатибе И. Б. Хәйбуллин, физика, энергетика һәм җир турындагы фәннәр бүлеге академик-сәркатибе Н. А. Сәхибуллин бар иде.

Визит вакытында ТЮБИТАК һәм Татарстан Фәннәр академиясе арасында фәнни хезмәттәшлек турындагы шартнамәгә кул куелды.

## ДУСЛЫК ЭЛЕМТӘЛӘРЕ НЫГЫЙ

Чит төбәкләрдә — күрше республикаларда, өлкәләрдә яшәүче кан кардәшләребез, милләттәшләребез белән үзара элемтәләр көннән-көн ныгый. Быел язын, мәсәлән, Татарстанда Удмуртия көннәре, Пермь өлкәсенең Барда районы көннәре шаулап-гөрләп узган иде. Июнь аенда исә безгә кунакка тугандаш Башкортстанның Яңавыл районы хезмәтчәннәре, сәнгатькәрләре килде. Алар Казанның Вахитов районы һәм Саба районында булдылар. Аннан алда гына татарстанлылар, аерым алганда, Саба районы вәкилләре, Яңавыл җирендә ямьле очрашулар үткәреп кайтканнар иде.

## «БОЛГАРИЯ-ТАТАРСТАН» ҖӘМГЫЯТЕ

Софиядә «Болгария-Татарстан» җәмгыяте төзелде. Оештыру җыелышында катнашкан сәяси эшлеклеләр, Болгария интелли-

генциясе вәкилләре, бизнесменнар: яңа оешма һәр ике илдә бара торган демократик үзгәртеп кору шартларында Болгария белән Татарстан арасында дуслык мөнәсәбәтләрен саклау һәм үстерүгә булышлык итәр, дип белдерделәр.

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ ГАЛИ АКЫШНЫ ХӨРМӘТЛИ

Татар милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, Бөтендөнья Татар Лигасының Президенты, Татар халкы Милли Мәҗлесенең почетлы депутаты Гали Акшның туууна 75 ел тулуга багышлап, ошбу елның 24 июнендә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында юбилей кичәсе үткәрелде. Татар халкы Милли Мәҗлесе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма Комитеты, Бөтентатар иҗтимагый Үзәге һәм «Ватан» җәмгыяте тарафыннан оештырылган әлеге истәлекле кичәдә Г. Акышның шәхсән катнашуы, аның гыйбрәтле тормышы вә эшчәнлегенә багышланган чыгышлар һәм татар сәнгать осталары концерты нур өстенә нур булды.

## ӘМИНӘ ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕ

«Моабит дәфтәрләре» белән дөньякүләм танылган каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең хатынына — Әминә Котдус кызына — 21 июньдә 80 яшь тулды. Шул уңайдан Казанда, М. Горький урамындагы 17 нче йортта — заманында шагыйрь үз гаиләсе белән яшәгән фатирда (хәзер биредә музей) Әминә ханымны туган көне белән котлау тантанасы булды. Танылган язучы-җәлилче, «Татарстан» журналының баш мөхәррире Рафаэль Мостафин, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, герой-шагыйрь исемендәге премия лауреаты Илдар Юзеев һәм башкалар юбиляр адресына кайнар тәбрик сүзләре әйттеләр һәм аңа Казанның атаклы «Мелита» мехсәүдә берләшмәсе оста куллары тарафыннан тегелгән затлы бүрек бүләк иттеләр.

## ГЕРМАНИЯДӘ — «САК-СОК» АВАЗЫ

Германиянең тавыш яздыру студиясе Чаллыдагы «Сак-Сок» фольк-рок группасы белән килешү төзеде. Хәзер ул беренче пластинкаларын яздыра. Татар җыры Германиядә генә түгел, тиздән башка илләрдә дә яңгырар, төрле кыйтгаларга сибелгән милләттәшләребезгә бер-берләре белән җыр ярдәмендә аралашып-аңлашып яшәргә ярдәм итәр.

## УФА-КАЗАН ДУСЛЫГЫ

Башкортстан хөкүмәте Уфада «Нур» татар дәүләт театрын ачу хакында карар кабул иткәч тә, аның җитәкчеләре Казан театр училищесына эшлекле тәкъдим белән килделәр. Аларны Татарстан һәм Башкортстан мәдәният министрлыклары да хуплады. Нәтиҗәдә, килешү төзелде: Казан театр училищесы «Нур» өчен актерлар әзерләячәк, ә Казан театрларында эшлисе актерлар Уфада бию һөнәренә, ягъни хореографиягә өйрәнәчәкләр.

* * *

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры җәй башында «Нур» татар дәүләт театры артистларын кабул итте. 21-30 июнь көннәрендә кунакларыбыз Казан тамашачыларына Т. Гыйззәтнең «Башмагым» музыкаль комедиясен, М. Фәйзинең «Адашкан күңел», Ф. Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш», Г. Каюмовның «Ач күзеңне, монда мин!» спектакльләрен күрсәттеләр. Һәр спектакль зур уңыш белән барды.

## ГАЛИМНЕҢ ЯҢА КИТАБЫ

Күренекле тарихчы-археолог Равил Фәхертдиновның «Татар угълы татармын» дигән яңа китабы дөнья күрде. Ул йөз мең данәдә Чаллыдагы «КамАЗ» газета-китап нәшриятында басылган. Китап Чаллы сәүдәгәрләре — бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповларның, шулай ук Илфат Гыйльмазовның матди булышлыгы белән чыгарылган. Аны халкыбызның үткән тарихына кагылышлы рәсемнәр белән бизәүдә рәссамнардан Рәис Шаһи, Фаил Исламов катнашкан, шунда ук бүгенге көнебезне сурәтләүче фоторәсемнәр дә урнаштырылган. Китап милләттәшләребезгә бушлай таратыла.

## ЧИСТАЙ — ФЛОРИДАГА

АКШның Флорида штаты Татарстанга заказ бирде. Чистайның «Шәрыкъ» фирмасы америкалылар өчен махсус эшләнгән сәгатьләр чыгара башлады. Алар диңгез һәм елга судноларының өчен әзерләнгән һәм дөньякүләм таләпләргә тулысынча җавап бирә.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте

# ЯҢА КИТАПЛАР

Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикә турында татар халкы бик күп риваятьләр, легендалар иҗат иткән. Хәзер, дәүләтебез үз мөстәкыйльлеген елдан-ел ныгыта барганда, милләтнең андый каһарман кызлары һәм уллары турында безнең тагын да күбрәк беләсебез килә. Язучы Батулланың 1992 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Сөембикә» дигән кыйссасы соңгы ханбикәбезнең тормышына һәм үлеменә бәйле риваять-вакыйгалардан тора. Каһарманнарның язмышы автор фантазиясе белән дә баетылган. Әсәрдә Казан ханлыгы төзелүдән алып Явыз Иван тарафыннан җимерелүгә кадәрге чор вакыйгалары тасвир ителә.







Башкортстанда 1 миллион ярым чамасы милләттәшләребез яшәве һәркемгә дә мәгълүм. Ә менә татардан чыккан язучылар кая барырга, нишләргә тиеш? Моңа кадәр Башкортстанда ни өчен татарча китаплар басылмады? Шундый сораулар әле һаман бик күпләрне борчый.

Соңгы вакытта күрше республикадагы милләттәшләребезнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү юнәлешендә күркәм адымнар ясала башлады. Уфадагы «Иҗат» нәшрияты тарафыннан бастырып чыгарылган «Сер» исемле китап — шуның бер мисалы. Аның авторы — Дилә Булгакова. Бирегә язучының кызыклы хикәяләре һәм нәсерләре тупланган.

Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге рес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 нче китап кибетибетбе почта» бүлеге.**

Бәясе 30 сум

Индекс 73210



УТЛАРЫ
UTLARI
ҠАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог